Татарстан Республикасы “Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе
"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе
"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Ямаширмә "Йолдыз" балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе

# “ИҢ МИЛЛИ ТӘРБИЯЧЕ”

***( ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ)***

Биектау, 2025

УДК 37.035.6

ББК 74.

Төзүче авторлар:

Яруллина М.Р. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе ярдәмчесе;

Габдрахманова Р.Г. - Татарстан Республикасы Биектау  муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе мәктәпкәчә белем бирү методисты;

Гыймадиева Л.М. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе мөдире;

Яруллина А.Р. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе өлкән тәрбиячесе;

Гыйләҗиева Э.Р. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе тәрбиячесе;

Сафиуллина Л.А. - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә “Йолдыз” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе музыка җитәкчесе;

Гарипова Л.Ф.- “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш “Умырзая” мәктәпкәчә бюджет белем бирү учреждениесе тәрбиячесе;

“Иң милли тәрбияче”: бәйгегә килгән эшләр белән тәҗрибә уртаклашу җыентыгы./төз.авт: Яруллина М.Р., Габдрахманова  Р.Г., Юнысова С.Ф., Гыймадиева Л.М., Фәтхриева Э.Ә., Яруллина А.Р., Гыйләҗиева Э.Р., Сафиуллина Л.А., Гарипова Л.Ф. - Биектау, 2025.- 606 б.

Рецензент : Төхфәтуллина Ә.Г. – филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы “Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте” дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Җыентыкка “Иң милли тәрбияче” Республикакүләм бәйгесенә килгән иң яхшы эшләр урын алды. Җыентык  татар телендә милли белем һәм тәрбия бирүче балалар бакчалары педагоглары, татар теле укытучылары, эти – әниләр  өчен ярдәмлек булып тора.

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә "Йолдыз" балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе коллективы
тарафыннан төзелгән ""*ИҢ МИЛЛИ ТӘРБИЯЧЕ*" җыентыгына

**БӘЯЛӘМӘ**

Радио һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына, тәрбиясенә тискәре йогынты ясаган хәзерге заманда, мәктәпкәчә белем бирү учрежденияләрендә халкыбыз хәзинәләре нигезендә милли үзаң тәрбияләү проблемасы аеруча актуальләште. "Иң милли тәрбияче" республикакүләм бәйгегә килгән иң яхшы эшләрдән тупланган җыентык әнә шул максатка юнәлтелүе белән игътибарга лаек. Хезмәттә туган телдә белем һәм тәрбия бирү балаларга ана телен өйрәтү бурычы халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф-гадәтләренә таянып алып бару аша хәл ителә. Җыентыкта урын алган бәйрәмнәр, кичәләр, йолалар, шөгыльләр, мастер-класслар, дидактик уеннар бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән рухи хәзинәләребезне саклап калу, онытыла башлаган гореф-гадәт, йолаларыбызның, иң матурларын сайлап алып, киләчәк буынга өйрәтүгә нигезләнгән. Хезмәтнең максаты - халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф-гадәтләренә таянып балаларга ана телен өйрәтү. Чаралар барысы да мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшь үзенчәлекләренә тулысынча җавап бирә.

Гомумән, балаларга халкыбызның гореф-гадәтләре, әдәби һәм мәдәни байлыгыбыз турында мәгълүмат бирү белән берррәттән, туган телдә сөйләшергә теләк уяту, аны хөрмәт итү; милли бәйрәмнәрнең тарихы белән таныштыру, аларда катнашу; халыклар, милләтләр арасындагы дуслык төшенчәсе кебек мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән әлеге җыентык мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә милли тәрбия бирү юнәлешендә эшләү өчен файдалы чыганак.

Төхфәтуллина Ә.Г. – Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, филология фәннәре кандидаты.

ГАПОУ «Арский педагогический колледж им. Г.Тукая»

**Кереш сүз**

Милли мәдәният ул - халыкның милли хәтере, бу халыкны башкалардан аерып торучы, кешене шәхессезлектән саклаучы, аңа заманнар һәм буыннар бәйләнешен тоярга, рухи ярдәм һәм тормыш терәге алырга мөмкинлек бирүче.

Балаларны халык мәдәниятенә тарту аларда патриотик хисләр формалаштыру һәм рухи үсеш чарасы булып тора.

"Хәтерсез гореф - гадәтләр юк, гореф - гадәтләрсез Мәдәният юк, мәдәниятсез - тәрбия юк, тәрбиясез - рухилык юк, рухилыксыз шәхес юк, шәхессез - тарихи шәхес буларак халык юк».

Без кызыклы һәм катлаулы чорда яшибез, күп нәрсәгә башкача карыйбыз. Күп нәрсәне яңадан ачабыз һәм артык бәялибез. Хәзерге җәмгыять милли үзаңның үсүе, үз халкының тарихын, мәдәниятен аңларга омтылуы белән характерлана. Балаларны тәрбияләүдә милли факторларны тирәнтен һәм фәнни нигезләү мәсьәләсе аеруча кискен тора, чөнки мәдәни мирасны саклау һәм торгызу үсеп килүче буынны тәрбияләүдә мөһим роль уйный.

Һәр заманда һәм барлык халыкларда тәрбиянең төп максаты булып халыкның яхшы гореф-гадәтләрен саклау, ныгыту һәм үстерү, үсеп килүче буыннарга рухи, шул исәптән педагогик, алдагы буыннар туплаган тәҗрибәне тапшыру торган. Халык педагогикасының, халык традицияләренең көче нәрсәдән гыйбарәт соң? Җавап гади: барыннан да элек шәхескә кешелекле, игелекле, гуманлы якын килүдә һәм аның тарафыннан тирә-юньдәгеләргә карата үзара кешелекле мөнәсәбәтне таләп итүдә. Нәкъ менә кеше күңелен «затландыру» максаты халык педагогикасында расланган да инде.

Балалар бакчасының төп бурычы - мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү, укыту һәм үстерү нигезенә рухи - әхлакый башлангычлар кертү, бу исә бөтен мәгариф системасын модернизацияләү шартларында мәктәпкәчә белем бирүнең эчтәлеген, формаларын һәм методларын яңартуга ярдәм итә.

Халык мәдәнияте - зирәклек һәм тәҗрибә хәзинәсе, милли горурлыгыбыз. Нәкъ менә шуның өчен, мәктәпкәчә яшьтә баланы туган җирне, туган табигатьне, үз халкын тоярга һәм яратырга, рухи байлыкны, халыкның акылын, талантын һәм зирәклеген кадерләргә өйрәтергә кирәк. Милли патриотлык, үз илең өчен горурлык хисе тәрбияләү балалар бакчасының төп юнәлешләре булып тора.

«Традиция» сүзе - тарихи формалашкан һәм буыннан-буынга тапшырыла торган гореф-гадәтләрне, тәртипләрне, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлата.

Традиция социаль мирас объектларын: матди һәм рухи кыйммәтләрне, социаль мирас процессын, аның ысулларын үз эченә ала. Традиция буларак билгеле бер иҗтимагый карашлар, үз-үзеңне тоту нормалары, кыйммәтләр, идеяләр, гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр һ.б. чыгыш ясый. буыннан-буынга тапшырыла торган халык традицияләре үзләрендә төрле тәрбия чаралары һәм формалары тудыра.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны этник мәдәнияткә һәм традицияләргә тарту чараларына халык иҗаты, декоратив-гамәли сәнгать, шул исәптән халык авыз иҗатының төрле жанрлары керә. Болар барысы да балалар бакчасында гамәлгә ашырыла һәм бирелгән җыентыкта милли гореф – гадәтләрне яңартып күрсәтелгән эшләр балалар бакчалары педагоглары, мәктәп укытучылары , эти – әниләр өчен тәкъдим ителә.

**Габрахманова Рамилә Гомәр кызы,**

Мәктәпкәчә белем бирү методисты.

**Гыймадиева Ләйлә Мансур кызы**,

Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы мөдире

# БӘЙРӘМНӘР
# КИЧӘЛӘР
# ЙОЛАЛАР



**“БАЛ БӘЙРӘМЕ- ТАТЛЫ БӘЙРӘМ!”**

***Шәвәлиева Гөлнара Мөбәрәкҗан кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*«Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 6 нчы*
*номерлы «Сандугач» балалар бакчасы»*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

| | |
|---|---|
| **Яшь үзенчәлекләре:** | Уртанчылар төркеме |
| **Тема:** | «Бал бәйрәме- татлы бәйрәм!» |
| **Эш төре:** | Милли күренеш |
| **Чарага кертелгән белем бирү өлкәләре:** | Танып-белү, әйләнә-тирә белән танышу, туган телдә сөйләм телен үстерү, нәфис-нәфәсәти үсеш |
| **Максат:** | Балаларны халкыбызның хөнәрчелеге, кәсебе һәм гореф-гадәтләре белән таныштыру. |
| **Бурычлар:** | - Татар халкына, теленә, хөнәрчелегенә, гореф-гадәтләренә, йола бәйрәмнәренә карата кызыксыну һәм хезмәт кешесенә хөрмәт, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.<br>- Балаларның акыл, логик фикерләү тизлеген, танып-белү активлыгын, игътибарлылыкларын, хезмәттәшлек, түземлелек, үз-үзеңә бәя бирү, максатка ирешүчәнлек сыйфатларны формалаштыру, туган телдә сөйләм телен һәм сүз байлыгын, хәтер, фикерләү сәләтләрен, артистлык осталыкларын үстерү.<br>- Табигать могҗизасы- бал, аның үзлеге, барлыкка килүе, төрләре, “бал аерту” турында күзаллау булдыру, белемнәрен баету. |
| **Методик алымнар:** | Әңгәмә<br>Күрсәтмәлек (предметлар һәм иллюстрацияләр куллану).<br>Сүзлек (сораулар, балаларның шәхси җаваплары, искәрмәләр).<br>Кызыксындыру, нәтиҗә. |
| **Җиһазлау:** | Өй эче күренеше белән банер, атрибутлар: сандык, мендәрләр, өстәл, урындыклар, самавар, кәсаләр, кашыклар, ипи, бал. Умарталык өчен атрибутлар: умарта оялары, кәрәз, демарлар, канатлар, битон һ.б. |

| | |
|---|---|
| | Кмемнәр: татар халык киемнәре һәм умартачыларның махсус киемнәре. |
| **Алдан үткәрелгән эш:** | Умарталык белән танышу, бал турында мәгълүмат туплау, матур әдәбият уку, иллюстрацияләр карау, балның барлыкка килүе, файдасы, әһәмияте турында әңгәмәләр үткәрү, биюләр, җырлар өйрәнү. |
| **Катнашалар:** | Әхмәт, Нәҗия, Закирҗан, Зәйнәп, Галия. Асия:<br>4 бал корты;<br>башкорт кызы, башкорт малае, марый кызы, марый малае; |

**Күренешнең барышы**

**1 нче эпизод**

*Өй эче. Бер гаиләдә үсүче балалар: Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан, Зәйнәп, Галия, Асия. Уйныйлар.*

**Әхмәт:** Әйдәгез, бергәләп “Без-без” уенын уйнап алабыз!

**Барысы бергә:** Әйдәгез!

Без-без, без идек,
Без 12 дус идек.
Базга төштек май ашадык,
Келәткә кердек бал ашадык.
Өйгә кердек чәй эчтек.
Таң атканчы юк булдык!
Авызыңны ач та йом!

*(авызларын куллары белән каплыйлар)*

**Әхмәт:** Галия авызын ачты!

**Зәйнәп:** Нишләтәбез?

**Нәҗип:** Сорауларга җавап бирсен!

**Әхмәт:** Галия, әйт әле! Келәткә кереп бал ашаганың бармы?

**Галия:** Бар! Умартачы кызы булып- бал ашамый тормам инде!

**Әхмәт:** Әйе шул, бабамның бабасыннан килгән, буыннан буынга күчкән шөгыль бит ул безнең нәселнең....Умартачылык!

**Зәйнәп:** Әйе шул, Әхмәт! Шуңа да өстәлебездә бал өзелгәне юк!

**Закирҗан:** Әти аерткан бал- бигрәк тәмле була!

**Асия:** Абый, бал ул нәлсә? Бал ул кайда үсә?

*Балалар елмая, көлешәләр.*

**Зәйнәп:** Асия әле кечкенә, аңа бары өч кенә!

**Закирҗан:** Бал ул үсми орлыктан!

**Нәҗип:** һәм ул чыкмый фабриктан!

**Зәйнәп:** Бал ашаган кешенең теле тәмле, матур сүзләргә бай була ди дәү әни.

**Галия:** Әле тагы, балны 70 төрле авырудан шифалы диләр...

**Нәҗип:** Ә сез беләсезме, тиздән бал бәйрәме булачак!

**Асия:** Бал бәйрәме?

**Әхмәт:** Әйе, бал бәйрәме! Бу бәйрәм бик татлы бәйрәм! Бал кортлары чәчәктән нектар җыюдан туктагач, умарталарны ачып бал алалар. Шуннан соң туганнар һәм дусларны дәшеп "Бал бәйрәме" уздыралар.

**Закирҗан:** Без дә күршеләрне, дусларыбызны чакырырбыз!

**Әхмәт:** Әйдәгез, умарталыкка барып карап, күзәтеп кайтык әле!(кереп китәләр)

**2 нче эпизод**

*Умарталык. Бал кортларының сары йортлары- умарталар тезелеп тора. Көй яңгырый, бал кортлары бию.*

**1 нче бал корты:**

Бал кортлары без дә без,
Әй очабыз тыз да быз.
Бал җыябыз кышлыкка,
Ашар өчен тансыкка.
Мин ерак басуда үскән **карабодайдан бал** җыйдым!
Анда тимер күп була,
Канны яхшырту өчен кулланыла!

**2 нче бал корты:**

Белмәгәннәр-белсеннәр:
Тырышып бал җыябыз!
Җәйнең урталарына
Тулы була оябыз.
Матдәләр алмашы бозылса- **көнбагыш балы** файдалы.Әнә теге яктагы көнбагыш басуыннан арып-талып кайттым!

**3 нче бал корты:**

Бик теләгән вакытта
Алып нәни кашыкка,
Салкын тигәндә генә,
Бик чирләгәндә генә,
Аз-азлап кабар өчен,

Тәм- дәва табар өчен.

**Юкә балы** белән дәвалану кирәк!

**4 нче бал корты:**

Чәчәк балы балларның

Туклыклы, шифалысын.

Йөрәк, кан, үпкә авыртса

Беләм ул булышасын!

**Чәчәк балы** иммунитетка да бик файдалы!

*(Музыка, бал кортлары залдан чыгып китәләр.)*

*3 малай: Нәҗип, Әхмәт, Закирҗан чыга, башларында махсус битлекләр, күкрәкләрендә алъяпкычлар, кулларында төтен йөгерткечләр.*

**Нәҗип:** Һәрбер чорның үз матурлыгы бар шул!

**Әхмәт:** Быелгы җәйнең һавасыннан ук бал исе килә!

**Закирҗан:** Җәй яхшы быел! Бал да күп булыыр!

**Нәҗип:** Бигрәк гаҗәп инде үзләре! Тырышалар бит!

Кечкенә генә бөҗәк,

Ояда яши гожләп.

Җәен оча без-безләп,

Чәчәкләрдән бал эзләп.

**Әхмәт:** (*Кулына кәрәз тоткан)*

Үзләре бигрәк уңган,

Шаккатам инде шуңа:

Кай арада кәрәзләре

Тәмле бал белән тула!

**Закирҗан:** (*Кулына бал кисмәг- бачонок тоткан)*

Бер корт ундүрт мәртәбә

Яланга оча икән.

Хуш исле гөлчәчәкләрне

Яратып коча икән.

**Нәҗип:** Хезмәте авыр булса да- балы татлы!

**Әхмәт:** Хәзер инде дусларны кунакка дәшсәк тә була!*(кереп китәләр)*

**3 нче эпизод**

*Өстәл, самавар, табында икмәк, касәләрдә бал.*

**Зәйнәп:** Чәй эчәбез бал белән

Бала-чагалар белән!

**Әхмәт:** Бала-чага алты җан,

Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан!

**Галия:** Зәйнәп белән Галия

Иң кечесе- Асия!

**Нәҗип:** Өстәлебез түгәрәк,

Ипиебез түрдәрәк.

Кунаклар да килерләр

Балдан авыз итәрләр!

*Башкорт музыкасы. Башкорт кызы һәм башкорт малае керә*

**Башкорт кызы:** Алып килдем сезгә, дуслар,

Күчтәнәчкә башкорт балы:

Чәчәк балы, юкә балы –

Безнең бал ул бик шифалы.

Гәрәбәдәй якты булсын,

Мәңге булсын дуслык балы! *(өстәлгә куя)*

*Марый музыкасы. Марый кызы һәм марый малае керә*

**Марый малае:**

Күчтәнәчкә баллы прәннек-

Кабул итеп алыгыз!

Бердәмлектә-татулыкта

Дуслар булып калабыз! *(өстәлгә куя)*

**Галия:**

Гәрәбәдәй сары бал-

Ашыйсың килсә, татып ал!

Тырыш кортлар хезмәтенең

Кадерләрен белеп кал!

***Җыр башкаралар***

1.Бал кортлары уңган кортлар

Шундый җитез, булганнар.

Көннәр буе очып йөреп

Татлы балны җыйганнар.

Куш. Кайсы җирең авыртса да

Кабып куй балны, дускай.

Җитмеш төрле чиргә дәва

Терелерсең тиз һәм җай!

2.Бал йөрәккә шифалы ул,
Көч-куәт бирә безгә.
Бал кортыдай тырыш булыйк,
Гөрләшеп яшик җирдә!

**Печән өсте бәйрәме**

**Мөхәммәтшина Диләрә Фоат кызы**
*"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче "Күбәләк" балалар бакчасы"- муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе"*

***Максат.*** Балаларда милли уеннар, җырлар, халык авыз иҗаты аша татар халкының милли традицияләренә, милли йолаларына ихтирам тәрбияләү; балаларның аралашу, иҗади сәләт күнекмәләрен үстерү; ана теленә мәхәббәт тәрбиләү.

Бәйрәм барышы.

Залда авыл күренеше. Өйләр, коймалар, өй алдында эш кораллары, тырма, сәнәк, чалгылар сөяп куелган.

Әкрен генә "Таң ату" көе яңгырый. Көй көчәя бара. Сыер, әтәч кычкырган, эт өргән тавышлар ишетелә.

*Өйдән бер кыз йөгереп чыга.*

- Әй, Ходаем әллә инде йоклап калганмын. Барысы да печәнгә киткәннәр ахрысы. Кызлар!

*Өйдән кызлар чыгалар.*

**2 кыз**. Ни булды, Зөһрә, нигә чакырдың?

**1 кыз**. Печәнгә соңга калабыз бит, кызлар!

**3 кыз**. Юк әле, юк, соңга калмаганбыз. Әнә, малайлар да куренмиләр әле.

**4 кыз.** Алар инде әллә кайчан киткәннәрдер. Менә хәзер бездән йокы капчыклары, дип көләчәкләр.

**2 кыз**. Юк инде, кызлар. Без иртә торганбыз. Әнә, малайлар яңа гына торып киләләр. Хәзер аларның узләреннән йокы капчыклары  дип көләчәкбез.

*Малайлар керәләр.*

- Саумысыз, кызлар!

**1 кыз**.Сау булмасак, табиб тугелсеңдер әле.

**1 малай**. Эх, шул кызларның телләренең зәһәрлеге! Иртүк ничек үртәшәселәре киләдер, белмим?

*Такмаклар.*

**Кызлар**. Ал ашыйсың киләме,
Гөл ашыйсың киләме,
Кызаргансың, бүртенгәнсең,
Талашасың киләме?

**Малайлар.** Кибәргә элгән керләрең
Җилгә очып китмәсен.
Авызыңны бик зур ачма,
Карга кереп китмәсен.

**Кызлар.** Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Ибырай.
Ата каз кыланышлары,
Биргәндер сиңа Ходай.

**Малайлар**. Зәйнәп балык пешергән,
Галия бәреп төшергән,
Саниясе җыя-җыя
Баш бармагын пешергән.

**Кызлар.** Әнә килә автомобиль
Төягәннәр калайлар,
Безнең авыл малайлары
Туксан яшьлек бабайлар.

*Малайлар үпкәләп борылып басалар.*

**2 кыз**. Менә, кызлар, малайларны үпкәләттек тә.

**3 кыз.** Ярар инде, малайлар. Үпкәләмәгез инде, без бит шаярдык кына.

*Кызлар хор белән.*Яле, елмаегыз!

*Шаян бию “Елмай”*

**2 малай**. Ярар үпкәләшеп торырга вакыт юк. Кызлар, әйдәгез тизрәк, кузгалдык.

*Җыр “Күңелле сәяхәт” А.Минһаҗев сүзләре, Ә.Һадиева музыкасы*

*Урман шаулаган, кошлар сайраган тавышлар.*

**5кыз**. Нинди күңелле, нинди матур илебезнең табигате!

**2 малай**. Матур илем! Синең болыннарың,

Борылып аккан Идел суларың,

Җиләк урыны – яшел аланнарың,

Киң күкрәкле Урал тауларың.

**3 кыз**. Син матурсың, миңа бик якынсың,

Туганнан,  юк,  үги түгелсең.

Көз, кыш, җәй һәм язың,

Мәңге бакча, былбыл һәм гөлсең.

*Җыр  “Гүзәл туган ягыбыз” А.Минһаҗев сүзләре, Ә.Һадиева музыкасы*

**3 малай**. Эх, урман аланның матурлыгы.Ул тәмле исләр, карагыз әле,

печән нинди биек үскән.

**4 малай.**Тиз, тиз, тизерәк!

Илебез матур бигерәк!

Сандугачым сайра,

Чалгыларың кайра!

Җәйге таңда чык төшкәндә,

Җырлап калыйк, әйдә.

**5 малай**. Чалгыларны үткенләтеп,

Печән чабыйк җир тетрәтеп.

*Җыр “Җәй айлары” Зөлфия Минхаҗева сүзләре һәм музыкасы*

*(Печән чабу хәрәкәтләре, чалгы янау)*

**6 малай**. Чабып бетерүен  бетердек, яңгыр яумасмы икән?

**1 малай.** Юк, юк, яумас. Бүген иртән чык күп төшкән иде, көне бик эссе була, печән бик тиз кибәр.

**1 кыз**. Әйе, әйе. Бүген көн аяз була. Мин кичә карадым, кояш аязга баеды.

**2 малай**. Ә безнең иртән мәче табанын ялады. Әби әйткән иде, әгәр дә мәче табанын яласа, көн аяз була, дигән иде.

**2 кыз**. Әнә бит бака да су эчендә кычкыра – димәк көн аяз була.

**3 малай**. Ә мин тилгән кычкырганны ишеттем. Тилгән кычкырса да, көн аяз була.

**3 кыз**. Карагыз әле, кояшны томан каплаган, шулай булгач, көн аяз була

**4 малай**. Алайса хәзер печән кипкәнче ял итеп алабыз.

*“Утыр, утыр, Хәлимә” җырлы-биюле уен.*

*(Җәзалар җыр “Яшә син, туган илем!” Татар халык җыры,  шигырь “Туган телем” Энҗе Мөэминова.)*

**5 малай.** Дуслар, карагыз әле, Хәсән килә. Әйдәгез, кызык итәбез үзен.

Хәсән, ни эшләп йөрисең?

**Хәсән.** Сыерыбыз югалды

Көтүдән кайтмый калды.

Эзли-эзли арып беттем,

Урманга ук килеп җиттем.

**Малай**. Сыерыгыз югалдымы?

Көтүдән кайтмый калдымы?

**Хәсән**. Әйе, Әхсән, күрмәдеңме,

Бу тирәдә йөрмәдеме?

**Малай**. Сыерыгыз аламы?

**Хәсән**. Ала, Әхсән, ала!

**Малай**. Койрык очы карамы?

**Хәсән.** Кара, Әхсән, кара!

**Малай**. Дугадай зур мөгезлеме,

Шайтан кебек мут күзлеме?

**Хәсән**. Нәкъ шул үзе, Әхсән!

**Малай**. Күрмәдем шул, Хәсән!

**Кыз**. Туктагыз әле, туктагыз! Әле кичә генә Хәсәннең бабасы сыерга печән салырга чыккач, печәнлектән егылып төшкән дип ишеттем. Хәсән, дөресме шул сүз.

**Хәсән**. Дөрес, дөрес. Бабай ахылдап өйгә керде дә “Хәсән балам, абзар башыннан егылып төштем, уттан күзләр күренде, син бар, печәнгә сыерны сала тор, печән сөтләсен”-диде.

**Кыз**. Һи, шулда булдымы хәбәр! Менә мин кичә бер тешемне суырттым.

**Малай**. Хәзер авыртмыймы соң?

**Кыз**. Белми?

**Малай**. Ничек инде белмисең?

**Кыз.** Соң авырткан теш врачта калды бит.

**Малай**. Ә миңа табиб кишер күп ашасаң, күзләрең әйбәт күрер, диде.

**Кыз**. Бу дөресме?

**Малай**. Әлбәттә! Күзлек киеп йөргән куянны күргәнең юктыр бит?

**Хәсән**. И-и, тел бистәләре! Сезнең белән вакыт уздырып торам бит әле. Минем бит сыерымны табасым бар, киттем мин!

**Хор**. Хәсән, Хәсән!

Сабан туе кайчан була?

**Хәсән**. Сабан туе иртәгә

**Хор**. Мен дә утыр киртәгә.

**Хәсән**. Киртә башы җимерелгән

**Хор**. Хәсән башы тишелгән.

**Хәсән**. Уф. Бетте башым!

**Хор**. Нишләде башың?

**Хәсән**. Тишелде.

**Хор**. Кайсы җире?

**Хәсән.** Төбе тишелгән.

**Хор**. Кайсы төбе?

**Хәсән**. Башның төбе кайсы җирдә, шул җире тишелгән

*Көләләр.*

**1кыз**. Хәсән, сөйлә бер кызык.

**2кыз**. Юк, җырласын!

**1малай**. Юк, биесен!

**Хәсән**. Җырламыйм да, биемим дә.

**Кыз**. Нигә?

**Хәсән.** Әйдәгез, бергәләп уйныйбыз.

*"Менә сиңа куш кулым" – җырлы-биюле уен.*

**Кыз**. Я, сөйлә инде, ялындырма.

**Хәсән.** Кулъяулык бирегез, аннан соң сөйлим.

**Кыз.** Алай булгач кулъяулык бирәбез.

**Хәсән.** Юк инде, юк инде,

Вәгъдәгез белән тук инде.

Чиккән яулык бирмәсәгез,

Хәсәндә сүз юк инде.

**Кыз**. Мә инде. (Яулык бирә)

**Хәсән**. Арагызда дан тоткан,

Кызлардан яулык откан.

Хәсән абзагыз тора

Һәммәгездән уздыра.

*Яулык белән борынын сөртә дә, кесәсенә салып куя.*

**Хәсән.** Юк сөйләмим, мин сезне кызык кына иттем.

**Кыз**. Алайса мин бер нәрсә сөйлим,

Син һәр сүзгә "Мин дә!" -дип бар.

**Хәсән**. Мин риза.

**Кыз**.- Бардымурманга

-Мин дә!

-Җыйдым чикләвек.

-Мин дә!

-Салдым улакка.

-Мин дә!

-Дуңгызлар ашый калды.

-Мин дә!

*Көләләр.*

**Кыз**. Кызык иттемме үзеңне?

**2 кыз**. Ярар инде, Хәсәнне аптыратмагыз.Әйдәгез,  тагын бер уен уйнап алабыз.

**Хор**. Әйдәгез, әйдәгез!

**Малай**. Машина, дип әйт әле.

- Машина.
- Менә синең башыңа
- Кабартма диген.
- Кабартма.
- Бәбәгеңне алартма.
- Пәрәмәч диген
- Пәрәмәч.
- Ике күзең тәгәрмәч.
- Әтиең кайда эшли?
- Комбайнда
- Мә, берне маңгаеңа *(маңгаена суга).*
- Нигә сугасың?
- Үзең сук, дидең бит!

**Кыз**.  Ярар, сугышмагыз, җитте. Хәзер мин сезгә бер әкият сөйлим. Кара урманда бер убырлы карчык яшәгән, ди. Ул һәр елны урманга килгән. Бер баланы алып китеп сихерли икән.

**2 кыз**. Юк, сөйләмә, мин куркам. Я убырлы карчык үзе килеп чыгар.

**3 кыз**. Әнә, әнә, килеп чыкты да инде.

*Музыка. Убырлы карчык керә.*

**Убырлы**. Фу! Фу! Адәм исе килә түгелме соң? (*Исни*). Шулай шул, адәм исе *(бии, әйләнә).* Ә-ә-ә, күпме бала килгән икән монда. Тукта әле, тукта әле, күптән балалар урлаганым юк иде. Әһә, боларның барысын да сихерләп йоклатам да, берсен урлап китәм.

*Убырлы балаларны сихерләп бии. Балалар утырып йокыга китәләр.*

**Убырлы**. Әһә, барысы да йоклыйлар. Әгәр дә уянып бу малайны коткарырга килсәләр, мин аларның өсләренә утларымны җибәрәм. *(Малайны алып китә)*

*Музыка астында балалар уяналар.*

**1 кыз.** Дуслар, убырлы карчык Йосыфны алып киткән бит. Ничек тә булса аны коткарырга кирәк.

*Урманга таба баралар. Аннан утлар килеп чыга.*

*Утлар бию.*

**Балалар.** Ут, ут, пешерә! *(чигенәләр)*

*Утлар бию убырлыны үзләре белән алып китәләр.*

*Музыка. Йосыф йоклый.*

**2 кыз**. Дуслар, ә мин убырлы карчыкның сихерен ничек бетерергә икәнен беләм. Хәзер мин әфсен укыйм да, без кошларга әвереләбез. Аннан канатларыбыз белән җилпенеп сихерне куабыз.

Әфсен, төфсен,
Җилләр иссен,
Кызлар кошлар булып китсен.

*Кошлар бию.*

**3 кыз**. Кызлар, кызлар, карагыз әле. Әнә Йосыф яңадан безнең арада. Убырлының сихере бетте.

**1 малай**. Карагыз әле, без ял иткән арада печән дә кипкән. Әйдәгез, җыеп алыйк инде.

*Бию "Печән җыю"*

**4 кыз**. Печән җыеп бетергән шатлыктан бер җырлап алсак та була.

*Җыр "Печән өсте" Балалар җырлый-җырлый кереп китәләр.*

## Йомырка җыю бәйрәме – керәшен һәм татар авыллары дуслыгы

***Шәфигуллина Әлфия Миннәхмәт кызы***

*Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*«Түбән Сон балалар бакчасы»*

**Максат:** керәшен халкы бәйрәмнәренә, татар халкының йомырка җыю бәйрәмнәренә карата кызыксыну уяту, әби-бабайлардан калган моңнарны, йолаларны, гореф-гадәтләрне ике авыл арасындагы дуслык бәйрәмендә яңарту.

**Җиһазлау:** сәхнәдә авыл өе күренешен күрсәтү, төрле төсләргә буялган йомыркалардан күргәзмә, киндер тукымадан тегелгән күлмәк, сүрәкә, «Керәшенем - асыл бизәгем» дип исемләнгән кул эшләре күргәзмәсе, пөхтә генә ашъяулык ябылган өстәл, самавыр, кызартылган йомыркалар, эскәмия, проектор, экранда алдан төшерелгән бәйрәм күренешләре.

**Әзерлек эше**: балаларга алдан шигырьләр бирелә.

**Бәйрәм барышы:**

Сәхнәдә Әни кеше йомырка кызартып йөри(үзалдына сөйләнә), балалары янында йөри. Аның янына Галя кызы белән керә.

**Галя:** арулармы күршекәем! Иртәгә олуг бәйрәмебез, ничегрәк әзерләнәсең икән, шуны белешергә дип кердем әле. Мин бит яңа килен кеше бу авылда бик рәтен дә белеп бетермим.

**Люда**: курыкма күршекәем, яши-яши барсына да төшенерсең.

**Галя**: Печкәчәм, сөйлә әле әлеге бәйрәм турында, мин бик төгәл итеп белеп бетермим.

**Люда:** балалар, сез дә тыңлап торыгыз әле. 7 гыйнварда Рождество (авыз ачу) көнне Иисус Христос туганнан соң, 19 январьда чумылдырыла һәм 33 яшендә, явыз җаннар тарафыннан тотылып, тере көенчә Качка кадаклана. Шуннан соң бар дөньяны гаҗәпкә калдырып, ул яңадан терелеп, аякка баса һәм бу көн – Олы көн дип атала.Пасха бәйрәме язгы көн-төн тигезләнүгә, һавадагы айның торышына карап, һәр елны төрлечә – 4 апрельдән 8 май араларындагы атна көнгә туры килә. Христиан дөньясында Христос терелеп тору көне бик зурлап уздырыла. Православие дине өйрәтүләре буенча, Иисус үз ирке белән үзенә газап һәм җәфалы үлем алып, шуның белән кешеләрнең җазыкларын үзе җолып ала. Олы көнгә каршы төн бөтенләй үзгә, серле, язгы төннәрнең берсе. Ул төнне берәү дә йокламаска тиеш, чөнки бу төнне бәхет өләшәләр, ә йокласаң, өлешсез каласың. Бәйрәмгә кадәр олылар 7 атна ураза тота. Элек ураза тотудан бала-чага да читтә калмаган. Ураза тотучылар үсемлекләрдән әзерләнгән ризыклар белән генә тукланырга тиешле. Гайбәт сөйләү, җазыклы эшләр башкару тыела. Пасхага хәтле өч атна элек өй юыла, йорт тирәләре тазартыла. Олы көнгә каршы кичтә, мунча кереп чыккач, күпләп йомырка манnetwork. Хуҗа хатыннар иртәнгә кадәр тәм-том өлгертә, күмәч, пилмән, шишара пешерә. Изгеләр китабында бәйрәм көнне менә мондый сүзләр әйтергә кушылган: «Бүген Христос терелеп торган көнне, бәйрәм итеп җактырылышыйк та, әй туганнар диешеп, бер-беребезне кочаклыйк. Барын да кичерик, аннары болай әйтик:«Христос үлгәннән терелеп торган, үлгән кешеләргә дә тереклек биргән».

**Валерия:** нәнәй, ә ни өчен йомырканы кызарталар?

**Әни:** Иисус Христос җәзалап үтерелгәннән соң кызыл төсне Пасха төсе итеп кабул иткәннәр. Шуннан соң йомыркаларны да кызыл төскә мана башлаганнар.

**Галя:** рәхмәт сиңа күршекәем, мин дә чыгып йомыркаларны кызартып бетерим әле. Әйдә кызым.

**Урам күренеше**

**Балалар йорттан-йортка кереп йомырка җыеп йөриләр. Балалар сөйләшә:**
**Валерия:** әйдәгез, Люда түтиләргә керәбез. Аларның йомыркалары матур була.

**София.**

Чиби-чиби чип тавык,

Куначага мен тавык.

Куначага менәлмәсәң,

Чебешеңне җый тавык.

Люда түти, үдәмесең,

Бер җомырка бирәмесең?
**Люда түти :** әйдәгез, балалар, керегез, әйдәгез. Менә монда мендәргә утырып башта черләгез әле, аннары йомырка бирермен **(1 бала мендәргә утырып черли).** Аяк-кулларыгыз җиңел булсын, җыл буе яхшылыклар гына булсын.
**Зәмирә.** Бу урамга кадәр килгәч, Үринә түтиләргә дә кереп чыгыйк инде. **(Керәләр)**
**Үринә түти:** Христос чынлап терелеп торган. И-и балалар, сез озак йоклагансыз инде, безгә беренче булып керә алмадыгыз. Ярар, зыян юк, йомыркам күп әле, Алла боерса, бар балаларга да җитә.
(Йомыркага кереп китә дә, озак кына чыкмый тора).

**Зәмирә.**

Үринә түти,

Җәтрәк бир йомырка.

Безгә бирсәң бер йомырка,

Тавыгың салыр җөз йомырка.

**Ирина түти**. Менә, менә, балалар. (Төрле төскә буялган йомырка тутырган кәрзин күтәреп чыга һәм балаларга өләшә).

**Балалар.** Рәхмәт, Ирина түти.

**Валерия:** Чип-чип, чибарук,

Йомыркасы югарук.

Ак тавык, күк тавык,

Ходай бирсен күп тавык.

**София: әйдәгез тизрәк йомырка җыйыйк та, аннан күрше авылга – Түбән Сонга дусларыбыз белән уенга төшәрбез.**

**(Балалар чыгып китәләр, пәрдә ябыла).**

**Татар авылы күренеше**

**Өй күренеше.** Әни кеше ике улы белән йомыркалар кызарта.

**Сәйдәш:** иң матур йомыркалар бездә булачак әнием!

**Әни**: әйе улларым!

**Самат**: әнием сез кечкенә вакытта да шулай буйыйлар идеме?

**Әни:** әйе улларым, мин дә сезнең кебек вакытта әнием янында шулай булышып йөри идем. Без кечкенә вакытта йомыркаларны суган кабыгы эремәсе ярдәмендә генә буйыйлар иде. Суга суган кабыгы, әзрәк тоз салып, бераз кайнатып алып, суына төшкәч йомыркаларны шунда салып пешкәнче тоталар иде. Менә мин дә шулай итеп буядым. Ә менә сезнең белән ясалма буяулар ярдәмендә дә буярбыз балалар.

**Сәйдәш:** күп җыя идегезме сез дә?

**Әни:** әйе балам, бөтен авылны йөреп чыга идек. Йөреп бетергәннән соң бәләкәчләр үзара көч сынашып, күпме йомырка җыйганнарын санап, мактанышып та алалар иде. Хәзер инде кайбер кешеләр чупа-чупс, шоколад, печенье, вафли, сагыз, кәнфит кебек тәм-томнар да өләшә. Йомырканы исә күбрәк туган-тумачаларга, күршеләргә, якын кешеләргә генә бирәләр. Йомырка җыю белән генә бәйрәм тәмамланмый! Һәр өйдән этиләр - абыйлар җыелышып, зират чистартырга бара. Аннары кичкә урамда зур тамаша башлана. Җыр-биюләрдән соң халык бергәләшеп елга буена кичке уенга төшеп китә иде. Балалар, йокларга ятыгыз, иртәгә иртүк торасыгыз була.

**Әтәч тавышы ишетелә, татарча көй яңгырый.**

**Энҗе әни:** хәерле иртә, балакайларым! Тордыгызмы? Бүген бит йомырка җыю бәйрәме!

**Кызлар:** әйе әнием, тордык!

**Энҗе әни:** әнә күрше малайлары кәрҗин тотып йомырка җыярга чыгып киттеләр инде. Соңга калмагыз сез дә!

**Зифа:**

Шатлыклар - күңелебездә,

Зур кояш - күгебездә!

Килегез, дуслар, кунакка -

Бәйрәм бит бүген бездә!

**Әминә:** әнием, йомырка җыю бәйрәме каян килеп чыккан?Аны кем уйлап тапкан?

**Энҗе Әни**: бу йола якындагы керәшен авылларында уза торган Пасха бәйрәменнән килеп чыккан дип сөйлиләр. Ләкин татар авылларында ул йомырка алыштырудан башланган. Әби-бабаларыбыз күршеләр белән йомырка алмашып, тавык астына салып куя торган булганнар. Алар уйлавынча, шулай эшләгәндә, чебешләр яхшы үрчегән. Бу күренеш йолага кереп киткән. Керәшеннәрдә дә, татар халкында да йомыркалы уенар авыл хуҗалыгы эшләренә

бәйле. Йомырка ул – туып килүче яңа тормыш, тереклек символы һәм ул үлән-үсемлекләрнең гайрәтен арттырырга тиеш дип санаганнар. Элек йомырка уеннарын яшьләр уйнаган, әкренләп ул балалар уенынна әйләнгән.

Төркем-төркем 3-12 яшьлек бәләкәчләр, кулларына аллы-гөлле матур кәрҗиннәр тотып, йорттан йортка кереп, йомырка җыеп йөри. Алдан кергән кешенең аяк ялын да сынаганнар. Бу үзенчәлекле борынгы традиция буенча алар үзләренең туганнары һәм якын кешеләре белән очрашканнар, сөйләшкәннәр, аралашканнар. Өлкәннәр дә балаларны игътибар белән күзәткән: исәнләшә беләме, кыюмы, тапкырмы, оялчанмы – гомумән, баланың үз-үзен тотышына бәя биргәннәр. Ә балалар өлкәннәрнең ачыклыгын, кунакчыллыгын, юмартлыгын сынаган. Һәр йортта балаларны ачык йөз белән каршы алганнар. Без дә шулай йомырка җыеп йөри идек. (чыгып китәләр)

**Урам күренеше. Зифа белән Әминә кәрҗин тотып чыга.**

**Әминә:** Безнең якта бәйрәм бүген,

Бездә бүген тантана!

Өйдән-өйгә йөреп әнә

Йомырка җыя һәр бала.

**Сәйдәш, Самат йөгереп чыгалар.**

**Сәйдәш:** кызлар, сәлам,әйдәгез бергә йомырка җыябыз!

**Кызлар:** әйдәгез!

**Татарча көй куела**

**Зифа:** исәнмесез, саумысез?

Хуҗалар өйдәме?

Бер йомырка бирәме?

**Ләйсән әни:** исәнмесез, балалар!

Аягың җиңел булсын, тавык чебеш куп булсын. Тик мин сезгә йомырканы җырласагыз гына бирәм! Я, кайсыгыз булдыра?

**Самат:** Зифаны җырлатабыз! Ул матур җырлый

(Зифа җыр) « Шаян Песи »

**Сәйдәш:** әйдәгез, Энҗе апаларга керәбез

Исәнмесез, саумысез,

Кәҗәгезне саумыйсыз.

Әтәчегез күкәй салган,

Нигә чыгып алмыйсыз?

**Энҗе Әни:** ай наяннар, килеп җиттегезме балакайлар?

Уйныйк әле, уйныйк әле,

Сынатыштан булмасын.

Сезнең арада берәү дә

Авыз йомып тормасын.

Бик тиз җавап бирсәгез,

Йомырка бирермен сезгә.

Яшел чирәм өстендә корт- корт кортлар.

Канатларын җәеп балаларын туплар.

Балалар: (**Тавык**)

**Энҗе Әни:** бигрәк зирәкләр икән сез, балалар! Төкле аякларыгыз белән. Елларыбыз тыныч, имин, мул булсын! Сәйдәш, Самат, мин өйрәткән борынгы теләкләрне онытмадыгызмы?!

**Сәйдәш**: мә-ә,мә-ә, куйларыгыз күп булсын,

Му-у, му-у, сыерыгыз сөт бирсен, бозавыгыз булсын.

Кыйтак-кыйтак, тавыкларыгыз йомырка салсын, чебиләр чыгарсын.

Га-га-га, казларыгыз күп булсын, ястык-түшәк җыегыз.

Аягым җиңел булсын.

Пр-р, пр-р умарталарыгыз бал бирсен,

Мине чәй эчәргә чакырыгыз.

**Самат:**Абыстай каба төбендә йон эрләсен,

Миңа ыштан тексен.

Абзый чабата тукысын, миңа да бер кием бирсен.

Балаларыгыз күп булсын.

Минем кебек йомырка җыеп йөресен.

Хуш, сау булыгыз!

**Балалар:** сау булыгыз! Рәхмәт сезгә!

**Зифа:** әйдәгез, яңа урамга киттек! Колышчыдан керәшен дусларыбыз да төшеп җитәр.

**Балалар:** әйдәгез!

**Кичке уенга барысы бергә җыелышып төшәләр.**

Керәшен карендәшләргә **Түбән Сонлылар**: арулармысез, карендәшләр!

Керәшен дусларыбыз **Колышчылылар**: арулар без! Үзегез ни хәлләрдә яшәп ятасыз?

**Түбән Сонлылар**: Аллаһка шөкер!

**Энҗе**: Олы көн Пасха бәйрәмегез белән котлыйбыз сезне!

**Люда:** рәхмәт якын күршеләребез! Әйдәгез җыелышкач борынгыча бәйрәм итик. Бергәләп уеннар уйныйк, җырлар җырлыйк.

**Ләйсән:** әйдәгез, якын күршеләребез, балалар белән «Кулъяулыгым» уенын уйныйбыз!

**Әлфия:** матур кулъяулык кемдә бар соң дусларым?

**Зифа:** миндә бар матур кулъяулык!

«Кулъяулыгым» уенына җәзалар:

1)Валериягә «Тигәнәкле су буе» шигыре

2) Сәйдәшкә (бию)

3) Софиягә («Бас әле ыстанукка» җыры 3 кыз бергә)

« Йомырка йөртешле » уены.

Җәзалар

1) Саматка (әтәч булып кычкыру)

2) Әминә шигырь сөйли (гаилә турында)

3) Люда (Керәшен халык җыры)

**Әни кеше:** борынгыдан килгән йолаларыбыз, бәйрәмнәребез – кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Ул бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Яшь буын бәйрәмдә катнашу тәртибен кечкенәдән үк өйрәнеп үссә, милләтебез, гореф-гадәтләребез югалмас.

**Икенче Әни:** һәр кеше, табигый рәвештә, үз-үзен тоту гадәтләрен үзләштерә, милли тәрбия ала. Ике күрше авыл – Түбән Сон һәм Колышчы авыллары арасындагы күркәм бәйрәмебез гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга, әби-бабайдан әти-әнигә, әти-әнидән балага гореф-гадәтләрне, йолаларны югалтмыйча тапшырып килгән, һәм алар, күпмедер дәрәҗәдә үзгәреп, безнең көннәргә дә килеп җиткән. Онытылмасын бәйрәмнәребез, онытылмасын йолаларыбыз, югалмасын тату кавемебез!

## “Сандык җилләтү” йоласы

***Гарифуллина Рәмзия Хәйдәр кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 10 нчы балалар бакчасы" муниципаль бюджет*
*мәктәпкәчә белем учреждениесе*

*Залга бер-бератлы тезелеп тәрбияче һәм алты бала керә.Тәрбиче балаларны үз янына җыя.*

**Тәрбияче.** Я, балалар, барыгыз да биредәме. Әйдәгез, без сезнең белән  авыл буйлап йөреп кайтабыз. Матур бизәкле капкаларны күреп, ачык йөзле авыл әби- бабайлары белән дә аралашып кайтырбыз.

**Балалар.** Әйдәгез, әйдәгез*( чыгып китәләр).*

*Татар авылы ишегалды күренеше. Йорт күренеп тора. Пөхтә генә урынга уртага сандык куелган. Өйдән әби чыга.*

**Әби**.  Эшләремне төгәлләдем, я бер утырып ял итим, хәл алыйм әле. *( сандыкка барып утыра, дога кыла)* Иии авыл кешесенең эше бетә димени аның, тавык-чебешен ашат, сыерын көтүгә ку, сепаратын аерт, ишегалдын себер... Менә шулай утырып ял иткән дә юк. Көне бигрәк матур бүген, үзе кыздыра, үзе җиләс. Мондый көнне юкка үткәрмик дип бабаем белән сандыгымны җилләтергә алып чыккан идек. Элек-электән матур җәй көннәрендә сандык җилләтү безнең бик мөһим эшебез иде *( сандыгын сыпыра).* Ай, сандыккаем, сиңа утырып бер дә дөрес эшләмәдем бит әле мин. Үзем белән бергә картайган, минем белән яшәгән сандыгым бит сииин! Үзең шкаф та, үзең караваат та булдың бит син. Хәзерге яшьләр моны белми, аңламый... Закир картыма кияүгә чыкканда әнием белән шуңа бирнәләр тутырган идек, кызыл башлы сөлгеләр, ефәк шәлләр, күн читекләр...

*Шулчак бер төркем балалар, тәрбияче үтеп бара.Алар әбигә эндәшәләр.*

**Тәрбияче.** Исәнмесез, Сания апа. Хәлләрегез ничек?

**Әби.** Исәнмесез, балалар.Исәнме, кызым. Хәлләр әйбәт, Аллаһка шөкер.

**Тәрбияче.** Менә капкаң ачык икән, сине күрдек тә кереп чыгырга булдык Сания апа.

**1 бала**. Сания апа, син нишлисең?

**Әби.(***шаяртып)* Менә сезне көтеп утырам*( көләләр).*

**2 бала.** Сания апа, ә бу нинди тартма?

**Әби.**Тартма түгел ул, балалар, сандык, кияүгә чыккан сандыгым.

**3 бала.** Ә анда нәрсәләр бар соң?

**Әби.** Әйдәгез, балалар, минем янга килеп чыгуыгыз бик яхшы булды әле. Бу сандыгымны өйдән җилләтергә дип алып чыктым. Җәй көне безнең әниләр дә, без үзебез дә сандык

җиллэтә идек. Сандык эчендәге әйберләрне читәннәргә, коймаларга элеп, җилләтеп, киптереп аласың икән, андагы әйбеләр күпереп, хуш исләнеп китә.

**Тәрбияче.** Әйе, минем әбием әйтә иде. “Сандыкны теләсә нинди көндә җилләтеп булмый, аның көнен үзең сизәсең. Урамдагы һава торышына карап”- дип әйтә торган иде.

**Әби.** Кайберләрегезнең мондый сандыкны күргәне юктыр да әле. Ә анданиләр бар икәнен белергә сезгә бик вакыт, балалар.Әйдәгез, сез миңа булышырсыз, бергәләп ачып җилләтик әле. Ә сандык эчендә иң кадерле, затлы әйберләр генә саклана*( сандыкны ача, чигелгән сөлгеләрне ала)*.

**4 бала.** Бу бит кызыл башлы сөлге. Күрегез ничек матур!

**5 бала**. Ә монысы бизәкле!Ничек оста чиккәннәр!

**Әби.** Беләсез икән бит , балалар. Чиккән сөлге ул безнең халкыбызның әләме кебек символ. Яңа туган баланы да ак сөлгегә салганнар, Сабантуйларда колга башында чигүле сөлге җилфердәгән, икмәкне дә мичтән алгач, сөлгегә төреп куйганнар*(әби сөлгеләрне балаларга күрсәтә)*

**6 бала.** Атларны да бәйрәмнәргә сөлге белән бизиләр.

**1 бала.** Кунакларны да сөлгегә куелган ипи-тоз белән каршы алалар.

**Тәрбияче.** Балалар, сөлгеләрне тотып бии беләләр, әбекәй. Кызлар, әллә биисезме?

**Балалар**. Биибез.

*“Сөлге” биюе. Әби балаларны мактый.*

*Биеп бетергәч, әби балалар белән сөлгеләрне җилләргә коймага эләләр.*

**2 бала.** Әбекәй, бу сандык сиңа каян килде?

**Әби.** Кияүгә чыккан сандыгым. Күрше бабай ясап биргән иде. Элек бит һәр кыз кияүгә чыгарга дип шунда үзенә бирнә тутыра иде. Кияү егетенә аны бушка бирмиләр иде. Кияүнең булачак кайнэнекәше шунда менеп утырыр иде дә:

“Ишек бавы бер алтын,

Безнең апай мең алтын;

Җылыныйм дисәң, бер алтын

Бир, җизни, тыш бик салкын" дип кычкырыр иде. *(көләләр)*

**3 бала.** Мин дә әйтим әле, этием булачак җизнәсенә сандыкны болай саткан:

"Безнең апай гәүһәрдер,

Тәннәре чын мәрмәрдер,

Кыйммәтле таш, гәүһәрдер,

Авызы балдыр, кәүсәрдер" *(көләләр)*

**Әби.** Балалар, бу сандык янында ни бар дисезме? Менә- бабагызныкы...*(сандык яныннан гармун ала)*

**Балалар бергә**. Гармун!

*Өйдән бабай чыга.*

**Бабай**. Иии кемнәр кергән безгә, сөбеханалла! Минем гармуным шул монысы. Гармунда уйнаган кеше элек иң затлы кеше иде. Татарлар шатлык килсә дә, сагыш басса да кулына гармун алган.

**Тәрбияче**. Гармунда уйнаган кешеләргә хәзер дә хөрмәт. Алар бит кеше күңелен тәрбияләүчеләр.

**4 бала**. Беләсезме, минем энем Әсхәт гармун уйнарга өйрәнде бит әле.

**Тәрбияче.** Әйдә әле, Әсхәт, сөйлә әле кем өйрәтте сине гармун уйнарга.

*Шигырь Гөлчирә Нәҗметдинова " Гармун". Бабай талгын гына гармунда уйный.*

**5 бала.** Әби, сандыкта тагынниләр бар?

**Әби.** Менә монысы калфаклар, мендәр япмалары,оекбашлар, монысы шәл, балалалар. Элек без әбиләр, әниләр белән кич утырып, шәлләр, оекбашлар бәйли идек. Шәл бәйләргә дип аулак өйләргә, шәл өмәләренә йөри идек.

**Тәрбияче**. Ярый әле, кул эшләре, гореф- гадәтләребез кабаттан халкыбызга әйләнеп кайта башлады. Милли киемнәр киеп, милли бәйрәмнәр үткәрү хәзер модада бит, Сания апа.

**Әби**.*(ак шәлне кулына тотып алга килеп сөйли, гармун тавышы)*

Зур тормышның серле йомгагын

Әле бәйлим, әле сүтәм мин.

Газиз әниемнең бүләген

Иңнәремә салып йөртәм мин.

**Тәрбияче.** *(икенче шәлне кулына тотып сөйли)*

Шәлгә түгел әнием җепләр белән

Йөрәгемә үргән бизәкләр.

Гомерем буе мине озата бара

Мамык шәлдәй җылы теләкләр.

(*Надия Йосыпова. Яңа Кишет авылы.”Әнием шәле”.)*

*“ Шәл бәйләдем” биюле җыры. Шәлләрне җилләргә эләләр.*

**Әби.** Менә монысы кулъяулыкка төргәне ни дип уйлыйсыз?(*Әби ачып күрсәтә)*

**Балалар.** Медаль!

**Бабай.** Әйе, монысы бабайның медале.Бик кадерле истәлек. Минем бабай сугышта катнашкан. Шушы медаль аның гомерен саклап кала.

**6 бала.** Ничек була ул, бабай, сөйлә әле.

**Балалар.** Сөйлә, бабай, сөйлә.

**Бабай.** Сталинградта дигән шәһәрдә сугыш барганда, бабам Рәхим иптәшләре белән өч немец солдатын кулга алалар. Шуның өчен аларга менә шушы “Батырлык өчен” медале бирелә. Ә берьюлы фашистлар самолеттан бомбалар яудырганда, мина кыйпылчыгы бабама эләгә. Ярый ул кыйпылчык шушы йөрәк турысына куелган медальгә тия. Шулай итеп медаль бабамның гомерен саклап кала.

**1бала.** Безнең өйдә дә минем карт бабамның медальләре бар. Без аларны саклыйбыз.

**Тәрбияче**. Бик дөрес эшлисез. Алар бит бик кадерле тарихи истәлек.

**Бабай.** Әбисе, монда төргәкләр күп әле. Алары турында да әйт.

**Әби**. Бала туганнан соң сандыкта аның беренче чәче саклаган. Тора-бара сандык гаилә истәлекләре булган хатлар, открыткалар, фотоальбом, документлар белән байый.

**2 бала.** Сандыкның капкачына нидер язылган да бугай.

**Бабай**. Туганлык җепләрен югалтмас, кемнең кайчан туганын, кайчан якты дөнья белән хушлашканын онытмас өчен әбиләр әлеге даталарны карандаш белән сандык капкачына язып баралар.

**Әби.** Менә шулай итеп сандыгыбыз бушады, балалар. Сезнең белән бигрәк вакыт тиз үтте. Инде әйберләр җилләр алса, төштән соң, тутырып та куярмын.

**3 бала.** Зур да булмаган сандык эчендә күпме хәзинә саклана икән.

**4 бала.** Күпме тарих!

**Бабай.** Ә хәзер , балалар, өйгә үтегез, әбиегез тәмле кабартмалар пешергән иде, бергә- бергә чәй эчик.

**Әби.** Тик  шуны әйтим, балалар, сез дә әбиләрегезнең сандыгына ешрак күз салыгыз. Анда ниләр барлыгын яхшылап өйрәнегез. Әбиләрегезнең сандыгында ятучы хәзинәләребез – алар безнең байлыгыбыз.Алар - милләтебез төсе, рухи ядкарьләребез.

**Бабай**. Матур җәй көнендә авылларга кайткач, әбиләрегезне, әниләрегезне сандык җилләтергә эндәшегез. Бергә-бергә гаиләгез, нәселегез тарихына төшенегез.

*(Барысы бергә өйгә кереп китәләр)*

## “Мендәр тутыру йоласы”

***Хәкимова Г.Р., Хисмәтуллина А. Ә., Камалиева Г.Р.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*“Арча 1 нче балалар бакчасы” муниципаль бюджет*
*мәктәпкәчә белем учреждениясе*

**Максаты:** балаларда туган телебезгә, милләткә һәм аның гореф-гадәтләренә, йолаларына мәхәббәт тәрбияләү.

**Катнашалар: әни,әби(олы кешеләр)милли киенгән балалар.**

Татар өе эче күренеше.Түрдә әби белән әни утыра.Алар тирәсендә җыелышып балалар утыра.

Түр яктагы кроватка

Әйтерсең болын кергән.

Чигешле япма өстендә

Утыра чиккән мендәр.

Ап-ак мендәр тышында

Аллы-гөлле чәчкәләр.

Кил әле, ял итеп ал дип

Гүя безне дәшәләр.

- Әбием, әнием, бу йомшак мендәрләрне ничек ясыйлар соң?
- Безгә дә шул турыда сөйләгез әле!
- Мендәрләр ничек шулай йомшак булалар? Безнең бик беләсебез килә.

Әби. – Сөйлибез, сөйләп кенә калмыйбыз, ясап та күрсәтәбез әле.

Әни. – Әйе, менә мамыкларым да әзер инде, хәзер әбиегез белән мендәр тутырып күрсәтәбез сезгә. Ә сез безгә булышырсыз инде яме.

Балалар. – Бик теләп булышабыз!

Әби. – Әнә беркөнне “Каз өмәсе” үткәрдекме күршеләр белән җыелышып. Менә шунда казлардан йолкыган мамыклар инде бу, балалар.

Бала. -Без анда бик матур җыр җырлаган идек, әбием! Әйдә тагын җырлап алыйк әле. Камилэ

“Дүдәк-дүдәк” җыры

1. Йөгерә үрдәк, йөгерә каз

Боты озынга күрә.

Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,

Басма өстендә каз, үрдәк,

Кыйгак-кыйгак,

Бак, бак, бак, бак,

Басма өстендә каз, үрдәк.

2. Без кызларны яратабыз

Бите кызылга күрә.

Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,

Басма өстендә каз, үрдәк,

Кыйгак-кыйгак,

Бак, бак, бак, бак,

Басма өстендә каз, үрдәк.

3. Йөгерә үрдәк, йөгерә каз,

Кала эзеннән тамга.

Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,

Басма өстендә каз, үрдәк,

Кыйгак-кыйгак,

Бак, бак, бак, бак,

Басма өстендә каз, үрдәк.

4. Үтә матурларны сайлап,

Урта матурдан калма.

Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк,

Басма өстендә каз, үрдәк,

Кыйгак-кыйгак,

Бак, бак, бак, бак,

Басма өстендә каз, үрдәк.

Әни. – Мин мамыкларны чистарттым, юасын юдым, бик әйбәтләп киптердем.

Әби. – Менә бу – мендәр сүрүе дип атала. Ул бик тыгыз тукымадан бик яхшы итеп тегелә. Мамыклар чыгып китмәсен өчен.

Әни. - Ә бу мендәр тышларын мин күптән чигеп әзерләп куйган идем инде. Балаларыма мендәрләр матур булсын дип тырыштым. Йокылары татлы булсын дидем.

Әби. – Хәзер сүрүгә мамыкны әкрен генә тутырабыз. Башта карап торыгыз. Аннары сез дә булышырсыз яме.(Әби белән әни мендәр тутыра.)

- Әби Мендәрләребез саф, чиста, йомшак булсын!
- Балалар татлы йокы белән йокласын!
- Әби Шушы йомшак мендәрләрдә йоклап сиһәтләнсеннәр, тәннәренә көч һәм иман керсен!
- Әйдәгез сез дә безгә булышыгыз әле!

Балалар мендәр тутырыша

- Мендәрләр күпереп торсын! Тагир
- Әни әйткәч тә, йоклап китәрлек булсын!
- Иң йомшак мендәрләр безнеке булсын!
- Караңгыда бүлмәне яктыртып торсын! Алайса мин караңгыдан куркам. Камилә
- Әби. – Балалар, менә күпме эш эшләдек. Бердәмлектә көч ди. Бергә бергә эшләгәч, җиңелрәк тә булды, эшебез дә уңды.
- Әни–Хәзер менә шушы йомшак мендәрләргә мендәр тышы киертәбез. Алар бик матур, чәчәкләр белән чигелгән
- Әби Әйдәгез, хәзер бер биеп тә алыгыз әле, мин дә яшьлегемне искә алырмын.
- Үзебез тутырган мендәрләр белән биеп алыйк әле!

“Мендәрләр белән бию”

Бар йоласына китереп,

Күңелле өмә җыеп.

Кызлар тутырган мендәрләр

Күңелен биреп сөеп.

Күпереп торган мендәрдә

Экологик чисталык.

Үрнәгенә бизәк биргән

Кул эшенә осталык.

Мамык мендәр һәр кунакка

Олы хөрмәт билгесе.

Татар хатын-кызларының

Уңганлыгы көзгесе.

Әни : Әйдәгез бер күнелле бер уен да йунап алйк инде.Уен “Тукмак”

Әби. –Балалар, сез бүген нинди күп эш эшләдегез. Бәлки хезмәт турында мәкальләр дә беләсездер әле.

Әни :Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.

Кем эшләми, шул ашамый.

Хезмәт төбе - хәзинә.

Аз сөйлә, күп эшлә.

Хезмәте каты - җимеше татлы.

Җыр “Чәй эчәбез бергәләп”

1.Бакчада әби-бабайның өстәлләре түгәрәк,
Килдек әле кунак булып чәй эчәбез бергәләп.
куш.-та Бигрәкләр дә тәмле инде әбиемнең чәйләре
Рәхәтләнеп тагын берне эчикме әллә әйдә әле
2.Сыйланыгыз дигән сыман самовар кайнап тора
Күбәләкләр очып уйный, тургайлар сайрап тора.
Бигрәкләр дә тәмле инде әбиемнең чәйләре
Рәхәтләнеп тагын берне эчикме әллә әйдә әле.
Әни. – Булдырдыгыз, балалар, гел шундый акыллы, ярдәмчел булыгыз!
Иртәгә дә килегез яме, мин сезне май канаты ясарга өйрәтермен.
Әби:Әйдәгез әле хәзер чәй эчәргә түр булмәгә үтик.

**“Мич котлау йоласы”**

***Сәләхова Гөлнур Мөбәрәкҗан кызы***

*Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*катнаш төрдәге “Кызыл Тау “Салават күпере” балалар бакчасы”*

**Максат:** балаларны йола-бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү, өлкән буыннарның яшәү рәвешенә кызыксыну тәрбияләү.

**Бурычлар:**

- балаларның монологик һәм диалогик сөйләм телен үстерү;
- татар халык уеннары белән танышуны дәвам итү һәм уеннарда балаларның теләп катнашуларын тәэмин итү;
- туган илебезгә һәм халкыбызга карата хөрмәт хисе тәрбияләү;
- татар милли ризыкларының һәм кул эшләнмәләренең исемнәрен хәтердә ныгыту.

**Җиһазлау:**

Мич
Табалар, ипи савыты, табагач
Чиккән кул эшләнмәләре
Татар халкының милли киемнәре ( балаларга)
Савыт-саба
Милли ризыклар (чәк-чәк, өчпочмак, мич коймагы, ипи)
Музыкаль бизәлеш
Сандык

**Алдан эшләнгән эш:**

“Мич котлау” йоласы турында әңгәмә үткәрү.

Балаларны татар халкының башка төрле йолалары, гореф-гадәтләре белән таныштыру.

Татар халык уеннарын өйрәнү.

Татар халык биюе өйрәнү.

Татар милли ризыклары турында әңгәмә үткәрү.

**Катнашучылар:**

Рабига әби

Килен

Зәйнәп әби

Балалар

**Чараның барышы:**

**Зал бәйрәмчә бизәлгән. Авыл өе күренеше. Өй түрендә яңа мич. Аның янында әби йон эрләп утыра. Татар халык көе ишетелә.**

**Бер төркем балалар килеп керә.**

**1нче бала:**

- Кызлар! Малайлар! Карагыз әле, Рабига әби иске мич урынына яңаны чыгартып куйган, ди!

**2 нче бала:**

- Миченнән төтен чыга түгелме? Әйдәгез, мич котларга барабыз.

**3 нче бала:**

- Әйдәгез! Бергәләп ял итәрбез: уйнарбыз, җырларбыз, рәхәтләнеп күңел ачарбыз!

*Шау-гөр килеп "капка" төбенә киләләр. Балалар тавышын ишетеп Рабига әби чыга.*

**Рабига әби:**

- Бәрәкалла, миңа балалар килгән түгелме соң! Нишләп йөрисез?

**Балалар:**

- Исәнмесез, әби! Сезнең мичтән төтен чыкканны күрдек, яңа мичне котлап кунакка килдек, ярыймы?

**Рабига әби:**

- Ярамаган кая, ярый, балакайларым, ярый. Балалар, күрегез әле безнең яңа, матур мичне!

*Балалар мич тирәли йөгереп әйләнеп чыгалар.*

**Рабига әби:**

- Менә шулай , балакайларым, элек – электән авыл өйләрендә шундый зур, матур, ап-ак итеп агартылган мич булган. Мичне кирпечтән ясаганнар, балчык белән яхшылап сылаганнар һәм агартканнар. Мичкә утын ягып, өйне җылытканнар, мичтә тәмле ризыклар пешергәннәр. Борынгы заманнардан ук мич һәр өйдә булган.

**Барысы бергә:**

- Бәрәкәтле мич булсын! Таңнар атып кич булсын. Туганнарыгыз күп булсын. Ә дошманнар юк булсын.

*Килен эштән кайтып керә.*

**Рабига әби:**

- Килен, син дә кайткансың икән. Бергә күңел ачканнан сон чәй дә әзерләп алырсың безгә.

**Килен:**

- Яңа мичне котлап, икмәк салырмын бүген.

*Икмәк өчен әзерләнгән камыр салынган ипи савытын күрсәтеп әйләнеп килә. Ипине мичкә тыгып, капкачын каплый.*

**4 нче бала:**

- Мичтә пешкән коймак бик тәмле була.

**Рабига әби:**

- Коймак та булыр, балакайларым. Сездәй кунакларга пешермичә булмас!

**Килен:**

- Кердек алма бакчасына,

Алма җиргә коелган.

Бер матур җыр җырлап алыйк

Якын дуслар җыелган.

**Җыр "Хәерле көн".**

**5 нче бала:**

- Алма бакча– челтәр капка, ачыла ике якка.

**6 бала:**

- Килдек, дуслар, сезнең белән уйнап күңел ачарга!

**Килен:**

-Нинди уен уйныйбыз? Әйдәгез, әйтешләр әйтеп уйныйбыз!

**Әйтешләр әйтү "Куяннар":**

- Куяннар кая барасыз?

- Әбиләргә барабыз.

- Анда нигә барасыз?

- Каз ботына барабыз.

- Аны кая куясыз?

- Кулъяулыкка төрәбез.

- Пычранса нишлисез?

- Суга кереп юабыз.

- Агып китсә нишлисез?

- Кычкырып, кычкырып елыйбыз.

**Килен:**

- Без елап тормыйбыз, ә күңел ачуны дәвам итәбез.

**Татар халык биюе.**

**Рабига әби:**

- Балалар, шул хәтле күңелле утырабыз, мин бу күңеллелекне күрергә күршедә торучы Зәйнәп әбиегезне дә чакырдым әле.

**Зәйнәп әби керә.**

**Зәйнәп әби:**

- Исәнмесез, балалар.  Әйдәгез, без  яшь чагында уйный торган  бер кызыклы уен белән таныштырыйм әле сезне.  Уенның исеме “Куш кулым”.

**Уен уйнау “Куш кулым”.**

**Килен:**

**-** Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, игътибар белән тыңлагыз.

**Сандык турында табышмак әйтелә:**

Бар бер матур агач сарай,

Әйләнәсе суккан калай.

**Балалар:**

- Сандык.

*Чиккән кул эшләнмәләре салынган сандык куелган. Рабига әби белән Зәйнәп әби сандык эчендәге кул эшләнмәләре турында сөйлиләр (чиккән сөлге, мендәр тышы, кулъяулык, ашъяулык, чынаяк өсте).*

**Рабига әби:**

- Без кечкенә чагында бик яратып “Уңга кара, сулга кара” һәм “Чума үрдәк – чума каз” уеннарын уйный идек. Сезгә дә әлеге уеннарны тәгъдим итәм . Уйнап алабызмы?

**Уеннар уйнау:**

1.”**Уңга кара, сулга кара**”(ике бала бер-берсенә аркаларын куеп басалар. Өчкә кадәрсанагач, башларын боралар. Әгәр  икесе дә бер якка карый икән, “бүләк”(приз) бирелә, төрле якка карыйлар икән –“җәза” бирелә.).

**2. “Чума үрдәк – чума каз” уены.**

**Рабига әби:**

 - Карагыз әле, балалар, сезнең белән күңел ачып утырып,  көтү кайтканын да күрми калганмын. Минем кечкенә бәрәннәрем кая соң?

**Бию: “Бәрәннәр”.**

**Килен:**

- Биедек тә, җырладык та, уйнадык та – бергәләп рәхәтләнеп күңел ачтык. Мин сез уеннар уйнап, күңел ачкан вакытта тәмле итеп мич коймагы өлгерттем, кадерле кунакларым.  Хәзер, әйдәгез, тәмләп чәй эчеп алыйк.

**Борынгыдан килгән йола - татарның каз өмәсе**

***Галимуллина Венера Имель кызы***
*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Сабабаш«Кояшкай»муниципаль бюджет мәктәпкәчә*
*белем бирү учреждениесе*

**Тема: Борынгыдан килгән йола - татарның каз өмәсе**

**Максат:** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны халкыбызның йола бәйрәме - каз өмәсе белән таныштыру; гореф-гадәтләргә, милли йолаларга ихтирам, мәхәббәт тәрбияләү.

*Авыл өе күренеше. Түрдә борынгы сандык, мендәрләр, гармун, көянтә, чиләкләр, зур кәрҗин*

Радиодан «Каз канаты» көе яңгырый.

**Алып баручы.**

Авылларда каз өмәсе гөрли,
Юл буена канат сипкәннәр.
Канат өсләренә баса-баса,
Кызлар каз юарга киткәннәр.
Әллә нинди генә сәер чак бу,
Үзе моңсу, үзе күңелле.
Казгомерекирекайтмыйторган
Яшьлеккебеккыскагомерле.

**Ана.**Кызым, күрше кызларына, туган-тумачаларга бүген бездә каз өмәсе икәнен әйтергә кирәк.

**Гөлшат.**Хәзер, әнием, борчылма, барысына да әйтермен.

**Ана.** Әтисе, Гөлшатыбыз өмәгә кызлар чакырырга китте, син казларны әзерләп куй инде.

**Ата.** Әнисе, казлар әзер, мичкә ягып, казанда су кайнаттым.

*Йортка кызлар җыела.Күрше карчыгы Сәлимә әби керә.*

**Сәлимә әби.** Кәримә, казларың бик симергәннәр.Өмәгә җыелган кызлар да бик уңган күренәләр.

**Ана.**Әйе, Сәлимә әби, безнең авыл кызлары бик уңганнар шул.

**Сәлимә әби.** Кызларым-балакайларым, сезнең каз йолыкканыгызны күргәч, яшь чаклар искә төште.

**Айсылу**. Әбекәй, сез яшь чагында каз өмәсен ничек уздыра идегез? Сөйләгез әле.

**Кызлар** (барысы бергә). Сөйләгез әле, сөйләгез әле, әбекәй.

**Сәлимә әби.** Иии  балакайлар, без яшь чакта су буе тулы каз була иде.Һәр өйдә икешәр-өчәр оя каз бәбкә чыгара.Аны бала чакта каргадан, тилгәннән саклый идек. Ә көз җиткәч, авылда каз өмәләре гөрли. (Серле елмаеп) Бабагыз белән дә каз өмәсендә таныштык. Кичен аулак өйгә килгәч, ул миннән канат сатып алды.

**Кызлар.**  Ничек?...Сатып алды?

**Сәлимә әби.**Хәзер мин сезгә барысын да сөйлим. Ә кичен аулак өй үткәрерсез.

Менә, балакайлар, казны шулай йолкый идек. Мамыгын җыябыз, аннан мендәрләр ясыйбыз (Мендәр ясап күрсәтә). Каз канатларын ташламыйлар (канатлар күрсәтә) Аның белән идән себерә идек.Казларны йолкып бетергәч, су буена юарга төшә идек. Ә кичен аулак өйгә җыелып күңел ачтык. Гармун, җыр тавышыннан авыл гөрләп тора иде.

*(Аулак өйнең ничек уздырылуын сөйли, кызлар шатланып рәхмәт әйтәләр).*

**Ана.**Ярдәмчел күрше апайлар,

Киленнәр һәм яшь кызлар.

Бигрәк җитез, тырышлар

Мамык йолыккан куллар.

Тау өелгән мамыктан,

Әйтерсең лә кар яуган.

Йоклавы рәхәт булыр

Йомшак мамык өстендә.

*Кызлар, йолыккан казларны көянтәгә асып, инеш буена юарга китәләр. Урамда гармун тоткан егетләр каз юучы кызлар янына киләләр.*

**Гармунчы егет.**Кызлар, бигрәк уңган икәнсез. Бу казларны кай арада чистарттыгыз?

**Айсылу.** Безнең авыл кызлары булганда, бар эшкә дә өлгерәбез.

**Айгөл** (шаянланып).Кирәк булса, сезнең дә казларыгызны йолкырбыз. Без эштән курыкмыйбыз, эш бездән курка.Шулаймы, кызлар?

**Кызлар** (көлешеп). Шулай, шулай, Айгөл, эш бездән курка.

**Егет.** Кызлар, инеш суында каз юып туңып та киттегез бугай.Әйдәгез, бер биеп алыйк.

*(Егетләр, кызлар инеш буенда татар халык көенә бииләр).*

**Кызлар.**  Бигрәк күңелле булды әле. Кичен аулак өйгә килегез!

**Егетләр.** Килербез, килербез! *(гармун уйнап, җырлап китеп баралар).*

**Алып баручы.**

Кызлар кайта  су буеннан

Казлар кебек тезелеп.

Егетләр карап кала

Үзәкләре өзелеп.

Иңнәрендә көянтә,

Көянтәдә - казлары.

Бигрәк матур, бигрәк уңган

Безнең өмә кызлары.

*(Бер кыз юлга кызлар артыннан каурый сибә)*

**Кыз.**Каурый сибәм су юлына

Ишле булсын казыгыз

Өмәләрдә эш күрсәтеп,

Ярлар табып калыгыз.

**Ана.** Бизәкле көянтәгә асып,

Казлар юып кайтуга,

Самовар җырлап утыра

Азык тулы табында.

**Гөлшат.** Әниемнең табыннары

Сокланып та торырлык.

Каз коймагы шундый тәмле,

Телкәеңне йотарлык.

**Айсылу.**Табыннар булсын бик мул,

Үткәрелсен өмәләр.

Буыннан – буынга калган

Борынгы йола бит ул.

**Гөлшат.**Әни, без дә аулак өй үткәрик әле. Сәлимә әби безгә аулак өйләр турында сөйләде.

**Ана.**Ярый, кызым, Без бүген әтиең белән күрше авылга туганнарга кунакка барабыз. Тәртипле генә утырыгыз.

**Гөлшат.**Рәхмәт, әнием!

*Кич. Аулак өйгә кызлар җыелган. Ерактан гармун тавышлары ишетелә.*

**Айгөл.**Кызлар, егетләргә канат сатабызмы?

**Айсылу.**Сатабыз, әлбәттә.

**Гөлшат.** Йә, кызлар, һәркайсыгыз үзегезгә канатлар алыгыз. Җебептормагыз. Акчасалмыйча, канат бирмәгез.

**К ы з л а р** *(һәркайсы кулларына икешәр канат алалар)*. Чү, киләләр, киләләр!

*Ыгы-зыгы башлана. Еракта «Каз канаты» җыры башлана.*

**Айгөл.**Йә, кызлар, урыннарыгыздабулыгыз.

*Кызлар ишекне ябып тотып торалар.*

**Е г е т л ә р** *(ишек янында«Каз канаты» көенә җырлыйлар)*.

Каз канаты кат-кат була,

Ир канаты атбула.

Җаныңсөйгән яр алдында

Җангарәхәтлекбула.

**К ы з л а р .**

Каз канаты кат-кат була,

Кыз канаты акбула.

Бусагаялынтүләгән

Хөрмәтле кунак була.

**Е г е т л ә р** *(шау-шаулап ишеккә ябырылып)*. Кая, нигә кертмисез инде? Кызлар-йолдызлар, кертегез инде!

**А й г ө л .** Ашыкмагыз, авызыгыз ашка пешәр. Янчыкларыгызны капшап, берәм-берәм керегез!..

**А й с ы л у** . Сиңа, егет, кем кирәк?

**1 н ч е е г е т** . Кара кашлы кыз кирәк.

**А й с ы л у** Ни эшкә соңулкирәк?

**1 н ч е е г е т** . Әнигәкиленкирәк.

**А й г ө л .** Егет, сиңа ни кирәк?

**2 н ч е е г е т** . Миңанечкә бил кирәк.

**А й г ө л .** Ни эшкә соң ул кирәк?

**2 н ч е е г е т** . Ансыз яна яшь йөрәк.

**Г ө л ш а т .** Сиңа, егет, ни кирәк?

**3 н ч е е г е т** . Каз мамык ястык кирәк.

**Г ө л ш а т .** Казларыбыз мамыксыз. Кызлар йоклый ястыксыз!..

**А й г ө л** . Шуны да синбелмәгәч, йөрмә монда вакытсыз!..

**К ы з л а р** . Канат сатам, канат сатам, канат сатам!..

**Е г е т л ә р .** Мин алам, мин алам, мин алам. *(Һәрберсеберкызкаршына баса.)*

**К ы з л а р** . Канат хакы бер алтын.Чын егет булса алсын!

**Е г е т л ә р** *(борылып)*. Йә?

**К ы з л а р** . Егет, сиңа кем кирәк?

**Е г е т л ә р** . Канатлы яшь кыз кирәк.

**К ы з л а р** . Ни эшкә?

**Е г е т л ә р** . Канатыңда очармын, үзең сөеп кочармын ( *Егетләр барысы да канат сатып алалар).*

**Б а р ы с ы  б е р г ә .**

Каз канаты каурый-каурый,

Хатлар язарга ярый.

Яшь чагында уйнамасаң,

Ул аннан нигә ярый.

*Аулак өйгә җыелган кызлар, егетләр җырлыйлар, бииләр. Йөзек салыш, Наза уеннарын уйныйлар)*

**Алып баручы.**

Бии – уйный сылу кызлар,

Чыңлый чулпы төймәсе.

Борынгыдан килгән йола –

Татарның каз өмәсе.

## “Солдатка озату ” йоласы

***Бариева Зөлхия Радик кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*“Гомуми үсеш бирүче төрдәге Балтач 2 нче*
*номерлы балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** балаларның татар халык йолалары, бәйрәмнәре турында белемнәрен баету.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:** Ватанны саклау – һәр егетнең иң изге бурычы һәм элек-электән килгән канун икәнлеген балаларга төшендерү;

**Тәрбия бурычы:** халык авыз иҗатына, гореф-гадәтләренә, йолаларга, милли уеннарга хөрмәт хисе тәрбияләү;

**Белем бирү бурычы:** татар халкының әби-бабайлардан калган йолаларын яңарту.

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сәнгәти- эстетик үсеш, сөйләм үсеше, социаль-коммуникатив үсеш.

**Методлар алымнар һәм чаралар:** үстерелешле әңгәмә, сораулар, уеннар, күзәтү, сюрприз момент.

**Материал һәм җиһазлар:** авылча бизәлгән зал, милли киемнәр, солдат киеме, чиккән сөлгеләр, чиккән кулъяулык, өстәлдә самовар белән чокырлар, йон эрли торган каба.

**Сүзлек эше:** армия сафлары, дога, ил чикләрен, кулъяулык.

**Алдан эшләнгән эш:** халык уеннары уйнау, шигырьләр, җырлар ятлау.

**Бәйрәм барышы:**

*Бәйрәм уткәреләсе зал матур итеп бизәлгән. Авыл өе күренеше. Әби белән бабай ишектән керәләр.*

**Әби:** И бабай, сиңа әйтәм бүген  төпчек улыбызда армиягә китә бит.

**Бабай:** Һай, шулай мени?

**Әби:** Әйе, менә шәһәрдән олы балалар да кайтырга тиеш. Күренмиләрме соң үзләре? *(Тәрәзәдән карый.)* Кайталар түгелме соң... Әйе, әйе, алар... Балалар кайта!

**Бабай:** Бәрәкалла, шулай бугай шул, безнең балалар! Чыгып каршы алыйк үзләрен.

*(Ишек төбенә киләләр, аннан балалар керә башлый.)*

**Бабай:** Әйдәгез, балакайларым, керегез!

**Әби:** Исән- сау гына кайттыгызмы? Ай һай әллә кунак кызлары да алып кайттыгызмы?

**Бабай:** Кунак малайлары да бар икән. *(Аркаларыннан сөя.)* Ягез, балалар, утырышыгыз, ял итегез.

**Солдат малай:** Исәнмесез! Әбием мин Армия сафларына китәм инде. Хәерле юл теләгез миңа.

**Беренче әби:** И, улым, илләребез тыныч булып исән сау хезмәт итеп кайт. Ярар, улым, сәламәт булып, туган җиреңә кайтырга язсын. Исәнлектә күрешергә язсын, улым. Сау бул, без сиңа хәер дога кылып торырбыз. Менә, улым, берәр кирәгеңә тотарсың *(акча бирә)*.

**Солдат малай:** Ярар, әбием, мине догаңнан ташлама. Мин хезмәт итеп кайтканчы исән сау торыгыз.

**Бабай:** И-и бар иде яшь чаклар... Без яшь чакта бик күңелле үтә иде армиягә озату кичләре.

**Әби:** Җыр, бию, уен-көлке! Андагы күңеллелек, сөйләп аңлата торган түгел!

**Солдат малай:** Әйдәгез, бер биеп алыйк әле.

*Парлы татар биюе.*

**Бабай:** Ярар, балам, сау бул. Еллар имин. Күкләребез аяз булсын. Хәерле сәфәр, улым.

**Солдат малай:** Рәхмәт бабай, сау булып тор.

**Кыз:** Әйдәгез әле бер уен уйнап алабыз.

**Барысы бергә:** Нинди уен?.

**Кыз:** Яулык салыш уенын уйныйбыз.

**Барысы бергә:** Әйдәгез.

**Санамыш:**

1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 10
Байлар кия төлке тун.
Төлке тунның бәясе
Йөз дә кырык ике сум.

**Уен:**

Кульяулыгым яшел, яшел
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

**Малай:** Ну, брат, давай, без үзебезнең ил алдындагы бурычыбызны үтәп кайттык. Чират синдә, анда баргач җебеп торма. Үзеңнең кою йөрәкле, татар егете икәнеңне онытма.

**Бабай:** Фамилиябезгә тап төшерә күрмә. Кыю, батыр бул. Бер ел күп тугел инде, кеше тормышында бер мизгел генә. Яхшы хезмәт ит, улым, тәртипле бул.

**Әби:** Улым, тәртипле бул, олыларның сүзен тыңла. Исән –сау кире әйләнеп кайт. Сиңа икмәк каптырам, калган кисәген җыеп куям. Ул син кайтканны теләп иң кадерле урында сакланыр. Улым, туган йортыбызга сау сәләмәт әйләнеп кайтыр өчен он белән ике кулыңны буяп тактада кул эзен калдырырсың, ул эзгә тияргә ярамый син кайтканчы.

*(Машина тавышы килә)*

**Солдат малай:** Җыенырга вакыт җитте. Барыр юлым уңышлы булсын, үз аякларым белән исән-имин туган йортка кабат керергә язсын.

**Бергә:** Амин!

*Кыз белән солдат малай алга чыгалар.*

**Кыз:** Ярый, сау бул. Исән-сау йөр.

**Солдат малай:** Син мине көтәсеңме?

**Кыз:** Көтәрмен, борчылма. Менә сиңа вәгъдә билгесе – кульяулык.

**Солдат малай:** Мин аны йөрәк түремдә генә саклармын.

**Солдат малай:** Сау булыгыз, туганнар, дуслар, куршеләр, әнием, әтием.

**Кыз:** Сине һәркөн искә алып үтәрбез. Изге бурычыңны яхшы дәвам ит, исән-имин кайтуыңны көтәбез.

*Солдат малай җырлый-җырлый чыгып китә.*

Без авылдан чыккан чакта
Күтәрелде томаннар
Яз кайтмасак, көз
кайтырбыз
Сау булыгыз, туганнар.

# “ТЕЛЛӘР ТӨРЛЕ – ТЕЛӘКЛӘР БЕР”

(Идел буе халыклары мәдәниятенә багышланган кичә)

***Солтанова Рушания Әсгатулла кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*“Олы Кибәче “Күбәләк” балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:**

- төрле халыклар мәдәнияте, аның башлангычы, теле, гореф-гадәтләре, көнкүреше турында күзаллауларын формалаштыру;

- үз милләтеңне, аның телен саклауга уңай йогынты ясау;

- башка милләт халыкларына уңай мөнәсәбәт тудыруга йогынты ясау;

- төрле милләт халыкларының милли орнаментларын, дәүләт символикасын аера белү өстендә эшләү;

- туган илгә, үзеңнең милләтеңә һәм башка милләт халыкларына карата хөрмәт тәрбияләү;

- төрле милләт вәкилләре (татарлар, чувашлар, удмуртлар, марилар, башкортлар, руслар, мордвалар һ.б.), милли ризыклары, кул эшләре, уеннары, бәйрәмнәре турында сөйли белүләренә игътибар итү.

**Кичәнең барышы:**

**Радио тавышы:**

- Тыңлагыз, тыңлагыз, Саба районы Олы Кибәче авылында урнашкан “Күбәләк” балалар бакчасыннан Сезгә бик шәп яңалык җиткерәсебез килә. Бүген бу бакчада бик матур кичә. Идел буе халыкларының җыены – бәйрәме була. Бик күңелле булачак, килми калмагыз!!!

*Күңелле музыка астында залга милли киемнәрдән, кулларына милли ашлар, күчтәнәчләр тотып: татар – чәк –чәк, рус –күмәч-каравай, башкорт – бавырсак, бал, удмурт – перепечи, чуваш – бәлеш-хуплу, мари – коймак – коман-мелна, мордва –итле пирог тотып балалар керәләр һәм урыннарына утыралар.*

**Татарлар.** Исәнмесез, кадерле кунаклар! Күчтәнәчебез – баллы, татлы чәкчәгебезне кабул итеп алыгыз! *( Өстәлгә куя.)*

**Руслар.** Здравствуйте, дорогие гости! Примети наш национальный гостинец – каравай! *(өстәлгә куя.)*

**Башкортлар.** Һаумыһыгыз, дуслар карендәшләр! Һедгә дигән күчтәнәчебез – бавырһак, кабул итеп алыгыз! *(Өстәлгә куя.)*

**Удмуртлар.** Зеч буреч, гаӊано кунеес! Мы вам привезли перепечи, угощайтесь! *(Өстәлгә куялар.)*

**Чувашлар.** Салам, авани. Сыван! Без, чувашлар, хуплу, бәлеш яратабыз, сез дә авыз итегез әле! *(Өстәлгә куя.)*

**Марилар.** Салам лийже, йолташ-влак. Сезгә бездән коймаклар – коман мелна! *(Өстәлгә куя.)*

**Мордвалар.** Сезгә Саранск каласыннан, мордвалардан күп сәлам! Күчтәнәчебез итле пирог! Бик тәмле! *(Өстәлгә куя.)*

**Алып баручы:** Хуш килдегез, кадерле туганнар! Алып килгән күчтәнәчләрегезгә зур рәхмәт! Сезне үзебезнең “Күбәләк” балалар бакчасында күрүебезгә без бик шат! Ә хәзер бәйрәмебезне башлыйбыз.

*Җыр:”Әссәләмәгаләйкүм”.*

**Алып баручы:** Идел елгасыннан алып Урал тауларына кадәр җәелгән киңлекләрдә төрле милләт халыклары – рус, татар, башкорт, удмурт, чуваш, мари, мордвалар бик дус, тату яшиләр. Һәр милләтнең теле, гореф – гадәтләре, бәйрәмнәре төрле булса да, алар бер-берсен хөрмәт итеп, бер-берсенә кунакка йөрешеп, милли бәйрәмнәрен тәбрикләп, тынычлыкта, дуслыкта, гомер итәләр. Алар дуслык, туганлык телендә сөйләшәләр, аңлашалар. Бугенге бәйрәм кичәбездә без һәр халыкның уеннары, биюләре, җырлары белән тирәнтен танышырбыз. Ә хәзер сәхнәбез түренә татар егетләре һәм кызларын чакырабыз.

*Татарлар. Зурлар төркемендә тәрбияләнүче балалар “Мин яратам сине, Татарстан” җырын башкаралар.*

**Зөһрә.** Татарстан – гүзәл илем,

Газиз миңа туган телем.

Данлы, шанлы Казаным,

Тарихы да зур аның.

**Риназ.** Аралар ерак димичә,

Дуслар безгә килдегез.

Мәкнең алсу чәчәгедәй,

Күземә күрендегез.

**Ралинә.** Барлык милләт балалары.

Җирдә дус булсын.

Бу очрашу күңелләрдә,

Йөрәктә калсын.

**Алып баручы:** Ә хәзер безнең әби-бабаларыбыз яратып уйнаган “Утырып кал” уенын уйнап күрсәту өчен сәхнәбезгә зурлар төркемендә тәрбияләнүче балаларны чакырабыз. Рәхим итегез сәхнә түренә. Кем иң җитезегез икән? Уңышлар сезгә!

**Уен тәртибе:** Көй башлануга урындыклар тирәли татарча бииләр. Көй туктауга урындыкка утырып калырга тиешләр. Урындыксыз калган уенчыга җаза бирелә һәм ул уеннан чыгып китә. *(Урындыклар саны уенчылар санынннан бергә ким алына).* Иң ахырдан калган уенчы җиңүче була.

**Алып баручы:** Бик күңелле, матур уен күрсәттегез зур рәхмәт сезгә! Ә хәзер сүзне татарлар белән иңне-иңгә куеп яшәүче рус милләтенә бирәбез. Рәхим итегез дуслар!

**Руслар.**

**Камил.** Добрый день, веселый час!
Мы приветствуем всех нас!
С праздником поздравляем,
Счастья, радости желаем!

**Амир.** Родная мне моя семья,
Мой дом родной –
Одна семья!
В краю родном – как дома я!
Одна семья!
Для всех родимых дом – Земля!
Планета вся – одна семья!

*Мәктәпкә хәзерлек төркеме кызлары “Матрешки” җырлы бию күрсәтәләр.*

**Алып баручы:** Афәрин, булдырасыз икән! Сүзне удмурт милләте вәкилләренә бирик.

**Удмуртлар**

**Мәдинә.** Зеч буреч, гажано, диеп,
Удмуртия сәламли.
Һәр җирдә дуслык булганга
Ул яңа үрләр яулый.

**Райназ.** Шәһәрләре – Ижау, Сарапул, Можга,
Глазов, Воткинск, Камбарка.
Варзи – Ятчи, Кыйлуд,Ува-
Санаторийлар монда.

**Ильяс.** Күлләре, урман, сулары,
Сазлыгы да сихәтле.
Минемчә, Удмурт илендә

Бар кеше дә бәхетле.

*Мәктәпкә хәзерлек төркеме кызлары башкаруында Удмурт халкының “Тыпыртон” биюе.*

**Алып баручы:**

“Мари” - “кеше” дигән сүз,
Сай улыда- исәнме !
Мари халкын барыбыз да
Хөрмәт итеп сәләмли.

*Марилар.*

**Ясминә.** Салам лийже, йолташ – влак!
Сәламли сезне мари,
Пагален ужена, диеп,
Түргә узарга сорый.

**Алия.** Рәхим ит Мари иленә,
Йошкар – Ола җиренә!
Төрле халык Марий – Элда,
Яшиләр үз коенә.

**Дамир.** Әйдәгез дусларым бергә мари халык уенын уйнап алыйк.

*Уртанчылар төркеме “Кайда яулык?”- мари халык уенын күрсәтәләр.*

Әй урман кошы, күке,
Син безгә таныш түгел.
Кәккүк, кәккүк, дип сөйлисең.
Моңлы җырыңны көйлисең.

**Күке.** Яшим калын урманда,
Өем бөек имәндә.
Калдым мин бер ялгызым,
Югалды балаларым.

Әй син күке, моңайма,
Килче монда уйнарга,
Булыш яулык эзләргә.
Күңелле булыр безгә.

**Алып баручы:** Идел буе халыклары арасында элек-электән татарлар белән башкортлар аеруча дус яшәгәннәр. Хәтта безнең телләр дә охшаш.

*Башкортлар.*

**Диләә.** Башкалам- Өфе калаһы
Ямьле Идел буенда.

Кайда гына яшәһәм дә

Һез булырһыз уемда.

**Лиана.** Һаумыһыгыз! Һаумы! Һаумы!

Һаулашам – сәлам бирәм.

“Һаумы” тигән һайбәт һүзне

Бар дөньяга ебәрәм.

**Сөләйман.** Башкорт егете курай уйнай.

Бөтеһе аны тыңлай.

Башкорт һылуы биегәндә

Телдән язалар бугай.

*Зурлар төркеме кызлары башкаруында “Башкорт халык биюе”.*

**Алып баручы:** Ә хәзер сүзне чуваш дусларга бирәбез.

*Чувашлар.*

**Иделия.** Салам, авани, сывай!

Чуваш сезне сәламли.

Барыгызга да тазалык,

Бәхет, тынычлык телим.

**Илгизәр.** Чуваш иле –Чувашия,

Чабаксар – башкаласы.

Җире матур, халкы батыр,

Хезмәт сөя барчасы.

**Алып баручы:** Чуваш егете бит очкан

Космос хәтле космоска.

Чуваш телендә сәламләп,

Кул болгаган ул аска.

Ә хәзер уртанчылар төркеме балалары безгә чуваш халык уены “Ай белән Кояш” җырлы бию уенын уйнап күрсәтәләр.

Базарда ярминкәдә

Ике егет кайнаша.

Икесе дә тулпар сайлый,

Берсен-берсе узыша.

Ә тулпары кап-кара,

Йөгәне генә алтын.

Башындагы йолдызы –

Әйтерсен кызыл ялкын.

**Алып баручы:** Сәхнәдә мордва халкы вәкилләре.

*Мордвалар.*

**Мәрьям:** Очень интересны жить,

Очень весело дружить.

Если есть друзья –

Скучно жить нельзя!

**Ильяс:** Әйдәгез бергәләп,

Куллардан тотышыйк,

Җир шары – уртак йорт,

Шул йортта дус яшик.

**Әдилә.** Барлык милләт балалары

Җирдә дус булсын.

Бу очрашу күңелләрдә,

Йөрәктә калсын. *(Җир шары макетын кулларына тотып чыгалар.)*

**Алып баручы:** Тыныч булсын аяз күгебез,

Нур бөркесен көләч йөзебез.

Хуҗалары илнең үзебез,

Бердәмлектә безнең көчебез.

Күңелләрдә безнең бер теләк –

Дус яшик әйдәгез бергәләп!

*Барлык милләт вәкилләре сәхнәгә чыгалар.*

**Бергә:** Я, ты, он, она!

Вместе целая страна.

Вместе дружная семья.

Вместе мы – сто тысяч я!

**Алып баручы:** Рус, татар, башкорт, мордва,

Мари, чуваш, удмурт – бер гаилә.

Бер-беребезне хөрмәт итеп,

Яшәүләре рәхәт лә.

**Барысы бергә:** Әйе шул, шулай шул,

Яшәүләре рәхәт шул!

Нам все – хорошо!

*"Тынычлык турында җыр"ны җырлап кичәне тәмамлыйбыз.*

# “АЛТЫДА КЕРМӘГӘН – АЛТМЫШТА КЕРМӘС”

***Минневәлиева Эльмира Мәхмүт кызы***

*Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы*
*“Кукмара шәһәре җиденче номерлы “Кыңгырау”*
*һәрьяктан үстерелешле балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Әти -әниләр белән тәрбияви милли чара.**

**Алып баручы:** Хөрмәтле, әти-әниләр! Бүгенге тормышыбыз бер дә мактанырлык түгел. Үсмерләр арасында җинаятьчелек котырынып үсә, ата-ана үзенең төп вазифасын онытып бара, “ата – улны, ана – кызны белми”, кайбер балалар ата-анадан ваз кичә, икенче бер аналар үз балаларын ташлап китә. Яшьләр арасында дорфалык, тәртипсезлек, тупаслыкның чиге юк. Бу нилектән шулай? Без тәрбиядә нинди ялгышлар җибәрдек? Моны ничек төзәтергә? Балаларыбызны бәхетле итү өчен нәрсә эшләргә? Ә бит үткәнебезгә әйләнеп карасак, татар халкы гомер-гомергә эшчән, намуслы, тәртипле, әдәпле, кунакчыл, ачык йөзле булуы белән танылган. Матур гореф-гадәтләр, кунакка йөрешүләр, милли бәйрәмнәр уздырулар хезмәт кешесенә дәрт өстәгән. Өлкәннәрне аксакал дип йөрткәннәр, авыр хезмәт башкара алмасалар да, алар гаиләдә терәк булып саналганнар. Әйе, ата-баба мирасына күз салсак, без үзебез өчен бик күп гыйбрәтләр алыр идек. Дәүләтебез, милләтебез һәм балаларыбызның киләчәге үткәнебезнең иң яхшысын кире кайтаруга, аны яңартуга, ягъни тарихыбыз, мирасыбызны, татар халкының гореф-гадәтләрен, телен, аның элек-электән килгән бала тәрбияләү, гаилә кору, анда хезмәткә өйрәнү, тормышка әзерләү тәҗрибәсен янадан өйрәнүгә килеп тоташа. Без бүгенге чарада тормышта еш була, ләкин аларга игътибар бирми торган кимчелекләр һәм дә уңай яклар белән очрашырбыз. Күзәткән тамашалар турында үз фикерегезне әйтерсез.

*(Хәзерге татар авылы өенең эчке күренеше сүрәтләнгән.)*

**1 нче тамаша.**

**Катнашалар:** әби, ана, онык, күрше карчыгы *(рольләрне тәрбиячеләр башкара).*

*Ике карчык, сөйләшә-сөйләшә, чәй эчеп утыра. Ана (килен) чәй ясый.*

**Күрше карчыгы:** И, Мәрфуга ахирәт, киленең бигрәкләр дә уңган инде. Ул чәегезнең тәмлелеге, ипиегезнең йомшаклыгы!

**Ана:** Яратсагыз, ашагыз әле, каймагыннан да авыз итегез, балына да җитешегез.

*(Шул вакыт оныклары ашыгып кайтып керә, аяк киемнәрен төрле якка ыргыта.)*

**Оныk:** Уф, арыдым. Урам сугышында тәки теге өч малайларын җиңдермәдек бит, тукмадык кына үзләрен. Кара, узләре чәй эчеп утыралар, ә миңа бирмиләр. *(Зурлар арасына кереп утыра, аякларын селки, кашыкны алып өстәлгә бәрә).*

**Күрше карчыгы:** Исәнме, улым?

**Оныk:** Привет, бабуля!

**Ана:** И, улым, матурым, бигрәк ачыгып кайткан шул. Хәзер ашатам.

**Әбисе:** Әйе, хәзер заманалар узгәрде. Без яшь вакытта... *(Алып баручы шул вакытта алга чыгып баса һәм әти-әниләргә мөрәҗәгать итә.)*

**Сораулар:**

1. Әби ни әйтергә теләде?
2. Сез әни кешенең нинди яхшы якларын һәм кимчелекләрен күрдегез?
3. Татар халкында шундый сыйфатлар турында нинди мәкальләр һәм әйтемнәр бар?

**Жаваплар:**

1. Әби хәзерге яшьләрнең, балаларның тәртипсезлеге хакында әйтергә, үзләре яшь вакытта балалар белән зурлар арасында икенче төрле мөнәсәбәтләр булуын искә төшерергә жыенгандыр, бәлки?

2. Уңай яклар: килен кешенең күрше карчыгын аяк өсте сыйлавы, кунакчыллык, зурлар арасындагы үзара мөнәсәбәткә ихтирамы.

Кимчелекле яклар: баланың исәнләшә белмәве; сугышып кереп, мактанып сөйләве; бит-кул юмыйча, рөхсәт сорамыйча, зурлар арасына кереп утыруы, өстәл артында үз-үзен тота белмәве; әдәпсезлеге һәм олылар тарафыннан кисәтү ясалмау.

3. “Олыны олы итмәгән олыгайганчы игелек күрмәгән”. “Яман чир белән яман гадәт тиз йога”. “Аяк болгап шайтан чакырма”. “Баланы артык иркәләү типкәләүдән яман”. “Иркә бала – ир булмас”.

**Алып баручы:** Бу тамашада катнашкан бала үзен тәртипсез итеп күрсәтте. Аңа үз-үзен тоту кагыйдәләрен өйрәткәндә, төп өч шартны истә тотарга кирәк була: кагыйдәнең асылын, эчтәлеген аңлатырга, аны ничек үтәргә кирәклеген күрсәтеп бирергә, кагыйдәнең үзләштерелүен көн дә тикшереп торырга һәм үзеңә дә шул кагыйдәне истән чыгармаска кирәк.

**Музыкаль мизгел.** *Зурлар төркеме балалары сәхнәгә чакырыла. Алар белән “Чума үрдәк, чума каз” дигән жырлы татар халык уены оештырыла.*

*Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып төзеләләр, парлашып кулга-кул тотыналар. Рәт башында бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:*

Чума үрдәк, чума каз,

Тирән күлне ярата ул, ярата.

Әлфия үзенә иптәш эзли,

Белмим, кемне ярата шул, ярата.

Илназны ярата шул, ярата.

*Уйнаучылар, җыр ритмына туры китереп, хәрәкәтләнеп торалар. Ялгыз бала (Әлфия), рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм аны (Илназны) җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы рәт башына китә. Уен шулай дәвам итә.*

**2 нче тамаша.**

**Катнашалар:** әби, ана, онык (кыз). *(Әбисе оныгына яшь вакыттагы сандыгын курсәтә.)*

**Әби:** Менә бусы - чиккән сөлге, монысы түрләмә дип атала, аны элек өйнең буеннан буена эләләр иде, ә менә бусы, кызыл чәчәклесе, өстәл япмасы була.

**Кыз:** Әбием, рәсемнәре бирәк матур.

**Әби:** И, бәбкәм, рәсемнәр тугел ул, аны кияүгә чыкканда бирнә итеп төрледән төрле җепләр белән чиккән идем.

**Кыз:** Әйдә, әбием, эскәтерне өстәлгә ябып куйыйк, матур булып торсын. *(Өстәлгә япкач, сокланып карап торалар. Әнисе кайтып керә).*

**Ана:** Бусы ни тагын? Кем инде иске модадагы мондый әйберләрне яба? Кеше күргәнче, тизрәк алып куегыз, көләрләр.

**Кыз:** Аны мин җәйдем. Әле әбием мине шундый матур җепләр белән чигәргә дә өйрәтәм, диде.

**Ана:** Кит аннан, күз бетереп утырырга, матур-матур эскәтерләр белән базар тулы, акчаң гына булсын. Чигү чигеп утырганчы, китабыңны укырга өйрән. Әнкәй, син дә инде, әллә саташа башладың, сонгы вакытта гел шул иске сандыгыңны актарасың. **(Алып баручы әти-әниләргә мөрәҗәгать итә.)**

**Сораулар:**

1. Ана кеше нинди ялгышлар җибәрде?

2. Иске сандыклар сездә сакланамы һәм аларны нинди тәрбия чаралары итеп файдаланырга була?

3. Борынгы заманда яшь кызлар, киленнәр кичләрен нинди эшләр белән шөгыльләнгәннәр?

**Җаваплар:**

1. Ананың ялгышлары: олы кешенең хәтерен калдыруы, баланы эштән биздергеч сүзләр әйтүе, кул хезмәтенә үзе өйрәтергә тиеш булса да, ул турыда уйланмавы.

2. Иске сандык – әби сандыгы әле бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмый. Андагы әйберләрне балаларны әбиләребезнең элекке тормышлары белән таныштыру чарасы буларак, шулай ук

татар сәнгате аша эстетик тәрбия бирү өчен файдаланырга мөмкин. Сабыйларны чигәргә, тегәргә өйрәтү дә милли тәрбия бирүнең бер өлеше булып тора.

3. Борынгы заманда кызлар, аулак өйләрдә жыелып, кул эшләре өмәләре үткәргәннәр.

**Алып баручы:** Әйе, татар халкы гомер-гомергә эшчән халык булган. Аулак өйләрдә күңелле итеп кул эшләре оештырылган, жыр-музыка эшкә дәрт өстәгән. Шәл бәйләү, бирнәлекләр чигү, тегү кебек эшләр һәрвакыт кич утырганда башкарылган. Кечкенә кызларны да, кул арасына керә башлауга, һөнәргә өйрәтү максат итеп куелган. Әби янында тегәргә, чигәргә өйрәнеп үскән балалар тырыш, инсафлы, тәүфыйклы, йомшак телле булулары белән аерылып торалар.

**Музыкаль мизгел.** *“Аулак өй” темасына аерым күренеш күрсәтелә.*

**3 нче тамаша.**

**Катнашалар:** ата, ана, бала. **(Ана ашарга әзерли, ата кырын ятып, телевизор карый, бала әнисе янына килә)**

**Бала:** Әни, мин дә мәмәй пешерим әле?

**Ана:** Әй, эчемне пошырмасана. Сиңа эш кушсаң, бөтен өйне яңадан жыештырасы була. Бар әле, бар, әнә атаңның бер эше дә юк.

**Бала:** *(әтисе янына килә).* Әтием, бүген бакчада шундый кызык булды, сөйлимме? Әле яңа жыр да өйрәндек.

**Ата:** Күрмисең мени, арып кайттым. Әнә телевизор кара, футболның иң кызган вакыты, тәки безнекеләр жиңеләләр инде. *(Бала куңелсезләнә, кая барып сугылырга, ни эшләргә белми. Киштәдән нидер алмакчы була, ул ишелеп төшә. Тавышка ата белән ана йөгереп килеп җитәләр, бала елый башлый.)*

**Ана:** Уф, алла! Үләм инде мин синең белән! Бер эш рәте белмисен! Ни берәр уен уйнамыйсын! Ул бакчадагы апаларың ни генә өйрәтәләр соң сиңа?

**Сораулар:**

1. Гаиләдә баланы хезмәткә өйрәтүдә сез нинди кимчелекләр күрдегез? Татар гаиләләрендә бу эш ничек куелган булган?

2. Һөнәрле кеше турында сез нинди татар халык мәкальләрен беләсез?

**Җаваплар:**

1. Ата-ана баласын кече яшьтән хезмәткә өйрәтергә кирәклеген белми, аны кемдер башкарырга тиеш, дип уйлый.

2. Һөнәргә ир балаларны – ата, кыз балаларны – ана өйрәткән. Күпчелек бала әти-әнисеннән үрнәк алган, хәллерәк кешеләр балалары махсус һөнәр ияләреннән төрле һөнәрләр үзләштергәннәр.

3. “Һөнәрле – үлмәс, һөнәрсез – көн күрмәс”, “Алтыда кермәгән – алтмышта кермәс”, “Хезмәт төбе- хөрмәт”, “Һөнәрсез кеше кулсыз кеше” һ. б.

**Алып баручы:** Әйе, татар гаиләләрендә ата-ана балага кечкенәдән үк әдәп-әхлак кагыйдәләрен һәм һөнәр өйрәтергә бурычлы булган. “Бер генә кеше дә үз башына ниләр киләсен белми, шуңа күрә һөнәрнең һәрвакыт һәркайсы ярап куя”, - дигәннәр борынгылар. Үз баласына һөнәр өйрәткән өлкәннәрнең милләт каршында да изге вазифасы үтәлгән булып саналган. “Һөнәр өйрәткәндә ата-ана һич йомшаклык күрсәтергә тиеш түгел, гыйлем вә һөнәр өйрәткәндә нык куллы булу зарури”,- дип язып калдырганнар гыйлем ияләре.

**Музыкаль мизгел.** *Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән “Ефәк элдем читәнгән” дигән жырлы уен оештырыла. Балалар кулга-кул тотынышып кара-каршы ике сафка тезелеп басалар. Беренче рәттәгеләр икенче сафтагыларның каршысына таба барып түбәндәгечә җырлыйлар:*

Ефәк элдем читәнгә,
Җилфер-җилфер итәргә.
Без килмәдек буш китәргә,
Килдек алып китәргә.

*Икенче сафтагы балалар үз урыннарында торган килеш кулларын җыр ритмына селкеп каршы җырлыйлар:*

Алын алырсыз микән,
Гөлен алырсыз микән?
Урталарга чыгып сайлап
Кемне алырсыз икән?

*Беренче сафтагылар болай җавап бирә:*

Алларын да алырбыз,
Гөлләрен дә алырбыз.
Күңелебезгә кем ошаса,
Шуны сайлап алырбыз.

*Шулай дип җырлаган арада беренчеләр икенче сафтагыларның берсен үз рәтләренә алалар да кире үз урыннарына чигенәләр. Аннан соң җырны икенче сафтагылар башлап, каршы яктан үзләренә бер баланы алып китә. Уен шул рәвешле дәвам итә.*

**Йомгаклау сүзе:**

**Алып баручы:** Күрсәткән тамашалар нинди дә булса гыйбрәт алырга ярдәм итсә һәм бала тәрбияләүдә яхшы этәргеч ясаса, без бик шат булыр идек. Без бүгенге кичәбезнең темасын да юкка гына “Алтыда кермәгән – алтмышта кермәс” дип атамадык. Чөнки сабый иң саф, изге зат булып дөньяга килә. Алты яшькә кадарге вакыт аның өчен иң әһәмиятле чор. Галимнәр

раславынча, кеше үзе аласы белем һәм тәрбиянең 70 процентын 6 яшькә кадәр үзләштерә, калганын гомере буе тулыландыра гына. Бала туганның беренче көннәреннән үк алып барылган эчтәлекле тәрбия эше өзлексез давам иттерелгәндә үзенең җимешләрен бирә. Бала тәрбиялаүдә иң изге хәзинә – туган тел! Сөю, сабырлык, зирәклек курсәтсәк, ана сөте, изге ана теле балада әткә - әнкасенә, якыннарына, тереклеккә мәхәббәт, үзен чолгап алган дөньяны танып-белү теләге тәрбияләр. Балаларыбыз безнең киләчәгебез, аларны ничек тәрбияләсәк, безнең картлыгыбыз да шулай булачак. Безнеке генә түгел, милләтебез, илебез киләчәге дә алар кулында. Шуңа күрә сабыйларыбызны чын татар балалары итеп үстерү өчен көчебезне кызганмыйк. Барыгызга да исәнлек-саулык, эшегездә зур уңышлар, балаларыгызның сәламәт, эшчән, намуслы, кыю, зирәк, ипле булып үсүләрен, аларның сезгә шатлыклар гына китерүен телибез. Игътибарыгыз өчен рәхмәт! *(Чарадан соң әти-әниләр белән татар халык уеннары, биюләр оештырыла.)*

## “КЫЗЫЛ ЙОМЫРКА” БӘЙРӘМЕ

***Хисаметдинова Гөлнара Альберт кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*

*“Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы “Балачак” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** балаларны милли мәдәнияткә тарту.

**Бурычлар:**

-балаларны татар халкы фольклоры белән таныштыруны дәвам итү;

-милли уеннарга кызыксыну тәрбияләү һәм үстерү;

-туган телгә, туган якка мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** авыл күренеше, өйләр, су буе күренеше, кәрҗиннәр, бизәлгән чиләкләр, пешкән йомыркалар.

**Бәйрәм барышы:**

**Сафия**. Гөрләвек ага,
Кояш елмая,
Торналар үтте
Тезелеп бая.
Гөрләвекләрдә

Уйный үрдәк, каз.

Илне яшәртеп,

Шаулап килә яз.

**Радэль**. Елгада бозлар кузгалды...

Елмая, көлә кояш.

Урамнар буйлап атлый

Ямьле һәм күңелле яз.

**Ралина**. Яз килә! Яз килә!

Сыерчыклар килә!

Гөрләшеп, сайрашып,

Җырчы кошлар килә.

**1 нче тәрбияче:** Без бүген “Кызыл йомырка” бәйрәменә җыелдык. Ул нинди бәйрәм икәнен кем белә?

**2 нче тәрбияче:** Ул бәйрәмне яз көне, табигать уяна башлагач бәйрәм итәләр.

**1 нче тәрбияче:** Бу көнне төрле төсләргә буяп йомырка пешерәләр. Шул йомырка белән балаларны сыйлыйлар.

**2 нче тәрбияче:** Өйгә кем беренче керер икән дип, сынамышлар үткәрәләр.

**1 нче тәрбияче:** Бу бәйрәм хуҗалыкта тавык-чебешләр, башка кош-кортлар үрчесен өчен үткәрелә. Гаиләгә бәхет, тазалык-саулык килсен өчен дә ясаганнар бу бәйрәмне.

**2 нче тәрбияче:** Тагын әле өлкәннәр балаларны күзәткәннәр: исәнләшә беләме, кыюмы, тапкырмы, әллә инде оялчанмы. Ә балалар өлкәннәрнең ачыклыгын, кунакчыллыгын, юмартлыгын сынаганнар.

**1 нче тәрбияче:** Әйдәгез, без дә бергәләшеп бәйрәм итик, без дә бер-беребезне сынап карыйк.

Безнең якта бәйрәм бүген,
Бездә бүген тантана!
Өйдән-өйгә йөреп әнә
Күкәй җыя һәр бала.

*Бу сүзләрне әйтә-әйтә керәләр.*

Өйдәме түтәй,
Тизрәк бир күкәй.
Бирсәң безгә бер күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй.

*Зал буйлап баралар, беренче өйгә керәләр.*

Әби-бабай өйдәме?

Бер йомырка бирәме?
Әби күлмәгең чибәр,
Бер йомырканы чыгар!

**Балалар:** Рәхмәт, әбекәй!!!

*Икенче өйгә керәләр.*

Тавыгыгыз ояда,
Әтәчегез курада.
Берсе ак, берсе кара
Бир йомырка миңа да!

**Балалар:** Рәхмәт, әбекәй!!!

*Өченче өйгә керәләр.*

Чип-чип, чибәрүк,
Йомыркасы югарук.
Ак тавык, күк тавык,
Ходай бирсен күп тавык!

**Балалар:** Рәхмәт, әбекәй!!!

*Дүртенче өйгә керәләр.*

Ак тавыгың утырсын,
Сый һәм хөрмәт күп булсын!
Безгә күкәй биргән өчен
60 чебеш чыгарсын.

**Балалар:** Рәхмәт!!!

*Балалар ярымтүгәрәккә басалар.*

**1 нче тәрбияче:** Балалар һәрбер хуҗалыкта йореп чыгып, йомырка, күчтәнәчләр җыя торган булганнар, җыелышып шуларны санаганнар, чагыштырганнар.

**Динә:** Карагыз әле, Мәрьям апай, нинди матур итеп күкәйне буяган.

**Данир:** Ә Зәйтүнә апай тәмнүшкәләр пешергән, әйдәгез, бергәләп авыз итәбез!

**2 нче тәрбияче:** Ашап туйгач, балалар болынга күмәк уеннар уйнарга бара торган булганнар.

**Б.Риназ.** Әйдәгез, шушы хөрмәттән күмәкләшеп бер уйнап алыйк әле.

**Г.Диләрә**. Әйдәгез, “Капкалы” уенын уйнап алыйк.

*“Капкалы уены”*

**Г.Диләрә.** .... нинди җаза бирәбез?

**Балалар.** Шигырь сөйләтәбез!

Әнә килә автомобиль

Төягәннәр кыярлар

Борыныңны бик күтәрмә

Чиләк элеп куярлар.

**Г.Диләрә.** Уенны дәвам итәбез!

**Г.Диләрә.** .... нинди җаза бирәбез?

**Балалар.** Биетәбез!

**Г.Диләрә**. Уенны дәвам итәбез!

**Г.Диләрә.** .... нинди җаза бирәбез?

**Балалар**. Шигырь сөйләтәбез!

Ике песи суга бара

Көянтә-чиләк асып.

Ике тычкан карап кала

Капка төбенә басып.

**Г.Диләрә**. Уенны дәвам итәбез!

**Г.Диләрә**. .... нинди җаза бирәбез?

**Балалар.** Шигырь сөйләтәбез!

**Г.Диләрә.** Уенны дәвам итәбез!

**Г.Диләрә.** .... нинди җаза бирәбез?

**Балалар.** Җырлатабыз!

Җиләк җыям чиләккә

Дәү әнигә бүләккә

Ул бүләккә шатланыр

Мине тагын яратыр.

*Кушымта:* Бүләккә, бүләккә

Җиләк җыям чиләккә.

Бүләккә, бүләккә

Җиләк җыям чиләккә.

*Балалар ярымтүгәрәккә басалар.*

**Сафия**.  Әйдәгез, күкәй тәгәрәтеп уйныйбыз

*Балалар ярымтүгәрәккә басалар.*

**Бала.** Әйдәгез, “Чума үрдәк, чума каз” уйныйбыз .

*Балалар ярымтүгәрәккә басалар.*

**Такмаклар**

Идәнегез тигез икән
Фанер җәйдегез мәллә.
Килдегез дә утырдыгыз
Тамыр җәйдегез мәллә. **Алия**

Бие әйдә, бие әйдә,
Сындыр идән тактасын.
Сындырсаң идән тактасын
Хуҗа түләр акчасын. **М.Риназ**

Беләзегем-йөзегем
Киярмен әле үзем.
Сезгә ялынып тормыймын
Биермен әле үзем. **Г.Диләрә**

Бие әйдә, бие әйдә
Биегәнгә бер бәрән.
Әгәр бии белмим дисәң,
Кайтарам да җибәрәм. **Раян**

Агыйделнең суы ага,
Су астыннан ком ага.
Җырлыйбыз да, биибез дә,
“Күз тимәсен дип кара!” **Бергә**

**Бергә.** Онытмыйбыз йолаларны
Такмаклар, уеннарны.
Язгы матур бәйрәм белән
Котлыйбыз сез дусларны.

**1 нче тәрбияче:** Ә хәзер, әйдәгез, су буена барабаз, боз киткәнен карыйбыз.

# “САБАЛАРДА ЭЧӘР СУЫМ...” (ЧИШМӘ БӘЙРӘМЕ)

***Галиева Алия Рафаэль кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең гомуми үсеш бирүче төрдәге*
*5 номерлы Саба “Бэлэкэч”балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе»*

**Бурычлар:** Балаларга суның яшәү чыганагы икәнен төшендерү, тормышта чишмәләрнең әһәмиятен аңлату. Балаларның чишмә темасына сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру. Чишмәләргә мәхәббәт һәм сак караш тәрбияләү, табигатьнең матурлыгын, байлыгын күрә, аңлый белергә өйрәтү.

**Җиһазлау:** Ясалма чишмә, агачлар, чиләк, көянтә.

**Алдан эшләнгән эш:** балалар белән якындагы чишмәләргә экскурсиягә бару. Чишмә турында җырлар, шигырьләр өйрәнү.

**Бәйрәм барышы:**

*(Музыкаль язмада челтерәп аккан чишмә тавышы яңгырый. Балалар музыка астында залга керәләр.)*

**Алып баручы:** Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез,
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

Балалар, без бүген чишмә янына бәйрәмгә җыелдык. Һәр чишмәнең үз тарихы, үз моңы, үз юлы бар. Чишмә – суның яшәү чыганагы. Су бөтен тереклек ияләренә – үсемлекләргә дә, хайваннарга да, кешеләргә дә кирәк. Ә эчәр өчен чиста су гына кулланыла. Чиста су – бик кыйммәтле әйбер. Аны сакларга, урынлы файдаланырга кирәк.

**Бала:** Челтер- челтер чишмә ага,
Көмеш төсле сулары.
Су өстендә җем-җем итә
Көннең алтын нурлары.

**Бала:** Татлы сулы, затлы сулы
Чишмә була ул.
Тамчы булып чәчәкләргә
Тамып куна ул.

**Бала:** Безнең чишмә борыла-борыла,
Зур инешкә коела.

Идел суы шундый бик күп
Чишмәләрдән җыела.

**Алып баручы:** Ягез әле, балалар, чишмә янына якынрак килик. Тыңлыйк әле, ул ничек челтерәп ага. *(Челтерәп аккан су тавышы куела). (Көянтә, чиләк тотып чишмә янына әби килә.)*

**Әби:** Исәнмесез, балалар! Сез дә тәмле су алырга килгән идегезме? Чишмәнең суы искиткич тәмле, шифалы шул. Чишмәләр кечкенә генә булсалар да, табигатькә җан кертүчеләр, елга, күл, инеш, диңгез һәм океаннарга тормыш бирүчеләр. Чишмә яшәүдән туктаса, елга-күлләрдә су бетәчәк, авылда ямь калмаячак. И, балалар, без яшь чакларда кичләрен чишмә янына җыела идек. Уеннар, кичәләр оештыра идек. Безнең яратып уйнала торган уен “Яшерәм яулык” дип атала. Әйдәгез уйнап алабызмы?

*(“Яшерәм яулык” уены уйнала. Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында кулъяулык. Ул, түгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йөри:*

Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

*(Сүзләрне әйткәндә, бер баланың уч төбенә кулъяулыкны калдырып китә. Үзе түгәрәк эченә кереп баса. Кулъяулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кулъяулык салганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.)*

**Алып баручы:** Әбекәй, безнең балалар чишмә турында бик күп шигырьләр, җырлар, биюләр беләләр.

**Бала:** Чишмә суын мактый әби
“Тәнгә бик шифалы”, - ди
Самаварга җитми инде
Кирәкми “Тифаль” дә, - ди.

**Бала:** Бүгендә әбиебезгә
Чишмәдән су китердек.
Кайткан чакта чалбарларга
Түгеп- чәчеп бетердек.

**Бала:** Очраган бөтен кешегә
Әбидән сәлам әйттек.
Бер чиләк су алып кайттык,

Бер чиләк – сәламәтлек!

**Бала:** Чылтыр-чылтыр көмеш чишмә

Яр астыннан агадыр.

Әби көн дә тәмле чәйгә

Суны шуннан аладыр.

Көрәк тотып чишмәне мин

Чистартып кына торам.

Кыр-кырларына ташлар түшим,

Аннан ерганак ерам.

**Бала.** Әби әйтә: чишмә суы

Гади түгел, серле, ди.

Ул кешегә көч бирә, ди,

Ямьли туган җирне, ди.

*(Кызлар башкаруында бию “Суга баручы кызлар”)*

**Алып баручы:** Әби-бабаларыбыз заманында чишмәләргә игътибар зур булган. Аерым кешеләр чишмә-чыганакларны карап торган. Чишмәләрне күз карасыдай саклаганнар. Кеше исемнәре белән аталган чишмәләр шул караган кешеләрнең исемнәрен мәңгеләштергәннәр. Сабабызның яр буенда чишмәләр бик күп, шулар турында сөйләп китик әле.

**Бала:** Ерганак итәгендә

Шаулап “Вәликәй” ага

Сәфәргә китәр кешеләр

Туктап аннан су ала. (ВӘЛИКӘЙ чишмәсе)

**Бала:** Янгын чыгып, урам яна

Бары тик бер өй кала.

Бикет урамы халкы,

Ачы күз яшен юарга,

“Әмәнде”дән су ала. (ӘМӘНДЕ чишмәсе)

**Бала:** Кәли абзый улак куйган

Йорт янында чишмәгә

Капка төбендә салкын су

Яр буена төшмә дә. (КӘЛИ чишмәсе)

**Бала:** Каз куганда Бәдриҗамал

Яр буенда чишмә таба.

“Бәдеркәйгә соңрак ирләр

Бик матурлап улак сала. (БӘДЕРКӘЙ чишмәсе)

**Бала:** Төгәл исемен өлкәннәр
Аңлатып бирә алмый.
“Егор”, “Ягур” чишмәсен
Балалар күрми калмый. (ЯГУР чишмәсе)
**Бала:** Челтерәп аккан чишмә
“Челтер” дип исем алган.
Челтер чишмә исеме
Борынгылардан калган. (ЧЕЛТЕР чишмәсе)
**Бала:** “Чокыр” чишмәсе охшаган
Чәй салынган касәгә.
Суы мул, һич саекмас,
Бөтен Саба килсә дә. (ЧОКЫР чишмәсе)
**Бала:** “Изгеләр чишмәсе” ага
Иске зират аркылы.
Көч керткән юлчыларга
Саф суының салкыны. (“ИЗГЕЛӘР чишмәсе”-“ТАҢСЫЛУ”)

*“Болында” татар халык уены уйнала.*

*Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Бер бала (Халидә) уртада кала. Түгәрәктәгеләр әйләнә буенча бер якка хәрәкәт итеп, җыр җырлыйлар:*

Чәчәкләр үскән болында
Җырлыйбыз әйлән-бәйлән.
Халидә, Халидә,
Әйләнәсең кем белән?

*Халидә бер иптәшен уртага ала (Әминә). Җыр тагын кабатлана:*

Әминә, Әминә,
Әйләнәсен кем белән?

*Шул рәвешчә уртага 5-6 бала җыелгач, уртадагылар түгәрәкләнеп басалар да, кырыйдагыларга капма-каршы юнәлештә хәрәкәт итеп, барысы бергә җырлыйлар:*

Гөлнара, Гөлнара,
Син каласың уртада.

*Хәрәкәт туктала. Уртадагылыр күмәк рәвештә бер яраткан җырларын башкаралар. Аннан соң, Гөлнарадан башкалары кырый түгәрәккә басалар, һәм уен яңадан башлана.*

**Алып баручы:** Чишмәләр! Кайда гына юк та, кайда гына очрамый алар. Тау asларыннан, үзән-су җирләрдән өскә бәреп чыгалар да, үсемлекләр дөньясы, җирдәге тереклекне назга

төрергә, алҗыган тәнгә сихәт, көч бирергә теләгәндәй, һәркайсы үз көе, үз моңы белән туктауны белми ага бирәләр. Карагыз әле, безнең чишмәбез дә ничек челтерәп ага. Әйтерсең лә бер матур көй көйли. Әйдәгез чишмәбезнең җырына без дә кушылыйк.

*(“Чишмә” җыры. М.Җәлил сүзләре, Җ.Фәйзи көе)*

**Алып баручы:** Чишмәләр бик кадерле. Чүпләр ташланса, пычранса алар корый. Чишмәләр агып төшә торган елгалар, инешләр дә кибә. Су, дым булмагач үсемлекләр, агачларда корый, кошлар да оя кора алмый. Гомумән, табигать үлә. Шуңа күрә дә, булган чишмәләрне саклау безнең бурычыбыз.

## “ХУШ КИЛӘСЕҢ, НӘҮРҮЗБИКӘ!”

***Гәрәева Мәдинә Мансур кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*

*ш.т.б. Байлар сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге*

*Саба 2 нче “Әллүки” балалар бакчасы”*

*мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** яшь буында халкыбызның милли йолалары һәм традицияләре белән кызыксынуларын арттыру, балалар күңелендә милли бәйрәм рухы булдыру, бу бәйрәмгә карата эмоциональ яхшы хисләр тәрбияләү, бәйрәмдә актив катнашу теләге уяту.

**Бурычлар:** халкыбызның гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен белү, алар белән кызыксынуларын үстереп балаларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү. Халкыбызның милли бәйрәмнәре, йола уеннары, гореф-гадәтләре аша балаларның бер-берсе белән аралашу, коммуникатив осталыкларын, сөйләм телләрен баету.

**Алдан эшләнгән эшләр:** халкыбызның милли бәйрәмнәре турында булган белемнәрен ныгыту максатыннан чыгып, тематик әңгәмәләр кору, милли киемнәрне, татар халык ашларын чагылдырган рәсем, иллюстрацияләр карау, милли рухлы сюжетлы- рольле уеннар оештыру.

**Катнашалар:** мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, педагоглар, Нәрүзбикә, Кыш бабай, сыерчыклар ролендә балалар, Шүрәле, Убырлы карчык.

*Зал бәйрәм рухында, матур итеп бизәлгән. Арткы планда, матур язгы урман*

*күренеше сурәтләнгән. Агач башларында кара каргалар утыра, сыерчык оялары күренә, кар астыннан умырзаялар баш калкыткан... Урмандагы кошлар тавышы ишетелә... Талгын гына музыка астында залга бәйрәмчә киенгән балалар ярым түгәрәк ясап кереп басалар. (милли киемнәрдән киенгән татар кызы һәм татар малае алга килеп басалар, бәйрәмне башлап җибәрәләр.)*

**Татар кызы:** Исәнмесез, хәерле кояшлы, матур көннәр белән, хөрмәтле кунаклар, дуслар!

**Татар малае:** Хәерле, имин көннәр булсын хөрмәтле дусларыбыз!

**Татар кызы:** Менә сагынып көтеп алган бәйрәмебездә килеп җитте!

**Татар малае:** Хөрмәтле кунаклар һәм дусларым, сезне чын күңелдән бәйрәм белән котлыйбыз, бергәләшеп яз кызын - Нәүрүзбикәне каршыларга чакырабыз!

**Татар кызы:** Ә безнең балалар үзләренең матур җырлары, күңелле биюләрен дә алып килделәр, бик күңелле булыр бәйрәмебез!

**Татар малае:** Нәүрүзне каршылыйбыз дибез, гафу итегез, ләкин бу хакта бик хәбәрдар түгел шул, дусларым миңа бик кызык булып китте, аңлатып үтегез әле, нинди бәйрәм була соң ул ?

**Татар кызы:** Шәүкәт, дускаем, без сиңа бик теләп аңлатып бирербез бу хакта, бик күңелле итеп бәйрәмебезне дә үткәреп җибәрербез.

**Тәрбияче:** Нәүруз ул – язгы чәчү эшләре башланыр алдыннан үткәрелә торган бәйрәм. Ул игелек, дуслык бәйрәме. Бу бәйрәм халыкны элек-электән матурлыкка, тынычлыкка өндәгән. Көн белән төн тигезләшкән вакытта, язгы бәйрәмдә кешеләр бер-берсенә кунакка йөргәннәр, бер-берсенә булган үпкәләрен онытканнар, җырлап-биеп күңел ачканнар.

Борын- борын заманнан,
Болгар белән Казаннан.
Җаек белән Иделдән.
Бу бәйрәм безгә килгән.

**Татар малае:** Менә нинди матур, кызык бәйрәм икән, чыннан да язны барыбызда зарыгып көтеп алабыз бит, димәк тиздән яз җитә дусларым!!!

**Тәрбияче:** Бәйрәмне башларбыз да башлавын, ә бит көтеп алган бәйрәмебезнең төп хуҗасы юк бит әле. *(Күңелле, матур музыка көенә сыерчыклар булып киенгән балалар килеп керәләр)*

**1 нче сыерчык:** Исәнмесез, дусларым, исәнмесез... Хәерле, матур көннәр сезгә!

**Тәрбияче:** Исәнмесез, исәнмесез, канатлы дускайларыбыз, рәхим итегез..., рәхим итегез, без сезне зарыгып көттек...!

**2 нче сыерчык:** Дуслар, бездән сезгә хәбәр бар....сезнең бәйрәмегез була дип ишеттек, Нәүрүзбикәне көтәсез икән....

**Тәрбияче:** Канатлы дускайларыбыз, әйе, бик белеп әйтәсез, бәйрәмебезгә хөрмәтле төп хуҗабикәне Яз кызын, сагынган кунагыбызны көтәбез, ләкин нигәдер күренми шул әле.

**3 нче сыерчык:** Без сыерчыклар – яз хәбәрчеләре буларак Нәүрәзбикә дустыбызны канатларыбызда алып килергә чыктык кына, теге усал – явыз карчык юлыбызга аркылы чыкты, себеркесе белән әвәләп Нәүрүзбикәне тартып алып каядыр алып китте!!

**Татар кызы:** Менә сиңа мә.... эш харап....

**Татар малае:** Зифа, болай булмый... тизрәк Нәүрүзбикәне ул явыздан коткарырга кирәк!*(чыгып китәләр)*

*(Залга себеркесенә атланган убырлы карчык килеп керә)*

**Убырлы карчык**: Фу, фу, кеше исе килә..., кайларга килеп кердем соң әле мин, бер дә болай ялгышып йорми идем... картаям ахыры, болары кемнәр тагын моның, *( кунакларга)*. Сез кемнәр соң? *(җаваплар).* Әй, шулайдыр инде.... менә әле генә кәперәеп үзен дөнья гүзәленә санап йөрүче Нәүрүзбикә дигәннәрен дә урмандагы бер өйгә бикләп калдырдым әле, әх шәп булды... үзенә... йөрмәс монда мактанып... мин матур диеп... *( кулын каш өстенә куеп, кемнедер эзли, урман ягына табарак бара).* Күренми..... әле теге, шүрәле дигәннәре – урман сарыгы. Каядыр югалып йөри! Менә шушы урман авызында очрашырбыз диеп сөйләшкән идектә, югыйсә....*(телефонына карап)* Ватсаптан да тавышы килми, шалтыратмыйда әле бу.... басып торып булмас... *( агач төбенә утыра, шулвакыт урман ягыннан сулуы кабып, йөгереп Шүрәле керә.)*

**Шүрәле:** А-ха-ха-ха.. телефонымны харап иттем... югалттым... *(пышылдап кына балаларга карап),* теге явыз карчык яз кызын бәйрәмгә китермәү ягында бит.., кесәмдә телефоным.....

**Убырлы карчык:***(ишетеп алып).* Бирермен менә мин сиңа явызыңны. Миннән дә әйбәте, матуры юк әле монда...., менә үзең син урман сарыгы, адашып йөрисең анда... урманыңнан чыга алмыйча.

**Шүрәле:** Ой... әбекәй... гафу ит, гафу ит....зинһар. Безнең Саба урманнары бик зур, бик куе шул, адашырсыңда.... Менә каядыр шунда телефоным да төшеп калган бит әле. Шуңа күрә синең белән дә элемтәгә керә алмадым бит, борчылма.. менә килеп җиттем бит барыбер...

**Убырлы карчык:** Ха-ха- ха, шулайдыр инде урман сарыгы.. Хаман шул Сабаң белән мактанасың... Кайда юк ул куе урманнар...Бик күп алар...Сиңа караганда мин бик яхшы беләм ул урманнарны...Себеркемә атланып бөтен дөньяны гизәм, менә Себердә ул ичмасам урманнар...Очы-кырые юк...Оча-оча арып бетәм кайвакытта.

**Шүрәле:** Шулай инде әбекәй, мин дә үземнең туып үскән җирем – Сабамнан зарланып утырмыйм инде яме!....Һәркемгә үзенеке!!!Бөтен якыннарым, дусларым шунда яши бит, урманыбыз искиткеч!!!*(баш бармагын күрсәтеп)*

**Убырлы карчык:** Ярар, ярар, мактанып утырганыңны карарга килмәдем, теге кызыйны урмандагы бер иске өйгә ябып калдырдым. Килә алмый ул монда хәзер.....Ух шәп булды бу.... Бу адәмнәр мәнге суыкта утырачаклар хәзер....Ха-ха-ха-ха...

**Шүрәле:** Урманда нинди йорт булыр икән бу..., урманда бит әдәм затлары яшәми, анада без шүрәлеләр, һәм урман хайваннары гына яши, әнә күрәсеңме ул син әйткән әдәм затлары барысыда монда утыралар... *(кунакларга күрсәтеп)*

**Убырлы карчык:** Теләсә нишләсеннәр шунда, ул кызыкай монда килә алмый!

**Шүрәле:** Тукта, тукта син аны бит алайса урман каравылчысы өенә ябып калдыргансың инде, вәт булдыргансың инде алайса..!.

**Убырлы карчык:** мин аңа йоклата торган дару бирдем, ул кызыйның мәңгегә йоклап китүе дә ихтимал әле... юк... килә алмый ул монда...

**Шүрәле:** Син әбекәй, минем бик ачуымны чыгара башладың әле, бөтен табигатьне пыр туздырып ятырга җыенасыңмы, аның быел Кыш бабаеда үз вазыйфаларын дөрес итеп башкара алмады, инде килеп син монда бутап йөрисең...

**Убырлы карчык:** Әәә теге ак сакаллы картны әйтүеңме? Ай бик сынатты ул быел картлач... Бик зарландылар аннан...Аны да мин сихерләдем бит. Башы эшләп бетермәде, ха-ха-ха-ха, минем сихерле даруым аңа да килеште...!

**Шүрәле:** Нәрсә ди... Ах сине юньсез, ярамый бит, болай булмый..., табигать белән алай шаярырга ярамый, бу хәлне төзәтергә кирәк*!.....(убырлы телефонында уйнап утыра,шүрәле читкәрәк бара да кесәсеннән телефнын алып шалтырата)*

**Шүрәле:** Алло, алло, урман каравылчысымы бу, зинһар өчен Нәүрүзбикәне идән астыннан ачып чыгара алмассызмы икән, аны явыз убырлы шунда ябып куйган. Аны монда “Әллүки” балалар бакчасында балалар бәйрәмгә көтәләр *(кунаклар, балалар янынарак елышып).* Балалар, кунаклар, бердә борылмагыз, безнең урман каравылчысы, бик яхшы, батыр кеше, ул. “Нәүрүзбикәне хәзер кар чанасына гына утыртам да китереп җиткерәм”, - диде.

**Тәрбияче:** Балалар, сез сиздегезме, бу шүрәле бик әйбәт шүрәле икән, безгә ярдәм итәргә генә тора. Шүрәле дус, бик зур рәхмәт инде сиңа, ә бу явыз карчык безгә бәйрәмне үткәрергә комачаулар инде...Эш харап..

**Шүрәле:** Борчылмагыз дусларым, хәзер көйлим, җайлыйм, озатам мин аны, тик йөрсен шунда үзенең әкият дөньясында очып, себеркесенә атланып. Гафу итегез инде сез аны. Олы кеше, карт бит инде...Аңа бу хәл өчен җәза биреп булмас инде.

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез әле Нәүрүзбикәне коткарганы өчен киткәнче Шүрәлегә бер матур җыр башкарыйк.

*“Шүрәле” җыры башкарыла.*

**Шүрәле:** Әйдә, әйдә, әбекәй..... үз юлыбызда булыйк, китик тизрәк. Без бу адәми затларны барыбер җиңеп булмас. Әнә нинди матур итеп җырлап та күрсәттеләр.... *(Шүрәле һәм убырлы чыгып китәләр)*

**Тәрбияче:** Ә хәзер әйдәгез, тынычлап кунагыбызны чакырып карыйк әле.

**Балалар:** Нәүрүзбикә, Нәүрүзбикә!

**Тәрбияче:** Балалар, Нәүрүзбикәбез күренми әле, әйдәгез килеп җиткәнче сезнең бик матур шигырьләрегез бар бит, кунакларыбызны ардырмыйк, сөйләп күрсәтик әле.

*(Балалар шигырь сөйлиләр.)*

**Тәрбияче:** Дусларым, әйдәгез бергәләшеп җырлап алыйк.

*"Яз килә" җыры башкарыла.*

*(Залга башына чәчәктән такыя, матур яшел күлмәк кигән Нәүрүз кызы килеп керә.)*

**Нәүрүзбикә:** Исәнмесез, нәни дусларым, хөрмәтле кунаклар! Мин яз кызы – Нәүрүзбикә! Сезгә матур язлар, шатлык алып килдем, барыгызны да бәйрәм белән котлыйм!

Агымсулар кичтем мин,
Сезгә килеп җиттем мин,
Нәүрүз әйтеп, үттем мин!
Нәүрүз мөбәрәк булсын!
Инде мине тыңлагыз, моңаеп утырмагыз,
Уйнагыз да көлегез, биегездә җырлагыз!

**Тәрбияче:** Нәүрүзбикә, без синең көн белән төн тигезләшкәндә килгәнеңне дә белдек. Әйдәгез әле барыбыз бергәләп "Көн һәм төн" уенын уйнап алыйк.

*"Көн һәм төн" уены.*

*(Ишектән ах-ух килеп Кыш бабай килеп керә)*

**Кыш бабай:** Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, балалар!

**Тәрбияче:** Туктале, туктале....исәнме....бабакай...Бу ни бу...Син нигәдер монда ялгышып килеп кердең бугай....Безгә бит син тагын бер елдан соң гына киләм дигән идең....Безгә бит яз кызы килде, менә без шуны бәйрәм итәбез..

**Кыш бабай:** Ничек инде?!.Ә мин бит әле китмәдем, китәргә дә җыенмыйм әле. Карагыз әле, бөтен җиремдә кар ята. Ә алар бәйрәм итеп яталар... Хәзер...Карыйбыз менә кем көчлерәк булуын...

**Нәүрүзбикә:** Шып дисәм җилең тынар, карың елар, үзең кит кыш!

**Кыш бабай:** Кар яу, кар яу...

**Нәүрүзбикә:** Кояш чык, чык, чык...

Тәти кашык базарда...

Ботка пешәр казанда.

Батыр карны елак ит,

Җилең белән кунак ит!

**Кыш бабай:** Кара куна җиремә,

Уңа бара төсләрем.

Ай еладым, еладым..

Әле яшәп туймадым,

Юк.. юк... мин китмим!

Тартышмыйча гына биләмәләремне

Нәүрүзбикәгә бирү юк!

**Нәүрүзбикә:** Синең бөтен шартыңа да түзәм!

**Кыш бабай:** 1 нче шартым шул, менә кашык менә күкәй, тот кулыңны, чибәркәй! Синдә йөгер, миндә калмам. Кем узар бу ярышта? *(Ярышалар, Нәүрүзбикә җиңә)*

**Кыш бабай:** 2 нче шартым, әйдә биеп ярышбыз! *(татар биюе музыкасы куела, Кыш бабай егыла)*

**Кыш бабай:** Уф арыдым, сусадым....Харап булдым...Җиңелдем...Эредем бит...Эредем..

**Тәрбияче:** Ярар, бабакай, бердә борчылма әле син, син безгә тагын 1 елдан килеп җитәсең бит.

**Кыш бабай:** Дөрес әйтәсең, кызым, чыннан да китим мин, һәр нәрсәнең үз вакыты бит. Нәүрүзбикә кызым, тыныч күңел белән сиңа тапшырам табигатемне! Сау булыгыз!

*(Кыш бабай чыгып китә)*

**Нәүрүзбикә:** Әйдәгез, дусларым, бер уйнап, күңел ачып алыйк.

*Түгәрәктә "Яз килә" әйлән- бәйлән уены уйнала.*

**Нәүрүзбикә:** Дусларым, мине сагынып, көтеп алуыгыз өчен зур рәхмәт сезгә. Бигрәк уңган балалар икәнсез.! Җырлыйсыз, биисез, бик күңелле яшисез! Уңган, тырыш, хезмәт яраткан кешеләрнең генә теләкләре Нәүрүз бәйрәмендә кабул була. Хезмәт, тырышлык турында халкыбызның күп кенә мәкальләре бар. Ә сез аларны беләсезме?

*Балалар мәкальләр әйтәләр:*

-Эше барның ашы бар.

-Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

-Эш беткәч уйнарга ярый.

-Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

-Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй.

**Татар малае:** Нәүрүзбикә, җырладык та, уйнадык та ә хәзер син үзеңнең һөнәреңне күрсәт.

**Нәүрүзбикә:** Ярый, балалар, бик теләп, шатланып риза булып биим сезнең алда, мин биергә иптәш кызларымны да чакырам.

*Чиккән кульяулыклар белән бию башкарыла.*

**Нәүрүзбикә:** Ә хәзер әйдәгез, дусларым, бергәләп уйнап алыйк.

*"Без- без идек" уены уйнала.*

**Тәрбияче:** Дуслар, ниһаять табигатебезгә яз килде, тиздән бар җиһанга җылылык киләчәк, бөреләр ачылып беренче чәчәкләр күренәчәк, яз белән бергә канатлы дусларыбыз килер. Яз кызы безнең белән бергә булыр, ул үзенең җылы нурлары, түбәдән тамган тамчылары белән безне каршы алыр. Рәхмәт сиңа, яз кызы!!!

**Нәүрүзбикә:** Дусларым, көн белән төн тоташкан көнне кешеләргә бәхет телəгез, бер-берегезгә ягымлы булыгыз, матур итеп исәнләшегез, шул вакытта сез бәхетле булырсыз, шул вакытта гына күңелегезгә игелек нуры иңәр. Бәйрәмегез өчен бик зур рәхмәт! Табигатьне саклагыз, агачларны сындырмагыз, кош ояларын туздырмагыз. Бәхетле булыгыз дусларым!!!

*"Кояшлы ил" җыры башкарыла.*

**Кулланылган әдәбият:**

**"**Күңел ачыйк бергәләп" ("Мәгариф" нәшрияты)

**"КАЗ ӨМӘСЕ"**

***Абдреева Гөлназ Фадаэль кызы***

*Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы*

*Мөслим авылы "Ләйсән" гомуми үстерелешле балалар бакчасы*

*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:**

- балаларны татар халык бәйрәме – "Каз бәйрәме" тарихы һәм эчтәлеге белән таныштыру;
- музыкаль-театральләштерелгән чара аша балаларда татар телендә ирекле аралашу күнекмәләрен һәм сәләтләрен формалаштырырга ярдәм итү;
- балаларның иҗади активлыгын күрсәтергә, аларда патриотлык һәм Ватаннарына мәхәббәт хисләре формалаштыру, татар халкының мәдәни мирасын саклап калу һәм арттыру омтылышы булырга ярдәм итү;

**Җиһазлар:** 8 каз (кулдан ясалган), 8 каз канаты, бизәкле табак, 4 көянтә.

**Барышы:**

*Бүлмәнең бизәлеше элекке авыл өен чагылдыра. Катнашучылар татар милли киемнәреннән. Музыка астында бабай табак белән казларны күтәреп, дүрт кызны ияртеп залга керәләр.*

**Бабай.** Кызлар, менә сезгә казлар. Баш-аякларын, канатларын кистем. Яхшылап йолкыгыз.

*Кызлар эскәмиягә утырып каз йолкыйлар.*

- Әйдәгез, кызлар, эшкә тотыныйк.
- Әнвар бабай, казларны үзең суйдыңмы?
- Үзем, кызым, үзем.
- Син суйган казларның ите тәмле була шул *(бабай китеп китә).*

*Койма янына дүрт егет килә.*

- Исәнмесез, кызлар!
- Исәнмесез, егетләр!
- Кызлар, сез нишлисез?
- Каз мамыгы аерабыз,

  Борынгыдан килгән ул.

  Ястык, мендәр, түшәкләр.

  Татар өен бизәр ул.
- Кызлар, казларыгыз качмас, әйдәгез бер уйнап алыйк әле.
- Әйдәгез!

  *"Чума - үрдәк, чума - каз" уенын уйныйлар*
- Егетләр, кызлар, әйдәгез бер биеп тә алыйк.
- Әйдәгез!

  *"Каз канаты" җырына кызлар кулларына канатлар тотып малайлар белән парлашып биилләр.*
- Кызлар, әйдәгез, казларның эчләрен алып, чишмәгә барып юып кайтыйк. Егетләр, сез казларны көянтәгә эләргә ярдәм итәсезме?
- Әлбәттә, кызлар!

Иңнәрендә көянтә

Көянтәдә казлары

Бигрәк матур, бигрәк уңган

Безнең өмә кызлары.

Малайлар көянтә башларына казларны элләр дә, парлашып музыка астында чыгып китәләр.

# “ХУШ КИЛӘСЕҢ, ГҮЗӘЛ НӘҮРҮЗ!”

***Җәләлова Айгөл Әлфрит кызы***
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*“Катнаш төрдәге “Тургай” Норма балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:**

1. Балаларны татар халкының милли бәйрәме – “Нәүрүз бәйрәме” белән таныштыруны дәвам итү.

2. Халкыбызның борынгы уеннары аша балаларда йола-бәйрәмнәргә карата кызыксыну, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

3. Мәрхәмәтле, игътибарлы, әхлаклы балалар тәрбияләү.

**Бәйрәм барышы:**

**Алып баручы:** Исәнмесез, балалар! Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар! Менә салкын кыш та үтеп китте, ямьле яз җитте. Яз белән бергә Нәүрүз бәйрәме дә килеп җитте. Нәүрүз – язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Нәүрүз сүзе яңа көн *(ел)* дигәнне аңлата. Нәүрүз бәйрәме – ул игелек, дуслык бәйрәме. Бу гүзәл, язгы бәйрәм көнендә кешеләр бер-берсенә кунакка йөриләр, бер-берсенә булган үпкәләрен оныталар, җырлыйлар, бииләр, рәхәтләнеп күңел ачалар. Бу бәйрәмнең хуҗасы – Нәүрүзбикә. Нәүрүз котлы булсын!

*Җыр: “Хәерле көн”*

**Алып баручы:** Нәүрүз бәйрәме башланды, Нәүрүзбикә юк! Әйдәгез әле балалар, без аның турында шигырь сөйлик, бәлки ул килеп тә җитәр.

**1 бала:** Тып-тып тама тамчылар
Жырлап бәйрәм көенә
Бәйрәм бүген диеп хәтта
Тамчылар да сөенә.

**2 бала:** Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз! –
Язгы яңа елыбыз,
Яңа елда туры булсын,
Нурлы булсын юлыбыз!

**Алып баручы:** Күренми, әйдәгез бергәләп чакырабыз! Нәүрүзбикә!

**<u>Балалар</u>:** Нәүрүзбикә! Нәүрүзбикә, кил монда!

*Шомлы койгә Убырлы чыга.*

**Убырлы:** Хә, бәйрәм итеп яталар, ә мине чакырмадылар! Мин сезгә күрсәтермен әле! Яңа елда чакырдыгыз, ә яз бәйрәменә юк! Менә шуңа күрә, Нәүрүзбикәне сихерләп яшереп куйдым. *(Чыгып китә)*

**Алып баручы:** Балалар, нишлибез инде? Кем безгә булышыр икән? Яз җитте, кар сулары кырлар, таулар буйлап ага, су хуҗасы – Су анасы күрмәдеме икән? Аның чишмәләре бар җирдә дә агалар, күпне күрәләр, бәлки алар Нәүрүзбикәне дә күргәннәрдер. Әйдәгез әле балалар, язгы тамчылар турында җыр җырлыйк.

*Җыр: “Язгы тамчы”*

**Алып баручы:** Балалар ишетәсезме, ниндидер тавыш ишетелә.

*Матур чишмә чылтыравы көенә Су анасы чыга.*

**Алып баручы:** Су анасы, безнең Нәүрүз кызын явыз Убырлы карчык сихерләп яшереп тота. Мине Яңа ел бәйрәменә чакырдылар, ә яз бәйрәменә юк диеп ул безгә бик нык үпкәләгән.

**Су анасы:** Мин сезгә булышырмын. Ләкин иң элек сөйләгез әле миңа, нинди бәйрәм ул Нәүрүз бәйрәме?

**Алып баручы:** Балалалар, әйдәгез Су анасына Нәүрүз бәйрәме турында сөйлибез.

**1 бала:** Нәүрүз – язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган халык бәйрәме ул. Бу бәйрәмне 21-22 мартта, көн белән төн тигезләшкән вакытта үткәрәләр.

**Су анасы:** Ә сез яз турында мәкальләр беләсезме соң?

**Балалар:** Әйе, беләбез!!!

*Яз турында мәкальләр*

- Яз яме чәчәк белән, Көз яме келәт белән.
- Язгы хезмәт – көзге хөрмәт.
- Язгы көн ел туйдыра.
- Яз сөрерсең, көз урырсың.
- Яз кайгысын кыш кайгырт,
  Кыш кайгысын яз кайгырт.

**Су анасы:** Мин сезгә ярдәм итәрмен! Кошларым, очыгыз, Нәүрүзбикәне алып килегез!!! *(чыгып китә).*

*Кошлар тавышы көенә Нәүрүзбикә керә.*

**Нәүрүзбикә:** Исәнмесез, балалар, кунаклар! Мин – Нәүрүз кызы булам! Бәйрәм белән сезне!

**1 алып баручы:** Нәүрүзбикә, без бик шат сине кабат күрүебезгә. Сине каршылап, яз турында бик матур җырлар өйрәндек, балалар, әйдәгез матур итеп җырлыйк әле.

*Җыр: “Яз җитә”, “Сыерчык”*

*Кинәт бәйрәмгә Кыш бабай килеп керә.*

**Кыш бабай:** Исәнмесез, кадерле балалар!! Миннән башка бәйрәм итеп яталар.

**1 алып баручы:** Тукта әле, Кыш бабай, кызма. Безгә Яз кызы – Нәүрүзбикә килде, без аны каршылап бәйрәм итәбез.

**Кыш бабай:** Мин әле китмәгән, ә алар бәйрәм итәләр. Менә хәзер карарбыз, кем көчлерәк һәм җитезрәк!! Әйдә, Нәүрүзбикә, көчләрне сынап карыйк әле! Хәзер мин күрсәтәм кем көчле!

*“Аркан тарту” уены. Кыш бабай җиңелә.*

**Алып баручы:** Балалар, сез дә көч сынап карыйсызмы?

*(Балалар үзара аркан тартышалар)*

**Кыш бабай:** Туктагыз әле, туктагыз, әйдә әле Нәүрүзбикә биеп карыйк, кем матурырак биер икән.

**Нәүрүзбикә:** Әйдә, Кыш бабай, биибез.

*(Биегәндә Кыш бабай хәле бетеп егыла)*

**Кыш бабай:** Уф арыдым, эрим, агам, ярдәм итегез!

**Алып баручы:** Балалар, Кыш бабай эри, җилләтергә кирәк.

*(Балалар Кыш бабайга өрәләр)*

**Кыш бабай:** Менә күрдегезме җиңелдем. Нәүрүзбикә, кызым, син бик җитез, тырыш булып чыктың! Хәзер инде мин тыныч күңел белән китә дә алам. Исән-имин булыгыз! Бәйрәм белән! Сау булыгыз! *(Чыгып китә)*

**Нәүрүзбикә:** Сау бул, Кыш бабай! Тынычлап ял ит.

**Алып баручы:** Кыш бабайны озаттык, бәйрәмебез дәвам итә. Нәүрүзбикә, әйдә утыр әле, балалар сиңа бик матур җырлы уеннар әзерләделәр.

*Җырлы уен: “Матур уен”, “Түгәрәк уен”*

**Убырлы:** Туктагыз! Туктагыз! *(каты итеп кычкыра)*. Зинһар мине гафу итегез! Минем бәйрәмгә киләсем килгән иде. Мин шуны аңладым, Нәүрүзбикәдән башка яз килмәячәк, кышкы йокыларыннан җәнлекләр дә уянмаячак. Гафу итегез мине!!!

**Алып баручы:** Нәүрүзбикә, балалар, әйдәгез без аны гафу итик. Язга багышланган җыр җырлыйк.

*Җыр: “Яз килә”, “Весенняя полечка”*

**Убырлы:** Зур рәхмәт сезгә, балалар! Бәйрәм белән сезне! Нәүрүз котлы булсын**!** Уңышларыгыз бай булсын**!** *(чыгып китә)*

**Нәүрүзбикә:** Бик матур уйнадыгыз. Ә хәзер минем сезнең тапкырлыгыгызны тикшереп карыйсым килә. Ягез әле, табышмакларга җаваплар табып карагыз, игътибар белән тыңлагыз.

1. Боз һәм кар эреде
Сулар йөгерде.
Елап елгалар
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара
Бу кайсы вакыт
Я, әйтеп кара. *(Яз)*
2. Лампа түгел – яктырта,
Мич түгел – җылыта. *(Кояш)*
3. Борынсыз чыпчык боз тишә. *(Тамчы)*
4. Күктән килде, җиргә инде. *(Яңгыр)*
5. Үзе туңа, өйгә керми
Үзе елый да, елый. *(Тамчы)*

**Нәүрүзбикә:** Бик зур рәхмәт сезгә, балалар!

**Алып баручы:** Бәйрәмебез ахырына якынлашты. Бәйрәм белән сезне, балалар! Исәнлек-саулык, зур уңышлар телим сезгә!!

## “КАУРЫЙ БӘЙРӘМЕ” ФОЛЬКЛОР КҮРЕНЕШЕ

***Шакирова Гөлгенә Мөсәвир кызы***

*Татарстан Респбуликасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 8 нче номерлы балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

*(Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен)*

**Катнашалар:**

Хуҗабикә (тәрбияче)

Күрше

3 кыз

3 малай

*Йортта хуҗабикә эш эшләп йөри*

**<u>Күрше:</u>** Исәнмесез, саумысыз,

Әй хуҗалар, кайда сез?

Өмәчеләр килеп җитте,

Нигә каршы алмыйсыз?

**<u>Хуҗабикә:</u>** Күрми дә торам, әйдәге рәхим ит, түрдән уз, күрше! Менә өмә хөрмәтенә чәй әзерләп йөри идем.

**Күрше:** Эш эшләми торып, нинди чәй ди ул, күршекәем? Башта эшне бетерик, аннары эчәрбез. Кызлар килгәнче эшне башлап куйыйк. Башланган эш, беткән эш. Яшьләр безнең кебек оста каз каурые сыдыра да белмәсләр ул.

*3 кыз керә*

**<u>1 нче кыз:</u>** Карагыз эле сез боларны, нәрсә диләр, ә сез безне өйрәтегез.

**<u>2 нче кыз:</u>** Эйе шул, без башкара алмаслык эш булмас. Рәтен белсәк, туктата да алмассыз эле.

**<u>Күрше:</u>** Ышанабыз, ышанабыз. Баскан җирдән ут чыгара торган чагыгыз.

**<u>Хуҗабикә:</u>** Ягез әле, килегез бире. Менә, көз көне бергәләп суйган казларның каурыйлары монда. Электән үк, кышкы озын кичләрдә җыелышып каурый сыдырганнар. Чөнки карый мамыгы мендәрләрне тагын да кабартып җибәрә.

“Каурый өмәләре” бик күңелле үткән. Анда җыр-такмаклар, уен көлке дә, биюләр дә булган. Каурый сыдыруның үз хикмәтләре дә бар. Карагыз, каурыйны алабыз, йомшак башыннан тотабыз һәм әкренләп мамыкны тартып төшерәбез.

*Берничә каурыйны сыдырып күрсәтә.*

**<u>Күрше:</u>** Бу кадәр каурыйны үзебез генә ничек эшләрбез дип бик борчылган идек, ярый эле килдегез. Яхшылап эшләгез кызлар, егетләр уңган, тырыш кызларны яраталар.

*Җырлап эшлиләр “Каз каурые”*

**<u>3 нче кыз:</u>** Кызлар, карагыз эле, ә бу мамыклардан ясалган мендәрләр кемгә була ул?

**<u>1 нче кыз:</u>** Кемгә? Кемгә? Миңа булачак.

**<u>2 нче кыз:</u>** Ничек сиңа? Безгә дә кирәк йомшак мендәрләр.

**<u>1 нче кыз:</u>** Ярый инде, мин бит шаяртып. Сезне үртәп кенә әйтәм, кызлар.

**<u>Күрше:</u>** Менә мин кияүгә килгәндә пар мендәрләр белән килдем, бик куп еллар парлы яшибез. Әле әтисе егетләрне алырга дип киткән иде.

**<u>Егетләр:</u>** Сандугачның балалары

Талга кунганнар икән,

Кызларыгыз тырышып эшли

Бигрәк уңганнар икән.

**<u>1 нче кыз:</u>** Канат сатабыз, канат

Яхшысын сайла карап.

Егет булсаң канат ал,

Бер алтын чыгарып сал.

**<u>1 нче егет:</u>** Кыйммәт икән бер алтын,

Канатлар сездә калсын.

**<u>2 нче кыз:</u>** Егет саран булмасын,

Акча җәлләп тормасын,

Кем чын-егет шул алсын.

**<u>2 нче егет:</u>** Ягез, үзем алам.

**<u>3 нче кыз:</u>** Егетләр-кызлар алыш-биреш ясадык, әйдәгез уйнап алыйк.

*Җырлы-биюле уен уйныйлар "Парыңны тап", "Ал кирәк гөл кирәк", "Канат салыш уены"*

**<u>Күрше:</u>** Егетләр-кызлар, тагын бер йоласы бар. Канатлардан сыдырган каурыйларны су буена төшә торган юлга сибәргә кирәк. Икенче елга казлар күп булсын өчен эшләнә.

*Җырлый-җырлый каурый сибеп чыгып китәләр.*

*Тәмам.*

**"СУ БУЕНДА КИЧКЕ УЕН" КҮРЕНЕШ**

***Ибраһимова Ләйсән Габдрашит кызы***

*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы*
*Шәле авылы "Тургай" балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Татар халкының гореф-гадәтләре, йола-уеннары аша балаларның аралашу, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү һәм мәхәббәт тәрбияләү

*("Аулак өй" көе)*

**<u>Муз. җит:</u>**

Кумәк бию, уен көлке була кичке уенда.

Кызлар-егетләр жыела таллыкта, су буенда.

Пар табышлы, әсир алыш кичке уенда була

Таныштыра, дуслаштыра яшьләрне шушы йола.

Жырлар, биюләр өзелмәс, шатлык өстәр гармун да.

Үкенерсез килмәсәгез, кызык булачак монда!

*(“Аулак өй” көенә көянтә-чиләкләр тотып кызлар керә, сөйләшәләр)*

**<u>1 кыз:</u>** Кызлар! Әйдәгез, кичке уенга чакырабыз.

**<u>Барысы:</u>** Әйдәгез!

**<u>2 кыз: ______,</u>** кичке уенга чыгасыңмы?

**<u>3 кыз: _______,</u>** *тәрәзәдән карый һәм әкрен генә*. Хәзер чыгам. *(чыга)* Исәнмесез, кызлар!

**<u>Кызлар:</u>** Исәнме, **<u>(__________)</u>**! *(Егетләр читән артында утыралар һәм кызларны күзлиләр.* Берсе *тавышланмагыз* **<u>(________)</u>** *дип ишарә ясый*, икенчесе **<u>(________)</u>** *кинәт килеп чыга, калганнар аның артыннан*.)

**<u>Малайлар:</u>** А-ХААА! *(Кызлар куркып китәләр)*

**<u>1 егет:</u>** Исәнмесез, саумысыз!

Нигә кәҗә саумыйсыз.

**<u>2 егет:</u>** Әтәчегез күкәй салган,

Нигә чыгып алмыйсыз?

**<u>4 кыз:</u>** Әй, Әпсәлам, Әпсәләм!

Сәлам бирдем әссәлам!

Сездән безгә тиештер бит…

**<u>Малайлар:</u>** Сәлам!

**<u>Барысы кызлар:</u>** Шуннан?..

**<u>3 нче егет:</u>** Тугыз ким уннан…

**<u>Барысы кызлар:</u>** Шуннан?..

**<u>4 нче егет:</u>** Утырган да шуган…

**<u>Барысы кызлар:</u>** Шуннан?..

**<u>5 егет:</u>** Кишер белән суган..

**Барысы кызлар:** Шуннан?

**<u>6 егет:</u>** *(аптырап)* Егетләр, ярдәм итегез әле миңа!

*(Егетләр кул селтиләр. Җырларга җыеналар, бер-берсенә капма-каршы басалар.)*

**<u>7 егет:</u>** Егетләр, кызлар, әйдәгез әле, жырлап алыйк!

**<u>Барысы:</u>** *(торалар уртада басып, 2 төркемгә бүленеп җырлыйлар.)*

*“Такмаклар”Сафия кара әле көе*

1) **Бергә:** Без җырлыйбыз шаян җырлар,

Ә сез тыңлап торыгыз.

Әнә килә автомобиль -

Булыр безнең җырыбыз.

2) **Кызлар:**

Әнә килә автомобиль -

Төягәннәр калайлар.

Безнең авыл малайлары

Туксан яшьлек бабайлар. *(кызлар малайларга каршы 2 шәр тапкыр тыпырдап, кулга-кул яки алъяпкычларын тотып киләләр)*

3) **Малайлар:**

Әнә килә автомобиль -

Төягәннәр капчыклар.

Безнең авылның кызлары

Сиксән яшьлек карчыклар. *(егетләр кызларга каршы 2 шәр тапкыр тыпырдап, кулларын бер-берсенең иңнәренә куеп киләләр)*

4) **Бергә:**

Тыпыр, тыпыр, тыпырдашып

Бергә басаек әле.

Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,

Күңел ачаек әле.

**<u>5 нче кыз:</u>** *(алга чыгып)*

Булды-булды. Кызлар! Малайлар!

Без биредә бик шаулашабыз.

Әйдәгез, чишмәгә суга барабыз.

**<u>Барысы кызлар:</u>** Әйдәгез, әйдә!

**<u>Малайлар:</u>** Без дә барабыз!

**<u>Барысы кызлар:</u>** Юк, без сезне алмыйбыз!

**<u>Барысы малайлар:</u>** Барабыз!

**<u>6 нчы кыз:</u>** Әйдәгез, чиләкләрне алыйк.

*(Көянтә - чиләкләрен алып җырлый-җырлый биеп баралар)*

*“Су юлы” (татар халык жыры)*

1. **<u>(Кызлар)</u>** Әйдә, иркәм, алып барам -

Чишмәләргә, суларга;

Чишмәләрдән су алганда

Су чәчрәтеп уйнарга.

Ай, җаныем, суларда

Су чәчрәтеп уйнарга.

2. **(Малайлар)** Суда сусар йөзә микән, -

Салкын суга салмыйча?

Син бәгъремне сагынып көтәм,

Юлдан күзем алмыйча.

Ай, җаныем, суларда

Су чәчрәтеп уйнарга.

Ай, җаныем, суларда

*(Кызлар көянтә-чиләкләрен тотып горур басып торалар, (              ) аларга елгадан су алып бирә).*

**7 кыз:** Әйдәгез, уеннар уйныйбыз.

**Барысы:** Әйдәгез!

**8 егет:** Нинди уен уйныйбыз?

**8 кыз:** “Капкалы уен” ын.

**Алып баручы:** Яңа утырткан капканың

Баганасы бик шома.

Капка эләктереп калмасын

Ычкынырга чамала.

*(Бер кыз белән егет кулларын өскә күтәреп басалар, калганнар парлашып басалар, капкадан чыга башлыйлар. Капкачылар кемнедер тотып калалар. Җәза бирәләр).*

*Көй тала-тала уйный*

**9 кыз:** *(1 кыз      )* нишләтәбез?

**Барысы:** Җырласын.

**Барысы:** *(1 егет      )* нишләтәбез? Мәзәк сөйләсен.

- Юк, мин табышмак әйтәм.

Сырлы, сырлы, сырлы ул,

Безнең белән җырлый ул,

Биетә дә, җырлата да,

Күңелле ул, моңлы ул. Я, нәрсә ул, әйтеп карагыз?

-Гармун. Ә гармунда кем остарак уйный, ягез әле, егетләр *( Бер егет гармунда уйный “Бөрлегән”. Калганнар парлап әйләнәләр).*

*Уен дәвам итә.*

**Барысы:** *(Бу парны )* нишләтәбез? Биетәбез.

**10 кыз:** Кызлар, егетләр! Уйнадык та, җырладык та, биедек тә! Әйдәгез кайтыйк!

**Барысы:** Әй, кайтасы килми бит әле!

**10 кыз:** Кайтыйк инде, әни өйдә су көтә.

**Барысы:** Ярар! Әйдәгез!

*(Балалар түгәрәк буенча, парлашып, әкрен генә баралар)*

**Музыка җитәкчесе:** *"Бормалы су" көенә укый*

Айкалмасын, чайкалмасын
Китергән суларыгыз.
Кайсы йолдыз асларында
Йөргән юлларыгыз?!
Яшь чаклар бер чак,
Яшь гөлнең кадерен бел.
Ал белем, алга бар,
Белем гөле сүнмәс гөл.

*(Түгәрәк буенча барган вакытта, 1 кызны урлыйлар)*

**Музыка җитәкчесе:** *("Аулак өй" көенә Уйга калып.)* Бүген тагын бер пар кавышты. Бәхетегез булсын, балалар! *(Карап кала)*

## "ТУГАН ТЕЛЕМ – САЕКМАС ЧИШМӘ"

*(Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен әдәби-музыкаль кичә)*

***Сәйфуллина Гөлнар Рөстәм кызы***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 8 нче балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** халкыбызның борынгы гореф-гадәтләре, йолалары һәм милли бәйрәмнәре аша балаларда үз халкы белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Тәрбия бурычы:** балаларда милли горурлык, туган телгә мәхәббәт хисе тәрбияләү. Өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтү. Йола һәм гореф-гадәтләрнең алыштыргысыз тәрбияви чара булуын балаларга җиткерү.

**Үстерү бурычы:** балаларның сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, өйрәнгән шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйли алуларын, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү;

**Белем бирү бурычы:** бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, халкыбызның миллли киемнәре (яулык төрләре), халыкка хас әдәп кагыйдәләре белән таныштыру.

**Җиһазлау:** рус, татар, башкорт, удмурт, мари, чуваш халык костюмнары, түбәтәй, лента, йөзек, яулык, сары чәчәк.

**Кичә барышы**

*Зал бәйрәмчә бизәлә. Күңелле көй яңгырый, балалар залга кереп басалар.*

**Алып баручы:**

Торсак та без төрле җирләрдә,
Без яшибез Рәсәй илендә.
Сөйләшәбез төрле телләрдә,
Аңлашабыз дуслык телендә.
Үстергән дә безне чын дуслык,
Көч биргән дә безгә чын дуслык,
Дуслык булса булыр гомергә
Бөтен җир шарында тынычлык.

Туган ягыбыз – Идел буе. Анда бер-берсен аңлаучы, дус, тату милләтләр яши: татар, рус, чуаш, мари, башкорт, удмурт...*(һәр милләт үз исемен әйткәндә биеп залга керә)*

Төрле милләт төрле телдә сөйләшә
Аңлаша тик дуслык телендә.
Әйтә беләбез төрле телләрдә
“Исәнмесез”сүзен дә.

*Төрле милләт үз телендә “исәнмесез”сүзен әйтәләр*

**Татарлар:** - Исәнмесез!

**Руслар:** - Здравствуйте**!**

**Башкортлар:** -Хаумыһыгыз!

**Чувашлар:** -Лаих!

**Марийлар: -**Сайулда**!**

**Удмуртлар: -**Джеч буресь**!**

*“Моя Россия” җыры башкарыла*

**1 нче бала:** Карап тормый ара еракка
Дуслар килгән безгә кунакка
Дуслык бит ул – тормыш үзәге
Дуслык бит ул – бәйрәм бизәге!
Төрле костюмнар киеп,
Йөрербез җырлап – биеп.
Атадык без бу бәйрәмне
Дуслык бәйрәме, диеп.
**2 нче бала:** Төрле телдә сөйләшсәк тә,
Төрле милләт булсак та
Тик бер безнең туган илебез,
Тик бер безнең туган җиребез.
**3 нче бала:** Без бер илнең балалары,
Барыбыз да дуслар без.
Татарлар, чуваш, марилар,
Башкорт, удмурт, руслар без.
Туган җирем – Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган җирем кебек назлы,
Җырдай моңлы туган теле.
**4 нче бала:** Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә сайрый кошлар,
Туган телдә дәшсәм генә,
Туган җирем мине аңлар.
Туган телем-әни теле,
Иң борынгы бабам теле.
Буыннардан буыннарга
Күчеп килгән заман теле.
*“Туган тел” җыры башкарыла (Г.Тукай сүзләре)*
**5 нче бала:** Нинди таныш моңлы көй бу?
Тукай җыры – “Туган тел”.
Истән бер дә чыкмый торган
Халык көе – “Туган тел”.
**6 нчы бала:** Дөньяда иң матур ил
Ул-минем туган илем.

Дөньяда иң матур тел

Ул-минем туган телем.

**1 нче бала:** "Туган тел"-иң әйбәт шигырь.

**2 нче бала:** "Туган тел"-иң әйбәт китап.

**3 нче бала:** "Туган тел"-иң әйбәт җыр.

**4 нче бала:** "Туган тел"-иң әйбәт тел.

**5 нче бала:** Туган тел әйбәт булганга,

Шигыре дә, китабы да,

Җыры да әйбәттер!

**Бала:** Онытмагыз, бу дөньяда

Иң зур бүләк бер генә-

Көмеш чыңлы, талгын моңлы

Газиз туган тел генә.

**Бала:** Түгәрәктә матур итеп,

Без уеннар уйныйбыз.

Татарча матур итеп

Биибез дә, биибез!

*Татар халык биюе*

**Балалар бергә:** Әйдәгез, "Түбәтәй" уенын уйныйк.

*"Түбәтәй" уены*

**Җәзага:**

**1- такмак әйтсен:**

Исәнмесез, саумысыз.

Нигә кәҗә саумыйсыз?

Әтәчегез күкәй салган.

Нигә чыгып алмыйсыз?

**2 - атна көннәрен әйтсен:**

*Рус балаларының чыгышы*

**Алып баручы:** Россия-Россия, края дорогие!

Здесь издавна русские люди живут.

Они прославляют просторы родные,

Раздольные русские песни поют.

*Звучит русская народная музыка на сцену выходит дети в русском народном костюме.*

**Бала:** А мы живем в России

У нас леса густые

У нас березы белые,

И девочки красивые.

И небо наше чистое,

И реки наши быстрые.

**Бала:** У русских так заведено

Коль гости в дом приехали

Ты караваем их встречай

И от души всех угощай.

По обычаям русским всем поклон мы шлем вам низкий,

С добрым словом и любовью, с хлебом, солью.

Примите соль, примите хлеб,

Живите долго и без бед.

Пусть дом ваш будет полным,

Приветливым и хлебосольным.

*Под русскую народную мелодию представители русского народа ставят свои угощения на стол и садятся на свои места.*

**Бала:** Костюм на Руси был широким и скромным,

Был длинным, красивым и очень удобным.

Одежду короткую не надевали,

А длинные сарафаны в труде не мешали.

**Бала:** Нес костюм характер благочинный.

Был для всех свободным, строгим, длинным.

На Руси короткие одежды

Надевать не смели и невежды.

**Бала:** Из полотен вырубали пряхи

Длинные холщовые рубахи.

Ворот и подолы украшали,

Дивные узоры вышивали.

**Бала:** На узорах – травы, кони, птицы…

Выводили тонко мастерицы.

Вышивка людей оберегала –

Нечисть и болезни отгоняла.

**Бала:** Пояс на рубахи надевали,

Им себя от зла остерегали.

Ну а распоясаться, конечно,

Было стыдно, да и просто грешно.

**Бала:** Обо всем одежда говорила,

По одежде сразу видно было

Холост ли, женат? Откуда родом?

Возраст, ремесло и связь с народом.

**Бала:** Наша Родина большая

И на свете лишь одна

Где же есть еще такая

Необъятная страна

**Алып баручы:** Друзья мои, а русский народ очень веселый и задорный, любит играть в подвижные игры. Я предлагаю вам поиграть в русскую народную игру “Заря - заряница" – это Богиня утра. Русские люди ее почитали, уважали, называли «красною девицей», верили, что она прогоняет зло.

**Кагыйдә:** *Игроки становятся лицом в круг и держат руки за спиной. Водящий ходит по кругу за спинами игроков со словами:*

Заря - заряница, красная девица,

По полю ходила, ключи обронила,

ключи золотые, ленты голубые!

*С последними словами водящий кладёт ленту одному из игроков, игрок заметив это быстро берёт ленту и они бегут в разные стороны, чтобы вперёд занять пустое место. Кто останется без места, становится водящим.*

*Мари балаларының чыгышы*

**Бала:** Без матур Мари Республикасыннан килдек. Башкалабыз - Йошкар-Ола.

**Бала:** Өстебездә чигелгән күлмәк,

Бил бау, алъяпкыч булыр,

Башыбызда-тиредән башлык,

Калфак килешеп торыр.

**Бала:** Кайсы якта яшәсәк тә,

Дуслык кирәк һәркемгә.

Дуслар булса янәшәдә,

Дошманлык булмас җирдә.

*Мари халык уены “Йөзек кемдә, күгәрчен?”*

*Башкорт балаларының чыгышы*

**Бала:** Без Башкортостаннан килдек. Башкалабыз – Өфе шәһәре. Республикабыз игенчелек, терлекчелек, умартачылык белән шөгыльләнә.

**Бала:** Алып килдек сезгә, дуслар,
Күчтәнәчкә башкорт балы.
Салкын тиеп китсә әгәр,
Безнең бал ул бик шифалы.
*Башкорт уены “Тирмә”(“Юрта”)*
*Чуаш балаларының чыгышы*
**Бала:** Чуашстан Республикасыннан килдек без. Башкалабыз – Чебоксар шәһәре.
**Бала:** Ак һәм кызыл төсләрдән
Тегелгән костюмыбыз.
Тәнкәле тухчяны без
Бәйрәмнәрдә киябез.
*Чуваш халык уены “Тили-рам, бездән сезгә кем кирәк?”*
*Удмурт балаларының чыгышы*
**Бала:** Ә без Удмурт Республикасыннан. Башкалабыз - Ижау шәһәре.
У*дмурт халык уены “Италмас”*
**Алып баручы:**
Дус яшәргә кирәк җир йөзендә
Дуслар кирәк һәрбер кешегә
Дуслык булса, яшәү дә күңелле,
Уңай була һәрбер эшең дә.
*Дуслык вальсы башкарыла*
*“Дуслык турында җыр” башкарыла*
**Алып баручы**: Туган җиребез дус яшәүче милләтләре белән горурлана ала.
Һәрвакыт күркәм булыгыз
Авырмагыз беркайчан.
Кайгыларга бирешмәгез,
Шатлыклар йөрсен алдан.

Һәркемнең Үз теле, үз йөзе, үз төсе,
Бер җыр- аз, бер моң- аз, Бер тел- аз,
Йөз телдә сөйләшеп үсегез!

Якты матур киләчәк, бергә тату, тыныч тормышта яшик!
-Саубулыгыз! *(төрле телдә саубуллашалар).*

## “ХӘТЕР САНДЫГЫ” МИЛЛИ БӘЙРӘМ

***Мостафина Рәмзия Сөләйман кызы***
*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы*
*“47 нче санлы гомуми үстерелешле балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** балаларны татар халкының онытыла барган гореф-гадәтләрен хәтердә яңарту һәм саклау, элекке чорның матурлыгын күрсәтү, йолалары һәм милли киемнәре белән тирәнтен таныштыру. Туган телебезгә, милли традицияләргә мәхәббәт тәрбияләү.

**Бурычлар:**
- балаларны халкыбызның милли бәйрәмнәре, йолалары, гореф-гадәтләре белән таныштыру;
- җырлы – биюле уеннарга кызыксыну уяту;
- халкыбызның көнкүреше, яшәеше, кул эшләре, татар милли киемнәренә, бизәкләре белән таныштыу. Үз халкыңның хезмәте белән горурланырга өйрәтү;
- уеннарда аралашу аша сүзлекне һәм мөстәкыйльлекне үстерү, аралашу тирәлеген киңәйтү;
- халкыбызның традицияләре белән горурланырга өйрәтү.

**Җиһазлар**: мич, сандык, караваt, лампа, чигелгән сөлгеләр, бизәнү әйберләре, өс-киемнәре, өстәл, урындыклар, рус-халык уен кораллары, музыкаль бизәлеш.

**Катнашалар:** Әби – Рәмзия Сөләймановна**,** онык – Ясминә Хузеева

**Татар блогы -** 9 нчы төркем балалары

**Чуваш блогы**- Богдан Ларионов 11 нче төркем баласы, Ирина Александровна бакчабыз хезмәткәре

**Керәшен блогы -** тәрбиячеләр

**Рус блогы** - 8 нче төркем балалары

**Бәйрәм 3 күренештән тора.**

Әсәрне язучы автор һәм куючы режиссёр: Мустафина Р.С.

**1 НЧЕ КҮРЕНЕШ**

*(Зал авыл өе кебек итеп бизәлгән: тәрәзәләрдә борынгы челтәрләр; тәрәзә араларында кызыл башлы сөлгеләр, чиккән кашагалар; уң якта-караваt, аңа челтәрле ямпа ябылган, чигүле мендәрләр куелган. Сул якта-мич, мич янында-кисәү агачы, табагач сөяп куелган, алъяпкыч эленгән. Мич алдында җиз комган, чүлмәк тора. Түрдә-сандык; алдарак-самовар, чәйнек һәм татар халык ашлары (өчпочмак, чәк-чәк, кош теле, түгәрәк ипи, чынаяклар) куелган, борынгы ашъяулык япкан өстәл. Сандык өстендә чигүле япма. Идәндә сугылган паласлар җәелгән. Караваt янында-чаршау, келәм)*

*(Автор башкаруында “Әбиемнең күңел сандыгы” дигән шигырь язмада яңгырый).*

**Әбиемнең күңел сандыгы!**

Нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме,
Нинди серләр саклый икән ул?
Әбиемнең күңел сандыгын
Бер ачасы иде, ачасы…
Әби-бабам белгән йолаларны,
Халкыбызның күңел җәүһәрләрен
Бер ачасы иде, ачасы.
Әбиемнең күңел сандыгы
Кызыктыра инде күптәннән.
Ач, әбием, безгә күңелеңне,
Яшь буынга мирас булып калсын,
Бер хәзинә калсын үткәннән.

*(Әби казлар куып, оныгы белән килеп керә.)*

**Әби:** Аййййй, арытты да соң кызымммммм, әйдә әле, әйдә ял итеп алыйк әле бераз, син дә утырып ял ит кызым, чәйләр дә эчеп алырбыз. Ohhh, *(утыралар)* **.**

*(Кулына бәйләмен алып оныгына оекбаш бәйли-бәйли сөйли башлый)*

**Әби**: Кайталар да җитәләр шул, казларны әйтәм. Матур елгада йөзеп, ашап йөрсәләр ни була? *(Уйга чума).* Йә, шушындый матур тормышта яшәвемә мең рәхмәтлемен Аллахыма! Рәхмәт. Ашарга дисән – ризык, эчәргә дисәң – чәй бар. Барысы да җитәрлек, Аллага шөкер. Сәламәтлегем дә зарланырлык түгел. Аллага шөкер! Балаларым да кеше арасында оятка калырлык итмәделәр. Яхшы гына укып, гаилә корып шәһәрдә көн күрәләр. Тик сирәгрәк кайталар шул. Эш кешеләре бит. Аның каравы онықларым һәрвакыт кайтып йөриләр, шулай бит, кызым *(оньк үзе килә, оныгын сөеп ала).*

**Оньк**. Әйе, әбием. Без сине гел сагынып кайтабыз яныңа *(оныгы ялгыш сандык өстенә менеп утыра)*

**Әби:** Ай, Аллам, балакаем, сандык өстенә утыргансың түгелме соң? Төш балам, төш, ярамый! Бу кызым, гади генә сандык түгел шул, бик серле сандык *(сандыкны сыйпап).* Мин аны яратып, ахирәтем сердәшем дип йөрим. *(кеткелдәп ала).*

**Оньк**: Серле? Синең сандык янында еш кына уйланып утырганыңны күргәнем бар минем. Нинди серләр бар анда, әбекәем, сөйлә әле, сөйлә индеееее.

**Әби:** *(торып басып)* Бу сандыкка бик күп еллар инде балам, безнең нәселнең тарихын саклый ул. Ул миңа минем әбиемнән калды. Дөрес, хәзер бик ачмыйм, бары тик җилләтер өчен генә ачкалыйм. Аның эчендә мин иң кадерле, иң изге истәлекләрне саклыйм. Кая әле сиңа да күрсәтим әле, кызым. *(сандыкны ачып).* Яшь вакытта бик матур күренәсе килә бит ул, менә яшьлегем хәтирәләре булган, кадерләп саклаган әйберләрем шушында инде, кызым. Яшь чакта кигән күлмәгем. *(сандыктан матур күлмәк, һ. б. алып күрсәтә).* Алъяпкычым да бар иде, алка-беләзекләрем дә сакланган, менә алар. Кара әле нинди матурлар.

**Онык:** Әйе , бик матур шул.

**Әби**: Кичләрен, шушы матур күлмәкләребезне киеп, кичке уеннарга төшә торган идек. Ә аякта чигүле читек. Эххххх, ул яшь вакытлар *(уйга кала).*

**2 НЧЕ КҮРЕНЕШ**

**1) Татар блогы**

1. “Кәрия –Зәкәрия”
2. “Кунакка йөрү”
3. Татар халык биюе

**2) Чуваш блогы**

*(Өйгә бер бала йөгереп керә )*

**Онык**: Әбекәй, кара әле, минем янга дустым Богдан керде.

**Әби**: *(торам)* Иии, шулай мени, кызым, бик әйбәт, “Дуслык- зур байлык” – ул. Кем малае буласын син улым? Әниеңнең исеме ничек? Как маму зовут?

**Малай**: Ирина исемле.

**Әби**: *(торып басып)* Син әллә теге минем дус кызымның (ахирәтемнең), Татьянаның оныгы буласыңмы?

**Малай**: Әйе, әбекәй.

*(Богданның әнисе Ирина керә, үз телләрендә сөйләшәләр)*

**Ирина:** Богдан, ты гдее? (на чувашском языке.) Исәнмесез, әби. Хәлләр ничек сезнең?

**Әби**: Әйбәт, кызым, әйбәт, Аллага шөкер. Уз әйдә.

**Ирина:** Богдан, я же тебя обыскалась. А ты здесь, оказывается (на чувашском языке).

**Әби**: Әстәгафирулла, гел әниең икән бит син, бик ошагансың. Ирина, без әниең белән яшь вакытта бик дуслар идек. Бер – беребезгә бик матур шигырьләр сөйләп күңел юата торган идек. Шушы шигъри юллар әле дә сандыгымда саклана,кая әле,алып күрсәтим әле,менә алар **(язмаларны күрсәтә).**

**Ирина:** Да, все верно. Моя мама очень любила стихи рассказывать и до сих пор удивляет своими занимательными рассказами. И меня с детсва этому учила. Хотите и вам расскажу, әбекәй?

**Әби:** Яле, яле кызым.

**(Ирина үз телендә шигырь сөйли)**

**Әби**: Булганнан бар да була шул. Үз телегезне онытмыйча саклап яшисез, әфарин, кызым!

**Ирина**: Рәхмәт. Сау булыгыз.

**Әби**: Сау бул, кызым. Әниеңә миннән зууур сәлам әйтерсен. Исән – сау йөрегез.

*(Чыгып китәләр)*

**3 НЧЕ КҮРЕНЕШ**

**3) Керәшен блогы**

**Онык:** Әбием, тагын дус кызларың бар идеме синең?

**Әби: (утырам).** Бар кызым, бар. Хәтерлим, элек, бер бииик якын керәшен дус кызым бар иде, Анна исемле. Мин анарга яратып якын итеп **(Анный)** дип йөртә торган идем **(көлеп куя).** Аның чаялыгы искиткеч сикереп сикереп биюләре әле дә күз алдымда тора. Аның миңа истәлек итеп биргән чиккән яулыгын күрсәтим әле сиңа , кызым **(сандыктан алып күрсәтә).**

**Онык:** Бик матур шул.

**Әби**: Керешәен халкының бик күркәм, йолалары, бәйрәмнәре бар кызым. "Бердәмлектә – көч" балам, без бииик тату яшәдек **(кызымны янıма утыртам).**

*(Кызлар башкаруында, керәшен җыры һәм халык биюе)*

*(Өстәл янында онык белән мәш килү)*

**4) Рус блогы**

*(Кызы белән чәй эчәләр)*

**Әби:** Әйдә әле, кызым, чәй эчеп алыйк әле, әйдә әле. Бер кызыклы вакыйга исемә төште бит әле, сөйлим әле үзеңә, оныгым, әйдә әле утыр әле, утыр. Урысчам такы токы булса да, эткәйгә ияреп, аның күрше рус авылында Ычтапан исемле дусты бар иде. Шуларга еш кына кунакка бара торган идем. Аларның да балалары бар иде. Бик җырга – моңга бай гаилә. Әтиләре балалайкада, әниләре думбрада, балалары әтиләре ясап биргән **(САНДЫКТАН АЛЫП)** менә шушындый агач кашыкларда **(агач кашыкларны шакылдатып алу)** уйнап кәнчирт куя торган иделәр. Әй өздереп тә уйный иделәр. Колагымда әле дә яңгырый шул моңнар (уйга калып) *(Балалар тарафыннан, рус халык уен коралларыннан оештырылган оркестр һәм күмәк бию).*

**Онык:** Рәхмәт сиңа, әбекәй, күңел сандыгың бик бай икән. Бик күп кызыклы нәрсәләргә өйрәндем, бик зуур рәхмәт сиңа

**Әби**: Әйе, кызым, төрле милләт халкының күңелле бәйрәмнәрен, гореф – гадәтләрен һәм йолаларын белергә һәм сакларга кирәк. Аларны халык белә, хөрмәт итә икән, димәк милләт яши, милләт яшәгәч тел яши, кызым. Ягъни, тормыш дәвам итә. Сер итеп кенә әйтәм, бу

сандыкны мин сиңа калдырырмын дигән идем, кызым. Мине искә алырсың, балаларыңа да күрсәтерсең. Нәсел җебе өзелмәсен идеее, балакаем! Кояш җир йөзен  үзенең якты нурлары белән җылытып торсын! Дөньялар тыныч, имин булсын! Сугыш афәтләре күрергә язмасын! Дус булыйк, бердәм яшик! Бердәмлектә бит көч булуын онытмыйк!

Дус яшәргә кирәк җир йөзендә

Дуслар кирәк һәрбер кешегә

Шуңа күрә кирәк дөнья буйлап

*Дуслык орлыкларын чәчәргә! (Бергә әйтү.)*

(Күмәкләшеп Халыклар дуслыгы биюе  белән төгәлләү, Флешмоб.)

**(Тәмам)**

## “КАРГА БОТКАСЫ” МИЛЛИ БӘЙРӘМЕ

***Гыйлметдинова Нәзирә Зөфәр кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*

*“Арча 8 нче балалар бакчасы”*

*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларны ата-бабаларыбызның милли бәйрәме, аның тарихы һәм халык тормышындагы әһәмияте белән таныштырырга.

**Бурычлар:**

- Татар халкының көнкүреше һәм мәдәнияте белән кызыксынуны үстерергә.
- Бәйрәмне әзерләүдә һәм үткәрүдә балаларның үзләренең, әти-әниләрнең  катнашу активлыгын үстерү.
- Шигырьләрне, әкиятне сәнгатьле итеп сөйли белү күнекмәләрен камилләштерү

**Җайланмалар:** магнитофон, түбәтәй, ашъяулык, балалар саны буенча кашыклар.

**Башлангыч эш:** "Карга боткасы" бәйрәме турында балалар белән әңгәмә; татар телендә чакыруларны һәм җырларны өйрәнү.

**1 Алып баручы**: Исәнмесез, кадерле кунаклар. Татар-халык календаренда иң популяр, иң күңелле язгы бәйрәмнәрнен берсе, һичшиксез, карга боткасы.

**2 Алып баручы**:  Борын-борын заманда кешеләр нилектән җирдә яз булганын белмәгәннәр, ди. Алар ямьле җылы яктан кара каргалар алып килә икән, дип уйлаганнар.

**1 Алып баручы**: Борынгы заманда кешеләр язны канатларында каргалар китерә дип уйлаганнар. Шуңа күрә каргалар килеп төшкәч, халык “карга боткасы” бәйрәмен оештыра. Кошлар килүгә һәм язга алар әнә шулай шатландылар.

*Залга Карлыгач (Сәйдә) очып керә*

**1 Алып баручы:** Карлыгач, Карлыгач, сөйкемле Карлыгач. Син кайда идең? Нинди хәбәр китердең?

**Карлыгач:** Диңгез аръягында булдым. Язны чакырдым, сезгә яз алып киләм.

*Музыкага яз керә*

**Яз:** Саумы, нәни дусларым, Сезне сагынып килдем мин. Сезгә аяз көннәр дә, Янгыр да китердем мин.

**1 Алып баручы**: Исәнме, яз!

*“Хәерле көн” бию*

**Карлыгач:** Безгә каргалар очып килде

Кар-кар кычкыра алар

Барыбызны да болынга чакыралар.

Син дә кил минем дустым

**Диана:** Ямьле, бик ямьле Туган илебез . Килегез, кошлар, Безгә килегез!

**1 Алып баручы:** Бу көнне балалар матур итеп киенгәннәр. Бергәләшеп өйдән-өйгә йөргәннәр, йомырка җыйганнар.

**2 Алып баручы:** бәйрәм көнендә балалар матур итеп киенгәннәр, өйләрдән өйләргә кереп йомырка һәм төрле ярмалар җыйганнар. Аннары аланда учак ягып, төрле ярмалардан ботка пешергәннәр, ә ботка пешкән арада кунакларны җырлап чакырганнар, әйлән-бәйлән уйнаганнар, ярышлар һәм халык уеннары оештырганнар. Без дә бүген биербез, күңел ачырбыз һәм уйнарбыз.

*Җыр “Кил син язым”*

*Залга әби керә*

**Әби:** Исәнмесез, балалар.

**Балалар:** Исәнмесез, әби.

**Әби:** хәлләр ничек?

**Балалар:** Әйбәт, рәхмәт.

**Әби:** Менә мин дә килдем, ярма, тоз, май, йомырка, он китердем. Исәнмесез, кадерле балалар! Хәерле көн сезгә, хөрмәтле кунаклар! Мин – Әминә әбисе, “Карга боткасы” бәйрәменә килдем. Балалар, карагыз әле, каргалар җылы яклардан очып килгәннәр. Табигать кышкы йокыдан уянганда, карлар эрегәндә, елгалардан сулар акканда, кешеләр “Карга боткасы” бәйрәмен үткәрә иде. Татар авылларында балалар авыл буйлап йөгереп,

кунакларны чакырдылар, азык-төлек җыйдылар. Шуннан соң бөтен халык елга буена аланга җыелып бәйрәм башлаганнар. Биегәннәр, җырлаганнар, уйнаганнар, һәм, әлбәттә инде, тәмле ботка пешергәннәр.

**2 Алып баручы:** Балалар, әйдәгез, без дә уйнап алыйк. Башта ботка пешерү өчен азык-төлек җыйыйк. Аннан соң казанда ботка пешерербез.

*“Капчык” уены.*

*(Балалар түгәрәк буенча азык-төлек атыйлар)*

**1 Алып баручы:** Бигрәк акыллы балалар, барысында беләләр. Менә без боткага кирәкле бөтен әйберләрне дә җыеп алдык. Менә кунаклар бар да бар: май да, ярма да. Ботка бик тәмле булыр.

**2 Алып баручы:** Әби бик юмарт. “Карга боткасы” пешерергә вакыт җитте дип уйлыйм. Әби, безгә ботка пешерергә булышырсызмы?

**Әби**: Әлбәттә, балалар. Мин ботканы пешерергә куйыйм, сез күңел ача торыгыз.

**1 Алып баручы:** Ботка пешкән арада әйдәгез “Чума үрдәк, чума каз” уенын уйнап алыйк

*“Чума үрдәк, чума каз”*

*Карлыгач һәм песнәк очып керәләр (үпкәләгәннәр)*

**Песнәк**: Сез монда җырлыйсыз, уйныйсыз, ә безне чакырмадыгыз. Каргалар очып килде – сез аларны каршы алдыгыз, кунаклар каршыладыгыз, ә безнең турыда онытттыгыз.

**Алып баручы 2:** кошлар, зинһар, безгә үпкәләмәгез. Безнең белән калыгыз.

**Карлыгач:** Яхшы. Без сезнең белән уйнарбыз, сез безнең табышмакларны чишегез.

**Песнәк:** Ак һәм чал иде, ә яшел һәм яшь килде. (Кыш һәм яз)

**Карлыгач:** кар эри, болыннар җанлана. Көннәр озая, бу кайчан була? (Яз)

**Песнәк:** Нинди язгы кара кош Сабан артыннан ашап йөрергә ярата? (Кара карга)

**Песнәк:** Сикерергә һәм очарга, ипи белән бөртекләрне чукырга ярата. Чик-чирик дип исәнләшә. (Чыпчык)

**2 Алып баручы:** Табышмаклар өчен рәхмәт сезгә, кошкайлар. Балалар ә сез безгә кунакка нинди кошлар килгәнен белдегезме?

**Балалар:** Әе! Әйдәгез бер биеп алыйк әле.

*“Татарча бию”*

**Әби:** Кунаклар, уеннарыгыздан туктап торыгыз ботка пеште. Балалар ботка пеште.

**2 Алып баручы:** Хөрмәтле дуслар! Иң күңелле язгы бәйрәмнәрнең берсе “Карга боткасы” бәйрәме ахырына якынлашып килә. Рәхмәт сезгә!

**1 Алып баручы:** Хөрмәтле кунаклар, татарыбызның милли бәйрәме “Карга боткасы” ахырына якынлаша һәм ахырда без "Кояшлы ил" җырын башкарырбыз

*"Кояшлы ил"*

**2 Алып баручы:** Без барлык кунакларга да зур рәхмәт әйтәбез. Балаларны Карга боткасыннан авыз итәргә чакырабыз.

## “ОРЧЫК БӘЙРӘМЕ”

***Гыйләҗиева Алия Васыйл кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*“Арча 8 нче балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** балаларда татар халкының җырлы-биюле уеннарына, йолаларына, татар халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияләү

**Алып баручы:** Балалар, элек кышкы көннәрдә, әти-әниләре кунакка киткәч, яшьләр җыелышып аулак өй оештырганнар, шул ук вакытта яшьләргә “Орчык бәйрәме” дә күрсәткәннәр. Әлеге өмәләрдә алар җырлаганнар да, уеннар да уйнаганнар, эрләгән җепләре ап-ак булсын өчен кызларны карда ауната торган булганнар, төрле тәм-том пешереп сыйлаганнар.

**Алып баручы:** Борын заманнарда ук көзге уңышларны җыеп алгач, авылларда орчык өмәсе үткәрелгән. Бу өмәне бигрәк тә кызлар көтеп алганнар. Анда алар үзләренең уңган-булганлыкларын күрсәткәннәр. Шаян сүз, җыр-бию, уеннар белән аралашкан, эш бик тиз барган.

**Алып баручы:** менә бу – каба, бусы – орчык, кул белән җеп эрләү коралы. Бер башы тупыйк, икенче башы нечкә итеп эшләнгән таякчык. Белгәнебезчә, элек тукылган кием кигәннәр. Тукыма туку өчен йоннан җеп эрләргә кирәк. Бер пот җеп эрләр өчен 955 сәгать кирәк булган, шуның өчен кызларны 5 яшьтән җеп эрләргә өйрәткәннәр. Ш.Перроның “Йокыга талган кыз” әкиятендәге кыз да җеп эрләгәндә орчыкка кадалып йокыга китә.

*Хәзер “Орчык бәйрәмен” башлыйбыз.*

**Әби:** Кызым, бар иптәш кызларыңны чакырып кайт. Әти-әниләр кунакка китәләр, буген бездә аулак диген. Иптәш кызларың үзләре белән орчык-кабаларын да алып килсеннәр, сез җеп эрләрсез, мин сезне бер тәм-том пешереп сыйлармын.

**Кыз:** ярый, әбием, хәзер чакырып кайтам.

*(Кыз иптәшләрен чакырырга китә)*

*Чакырылган кызлар исәнләшеп, өйгә керәләр. Әби кабаларга йон бәйли. Кызлар җеп эрләргә утыралар. (Кызлар эшкә тотыналар)*

**Кыз:** Әйдәгез, кызлар, җырлап эшлик эле

*("Җомга" җырын җырлыйлар)*

**Әби:** бик матур җырладыгыз, яшь чакларым исемә төште. Без яшь чакта мәкальләр дә әйтешә идек, сез беләсезме?

Кызлар мәкальләр әйтәләр, әби аларның мәгънәсен аңлата.

1. Эш беткәч – уйнарга ярый.
2. Кем эшләми – шул ашамый.
3. Ашаганда авызың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен.

**Әби:** Нинди уңган-булган икән бу кызлар, бик күпне беләләр икән. Әйдәгез, бераз ял итеп чәйләп алыйк.

*(Чәй эчәләр)*

**Кыз:** никтер күңелсез булып китте, нигә малайлар килми икән безнең "Орчык бәйрәме"нә? Әллә белмиләр микән ?

**Әби:** Белми калмаганнардыр, килерләр. Аңарчы мин сезгә табышмаклар әйтә торам:

*(Каба, орчык, самовар)*

**Әби:** рәхмәт, кызларым.

*Ишек шакыган тавыш ишетелә.*

**Малай:** без дә өмәгә килдек. Җепләрегез ак булсын, җепләргез нык булсын, шуның өчен хуҗа кызны карда аунатып керәбез.

*Балалар такмак әйтешәләр.*

**Малай:** кызлар, әйдәгез, безнең яраткан уеныбыз "Капкалы"ны уйныйк.

**Кыз:** "Орчык өмәсе" булгач, "Орчык тәгәрәтү" уенын да уйныйк (орчык кемдә туктый, шул балага җәза бирелә)

**Әби:** Иии, балалар, таң атарга да күп калмаган, таралышырга вакыт җиткән. Икенче өмәгә кадәр исән-сау булыйк.

## “КИЧ УТЫРУ КҮРЕНЕШЕ” (ӘНИЛӘР БЕЛӘН БЕРГӘ)

***Нуретдинова Зимфирә Солтан кызы***

*Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре*
*“Балаларны һәрьяклап үстерү төрендәге*
*14 нче номерлы “Әкият” балалар бакчасы”*
*муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

*Зал бәйрәмчә бизәлгән: стеналарда татар халкының киемнәре, залның бер почмагында борынгы өй күренеше. Анда сандык, өстәл, эскәмия, ясле. Алар өстендә суккан паласлар, чигешләр, самовар ( борынгы), тәрәзәләрдә чигешле пәрдәләр.*

*Алгы планда – өй эче күренеше. Анда кич утырырга килгән кызлар чигү чигәләр җыр җырлыйлар. Җыр тавышы акрыная.*

*“Хәерле иртә” көе яңгырый.*

*Бәйрәмчә киенгән кызлар һәм малайлар залга керәләр, ярымтүгәрәк ясап басалар.*

**Алып баручы:** Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар, хөрмәтле балалар! Бүген без сезнең белән 8 мартка багышланган кичке уенга җыелдык. Куңелегезгә шатлык, тәнегезгә исәнлек-саулык, өегезгә иминлек телим, бәхетле булыгыз.

Балалар, дәү әнине бәйрәм белән котлап , кич утырырга барасыгыз киләме?

**Балалар:** килә. (*Тын гына музыка уйный, балалар җитәкләшеп дәү әни өенә юнәләләр.)*

*Малайларны, кызларны кич утырырга килгән кызлар, дәү әни каршы ала.*

**Алып баручы:** дәү әни, без сине бәйрәм белән котлап, кич утырырга килдек. Һәм сиңа оныкларың күчтәнәч алып килде .

*Җыр “Дәү әнигә бүләккә” (утыралар*)

**Дәү әни:** рәхмәт яусын, оныкларым, күңелләрем йомшарып китте.

**Онык:** Дәү әни, әйдә безгә, үзеңнең борынгы истәлекләреңнедә күрсәтеп, алар хакында сөйләп кит әле.

**Дәү әни:** Хәзер оныкларым, чәй генә куям да. Әйе, минем сандыкта буыннан-буынга тапшырылган истәлекләр саклана. Әйдәгез, сандыкны, бергәләп ачып минем яшь чакларыма кайтып килик.. *( борыңгы сандыгын ача.) (Әби йөзек, алка чыгара.)*

Балкып тора алкаларым,
Бизи кулны йөзегем.
Тәңкә чыңын ишеткәндә
Өзгәләнә үзәгем.

Менә бу йөзек, бабагыз бүләге, бик, бик кадерле бүләк ул минем өчен. Йөзек салыш уены уйнаганда, син минеке дип бүләк иткән иде. Сугыш кырында ятып калды бабагыз. Күпме еллар үтсәдә, җиңү көне җиткәндә күңелләрем әллә нишли шунда. *(елап ала)*

**Онык:** Дәү әни, әйдә, бабайның бүләге белән бездә йөзек салыш уйнап алабыз.

**Дәү әни:** әйдэгез, улым, уйнап алыйк, бабагызда бик шатланыр.

*Уен "Йөзек салыш" (әниләр, оныклар уйный)*

**Дәү әни:** бигрәк күңелле булды . *(Шул чакта күрше әби килеп керә)*

**Күрше әби:** Исәнмесез, саумысыз! Нишләп ята икән күрше? *(балаларны, әниләрне күреп)* Күршем, синдә кунаклар бар икән бит!

**Дәү әни:** Кунакларым бар шул, күршекәй. Бәйрәм белән котларга оныкларым килде.

**Күрше әби:** Мин сине кич утырырга чакырырга кергән идем, яшь чакларны искә төшереп, йон эрләрбез дигән идем.

**Дәү әни:** Син үзең кал бездә, күршекәем, күрәсеңме ничек күңелле бездә.

**Күрше әби**: ярар, күршекәем, калырмын да шул.

**Дәү әни:** Әйдә әле, күршекәем, бер утырып дога кылыйк. *(Әбиләр дога укыйлар)*

*Балалар: (әмиин әйтәләр)*

**Дәү әни:** Менә күршекәем, оныкларыма сандыктагы истәлекләрне күрсәтеп утыра идем әле. Эх, хәзерге яшьләр элекке без уйнаган уеннарны уйный белмиләр шул. Заманаларны шушы телевизор, компьютер, телефон дигән зәхмәт басты бит...

**Күрше әби:** Шулай шул, бик дөрес сөйлисең, күршекәем. Һәрбер кеше үз өендә бикләнеп тик утыра. Күршекәем, син бит түбәтәйләр тегәргә, чигәргә бик оста идең. Күрсәтеп кит әле.

**Дәү әни:** Менә ул, оныкларым, бабагызга кияү бүләге итеп теккән идем бу түбәтәйне. *(сандыктан түбәтәй чыгара)* Шушы өйгә килен булып төшкәч кигезгән идем, саклап кына киде җаным ничә еллар буе.

**Күрше әби:** Күршекәй, бу түбәтәйне күргәч чишмә буенда уйный торган "Түбәтәй" уены искә төшеп китте бит әле, әллә уйнап алабызмы балалар?

**Балалар:** Әйе.

*"Түбәтәй" уены уйнала. (Уен барышында түбәтәй кемдә кала, шул бала җырлый, бии, сикерә, әтәч булып кычкыра һәм башкалар).*

**Дәү әни:** Шул чишмә буенда Камилемне беренче тапкыр күргән идем дә инде.

**Күрше әби:** Искә төшермә әле, шул кичне сине урлап та китте бит ул. Без Наза түтәйгә әйтергә куркып беткән идек.

**Онык:** Ничек инде урлады сине бабай?

**Дәү әни:** Безнең заманда шулай иде шул, кызым, ошаткан кызны димләп *(яучы – сорап килүче)* алганнар, йә булмаса урлап киткәннәр.

**Онык:** Бабаем бик яраткан инде сине, дәү әнием, әле син сабантуйда бабайга чиккән сөлге дә бүләк иткән идем дигән идең, ярышта беренче килгәч, күрсәтеп кит әле безгәдә. *(Әби сугылган сөлге чыгара*). Искиткеч бит бу, дәү әнием, нинди матур чигелешле сөлге. Минедә бу осталыкка өйрәт әле, дәү әнием.

**Дәү әни:** өйрәтәм, кызым, бик шатланып .

Батырларга сабантуйда

Бирелгән сөлге-бүләк.

Их ,биисе килеп китте.

Әйдәгез әле, кызларым, биеп алыйк әле.

*Бию "Сөлге чигәм" (әниләр биюе)*

**Дәү әни:** Менә бу истәлектә бик күптәнге, бабам мин тугач ясаган булган, үзем үскән бишек... Ул да миңа бик кадерле. *(моңлана)* Улым белән кызымда шул бишектә үстеләр, күршекәем.

Әниемнән күчкән туган тел,

Әбиемнән күчкән саф күңел,

Әнием моңлы көе белән

Безне бишектә көйләгән.

*Җыр "Әлли-бәлли бәү" (әни кеше үзенең кызын итәгенә утыртып җырлый)*

**Дәү әни:** Рәхмәт, кызым, сезне үстергән чакларым күз алдыма килде. *(кочаклап ала онык белән кызын)*. Менә бу көянтәләрне дә иң башларыма салып каз, үрдәкләрне чайкарга су буена бара идем кызлар белән.

*(Салмак кына татар көе башкарыла, кызлар биергә чыгалар.)*

*Бию "Каз канаты"*

**Күрше әби:** Барысыда шундый уңганнар. Барысыда шундый булганнар оныкларың.

Йөзләре кояш кебек

Торалар нурлар сибеп.

*Бию "Кульяулыклар юабыз"*

**Дәү әни:** Әйе, минем оныкларымда зур устеләр шул. Рәхмәт сезгә, оныкларым, керләремнедә юып куйдыгыз. Чү, күрсәтми калам бит *(читек чыгара).*

Бизәк төшкән итекне

Читек дип йөргәннәр.

Аларны татар кызлары

Бәйрәмнәрдә кигәннәр.

**Дәү әни:** күршекәй, синнән дә оста биюче бар идеме икән? Әйдә, бер биеп күрсәт әле матур читекләрне киеп.

**Күрше әби.** Юк, юк күршекәй, ояламда, аякларымда тыңламас

**Онык :** Күрше әбекәй,

Койма аркылы таяк тыгып

Кемне абындырасың.

Бие дигәч, биемисең,

Кемне ялындырасың.

*Бию "Бас, кызым, Әпипә" (Бию көе яңгырый. Әби ,балалар биилəр.)*

**Күрше әби:** Бигрәкләр дә күңелле булды, яшь чакларыбызда искә төште. Ярый әле кергәнмен. Болай булгач гореф-гадәтләребез югалмый, аларны дәвам иттерүчеләребез бар. Рәхмәт сезгә, балалар!

**Алып баручы:** Бәйрәм, бәйрәм булмас иде,

Бергәләп биемәсәк.

Әниләрне чакырабыз

Хәзер биергә, димәк.

Дәү әни, күрше әбекәй, әниләр, балалар, кунаклар, әйдэгез бергәләп уенга чыгыгыз, биеп җырлап алыйк.

*Уен "Наза" (бергәләп уйныйлар)*

**Дәү әни:** Оныкларым, кунаклар сез бик арып киткәнсездер, тамакларыгыз да ачкандыр, әйдәгез, бергәләп коймак белән чәй эчик тә ятарбыз, ял итәрбез.

*( коймак белән чәй эчу)* Бәйрәм тәмамлана.

**"ӘБИДӘ КУНАКТА"**

***Җиһаншина Чулпан Фирдинанд кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 8 нче балалар бакчасы"*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

Барышы

***( слайд капка төбе )*** *(Өй күренеше, капка төбе)*

*(Балалар музыка астында тезелешеп керәләр)*

**Алып баручы:** Балалар, менә без әбигә килеп життек, ишеге бикле икән әбинең, әйдәгез шакып карыйк әле (*ишек шакыйлар- Ишетми*). Ишетми әби, бик каты коймак пешерә ахры, әйдәгез ул чыкканчы бер уйнап алабыз. Уйныйбызмы балалар? (*Балалар уйныйбыз диләр)*. Без сезнең белән “Ачык авыз” уенын уйныйбыз (*түгәрәккә басабыз парлашып, беребез артына беребез, музыка уйный арттагы кызлар уртага чыгып бииләр, алдагы малайлар урыннарында басып кул чабалар, музыка туктый балалар урыннарына барып басалар. Бер бала парсыз кала, ул уртага килеп баса –сорыйбыз бу кем диеп, балалар –ачык авыз диеп кычкыралар).*

*(Ишек артыннан әби чыга)*

**ӘБИ:** Исәнмесез, балалар, ишетмичә дә торам икән сезне.

**БАЛАЛАР:** Исәнме әби, без сиңа кунакка килдек.

**ӘБИ**: Бик әйбәт, мин сезне күптән көтәм инде. Әйдәгез, түрдән узыгыз, балалар. Сезне сыйлыйм дип төрле-төрле тәмле ризыклар пешереп куйдым, балаларым. Әйдәгез, өстәл артына утырыгыз. Менә шулай (*өстәл артына утыралар).* Өчпочмаклар, бәлешләр, өлешен дә пешердем балалар. Ә коймакларын авыз итегезче.

**Фәридә:** Коймагы да коймагы,
Агып тора каймагы.
Табада пешеп тора,
Табынга тешеп тора.
Кайнар! – ялан кул тотма,
Тәмле! – телеңне йотма.
Син телең йотсаң, Нәбирә,
Кем рәхмәт әйтер әбигә?

**ӘБИ:** И рәхмәт инде, кызым, матур сүзеңә. Бигрәкләр дә мактап җибәрдең үземне. Ашап утырыгыз, балалар. Әйдәгез, бер дога кылыйк та.

**БАЛАЛАР:** Рәхмәт, әби.

**ИСЛАМ:** Өчпочмакарын тәмле булган, әби.

**АЙЗИЛӘ:** Бәлешең телеңне йотарлык булган.

**ЧУЛПАН:** Инде бераз ашап эчеп алдык, әллә бераз уйнап алабызмы?

**БАЛАЛАР:** Әйдәгез, уйныйбыз.

*(“Ак калач” уены. Балалар түгәрәккә тезелеп басалар, Сәйдә уртада, Ак калач җырын җырлыйлар. Аннан түгәрәк эченә Айзилә керә, кабаттан җырлыйлар.)*

**ӘБИ:** Балалар сезнең теге юлы килгәндә курчакларыгыз калган иде бездә. Әйдәгез карап карыйк әле, бәбиләрегез сагынгандыр инде сезне. *( Балалар керәләр, курчакларын кулларына алып идәнгә утыралар)*

**СӘЙДӘ:** Әлли-бәлли бәү итә,

Бәби йокыга китә.

Бәби йокыга киткәч,

Әнисе кайтып җитә.

**Тәрбияче:** И-и балалар, сабыйга ана назы, йөрәк җылысы кергән бишек җыры кирәк ул. Әби-бабаларыбыз элек-электән әйтеп килгәннәр, бишек җыры тыңлап үскән баланың теле иртә ачыла, сәләтле, акыллы бала булып үсә.

**ӘБИ:** Ул аны тынычландыра, йоклата. Сиңа да кызым нәни чагыңда бишек җырларын җырлый идем. Кызлар, әйдәгез, без дә бәбиләребезне алып йоклатыйк әле. Утырыгыз минем янга. *(Килеп тезелешеп утыралар)*

**Тәрбияче:** Әби, сезнең яшь чакта, балаларны бишек җырлары көйләп йоклатканнар. Әйдә, син дә безгә бер бишек җыры җырлап күрсәт әле?

*(Бишек җыры)*

**Тәрбияче:** Әби, бик зур рәхмәт матур җырларың өчен, сый-хөрмәтләрең өчен. Ә безгә инде бакчага кайтырга да вакыт җитте. Әйдәгез, балалар, әбигә рәхмәт әйтеп, кайтыйк.

*(Музыка астына чыгып китәләр)*

## “ЯШӘГЕЗ, ЧИШМӘЛӘР!”

***Бәзгетдинова Гөлчәчәк Рәшит кызы***

*Татарстан Республикасы Кукмара районы*
*6 нчы “Салават күпере” балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

- балаларның су чыганаклары турында күзаллауларын киңәйтү;
- “Зиннәт” чишмәсенең тарихы белән таныштыру;
- чишмәләргә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү

**Материал:** Каенсар авылы турында фильм

**Әдәбият:** Г.Тукай «Безнең авыл”, Каенсар авылында туып үскән шагыйрь Харис Мостафинның “Зиннәт чишмәсе” шигыре

**Чараның барышы**

**Алып баручы:** Исәнмесез, кадерле балалар, кунаклар! Бүгенге чарабызны бөек татар шагыйренең сүзләре белән башлыйсы килә:

Тау башына салынгандыр безнең авыл
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным-тәнем белән.

*(Экранда Каенсар авылына багышланган видео күрсәтелә)*

**Алып баручы:** Һәр кешенең үз туган җире бар. Ул аның өчен җан атып яши, саклый, горурлана, чит җирләргә китсә аны сагынып кайта. Без дә Кукмара шәһәребезне бик тә яратабыз. Бүген без сезнең белән Кукмара районының Каенсар авылына сәяхәткә барырбыз. Каенсар авылы бик бай табигатьле, бөтен яктан да иксез-чиксез иген-кырлары, калкулыклар, җиләкле болыннар чорнап алынган. Иң матур, истәлекле урыннарның берсе - "Зиннәт" чишмәсе. Ул авыл башында ике таулык арасыннан саркып чыга. Бу авылда Зиннәт исемле агай яшәгән. Ул шушы агып чыккан сулыкны күреп, чистарткан, тирә-ягын рәтләнгән. Менә шуннан башлап авыл халкы бу чишмәгә йөри башлаган һәм аңа "Зиннәт" исеме биргәннәр. "Зиннәт" чишмәсенең суы салкын, чиста, саф. Ерак аралардан кайткан авылдашлар аның суын татып карамыйча китмиләр.

- Элек электән татар кызлары, егетләре чишмәгә суга төшкәннәр. Анда алар бер берсе белән аралашканнар, төрле-төрле уеннар уйнаганнар. Әйдәгез әле, без дә бүген, татар халкының матур бер гореф-гадәтләренең берсен чишмә бәйрәмен уздырыйк.

**1 нче бала**

Таң алдыннан сандугачлар җыры
Кушылгандыр синең моңыңа.
Салкын суың эчеп юлаучылар
Юнәлгәндер барыр юлыңа.

**2 нче бала**

Күпме еллар инде бер туктамый
Халкым йөрәгедәй тибәсең.
Каенсарның үткәннәре кебек
Тамырларын тирән күрәсең.

**3 нче бала**

Тирә-якка матур бер ямь биреп,

Челтер-челтер җырлап агасың.

Саклыйсыңмы хәтереңдә, суың

Эчеп үскән авыл баласын.

**4 нче бала**

Зиннәт чишмәсе – җырлы чишмә,

Сукмак бетмәс синең янына.

Ничә буын шифалы суңнан

Куәт алып яши җанына.

*(Чиләк тоткан карт белән карчык килеп керәләр)*

**Карт:** - Һай, әбисе кара әле, кара, чишмә янында күпме яшьләр җыелган. Нәкъ безнең яшь вакыттагы шикелле!

**Карчык:** - Әиии, бабасы, бар иде заманалар!

**Карт:** - Исәнмесез, балалар! Бигрәк матур киенгәнсез, бигрәк күп җыелгансыз. Берәр бәйрәмме әллә монда?

**5 нче бала:** Исәнмесез, бабакай,

Исәнмесез, әбекәй!

Җыелдык без уйнарга

Чишмә янында күңел ачарга!

Тик менә берәр кызыклы уен уйныйсы килә иде дә...

**Карчык:** - Әәәә! Алай икән! Әйдәле, картым, өйрәтик әле балаларга үзебез яратып уйнаган уенны.

**Карт:** - Әйдә! Әйдә! Уенның исеме “Алдыр чишмә тамчылый”.

*(Балалар, ике командагы бүленеп, бер команда залның бер башына, икенчесе икенче башына басалар һәм кулга-кул тотынышалар. Беренче команда икенче яктагы балаларга кычкырып түбәндәге сүзләрне әйтәләр:*

Алдыр чишмә тамчылый,

Гөлдер чишмә тамчылый,

Ал кирәк, гөл кирәк,

Бездән сезгә кем кирәк?

*Икенче командадагы балалар җавап бирәләр:*

Алдыр чишмә тамчылый,

Гөлдер чишмә тамчылый,

Ал да кирәк, гөл дә кирәк,

Ләлә матур кыз кирәк.

*Исеме чыккан бала икенче команданың сафын йөгереп барып өзеп чыгарга тиеш. Өзә алса, бер баланы ияртеп, үз командасына алып кайта. Өзә алмаса, үзе шул якта кала. Уен шулай дәвам итә)*

**6 нчы бала:**

Алсу кая җенган?

Су алырга чишмәдән.

Юлын белә, урынын белә,

Ул бер генә тәшмәгән.

**7 нче бала:** Көянтә-чиләк асып,

Кыз өч адым атлауга,

Суга мин дә барам дип

Килеп җитә Акбай да.

**8 нче бала:** Ахирәтен озатып,

Ияреп бармыймы соң;

Кызларның үзен генә

Җибәрү ярймы соң?!

**9 нчы бала:** Чишмәне дә тикшереп

Чыга Акбай, килгәч тә,

Эт телендә үзенчә

Бирә әле киңәш тә.

**Карт:** Әбекәй, син бит иң матур биюче кыз идең. Баскан җирдән ут чыгара идең.

**Карчык:** Ииии, рәхмәт инде, картым! Мин әле хәзер дә булдырамдыр.

*(Татар халык бию көе яңгырый. Әби бии башлый, арып карты янына килә)*

**Карт:** Булдырдың, әбисе! Балалар, ә сез бии беләсезме?

**10 нчы бала:**

Биемичә ничек инде

Түзсен җаныбыз?!

И-и-их, биибез! Безнең әле

Бик матур чагыбыз!

*(Кызлар татар халкының “Су юлы” җырына бииләр)*

**Карт:** Бигрәк матур бииләр инде бу кызлар! Чишмәнең суын эчеп карадыгызмы соң әле сез? Ничек сулары?

**Бала**: Эчтек, әбекәй, эчтек, бабакай. Бигрәкләр дә тәмле инде бу чишмә сулары.

**Карт:** Ул тәмле генә түгел, файдалы да әле ул. Ул сусаганны гына басмый, ә шифасын да бирә. Менә сезнең кулыгызда гел төймәле... нәрсә әле ул? Әй, карчык, нәрсәләрдә уйныйлар әле хәзерге замана баласы?

**Карчык:** Тилифун,тилифун

**Карт:** Әйе, әйе. Менә шул нәрсәгә көне-төне карап утырасыз, күзләрегезне бозасыз. Менә шушы чишмә суы белән юынсагыз файдасы тими калмас!

**11 нче бала:** Челтер-челтер көмеш чишмә
Яр астыннан агадыр.
Әби көндә тәмле чәйгә
Суны шуннан аладыр.

**12 нче бала:** Көрәк тотып чишмәне мин
Чистартып кына торам.
Кыр-кырнына ташлар түшим
Аннан ерганак ерам.

**Алып баручы:** Балалар, әйдәгез әле безнең әби белән бабайга җырлап та күрсәтик әле.

*(Җыр башкарыла: Раушания Закирова музыкасы, Гөлфия Шакирова сүләре “Чишмә” җыры)*

**13 нче бала:** Җырлап кайта көянтәм,
Тирбәлә чиләкләрем.
Чәчәкләрем су эчә,
Чылана чүәкләрем

**14 нче бала:** Тау астында җырлап чишмә ага,
Камышлыкка кереп югала.
Татлы суы, дәртле җыры белән
Гөлчәчәкле җирне сугара.

**15 нче бала:** Җир яшәрә аның суын эчеп,
Ак каеннар яфрак яралар.
Таң алдында аның җырларыннан
Сандугачлар канатланалар.

**Карт:** Ай, балалар, булдырдыгыз! Рәхмәт сезгә! Нинди күңелле ял иттек!

**Карчык:** Балалар, исегездә тотыгыз! Чишмә – су чыганагы гына түгел, ул безне үткән белән киләчәкне бәйләп торучы җеп тә. Чишмәләр кебек урыннарны сакларга һәм төзекләндерергә кирәк.

**Карт:** Бик дөрес, карчык. Аларның кадерен белеп торыгыз. Без сезгә аларны мирас итеп калдырабыз. Ә хәзергә хушыгыз. Безгә инде кайтырга кирәк.

**Балалар:** Сау булыгыз

**Алып баручы:** Ә мин бәйрәмне Ильдар Юзеевның шигыре белән тәмамлыйсым килә:

Көлгәндә дә чишмә кебек челтерәп
Нәкъ татарча тыйнак көлегез.
Тәнгә-җанга сихәт-дәрман биргән
Чишмәләрнең кадерен белегез!

## “ИСЕМ – КҮҢЕЛ КӨЗГЕСЕ”

***Хөсәенова Римма Нәзгать кызы***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*“Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге*
*“Балачак” балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджетлы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Бурычлар:** Әби-бабайларның гореф-гадәтләрен саклап калу, балаларга исемнәрнең мәгънәләре турында аңлату, милли йолалар турында белемнәрен киңәйтү, аларда татар милләтенең йолалары, традицияләренә карата кызыксыну уяту, бер-берсенең исеменә хөрмәт тәрбияләү.

*Талгын гына көй яңгырый.*

**Алып баручы.**

Бала туды бүген җиргә,
Фәрештәләр аңа юл ачты.
Күкләр иле садә җаннан булган
Бер баласын җиргә озатты.

Гаиләгә шатлык булып, өмет һәм куанычлар өстәп дөньяга олы зат туды. Дөньяга яңа кеше туды! Ул үзенә бәхет даулап тәүге авазын салды.

*(Бала елаган тавыш ишетелә. Пәрдә артыннан ана чыгып баласын юата, бишекне тирбәтә)*

**Алып баручы.** Татар халкында борынгыдан килгән тал бишек. Элек-электән аны әтиләр үз куллары белән үреп, үзләренең йөрәк җылыларын биреп ясаганнар. Ә матур чыбылдыкларны әниләр теккән. Ул чыбылдык сабыйны явыз көчләрдән, күзләрдән, салкыннардан саклаган.

Сездә ничек, бездә бишек талдан,
Җырдан үрелә.
Җырлы бишек, җылы бишек
Эленә өй түренә.

*Ана башкаруында "Бишек җыры" Габдулла Тукай шигыре. Татар халык көе.*

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып житәр бу.
Йокла, углым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сина теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.
Гыйzzәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

*(Ана баланы йоклатып, пәрдә артына кереп китә).*

**Залга әби керә**: Аллага шөкер, оныгым туды. Балакаем, алтыным сау-сәламәт,озын гомерле, тәүфыйклы, мәрхәмәтле булып үссен. Бүген оныгыма исем кушабыз.

Тавышлар килә, кунаклар да килеп җитте ахры..

(*Ишектән балалар керәләр. Татар киемнәреннән киенгәннәр, кулларында бүләкләр, күчтәнәчләр, чиләк белән су)*

– Әәәй, кунаклар киләләр икән. Исәнмесез, балалар!

**Балалар**: Исәнмесез, әбекәй, без бәбине котлап бәйрәмгә килдек. Бәбигә бүләк, күчтәнәч, юындырырга изге су да алып килдек.

**Әби**: Алланың рәхмәтләре яусын сезгә, балалар, аяк кулларыгыз сызлаусыз булсын. Әйдәгез, суларыгызны алып куйыйм әле. Бүген кич бәбәй мунчасында сез алып килгән су белән оныгымны юармын. Сез бик изге эш эшләгәнсез. Әйдәгез, балалар, әйдәгез, түрдән узыгыз. *(балалар барып урындыкларга утыралар).* Балалар, ә сез баланы юындырганда әйтә торган юаткычны беләсезме соң ?

**Бала:** Мин беләм, үзем сөйләп күрсәтим әле.

Йомшак су, йөгерек су!

Син мине чиста ю!

Бер тап та калмасын.

Битләрем аллансын,

Кулларым агарсын.

Тешләрем тазарсын..

Авызым елмайсын,

Колгым тыңласын,

Йомшак су, йөгерек су!

Һәммәсен чиста ю!

**Әби:** Ай, рәхмәт, улым. Оныгым бишектә, әле генә йоклаган иде. Бүген аның бәйрәме- Бәби ашы, исем кушабыз.

**Алып баручы**. Без бәбигә тәмле телле булсын дип, татар халкының милли ризыгы баллы, татлы чәк-чәк алып килдек.

Чәк-чәк табынга куела
Ямьле бәйрәм көнендә.
Иң тәмле ризык санала
Һәр татарның өендә.

**Алып баручы.** Әбекәй, оныгыгыз акыллы, уңган, тәртипле булсын дип татар халкының милли киеме түбәтәй алып килдек.

Түбәтәй киеп йөрергә
Кушкан ата-бабабыз,
Түбәтәйле ир-атларга
Без сокланып калабыз.

**Әби**: Бик зур рәхмәт сезгә, балакайларым. Бик зурлап килгәнсез.

**Бала:**

Бала туды җиргә аваз салып,

Кеп-кечкенә, ләкин ул – кеше!

Шул кешегә матур исем кирәк,

Аның булсын тирән мәгънәсе.

**Алып баручы:** Бала тугач, күңелле мәшәкатьләр башлана. Аның беренчесе – исем кушу. Аңа нинди исем бирергә. Бу сорау ата-ананы, туганнарны борчый, чөнки исем кешегә бер генә тапкыр бирелә. Һәр кешегә исеме туган тел кебек якын, газиз, кадерле. Балага исем кушу – бик җаваплы вакыйга. Күркәм исем белән дәшү балага дога кебек уңай тәэсир итә. Шуңа да балага яхшы мәгънәле исем кушарга кирәк.

**Балалар:** Әби, оныгыгызга нинди исем кушасыз?

**Әби**: Илдус дип кушабыз кызым, Алла боерса. Менә озакламый хәзрәт тә килеп җитәр. Илдус исеме иленең дусты, илен сөюче, ягымлы, мәрхәмәтле дигән мәгънәне аңлата. Исемнең мәгнәсен белеп кушарга кирәк, балалар. Ә сез, үзегезнең исемнәрегезнең мәгнәсен беләсезме?

1. Минем исемем Ризван. Ризван – шатлыклы, ягымлы, күңелле, шат күңелле, җәннәт капкасын саклаучы фәрештә исеме.
2. Минем исемем Мәрьям. Мәрьям — сөекле, газиз, кадерле. Мәрьям ана исеменнән алынган.
3. Мин Зәринә булам. Зәринә исеме – “Алтын, алтынлы, алтын бизәкле” мәгънәсен белдерә.

4.Мин Гөлшат .Үзем дә, исемем дә гөл кебек шат.

5. Минем исемем Гөлназ. Гөл һәм наз сүзләреннән ясалган. Мин гөл кебек назлы, ягымлы.

6. Мин Наилә булам. Наилә исеме бүләк, буләккә лаек дигәнне аңлата.

7. Таныш булыйк, мин Илмаз булам. Илмаз кыю, батыр дигәнне аңлата.

8. Минем исемем Аида. Аида исеме кунак, кунакчыл, юмарт дигәнне аңлата.

9. Мин Сөмбел булам. Сөмбел башак, сөмбел чәчәге дигән мәгънә белдерә.

10. Минем исемем Риназ. Туры юлдан баручы дигәнне аңлата.

**Әби**: Балалар, исемнәрегез дә үзегез кебек бик матур, мәгънәле икән. Тәрбияле, бәхетле һәм сау-сәламәт булыгыз.

**Бала:**

Иң беренче бәйрәме баланың,

Бәби туе бүген үтәчәк.

Мулла дога укып колагына

Серле итеп исем әйтәчәк.

*(Исем кушу догасы укыла)*

**Әби**: Балалар, менә минем оныгым да исемле булды. Зариф улыма матур теләкләрегезне теләп китегез әле, әйдәгез.

**Балалар**:

- Илдус, бәхетле бул!

– Әти- әниеңнен сүзен тыңла!

– Батыр, көчле булып үсеп җит!

– Сау – сәламәт, озын гомерле бул!

– Матур, ягымлы, шат күңелле бул!

– Таза- сау, тигез канатлы бул!

- Тәүфыйкълы, тәртипле бул!

- Максатчан, мәрхәмәтле бул!

- Рәхимле, имнлы бул!

- Тырыш, акыллы, тәрбияле бул!

**Әби**: Рәхмәт, балакайларым. Сезгә дә изге теләкләр. Оныгыма бүләк итеп алып килгән матур җырларыгызны да җырлап күрсәтегез әле.

*1. Ш.Ризван җыр*

*2. Г.Аида җыр*

*Уен "Зәңгәр чәчәк"*

*(Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәлә)*

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Йомшак мендәр ярата.

*(Туктап биеп торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри):*

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр -
Мендәреңне сал әле.

*(Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.)*

**Әби**: Иии, балалар, сезгә карап сокланып утырдым әле. Нинди матур итеп җырладыгыз. Ана телен хөрмәт иткән, әби-бабаларының гореф-гадәтләрен белгән бала үз кыйбласын югалтмас, инсафлы, иманлы бала булып үсәр. Рәхмәт сезгә, балалар.

**Алып баручы.** Саклыйк буыннарга рухи хәзинәне,
Исем - һәр кешенең күңел көзгесе.
Киләчәктә шәхес булыр өчен

Тәүге адым, яшәү өлгесе.

Татар халык мәкалендә хаклы рәвештә: «Начар исем – начар язмыштан да яманрак», дип әйтелә. Балаларыбызга дөрес һәм мәгънәле исемнәр бирик.

## “ТАТАРСТАН ДУСЛЫК ИЛЕ, ҺӘРБЕР МИЛЛӘТ АНЫҢ ГӨЛЕ”

***Сәмигуллина Гүзәл Муллахмәт кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*“Яңа Кенәр балалар бакчасы ”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның Идел буе халыклары мәдәнияте, аның башлангычы, теле, гореф-гадәтләре, көнкүреше турында күзаллауларын формалаштыру. Үзенең милләтенә һәм башка милләт халыкларына карата хөрмәт тәрбияләү. Балаларның төрле милләт вәкилләре (татарлар, башкортлар, руслар, чувашлар), аларның тормыш-көнкүреше, милли ризыклары, кул эшләре, уеннары, бәйрәмнәре турында сөйли белүләренә ирешү. Ата-аналар һәм социум, балалар бакчасы, балалар арасында хезмәттәшлек итү теләге булдыру.

**Әзерлек эше:** Республикада яшәүче төрле милләт халыклары белән танышу, аларның көнкүрешләрен, шигырьләр, җырлар, биюләр өйрәнү.

*Зал бәйрәмчә бизәлгән. Экранда “**Татарстан дуслык иле, һәрбер милләт аның гөле**“ дигән сүзләр язылган. Рус халык көе яңгырый. Бер малай бер кыз рус халык биюен башкаралар. Чуваш халык биюен башкарып тагын бер пар чыга. Икенче якка килеп басалар. Башкорт халык биюе белән тагын бер пар чыга. Алга килеп басалар. Татар халык биюен башкарып тагын бер пар чыга. Бию тәмамлангач балалар бер рәткә тезелеп басалар.*

**1 бала**. Бакчабызда бүген бәйрәм
Бәйрәмнең дә нindие?!
Барыбыз да көтеп алган,
Безгә кунаклар килде !

**2 бала** .(т) Дөньялар киң . Анда илләр күп
Туган илем минем бер генә
Туган илемдә дә телләр бик күп

Туган телем минем бер генә.

**3 бала** (т) Татар телемдә сөйләшеп

Яшим мин туган илдә

Туган ил дигән сүзне дә

Әйтәм мин туган телдә.

4 бала. (ч) *Я в Чувашии живу,*

*Я Чувашию люблю.*

*Любит праздник мой народ,*

*В праздник пляшет и поёт*

**5 бала** (ч) Барлык милләт балалары

Безгә дус булып калсын

Дуслык күпере күкләргә

Өзелмәс юллар салсын.

**6 бала**.(б) Ут күршеләр булып яшик

Охшаш безнең телләр, гадәтләр.

Тынычлык һәм дуслык чәчәк атсын.

Уртак безнең теләкләр.

**7 бала**.(р) Мы в любимом Татарстане

Дружно, весело живем

По-татарски и по русски

Мы танцуем и поем.

**8 бала**(р) Наш Татарстан

Дружбой славится

Нам жить в Татарстане

Очень нравится.

*Күмәк җыр: "Мин яратам сине Татарстан"*

*Роберт Рәкыйпов сүзләре .*

*Роберт Андреев көе.*

Мин яратам сине, Татарстан

Ал таңнарың өчен яратам,

Күк күкрәп, яшен яшьнәп яуган

Яңгырларың өчен яратам.

Мин яратам сине, Татарстан,

Горур халкың өчен яратам,

Җан эреткән әнкәм телең өчен,

Татар телең өчен яратам.

*Җырлап бетергәч тезелеп чыгып китәләр.*

**Экранда слайд 1**.

*Залда татар өе эче күренеше. Милли бизәкләре белән бизәлгән сандык куелган. Түрдә ак әби йон эрли. Янында милли киемнән балалар. Ике малай һәм ике кыз. Алар да эш белән мәшгуль. Кызлар чигү чигә. Малайлар чабата үрә. Әби җыр суза. Аңа балалар да кушыла. (бер татар халык җыры)*

**1 бала**. Бигрәк матур җырлыйсың син, әбием.

**2 бала**. Җыры да бик матур бит!

**Ак әби.** Әйе, балакайларым, безнең татар халкының моңлы җырлары бик күп бит. Без яшь чакта кул эшләре эшләгәндә, аулак өйләрдә, кич утырганда җырлар җырлый идек, уеннар уйный идек.

**3 бала**. Әбием, ә сез нинди уеннар уйный идегез?

**4бала**. Ә мин беләм, әбием, сез кич утырганда уйнаган уеннарыгызны. Безгә бакчада тәрбияче апабыз ул турыда сөйләде.

**Ак әби**. Шулай мени, бәбкәчем. Я, нинди уеннар уйнадык икән?

**4 бала**. Йөзек салыш, Капкалы.

**2 бала**. Яулык йөртеш, Ачык авыз уены.

**3 бала**. Гөлбану, Миңнебай уеннарын да уйнадыгызма, әбием?

**Ак әби**. Уйнадык, балам, уйнадык.

**1 бала**. Без дә бакчабызда уйныйбыз ул уеннарны.

**Ак әби**. Әфәрин, балакайлар. Һәр кеше үз халкының үткәнен, ата-бабаларының ничек көн иткәнен, гореф-гадәтләрен, йолаларын белергә тиеш. Сез дә белеп үсегез. Ана телегезне онытмагыз. Балалар, ә сез нинди милләтләрне беләсез ?

***Балаларның җавабы.***

**Ак әби**. Әйе, безнең Татарстаныбызда бик күп милләтләр яши. Аларның үз телләре, үзләренә хас гореф-гадәтләре, йолалары, уеннары, хәттә ризыклары бар. Безнең авылыбыздан ерак түгел, күрше авылда чуваш халкы яши. Бүген алар безгә кунакка килергә тиешләр.

*Бии, бии кучтәнәчләр күтәреп милли киемнәң 4 бала һәм чуваш кунак әбисе килеп керә.*

**1 бала.** Исәнмесез!

**Чуваш әбисе:** Сывӑ-и! (Исәнме!)

**2 бала.** Здраствуйте!

*Ак әби белән чуаш әбисе кул биреп күрешәләр.*

*Өстәлгә алып килгән күчтәнәчләрне куялар.*

**Ак әби**. Рәхим итегез. Безнең татар халкы бик кунакчыл. Түргә узыгыз. Хәзер самоварымны яңартам. *(Самоварны хәстәрли)*

*Утырышалар.*

**Ак әби**. Без оныкларым белән милли йолалар, гореф-гадәтләр турында сөйләшеп утырабыз. Сезнең чуаш халкының үткәне, йолалары, гореф-гадәтләре белән танышып үтәсебез килә.

**Асанне әби**: Рәхәтләнеп сөйлим мин үзебезнең халык турында.

**1 слайд**. - Чувашлар һәм татарлар күп гасырлар дәвамында дус булып, янәшә яшәүче ике төрки халык. Идел Болгары әлеге ике тугандаш халыкның ватаны булып санала. Гомуми халык саны – 1842,3 мең кеше. Россиядә 1776,3 мең чуваш яши, ә Татарстанда 116 мең чуваш исәпләнә. Чуваш теле төрки телләр гаиләсенең болгар төркеменә керә. Чуваш теленә татар, гарәп, мари, рус теленнән күп кенә алынмалар кабул ителгән.

**Слайд 2**

Чуаш мәҗүсилегенең үзенчәлеге мәрхәмәтле, шулай ук явыз рухларны шәфкатьләндерү максатында урманнарда, мәҗүсиләрнең махсус гыйбадәтханәләрендә – кирәмәтләрдә корбан чалудан гыйбарәт.

Бүгенге көндә чуашлар башлыча православие динен тоталар. Араларында мәҗүсиләр дә бар. Тел буенча чувашларны ике төргә бүләләр: вирьял (верховые) һәм анатри (низовые). Чуваш халкы, татар халкы борынгыдан ук дус –тату яшәгәннәр. Бөек Ватан сугышында да иңгә –иң куеп фашистларны җиңгәннәр.

**Слайд 3**. Экранда фотолар күрсәтелә.

Гореф-гадәтләрне, йолаларны, милли бәйрәмнәрне бар нечкәлекләренә кадәр исәпкә алып әле дә чуваш авылларында бәйрәмнәрне үткәрәләр.

Чуваш халкы ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләренә һәм йолаларына сакчыл карый.

**Асанне әби**. Балалар, әйдәгез, милли бәйрәмнәребез турында да сөйләп үтик.

**1 бала** .Уяв — яз-җәй айларында уздырыла торган бәйрәм. Ул «үтәү» дигәнне аңлата. Аны чувашлар язгы уҗымнар, чәчелгән культуралар шытып чыккач, ягъни 19 нчы июньнән соң бәйрәм итә башлый. «Уяв» бәйрәменең нигезен уеннар, җыр-бию, әйлән-бәйлән уйнау кебек мәдәни күңел ачулар тәшкил итә. Электән килгән бу бәйрәмне җомга яки якшәмбе көнне үткәргәннәр. Яшь егет һәм кызлар, кулга-кул тотынышып, учак тирәли җырлап әйләнгән

**2 бала**. Улах бәйрәме. Әти-әниләре өйдә булмаган вакытта кызлар яшьләрне кичке җыенга дәшә. Хуҗабикә дуслары белән түгәрәккә утыра һәм кул эшләре белән шөгыльләнә, ә бу вакытта егетләр аларны күзәтеп, гармунга җырлар җырлый, шул рәвешле күңел ачалар. Башта ук мондый очрашуларның максаты киленнәр эзләү булган.

**3 бала**. Икенче милли йола – Çăварни − кыш озату бәйрәме. Бу бәйрәм күңелле, җыр-бию белән үрелеп бара. Кешеләр үтеп баручы кыш символы буларак карачкы киендерәләр.

Шулай ук Чувашстанда бу көнне атларны бизиләр, аларны матур чаналарга җигәләр һәм балаларны йөртәләр.

**4 бала**. Элек-электән Акатуй бәйрәме чуваш халкында язгы эшләр тәмамлангач билгеләп үтелгән. “Ака” сүзе-чәчү, ә туй – туй дигәнне аңлаткан. Бер сүз белән әйткәндә бу җир белән суканың бәйләнешкә керүе, дигән мәгънәгә ия. Чуваш халкы бәйрәмгә бер-берсен котларга һәм яңа уңышның әйбәт булуын теләргә җыелган, милли йолалар башкарган.

**Ак әби**. Менә бу алып килгән әйберләрегез турында да сөйләп үт инде.

**Асанне әби**. Болар чуваш  халкының борынгы музыка уен кораллары.

**Бала.** Бу уен коралы Шăпăр (волынка-пузырь) дип атала. Ә монысының исеме **Гусли (Кĕсле).**

*Экранда видео.*

**Слайд 4**.  Аш –суга оста чуваш халкы. Әйдәгез әле, балакайларым ,сөйләп үтегез әле милли ризыкларыбыз турында.

**1 бала. Хуплу** (русчага тәрҗемә иткәндә – “курник”) – бәрәңге һәм тавык яки дуңгыз ите белән бәлеш. Камыр сөт һәм оннан әзерләнә.

**2 бала. Кукыль** – чуаш кухнясының иң гадәти булмаган бәлеше. Ул традицион бәлештән бик нык аерыла: биек, озынча һәм бизәкле. Аның эчлеге шулай ук бәрәңге белән иттән тора, тик итне ит тарткыч аша үткәрәләр, ә бәрәңгене турыйлар. Ул бик туклыклы килеп чыга, шуңа һәркемнең күңеленә хуш киләчәк.

**3 бала. Улма пюремече** – алтынсыман төстәге бәрәңгеле пәрәмәчләр. Камыр сөткә басыла, чүпрә һәм тәменчә тоз өстәлә. Аннары камырдан зур булмаган җәймәләр җәелә һәм табада кыздырыла. Алар өстенә пешкән бәрәңгедән эчлек салына, аннары өсләренә чи йомырка сылаганнан соң барысы да духовкада пешерелә.

**4 бала. Йывва** – камырдан шарчыклар. Аларны әзерләү өчен кирәк: сөт, йомырка, он, кабарту өчен сода. Камырдан шарчыклар эшләнә һәм духовкада майда кыздырыла. Гадәттә бу ашамлык Пасхага пешерелә: шарчыклар никадәр күбрәк була, хуҗалыкта шулкадәр күбрәк сарык булачак.

**Слайд 5**. Чувашларның  милли киемнәре дә үзенчәлекле.

Хатын-кызлар киеменең нигезен туника рәвешендәге күлмәк (кепе) тәшкил итә, тау ягы чуашлары һәм болын ягы чуашлары – өйдә тукылган юка ак тукымадан тегелгән кепеләр, түбән як чуашлары XIX йөз уртасына – XX йөз башына кадәр аска таба киңәеп киткән ак, соңрак чуар тукымадан бөрмәләп тегелгән күлмәкләр киеп йөргәннәр. Аларны чигелгән, аппликацияләп бизәлгән алъяпкыч һәм күкрәкчә белән кигәннәр (түбән як чуашларыннан тыш).

Ирләр киеме – ак киндер күлмәк һәм ыштан (йем). Тышкы кием – киндер кафтан (шубёр), көзен – постаудан тегелгән кәзәки (сахман), кышын – сарык тиресеннән билле итеп тегелгән тун (керек).

Ирләрнең җәйге баш киемнәре – кара яки ак киез эшләпәләр (ялкас), кышкылары – киң кырпулы һәм өсте гөмбәз сыман озынча бүрекләр (челек).

Хатын-кызлар җитен һәм киндер яулыклар, читләренә тасмалар тегелгән япмалар ябынганнар. Хатын-кызларның бәйрәмчә баш киемнәре – шлем сыман башлык (пухья), киселгән конус рәвешендәге башлык (хушпу).

Хатын-кызлар киемен көмеш һәм бакыр акчалардан, сәйлән, комач, тасмадан гыйбарәт бизәнү әйберләре (күкрәкчәләр, бәйләвечләр, йөзекләр һ.б.) тулыландырган.
Чуашларның традицион аяк киемнәре – ыштырлы яки оеклы курыс чабаталар (чапата), күн итекләр.

**Асанне әби.** Чувашлар бик борынгыдан ук елга буйларында, каенлыкларда биергә, җырларга, уйнарга яратканнар. Анда туган якның искиткеч матурлыгы һәм киңлеге сокландырган аларны. Хәзер без сезнең белән шул вакытта уйналган “Пешекче” дип аталган уенын уйнарбыз.

***Пекарь (Çăкăрпĕçерекен)***

Среди игроков выбирается водящий - пекарь. Остальные встают парами друг за другом. Пекарь стоит спиной к игрокам во главе колонны и говорит: «Я пеку хлеб».

Игроки: « Успеешь ли испечь?»

Пекарь: «Успею».

Игроки: « Сумеешь ли догнать?

Пекарь: «Попробую!»

Игроки последней пары бегут мимо пекаря, пекарь их ловит.

**Правила игры.** Пекарь осаливает игроков касанием руки. Если пекарь поймает одного из игроков, то встает с ним в пару. Игрок, оставшийся без пары, становится пекарем. Если пекарь никого не поймает, то остается водящим. Пекарь не должен ловить игроков, если они, обежав его, взялись за руки.

**Асанне әби:** Тагын бер уен уйнап алыйк әле сезнең белән. Ул уен “Пустая изба” дип йөртелә

***Пустая изба (Пушă пуртлĕ)***

Игроки становятся в круг на расстоянии 3-4 м друг от друга. Один из игроков выбирается водящим. Он выходит в середину круга. Игроки чертят на земле круги (избы) и встают в них. Водящий громко говорит: «В путь!» Игроки меняются избами. Водящий старается занять свободную избу.

**Правила игры**. Игроки меняются избами только после сигнала «В путь!» Водящим становится игрок, оставшийся без избы.

**Ак әби.** Рәхмәт, әби, балалар. Чуваш халкы турында күпме әйбер белдек. Без дә сезгә рәхмәт йөзеннән җыр һәм бию бүләк итәбез.

**Татар халык биюе .__________________________**

**Җыр**. Ай җаный –вай җаный.

**Асанне**. Әйдәгез, хәзер бергәләп күмәкләшеп җырлап-биеп алыйк

*“Журавушка” җыры.*

**Ак әби**. Бәйрәмгә әниләребез дә килде бит. Алар безгә дәртле чуваш халык биюен алып килгәннәр.

*Күмәк бию әниләр –балалар белән.*

**Асанне**. Ай рәхмәт төшкерләре. Менә нинди күңелле очрашу булды бит.

**Бала (т):** Без -татарлар !

Шушы исем белән

Җирдә яшәү –үзе бер бәхет .

**Бала (ч):** Без –чувашлар!

Яшибез без җирдә

Бар халыклар белән берләшеп!

**Бала (т):** Үстергән дә безне чын дуслык!

**Бала (ч):** Көч биргән дә безгә чын дуслык !

**Бергә:** Дуслык булса яшәр гомергә ,

Бөтен җир шарында Тынычлык !

## “САБАН ТУЕ – МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ ИҢ МАТУР БӘЙРӘМЕ”

***Гарифуллина Рәсилә Гаптелсабир кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*“Бөрбаш балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

Сабантуй – дуслык, туганлык һәм җитезлек бәйрәме.

Сабантуй буласы атнада авыл халкыннан әрәпә җыю узе бер зур бәйрәмгә әверелде.

Сабантуй колгасына матур чигүле сөлгеләр элеп тоткан тәрбиячеләр һәм аларга ияргән бакча балалары «әрәпә» дип кычкырып әйбер жыйдылар. *Сабантуй буласы мәйданчык бәйрәмчә бизәлгән. Озын колгага чигүле сөлгеләр, кулъяулыклар, төрле төстәге шарлар эленгән. Уеннар оештырыла торган урыннар тиешенчә жиһазландырылган. Балалар милли киемнәрдән. Уртага ике бала чыга.*

Шатлыклар күңелебездә
Ал кояш кугебездә.
Килегез, дуслар, кунакка:
Сабантуй буген бездә.
Жилферди чиккән сөлгеләр,
Ал кояш күгебездә,
Көрәшик тә, узышыйк та
Сабантуй бүген бездә

*Балалар бергәләп «Сабантуй» җырын (М.Садри сүзләре, татар халык көе) башкаралар.*

Сабан туе — хезмәт туе, шатлык һәм бәхет туе,
Уйнап-биеп, җырлап-көлеп бәйрәм итик көн буе.
Шау-гөр килә киң болыннар, кырлар һәм су буйлары,
Котлы булсын, гөрләп торсын ямьле Сабантуйлары!

**Алып баручы:** — Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар, хәерле көн! Иң беренче сезне котлау өчен сүз бирелә балалар бакчасы мөдире Р.Х.Шарифуллинага:

-Без бүген татар халкының олы бәйрәме — Сабантуена җыелдык. Сабантуй — ул хезмәт, дуслык бәйрәме, һәркемнең көтеп алган изге бәйрәме. Барыгызны да шушы бәйрәм белән котлыйм. Балалар бакчасында эшләүче барлык апаларыгыз, тәрбиячеләр исеменнән сезгә бәхетле балачак, ныклы сәламәтлек телим. Алдагы көннәрегез дә бүгенге кебек ямьле, күңелле булсын! Өстәлләребездә ризыклар мул булсын!

*«Сабан туе» җыры (Г.Зәйнәшева сүзләре, Л.Батыр-Болгари көе) башкарыла.*

Күңелле Сабантуйлары, буген бәйрәм, зур бәйрәм.
Матур җырлар җырлый-җырлый уйныйбыз әйлән-бәйлән.
К.: Без жырлыйбыз Сабантуйда, иң матур жырлар сайлап,
Безнең җырга зәңгәр күктән кошлар кушыла сайрап.
Күбәләкләр безнең белән уйныйлар әйлән-бәйлән
Сабантуй — кубәләкләр һәм кошлар өчен дә бәйрәм.
Әти-әниләребезгә җыйдык чәчәк бәйләме.
Матур булсын, ямьле булсын Сабан туе бәйрәме.

**Алып баручы**: кадерле балалар, ә хәзер әйдәгез Сабантуй уеннарын башлыйбыз. Иң беренче

балалар көрәше. Хәзер мәйдан уртасына яшь көрәшчеләрне чакырабыз.

Алар артыннан мәктәпкә хәзерлек төркеменең башка малайлары да мәйданга чыга.

**Юныс:** Сабан туе- сабан туе,

Шундый кызык куңелле,

Көрәшик тә, узышыйк та,

Сабантуй бүген бездә.

**Артём:** Егылсам да, исем китми

Булыр еккан чаклар да,

Бәйрәм бүген, Сабантуе

Безнең ямьле бакчада.

*Малайлар көрәше тәмамланганнан соң спонсорлар тарафыннан хәзерләнгән бүләкләр тапшырыла.*

*Беренче батырга «зур машина», икенче батырга машина, өченче батырга- йомшак уенчык тапшырыла.*

**Алып баручы:** хәзер чүлмәк вату уены оештырыла. Уенга керергә теләгән балалар тәрбияче Раилә апагыз янына жыелабыз.

**Сәйдәш**: Чулмәк ватам, чулмәк ватам

Ватып булырмы икән?

Бүләккә бер чиккән яулык,

Алып булырмы икән?

«Чүлмәк вату» уены уйнатыла.

**Алып баручы:**  Икегезгә ике капчык,

Ягез әле, тотыгыз.

Сабантуенда ярышып,

Сез дә бүләк алыгыз.

Малайлар арасында капчык сугышы уены уйнатыла.

«Су ташу» уенын тәрбияче Рәсилә апагыз уйната. Чиләк-коянтә асып кызлар ярышырга китәләр.

**Алып баручы:** Менә сезгә сулы чиләк

Көянтә ал иңеңә.

Йөгер тизрәк, иң алдан кил,

Егыла гына күрмә.

*Мәйданга Камырша белән Батырша керәләр:* —Исәнмесез, балалар, исәнмесез, кунаклар!

**Камырша:** Таныш булыйк. Бу минем туганым Батырша була.

**Батырша:** бу — минем җан дустым Камырша.

**Алып баручы**: безнең бәйрәмгә килүегезгә зур рәхмәт, кунаклар. Әйдәгез, бергәләп куңел ачыйк. Уеннар уйныйк. Менә сезгә бау, «аркан тартыш» уйныйбыз. Камырша, Батырша (бергә): Була ул! *Икесе аркан тартышалар.*

**Алып баручы**: балалар, әллә сез дә булышасызмы? *Барысы бергә, ике якка буленеп, бау тартышалар.*

**Алып баручы:** сабантуй елга бер килә, күңелле, олы бәйрәм! Нур өстенә нурлар иңсен биеп алыйк ичмасам.

*Татар халкынын, кумәк биюе башкарыла. Шаулаша-шаулаша шамакайлар керә:*

**Шамакайлар бергә:** -Исәнмесез, балалар!

— Котлы булсын Сабантуйлары.

**Алып баручы:** рәхмәт! Балалар, безнең бәйгегә шамакайлар килгәннәр, әйдәгез аларны да үзебезнең уеннарга катнаштырыйк.

*Капчык белән йөгерү. Башта шамакайлар, аннары балалар ярышалар. Аннары малайлар һәм кызлар йөгерешенә һәм кашыкка күкәй салып йөгерү уеннарына кушылып йөгерәләр.*

**Шамакайлар:** бик куңелле икән сездә! Балалар, сезнен, тагын нинди һөнәрләрегез бар?

**Алып баручы:** Җыр-биюсез бер бәйрәм дә

Узмый, шуны белегез.

Балаларыбыз бик булган,

Концерт карап китегез.

Балалар жырлар, биюләр башкаралар, шигырьләр сөйлиләр.

**Алып баручы:** дуслар, көтеп алган Сабантуйлары ахырына якынлашты. Барыгызга да саулык-сәламәтлек телим. Сабантуй бәйрәмендә барлык балалар да бүләкләнделәр. Бәйрәм уздыруда спонсорлык ярдәме күрсәткән барлык авыл халкына, аерым гаиләләргә аерым рәхмәт әйтәбез, исәнлек- саулык телибез.

*Киләсе Сабантуйларында очрашырга язсын.*

# “КАЗ КАНАТЫ КАУРЫЙ-КАУРЫЙ...”

***Шакирова Рузалия Мәүлемҗан кызы***

*Татарстан Респбуликасы Арча муниципаль районы*

*«Арча 1 нче балалар бакчасы»*

*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларны татар халык йолалары һәм бәйрәмнәре белән таныштыруны дәвам итү. Каз өмәсе йоласы турында мәгълүмат бирү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Жиһаз:** Авыл өе күренеше: чигүле пәрдәләр эленгән тәрәзә, диварларга эленгән чигүле тастымаллар, эскәмияләр, «каз йолкыр» өчен ләгәннәр, каз каурыйлары, өстәл, өстәлдә самавыр, чынаяклар, чәк-чәк.

**Бәйрәм барышы: (Әкрен генэ татар халык көе яңгырый)**

**Алып баручы:** Онытылган гореф-гадәтләрне

Яңартабыз хәзер көннән-көн.

Уен йолалары, җыр-биюе

Һәр киләчәк көнне бизәсен.

*Залга ана каз булып киенгән тәрбияче, аның артыннан бер-бер артлы төзелешеп, каз бәбкәләре булып киенгән балалар чыга. Алар “Кыйгак-кыйгак” дип каңгылдашып, “әниләре” тирәсендә әйләнәләр. Татар халык көе астында “Казлар биюе” башкарыла.*

**Алып баручы:** Менә шулай жил-давыл тидерми сакладылар казлар үз бәбкәләрен. Матур язлар, ямьле җәйләр үтте. Үзенең муллыгы белән “Алтын көз” дә килеп җитте. Су буйларында йөргән бәбкәләр дә үсте. Авылларда “Каз өмәсе” башланды.

**Бала**: Көзге байлык! Көзге муллык!

Авылда каз өмәсе.

Яше карты, бала-чага -

Шау-гөр килә һәммәсе! *(балалар кереп китә)*

**Әби чыга**: (үз-үзенә сөйләнеп) И-и-и, бу эш дигәне гел бетми, һич кенә дә житешеп булмый. Аллага шөкер казып алган бәрәңгеләрне базга урынлаштырдык, инде зур эшләрнең берсе генә калып бара. Авылыбызда каз өмәсе дә бетеп килә, урамда су буеннан кайтучы казлар да кимеде. Алла боерса бүген чират бездә. Курше кызларын да чакырдым. Озакламаслар, бик житез кызлар үсеп килә. *(Ишектән тавыш ишетелә)*

**1 кыз**: Исәнме, күрше әби! Әллә казларыңны йолкып та бетерденме?

**Әби**: Исәнмесез, кызларым. Килеп тә життегезмени? Бик иртә кердегез әле.

**2 кыз**: Шундый матур көз иртәсендә йоклап ятып буламени, әбием. Узең дә энә барысын әзерләп куйгансын.

**Әби**: Әйе, кызым, суым хәзер кайнап чыга, сез кереп утырыша торыгыз. Хәзер тәмләп чәй эчеп алырбыз.

**3 бала**: Чәй эчәргә өлгерербез. Башта эшне бетерик. *(Башка кызлар да ризалык белгертәләр)*

**Әби**: Алай булгач хәзер казларны алып кереп бирәм, йолка башларбыз *(йомшак уенчык “каз”ларны балаларга бирә).*

Менэ сезгә казлар, жырлый-жырлый, армыйча эшләгез. Ә мин бәлешләремне әзерли торыйм.

**1 кыз**: Казларыгыз бигрәк матур
Таза булып үскәннәр.
Ә йоннары, каурыйлары
Мамыкланып беткәннәр.

*Кызлар каз “йолкыйлар”.*

**Әби**: Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан гына мендәр ясыйм әле. Яңа, йомшак мендәрдә йокы тәмле була ул.

*(Урам якта капка тавышы ишетелә. Малай керә).*

**Малай**: Шыгыр-шыгыр капканы
Шыгырдатмый япмабыз.
Каз өмәсе булган жирдән,
Беребез дә калмабыз (татар милли киемнәре кигән малайлар керә).

**Малайлар бер-бер артлы**:
Исәнмесез, барыгыз,
Бездән сәлам алыгыз.

**Әби**: Мин бит күрше егетләрен үзем чакырган идем. Онытмаганнар, рәхмәт, килгәннәр. Үтегез, балакайларым .

*Жыр башкарыла: “Гармун алыйк әле, дуслар”.*

**Әби:** Кызлар казларны йолкып бетерделәр инде. Кызлар, әйдәгез казларны монда куегыз. Курше әби эчләрен тазартканчы, уйнап-җырлап алыйк.

**Уен “ Чума үрдәк, чума каз”**

**Әби**: Балакайларым, казлар әзер, барыгыз су буена төшеп чайкап менегез.

*(Казларны көянтәләргә элеп күтәрәләр , «су» буена төшәләр. Малайларга иләк белән каз каурыйлары бирелә. Алар түбәндәге сүзләрне әйтеп, каурый сибеп баралар).*

**Малай**: Каурыйлары, каурыйлары
Сибелсен су буена,

Казларыгыз шулай уңсын

Киләсе ел буена.

*(«Су» буенда кызлар каз “чайкыйлар”). Кызлар “туңдыра башлады бит әле, биеп алыйк булмаса”, диешәләр. Казларны бәке читенә куеп бииләр).*

**Уен “Кулъяулык»**

**Кыз**: Казларыбыз да чистарды. Җылынып та алдык. Әйдәгез, кайтабыз.

*(Казларны алып түгәрәккә басалар. Музыка астында кайталар. Аларны әби каршы ала. Түгәрәк эченә керә.)*

**Әби**: Кайтып та җиттегезмени, балакайларым? Кая казларыгызны алып куйыйм әле. Бигрәк уңган балалар булдыгыз. Мин әле бәлешләремне да пешереп бетермәдем.

**Кыз:** Ярар, әби, борчылма, без уйный торабыз. «Йөзек салышлы»лы уйныйк.

**Уен « Йөзек салыш».**

**Алып баручы** : Гөрләп үтте, шаулап үтте

Авылда каз өмәсе.

Бу айларны, бу көннәрне

Көтеп ала хәммәсе.

Менә шулай каз өмәсен

Татарда үткәргәннәр.

Ә яшь кызлар күңел биреп

Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Канатлар белән бию.**

**Әби:** Бәлешләрем дә пеште, коймакларым да әзер. Әйдәгез, балалар, бәлештән авыз итик, каз майларына манып коймак ашыйк, чәй эчик әле.

*(Балалар тезелешеп, өстәл янына чәй эчәргә утыралар).*

# “БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛЛЕ САБАНТУЙ”

***Рәхматуллина Регина Николай кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*"Ике Басу Арташ "Кубэлэк" балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Бәйрәмнең бурычлары:**

Балаларны татар халкының гореф-гадәтләре һәм йолалары белән таныштыруны дәвам итәргә: «Сабантуй» бәйрәме турында күзаллау, ярышларда катнашу теләге һәм кызыксыну уяту;

Балаларның физик сыйфатларын үстерүгә булышлык күрсәтергә: җитезлек, көч, тизлек, балаларның хәрәкәт активлыгына ихтыяҗын канәгатьләндерергә.

Татар халкына мәхәббәт һәм толерант мөнәсәбәт, милли бәйрәмнәргә, гореф-гадәтләргә кызыксыну тәрбияләргә.

Кагыйдәләрне һәм төрле биремнәрне үтәүгә җаваплы мөнәсәбәт тәрбияләргә. Уңай хис-кичерешләр үстерүгә, яшьтәшләрең белән аралаша белүгә, үзара аңлашуга һәм кайгыруга булышлык күрсәтергә.

**Материаллар һәм җиһазлар:** агач атлар, 4 төсле яулык, 2 касә, 2 мендәр, 2 капчык, аркан, 2 кечкенә мендәр.

**Башлангыч эш:**

"Татарстан мәдәнияте" темасына демонстрацион материалны карау.

Татар әйтемнәрен һәм мәкальләрен уку.

Хәрәкәтчән уеннар

"Сабантуй" татар милли бәйрәме" иллюстрацияләрен карау.

***Бәйрәм барышы:***

*Үзәк сәхнәдә “Сабантуй” язуы, шарлар. Мәйданчык уртасында флагны күтәрү өчен флаг урнаштырылган. Уеннар өчен барлык секцияләр дә флаглар белән бүленгән. Трибуналарда әти-әниләр, кунаклар утыра. Атрибутлар үз урыннарын ала. Барлык катнашучылар да трибуналарның сул ягында дүртешәрләп колоннага тезелә. Фанфарлар яңгырый. Алып баручы уртага чыга.*

**Алып баручы:** Исәнмесез, балалар!!! Хәлләрегез ничек? Балалар, бүген нинди бәйрәм?

**Балалар:** Сабантуй!

**Алып Баручы:** Дөрес!

Күңелле Сабантуйга

Без барлык дусларны чакырдык.

Җырларбыз һәм биербез,

Бердәм, күңелле уйнаулар оештырабыз.

Бүген без татар халык бәйрәме-Сабантуйны билгеләп үтәбез. Ә Сез Сабантуй сүзенең мәгънәсен беләсезме? Ә аны кайчан билгеләп үтәләр? (балалар җаваплары) барыгызны да күңелле Сабантуй бәйрәме белән котлыйбыз. Бу иң яраткан, иң күңелле, иң тантаналы халык бәйрәме. Ул язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң үткәрелә. Бу бәйрәмдә кешеләр көч, җитезлек һәм чыдамлык буенча ярышалар. Бүген без бу күңелле бәйрәмне бергә үткәрергә җыелдык.

**1 бала:** Сабантуй-хезмәт туе,

Шатлык һәм бәхет туе,

Уйнап, биеп, җырлап-көлеп,

Бәйрәм итик көн буе!!!

**2 бала:** шау-гөрә килә болыннар,

Кырлар һәм су буйлары.

Котлы булсын, якын дуслар,

Ямьле Сабан туйлары!!!

*«Сабантуй»Җыры*

*Татар халык уены "Кәрия-Зәкәрия"*

*("Шүрәле" әкиятеннән татар кызы Гөлчәчәк һәм егет чыга)*

**Егет:** Исәнмесез, балалар. Сезнең балалар бакчасы янынннан узып, шигырьләрне ничек яхшы укуыгызны, яңгыратып җырлавыгызны ишеттек.

**Гөлчәчәк:** Безнең сезгә кунакка керәсебез килде. Сез бүген бәйрәм итәсез бит? Ә нинди бәйрәм?

**Балалар:** Сабантуй!

**Гөлчәчәк:** балалар, бу бәйрәм — Сабантуйны кайчан үткәрәләр икән?

**Балалар:** Җәй Көне!

**Гөлчәчәк:** Ә, мин җәйне бик яратам. Җәй көне кояшта кызынырга була. Урманга гөмбәгә барырга. Елгада балык тотарга. Балалар, ә сез черкиләрнең ничек кычкырганын беләсезме? Ә чебеннәр ничек гөжли? Урманда кошлар ничек сайрый? Ә күке ничек кычкыра? Бака ничек бакылдый? Ә сез уйнарга яратасызмы? Әйдәгез, сезнең белән «Әй, дустым, чүлмәк сат!» дигән татар халык уены уйныйк.

*Татар халык уены «Әй, дустым, чүлмәкне сат!»*

Молодцы!

**Егет:** Игътибар, Игътибар!
Ярышны башлыйбыз,
Кем җитез, кыю һәм оста,
Түгәрәккә тизрәк чыгыгыз!
Уеннар-ярышлар:
*«Капчык киеп йөгерү»;*
*«Кашыклар белән йөгерү»;*
*«Чүлмәкләр сугышы»*
*«Аркан тартып ал»;*
*«Чиләкләр белән йөгерү»;*
**Егет:** менә сиңа капчык бирәм,
Дустың керсен.
Кем тизрәк барып җитә
Ул, әлбәттә, җиңәчәк!!!
*(капчык киеп йөгерү)*
**Гөлчәчәк:** менә кашык, кашыкта-йомырка!
Йөгерергә ярамый, калтыранырга ярамый,
Тын алырга мөмкин – тик сак кына!
*(кашыклар белән йөгерү)*
**Алып баручы:** Булдырдыгыз, балалар! Менә сезгә татлы сый *(конфетлар таратыла).* Сезгә ошадымы!? *(балалар җаваплары)*. Шуның белән безнең бәйрәм тәмам! Саубулыгыз!

## "КАУРЫЙ, КАЗ ӨМӘСЕ"

***Бариева Гөлнара Фоат кызы***
*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*"Ике басу Арташ "Күбәләк" балалар бакчасы"*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** Балаларны татар халык йолалары, бәйрәмнәре турында белемнәрен баету. Каз өмәсе йоласы турында әңгәмә, элекке гореф-гадәтләрне искә төшерү.

**Җиһазлар:** “Каз” йолкыр өчен тазлар, тегелгән казлар, утыргычлар, канат каурыйлары.

**Бәйрәм барышы:**

*(Бәйрәм үткәрәсе зал матур итеп бизәлгән. Авыл өе күренеше. “Каз” өмәсе өчен кирәкле әйберләр куелган. Әкрен генә музыка яңгырый.)*

**Әби:** *(үз-үзенә сөйләнеп керә)* И-и-и, бу эш дигәннәре гел бетми, һич кенә дә җитешеп булмый. Авылыбызда каз өмәсе дә бетеп килә, алла боерса бүген чират бездә. Әле менә, күрше кызларын да чакырдым.

*(“Каз канаты” җыры астында җырлый – җырлый кызлар керәләр)*

**Кызлар:** Исәнме, әбекәй, хәлләрең ничек?

**Әби:** Исән-сау килеп җиттегезме, кызларым? Менә мин сезгә эш әзерләп куйдым. Килгәнегез өчен бик зур рәхмәт. Өмәбезне башлап җибәрик, барыгызда җайлап утырыгыз. Мин сезгә казларны пешекләп әзерләп биреп торырмын.

**1 кыз:**

Казларың бигрәк матур,
Таза булып үскәннәр.
Ә йоннары, каурыйлары,
Мамыкланып беткәннәр.

**Әби:** И-и-и, онытып торам бит, каурыйларны җыярга сезгә әрҗәләр әзерләп куйдым *(әрҗәләрне алларына куя).* Соңыннан каурыйларны сыдырып су буена чәчерсез, бәбкәләре күп булуын теләп ятарлар алар.

**Кызлар:** Ярар, әби, ярар.

**Әби:** Күмәк эштә һәркем сынаша аз сөйлә, күп эшлә. Шулай да гел сөйләшмичә дә күңелле түгел. Шуңа курә җырлый-җырлый эшләргә кирәк.

*(Кызлар “Каз канаты” җырын башкаралар.)*

Каз канаты кат-кат була,
Кат-кат була, нык була.
Чит җирләрдә бик күп йөрсәк,
Туган җирләр ят була.

Каз канаты каурый-каурый,
Коймак майларга ярый.
Уйнамагач та, көлмәгәч,
Бу дөнья нигә ярый.

**Әби:** Сез бигрәктә матур җырлыйсыз. Менә без яшь чакта “Яшел яулык” уенын уйнарга ярата идек. Әйдәгез, бергәләп уйнап алыйк. *(барысы бергә “Яшел яулык” уенын уйнарга басалар)*

Кульяулыгым яшел-яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм,
Бер иптәшем артына.

**Кыз:** Әйдәгез, кызлар, яңадан “Йөзек салыш” уенында уйнап алабыз.

*(“Йөзек салышлы” уены. Уенда йөзек кемдә кала, аңа җәза бирелә)*

Зәй, зәй, Зәйнәбем,
Атны кая бәйләдең?
Алмагачка бәйләдем,
Алма төште шап итеп,
Зәйнәп чыкты ялт итеп.

**Әби:** Менә без шулай, кул эшләре эшләп, таң атканында сизми кала идек.

**Кыз:** Дусларым, канат сыдырасы бар бит. Әйдәгез әле, кем остарак, сыдырыр икән?

*(Каз канаты сыдыралар)*

**Әби**: Безнең халыкта “Эшләгәндә йөрәгең җилкенсен, ашаганда колагың селкенсен” дигән мәкаль бар. Кем сыдыра белми, миңа карагыз. Менә шулай сыдыралар аны. Сез эшли торыгыз, мин сезгә коймак камырын яңартам. Сезнең эшегез бетүгә әзер булсын *(әби чыгып китә).*

**Кыз:** “Күз курка, кул эшли”, - дигән мәкаль дөрес икән, кызлар. Казлар, каурыйлар бигрәк күп, ничекләр бетербез дип курыккан идек, менә бит эшебез гөрләп барды. Без дә йоласына туры китереп канатларны Мишә буена кадәр чәчеп кайтыйк.

**1 кыз:**

Каурый сибәм су юлына,
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш үрсәтеп,
Җырлап-биеп алыгыз.

**2 кыз:**

Каз өмәсе – иске йола,
Ул безне дуслаштыра.
Матурлыкны күңелләрдә,
Мирас итеп калдыра.

**Әби:** *(чыга)* Кызларым, сезнең белән бик күңелле булды. Рәхәтләнеп күңел ачтык. Ә инде хәзер сезнең белән бергәләп коймак белән чәй эчеп алырбыз.

*(Әкрен генә музыка уйный, барсыда залдан чыгып китәләр)*

**"АУЛАК ӨЙ КИЧӘСЕ"**

***Мөхтәрова Лилия Хәлил кызы***

*Татарстан РеспубликасыЯр Чаллы шәһәренең*
*103 санлы "Тургай" балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максатлар:** Татар халыкының әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләрне яңарту; укучыларны татар халык традицияләрендә тәрбияләү, гореф-гадәтләре аша татар теленә мәхәббәт хисләре уяту; татар халык уеннарын һәм җырларын өйрәтү; әдәплеккә, бер-береңә карата игътибарлы булырга, олылырны хөрмәт итәргә өйрәтү.

*Зал авыл өе күренеше итеп бизәлә (чиккән сөлгеләр, кульяулыклар, самовар, чынаяклар һ.б. куела)*

**Кичә барышы.**

**Алып баручы:** (мин). Исәнмесез, мөхтәрәм кунаклар, укытучылар, укучылар. Бүген бездә аулак өй. Аулак өй турында ишетмәгән кеше сирәктер. Ишеткәнегез булмаса, әйдәгез аулак өйгә рәхим итегез, без сезне аулак өйгә чакырабыз, әби-бабаларыбыздан калган йола, уен, бәйрәмнәрне искә төшерәбез. Әйе, гомер узган, тула оек белән чабаталар тузган. Ә халкыбыз мирасына булган мәхәббәт йөрәкләребездә саклана.

"Хәтерләүдән курыкмагыз сез!
Үткәнегезне онытмагыз сез.
Белегез сез ерак бабаларның,
Ничек итеп көн иткәнен...
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди җырлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

**1 кыз.** Әбием, әбием, кара әле, син өйрәткәнчә чәкчәк пешердем, авыз ит әле, тәмле булганмы?

**Әби:** Бик тәмле, кызым, булдыргансың!

**2 кыз:** Әбием, кара әле, син өйрәткәнчә оекбаш бәйләдем? Матур булганмы?

**Әби:** ОООО, бик матур булган, кызым. Кулларың алтын икән!

**3 кыз:** Әбием, ә без син өйрәнкәнчә алъяпкыч тектек. Матурмы?

**Әби:** булдыргансыз, кызларым! Аллага шөкер, чигәргә дә, тегәргә дә, бәйләргә дә, ашарга пешерергә дә өйрәттем үзегезне. Ә бүген мин сезне аулак өйгә чакырам.

**Бергә:** Аулак өйгәәәәәә!

**Әби:** Әйе, аулак өйгә.

**1 кыз:** Сезнең замандагы кебек аулак өйгәме, әбием.

**Әби:** Әйе, кызым, нәкъ безнең замандагы аулак өйгә чакырам сезне. Барыгыз, кул эшләрегезне алыгыз да аулак өйгә килегез.

**Барысы бергә:** Ә егетләр ?

**Әби:** Килерләр, егетләрне дә дәштем. *(Кызлар шатланышып кул эшләрен алып эскәмияләргә барып утыралар. Музыка уйный. Әби сөйли.)*

-Эх, бар иде бит безнең яшь чаклар. Егетләр гармун уйнап, җырлап урам әйләнерләр иде, кызлар янына аулак өйләргә килерләр иде. Эх, хәзер яшьләр элекке без уйнаган уеннарны оныттылар шул. Заманаларны шушы телевизор, телефон, компьютер дигән зәхмәт басты бит.

**1 кыз:** Егетләр дә килми һаман.

**Әби:** Килерләр, килерләр, килмичә кая китәрләр икән!

**2 кыз:** Килсәләр нишлибез соң?

**Әби:** Килсәләр, бусага ялы түләтмичә кертмәгез! Егетләрне матур итеп каршы алыгыз.

*Гармун тавышы. (Егетләр "Эх алмагачдарын" җырын җырлап киләләр)*

Эх алмагачлары сайрый сандугачлары

Сайрый -сайрый

Сагындыра башлады.

**Егетләр:** Кызлар, нигә кертмисез инде, ачыгыз!

**1 кыз:** Ач булсагыз ашап килегез (көлешәләр).

**Егетләр:** Ачыгыз тизрәк.

**2 кыз:** Егет сиңа ни кирәк?

**1 егет:** Кара кашлы кыз кирәк.

**1 кыз:** Ни эшкә соң ул кирәк?

**1 егет:** Әнигә килен кирәк.

*(Егетләр кереп утыралар)*

**Егетләр:** Исәнме, Мәдинә әби! Рәхмәт, безне аулак өйгә чакырганга.

**Әби:** Әйдүк, әйдүк, балакайларым. Түрдән узыгыз! Без аулак өйләрдә бик күп төрле уеннар уйный идек. “Йөзек салыш ” уенын өйрәтим әле.

Берәү сала, калганнарыгыз тоталар, йөзекле кешегә җәза бирелә .

*Җәзалар :*

1: Әтәч булып кычкыра.

2: биеп күрсәтә

**Әби:** Булдырдыгыз, алтыннарым .

**Әби:** Безнең өй янында кое бар шул коедан кызларым су алып кайтыгыз .

*(кызлар су алып кайталар көянтә чиләк бн)*

**Әби:** Һай, балакайларым, булдырдыгыз.

Рәхмәт, рәхмәт барыгызга
Күңелле ял иттердегез.
Яшь чакларны искә төшереп
Йөрәкләрне җилкеттегез .

**Алып баручы:** Милләтемнең гасырлардан килгән
Истәлекле гадәтләре бар.
Күркәм гадәтләрне яшәтүче
Олуг телем-татар теле бар
Чал тарихлы горур кешеләре бар .
Уен йолалары, җыр-биюе,
Һәр киләчәк көнне бизәсен

## “БИШЕК ҖЫРЛАРЫ” КҮҢЕЛ АЧУ ЧАРАСЫ

***Сәгыйтова Гөлназ Фәннур кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*“Арча 1 нче балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:**

Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән танышу, аларга кызыксыну уяту.

**Бурычлар:**

-Балаларның монологик һәм диалогик сөйләм телен үстерү.

-Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән танышуны дәвам итү.

-Горурлану, хөрмәт итү хисен тәрбияләү.

-Бишек җырларын өйрәнү.

-Ата-аналар белән тыгыз элемтәдә булу, аларның сценарий куюда ярдәм итү.

**Җиһазлау:**

- Бишек, самавыр, чиккән сөлгеләр
- Татар халкының милли киемнәре ( балаларга)
- Савыт-саба
- Милли ризыклар (чәк-чәк, өчпочмак)
- Курчак
- Магнитофон
- Пианино
- сандык

**Алдан эшләнгән эш:**

- “Бишек туе” темасына әңгәмә үткәрү.
- Татар халкының башка төрле йолалары, гореф-гадәтләре белән таныштыру.
- Халык авыз иҗатының “үчти-үчти” сикерткәндә, теләкләр, бала йоклатканда әйтелә торган шигырьләр өйрәнү.
- Дәрдмәнднең “Бәллү” шигырен өйрәнү.
- Татар халкының милли биюен өйрәнү.

**Катнашучылар:**

Әби, бабай, 2 кыз, 2 малай, әти, әни.

**Чараның барышы.**

**Тәрбияче: -**Хәерле көн, балалар!

Талгын гына җыр ишетелә:

Әлли-бәлли итәр бу

Мәдрәсәгә китәр бу;

Тырышып сабак укыгач,

Галим булып җитәр бу.

Йокла, углым, йом күзең,

Йом-йом күзең, йолдызым;

Кичтән йокың кала да,

Елап үтә көндезең.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!*(Г.Тукай “Бишек җыры”)*

**Тәрбияче:** Ишетәсезме, нинди моңлы җыр ишетелә. Сезнең мондый җыр ишеткәнегез бармы?

**Балалар:** Бар.

**Тәрбиче:** Балалар, бу бишек җыры. Бишек жырлары, гадәттә, баланы бишектә тирбәтеп йоклатканда көйләнә. Бишек тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртә башлаганнар.

Бишек электән ук табигый материаллардан хәзерләнгән. Ягы-ягы тал чыбыктан үрелгәннәре да очрый, тар гына такта кисәкләрен бизәкләп ясаганнарын да очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан рамка кебек озынча итеп эшлиләр. Аның төбенә нык тукыма тегеп куялар. Бишек сиртмә ярдәмендә ыргакка эләгә һәм түшәмгә ныклы итеп беркетелә *(бишек күрсәтелә).*

Балалар, сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы? Чыбылдык ул – бишек өстенә каплап куела торган тукыма. Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый. *(чыбылдык күрсәтелә)*

Бүген бер йортта зур сөенеч – бәби туган. Әйдәгез, бергәләп карап китик әле шул мизгелләрне.

*Авыл өе. Өстәл янында бабай, әби һәм ике оныкчыклары. Алар чәй эчеп утыра.*

**Әти**: *(ишектән килеп керә)*. Сөенче, сөенче, балакайларым! Дөньяга аваз салып сезнең энегез туды!

**Әби, бабай**: - Зур шатлык белән килгәнсен, улым! Әйдәгез, әйдәгез узыгыз, балалар.

*Әни баласын гаиләдәге бөтен кешегә күрсәтеп чыга. Һәрберсе теләк теләп чыга.*

**Әни**:

Минем улым дәү кебек,
Урмандагы имән кебек.
Ике күзе янып тора,
Кара бөрлегән кебек.

**1 нче кызы:**

Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә.
Энем йокыга киткәч,

Әнисе дә ял итә.

**Малай** :

Әлли бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Йокыларга киткәчтен.
Бик дәү булып үсәр бу.

**Әти** :

Әттә, әттә, эттәти,
Минем улым бик тәти.
Минем улым акыллы да,
Йөреп китәр ул тәпи.

**Бабай:**

Үсә-үсә бәбкәем,
Үсә-үсә зур була.
Кояш кебек сөйкемле,
Үзе сүзгә җор була.

**Балалар**: Әти-әни без сезгә бүләк әзерләдек (*Биилэр). Бала тавышка уянып елый башлый. Әни бишектә тибрәтә башлый. Бала һаман елый.*

**Әби:** И-и балалар, сабыйга ана назы, йөрәк җылысы кергән бишек җыры кирәк ул. Әби-бабаларыбыз элек-электән әйтеп килгәннәр, бишек җыры тыңлап үскән баланың теле иртә ачыла, сәләтле, акыллы бала булып үсә. Ул аны тынычландыра, йоклата.

**Әни**: Чынлап та истә минем бу җырлар. Әйдә әле җырлап җибәрик.

Кыйгач кашым,
Асыл ташым!
Йоклаек икәү!

Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү бәү!

*Дәрдмәнднең "Бәллү" шигыре, Р.Әхъярова көе*

*Катнашучылар бергәләп бәби тотып чыгып китәләр.*

**Тәрбияче:** Ана бишек җыры җырлаганда сабыена үзенең изге теләкләрен тели. Бала елаганда да, ана сабыйны бишек җыры көйләп юата. Бала җырны тыңлап изрәп йокыга китә.

-Балалар, сезгә әниләрегез бишек җыры җырлыймы? *( балалар җырлап күрсәтәләр)*

-Балалар, ишеттегезме, бишек җырында әнисе сабыена нинди матур сүзләр белән эндәшә?
-Дөрес, балалар, әни баласына бары тик матур, назлы сүзләр белән генә эндәшә: алсу алмам, бердәнберем, терәгем, алтыным, бәхетем, күз нурым, бәхет йолдызым.
- Ә сезгә әниләрегез нинди ягымлы сүзләр әйтә соң? Әйдәгез, без моны белү өчен “Ягымлы сүзләр” уенын уйнап алабыз. Бишек җыры башлануга бер-беребезгә курчакны тапшырабыз. Көй туктагач, кемдә курчак кала, шул ягымлы сүз әйтә.
-Балалар сез бүген нинди яңалыклар белдегез?
-Әти-әниегезгә, дусларыгызга нәрсәләр сөйләрсез?
-Сау булыгыз!

## “ЯҢГЫР ТЕЛӘҮ ЙОЛАСЫ”

***Сәлимова Ләйсән Камил кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*«Бала үсеше үзәге – Арча шәһәре 4 нче балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** Татар халкының йолалары, гореф-гадәтләре ярдәмендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар халкының онытылып барган милли бәйрәмнәре белән таныштыру, аларга карата уңай караш тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Табигать күренеше, казан асу җайланмасы, кирәкле савыт-сабалар, урманга бару көе, уенчык атлар һәм арба, төрле ярмалар, кечкенә итеп туракланган кәгазьләр, кечкенә уенчык чиләкләр.

**Тәрбияче:** Исәнмесез-саумысез, балалар, килгән кунаклар! Ничек хәлләрегез? Балалар, мин сезне бүген урманга кечкенә генә сәяхәткә дәшеп калам. Сез ризамы?
**Балалар:** Әйе, без риза.
**Тәрбияче:** Мин бик шат. Безнең сәяхәт берничә тукталыштан торачак, без бүген уйнарбыз, җырларбыз, шигырьләр сөйләрбез. Ә сәяхәткә без нинди транспортка утырып барырбыз?
**Балалар:** Автобус, машина...
**Тәрбияче:** Безнең автобуска, машинага утырып сәяхәткә барган бар. Мин сезгә бүген Ибрай бабайның атлы арбасына утырып урманга барырга киңәш итәм. Киттекме?

**Балалар:** Киттек.

*Урманга бару. (Балалар арбага тезелеп утыралар). (Музыка яңгырый).*

**Беренче тукталыш:** Таныштыру.

**Тәрбияче:** Балалар, менә без беренче тукталышка килеп җиттек. Карагыз әле, урманда ничек матур, чиста һава!.. Тик менә озак вакыт яңгыр яумый торса, урмандагы барлык тереклек кибә, сулыга башлый, урман гына түгел – барлык җир йөзе, андагы һәрбер тереклек суга сусый. Балалар, ә беләсезме, татар халкында шундый онытылып барган “яңгыр теләү” йоласы бар. Бу көнне олылыр: әби-бабайлар бисмилла әйтеп намаз укыйлар, яңгыр сорыйлар; ә инде яшьләр һәм балалар төрле ярмалардан ботка пешерәләр, уеннар уйныйлар, яңгыр сорап җырлар җырлыйлар. Әлеге йоладан соң яңгыр ява. Бу еллар күп авылларда уйнала, тик ул онытылып барган йолалардан санала. Әйдәгез, без дә бүген яңгыр теләү йоласын үтик!

**Тәрбияче:** Икенче тукталышка барыйк.

**Икенче тукталыш:** Бисмилла уку.

**Тәрбияче:** Менә икенче тукталышка килеп җиттек. Йола үтәлсен өчен беренче бисмилла уку кирәк. Безне шушы урманга алып килгән Ибрай бабайны бисмилла укырга чакырыйк. *(Бисмилла тыңлау).*

**Тәрбияче:** Ә хәзер безгә ботка пешерер вакыт та җитте. Балалар, ботка пешерер өчен нәрсәләр кирәк?

**Балалар:** Сөт, су, тоз, ярмалар...

**Тәрбияче:** Молодцы!

**Өченче тукталыш:** Ботка пешерү.

**Тәрбияче:** Хәзер безгә ботка пешерергә кирәк. Кем булышыр?

**Балалар:** Без!.. *(Ботка пешерү процессы башлана).*

**Тәрбияче:** Ботка пешкәндә менә бу такмакны әйтү кирәк. Әйдәгез, барыбыз бергә әйтик.

*Яңгыр яу, яңгыр яу!*

*Без сорыйбыз Ходайдан,*

*Арыштан, бодайдан,*

*Пәрәмәчтән, күмәчтән.*

*Сыерларның сөтләре*

*Аз булмасын, күп булсын.*

*Игеннәрнең башлары*

*Ач булмасын, тук булсын.*

**Дүртенче тукталыш:** Уен уйнау.

**Тәрбияче:** Боткабыз пешә торсын, без уен уйнап алыйк. Уенның исеме **“Кулъяулык алыш”** дип атала. Түгәрәккә басабыз, музыка башлана, кулъяулыкны түгәрәк буенча җибәрәбез, кемдә музыка туктый шул җәза үти. *(Уен уйнала).*

**Бишенче тукталыш:** Җыр җырлау.

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез, яңгырны чакырып бер җырлап алыйк.

**Балалар:** Җырлыйк! *(Җыр “Әйе шул, шулай шул”).*

*Без җырлыйбыз, җырлыйбыз,*
*Ялындырып тормыйбыз.*
*Яңгыратып басу-урманнарны,*
*Чакырабыз яңгырны.*
*Әйе шул, әйе шул*
*Чакырабыз яңгырны.*

**Тәрбияче:** Әйдәгез, уен уйнап алыйк. Яңгыр яумый да яумый, су сибеш уены уйныйк. *(Кечкенә уен чиләкләре һәм кәгазьләр).* Уенны башлыйбыз һәм әйтем әйтик.

*Яңгыр яу, яу, яу,*
*Иген-ипи күп булсын.*
*Яу, син, яу килеп кенә*
*Җиргә ямь биреп кенә,*
*Яңгыркаем яу, яу, яу.*

**Тәрбияче:** Ботка да пеште. Без бүген сезнең белән яңгыр теләү йоласын үтәдек. Такмаклар әйтеп җырлар җырладык, уеннар уйнадык, ботка пешердек. Ботканы тәмле итеп ашыйк та, кайту ягына кузгалыйк. Алдагы тукталыш.

**Алтынчы тукталыш:** Ботка ашау.

**Тәрбияче:** Менә балалар кире бакчабызга кайтырга вакыт. Ибрай бабайны аты белән чакырыйк, арбага утырып кайтыйк.

*Бакчага кайтканда яңгыр ява, балалар шатлана.*

# “ДӘҮ ӘНИГӘ САБАНТУЙГА КУНАККА”

***Билалова Гөлназ Галимҗан кызы***

*Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы*

*“Мишутка” балалар бакчасы*

*муниципаль мәктәпкәчә яшьтәге балаларга*

*белем бирү бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларда милли бәйрәмнәр турында белемнәрен үстерү. Балаларга халкыбызның милли бәйрәме – Сабантуйның язгы-җәйге бәйрәм икәнен, бөтен җирдә зурлап үткәрүләрен аңлату. Татар халкының йола-бәйрәмнәренә хөрмәт тәрбияләү.

*(Сабантуй көе яңгырый. Зал бәйрәмчә бизәлгән)*

**Алып баручы:** Исәнмесез, балалар! Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Без бүген татар халкының олы бәйрәменә Сабантуйга җыелдык. Сабантуй – ул хезмәт һәм дуслык бәйрәме. Сабантуй –ул һәркемнең көтеп алган бәйрәме. Котлы булсын Сабантуйлары!

Сабан туе-хезмәт туе,
Шатлык һәм бәхет туе.
Бәйрәм итик көн буе!
Котлы булсын, котлы булсын
Ямьле сабантуйлары!

**Сәхнәләштерү**.

**Җиһазлау:** Өй күренеше, авыл күренеше, сабантуй мәйданы.

**Катнашалар:** алып баручы, әни, дәү әни, кыз, Кәҗә белән Сарык, Чуар тавык, Батыр, Шүрәле, Чукмар белән Тукмар.

**Өй күренеше**

**Әни:** Кызым, кәрәзле телефоныңны ал әле, шалтыраталар.

**Кыз:** Алло, алло!

**Дәү әни:** Кызым, мин әле бу-дәү әниең, исәнме!

**Кыз:** Ә, дәү әнием, исәнме! Ничек яшисең, авырмыйсыңмы?

**Дәү әни:** Әйбәт, кызым! Сезне бик сагынам, бигрәк тә сине күрәсем килә.

**Кыз**: Мин дә сине бик сагындым, дәү әнием!

**Дәү әни:** Кызым, әйдә безгә килегез. Бүген бездә Сабантуй бәйрәме.

**Кыз:** Нәрсә ул – Сабантуй, дәү әнием?

**Дәү Әни:** Сабантуй – бик күңелле бәйрәм ул. Анда жырлыйлар, биилэр, төрле уеннар уйныйлар.

**Кыз:** Ә, алай булгач, кайтабыз, дәү әнием. Үзем белән дусларымны да алам.

**Дәү әни:** Әйдәгез, кайтыгыз, балакайларым! Мин хәзер үк тәмле әйберләр пешерермен.

*(Кыз шатлана-шатлана әнисе янына килә ).*

**Кыз:** Әнием, дәү әнием безне кунакка –Сабантуй бәйрәменә чакырды.

**Әни:** Ярар, кызым, бик яхшы булыр. Син бар тизрәк, дусларыңны чакыр, юлга чыгарбыз.

*(Кыз дуслары янына чыга).*

**Кыз:** Кызлар, малайлар, килегез эле тизрэк! *(Дуслары йөгерешеп киләләр)*

**Кыз:**Дусларым, мин сезне дәү әниемә кунакка алып барам, барасызмы?

**Бала:** Барабыз! Ә нинди бәйрәм соң ул Сабантуй?

**Кыз:** Баргач күрербез! Күчтәнәч тә алыйк. Дәү әнием конфет ярата.

Әйдәгез,әйдәгез
Кунакка дәү әнигә.
Ул инде безне көтә.
Сабантуй матур үтәр.

*( Балалар автобуска утырып, җырлый-җырлый, юлга кузгалалар)*

**Авыл күренеше.**

**Дәү әни:** Әйдәгез, балакайларым, исән-сау килеп җиттегезме?

**Кыз:** Дәу әнием , сиңа күчтәнәчләр алып кайттык. Менә синең яраткан конфетлар, дәү әнием!

**Дәү әни:** Рәхмәт, балакайларым. Сез үзегез –күчтәнәч.

**Кыз:** Дәү әни, нинди бәйрәм соң ул Сабантуй?

**Дәү әни:** Балалар, Сабантуй ул - халкыбызның иң яраткан, иң күңелле бәйрәме. Аңа әзерлек алдан ук башлана. Гаиләдә хатын-кызлар өй җыештыралар. Яшьләребез бәйрәм башланырга берничә көн калгач, сөлге җыеп йөриләр. Әнә, күрәсезме, бабагыз атны бизәп җигеп тә куйды. Әйдәгез, бергәләп, атларга утырып, без дә бүләк җыярга чыгыйк!

**Алып баручы**:

Шатлыклар күңелебездә,
Ал кояш күгебездә,
Килегез, дуслар, кунакка
Сабантуй буген бездә.

Без уйныйбыз, уйныйбыз,
Якты көннән туймыйбыз.
Сабан туе гөрләп торсын,
Биибез дә җырлыйбыз!

**Алып баручы**: Ә хәзер Сабантуй уеннарын башлыйбыз. Карагыз әле, карагыз, мәйданда Чукмар белән Тукмарыбыз сугыша. Чукмар, Тукмар, нигә сугышасыз?

Менә сезгә
Икегезгә ике капчык
Ягез әле, тотыгыз.
Сабан туенда ярышып,
Сез дә бүләк алыгыз.

*(Балалар уенны дәвам итәләр).*

**Алып баручы**: Кунакка Гали белән Кәҗә дә килгән. Әйтегез әле, сезнең нинди ярышта катнашасыгыз килә?

**Кәҗә:** Безнең су ташу ярышында катнашасыбыз килә.

Менә сезгә сулы чиләк,
Көянтә ал иңеңә.
Йөгер тизрәк, иң алдан кил,
Егыла гына курмә.

*(Балалар чиратлашып " Су ташу" уенын дәвам итәләр).*

**Алып баручы**: Ә хәзер концерт мәйданчыгына юнәлик.

**Бала:**
Тыпыр-тыпыр тыпырдый,
Аяк бер дә тик тормый,
Бию көе уйналсын.
Ә кызлар биеп алсын.

*("Кәсәләр " бию)*

**Бала:** Матур биисез икән,
Ардым, димисез икән.
Эх, тыңлар идек хәзер
Матур татар җырларын.

*( Җыр " Гүзәл Туган ягыбыз")*

**Алып баручы**: Чуар тавык килә, йомырка алып килә. Чуар тавык, бу йомырка белән нишлибез?

**Чуар тавык:**
Кашыкка салып күкәйне
Йөгерегез тизрәк.
Күрик әле бу ярышта
Кайсыгыз житезрәк?

*(Йомырка белән йөгерү ).*

*(Сөйләшә – сөйләшә кәҗә белән сарык мәйданчыкка керә)*

**Кәҗә:** Әйдә, Сарык,   шунда барыйк.

Безнең анда икәнлекне бүреләр дә белмәсләр.

**Алып баручы:** Әйдәгез, рәхим итегез, бездә дә буген Сабантуй бәйрәме. Кәҗә, Сарык безгә капчык киеп йөгерү ярышына капчык кирәк, капчык биреп торыгыз әле.

Кемнәр җитез, кем өлгер,
Минем янга килегез.
Әйдә, карыйк узышып,
Капчык киеп ярышып.

*(Капчык киеп йөгерү)*

**Алып баручы**: Балалар, Сабатуйның күркәм йоласы – ат чабышы.

Алай итик әле без,
Болай итик әле без.
Күңелле итеп бергә-бергә
Уйнап алыйк әле без.

*( “Ат чабышы “уены)*

**Шүрәле керә:** Исәнмесез, балалар!

**Алып баручы**: Балалар, безнең бәйрәмгә кем килде?

**Балалар:** Шүрәле.

**Алып баручы:** Шүрәле, бездә бүген бәйрәм, балалар белән ярышларда катнаш.

*(Былтырга күрсәтеп)*

**Алып баручы:** Шүрәле, менә безнең Батырыбыз.

**Шүрәле:** Ничек инде ул - Батыр?! Ә мин? Мин бит ел буе көч җыйдым, бернәрсә эшләмәдем, яхшы ашадым.

**Алып баручы:** Шүрәле, син борчылма, елама, син өлгердең. Безнең балалар сиңа Батыр белән көрәшергә рөхсәт бирәләр .

*( Былтыр белән Шүрәле көрәшәләр. Былтыр җиңә. Балалар көрәшне дәвам итәләр.)*

**Әби чыга:** Мактана дип уйламагыз,
Мин урынлы мактанам:
Чөнки бу чүлмәкне
Күрми дә вата алам.

*(“ Чүлмәк вату” уены)*

**Җыр:** “Дустым бар”

**Алып баручы:** Дуслар, көтеп алган Сабантуй ахырына якынлашты.

**Балалар:** Рәхмәт, кунакка килдек
Сабантуйларны күрдек.

Җырладык та, уйнадык
Күңел ачтык, биедек!

Сабантуймы , Сабантуй-
Уеннар туе бит ул,
Тәм- томнар сые бит ул,
Җиңүләр уе бит ул

*Күмәк җыр " Сабантуй җыры "*

## "СОЛДАТКА ОЗАТУ КИЧӘСЕ"

***Галимуллина Гөлнара Рүзэл кызы***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 9 нчы балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**
– балаларның татар халкының милли гореф-гадәтләре белән таныштыру, патриотик тәрбия бирү;
– балаларда бу гореф-гадәтләргә, йолаларга хөрмәт, ихтирам, милли җырлы-биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү;
– гореф-гадәтләренә, йолаларга, милли уеннарга хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Җиhазлау:** залда авыл йортының эчке күренеше: өстәл, самавыр, чиккән сөлгеләр.

**Кичә барышы**

**1 нче алып баручы.**
Солдат булды егет, менә китә,
Күз карашы чак-чак монсу да.
Ни әйтергә белми энисе дә:
Шатлык та бар, бераз борчу да.
Шатланмаслык мени: улы анын
Егет булып житкән, ләбаса.

Тик шулай да ана ул хезмәткә

Үзе барыр иде, яраса.

Борчыла шул инде әни күңеле,

Җибәрәсе килми күз нурын.

Насыйп булсын солдат егетләргә

Бу тормышта табу үз юлын.

**2 нче алып баручы**.

Исән генә йөрсен балам, диеп

Изге теләк тели аналар.

Туган илен сагынып хатлар язар

Чит җирләрдә йөргән балалар.

Солдат булды егет, менә китә

Еракларда аның уйлары.

Туган якларына алып кайтсын

Исән-имин аны юллары!

*(Өстәл янында әби-бабай, әти-әни, солдаттан кайткан малай, солдат малай, кызлар, малайлар утыралар.)*

**Солдат малай.** Туганнарым, дусларым, менә миңа да армия сафларына китәргә вакыт җитте. Минем өчен изге теләктә торыгыз.

**Армиядә хезмәт итеп кайткан солдат**. Энем, мин үзебезнең ил алдындагы бурычыбызны үтәп кайттым. Чират сиңа да җитте. Сиңа уңышлар телим. Кыю бул, дәрәҗәңне төшермә. Татар егетләре һәркайда мактаулы.

*(Малайлар чыгып тезелеп басалар. Солдатта булган дигән җырга бию бииләр)*

**Әби.** Улым, имин хезмәт итеп туган ягыңа әйләнеп кайтырга язсын. Без сиңа хәер-догада торабыз.

**Солдат малай.** Рәхмәт, әбием.

**Бабай.** Еллар тыныч, күкләребез аяз булсын. Хәерле сәфәр, улым.

**Солдат малай**. Рәхмәт, бабаем.

*(Кызлар, малайлар торып баса. Вальс бииләр)*

**Солдат малай**. *(сөйгән кызына)*

Син мине көтәрсеңме?

**Кыз.** Көтәрмен. Борчылма.

**Солдат малай**. Вәгъдәме?

**Кыз.** Вәгъдә. Тыныч хезмәт ит, ярыймы. Менә сиңа вәгъдә билгесе – кульяулык.

**Солдат малай**. Рәхмәт. Мин аны йөрәк түремдә генә саклармын. Сау бул.

**Әтисе**. Улым, нәселебезгә тап төшермә. Яхшы хезмәт ит. Хәерле юл, улым!

**Әнисе**. Улым, минем синең өчен борчылганны беләсең. Исән-сау кире әйләнеп кайт. Хәерле юллар, сиңа улым! Исәнлектә күрешергә насыйп булсын, амин. Улым, сиңа ипи каптырам. Калган кисәкне алып куям. Ул син кайтканны көтеп торыр. *(Ипи каптыра.)*

**Әтисе.** Улым, яхшы хезмәт ит, нәселебезгә тап төшермә. Хәерле юллар сина!

**Солдат малай.** Сау булыгыз, туганнар, дуслар, классташлар, күршеләр! Сау булыгыз, әти-әни! Сау бул, …!

**Барысы.** Сау бул, … Исән-сау йөреп кайт.

**Алып баручы.**

Бәйрәм белән сине, батыр солдатыбыз!
Сине һәркөн искә алып үтәбез!
Изге бурычыңны яхшы тәмам итеп
Исән-имин кайтуыңны көтәбез!

*(Катнашучылар тезелеп басып җыр башкаралар)*

**Солдатлар**

Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган,
Зур абыйда солдат булып
Ил чикләрендә торган.
Зур абыйда солдат булып
Ил чиклэрендэ торган.
Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына.
Мин үземдә солдат булам
Үсим генә аз гына.
Мин үземдә солдат булам
Үсим генә аз гына.
Мин үземдә солдат булам
Үсим генә аз гына
Мин үземдә солдат булам
Үсим генә аз гына.

# “НӘҮРҮЗ МӨБӘРӘК БУЛСЫН!”

***Хөсәенова Гөлфия Хәйдәр кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*“Бөрбаш балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Татар халкының милли бәйрәме “Нәүрүз” бәйрәме турында балаларның белемнәрен киңәйтү. Милли горурлык хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар:**

- бәйрәмдә катнашасы килү теләге булдыру, иптәшләренең чыгышларын дикъкать белән карарга һәм тыңларга өйрәтү;
- бәйрәм мөхите булдыру, балаларда күтәренке кәеф тудыру;
- матур әдәбият һәм фольклор әсәрләрен сәнгатьле итеп башкарырга өйрәтү.

**Җиһазлар:** уеннар өчен кирәк - яраклар, кулъяулык, ачкыч, кәрзин күчтәнәчләр, бүләкләр.

**Алдан әзерлек эше:** җырлар, шигырьләр өйрәнү. Әти-әниләрне, әби-бабайларны кунакка чакыру.

*(Әби чәй өстәле әзерли. Бабай чыга.)*

**Бабай:** Хәерле иртә, карчык.

**Әби:** Хәерле иртәләр, тордыңмы, картым. Бүген дә исән-сау йоклап тордык. Аллага шөкер.

**Бабай:** Аллага шөкер! Көннәр дә озыная башлады. Әй, буген ничәсе соң әле, карчык. Числаы да онытып торам бит. Әй, картлык диген шунда.

**Әби:** Мартның 21-е инде бүген. Бигрәк тиз үтә бу көннәр, таң ата да, кич була.

**Бабай:** Нәүрүз бәйрәме икән бит бүген, ләбаса. Нәүрүз мөбәрәкбад, карчык! Бу бәйрәмне безгә борынгы бабаларыбыз биреп калдырган. Кешеләр бу бәйрәмне кыш үтеп, табигать яңара башлагач, көннең төн белән тигезләшкән мәлендә билгеләп үткәннәр. Нәүрүз иң шатлыклы яз бәйрәме - өмет бәйрәме булып безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Таң ату белән кешеләр учак кабызганнар, аш-су пешереп бер-берсен сыйлаганнар, төрле уеннар, ярышлар уздырганнар.

**Әби:** И, картым, елның елында балалар котлап керәләр иде, бу ел да керерләр әле. Күчтәнәчләребезне әзерләп куярбыз, ботка пешерербез, алла боерса. Син, картым, акчаларыңны хәстәрләп куй.

*(Ишек каккан тавыш ишетелә).*

**Бабай:** Әллә килеп тә җитте инде оланнар.

**1 Бала:**

Ач ишегең, керәбез,
Нәүрүз әйтә киләбез
Әй, бабакай, бабакай
Мич башыннан төш, бабай.
Биш тиен акча бир, бабай,
Нәүрүз мөбарәк булсын.

*(Бабай белән әби чыгалар)*

**Бабай:** Исәнмесез, оланнарым. Мондый мөхтәрәм бәйрәм өчен биш тиен генә акчаны табабыз инде аны. Хәзерге заманда биш тиен пүчтәк бит ул. *(Янчыгын тартып чыгара да, вак акчалар сибеп җибәрә).* Ягез әле, кайсыгыз өлгеррәк икән? Күрсәтегез әле җитезлегегезне!

**Әби:** Әй балакайларым, күптән көтә идек сезне бабагыз белән. Күчтәнәчләремне дә әзерләп куйган идем. Иң элек сез безгә матур шигырьләрегезне сөйләп күрсәтегез әле.

**2 бала:** Әйдә, кояш, сип нурыңны,
Кызганма бер дә,
Зур бәйрәм, күңелле бәйрәм
Яз бүген бездә.

**3 бала:** Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!
Кошчыкларга җырлар өйрәт,
Уйна, сайра, көл.

**4 бала:** Тизрәк кил безгә, жылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!
Куяннар туңып беткәндер,
Иссен җылы җил.

**5 бала:** Урманда бит пешермиләр
Тугәрәк калач.
Песнәкләрнең туннары юк,
Тамаклары ач.

**6 бала:** Чәчәкләр белән күмелсен
Без яшәгән ил.
Тизрәк кил безгә, жылы яз,
Тизрәк-тизрәк кил!

*Җыр “Яз килә”*

*(Убырлы карчык керә. Җеп белән урап бәйләнгән Нәүрүзбикәне алып килә)*

**Убырлы карчык:** Килми генә торсын әле яз! Менә Нәүрүзбикәне алып китеп үземнең өемә бикләп куям. Миңа да бәйрәм кирәк. Минем өемә яз китерсен, матурлык китерсен!

**Нәүрүзбикә:** Юк – юк, җибәр мине, Убырлы, мин бикләнеп яши алмыйм. Мин кешеләрне бик, бик яратам. Балаларга яз китерәсем, шатлык өләшәсем бар.

**Убырлы карчык:** Ә – ә – ә, балаларны яратасың, ә мине яратмыйсыңмы? Нәүрүзбикә: Әйбәт булсаң, явызлыклар кылмасаң, сине дә яратырмын, сиңа да җылы, якты, кояшлы көннәр алып килермен.

**Убырлы карчык:** Җылы, якты, кояшлы көннәр алып килерсеңме? Андый рәхәтлекләрне башкалар белән бүлешеп булмый инде. Әйдә, үземә генә алып килерсең андый көннәрне. Менә мин сине шушы ачкыч белән өемдә бикләп тотармын *(ачкыч күрсәтә)*. Кулъяулыгыма яхшылап төенләп куйыйм әле.

*(Ачкычны кулъяулыкка төенләп, кесәсенә салганда төенле кулъяулык төшеп кала. Убырлы Нәүрүзбикәне алып чыгып китә).*

**Әби:** Балалар, нишлибез инде? Нәүрүзбикәдән башка яз да килми, кояш та чыкмый бит.

(*Аптырап йөргәндә, төенләнгән кулъяулыкны табып ала. Чишеп ачкычын алмакчы була, чишелми. Кулъяулык "Телгә килә")*

**Кулъяулык** *(аудио язма):* Юк, мин гади яулык түгел, бик тиз генә чишелмим. Мине чишәсегез килсә, җырлап-биеп, уйнап-көлеп күңелемне күрегез. Шартымны үтәсәгез, бәлки чишелермен – ачкычлы булырсыз.

**Бабай:** Кулъяулыкның да шарты бар икән, Убырлы карчыкныкы шул ул! Балалар, без бу шартны үти алабыз бит. Әйдәгез әле, уйнап-җырлап, биеп алыйк!

*1. Уен "Капкалы" (чишеп карый, чишелми)*

*2. Уен «Кулъяулык салыш» (чишеп карый, чишелми)*

*3.Уен «Ачык авыз»*

**Әби:** *(уен беткәч)*. Әйдәгез инде кулъяулыкның төенен чишеп карыйк.

*(Яулык чишелә, ачкычны алалар. Убырлы карчык керә.)*

**Убырлы карчык:** Кая югалттым соң шул кулъяулыгымны? Сез күрмәдегезме?

**Бабай:** Күрдектә, таптык та инде. Ачкычны да кулга төшердек. Менә! *(Күрсәтә)*

**Убырлы карчык:** Минем ачкыч бит ул, бирегез!

**Бабай:** Бирми генә торыйк әле. Менә безнең балалар белән ярышып кара, җиңә алсаң, карап карарбыз.

Ярышлар:

1. "*Кашыкка күкәй куеп узышу" (Убырлы җиңелә)*

2. *"Урындык белән уен".*

*(Соңгы уенда Убырлы да катнаша, ул урындыкка утыргач, аны бәйләп куялар. Ул кычкыра, чишүләрен таләп итә).*

**Әби:** Менә, Убырлы карчык эләктердек үзеңне! Нәүрүзбикәне азат итсәң, без дә сине коткарырбыз. Риза булмасаң, чыгармыйбыз.

**Убырлы карчык:** (*еламсырап)* коткарыгыз гына, җибәрәм Нәүрүзбикәне. Үз кулларым белән китереп бирермен.

**Бабай:** Ышанып җибәрәбезме, балалар? Ярый инде, бар чык. Алып кил Нәүрүзбикәне.

*(Чишәләр, ачкычны бирә. Убырлы чыгып Нәүрүзбикәне алып керә).*

**Убырлы карчык:** Менә алып килдем – сүземдә тордым. *(үзе чыгып китә)*

**Нәүрүзбикә:** Рәхмәт, сез мине явыз карчыктан коткардыгыз.

Агымсулар кичтем мин,
Биектаулар үттем мин.
Сезне сагынып килдем мин –
Нәүрүз котлы булсын!

**Әби:** Балалар, Нәүрүзбикәне уртага алып күмәк бию биеп алыйк.

*(Бию көе яңгырый.)*

**Кыш бабай:** Исәнмесез, кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар! Миннән башка нинди бәйрәм монда?

**Бабай:** Тукта әле, Кыш бабай, кызма. Безгә Яз кызы – Нәүрүзбикә килде, без аны каршылап бәйрәм итәбез.

**Кыш бабай:** Мин әле китмәгән, алар бәйрәм итәләр. Хәзер менә карап карыйк инде, кайсыбыз көчлерәк булыр икән! Кем жиңә, шул хуҗа булып калачак. Кул көрәштерәбез, кем ота – шул җиңүче була.

*(Кыш бабай белән Нәүрузбикә ярышалар)*

**Кыш бабай:** Бу юлы Нәүрүзбикәбез җитез булып чыкты. Хәзер кем көчлерәк булыр икән? Әйдә, Нәүрүзбикә, тагын сынашып карыйк. Хәзер мин күрсәтәм!

*(Кыршау тартышу, балалар да ярдәм итәләр)*

**Әби:** Балалар, әйдәгез Нәүрүзбикәгә булышабыз! Сез дә көч сынап карыйсызмы?

*(Балалар да ярыша)*

**Кыш бабай:** Туктагыз әле туктагыз, әйдә әле Нәүрүзбикә биеп карыйк, кем матуррак биер икән.

**Нәүрүзбикә:** Әйдә, Кыш бабай, биибез.

*(Кыш бабай, Нәүрүзбикә, балалар бииләр)*

**Кыш бабай:** Уф арыдым, эрим, агам, ярдәм итегез!

**Бабай:** Балалар, Кыш бабай эри, озатырга кирәк. (*Кыш бабайга өрәләр)*

**Кыш бабай:** Менә күрдегезме, җинелдем. Кызым Нәүрүзбикә тырыш, җитез, көчле, эш сөючән булып чыкты. Тыныч күңелем белән урынымны сиңа калдырып китәргә әзермен. Барчагызны да тагын бер кат бәйрәмнәр белән! Исән-имин булыгыз! Сау булыгыз!

*(Кыш бабай чыгып китә)*

**Нәүрүзбикә:** Сау бул, Кыш бабай! Тынычлап ял ит.

**Бабай:** Кыш бабайны озаттык, бәйрәмебезне дәвам итсәк тә була.

*(Убырлы керә)*

**Убырлы:** Туктагыз! Туктагыз! Зинһар мине гафу итегез! Минем бәйрәмгә киләсем килгән иде.

**Әби:** Нәүрүзбикә, балалар, әйдәгез без аны гафу итик. Бергәләп татар халык җырлы-биюле уены "Кәрия-Зәкәрия" не уйныйк.

(*«Кәрия – Зәкәрия» уены уйнала)*

**Убырлы:** Зур рәхмәт сезгә, балалар! Бәйрәм белән сезне! Нәүрүз котлы булсын! Уңышларыгыз бай булсын!

*(Убырлы чыгып китә)*

**Нәүрүзбикә:** Бик матур уйнадыгыз. Ә хәзер минем сезнең тапкырлылыгызны тикшереп карыйсым килә. Мин табышмак әйтәм, кем дөрес җавап әйтә, шул күчтәнәч ала.

1. Боз һәм кар эреде

Сулар йөгерде.

Егылап елгалар

Яшьләр түгелде.

2. Көннәр озая,

Төннәр кыскара

Бу кайсы вакыт

Я, әйтеп кара. *(Яз)*

3. Лампа түгел – яктырта,

Мич түгел – җылыта. *(Кояш)*

4. Борынсыз чыпчык боз тишә. *(Тамчы)*

5. Күктән килде, җиргә иңде. *(Яңгыр)*

**Нәүрүзбикә:** Балалар, сез мине акыллы, тырыш булуыгыз белән шатландырдыгыз. Сезнең белән бик күңелле. Мин дә буш килмәдем - сезгә язгы матур, җылы көннәр, сихәтле яңгырлар алып килдем. Язгы кояш һәр көнегезне шатлыкка, бәхеткә күмсен. Мин сезгә күчтәнәч итеп татар халкының иң яраткан ризыгын коймак алып килдем.

Сыерчык сайрап үтте.

Һавалар зыңлап китте.

Шатланып каршы алыгыз,

Яз җитте бит, яз җитте!

Әйдәгез әле бергәләшеп коймак белән сыйланып алыйк

*(Әби белән бабай чыгалар)*

**Әби:** Менә боткабыз да пешеп чыкты.

Әйдәгез, түрдән узыгыз.

Ботка белән коймактан авыз итегез.

*(Ботка белән коймак ашыйлар)*

## “КАЗ ӨМӘСЕ”

***Хәлиуллина Әлфия Фәрит кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*ш.т. Байлар Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге*
*Саба 2 нче “Эллуки”балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Алып баручы.** Хәерле кич, дуслар, хәерле кич. Бәйрәмнәрегез котлы, мөбәрак булсын!

Бүген бездә каз өмәсе,

Каз өмәсе бүген бездә.

Каз йолкырга килгән кызлар,

Уңыш юлдаш булсын сезгә!

Әйдәгез, кызлар, әйдәгез. Әти казларның эшен бетерде, эш бездән генә тора. Кызлар, тизрәк эшкә тотынсак, эшебез дә тизрәк бетәр.

**Кыз:** Кызлар, жыр жырласак эшләребез җиңелрәк эшләнер. Әйдәгез, җырлыйк әле.

*Җырлый-җырлый каз йолкыйлар. Җыр: “Каз канаты”*

***Жыр «Каз канаты»***

1) *Каз канаты, каз өмәсе.*

*Елларына бер генә.*

*Гомер буе онытылмый*

*Туып үскән ил генә.*

2) *Каз канаты, каз өмәсе-*

*Борынгыдан калган йола,*

*Сез дә була, бездә була,*

*Күңел шатлыкка тула.*

........ Ләйләнең казы чистарак булган бит, кызлар.

........ Әй уңган да инде безнең Ләйлә. Нәрсәгә тотынса, шуңа кулы килеп тора.

........ Безнеке дә анsocialыкыннан ким түгел. Менә карагыз. Ялт иттердек.

*Сикереп тора, каз түшкәсен кулында сикертеп "шап-шап" итеп суккалый.*

........ Гармун тавышы ишетелә, әллә малайлар киләме?

........ Чынлап та кызлар, малайлар җырлап киләләр.

*(Малайлар жырлап керә)*

Сандугачның балалары

Талга кунганнар икән.

Кызларыбыз тырышып эшли

Бигрәк унганнар икән.

Тәрәзәдән кайсыгыз,

Карап кемне таныйсыз?

Карап тилмереп торганчы

Ник чакырып алмыйсыз?

........ Кызлар, канатлар алыгыз. Канат сатабыз *(егетләр керә)*

**Малайлар.** Исәнмесез, кызлар!

**Кызлар.** Исәнмесез!

**Малай.** Кызларыгыз симез булсын!

Әй, юкла, казларыгыз симез булсын!

......... Тупсадан акча түләмичә кертмибез. Акчагыз бармы?

**Малайлар.** Акча бездә бер кесә. *(кесәләрен әйләндереп күрсәтәләр)*

........ Кызлар, малайларның бернинди дә акчалары юк.

**Кызлар:** Малайлар, сезгә кем кирәк?

**Малайлар:** Безгә матур кыз кирәк.

**К:** Ул кызыбыз бик елак.

**М:** Кәнфит, прәнник бирербез.

**К:** Кәнфит, прәнник яратмый.

**М:** Яратмаса, эләкми. Сез нишлисез, кызлар?

**К:** Без йон йолкыйбыз!

**М:** Без аларны таптарбыз.

**К:** Нәрсә белән таптарсыз?

**М:** Аяк белән таптарбыз.

**К:** Ә без сезне куарбыз *(канат белән сугалар)*

*Малайлар һәм кызлар кара-каршы җырлашалар («Челтәр өлдем читәнгә»)*

**М:** Каз канатлары йолкасыз,

Йолкып ни майтарасыз?

Бу өйләрдә жырлап-көлеп

Кемнәрне юатасыз?

**К:** Каз канатлары йолкабыз,

Йолкып эш майтарабыз.

Җырлап-көлеп, уйнап-биеп,

Күңелне юатабыз.

**Бергә:** Каз бәлеше тәмле пешә

Кызыл кирпеч мичләрдә.

Серләшәбез, сайрашабыз

Бу куңелле кичләрдә.

**Кызлар:** Әйдәгез, табышмак әйтешәбез.

1. Соскы борын – бакылдык,

Күп сөйләшә - такылдык. (Үрдәк)

2. Башы тарак, койрыгы урак,

Кычкыртып быргысын, уята барысын. (Әтәч)

3. Канаты бар – очмый

Аягы юк – йөри. (Балык)

4. Кулсыз-аяксыз тәрәзә ача. (Җил)

**Малай.** Мич тулы пәрәмәч,

Уртасында бер калач. (*Кызлар белмиләр.)*

**Малайлар.** Белмәделәр, белмәделәр. Нинди җәза бирәбез? Әтәч булып кычкырсыннар

**Ясминә**. Әтәч булып кычкыра.

**Кызлар.** Бигрәк тапкыр икәнсез малайлар, әйдәгез керегез.

**Кыз**. Бүген бездә каз өмәсе

Яңгырасын матур көй.

Биик-жырлыйк, уйнык-көлик

Гөрләп торсын безнең өй.

*Бию. Каз канатлары белән бию.*

.............Кызлар казларны йолкып бетерделәр инде. Кызлар, әйдәгез казларны монда куйыйк. Җырлап-уйнап алыйк әле.

***Җыр "Дүдәк"***

**Кыз.** Күчтәнәчләрем аз гына

Үрдәк белән каз гына.

**Бергә.** Әй, дүдәк, дүдәк, дүдәк

Басма өстендә каз үрдәк.

**Кызлар.** Кыйгак-кыйгак,

**Малайлар.** Бак-бак-бак

**Бергә.** Басма өстендә каз-үрдәк шул,

Басма өстендә каз-үрдәк.

**Малай.** Җаным кебек дусларыма

Җырлап бирим аз гына.

*Кушымта шул ук.*

*Кызлар казларны көянтәләргә элеп, бәкегә төшеп китәләр.*

**Малай.** Каз чайкыйлар безнең кызлар,

Куллары эшкә ята.

Мактаудан башка бер сүз юк,

Бу кызларга карата.

*Малайларга иләк белән каз каурыйлары бирәләр. Алар түбәндәге сүзләрне әйтеп, каурый сибеп баралар.*

**Малай.** Каурыйлары, каурыйлары

Сибелсен су буена

Казларыгыз шулай уңсын

Киләсе ел буена.

**Малай.** Кыйгак-кыйгак каз кычкыра

Каурыйларын җәлләмә.

Уңсын, уңсын казлары дип

Менә шулай сипкәлә.

*(Кызлар туңдыра башлады бит әле, биеп алыйк булмаса диешәләр. Казларны бәке читенә куеп бииләр)*

**"Парлы татар биюе"**

**Кыз**. Казларыбыз да чистарды. Җылынып та алдык. Әйдәгез, кайтабыз. *(казларны алып түгәрәккә басалар. Музыка астында кайталар.)*

**Малай.** Бәлешегез, көйми микән, кызлар?!

**Кыз.** Бәлеш, бәлеш?!

Нишләп бетте икән ул? *(Күтәреп алып чыга)*

**Кыз.** Зыяны юк. Йөзе килгән генә моның.

**Малай.** Ал да итәрбез әле,

Гөл дә итәрбез әле
Бергәләшеп, бәлештән дә
Авыз итәрбез әле.

## “ЯҢА ЙОРТНЫ КОТЛАУ” ЙОЛАСЫ

***Зиннәтова Гөлнара Барый кызы***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*“Арча 1 нче балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларны татар халкының онытыла барган милли гореф-гадәтләре, йолалары, милли ризыклары, борынгы заманнарда көнкүрештә кулланыла торган җиһазлар белән таныштыру, бу гореф-гадәтләрне, йолаларны сакларга кызыксындыру, туганнар үзара якын итеп бер-берсенә әйтә торган исемнәрне аңлату (мәсәлән: кода-кодагый, җизни, җиңги, балдыз, кайнагай, каенсеңел һ.б.) мәкаль, әйтемнәр аша татар телебезне сакларга, хөрмәт итәргә өйрәтү, татар телендә аралашуларын камилләштерү, туганлыкны саклау хисләре тәрбияләү.

**Алдан эшләнәсе эшләр:** Кода-кодагый, кияү-килен, җизни, җиңги, балдыз, кайнагай, каенсеңел, энекәш, сеңелкәш, дәү абый дип кемгә эндәшкәнне ачыклау, ир-атларның ике кул биреп күрешергә кирәклеген аңлату, элекеге заманнарда көнкүрештә кулланыла торган җиһазлар, эш кораллары белән таныштыру, шигырьләр ятлау, мәкаль, әйтемнәр өйрәнү, музейга экскурсиягә бару, презентация карау, татар халкының киемнәрен әзерләп кую.

**Җиһазлау:** экранда борынгы өй күренеше, зал уртасында чигүле ашьяулык җәелгән зур өстәл, өсәл өстендә самавар, тозлы камырдан ясалган ризыклар, чокыр- тәлинкәләр, тәсбих, сандык, стенада борынгы көзге, эскәмия, урындыклар, идәндә келәм, челтәр эленгән тәрәзә, корьән китабы, намазлык, чиккән ашьяулык, көянтә- чиләк, итле бәлеш, чәк-чәк, эш кораллары, чигүле мендәрләр, стена сәгате, кәрәзле бал, он иләү өчен иләк, урындыкка куя торган киезләр, каклаган каз; әби ролен –тәрбияче, калган рольләрне татар халык киемнәре кигән мәктәпкә әзерлек төркеме балалары башкара.

Гүзәл Уразова башкаруында “Күчтәнәч“, Нурзәдә башкаруында “Җизнәкәй“, Радик Юльякшин башкаруында “Чәк-чәк“, Фәридә – Алсу башкаруында “Парлы мендәрләр“,

И.Харисов сүзләре, Фирзәр Мортазин көе Рамил Садыйков  башкаруында “Кәрәзле юкә балы”, “Болгар кызлары” башкаруында “Күршеләр”  җырлары яңгырый.

**Барышы:**

*Өй эчендә тәсбих тартып әби утыра, татар киеменнән бер малай һәм бер кыз, сөйләшеп утыралар.*

**Әби:** И , Аллаһыга шөкер яңа өйгә күченеп чыктык бит балалар. Инде озак тормаслар, тиздән кода-кодагыйлар, кияү-киленнәр, күрше-күләннәр дә килеп җитәрләр, килен, самаварны кайнарлап куйдыңмы?

**Килен:** Әйе, әнкәй, бар да әзер.

**Әби:** Улым, капкаларны ачып куйдыңмы?

**Малай:** Әйе, әни, борчылма.

*Ишек шакыйлар.*

**Малай** *(кунакларны каршы ала, кода белән малай ике кул биреп күрешәләр)*: **Әйдүк, түрдән узыгыз.**

**Кода:** Әссәләмүгәләйкүм, кадерле кодагый, кияү, кызым.

**Әби:** Вәгәләйкүмәссәләм, хөрмәтле кода-кодагый, исән-сау гына килеп җиттегезме?

**Кодагый:** Әйе, Аллаһыга шөкер, ерак араларны якын итеп сезнең яңа йортка күченүегезне котлап килеп җиттек, я бер дога кылыйк. *(Утырышып дога кылалар)*

**Кода:** Хәерле бәрәкәт бирсен йортка, әәмиин.

**Әби:** Җаннарыгызга саулык бирсен, әәмиин.

**Кода:** Электән килгән йола буларак, яңа йортка буш кул белән килмәдек, күчтәнәч алып килдек. *(Г.Уразова башкаруында “Күчтәнәч“ җыры яңгырый, экранда корьән китабы, намазлык, чиккән ашьяулык рәсемнәре)*

**Кода:** Йортка бәрәкәт иңсен, дип-
Корьән бүләк итәбез.
Намаз укып, зекер әйтеп,
Аллаһ кушканча яшәгез!

**Кодагый:** Чигүле ашьяулыгым-
Сезгә минем бүләгем.
Ашлы-сулы булыгыз!
Кабул булсын теләгем!

*(Бүләкләрне тапшыралар)*

**Әби:** Аллаһының рәхмәтләре яусын кода-кодагый, бүләкләрегез һәм изге теләкләрегез өчен!

**Килен:** Әти-әни түрдән узыгыз, утырыгыз!

*(Ишек шакыйлар)*

**Малай:** *Әби белән бабайның аяклары җиңел булды, тагын кунаклар килде. (исәнләшәләр, кунакларны каршы алалар.  Апа, җизни керәләр. Ир-атлар ике кул биреп күрешәләр. Кулларында бүләкләр. Нурзәдә башкаруында “Җизнәкәй“ җыры яңгырый, экранда көянтә-чиләк, итле бәлеш  рәсемнәре)*

**Җизни:** Хәерле иртәләр, кадерле туган-тумачалар.

Яңа  йортыгызны котлап-
Бездән сезгә зур бүләк.
Чишмәләрдән су ташырга-
Менә көянтә-чиләк.

**Апа:** Исәннәрмесез, саулармысез,  кадерле туганнарыбыз.

Йортыгыз котлы булсын,
Хуҗалары сау булсын!
Игеннәре гел уңсын,
Ризыклары күп булсын!

Менә шушы итле бәлештән авыз итәргә насыйп булсын, әәмиин! *(Бүләкләрне тапшыралар)*

**Килен:** Апа, җизни, безне зурлаганыгыз өчен Аллаһы Тәгалә сезне дә зурласын!

**Әби**:  Балалар, түрдән узыгыз, утырыгыз! *(Ишек шакыйлар)*

**Малай:** *(исәнләшәләр, кунакларны каршы алалар, кайнагай белән сеңлекәш  күчтәнәчләр тотып керәләр. Ир-атлар ике кул биреп күрешәләр. Радик Юльякшин башкаруында “Чәк-чәк“ җыры яңгырый, экранда чәк-чәк, эш кораллары рәсемнәре)*

**Кайнагай:** Олы йортка ни кирәк? Кече йортка шул кирәк, дип
Әйткән бит борынгылар .
Эш кораллары һәрвакыт ,
Алыштыргысыз булырлар!

**Сеңлекәш:** Котлап яңа өегезне,
Пешердем тәмле чәк-чәк.
Тыныч гомер кичерегез,
Матур булсын киләчәк! *(Бүләкләрне тапшыралар)*

**Малай:** Бик зурлагансыз, рәхмәт яусын!

**Әби:**  Балалар, рәхим итегез, җайлап утырыгыз! *(Ишек шакыйлар)*

**Малай** *(исәнләшәләр,  кунакларны каршы алалар, дәү абый белән җиңги  күчтәнәчләр тотып керәләр.  Ир- атлар ике кул биреп күрешәләр. Фәридә – Алсу башкаруында “Парлы мендәрләр“ җыры яңгырый, экранда чигүле мендәрләр, стена сәгате рәсемнәре)*

**Дәү абый:**  Хуҗаларга телибез,
Сау-сәламәт яшәргә.

Сәгать телләре шикелле,

Армый-талмый эшләргә.

**Җиңги:** Парлы ап-ак мендәрләр,

Алып килдек өй котлап.

Яшәгез мул тормышта,

Шатланып, биеп, җырлап. *(Бүләкләрне тапшыралар)*

**Малай:** Хай, бик зур рәхмәт сезгә!

**Әби:** Балалар, Аллаһы Тәгалә сезгә үзегезгә дә уйламаган җирләрдән зур дәүләтләр бирсен, әәмиин!! *(Ишек шакыйлар)*

**Малай:** (исәнләшәләр, кунакларны каршы алалар, энекәш белән каенсеңел күчтәнәчләр тотып керәләр. Ир-атлар ике кул биреп күрешәләр. Рамил Садыйков башкаруында “Кәрәзле юкә балы” җыры яңгырый, экранда кәрәзле бал, он иләү өчен иләк рәсемнәре)

**Энекәш:** Туганыбыз килдек сезнең,

Яңа йортны котларга.

Дога кылып, теләк телик –

Бәрәкәт килсен йортларга.

**Каенсеңел:** Менә бездән күчтәнәчкә,

Кәрәзле юкә балы.

Нигезегез нык булсын,

Изге теләкләр бары.

Он иләргә бик кирәк,

Шушындый матур иләк.

Хуҗабикә шат булсын!

Камырлары гел уңсын! *(Бүләкләрне тапшыралар)*

**Килен:** Олы рәхмәтебезне җиткерәбез сезгә! *(Ишек шакыйлар)*

**Малай:** *(исәнләшәләр, кунакларны каршы алалар, күршеләр күчтәнәчләр тотып керәләр. Ир-атлар ике кул биреп күрешәләр. “Болгар кызлары” башкаруында “Күршеләр” җыры яңгырый, экранда урындыкка куя торган киезләр, каклаган каз рәсемнәре)*

**Күршеләр:** Каклаган каз белән сыйлыйк,

Кадерле күршеләрне.

Күрше хакы-Алла хакы,диләр,

Дус-тату яшик әле! *(Бүләкләрне тапшыралар, экранда зур өстәл артында утыручы кунаклар күренеше)*

**Малай:** Күршеләребез, түрдән узыгыз!

**Килен:** Чиксез рәхмәтебезне, тирән ихтирамыбызны белдерәбез!

**Әби:** Кадерле кода-кодагыйлар, туганнар, балалар, хөрмәтле күршеләр. Әйдәгез, табын янына рәхим итегез! Кунак-ашы, кара-каршы дигән безнең татар халкыбыз. Безнең яңа йортка күченүебезне котлап, алып килгән күчтәнәчләрегез, бүләкләрегез, изге теләкләрегез өчен әҗер-саваплары булсын, Аллаһының олы рәхмәте яусын! Сезгә менә бу тәсбихларны бүләк итәбез, Аллаһы Тәгаләгә зикер кылып, сау-сәламәт яшәгез! *(тәсбихлар өләшә)*

Йорт эчендәге серләрне, туганлыкның җепләрен саклап, дуслыкның кадерен белеп, күршеләребезнең хагын хаклап, бер- беребезгә терәк булып яшәсәк иде. Аллаһы Тәгалә һәрберегезнең йортына бәрәкәт бирсен, ут-күзләрдән, яман сүзләрдән сакласын! Әйдәгез бу яңа йортка, нигезгә, шулай ук алып килгән бүләкләргә, күчтәнәчләргә дога кылыйк. *(Барысы да өстәл тирәли утырышалар, дога кылалар)*

*"Яңа йортны котлау" йоласы шуның белән тәмам.*

## "КИЧКЕ АШ ВАКЫТЫ КҮРЕНЕШЕ"


***Гафурова Ләйсән Зөфәр кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*ш.т. Байлар Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге*
*Саба 6 нчы "Балачак" балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*


*Карт әби йон эрләп утыра. Кайнана мичтән икмәк ала. Өстен каплап тора.*

**Кайнана:** Кызым, ашны булдырып куйсак була инде.

**Килен:** Яхшы, әнкәй. Хәзер булдырам. *(чыгып китә) Кайнана өстәл янында икмәк кисә.*

**Карт әби:** Кызым, берүк икмәкнең валчыкларын чәчә күрмә. Икмәк –тормыш нигезе. Икмәкнең валчыгы да изге һәм кадерле.

**Кайнана:** Бик дөрес әйтәсең, әнкәй. Икмәкне кадерләп, саклап тоту – ул барыбызның да изге бурычы.

*Балалар керә.*

**1 Бала:** Әбием, әбием! Без бик ачыктык.

**2 Бала:** Ашыйсыбыз килә.

**3 Бала:** Бигрәк тәмле ипи исе чыккан.

**4 Бала:** Минем дә ашыйсым килә.

**Килен:** Әтиегез кайтмады бит әле. Бар, Байбулат, капка төбенә чыгып, карап кер әле. Кайтмыйлар микән?

**1 Бала:** Хәзер. *(чыгып китә)*

*Карт әби оныкларын чакыра. Баларга яшереп кенә шикәр бирә.*

**Карт әби:** Балаларым, килегез әле яныма. Беләсезме, татар халкында, элек-электән килгән гадәт бар – гаиләдә барысы да җыелып бетмичә, өстәл янына утырмыйлар. Бу олыларга карата хөрмәт күрсәтү, ризыкны олылау булып санала.

**Балалар:** Аңладык, әбием.

*Балалар тыңлап тора.*

*Ат тавышы ишетелә. Керәләр. Малай алдан йөгереп керә.*

**1 Бала:** Кайттылар!

**Балалар:** Урааа! Ашыйбыз!

**Бабай:** Әссәләмәгаләйкүм!

**Әти:** Әйбәт кенә тордыгызмы?

**Кайнана:** Аллага шокер, улым. Барысы да яхшы. Әйдәгез, кулларыгызны юыгыз да, табын алдына рәхим итегез.

**2 Бала:** Әйдә, әбием, барысы да җыелып бетте табын артына, сине генә көтәләр.

*Карт әбине оныклары өстәл янына алып килеп утырталар.*

**Карт әби:** Әйдәгез, балалар, ашар алдыннан дога укып алыйк әле.

*Дога кылалар.*

**Кайнана:** Ашларыбыз тәмле булсын!

**Барысы бергә:** Рәхмәт!

*Ашап утыралар.*

*1 Бала аягын селкеп утыра башлый.*

**Бабай:** Улым, ашаганда аяк селкеп утырмыйлар, ашыңны шайтаннар ашый дип әйтәләр.

**2 Бала:** Шайтан чакырып утырма әле, энем.

*Ашап бетерәләр.*

**Әти:** Әйдә әле, әби, бер дога укып алыйк.

*Дога укыйлар.*

*Өстәл җыештыру мизгеле.*

## “АТ ТОЯГЫ КЫЗДЫРУ”

***Диярова Гөлназ Мансур кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 8 нче балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

*Залга бер малай атка атланып йогереп йори*

**Тәрбияче:** Исәнме, егет. Кая чаптың?

**Малай:** Мин........ Иртәгә авылыбызда ат чабышы, шуңа әзерләнәм.

**Тәрбияче:** Ә беләсеңме, яшь егет. Минем бабам үзенең яшь вакыттагы истәлекләре белән бүлешкәне бар. Алар Сабантуйга бер көн кала ат чабыштырганнар. Ул тоягы кыздыру дип аталган.

Дөрестән дә, без аларны
Искә төшерик әле.
Халык йоласын кайтарып,
Бер уйнап алыйк әле.

*(уйланып китә...) Экран сүнә.*

*Чыр-чу балалар атка атланып залга керәләр.( ат тавышы килгән музыка)*

**1 малай:** Эх, егетләр, сезнең атларыгыз эзерме соң?

**2 малай:** Әзер, әзер, хәтта чәчен тарадым. *(сыйпап куя)*

**3 малай:** минеке дә әзер.

**4 малай:** Әйдәгез тикшереп карыйк.

**5 малай**: Карагыз әле, минем Алмачуарга чабам диеп кенә тора *(бер түгәрәк әйләнеп килә).*

**Алып баручы:** Туктагыз әле, чабышыр алдыннан дагаларыгызны тикшереп чыгыйк әле. Үз урынында микән.

*Ат дагасы кагу уены*

*(Балалар бер-бер артлы тезелеп басып кегльга божралар ыргыту)*

**Алып баручы:** Ә хәзер, әйдәгез, чабышып карагыз инде, кайсыгызның аты иртәгә Сабантуйга әзер?

**1 малай:** Атларны оста җигәбез
Йөгәнен тота беләбез.
И, киттек без атлылар,
Атлы кую батырлар

*Ат чабышу уены*

*(Балалар бер рәткә тезелеп басып 2 тапкыр түгәрәк ясап йөгереп киләләр)*

*Сөлге тоткан кызлар керә*

**1 кыз:** Эх, егетләр, әйтегезче, кайсыгызның аты чабышка әзер инде?

**2 кыз:** менә карагыз, мин нинди матур сөлге чиктем. Бу сөлге Сабантуйда кайсы ат беренче булып килә шуна бүләк итәм.

**1 малай:** Мин *(диеп кулыннан тартып ала)*

**1 кыз:** Эх, өлгерсең дә инде

*Сөлге белән бииләр.*

## "БИШЕК ҖЫРЫ" БӘЙРӘМЕ

***Гарифуллина Гөлназ Фидарат кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 8 нче балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

1. Балаларны халкыбызның йөрәк түреннән чыккан җәүһәрләре–бишек җырлары белән таныштыру;

2. Бишек җырларның эчтәлеген һәм тәрбияви үзенчәлекләрен ачыклау;

3. Әти - әнигә, әби-бабайларыбызга һәм моңлы бишек җырларына мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар**: Өй күренеше, сәке, бишек, чигүле сөлгеләр, мендәр һәм урын җир, диван.

**Бәйрәм барышы**

*Татар халык җыры яңгырый. Балалар залга керә, аларны Сания әби каршылый. Кулында курчак.*

**Әби:** Исәнмесез, кадерле балалар. Әйдәгез, рәхим итегез, оялмагыз. Уңайлы итеп утырыгыз. Мин Сания әбиегез булам, бу минем оныгым – Сөмбел.

**1 бала.** Сөмбел диеп, матур исем

Кушты икән кем генә?

Сөмбел гөлдән өзелеп төшкән

Чәчәк кебек Сөмбел ул.

**2 нче бала**

Әткәсенә, әнкәсенә

Ул-күз карасы кебек

Гөл арасында сайраган

Былбыл баласы кебек.

**3 нче бала**

Чәчәк кебек сөйкемле ул

Былбыл кебек моңлы ул.

Таң аткач та сүнми торган

Йолдыз кебек нурлы ул.

**Әби:** Без бүген оныгым Сөмбел белән бик күп эшләр эшләдек. Хәзер аңа йокларга вакыт. Сезнең килү әйбәт булды, миңа оныгымны йоклатырга булышырсыз.

**1 слайд (татар өе)** *Сөмбел кызымны кулда гына йоклатам һәм җырлыйм. (Әтәч тавышы ишетелә)*

**Әби:** Балалар, бу әтәчләр кызыма йокларга бирми. Нәрсә булган аларга, карагыз эле тәрәзәдән, сугышалар түгелме алар?

**2 слайд (әтәч, "Чукмар белән Тукмар" әкиятеннән өзек)**

**Әби:** әтәчләр сугышмасын өчен, әйдәгез, без аларны уйнатабыз.

**Флешмоб "Чеп- чеп чебиләрем"**

**Әби:** Мин Сөмбелне тагын йоклатып карыйм *(кулында селкетә)*. Барыбер йокламый бу кыз.

**3 слайд (ишегалды)**

**Әби:** Балалар, бәлки сез шигырь сөйләп карасыз.

**1 бала**

Үчти-үчти үчтеки, үсте китте кечтеки.

Үсте, үсте, зур булды, таза һәм матур булды,

Акыллы, зирәк булды, һәркемгә кирәк булды. (Ренат Харис)

**2 бала**

Йокла, курчак Йокла, курчак, нәни курчак,

Мин дә йоклыйм, ял итәм,

Йокласаң ял итәрсең.

Әлли-бәлли, бәү итәм. Әлли-бәлли итәрсең.

Йоклап туйгач, таза булып,

Таза булып, матур булып,

Матур булып, зур үсәм.

Курчагым, зур үсәрсең.

Әлли-бәлли, бәү-бәү. Әлли-бәлли, бәү-бәү,

Нәни курчак, тыныч ят (Гыйльмия Таһирова)

**Әби:** Болай да булмады әле, балалар. Бәлки песине чакырып карарбыз

**Балалар:**

Пес- пес- пес

Песи керә.

**Балалар:**

Мияу – мияу мышнаган,

Мич башында кышлаган,

Бүген тычкан тотмаган,

Тотар иде – йоклаган.

Песи – песи поскан,

Ике күзен кыскан.,

Кысса безне тоталмый,

Тотар иде, җиталмый.

*Хәрәкәтле уен "Песи һәм тычканнар» татар халык уены*

*Әби Сөмбелне кулында тирбәтә, бала йокламый.*

**Әби:** балалар, бер биеп алыгыз булмаса.

**4 слайд ( «Маша һәм Аю" мультфильмнан видео)**

*Флешмоб*

**Әби:** Менә гаиләгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, бала дөньяга килә. Әлбәттә, куаныч белән бергә, мәшәкатьләр дә өстәлә. Бәбине гел карап, тәрбияләп үстерәсе була. Ул борчыла да, елап та ала. Менә шул чакта әниләребез бишек җырларын көйләп, җырлап йоклаталар, юаталар. Халкыбызда бишек җырлары борын-борын заманнарда ук барлыкка килгән. Балалар сөйләшә белмәсә дә, шул авазларны тыңлап яткан, шулай рәхәтләнеп йоклап сөйләшә. *(Бала елаган тавыш ишетелә)*

Баланы йоклатканда әниләр бишек җыры белән йоклатканнар. Әйдәгез, без дә курчакларыбызны бишек җыры җырлап йоклатып карыйк. Бүген без дә кечкенә вакытта җырланган бишек җырларын искә төшербез. Менә сез кечкенә вакытта сезне дә әниләрегез бишек җырлары белән йоклатканнардыр.

Бишек җыры җырлау *(балалар үзләренең курчакларын тотып җырлыйлар)*

**Әби:** Менә Сөмбел йоклап та китте, әйдәгез, аны бишеккә салабыз. *(курчакны бишеккә куя)*

**Тәрбияче:** Сабый бишектә ята. Бишек электән ук табигый материаллардан хәзерләнгән. Ягы-ягы белән тал чыбыктан үрелгәннәре да очрый, тар гына такта кисәкләрен бизәкләп

ясаганнарын да очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан рамка кебек озынча итеп эшлиләр. Аның төбенә капчык чүпрәген тегеп куялар. Бишек сиртмә ярдәмендә ыргакка эләгә һәм тушәмгә ныклы итеп беркетелә. Бишекне әнисенең караваты янына асып куялар. Ә менә бишекләрне бүген очратып буламы соң? Бишекләр инде өйләрдә юк диярлек, аларны заманча бишек –коляскалар алыштырды.

Сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы? Чыбылдык ни өчен кирәк булган икән соң? Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый. Безнең бәбиебез дә тынычлап йокласын. Бишек җырлары бишек янына утырып та, баланы кулга тоткан килеш тә башкарыла. Әлеге җырлар аша сабый тәүге мәртәбә матурлык, ананың йөрәк җылысы, ата-ана мәхәббәте, үз халкының рухы, аһәңле теле белән, туган йорт, туган туфрак төшенчәләлре белән очраша. Элек балаларны бишектә генә түгел, ә мендәргә салып та йоклата идек.

Менә шулай, балалар, әниләрнең, әбиләрнең, дәү әниләрнең бишек җырлары – бала өчен иң беренче, иң ягымлы көй ул. Дөнья белән, табигать белән танышу туган тел аша, Тукай шигырьләре аша, бишек җырларыннан башлана.

**Әби:** Сөмбел йоклаган арада мин сезне пешергән күмәчләрем белән сыйлыйм.

## “НӘҮРҮЗ МӨБӘРӘК БУЛСЫН!”

***Шәмсемөхәммәтова Гөлүсә Илнур кызы***

*Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы*

*“Мамадыш шәһәре 4 нче “Әкият” балалар бакчасы”*

*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларны халкыбызның гореф – гадәтләре белән таныштыру.

**Бурычлар:** “Нәүрүз”–бәйрәме турында белемнәрен арттыру, фольклор запасларын баету, иҗади фикерләү сәләтләрен үстерү, туган телгә карата мәхәббәт тәрбияләү, баларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү, тәрбия традицияләренә нигезләнеп халкыбызның гореф-гадәтләре белән кызыксынуларын үстерү.

*Залның бизәлеше: зал язгы бизәкләр белән бизәлгән, кояш, чәчәкләр, кошлар сурәтләре эленгән.*

***Бәйрәм барышы:***

*Л.Батыр-Болгар музыкасы “Кайт карлыгач”- көе яңгырый, балалар залга керәләр һәм ярым түгәрәк булып басалар.*

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар! Балалар, карагыз әле! Табигать уянган, карлар эрегән, кояш елмая. Ә бу нәрсәне аңлата?

**Балалар:** Яз килде!

**Алып баручы:** Әйе, яз килде! Бүген без Нәүрүз бәйрәмен билгеләп үтәбез. Нәүрүз – ул игелек, дуслык бәйрәме. Ул тынычлыкка, матурлыкка өндәүче бәйрәм. Әйдәгез, язны җыр-биюләр, матур шигырьләр,уеннар белән каршы алыйк әле!

**Бала 1:**

Яз килә, яз килә
Кояш нурларын сибә.
Тып-тып итеп тамчы тама,
Инде кар эреп бетә.

**Бала 2:**

Яз килә, яз килә,
Сыерчыклар да килә.
Гөрләшеп, сайрашып
Жырчы кошлар да кайта.

**Бала 3:**

Әй яз-матур, яз-матур,
Хуш киләсен, уз бире.
Кунак булып килер дип,
Куптән көттек без сине.

*Җыр: «Нәүрүз, Нәүрүз килде!» (Балалар түгәрәк ясап җырлыйлар.)*

*(Җыр беткәч кыш керә.)*

**Кыш:** Туктагыз әле! Бу нинди шау-шу? Мин әле китәргә уйламыйм! Минем салкыннарым, бураннарым бар!

**Алып баручы:** Кадерле Кыш, син бик озак кунак булдың, без сине хөрмәт итәбез, тик инде яз килергә вакыт җитте!

**Кыш:** Язны кертмәс өчен мин сезгә сынаулар әзерләдем!

*Уен: «Бураннан кач»*

*(Балалар Кышның кар бөртекләрен (ак мамык) өрдереп читкә очыртырга тиеш.) (Уен беткәч Нәүрүз залга керә.)*

**Нәүрүз:** Исәнмесез, дусларым! Мин сезгә җылы кояш, яшел болыннар, кош сайрауларын алып килдем!

**Кыш:** Ай-яй, бик матур күренәсең, ләкин мин болай гына китәргә риза түгел!

**Алып баручы:** Балалар, әйдәгез, Кыш белән Нәүрүзне ярыштырабыз! Кем җиңә шул безнең белән кала, җиңелүче белән саубуллашырга туры килә.

*Уен: «Кем тизрәк карны эретер?» (Ике команда арасында уен: балалар карны (мамыкны) кояш нурлары (сары түгәрәкләр) белән алмаштыра.)*

**Кыш:** Афәрин! Сез бик җитез һәм тапкыр булып чыктыгыз! Сезнең белән хушлашырга вакыт җитте. Саубулыгыз, киләсе очрашуларга кадәр! *(Кыш чыгып китә)*

**Алып баручы:**

Салкын кышны яз жиңде,
Моны барчагыз күрде.
Кулны кулга тотынып,
Без бәйрәм итик инде.

*Бию: «Язгы тамчылар» (Балалар парлашып бии.). (Бию беткәч балалар ярым түгәрәп ясап басалар)*

**Бала 4:**

Хуш киләсез, гузәл Нәүрүз,
Язгы яңа елыбыз.
Яңа елда туры булсын,
Нурлы булсын юлыбыз!

**Бала 5:**

Яз килде, кояш көлде,
Дөньяга нур бөркелде.
Уянды бар агачлар,
Куанды алмагачлар

**Бала 6:**

Язлар, җәйләр имин килсен,
Күк йөзе аяз булсын.
Барчабызга сәламәтлек,
Бәхетләр алып килсен!

**Алып баручы:**

Яз нурлары-көмеш нурлар
Сибелсен жиргә.
Яз шатлыгы, яз бәхете,

Телибез сезгә

Язлар, җәйләр имин килсен,

Күк йөзе аяз булсын.

Барчабызга сәламәтлек,

Бәхетләр алып килсен!

Бәйрәмебез ахырына якынлашты. Тагын бер тапкыр бәйрәмнәр белән сезне, хөрмәтле кунаклар! Исәнлек-саулык, зур уңышлар телим сезгә. *(Балалар музыка астында чыгып китәләр)*

**“КАЗ ӨМӘСЕ”**

***Исламова Алия Илсур кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең гомуми үсеш бирүче төрдәге*
*5 номерлы Саба “Бэлэкэч”балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

Балалар, бүген без сезнең белән «Каз өмәсе» бәйрәменә җыелдык. Ул көз ахырында үткәрелә, салкыннар көчәя, кырлар, урманнар кар белән каплана, елгалар боз белән каплана. Бу бәйрәм авылларда бик мөһим һәм зур вакыйга булып санала.

**Бәйрәм барышы:**

*Бәйрәм уткәреләсе зал матур итеп бизәлгән. Авыл өе . Әкрен генэ музыка ишетелә.*

**Алып баручы:**

Безнең халык кунакчыл:

«Якты чырай, такта чәй, — дип

Каршы ала кунакны.

Ата-баба гадәтләрен

Без дә дәвам итәрбез.

Безгә кунакка килгәнсез -

Күнел ачып китәрсез.

Милли бәйрәмнәрнең һәркайсында халкыбызнын күркәм гореф-гадәтләре, матур йолалары, җыр-бию, уен-көлке чагыла. Кеше әлеге бәйрәмнәрдә һөнәргә, батырлыкка, тапкырлыкка һәм зирәклеккә өйрәнә.

*Акрын гына көй яңгырый. Әни, кыз кул эшләре белән утыралар.*

**Әни:** Кызым, бүген бит бездә каз өмәсе. Үзебез үстергән казларны суяр вакыт җитте. Ярдәмгә килүчеләрне тәмле каз бәлеше белән сыйларбыз. Коймак пешерербез.

**Кыз:** Әни, ә кемнәрне чакырдың син?

**Әни:** Күрше Фирая апаң килә, каладан оныклары кайткан аларны да алып киләм диде. Дәү апаң, Алма апалар килә, күрше-тирә бөтенебез җыелабыз, балам.

*Ишек тавышы. Кунаклар килә.*

**Кунаклар:** Исәнмесез, хәерле көннәр!

Сезне сагынып кайттык без.

Күчтәнәчкә татлы ризык —

Чәкчәк алып кайттык без.

Табын яме чәк-чәк дигән

Сүзләр йөри түгелме?

Һәрбер туйның иң түрендә

Урын ала түгелме.

*Күчтәнәчләр бирәрләр.*

**Әни:** Рәхмәт яусын, күчтәнәчегезгә. Чәк-чәк ул татар халкының табын күрке, милли ризыгы, кунак ашы.

**Кыз:** Әни, тагын кунаклар килә. *(татар халык киеменнән балалар белән олылар йөгереп керә)*

**Кунаклар:** Килдек ерак юллар үтеп,

Дусларыбыз янына.

Милли ризык — табын күрке,

Ямь өстәсен тагын да. *(кунаклар утырышалар)*

**Әни:** Зур рәхмәт, түрдән узыгыз. Күпме күчтәнәч алып килгәнсез. Мин сезгә хәзер аз гына каз өмәсе турында сөйләп китим әле.

Язлар җиткәч, ишекалларына яшел чирәмнәр чыккач, каз бәбкәләре дә оядан төшәләр. Яшел чирәм ашап, суда йөзеп, алар көзгә зур казлар булып үсеп җитәләр. Менә шул вакытта, җирләр туңып, карлар яугач, авылларда каз өмәләре башланып китә. Каз өмәсендәге җыр-бию, уен көлкесен сөйләп аңлата торган түгел. Җиткән кызлар каз йолкыйлар. Ә сезнең кебек балалар канат, каурый сыдыралар иде. Төнгә чаклы канат сатып «йөзек салыш», «йолдыз санау» уеннары уйныйлар иде. Күпме табышмак, мәкальләр әйтелер иде. Ә ул чакта мичтә каз бәлеше пешә. Балалар, ә сез җырлар, шигырьләр беләсезме соң? Кая сөйләп күрсәтегез әле.

**Кыз бала:**

Каурыйлары, каурыйлары

Сибелсен су буена

Казларыгыз шулай уңсын

Киләсе ел буена.

**Малай:**

Казларыгыз бигрәк матур

Таза булып ускәннәр

Ә йоннары, каурыйлары

Мамыкланып беткәннәр.

**Кыз:**

Шыгыр-шыгыр капканы

Шыгырдатмый япмабыз.

Каз өмәсе булган жирдән,

Беребез дә калмабыз.

Бөтенесе бергә: Афәрин! *(кул чабалар)*

**Кунак апа:**

Күмәк хезмәт, уен-көлке,

Була каз өмәсендә.

Кызлар - егетләр җыела,

Зур шатлык һәммәсенә.

Каз канаты,каз өмәсе,

Борыннан килгән йола.

Сездә була, бездә була,

Күңел шатлыкка тула.

Әйдэгез, бер җырлап та алыйк әле. *(“Каз канаты, каз өмәсе”-җыры)*

*Сызгырган тавыш ишетелә:* Әйдэгез, су кайнады, эшкә тотыныйк.

*Барысы бергә  чыгып китәләр. Бераздан иңнәренә көянтәгә казлар асып кызлар керә. Артларыннан апалар, әти кеше, балалар керә.*

**Әни:** Менә бит, Аллага шөкер нинди зур эш эшләдек дуслар.

**Апа:** Әйе шул, казларыгыз бик симез булган. Илгә-көнгә тынычлык, үзебезгә сәламәтлек насыйп итсен. Балалар, оныклар, туганнар белән тәмле итеп ашарга язсын.

**Барысы бергә:** Амин.

**Әти:** Эх, менә ичмасам, бу бәйрәм. Мондый мал-бәрәкәт булганда, биемичә ничек түзәргә кирәк.

*Татар халык көе яңгырый. Барысы бергә бииләр. Кызлар казларны матур итеп өстәлгә тезеп куялар.*

**Әни:** Әйдәгез, бер уен да уйнап алыйк әле. *"Йөзек салыш уены"*.

Бик матур уйнадык, рәхмәт Сезгә, кунаклар.

**Әни:** Эх, бигрәк күңелле булды безнең бәйрәм. Ә хәзер тәмле каз бәлешеннән авыз итик. Табын түренә рәхим итегез. Барысы бергә көлешә-көлешә чыгып китәләр.

*Тәмам.*

## "СӨМБЕЛӘ БӘЙРӘМЕ"

***Сафиуллина Алинә Фәрит кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге*
*7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

1. Татар бәйрәмнәренең матурлыгын күрсәтү;
2. Балаларның көз, уңыш, яшелчәләр турында белемнәрен киңәйтү;
3. Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, хезмәт кешесенә хөрмәт уяту.

**Алып баручы:** Хәерле көн, дуслар!!!

Бүген залга «Сөмбелә» бәйрәменә җыелдык. Бәйрәмебез күңелле үтсен. Балалар көлүе яңгырап торсын!

Елның сихри фасылында - көн белән төн тигезләшкән вакытта татар халкы «Сөмбелә» бәйрәмен уздырган... Ул – көзге бәйрәм, уңыш бәйрәме. Бу вакытта инде уңыш җыю эшләре тәмамлана. Табигать кышкы ялга әзерләнә. «Сөмбелә»- ул башак, иген дигән сүз. Сары чәчле, зәңгәр күзле, зифа буйлы, сүзгә тапкыр, эшкә уңган кызны да Сөмбелә дигәннәр.

**Балалар шигырь сөйлиләр:**

1. Ни арада җәй үтте,
Алтын көз килеп җитте.
Шатлык тулы бу бәйрәмне,

Балалар күптән көтте

2. Көз көннәре бик күңелле,

Бик күп җимешләр пешә.

Помидор, карбыз өлгерә,

Алмалар егылып төшә.

3 Килә шаулы Алтын көзем,

Оча яфрак, исә көзге җил,

Табигатең бигрәк сокландыргыч,

Хуш киләсен, көзем, әйдә, кил.

4.Моңлы, гүзәл,

Матур аяз көннәр,

Мул игеннәр -

Синең бүләгең.

Сокландыргыч синең табигатең,

Бигрәк матур, ай-ай күлмәгең.

**Җыр –«Көз килә»**

5. Бәйрәмебез бик күңелсез бит,

Күңелсездер сезгә дә.

Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә,

Бәйрәмнәр кирәк безгә дә.

Бәйрәмнәр кирәк һәммәбезгә дә.

6. Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта,

Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады инде бездән кошлар,

Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

**Алып баручы:** Әйдәгез, балалар, бәйрәмгә без Сөмбеләне чакырабыз!

**Балалар:** «Сөмбелә», кил безгә!

*Музыка астында «Сөмбелә» керә. (Биеп әйләнеп чыга)*

**Алып баручы**: Исәнмесез, «Сөмбелә». Без сине бик көттек.

**«Сөмбелә»:** Исәнмесез, балалар! Исәнмесез, кунаклар!

Мин сезгә буш кул белән килмәдем. Мин үземнең салкын җилләрем, яңгырларым белән килдем. Кәрзинем тулы алтын, сары, төрле төстәге яфраклар, уеннар, табышмаклар алып килдем. Әйдәгез, бергәләп зур түгәрәк ясыйбыз.

**Җырлы-биюле уен «Күрсәт әле үскәнем»**

**Сөмбелә:** Бик матур җырлыйсыз икән, балалар. Хәзер бераз ял итеп алсак та була. Сынап карыйм әле, үзегез турында табышмаклар беләсезме?

1. Җир астында алтын казык,
   Без аны алдык казып. (кишер)
2. Үсеп утыра бер чүлмәк,
   Өстенә кигән йөз күлмәк. (кәбестә)
3. Үзе йомры—ай түгел,
   Төсе сары –май түгел,
   Койрыклы—тычкан түгел. (шалкан)
4. Йодрык-йодрык булып үсә
   Алма кебек кызарып пешә,
   Үзе матур, аны кем әйтер? (помидор)
5. Кечкенә генә сары карт,
6. Кигән туны җиде кат.
7. Туннарын туныйсың,
8. Тунаганда елыйсың. (суган)
9. **«Сөмбелә»:** Булдырдыгыз, балалар, сезнең белән бик күңелле икән. Әйдәгез, уйнап алабыз.

**Уен «Бер сүз белән әйт»**

(1 кәрзиндә яшелчәләр, 2 нче кәрзиндә җимешләр, «Сөмбелә» 2 кәрзинне дә идәнгә буташтырып сибеп җибәрә, 2 бала чыга, берсе яшелчәләр җыя икенчесе җимешләрне җыя. Җыеп бетергәч «Сөмбелә» һәр баладан сорый. - Син нәрсәләр җыйдың? Бер сүз белән ничек атыйбыз?)

**«Сөмбелә»:** Яшелчә, җимешләрне бик әйбәт беләсез, булдырдыгыз. Хәзер 8 төркем балалары белән җырлы-биюле уен: «Бар матур бакча, анда кишер үсә»

**Җырлы-биюле уен: «Бар матур бакча, анда кишер үсә».**

**Алып баручы:** «Сөмбелә», безнең дә уен-ярышларыбыз бар. Әйдә сиңа без аны уйнап күрсәтәбез.

1. «Кем тизрәк» *(балалар 2 командага бүленәләр, һәр командадан берәр бала, аякларына сыңар галош киеп ярышалар.)*
2. «Гөмбәләр аланында» *(карточкалар ярдәмендә, агулы гөмбәләрне беренче команда җыя, икенче команда ашарга яраклы гөмбәләр җыя. Кем беренче җыеп бетерә, шул команда җиңүче була)*

**Сөмбелә:** Балалар, без сезнең белән бергәләп күңел ачтык, мине кыш ашыктыра, миңа китәргә вакыт җитте. Менә сезгә миннән истәлеккә яфраклар. Әйдәгез, бергәләп биеп алабыз. *«Яфрак белән бию».*

## "КАЗ ӨМӘСЕ"

***Газимова Раиля Рифовна***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*"Гомуми үсеш бирүче төрдәге Балтач*
*2нче номерлы балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларның татар халык йолалары, бәйрәмнәре турында белемнәрен камилләштерү.

**Бурычлар**:

**Үстерү бурычы:** татар халкының әби-бабайлардан килгән гореф-гадәтләрен яңарту, кызыксынучанлыкларын, сәнгатьле сөйләм телләрен үстерү;

**Тәрбия бурычы:** әдәплелек, игътибарлылык, ярдәмләшү, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү;

**Белем бирү бурычы:** гореф-гадәтләр, татар халык уеннары турындагы белемнәрен арттыру.

**Төп белем бирү өлкәсе:** Сәнгати-эстетик үсеш.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** танып белү үсеше, сөйләм үсеше, социаль- коммуникатив үсеш.

**Методлар алымнар һәм чаралар:** презентация куллану, үстерелешле әңгәмә, сораулар, уеннар, күзәтү, сюрприз момент.

**Материал һәм җиһазлар**: ИКТ (бәйрәм барышы буенча әзерләнгән презентация слайдлары кулланыла), авылча бизәлгән зал, тегелгән каз макетлары, көянтәләр, кечкенә чиләкләр, каз канатлары, үреп ясалган кәрҗин, милли киемнәр, коймак, поднос, гармун.

**Сүзлек эше**: милләт, милли, көянтә, ләгән, каурый, самавыр.

**Алдан эшләнгән эш**: "Каз өмәсе безнең якларда" дип исемләнгән видеоязма карау, халык уеннары уйнау, шигырьләр, җырлар ятлау.

### Бәйрәм барышы:

*Бәйрәм уткәреләсе зал матур итеп бизәлгән. Авыл өе күренеше. Әкрен генә музыка яңгырый. Уртага бала чыга.*

**1 кыз:** Көзге байлык! Көзге муллык!

Авылда каз өмәсе.

Яше-карты, бала-чага –

Шау-гөр кил һәммәсе! (Кереп китә)

**Хәния:** *(үз-үзенә сөйләнә-сөйләнә керә)* И-и-и, бу эш дигәне гел бетми, һич кенә дә житешеп булмый. Аллага шөкер, казып алган бәрәңгеләрне базга урнаштырдык, инде зур эшләрнең берсе генә калып бара. Авылыбызда каз өмәсе дә бетеп килә, урамда су буеннан кайтучы казлар да кимеде. Алла боерса, бүген чират бездә. Күрше кызларын да чакырдым. Озакламаслар, бик җитез кызлар үсеп килә. (Ишектән тавыш ишетелә.)

**1 кыз:** Исәнме, Хәния әби! Әллә казларыңны йолкып та бетердеңме?

**Хәния:** Исәнме, кызым. Килеп тә җиттегезмени? Бик иртә кердегез әле.

**2 кыз:** Шундый матур көз иртәсендә йоклап ятып була мени, Хәния әби. Узең дә әнә барысын әзерләп куйгансын, әллә казан астына да яктыңмы?

**Хәния:** Әйе, кызым, суым хәзер кайнап чыга, сез кереп утырыша торыгыз, Сабир бабагыз казларны алып кереп бирер, пешекләп йолка башларбыз.

**Сабир:** *(казлар тотып керә)* Безнең уңган күрше кызлары кереп тә җиткәннәр. Менә сезгә казлар, жырлый-жырлый армыйча эшләгез. *(Чыгып китә).*

**Хәния:** Иң элек култык астыннан канатларын йолкып алыйк. Аннары яндырырбыз. Хәзер калган канатларын йолкабыз. Кая әле, кызларым, һәр берегезгә каз бирим, йолка башлагыз.

**3 кыз:**Казларыгыз бигрәк матур

Таза булып үскәннәр.

Ә йоннары, каурыйлары

Мамыкланып беткәннәр.

**4 кыз:** Хәния әби иртә-кичен

Нык карады аларны.

Тилгәннәрдән, каргалардан

Көне буе саклады.

**5 кыз:**Үсә төшкәч, су буйларын

Бигрәк якын иттеләр.

Күрше казлар белән бергә

Дуслашып та киттеләр.

**6 кыз:** Кызлар, ә сез беләсезме?

Каз ярата елганы

Йөзәдә ул, чума да ул

Су үстерә бит аны.

**Хәния:** Картым, ал әле гармуныңны, кызлар жырлый-жырлый эшләсеннәр.

**Җыр «Каз канаты» (т.х.җ.)**

1. Каз канаты кат-кат була
Кат-кат була, нык була.
Чит җирләрдә бик күп йөрсәң,
Туган җирләр ят була.

2. Каз канаты каурый-каурый,
Коймак майларга ярый.
Уйнамагач та, көлмәгәч
Бу дөнья нигә ярый.

**Сабир***: (кызлар янына килеп)* Карчык, кара әле, бу кызлар бәләкәй генә булсалар да, ничек шәп эшлиләр, кая, мин дә йолкыштырып карыйм әле.

**2 кыз:** И, Сабир бабай, ите белән йолкыйсың бит.

**Хәния:** Кит инде, карт җүләр, ир-ат эшемени ул каз йолку. Кызлар кулы бит ул каз өстендә йөгереп кенә йөри.

**Сабир:** Бетте, бетте. Сарайга чыгып сарыкларга печән салыйм. Иркенләп, тынычлап эшләгез. *(Чыгып китә).*

**Хәния**: Балалар, казларның мамыгын аерым, каурыйларын аерым салыгыз. Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан гына мендәр ясыйм әле. Сабир бабагыз яңа, йомшак мендәр сорый. Әй, ул каз мамыгыннан гына торган мендәр… Аңа яту белән эреп китәсен инде. Без кияүгә чыккан да эти-әниләр бирнәгә түшәк-ястыкны каз мамыгыннан гына ясыйлар иде. Хәзер андый зур ястыклар юк инде, шулай да бу каз мамыкларыннан җыйнак кына ике мендәр ясыйм әле.

**1 кыз:** Сабир бабай эрепләр китәр инде яңа мендәрдә. (*Кызлар көлешәләр)*. Иртән йоклап калмасын.

**Хәния:** Кызлар, йолкып бетергәч, казларны әнә теге өстәлгә куярсыз. Үзем эчләрен алып, эшкәртеп бетерермен. *(Урам якта капка тавышы ишетелә).*

**1 малай:** Шыгыр-шыгыр капканы
Шыгырдатмый япмабыз.
Каз өмәсе булган җирдән,
Беребездә калмабыз. *(Егетләр керәләр)*.

**Малайлар бер-бер артлы:**

– Исәнмесез, барыгыз
Бездән сәлам алыгыз.
– Сәлам Хәния әбигә,

-Сәлам Сабир бабайга

-Сәлам матур кызларга.

**Бергә:** Өмә күрке – казларга. *(Көлешәләр).*

**Сабир:** Ай-һай егетләр телгә оста икәнсез. Әйдәгез алайса, бер җырлап алыйк әле.

*Татар халык җыры "Шома бас"*

**Хәния:** Безнең заман егетләре түгел инде болар. Үтегез, балакайларым.

**7 кыз:** Мин бит күрше егетләрен үзем чакырган идем. Онытмаганнар, рәхмәт, килгәннәр. *(Малайларга)* Кызлар казларны йолкып бетерделәр инде. Кызлар, әйдәгез, казларны монда куйыйк. Хәния әби эчләрен тазартканчы уйнап-җырлап алыйк. *(Казларны өстәлгә, урындыкларын ян-якка алып куялар).*

**8 кыз:** Каз өмәсе бик шәп бәйрәм,

Күңел ачаек әле.

Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр

Бергә басаек әле.

*Малайлар, кызлар кара-каршы басалар*. **"Челтәр элдем читәнгә"** (Җырлы- биюле уен).

**Хәния:** Балакайларым, казлар әзер, барыгыз, су буена төшеп чайкап менегез. *(Кызлар "Ярар" диешәләр. Казларны көянтәләргә элеп күтәрәләр. Тезелеп су буена төшәләр.Экранда су буенда каз чайкау слайдлары күрсәтелә.)*

**2 малай:** Каз чайкыйлар безнең кызлар

Куллары эшкә ята.

Мактаудан башка бер сүз юк

Бу кызларга карата.

**Хәния:** Кайтып та җиттегез мени, балакайларым? Кая казларыгызны алып куйыйм әле. Бигрәк уңган балалар булдыгыз. Мин әле коймакларымны да пешереп өлгермәдем.

**9 кыз:** Ярар, Хәния әби, борчылма, без уйнап алырбыз.

**Сабир:** Карчыккаем, коймагыңны аннан пешереп бетерерсең, әйдә әле балаларның уеннарын карыйк.

**Хәния:** Яшь чакларны искә төшерик дисең мени? Ярар, ярар. Балалар, "Чума үрдәк, чума каз"ны уйный беләсезме соң? Сезнең кебек яшь чакта бик яратып уйный идек без аны.

*Уен "Чума үрдәк, чума каз" (т.х.у.)*

**3 малай:** Кызлар, канатлар белән биеп күрсәтегез әле.

*Бию "Каз канаты" ( Канатлар белән бию башкарыла).*

**10 кыз:** Гөрләп үтте, шаулап үтте

Авылда каз өмәсе.

Бу айларны, бу көннәрне

Күтеп ала һәммәсе.

**4 малай:** Менә шулай каз өмәсен

Татарда үткәргәннәр.

Ә яшь кызлар күңел биреп

Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Хәния:** Коймагым да пеште. Әйдәгез, балалар, каз майларына манып коймак ашыйк, чәй эчик әле. *Балалар коймак белән чәй өстәленә утыралар.*

**"ОРЧЫК ӨМӘСЕ"**

***Уваева Алёна Данил кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 9 нчы балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

- балаларны кунакчыл булырга, олысына, кечесенә хөрмәт күрсәтергә өйрәтү;

-татар халкының милли бәйрәмнәрен - "Орчык бәйрәме"н искә төшереп китү;

-үткәненә ихтирам, кызыксыну уяту;

- татар халык уеннары аша туган телебезгә мәхәббәт хисе тәрбияләү

**Җиһазлау**: каба, орчык, сарык йоны, йоннан бәйләнгән оекбашлар, бияләйләр, авыл өен бизәү өчен (самовар, гармун, чәшкеләр һ.б)

**Кулланылган әдәбият:** Татар халык мәкальләре, табышмаклар, афоризмнар, җырлар китабы.

*(Сәхнә авыл өе күренеше белән бизәлгән, идәндә палас, мич, өстәл, самавар, чынаяклар, орчык белән каба, сарык йоны.)*

**Алып баручы.** Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Татар халкында милли бәйрәмнәр күп. Аларның кайберләре телдән-телгә күчеп безнең көннәргә кадәр килеп җиткән, кайберләре, кызганычка каршы, бөтенләй онытылып юкка чыккан. Ә бит борынгы әби-бабаларыбызның рухи хәзинәсе булган милли бәйрәмнәребезнең балалар тәрбияләүдә әһәмияте чиксез зур. Шуны истә тотып бүген сезнең игътибарыгызга "Орчык өмәсе" бәйрәмен тәкъдим итәргә булдык. Бәйрәмебезгә рәхим итегез!

**Сания әби**: И-и-и, күршекәем, син гел шулай тигез итеп, йон эрлисең, кулың ятып тора шул эшкә, син эрләгән җептән бәйләгән оекбашлар, бияләйләр бик матур, җылы һәм чыдам була.

**Бибинур әби**: Аның бөтен сере – синең бабаңның ясаган орчыкларын бит. Орчыклар шундый җайлы, кулга ятып торалар. *(Бер-берсенең эшләрен мактыйлар. Кызлар ишеккә шакый)*

**Сабира апа**: Карагыз әле, кызлар килделәр бугай?!

**Голжихан апа:** Керсеннәр, керсеннәр, эшләгәннәре кеше өчен булса, өйрәнүләре үзләре өчен булыр.

**Бибинур әби**: Әйе, дөрес.

*(Кызлар керә)*

**Асия:** Исәнмесез! Бүген сездә "Орчык өмәсе" була дип ишетеп килдек. Безгә дә сезгә булышырга, ярыймы?

**Гөлҗихан апа**: Узыгыз, кызлар, узыгыз, бик вакытлы килдегез. Рәхим итегез, утырыгыз.

*(Бергәләшеп эшли башлыйлар. Шул вакытта ишек шакыйлар, малайлар керә)*

**Малайлар**: Исәнмесез, саумысыз?

**Кызлар**: Нигә кәҗә саумыйсыз?

**Малайлар**: Әтәчегез күкәй салган,
Нигә чыгып алмыйсыз?

**Азат:** Халкыбызның йолаларын
Искә төшерик әле,
Күңелле итеп бүген
"Орчык бәйрәмен" үткәрик әле.

**Сабира апа**: Күпме булышчы! Сөбханалла. Болай булгач, язылмаган бер йон да калмый инде. Эш башланганчы, бер җыр җырлыйк әле.

**Асия:** Җырлыйк әле, җырлыйк әле.
Җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаган күңел,
Мәңге ачылачак түгел.

**Айгөл:** Ал да итәрбез әле,
Гөл дә итәрбез әле.
Матур җырлар җырлый-җырлый,
Бәйрәм итәрбез әле.

*"Сандугач, күгәрчен "җырын җырлыйлар*

**Азат**: Әби, ә "Орчык өмәсе" нәрсә аңлата? Кайчанрак уза ул?

**Сания әби**: Хәзер бөтенләй башка вакыт. Кибеттән теләгән бөтен әйберне алып була. Балалар йонның кайдан алынганын һәм ничек эшкәртелгә белмиләр. Ләкин яшьләрне гаепләргә ярамый, вакыты шундый. Орчык бәйрәме бу безгә борын заманыннан калган йола. Ул, җиргә кар яугач, көз көне үткәрелә. Хуҗа кеше күп итеп йон әзерли. Кичтән тәмле ризыклар пешерә. Ул кичкә дусларын, күршеләрен чакыра. Алар җыелып беткәч, күмәк эш башлана. Кемдер йон яза, кемдер өрли, кемдер аныката һәм йомгакка чорный. Ә кемдер бәйли. Эшне бар кешегә дә бүлеп бирәләр. Ә күңелле булсын өчен, ул эш бию, җырлау, шигырь сөйләү, табышмаклар һәм мәкальләр белән аралаштырып барыла. Ә эш беткәч, табынга утыралар. Менә бүген, балалар, шундый бәйрәм.

**Бибинур әби:** Балалар, аякларыгыз утырып оеп киткәндер инде. Бер биеп күрсәтегез инде.

**Лилия:** Без биибез тыпыр-тыпыр,
Без биебез тып та тып.
Бер башласак, бик тиз генә
Булмый безне туктатып.

**Айдар:** Әйдә, әйдә, катырак бас,
Биегәнне күрсеннәр;
Баскан җирдән ут чыгара
Безнең яшьләр дисеннәр.

*Татар халык биюе.*

**Солтан:** Әби, ә нәрсәгә сезгә шулай күп йон кирәк?

**Сания әби:** Кызым, без хәзер өлкәннэр инде. Бик тә җылы яратабыз. Җылы булган саен, безгә рәхәтерәк. Алла боерса, мин сезгә оекбашлар, бияләйләр бәйләрмен, Алла боерса. Минем сезнең кебек үк оныкларым бар. Алар мин бәйләгән әйберләрне бик охшатып кияләр. Менә кайберләренә бәйләдемдә инде. *(Сандыгын ачып, берәм-берәм күрсәтә, аңлата.)* Бәйләп кенә түгел, чигеп тә утыра идек әле. Менә чиккән сөлге, мендәр тышы, алъяпкыч һәм күкрәкчә. Ай, балалар, мин сөйлим дә сөйлим, сез мине тыңлап аргансыздыр инде. Әйдәгез әле, балалар, ярышып алыйк – йомгакны урап карыйк. Кайсыгыз җитезрәк микән?

*“Орчык бөтерү” уенын уйныйлар*

**Ильяс**: Безгә табышмаклар да әйтегез инде.

**Сабира апа**: Табышмак әйтәм мин сезгә,
Йон бирә нәрсә безгә? (Сарык)

**Голжихан апа:** Күрер-күрмәс күзләре,
Челтәр бәйли үзләре.
Челтәрләре түгәрәк,

Эшли алар үрмәләп.(Үрмәкүч)

**Сания әби:** Биш агайга бер күлмәк. (Бияләй)

**Бибинур әби:** Әйләнгән саен калыная. (Йомгак)

**Азат**: Ярый әле килгәнбез. Күп нәрсәләр белдек. Җырладык та, биедек тә, уеннар да уйнадык.

**Сания әби**: Менә, балалар, "Орчык өмәсе" шулай үтә иде. Эшен дә эшләдек, күңелне дә ачтык. Бүгенгә җитеп торыр.

**А.Б**: Хөрмәтле кунаклар! Безнең бәйрәмебез ахырына якынлашты. Гаиләләрегезгә татулык, күңелләрегезгә тынычлык, бәхетле матур киләчәк телибез. Сау-сәламәт булыгыз! Балаларыгызны татар җанлы итеп, милли рухта тәрбияләгез. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

## "ЗӘЛИДӘ" УЕНЫ

***Камалетдинова Гөлназия Хәбиб кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*"Б.С.Рахимов исемендәге Кенә төп гомуми белем мәктәбе"*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*

**Уен максаты**: татар халкының уен санамышларын, җырлы-уенннарын яңарту; белемнәрен тикшерү.

**Уен барышы:**

Уен барышында хәр уенчыга номерлар бирелә. Катнашучылар арасында кызлар саны малайлар санынıа караганда бергә артык булырга тиеш.

Уен санамышлардан башлана. Уенчынын берсе чыгып санамыш белән санап бер кешене чыгара.

"Әке бәке кыек сәке эремчек, син торып тор, энем чык."

Санамыш белән чыккан кеше уртага баса.

**1 уен "Гөлбану" уены уйнала.**

Уртадагы кеше биеп уртада йөри, ә калганнар анын тирәсендә әйләнәләр. Уртадагы кеше бер кеше белән парлаша(малай-кыз). Калган кешеләр дә парлашырга тиеш. Бер кеше артып кала. Бу кеше уеннан чыга. Уенннан чыкканда жюри янынıа барып өстәлгә куелган сорауга җавап бирә. Җавап бирә алса жюри бүләк бирә. Уен дәвам итә.

**2 уен**

Малайлар белән кызлар тигез, алар парланган килеш торалар. Кызларга бәйләү җебе бирелә. Малайлар шушы җептән йомгак ясарга тиеш. Кайсы малай иң ахырдан кала, шул уеннан чыга. Сорауга җавап бирә.

**3 уен**

Уеннан чыккан бер бала килеп санамыш белән ике кешене чыгара. Бу ике кешегә кулъяулыклар бирелә. Кулъяулыкларны үз каршыларына идәнгә куялар. Көй башлана. Алар түгәрәккә баскан уенчылыар арасыннан бии-бии, үз кулъяулыкларына килеп җитәргә тиеш. Кем соңыннан кулъяулыгына килеп җитә, шул уеннан чыга. Сорауга җавап бирә.

**4 уен “Җыешлы” уены**

Уенда калганнарның берсе алга чыга. Татар бию көенә биеп “Җыешлы” уенын башлый. Көй туктаганнннан соң парланырга кирәк. Кем парсыз кала шул уеннан чыга. Сорауга җавап бирә.

**5 уен “ Тукмак әйләндерү”**

Калган уенчылар түгәрәккә басалар. Алып баручы түгәрәктә тукмак әйләндерә, ә уенчылар биеп әйләнәләр. Тукмак башы кемгә карый, шул чыга. Сорауга җавап бирә.

**6 уен “Капкалы” уены**

Уеннан чыккан ике бала чыгарыла. Бу ике кеше кара-каршы басып, ике куллары белән тотынып капка ясый. Көй башлана – уенчылар шушы капкадан чыгарга тиешләр. Көй туктый капка төшә. Кем шушуы капка эчендә кала, шул уеннан чыга. Сорауга җавап бирә.

**7 уен “Йөзек салыш” уены**

Алып баручы уенчыларга йөзек сала. Салып бетергәч “Йөзек кемдә –йөгереп чык” дип әйтә. Йөзек кемдә шул чыгарга тиеш. Әгәр бу кешене тотып калалар икән, ул уеннан чыгарга тиеш. Сорауга җавап бирә.

**8 уен “Курчак йөртеш”**

Калган уенчылар түгәрәккә басалар. Тугәрәктәгеләргә курчак бирелә. Көй башлана курчакны кулдан-кулга йөртәләр. Көй туктаганда курчак кем кулында кала, шул уеннан чыга. Сорауга җавап бирә.

**9 уен “Урындык алыш”**

Өч уенчы калганнан соң урындыклар белән уен уйнатыла. Уртада ике урындык, өч кеше урындыклар кырында көйгә биеп йөриләр. Көй туктаганнан соң уенчылар урындыкка утырырга тиешләр. Кем утырмый кала шул уеннан чыга. Сорауга җавап бирә.

Бер урындык алып куела. Уртада бер генә урындык кала. Ике уенчы шушы урындык кырында биеп йөриләр. Көй туктаганнан соң кем утырмый кала, шул уеннан чыга. Сорауга

җавап бирә. Кем урындыкка утыра, ул кеше җиңүче итеп билгеләнә. Ләкин җиңүче дә сорауга җавап бирергә тиеш. Әгәр җавап бирсә ул җиңүче итеп таныла. Бүләкләнә.

## “КЫЗ СОРАУ” ГОРЕФ-ГАДӘТЕ

***Рәхмәтуллина Гөлназ Илхам кызы***

*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы*
*Шәле авылы “Тургай” балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларны татар халкының милли “Кыз сорау” йоласы белән таныштыру, халкыбызның күркәм гореф-гадәтләрере, матур йолалары җырларын өйрәнү.

**Бурычлар:**

Тәрбия:

-Халкыбызның йолалары аша гореф-гадәтләргә хөрмәт уяту.

-Эстетик һәм әхлакый шәхес тәрбияләү.

Үстерү:

-Театраль этюд шөгыльләре аркылы баланың кызыксынуларын, сәләтләрен һәм мөмкинлекләрен үстерү.

Белем бирү:

-Балаларның онытылып барган гореф-гадәтләр белемнәрен киңәйтү.

-Гореф-гадәтләр белән таныштыру, яңа күнегүләр өйрәтү.

**Төп өлкә:** нәфәсәти үсеш

Катнаш өлкәләр: сөйләм теле үсеше

**Күрсәтмә һәм таратма әсбаплар**: татар халык көйләре, костюмнар, агачлар, өй, татар халык ашлары, чигелгән кул яулыгы.

**Җиһазлар:** ноутбук, колонка

**Шөгыль төзелеше:**

Кереш өлеш:

1. Кереш сүз

2. Музыкаль исәнләшү

**Төп өлеш:**

1. Сораулар

2. Гореф-гадәтләр белән танышу

3. Хәрәкәтләр, сүзләр өйрәнү

4. Театраль күренешне күрсәтү

**Йомгаклау:**

1. Сораулар

2. Музыкаль саубуллашу.

**Шөгыль барышы:**

**Алып баручы**: Хәерле көн, кадерле кунаклар! Бүген без татар халкының онытылып бара торган “Кыз сорау” йоласына җыелдык. “Кыз сорау” борын-борыннан бар гаилә өчен генә түгел, ә бөтен авыл халкы өчен зур бәйрәм, тантаналы көнгә әйләнгән. Туйларның иң матур күренеше – кыз сорау булган.

Малайлар белән кызлар су буенда кич утыралар.

**Мәдинә**. Сәгать соңдыр инде, кайтырга вакыт, әти-әни борчыладыр.

**Кәрим.** Әйе, кайтыйк.

*Яшьләр саубулашып тарала башлый. Камил Камиләне кулларыннан тотып ала.*

**Камил.** Камилә, мин инде күптән сиңа гашыйк икәнемне беләсең, күңелем һәрвакытта сиңа тарта. Без синең белән күптән очрашабыз. Безгә мөнәсәбәтләребезне законлаштырырга вакыт. Мин әти-әни белән киңәшләштем без сезгә дүшәмбе көнне кыз сорарга киләбез.

**Камилә**. *(Уңайсызланып)* Камил, әйе, безнең хисләр үзара. Әти-әтиләргә ничек әйтәсе булыр.

**Камил**. Борчылма, безнең гаиләләр бер-берсен беләләр, алар яхшы мөнәсәбәтләрдә. Без бергә очрашып йоргәнне дә беләләр. Минемчә, каршы килмәсләр.

**Камилә**. Ярар, иртәгә әти-әнием белән сойләшеп карармын.

*Камил Камиләне өйенә озатып куя. Камилә төне буе уйлап чыкты. Иртә белән торуга гаилә (әти-әни, Камилә) иртәнге ашка җыенды.*

**Әни.** Кызым, син бүген бик сәерсен, йокын да туймаган ахырысы. Нәрсә булды? Барсыда яхшымы?

**Камилә.** *(Оялып кына)* Әти-әни, кичә Камил миңа тәкъдим ясады, душәмбе көнне кыз сорарга киләбез диде.

*Әни аптырап калды.*

**Әти.** Камилнең гаиләсен, үзен күптән беләбез бик үрнәк гаилә. Без каршы килмәбез, тик син кызым үзен ризамы?

**Камилә**. Риза

**Әти.** Алайса көтәбез, дүшәмбе көнен бик дөрес сайлаганнар, элеккедән иң уңышлы көн дип баш көн – дүшәмбе көн исәпләнгән.

*Камилә бик борчылып кичне көтте. Кич житте. Камил бн Камилә күрешәләр.*

**Камил.** Камилә, сәлам. Әти-әниең белән сөйләшеп булдымы? Нәрсә диделәр?

**Камилә.** Сәлам, Камил. Сөйләштем, әти сезнең гаиләгезне күптән беләбез, үрнәк гаилә диде, минем ризалыгымны сорады. Мин риза дигәч, каршы килмәде.

*Камил шатлыгыннан нишләргә белмәде, бии, сикерә, Камиләне кулыннан алып әйләнә. Яшьләр бик шатланып сөйләшә-сөйләшә Камиләнең өйе янына кайтып җиттеләр.*

**Камил.** Камилә, мин шундый шатмын. Дүшәмбе көнен бик атлыгып көтәм.

**Камилә**. Мин дә. Киттем, өйгә керим әти белән әни борчыладыр. Саубул.

**Камил.** Саубул, Камилә.

*Дүшәмбе көне килеп җитте. Камиләнең капка каршына Камил белән туганнары килеп төште. Күңелле җыр яңгырый. Кунакларның кулларында татар милли ашлары: чәк-чәк, бавырсак, кош-теле, гөбәдия, талкыш каләве. Камилнең әтисенең кулында икмәк белән тоз.*

**Камилнең әтисе:**

Йөгереп үк төштем инеш дип,
Боҗыралар элдем көмеш дип.
Эзли генә торгач табыштык,
Нәселегез асыл, имеш, дип

Яхшы җирдән килдем, теләгем сезнең белән кода-кодагый булу. Сезнең кызыгыз, безнең егет бар!

**Камиләнең әтисе:** Без кызыбызны уң белән сулны, ал белән артны, хәләл белән харамны, начарлык белән яхшылыкны аңлаган, аерган кешегә генә бирәбез. Кайда сезнең егетегез?

*Камил каршына чыгып баса.*

**Камиләнең әтисе:** Риза, кызымны бу егеткә бирергә, риза!

*Туганнар бер берсенә бүләк бирешәләр. Камилнең туганнарына Камилә үзе чиккән, үз куллары белән теген сөлге-ашъяулыклар бирелә. Кунаклар бик шатланып бүләкләргә сокланып кабул итәләр.*

**Кунакларның берсе**: Акны котлыйбыз! Яшь килен бәхетле булсын, тигез гомер итсеннәр! *(кул чабалар)*

*Камил белән Камилә кулга кул тотынышып калалар.*

# “ОРЧЫК ӨМӘСЕ”

***Хамитова Лилия Сәлимхан кызы***

*Казан шәһәре Совет районы*

*“159 нчы катнаш төрдәге балалар бакчасы"*

*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

**-** балаларның татар халкының милли гореф- гадәтләре белән таныштыру;

- балаларда бу гореф-гадәтләргә, йолаларга хөрмәт, ихтирам тәрбияләү, милли җырлы-биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү, балаларның сүз байлыкларын арттыру, сәхнә культурасы булдыру;

- халык авыз иҗатына, гореф-гадәтләренә, йолаларга, милли уеннарга хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Зал түрендә авыл өенең эчке күренеше, анда борынгы сандык, сәке, мич, чуен, ухват, бишек, чабата, комган, канат, самовар, милли ризыклар, чиккән мендәрләр, сөлгеләр, кызыл башлы суккан сөлгеләр, идәндә тукыган паласлар җәелгән, орчык, йон, каба.

**Техник чаралар:** магнитофон, дисклар.

**Алдан эшләнгән эш:** әңгәмә, балалар бакчасында оештырылган музейга сәяхәт, мәкальләр, җырлар, уеннарны, санамышларны, биюләрне өйрәнү.

**Бәйрәм барышы**

*(Әбиләр өйдә утыралар: кайсы бәйли, кайсы йон эрли, кайсы йомгакка җеп чорный, анага бала да ярдәм итә, бабай бер малай белән орчык ясап утыралар)*

**Бибинур әби**: И, Алия апа, син гомер буе шулай тигез итеп, йон эрләдең, кулың ятып тора шул эшкә, син эрләгән җептән бәйләгән оекбаш, бияләй дә матур була, күрегез әле сез аның ничек орчык тәгәрәтеп утыруларын!

**Алия әби:** *(елмаеп):* И, Бибинур, җепнең тигез булу сере миндә түгел бит, синең картың ясаган орчыклар үзләре шундый җайлы, кулга ятып торалар, үзеннән-үзе зырылдап әйләнүе генә ни тора.

**Сания әби:** Менә мин дә, оныгым Халилне да шул һөнәргә өйрәтергә дип алып килдем бит бүген, орчык ясарга өйрәнсә, бабасы кебек оста орчыкчы булыр әле, Алла боерса, әйе бит, улым.

**- Бибинур әби:** И, дуслар, өмәгә килүчеләр ни өчен күренмиләр әле? *(Ишек шакылдаткан тавышка балалар керәләр)*

**Кыз бала:** Сания әби, сездә өмә икәнен ишеттек тә, килеп җиттек әле.

**Бибинур әби:** Кунаклар килгән икән монда, кара әле, никадәр булышчы, никадәр өйрәнчек, чакырып та бу кадәр җыя алмассың.

**Алия әби:** Әйдәгез, узыгыз, балалар, ну эшлибез болай булгач, язылмаган бер йон да калмый инде. *( Балалар керәләр, исәнләшәләр ).*

**Малай:** Исәнмесез, өегезгә бәрәкәт иңсен. *(Утыралар, уртада кәрзинәдә йон – шуның янына утыралар)*

**Сания әби:** Әгузе бисмилла. И, ходаем, эшебез җиңел булсын. Тиз-тиз эшләп алыйк. Бездә бит бүген Орчык өмәсе.

**Малай:** Ә нәрсә соң ул орчык?

**Бибинур:** Алай икән, бу бәләкәчләр орчык өмәсенең нәрсә икәнен белмиләр икән бит.

*(Әбиләр үзара сөйләшәләр)*

**Алия әби:** Заманалар үзгәрде, бу балаларның белмәве гаеп түгел, җепне бит хәзер кибеттән генә сатып алалар, я булмаса, бәйләнгәнен, эше беткән матур оекбашлар, бияләйләр генә алып кияләр, белмәсләр дә шул.

**Бибинур әби:** Әйе, шул, балалар, сез белмәсәгез дә гаепләп булмый.

**Сания әби :** Орчык өмәсе – ул безгә әби-бабайлардан мирас булып калган бәйрәм. Ул көзен, кешеләр сарык йоннарын алып бетергәч уздырыла. Хуҗа кеше куп итеп сарык йоннарын әзерләп, тәм-томнарын, кәнфит-шикәрләрен әзерләп куя, өмә буласы көнне коймак пешерә. Өмәгә дус-ишләре, туган-тумачалары чакырыла. Анда кемдер йонны яза, кемдер эрли, кайберәүләр йомгакка чорный, кем бәйли, эшне шулай бүлешәләр. Эш уен-көлке белән алып барыла. Эш беткәч, хуҗа өмәчеләрне тәм-томнар белән сыйлый.

**Бибинур әби:** Менә бездә бүген бәйрәм. Өмә булгач, өмә булсын, сезгә дә эш бирик инде, балалар кеше эшләгәнне генә карап утыру килешмәс! Килегез әле менә монда, йон язаргы булышырсыз. *( Эш бирә).*

**Малай:** Әбием, ә нигә сезгә шулкадәр йон кирәк?

**Бибинур әби:** И, балам, без бит инде олы кешеләр, җылы яратабыз, «җылы сөяк сындырмас» ди бит, халык. Шуңа күрә, күпме җылырак булса, шулкадәр яхшырак. Оекбаш, бияләйләр бәйләрмен, алла боерса. Минем сезнең кебек оныкларым да бик күп әле.

**Алия әби:** Балалар, эшкә бик бирелеп китеп, телдән язмыйк тагын, әйдәгез. «Орчык» уенын уйнап алыйк әле. Халил улым син орчыкны әйләндер. Кемгә орчыкның очы эләгә шуңа җаза бирәбез. *( әтәч итеп кычкыра, татарча бии, шигырь сөйли).*

**Халил:** Ә мин «Орчык» турында шигырь дә беләм әле.

Әйләнә орчык, әйләнә,

Әйтерсен лә биюче;

Юк аңа бары, кул чабып:
“Булдырасың!” - диюче.
Мактаганны көтеп тормый,
Уйламый да туктарга-
Ничек инде, орчык булып,
Карап торсын юк-барга!
Әйләнә дә биеп китә,
Аннан сикереп куя.
Хәтта очып китәр иде,-
Останың кулын тоя.
Мин сокланып карап торам,
«Ай-һай җитез бу» - диеп;
Юкка әйтмиләр икән ул:
Орчык кебек бул!- диеп.

**Бибинур әби:** Балалар, булдырдыгыз! Бик уңган булып чыктыгыз бит әле сез.

**Сания әби:** Сезне орчык өмәсе дип өйрәтеп тә торасы юк, туганнан бирле Орчык өмәсенә йөреп, шомарып беткәннәр, дип әйтерсең.

**Алия әби:** Булдырдыгыз, рәхмәт барыгызга да!

**Кыз бала:** Әйдәгез, бер җырлап та алыйк әле.

1. Җеп эрлибез, җеп эрлибез,
Орчык өмәләрендә.
Биемичә түзеп булмый,
Орчык биеп торганда.

3. Кошлар да бит очып кайта,
Түгәрәк кулләренә
Биибез дә, җырлыйбыз да,
«Орчык» өмәләрендә.

**2 нче малай:**

Бәйрәмебез бетеп килә.
Кунакларга әйтик шуны
Сәламәтлек, бәхет телик,
Һич белмәсеннәр борчуны.

## “Самавыр агарту йоласы”

***Гыйльметдинова Гөлназ Равил кызы.***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*"Катнаш төрдәге Балтач 1нче номерлы балалар бакчасы"*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.*

**Максат:** балаларны онытылып барган “Самавыр агарту” йоласы белән таныштыру.

**Үстерү бурычы:** балаларны йолалар өйрәтүгә кызыксынуларын үстерү.

**Тәрбияви бурыч:** киләчәк буынны милли йолалар нигезендә тәрбияләү. Күмәк эштә дустанә мөнәсәбәтләрне, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:** татар халкының гореф – гадәтләрен хөрмәтләргә өйрәтү.

**Төп белем бирү өлкәсе:** “Сөйләм үсеше”.

**Интегральләшкән белем бирү өлкәләре:** “Танып-белү үсеше”, “Социаль-коммуникатив үсеш”.

**Методик алымнар һәм чаралар:** уен күнегүләр, әңгәмә, сораулар, күзәтү, сәхнәләштерү, картиналар карау, кызыксындыру алымнары, үзбәя бирү.

**Җиһазлау:** залның түрендә инеш буе күренеше: агачлар, куаклар, камышлар, чәчәкләр, елга макеты, ком, ноутбук, тавыш көчәйткеч колонкалар.

**Сүзлек өстендә эш:** самавыр, кершән, мунчала, самавыр агарту.

**Алдан үткәрелгән эш:** матур әдәбият уку, әңгәмәләр, слайдлар карау, такмаклар, шигырьләр, җырлар, тизәйткечләр, милли уеннар өйрәнү.

**Сәхнә артыннан**

Самавыр агарта кызлар,

Җырлап инеш буенда.

Табын күрке - җиз самавыр

Язгы Сабан туенда -дигән җыр ишетелә.

**“Эх, зилем-зиләле” татар халык уен җыры көенә кулларына самавыр тоткан өч кыз бала чыга.**

**Беренче кыз бала:** Кызлар, кызлар, безнең түбән оч кызлары килмәгән бит әле, сәгать берләрдә инеш буендагы кечкенә басмада очрашабыз дигән идек, күренмиләр бит.

**Икенче кыз бала:** Килерләр, килерләр, бер дә борчылма.

**Музыка астында кулларнына самавыр тоткан кызлар күренә. Бер кызның кулында мунчалар.**

-Әнә киләләр, хуш киләсез!  Әбиләр әйтмешли, түрдән узыгыз, рәхим итегез, ничек хәлләрегез!

**Өченче кыз бала:** Уф, инеш  буена төшеп җиткәнче, хәлдән тайдык, бигрәкләр дә авыр булды бу самавыр.

**Дүртенче кыз бала:** Кызлар туйдым бу самавырдан, атна саен агартырга кирәк бит узен.

**Беренче кыз бала:** Әйе  шул, атна саен агартып торсак та, бигрәк тиз карала бу кызлар!

**Икенче кыз бала:** Күмер белән куела бит, шунлыктан тиз карала.

**Өченче кыз бала:** Әле Сабан туена кадәр, инеш буйларыннан менә дә алмабыз, самавырларны агартып, ялтыратып, шулай бит кызлар.

**Дүртенче кыз бала:** Бу атнада Сабантуйлары  була икән,  безгә аеруча тырышырга туры киләчәк.

**Беренче кыз бала:** Кызлар, кызлар дим. Тыңлагыз әле мине. Миңа  әбием, самавыр агартуның да үз йоласы бар ди. Кызлар, сөйлимме сезгә дә?

**Кызлар барсы (бергә):** Кызык...Сөйлә әйдә, сөйлә.

**Беренче кыз бала:** Чәчүләр беткәч, Сабантуй бәйрәме алдыннан җиткән кызлар, әни-җиңгәчәйләр чишмә буена самавыр агартырга төшә идек. Башта, кызым самавырны комлы мунчала белән әйбәтләп ышкып, ышкып юа идек. Ә самавырны агарткач әче катык белән ялтырата идек, аннан кызыл кирпечне уып, шуңа бармак белән басып, чәчәк төшерә идек ди. Сабантуйга килгән һәр кунакны, шушы самавырда кайнаган хуш исле, тәмле үләннәр салып пешерелгән чәй белән сыйлый идек -ди.

**Кызлар барсы (бергә):** Менә, ни дә икән хикмәт!

**Икенче кыз бала:** Һәр эшнең үз йоласын белеп эшләгәндә генә нәтиҗәсе була шул кызлар.

**Өченче кыз бала:** Ай-яй, бигрәк матур булгандыр инде ул кызлар, әйе бит!

Дүртенче кыз бала: Кызлар, сезнең мунчалаларыгыз бармы, булмаса бирәм. Әйдәгез эшкә тотыныйк. (кызларга мунчалар өләшә)

**“Эх, зилем-зиләле” татар халык уен җырын җырлый-җырлый, самавыр чистарталар.**

Җитәкләшеп, тезелешеп,
Без урманга барабыз.
Урманда яшел аланда
Җырлап-биеп алабыз.

Кушымта:
Эх, зилем-зиләле,
Сандугачым, кил әле.
Кил әле, дустым, кил әле,
Бергә әйләник әле.

**Беренче кыз бала:** Карагыз әле, сез самавыр турында такмаклар беләсезме кызлар?

**Икенче кыз бала:** Мин беләм, мин беләм шул (үчекләгәндәй)

**Өченче кыз бала:** Белсәң әйдә, әйтеп күрсәт инде булмаса!

**Икенче кыз бала:**

Ак самавыр борыннарын
Күңелле борулары;
Сезгә ничек, миңа кыен
Аерылып торулары. **( такмак җырлый)**

**Дүртенче кыз бала:** Мин дә беләм шул, кызлааар!

Самавыр куйдым күмерсез
Кайнап чыгар күрерсез.
Без җырлап, сез биемәгәч
Безгә бик тә күңелсез.

**Беренче кыз бала:** Абау, чистарта-чистарта безнең самавырларыбыз ничек ялтырыйлар, кызлар карагыз әле, карагыз!

**Икенче кыз бала:** Әйе шул, күзләр камаша бит кызлааар! (көлешәләр)

**Өченче кыз бала:** Көзге дә кирәкми, кершән сөрткәндә самавырга гына карарбыз инде.

**Йөгереп, ләгән тотып Йосыф исемле малай керә:**

**Йосыф:** Апа, апа дим, әни шушы ләгәнне агартырга кушты.

**Беренче кыз бала:** Йосыф кара әле, менә мин әйткән тизәйткечне әйтә белсәң, чистартып бирәбез, шулай бит кызлар, сез минем белән килешәсездер.

**Барысы бергә:** Шулай, шулай, килешәбез.

**Беренче кыз бала:** Сезнең кызлар безнең кызларга киндер тукмаклашмакчылар иде. Тукмаклашырлар микән, тукмаклашмаслар микән? Тукмаклашсалар, тукмакларын алып килсеннәр, тукмаклашмасалар, тукмакларын биреп торсыннар.

**Икенче кыз бала:** Йә Йосыф, булдырырсың микән?

**Йосыф (кулын селкәп):** Әй, нәрсәсе бар аның!

Сезнең кызлар безнең кызларга киндер тукмаклашмакчылар иде. Тукмаклашырлар микән, тукмаклашмаслар микән? Тукмаклашмасалар, тукмакларын алып килсеннәр, тукмаклашмасалар, тукмакларын биреп торсыннар.

**Өченче кыз бала:** Әй, булмады бу Йосыф, берәр күңелле шигырь сөйләп күрсәтәсенме соң?

**Йосыф (уйланган кебек башын кашып):** Кайсысын сөйлим икән соң, кызлар!

**Дүртенче кыз бала:** Кызлар, әйдәгез, самавырларны куеп торыйк та, кайтып киткәнче, берәр уен уйнап алыйк.

**Барысы бергә:** Әйдәгез, әйдәгез уйныйбыз.

**Беренче кыз бала:** Ә нинди уен уйныйбыз соң?

**Икенче кыз бала:** Яулык алыш.

**Өченче кыз бала**: Йөзек  салыш.

**Дүртенче кыз бала:** Без-без, без идек.

**Барысы бергә:**  Әйдәгез, уйныйбыз.

Без-без, без идек,
Без унике кыз идек;
Базга төштек бал каптык,
Келәткә кердек май каптык;
Кап та коп,
Кара, Йосыф,
Тимер туп,
Авызыңны ач та йом!
М- м- м

Кагыйдә. Балалар уен сүзләрен көйләп әйтәләр, аннары, берьюлы авызларын йомып, җиңелчә, күңелле көйгә төрле шаян хәрәкәтләр ясыйлар. Кем көлеп җибәрә, шул уеннан чыга һәм җәза үтәргә тиеш була.

**Йосыф кызларның кыланмышына түзә алмыйча көлеп җибәрә.**

**Кызлар барсы бергә:** Йосыфка нинди җәза бирәбез?

Әйдә, Йосыф, булмаса шигыреңне сөйләп җибәрче **(көлешәләр)**

**Йосыф:**

Чишмә суын мактый әби:
 “Тәнгә бик шифалы , ди.
Самавырга җитми инде,
Кирәкми” Тифале”, -ди.

**Беренче кыз бала:** Кызлар, булмаса кайтыйк, әниләр эзли чыгарлар.

**Икенче кыз бала:** Булган булган барсы булсын инде, әйдәгез “Самавыр” уенын уйнап алабыз, аннан соң кайтырбыз.

Кагыйдә. Балалар арасыннан «Самавыр » һәм «әби» сайлап куела. Калган балалар читкәрәк тезелешеп утыралар. Әби балаларга тәм-том исемнәре әйтеп чыга, аларны самавыр ишетмәскә тиеш. Әби, самавырның колагына килеп: «Чәй эчәргә килә-килә ... шикәр!» — ди.

«Шикәр» акрын гына килеп, самавырның аркасына төртә дә үз урынына барып утыра. Самавыр карый, балаларның барысы да баш бармакларын өскә каратып утыралар. Самавыр

кем төрткәнен әйтергә тиеш. Әгәр белсә, тоткан бала самавыр була. Белмәсә, «шикәр» гә икенче исем кушылып уен дәвам итә. Өч мәртәбә әйтә алмаса, «самавыр » га җәза бирелә.

**Йосыф:** Мин самавыр булам.

**Өченче кыз бала:** Ә мин әби булам.

**“Самавыр” уены оештырыла.**

**Өченче кыз бала:** Кызлар, киләсе атнага тагын шушы урында очрашырбыз яме.

**Йосыф (ярым шаяртып):** Мине дә калдырмагыз, кызлааар!

**“Эх, зилем-зиләле” татар халык уен җырын дәвам итеп җырлап чыгып китәләр.**

Кояшлы матур аланда
Гөлләр чәчәк аталар.
Тирә-юньгә ямь, матурлык,
Хуш исләр тараталар.
Кушымта:
Эх, зилем-зиләле,
Сандугачым, кил әле.
Кил әле, дустым, кил әле,
Бергә әйләник әле.

**“Боз озату, йоласы”**

***Рәхимова Гөлинә Рәис кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау*
*муниципаль районы Хәй Вахит исемендәге*
*“Мәмдәл гомуми урта белем бирү*
*мәктәбе муниципаль бюджет гомуми*
*белем бирү учреждениесе”*

**Бәйрәмнең максаты:** Күңел ачу чараларында актив катнашырга омтылыш формалаштыру. Халкыбызның гореф-гадәтләрен, буыннан-буынга истәлек булып калган әйберләрнең исемнәрен хәтерләрендә калдыру. Шигырь һәм уеннар аша балаларны татар халкының үткәне белән таныштыру. Нәфасәти зәвыкларын үстерү, әйләнә – тирәдәге предметларны бәяли белергә өйрәтү. Татар халкына мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

Сәхнәдә  язгы елга буе күренеше. Зәңгәрсу пәрдә-суны, ак пәрдәләр бозны гәүдәләндерә. Югарырак-кояш,болыт рәсеме. ”Суда”-үрдәкләр, казлар.

**Тәрбияче**:” Боз озату” татар халкының беренче бәйрәме. Бу йола елгалардан боз китү белән бәйле. Татар авылларының күбесе су буйларында урнашкан,шуңа да аларда язның иң беренче бәйрәме булып боз китүне карау торган.Боз китүен карарга,гадәттә,бар халык җыелган. Яшьләр исә, елгадан боз китүне җигүле атларда килеп гармун уйнап, җырлап каршы алганнар. Халык йөзеп баручы боз кисәкләрендә салам яккан. Бу күренеш төнге аяз язгы кичтә аеруча матур күренгән.

(Залга бер кыз бала белән әби керә)

**Әби**:Исәнмесез,кадерле кунаклар! Исән-имин килеп җиттегезме? Бүген бездә зур бәйрәм. Менә бездә кызым белән,су буена боз озату бәйрәменә килдек. Табигать кочагында үткәрелә торган бәйрәмне кызым да күрсен әле.Ч ү,ишетәсеңме кызым, әнә балалар да киләләр бугай?!

(Кулларына тал песие ботаклары тоткан балалар керә)

**1 бала**: Тәрәз аша карале,
Тышта ап-ак кар әле.
Тал песие чәчәкле,
Алтын,көмеш бизәкле.

**2 бала**: Тышта карлар ява әле,
Суык көннәр бар әле .
Тал песиләре көлә,
Тиздән яз килеп җитә.

**Җыр “Яз килә”**

**Әби**: Карагыз балалар,каргалар да кайткан икән бит.Каргалар яз килүен хәбәр итә дә инде.

**3 бала**: Ямьле, бик ямьле
Туган илебез.
Килегез,кошлар,
Безгә килегез!

**4 бала**: Күтәрелеп биеккә,
Куанышып очалар.
Яз килгәнне хәбәр итә,
Канатлы дус каргалар.

**Әби**: Яз бәйрәме  мөбарәк булсын!Күңелләргә шатлык тулсын!

**Бию “Тал песиләре белән”**

(балалар милли киемнәрдән)

**Әби**: Балалар каргалар кайтканда безгә хат калдырып киткәннәр.(Агач төбеннән хатны алып укый).Балалар бу бит яздан хәбәр.

”Юлга чыктым,сезне тизерәк күрәсем килә.Тик күктә кара болытлар,кояш күренми,кояш булмагач мин дә тизерәк килә алмыйм”,-дип язган. Яз көне кояш иң кирәклесе,ул язның иң зур тяныčы .Әйдәгез,чакырыйк әле үзен.

**Кояшны чакыру.**

Эт кояшы,тегеләй кит

Безнең кояш,болай кил!

Кояш чык,чык,чык!

Болыт,кач,кач,кач,

Без уйнарбыз җылыткач!

Тәти кашык базарда,

Майлы ботка казанда,

Әти китте базарга,

Тәти кашык алырга

Тәти кашык сабы алтын,

Безгә кирәкми салкын.

(Кояш керә)

**Кояш**: Мин елмаеп бер карасам,бар дөнья көлә.Бозлар эри,тамчы тама,күңел сөенә!Исәнмесез,нәни дусларым.Сезне күрүемә мин бик шат.Сез дөрес әйттегез,мин язның таянычы.

**5 бала**: Дуслар килегез тизрәк,

Ясыйк ярымтүгәрәк.

Безгә килгән кунаклар,

Биик ,җырлыйк бергәләп.

**6 бала**: Сез дә безгә кушылыгыз

Без шатлык таратабыз,

Тирә-якны яңгыратып

Җырларга яратабыз.

**Җыр “Кояшлы ил”**

**Кояш**: Дусларым,матурларым мин сезне бик яратам.Мин сезгә үземнең алтын-сары нурларымны калдырам,минем әле табигатьне уятып бетерәсем бар.Ә хәзер сау булыгыз!(Чыгып китә)

**Әби**: Болай булгач тиздән елгада боз да кузгалыр,әзерләнә торырга кирәк.Балалар сез шигырьләр беләсез,ә мин сынамышлар беләм.Аларны сездә әйтеп карагыз әле?!

Язгы ташкын шәп булса...(иген уңар)

Елгаларда боз төнлә китсә...(ашлык уңар)

Елгалар яз көне боздан тиз ачылса...(ашлык уңар)

Булдырдыгыз балалар,тагын сынап карыйм әле үзегезне. Татарстан җиреннән күп елгалар агып үтә. Сез аларның исемнәрен беләсезме?

“**Елга исемнәрен әйт” дигән уен уйнала.**

**7 бала**: Барыгыз да тыңлагыз!Барыгыз да ишетегез!Кояш нурлары белән бозын эреткән. Боз китә,боз!Боз кузгалган!

**8 бала**:Кояш нулары белән,

Бозлар кузгалган.

Яз башлануын

Беләбез шуннан.

**9 бала**: Боз һәм кар эреде,

Сулар йөгерде.

Елап елгалар,

Яшьләр түгелде.

**10 бала**: Тамчы тама,тамчы тама,

Тамчы тама түгелме?

Матур язлар,тамчы тамгач,

Килеп җитә түгелме?

**Бергә**: Яз бәйрәме, Боз озату бәйрәме мөбарәк булсын! Күңелләргә,бар җиһанга шатлык йөгерсен.

**11 бала**: Боз озату күңелле,

Бүген бездә зур бәйрәм!

Матур җырлар җырлый-җырлый

Уйныйбыз әйлән-бәйлән.

**“Әйлән бәйлән” дигән җырлы уен башкарыла**

**Әби**: Сезгә карап бала чагым искә төште.Бездә нәкъ шушы вакытта Боз озату бәйрәмен каршылый идек.Иң матур киемнәребезне киеп,ул көннәрдә боз акканын карарга су буена төшә идек.Анда кызлар,малайлар төрле уеннар оештыра иде.Олылар,боз агымына карап,җәйнең нинди буласын юрый иделәр.Елга буе җыр-бию,уен-көлкедән яңгырап торыр иде!

**12бал**а:Уйный-уйный үсәбез,

Асыл егетләр,кызлар.

Уйнамыйча,шаярмыйча

Яшәп булмый дөньяда.

**“Яшерәм яулык” уены.**

13бала:Тыпыр-тыпыр тыпырдап,

Бергә басаек әле.

Уйнап-көлеп,җырлап-биеп,

Күңел ачаек әле.

**“Чиләк-көянтәле”бию башкарыла.**

**Әби**:Менә Бозны озаттык,инде тиздән ямьле язны каршы алырбыз. Яз безгә өйләребезгә җылылык,матурлык,илебезгә тынычлык алып килсен.

Шушы кояштай,тормышның,

Кадерен белеп кенә.

Әйдәгез,бер яшик әле

Елмаеп-көлеп кенә!

**Җыр “Мин яратам сине Татарстан”.**

## “Ястык кою” йоласы

***Минһаҗева Галия Рафаэль кызы***

*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче 3нче номерлы балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

Балаларны кечкенәдән гаиләдә, балалар бакчасында милли-мәдәни рухта тәрбияләгәндә үзебезнең татар халкының электән килгән гореф-гадәтләре, мәдәнияте белән кызыксынучы әхлаклы, әдәпле, инсафлы, белемле шәхес тәрбияләү өчен шартлар булдыру.

**Бурычлар**:

1. Тәрбия традицияләренә нигезләнеп балаларда халкыбызның гореф-гадәтләренә, бәйрәмнәренә карата кызыксыну уяту.
2. Татар халкының милли бәйрәмнәре, йола уеннары, гореф- гадәтләре аша балаларның аралашу күнекмәләрен, сөйләм телләрен үстерү.

3. Милләтебезнең асылын чагылдырган милли бәйрәмнәргә һәм йолаларга , гореф- гадәтләренә ихтирамлы караш тәрбияләү.

**Кереш сүз**.

Без- балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр, педагоглар алдында торган бурычларның иң мөһиме – балаларга үзебезнең туган телебезне өйрәтү, шул тел аша халкыбызның сәнгате, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары белән таныштыру- мөһим чараларның берсе булып тора. Ә бу эшләр барысы да үзебезнең җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, такмаклар, санамышлар, әкиятләр, бәетләр, билге инде моңлы бишек җырлары аша өйрәнелә.

Бүгенге көндә милли бәйрәмнәр, татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары онытылып бара. Туганнар, күршеләр белән аралашу, очрашулар сирәгәя бара. Шулай да бу күренешләрне югалтмау йөзеннән безнең балалар бакчасында даими рәвештә чаралар үтеп тора. Халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм бәйрәмнәренә игътибар итеп, балалар белән берлектә төрле милли чаралар оештырылып килә. Бүген сезгә тәкъдим ителәсе йола да, мин яшь вакытта әбием сөйләгәннәргә нигезләнеп язылды. Элек йорт казлары бәбкәләрне күп чыгара иде. Бергәләп каз өмәләре оештыра иделәр. Каз каурыйлары йолку күренешләре, мендәр, ул вакытта әбиләребез ястык ясыйлар иде, менә шулар бик кызык булып сакланып калган.

**Йола барышы.**

*Өй күренеше. Инде казлар йолкынган, эш беткән. Каз өмәсенә килүчеләр таралышкан. Урындык, өстәлләр куелган.*

Урамда малайлар,кызлар уйнап йөри.

**Малай.** Кызлар,малайлар, бүген бит Хәдичә әбиләрдә каз өмәсе булды. Әллә барып киләбезме. Әбинең каз мае белән майланган коймагы калгандыр әле.

**Кыз**. Әйе,әйе. Хәдичә әби бик тәмле пешерә. Мин аның коймагын Гөлфира оныгы белән уйнаганда ашаганым бар.

**Икенче малай**. Мин инде ашыйсым да килә башлады.

**Икенче кызлар** бергә. Әйдәгез барыйк тизрәк. Малайлар, сезне алып бармыйбыз. Үзебез генә барабыз яме.

**Кызлар**. Юк инде, бергә булгач бергә. Киттек Хәдичә әбиләргә.

*Өй күренеше. Әби өйдә йөри*.

**Әби**. Менә ничек күңелле үтте бүгенге каз өмәсе. Инде менә мамыгыннан ястык кына коясы калды.

Шул вакыт малайлар,кызларишек шакыйлар Хәдичә әби, безне керт әле диләр.

**Хәдичә әби**. Кунаклар көтмәгән идем. Кемнәр килгән икән? Ишек ачык ,керегез.

**Малайлар, кызлар**. Исәнме ,Хәдичә әби.

**Хәдичә әби**. Исәнме,Кызларым, улларым

**Кыз**. Сездә каз өмәсе булган.

**Икенче кыз**. Ул коймак исе бөтен авылга таралган.

**Малай**. Хәдичә әби, безнең бит синең коймагыңнан авыз итәсебез килә.

Өченче малай( әби янына ук килеп) безне авыз иттерәсеңдер бит,Хәдичә әби.

**Хәдичә әби**. Күр әле боларны. Берсеннән- берсе "тәмле телле". Коймагың тәмле диеп, мине юмалыйлар. Их сезне,бөтерчекләрем. Әйе шул. Каз өмәсе булды. Казлар йолкынган, эчләре алынган, юылган, бауга да эленеп куелган.

**Кыз.** Менә бит эш тә беткән.

**Малай**. Әйе, әйе, әбекәй, эш беткән. Эш беткәч уйнарга ярый ди безнең татар халкы.

**Икенче малай**. (Шаяртып) Ә безгә коймак ашарга ярый.

**Хәдичә әби**. Ай-яй,яй. Юк шул,балалар, әле аның тагын да зур эше- бер йоласы калды.

**Кызлар, малайлар**. Нинди йоласы калды?

**Хәдичә әби**. Ястык кою йоласы. Ястык коелмаган.

**Кыз**. Әби, өйрәт әле безгә.

**Хәдичә әби**. Әллә өйрәнәсез, булышасызмы?.

**Кызлар, малайлар**. Әйе, бик теләп өйрәнәбез дә булышабыз да .

**Хәдичә әби**. Менә бит. Аллаһның рәхмәт яугырлары. Кызлар, менә сезгә алъяпкыч,яулыклар. Ябыгыз, мамыгы ябышмасын. (кызларга яулык, алъяпкыч бирә), ә сез малайлар, барыгыз тиз генә мунча алдыннан ләгән белән каз мамыгын алып керегез. Менә,кызларым, мин ястык коя башлаган идем, арып киттем. Сезнең болай керүгез бик әйбәт булды. Эше бетеп тора хәзер .

*Кызлар алдына ястык чыгарыла, малалайлар ләгән белән мамык алып керәләр.*

*Утыралар*.

**Хәдичә әби.** Ястык коюның үзенең бер тәртибе бар, балалар. Мамыкны күпертеп һәм теләк тели- тели салырга кирәк. Шул вакытта гына бу ястык та йоклаулары "тәмле" була.

**Малайлар** .Ә без нишлибез,Хәдичә әби.

**Хәдичә әби**. И, балаларым, сезгә дә эш бетмәгән. Менә каз каурыйлары . Аларны йолкып, коймакларны майларга каз канаты ясарга кирәк. Шул вакытта гына коймак тәмле була ул,улларым. (малайлар алдына каз каурыйлары куя.)Менә шулай итеп йолкыйбыз.

**Кызлар, малайлар**. Әйдәгез теләкләр телик.

**Кыз**. Хәдичә әбинең икенче елга да казлары күп булсын

**Малай**. Исән- сау яшәргә язсын.

**Кыз**. Бу мендәрдә йоклаулар "тәмле " булсын.

**Малай**. Әбинең балалары игелекле булсын. (Һәм башкалар. Һәр бала кычкырып теләк тели эшли. Әби. “Әмиин” , “Әмиин” диеп тора.)

**Кызлар**. Әйдәгез әле күңелле итеп җырлый- җырлый эшлик. (такмаклар җырлашалар).

*Кулымдагы йөзегемнең*

*Исемнәре Фәния.*

*Шушы ястыкта йокларга*

*Яссын иде безгә дә.*

*Кызлар,йолдызлар,*

*Һавадагы йолдызлар.*

*Малайлар,калайлар,*

*Чүплектәге калайлар.*

**Хәдичә әби.** Малайлар, күрегез бу кызларны. Сездән үчеклиләр түгелме.

**Малайлар**. Борчылма, әбекәй. Хәзер без аларны.

*Әнә килә автомобиль,*

*Төягәннәр тәпәчләр.*

*Үзең монда,әниең кайда*

*Дип кычкыра әтәчләр.*

*Борың кызыл,*

*Борының кызыл,*

*Помидормы ашадың.*

*Әллә кем булып йөреп,*

*Безне күрми башладың*

(монда төрле тамаклар җырларга була)

**Кызлар**. Әбекәй, җырлаша җырлаша эшләп, ястыкларыбыз да әзер булды бит.

**Хәдичә әби**. Алайса, әйдәгез әле, ястыкларны урамга алып чыгып, кагып, күпертеп алып керик. (Чыгып китәләр дә, күпертеп кире алып керәләр. Бу арада әби эшләгән эшкә сөенә-сөенә йөри)

**Хәдичә әби**. Кайдан килеп чыкты бу балалар. Аллаһның рәхмәте яугырлары. Ничек эшләп бетерермен дип йөргәндә, ястыкларым да әзер булды бит.

*Кызлар мендәр, малайлар каз канаты алып керәләр*.

**Кызлар**. Менә ,Хәдичә әби, ничек йомшак ястыклар булды.

**Малайлар**. Әби, күр әле бу канатларны. (әбигә канат бирәләр). Хәзер инде коймак ашыйбыз.

**Хәдичә әби**. Кая ястыкларны куегыз әле монда. Ястык кою йоласының “Ястык “уены да бар бит әле. Аны уйнамасак, килешеп бетмәс.

**Малайлар , кызлар**. Өйрәт кенә ,хәзер уйныйбыз.

Ястыкларны берсе өстенә берсен куялар.

**Хәдичә әби**. Я, килегез әле монда уенның тәртибе болай. Санамыш белән берегезне сайлыйбыз. Шул кеше шушы ястыкка башын куеп ”йоклый”. Ә без аның тирәсендә җырлап- биеп әйләнәбез. Кем дә кем аның кулына кагылып китә, ул аның кем икәнен белергә тиеш була. Белмәсә, җәза бирелә. (уен шулай берничә тапкыр кабатла)

**Хәдичә әби**. Балакайларым, сезнең белән бик күңелле булды. Мин сезне бүләксез дә калдырасым килми. Минем сорауларга җавап бирсәгез, бүләкнең иң зурысы ,коймакның иң тәмлесе сезгә.

*Сорауларга табышмаклармәкальләр дә булырга мөмкин.*

*Каз бер аякта басып торганда икенче аягы кайда?*

*Каз судан ничек чыга? Һ. Б шундый казга кагылышлы берничә сорау булырга мөмкин.*

**Хәдичә әби**. Булдырдыгыз, балалар. Менә сезгә бүләк. (Каз канаты өләшә). Икенче елга да казларым күп булсын. Сез ястык коярга килерсез. Әйдәгез хәзер каз мае белән майланган коймак белән чәй эчәбез диеп, “Каз канаты” җырын җырлап чыгып китәләр.

## “Атнакич” бәйрәме

***Әминова Ләйсән Рәфкат кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль*
*районының “Дөбъяз”Гөлчәчәк” балалар*
*бакчасы, мәктәпкәчә белем бирү*
*муниципаль бюджет учреждениесе”*

**Максат:**

- балаларда халкыбызның хәзинәләренә кызыксыну уяту, нәниләрнең күңелен халкыбызның хәзинәләр байлыгы белән тулыландыру.

**Бурычлар:**

- татар халкының йола, гореф-гадәте һәм бәйрәмнәренең Татарстан халыклары тормышындагы ролен ачу ;
- халкыбызның хәзинәләренә карата сакчыллык-пөхтәлек тәрбияләү, матурлыкны күрергә өйрәтү.

**Катнашалар:** Әби, алып баручы, балалар, музыка җитәкчесе.

**Хәзерлек эше:**

1. Залны бизәү.

2. Җырлар, шигырьләр, уеннар, изге теләкләр, әйтемнәр, мәкәлләр өйрәнү.

**Җиһазлау:**

1.Экранда “Халкыбызның күңел бизәкләре” күренеше.

2. “Балалар иҗатында милли бизәкләр”.

3. “Көнкүреш кирәк –яраклары, сандык тулы маллар - хәзинә”

**Сүзлек өстендә эш:**

1. Балаларны сузык һәм җиңел сүзләрне ачык әйтеп җырларга өйрәтү.
2. Сүзләрдәге аерым авазларга басым ясатып, аларны ачык һәм дөрес әйтү.

Кереш өлеш

Матур итеп авылча бизәлгән өйнең эчке күренеше. Өйдә ялгыз әби яши, аның хәлен белергә балалар бакчасыннан балалар килеп йөри.Әби аларга кызыклы вакыйгалар турында сөйли, догалар өйрәтә.

**Алып баручы:** Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар! Без бүген сезнең белән "Атнакич" бәйрәмен үткәрәбез. Ул гадәти бәйрәм генә түгел, ә халкыбызның күңел бизәкләрен барлау һәм өйрәнү булачак. Җәүһәр - кыйммәтле таш дигән мәгънәне аңлата. Димәк, без бүген күңел кыйммәтләрен, күңел бизәкләрен өйрәнәбез, шулай ук үзебезнең белемнәребезне тикшерербез. Сынатмагыз, игътибарлы булыгыз, ишеткәннәрегезне күңелләрегезгә сеңдерә барыгыз.

**Алып баручы:** Бәйрәмебезне башлап җибәрәбез (ишектән балалар керә, әби янына төзелеп утыралар - Әле безнең кунаклар тагын килә икән. Рәхим итегез, балалар. **Балалар:** - Әссәламегаләйкем! (Әби белән исәнләшәләр, әби җавап бирә). **Әби:** Әйдәгез, бергәләп йортка дога кылыйк әле (Аллааһүммә раббәнәә әңзилнәә мүңзәләм мүбәәракә үә әңтә хайруль мүңзилиинә раббәнәә әәтинә фиддүньйәә хәсәнәтә үә фил әәхыйрати хәсәнәтә үә кы-йнәә гәзәәбә ннәәр).

**Нурислам:** Әби, ни өчен йортка дога кылалар? **Әби:** Өйгә бәрәкәт иңсен өчен дога кылу кирәк. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә һәр өйгә бәракәтен, уңышын бирер. Раббыбыз һәрберебезгә үз өендә тынычлыкта, иминлектә, бәхеттә, бәракәттә, хәләл муллыкта яшәргә насыйп итәр!

**Әдилә:** Әби, безгә тагын берәр дога укып, аңлатып күрсәтегезче, бик эчтәлекле, мәгънәле икән бит догаларыбыз.

**Әби:** “Ихлас” сүрә укып, аңлатма бирә. (Аллаһ бердер. Бөтен нәрсәләр Аллаһыга мохтаҗ. Тудырмады, тудырылмады. Аның һичбер тиңе вә охшашы юк.)
**Балалар**: Бик зур рәхмәт инде, әби, никадәр дога ишеттек.

**Алып баручы:** Үткән заманның серен сеңдергән бу йортның бусагасыннан ук борынгылар тормышы күренеп торадыр сыман. Әйе, биредә безнең халкыбызның югалмас мирасы тупланган. Ә ул мирасны тырыш хезмәт сөюче халкым тудырган. Сөекле Габдулла Тукаебызның "Эшкә өндәү" шигырен әби авызыннан тагын бер мәртәбә ишетик әле. (Әби "Эшкә өндәү" шигырен яттан сөйләп күрсәтә.)

**Алып баручы**: Биредәге милли җәүһәрләребез турында фикер алышуны дәвам итик. Бизәнү-ясану әйберләре турында нәрсәләр беләсез балалар? (рәсемнәр күрсәтелә). Балалар тәңкә, чулпы, яка чылбыры, энҗеле калфак турында белгәннәрен сөйлиләр.
**Алып баручы:** Балалар карагыз әле, безнең әбинең ниндидер бер сере бар ахры.
**Әби:** Әйе, балалар, минем серле, челтәрле сандыгым да бар бит әле. Аның сере шунда, ул үзе турында сөйләгәч кенә ачыла.

**Ризат:** "Челтәрле сандык" шигырен укый.
Серле сандык, матур сандык,
Кызыктыра безне күптәннән.
Әйдә, карыйк,ниләр калган икән
Истәлеккә безгә үткәннән
Әби сандыгын ачып, аннан әйберләр алып күрсәтә, балалар белән бергә исемнәрен кабатлыйлар.
(Кызлар сөлгеләр белән бию башкаралар).
**Алып баручы:** Халкыбыз элек-электән төрле әйберләргә бизәкләр төшерү белән шөгыльләнгән. Татар халык бизәкләрендәге орнаментларны карап китик. Орнамент ул-элементлар чиратлашу, кабатланудан торган бизәк**.**

Бу бизәкләрдән сез ниләр аңлыйсыз? Кем ничек уйлый?

**1 бала:** Безнең милли үрнәкләребез бер-берсеннән аерылып тора.
**2 бала:** Бизәкләр кыңгырау, лалә, канәфер чәчәкләренә һәм яфракларга охшатып ясалган.
**Алып баручы**: Шундый бизәкләрне эшләү ни өчен кирәк булган соң?

**Балалар:** Матурлык өчен. Матур булсын өчен

**Әби**: Сез үзегез бизәкләп эшлисезме соң? (балалар җавап бирә).

**Алып баручы:**Балалар, әйдәгез әбигә милли бизәкләребез белән ничек эшләгәнне күрсәтеп китик.

**Уен** : “Түбәтәй” һәм “Алъяпкыч” бизәү.

**Алып баручы:** Халкыбыз еллар һәм гасырлар буе бизәкләп эшләү һөнәрен саклап, үстереп килгән. Кайсыгыз әйтә, бизәкле әйберләрне хәзер дә эшлиләрме?

Җаваплар бирелә, рәсемнәр күрсәтелә.

**Алып баручы**: Эш сөюче халкыбызның язмышы халык аваз иҗатында да

киң чагылыш таба. Әйдәгез, балалар, тагын бер уен уйныйбыз .“Башы телемдә, ахыры төендә” дип атала ул. Мәкаль әйтеш була бу. Мин башын әйтәм, төен чишүче мәкальнең ахырын таба. ( бау алып 6-7 төен төенлим, балалар чишәләр**).**

Кем эшләми - ... (шул ашамый)

Оста кулда ... (һөнәр бар).

Тырышкан табар – ... (ташка кадак кагар).

Эш сөйгәнне... (ил сөйгән).

Ана күңеле балада –... (бала күңеле далада).

Күрше хакы,...( тәңре хакы).

**Алып баручы:** - Афәрин, балалар, булдырдыгыз.

**Әби:** Балалар элек – электән үк кич белән болыннарда, су буйларында, клубларда, кич утыруларда, аулак өйләрдә түгәрәк җырлы уеннар уйный торган булганнар. Ә сез татар халык уеннарын беләсезме соң, балакайларым?

**Балалар:** “Наза”, “Йолдыз санау”, “Чума үрдәк, чума каз”, “Сукыр тәңкә” , “Йөзек салыш”.

**Алып баручы:** Әйдәгез әле, балалар, берәрсен уйнап алыйк, арыгансыздыр - ял да булыр. “Чума үрдәк, чума каз” уенын уйнау.

**Әби:** Булдырдыгыз, балалар, бик тырыш, оста, зирәк һәм тапкырлар икәнсез. Борынгы заманнардан ук безнең әби-бабаларыбыз алдан кисәтә белгәннәр. Аларның зирәк кисәтүләре, акыллы гыйбарәләре бик кирәкле булган бит. Минем дә сезгә үземнең үгет-нәсыйхәтләремне бирәсем килә.

- **Җиргә ятып йоклама, җен кагылыр.(**Чынлап та шушы кисәтүне онытып, юеш җиргә ятып йоклаучылар азмыни).

-**Суга ятып су эчмә, эчеңә елан керер**. (Кемнең генә инде суга ятып эчәргә йөрәге җитсен .Ә савыт белән, чүмеч белән эчү - әдәп гигиена. Ни эчкәнеңне дә күрәсең, саграк

буласың. Безнең халык элек- электән үк чишмәләр янына – су эчәр өчен махсус савытлар куйган бит).

-Чүмечтән аш ашама, битең табак кадәр булыр.

-Өйдә сикермә, өй иясен кузгатырсың.

-Иләк аша карама, битең шадра булыр.

Сезгә, кызларга, малайларга бу үгет-нәсыйхәтләр бик кирәк. Өлкәннәрне һәрвакыт тыңлагыз.

**Алып баручы**: ”Атнакич”бәйрәме бик эчтәлекле, кызыклы булды, күп нәрсәләр ишеттек, күңелләребез сафланып, күтәрелеп китте. Кадерле балалар, халкыбызның күңел җәүһәрләре сезне гел матурлыкка, яхшылыкка, сакланырга, шәфкатъле, игелекле, әдәпле булырга өндәсен. Әйдәгез бу теләкне бик матур татар халык җыры “Матур булсын” дигән җырның сүзләренә салыйк һәм бәйрәмебезне җыр белән тәмамлыйк.

Син дә җырла, батыр егет,
Син дә җырла, матур кыз!
Матур булсын, матур булсын,
Матур булсын бу тормыш!

Безнең ил кояшы балкый
Якты булыр көн саен;
Якты булсын, якты булсьн,
Якты булсын көн саең!

Илебезнең халыклары
Матур тормыш коралар;
Тыныч булсын, тыныч булсын,
Тыныч булсын дөньялар!

# “Каз өмәсе”

***Гайфуллина Ләйлә Фәнил кызы***

*МБМББУ - “Олы Кибәче “Күбәләк” балалар бакчасы” Саба муниципаль районы Татарстан Республикасы*

**Максат:** Балаларны татар халкының милли бәйрәме “Каз өмәсе” йоласы белән таныштыру. Халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына хөрмәт, ихтирам тәрбияләү.Хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.Бәйләнешле сөйләм теле үстерү.

**Җиһазлау:** элеккеге авыл өе күренеше, ясалган казлар, канат-каурыйлар, самовар, чигелгән сөлгеләр, бизәкле көянтәләр, өстәл, утыргычлар.

**Бәйрәм барышы:**

*Бәйрәм үтәсе зал матур итеп бизәлгән. Салмак кына милли көй яңгырый.*

**1 нче алып баручы:** Хәерле көн кадерле әниләр! Безнең балалар бакчасы инде күп еллар сабыйларга милли-мәдәни тәрбия бирү өстендә эшли. Бу изге эштә милләтебезнең байлыгы булган бишек җырлары, мәкальләр, табышмаклар, милли йолалар, бәйрәмнәр ярдәмгә килә.

Милли бәйрәмнәрнең һәркайсында халкыбызнын күркәм гореф-гадәтләре, матур йолалары, җыр- бию, уен-көлке чагыла. Кеше әлеге бәйрәмнәрдә һөнәргә, батырлыкка, тапкырлыкка һәм зирәклеккә өйрәнә. Бүген без сезгә халкыбызның милли йолаларының берсе булган “Каз өмәсе” кичәсеннән өзек күрсәтербез.

**2 нче алып баручы:** Авыл халкы элек-электән күп көч сорый торган эшләрне ирекле рәвештә җыелышып, күмәкләшеп башкарган. Күп каз асраган гаиләләрдә каз өмәсен оештыруны тормыш үзе таләп иткән. Өмәдә барыннан да элек кызларның уңганлыгы сыналган. Булачак кайнаналар үзләренә ошаган кызларны шунда билгеләп куйганнар. Борынгы әби-бабаларыбыз казларны бик яратканнар. Күргәнебезчә, каз өмәсе авыл тормышының бер бизәге. Бу гадәтебез яшь буынга кире әйләнеп кайтыр дип ышанасы килә.

**1 нче алып баручы:** Каз мамыгыннан түшәк, ястык, мендәр ясаганнар. Ә итен, маен төрледән-төрле аш-су әзерләү өчен файдаланганнар. Каз бәлеше, каз коймагы, тәбикмәге, каклаган һәм тутырылган каз әзерләгәннәр. Каз маен дәва өчен кулланганнар, кышкы суыкларда бит-колак очлары өшесә каз мае сөрткәннәр.

**2 нче алып баручы:** Авылларда хәзер каз өмәсе,

Уз, рәхим ит, әйдә кунакка.

Өреләре чыккан каз ашларын
Табалмассың башка юллап та.
   Җырлый-җырлый каз йолкалар кызлар.
   Мамыклары ята сибелеп.
   Казларыбыз быел уңды диеп,
   Түшәгемә мамык булды диеп,
   Әбекәйләр йөри сөенеп.
Күзләр җиткәч, казлар киткән кебек,
Вакыт җиткәч китә кыз бала.
Ә авылда хәзер каз өмәсе.
Өмә җыры һәрбер ызбада.

*Акрын гына "Тәфтиләү" көе яңгырый. Әби-бабай кул эше эшләп утыралар.*

**Әби**: И-и-и картым, бу эш дигәне гел бетми, һич кенә дә житешеп булмый. Аллага шөкер, казып алган бәрәңгеләрне базга урнаштырдык, инде зур эшләрнең берсе генә калып бара. Авылыбызда каз өмәсе дә бетеп килә, урамда су буеннан кайтучы казлар да кимеде.

**Бабай**: Аллаһы боерса, бүген чират бездә. Курше кызларын чакырырга онытмадыңмы?

**Әби:** Чакырдым әлбәттә.Озакламаслар килеп җитерләр. Бик җитез кызлар үсеп килә. (Ишектән тавыш ишетелә)

**Кызлар:** Исәнмесез!

**Әби:** Исәнмесез,кызларым. Килеп тә җиттегезмени? Бик иртә кердегез әле.

**1 кыз:** Шундый матур көз иртәсендә йоклап ятып була мени. Узегездә әнә барысын әзерләп куйгансыз, әллә казан астына да яктыгызмы?

**Әби:** Әйе, кызларым, суыбыз хәзер кайнап чыга, сез кереп утырыша торыгыз, Камил бабагыз казларны алып кереп бирер, пешекләп йолка башларбыз.

**Бабай:** Хәзер оланнар , сез урнаша торыгыз . Озакламый кереп җитәм.

<u>Бию</u>

**Бабай:***(казлар тотып керә)* Менә сезгә казлар, жырлый-жырлый армыйча эшләгез.

**Әби:** Иң элек култык астыннан канатларын йолкып алыйк. Аннары яндырырбыз. Хәзер калган канатларын йолкабыз. Кая әле, кызларым, һәрберегезгә каз бирәм, йолка башлагыз.

**2 кыз:** Казларыгыз бигрәк матур,
Таза булып үскәннәр.
Ә йоннары, каурыйлары
Мамыкланып беткәннәр.

**3 кыз:** Камил бабайларның һәр елны казлары симез була. Сания әби әйбәт ашата торгандыр.

**Әби:** Җәйләр үтте, көзләр җитте

Бик симерде казларым.

Каз йолкыйлар тиңдәшләрем,

Күрше- тирә кызларым.

(Кызлар түгәрәкләнеп каз йолкыйлар.)

**4 кыз:** Кызлар, җыр җырласак эшләребез җиңелрәк эшләнер. Әйдәгез, җырлыйк әле.

Җыр.

Әби: Балалар, казларның мамыгын аерым, каурыйларын аерым салыгыз. Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан гына мендәр ясыйм әле. Әй, ул каз мамыгыннан гына торган мендәр… Аңа яту белән эреп китәсен инде. Без кияүгә чыкканда әти-әниләр бирнәгә түшәк-ястыкны каз мамыгыннан гына ясыйлар иде. Хәзер андый зур ястыклар юк инде, шулай да бу каз мамыкларыннан җыйнак кына ике мендәр ясыйм әле.

**2 кыз**: Камил бабай эрепләр китәр инде яңа мендәрдә. *(Көләләр)* Иртән йоклап калмасын.

**5 кыз:** Кызлар, канат сыдырасыбыз да бар бит әле. Әйдәгез әле, кем остарак сыдырыр икән?

**Әби:** Йонын сыдырып бетергәч, каз каурыйларын елга буена, тыкрыкка, сукмакларга чәчәләр. Бу-киләсе елда каз күп үссен, йортка тезелешеп кайтып керсен, дигән теләк белән эшләнә.

**6 кыз:** Алдан барсын әнкәсе, арттан барсын әткәсе. Пипелдәшеп йөгереп барсын 21 бәбкәсе.

**Әби:** Безнең дә бар иде яшь чаклар, каз өмәләре үтә иде. Казлар йолыкканда егетләр килеп күңел ачып китәләр иде.

**Бабай:** Гармун тавышы ишетелә, әллә егетләр киләме?

**Әби:** Кызлар, канатлар алыгыз. Канат сатабыз (егетләр керә.)

**1 малай**: Шыгыр-шыгыр капканы

Шыгырдатмый япмабыз.

Каз өмәсе булган җирдән,

Беребез дә калмабыз( Керәләр)

**Малайлар берәм-берәм:** Исәнмесез, барыгыз!

- Бездән сәлам алыгыз.
- Сәлам Сания әбигә,
- Сәлам Камил бабайга
- Сәлам матур кызларга.
- (бергә) Өмә күрке казларга!(Көлешәләр)

**Кызлар:** Исәнмесез!

**Әмир:** Кызларыгыз симез булсын!

Әй, юкла, казларыгыз симез булсын!

**Кызлар:** Егетләр сезгә кем кирәк?

**Егетләр:** Безгә матур кыз кирәк.

**Кыз**: - Ул кызыбыз бик елак.

**Малай**: - Кәнфит, прәнник бирербез.

**Кыз**: - Кәнфит прәнник яратмый.

**Малай**: - Яратмаса эләкми. Сез нишлисез кызлар?

**Кыз**: - Без йон йолкыйбыз!

**Малай**:- Без аларны таптарбыз.

**Кыз**: - Нәрсә белән таптарсыз?

**Малай**: - Аяк белән таптарбыз.

**Кыз**: - Ә без сезне куарбыз (канат белән сугалар.)

**Җыр : "Дүдәк-дүдәк"** (Егетләр һәм кызлар кара –каршы җырлашалар)

**Дамир:** Каз канатлары йолкасыз,
Йолкып ни майтарасыз?
Бу өйләрдә җырлап-көлеп
Кемнәрне юатасыз?

**Зөһрә:** Каз канатлары йолкабыз,
Йолкып эш майтарабыз.
Җырлап-көлеп, уйнап-биеп,
Күңелне юатабыз.

**Бергә:** Каз бәлеше тәмле пешә
Кызыл кирпеч мичләрдә.
Серләшәбез, сайрашабыз
Бу күңелле кичләрдә.

**Әби**: Әйдәгез әле, балалар, каз канатлары тотып бер биеп алыйк әле.

**Бию:"Каз канаты"**

**Әби:** Егетләрнең килүе әйбәт булды әле. Казларны юып алып кайтыйк әле. Егетләр ярдәм итсеннәр.( Казларны көянтәләргә элеп, су буена алып китү күренеше.Казларны чайкыйлар)

**Сөләйман:** Каз чайкыйлар безнең кызлар,
Куллары эшкә ята.
Мактаудан башка бер сүз юк,
Бу кызларга карата.

**7 кыз:** Кызлар, туңдыра башлады бит әле. Әйдәгез , җылынырбыз да “Чума үрдәк, чума каз” уенын уйнап алабыз.

**Бергә:** Әйдәгез, әйдә!

**<u>Уен:</u>** “Чума үрдәк, чума каз”

**Тимур:** Кайда бәлеш, май, коймак

Анда барсак без кунак.

**Кыз**: Казларыбыз да чистарды. Җылынып та алдык. Әйдәгез, кайтабыз.

(Музыка астында кайталар. Аларны әби каршы ала.)

**1кыз:** Әбекәй, казларыңның эшен бетердек, чистарттык, юдык, бәкедә чайкадык.

**2кыз:** Казларыгыз бик симез булганнар, әбекәй.

**Әби:**Бәрәкалла, әтисе, күр әле, казлар бик симез булганнар.Илгә-көнгә тынычлык, үзебезгә сәламәтлек насыйп итсен. Балалар, оныклар, туганнар белән тәмле итеп ашарга язсын.

**Бабай:** Эх, минә ичмасам, бу бәйрәм. Мондый мал-бәрәкәт булганда, биемичә ничек түзәргә кирәк. (бабай биеп ала)

**Әби:**Тукта әле, әтисе, яшьләр биесеннәр. Синең яшең узган, туның тузган инде. Әйдәгез, балакайлар бер түгәрәк уены уйнап күрсәтегез әле.

**Уен:** «Челтәр элдем читәнгә»

**Алып баручы** : Гөрләп үтте, шаулап үтте

Авылда каз өмәсе.

Бу айларны, бу көннәрне

Көтеп ала хәммәсе.

Менә шулай каз өмәсен

Татарда үткәргәннәр.

Ә яшь кызлар күңел биреп

Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Канатлар белән бию «Каз канаты»**

**Әби:** Чәйләрем дә пеште, коймакларым да әзер. Аллага шөкер, казлар да эш ителде!

**Бабай:** Менә мондый милли бәйрәм, йолаларыбыз онытылмасын өчен бергә җыелырга, балаларга кечкенәдән өйрәтергә кирәк шул.Яшь буынны тәрбияләү-безнең бурыч! Әби-бабайларсыз булмый әле ул!

**Әби:** Бәйрәмебезне чәй өстәле янында дәвам итәрбез.Барыгызны да каз коймагы белән чәй эчергә чакырам.Рәхим итегез!

## “Бишек җырлары- әнием моңнары”
## фольклор кичәсе

***Галиәхмәтова Гөлүсә Фаухетдин кызы.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципальрайонының“Арча 2 нче балалар бакчасы”муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

**Максат:** балаларны татар халкының әби-бабайлардан калган милли гореф-гадәтләре, борынгы йолалары белән таныштыру.

**Тәрбия бурычы:** балаларда милли гореф-гадәтләргә, йолаларга хөрмәт, ихтирам тәрбияләү, милли җырлы- биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата мәхәббәт хисләре уяту.

**Белем бирү бурычы:** балаларның сүз байлыкларын арттыру. татар халык уеннарын һәм җырларын өйрәтү; әдәплелеккә, бер-береңә карата игътибарлы булырга, олыларны хөрмәт итәргә өйрәтү.

**Үстерү бурычы:** балаларның хәтер һәм фикер йөртү сәләтен үстерү, бәйләнешле сөйләм телен камилләштерү.

**Кичә барышы.**

***Дәү** әни ике оныгы белән бәлеш ясап, мичкә куялар.*

**Дәү әни.** Балакайларым, менә тиздән бәлеш тә пешеп чыгар. Сез миңа булышкач, бәлешне тиз генә әзерләп мичкә куйдык бит. Итле бәлеш татар халкының иң тәмле милли ризыкларының берсе инде ул.

Гаиләбезгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, өченче оныгым дөньяга килде бит. Балакайлар, озакламый әти-әниләрегез дә кечкенә бәбиебез белән кайтып җитәрләр.

**Камилә.** Дәү әни, дусларыбызның да безнең кечкенә сеңлебезне бик күрәселәре килә. Алар кунакка керсәләр, әнием сүз әйтмәс микән?

**Дәү әни.** Балакайларым, дусларыгыз да керсеннәр. Бергәләшеп, күңелле итеп сеңлегезне каршы алырбыз. Бәбиебезгә исем дә уйларга кирәк бит әле. Бишекне дә әзерләп куярбыз, Аллаһ боерса. Халкыбызда бәби туу белән бәйле йолалар бик күп һәм алар хәзер дә саклана.

**Адилә.** Шул йолалар турында безгә дә сөйлә әле, дәү әни.

**Дәү әни.** Рәхмәт яугырлары, бик рәхәтләнеп сөйләрмен.

**Камилә.** Алайса мин дусларымны тизрәк кунакка чакырыйм әле, дәү әнием. Аларга хәзер тиз генә телефоннан хәбәр җибәрәм дә, озакламый килеп тә җитәрләр.

**Дәү әни**. Әйдәгез,балакайлар, өстәлне көйләп алыйк. Сез өстәлгә чәк-чәкне, коймакны һәм балны куя торыгыз, мин тиз генә самоварны куеп керәм. Тиздән бәлеш тә өлгерер, Аллаһ боерса. *(Дәү әни самоварны алып чыгып китә).*

**Камилә.** Адилә, дуслар килеп тә җитте инде! Каршы алыйк кунакларны!

**Адилә.** Кем бар анда?

**Ишек артыннан тавыш.** Бәлеш исен сизәбез, кунакка без киләбез. *(Балаларның кулларында күчтәнәчләр. Балалар кереп, ярымтүгәрәк итеп басалар)*

**Данир**. Исәнмесез –саумысез,
Бәби күрергә килдек без,
Нигә каршы алмыйсыз?

**Зилә.** Исәнмесез, дусларым!
Хәерле көннәр булсын!
Уен – көлке, җыр – моңнан
Күңелләребез тулсын!

**Ралинә.** Сабыегыз тормыш яме булып,
Ай үсәсен үссен көнендә.
Нәселегезнең гореф-гадәтләрен
Саклап барсын алгы көннәргә.

**Таир.** Ай нурлары булса кичтән ,
Таң нурыдай булсын иртәсе.
Сездә булган барлык яхшылыкны,
Буыннарга аның илтәсе.

**Адилә.** Исәнмесез! Хәерле көн!
Рәхим итегез түрдән!

**Сәйдә.** Күчтәнәчләр алып килдек,
Барыгызга күп итеп.
Баллысын да, татлысын да,
Озын юлларны үтеп.

**Дәү әни самавыр күтәреп керә.** Кунаклар килеп тә җиткән икән... Бик әйбәт булган. Менә самавыр да кайнап чыкты, тиздән бәлеш тә пешәр. Балакайлар, түрдән рәхим итегез.

*Балалар утыралар.*

**Камилә.** Дәү әни, нәрсә эшлисе бар?

**Дәү әни.** Балакайлар, безгә бишекне әзерләп куярга кирәк. Бишек дигәннән, әзрәк сөйләп китим әле. Борынгы бабаларыбыз яңа туган сабыйны тирбәтү өчен бишек уйлап тапканнар. Аларның нindиләре генә юк! Нечкә тал чыбыгыннан үргәннәре дә, агачны уеп

ясалганнары да, тактадан сырлап ясаганнары да... Бишек – сабый өчен изге оя бит ул. Баланың күп вакытын рәхәттә, тынычлыкта үткәрә торган урыны. Дөрестән дә, сабыйның иң рәхәт, иң тыныч чагы бишектә яткан вакыты бит. Бала бишектә тирбәлә, анда изрәп йоклап китә, аңа анда рәхәт. Уянып китсә дә, ул үзен үзе тирбәтә ала, чөнки сабый селкенүгә бишек тирбәлә башлый. Күп кенә кешеләр бишек эләргә ашыкмыйлар, инде модадан чыкты дип уйлыйлар. Ә менә минем оныкларым бишектә тирбәлеп үсте. Кечкенә оныгым да бишекне яратыр, Аллаһ боерса.

**Дәү әни.** Балакайлар, сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы?

**Балалар.** Юк.

**Дәү әни.** Чыбылдык ул – бишек өстенә каплап куела торган тукыма. Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Әйдәгез, бишеккә чыбылдыкны да элеп куйыйк. *(Бергәләшеп чыбылдыкны эләләр).*

**Дәү әни.** Менә бишегебез әзер дә булды. Шушы бишеккә бәбине салып, бишек җыры да җырласаң, бәби рәхәтләнеп йоклап китә инде. Балакайлар, сезгә әниләрегез бишек җырлары җырлыйлармы соң?

**Энҗе.** Минем әнием кечкенә энемне татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның "Бишек җыры"н җырлап йоклата.

**Камилә**. Дәү әнием, ул җырны безгә бакчада тәрбияче апаларыбыз өйрәтте. Дусларым, дәү әнигә "Бишек җырын" җырлап күрсәтик әле.

**Г.Тукай "Бишек җыры"**

Әлли-бәлли итәр бу
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла, балам ,йом күзең,
Йом-йом күзең , йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Елап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

**Дәү әни.** Бишек җыры җырлаганда ана сабыена үзенең изге теләкләрен тели. Бишек җырлары тыңлаган сабый тыныч холыклы булып үсә. Бала сөйләшә белмәсә дә, сүзләрне

аңламаса да, җырны тыңлап изрәп йокыга киткән.
**Дәү әни.** Балалар, ишеттегезме, бишек җырында әнисе сабыена нинди матур сүзләр белән эндәшә? Ә сезгә әниләрегез нинди ягымлы сүзләр әйтә соң? Әйдәгез, без моны белү өчен “Ягымлы сүзләр” уенын уйнап алыйк.

**“Ягымлы сүзләр” уены. (**Бишек җыры башлануга бер-беребезгә курчакны тапшырабыз. Көй туктагач, кемдә курчак кала, шул ягымлы сүз әйтә).

**Камилә.** Әйдәгез, дусларым,
Түгәрәкләргә басыйк.
«Зәңгәр чәчәк» уенын
Бергәләп уйнап алыйк!

**«Зәңгәр чәчәк» уены уйнала.**

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.
Дус- ишләрең арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр,
Мендәреңне сал әле.

**Дәү әни.** Мин оныткан да идем инде бу уенны, менә искә төшердегез бит, рәхмәт яугырлары.

**Адилә.** Дәү әнием, сеңлебезгә нинди исем кушарбыз икән?

**Дәү әни.** Халкыбызда бәби туу белән бәйле йолаларның иң беренчесе исем кушу. Исем ул кешенең язмышын билгели торган нәрсә дип каралган. Элек-электән мәгънәле эчтәлеккә ия булган исемнәр кушканнар. Мулла килеп азан әйтеп, исем куша, балага бәхет теләп, дога кыла. Исем кушуга хәзер халык бик игътибар итә. Әти-әни баласының бәхетле, озын гомерле, игелекле булуын тели, шуңа күрә сүзлекләрдән карап, укып исем сайлыйлар. Менә сез, балакайлар, үз исемнәрегезнең нәрсә аңлатканын беләсезме? Тагын бер уен уйнап алыйк сезнең белән. Мин хәзер кулъяулыкны төйним дә берәрегезгә ыргытам. Төенләнгән кулъяулыкны кемгә ыргытам, шул үз исеменең мәгънәсен әйтә.

**Камилә.** Тулы, бөтен, бар яктан камил килгән.

**Адилә.** Гадел, намуслы, дөрес, тугры.

**Айсылу.** Ай кебек» сылу, чибәр.

**Гүзәл.** Бик матур.

**Данир.** Көчле.

**Зилә.** Миһербанлы.

**Таир.** Сабыр.

**Сәйдә.** Бәхетле.

**Әмир.** Җитәкче.

**Дәү әни.** Барыгызның исемнәре нинди матур мәгънәгә ия икән бит. Ә яңа туган бәбиебезгә әти- әниләре Зөһрә дигән исем кушарга уйлап торалар. Зөһрә күктә балкып торган йолдыз дигәнне аңлата.

**Гүзәл**. Һәр кешегә матур исем кирәк,
Аның булсын тирән мәгънәсе.
Шушы исем аңа гомерлеккә!
Истә тотсын әткә-әнкәсе.

**Айсылу.** Шушы исем белән яшәп кеше,
Үрләр яулый, таный, таныла,
Исем мөһим кеше язмышында,
Һәркем салсын моны аңына.

**Зилә.** Ак биләүгә биләп,
Күкрәгенә кысып,
Моңлы җырын әнкәй көйләгән.
Кояш белән торып,
Белгәннәрен укып,
Баласына бәхет теләгән.

**Биләүгә биләгән курчаклар белән бию башкарыла.**

**Дәү әни.** Бигрәкләр дә күңелле булды сезнең белән, яшь чакларым искә төште. Мондый дәвам итүчеләребез барында халкыбызның гореф-гадәтләре югалмас, сакланыр, Аллаһ боерса. Рәхмәт сезгә, балалар!

**Адилә**. Дәү әни! Дәү әни! Әтием шалтыратты. Тиздән кайтып җитәбез диде.

**Дәү әни.** Кечкенә оныгымны каршы алырга бөтен нәрсә әзер. Самавыр да кайнады, бәлеш тә пеште. Исән- сау кайтып җитәргә насыйп булсын.

Әйдәгез, балалар, бәбәйне алып кайтканчы, кадерле әниләребез турында җырлап алыйк әле.

**Җыр: “Әнием” .**

1.Чәчәкләр матур булса да,
Бармы шаккатырлыгы?
Әниемнең күзләрендә
Дөньяның матурлыгы.

Кушымта. Әнием, әнием, әнием,
Таң җиледәй назлы кулларың.
Әнием, тик сиңа багышлап,
Жырлыйлар яраткан кызларың.
2. Кояшның  яктылыгына
Торасы юк аптырап.
Әниемнең нурлы йөзе
Кояштан да яктырак.
3.Диңгезне чиксез киң диләр,
Беләм алай түгелен.
Барлык диңгезләрдән дә киң
Әниемнең күңеле.

**“Каурый өмәсе”**

***Хажҗиева Альбина Рәшид кызы.***
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль Районының «Гомуми үсеш бирүче төрдәге Балтач 2нче номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** татар халкының милли бәйрәме- “Каурый өмәсе” белән таныштыру.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:** татар халкының милли бәйрәмнәре, йола уеннары, гореф- гадәтләре аша балаларның аралашу, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү;

**Тәрбия бурычы:** балаларда бердәмлек, дуслык хисләре, халкыбызның гореф- гадәтләренә, йолаларына хөрмәт, ихтирам тәрбияләү;

**Белем бирү бурычы:** халыкка хас әдәп кагыйдәләре белән таныштыру.

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып - белү үсеше.

**Материал һәм җиһазлар:** авылча бизәлгән зал, милли киемнәр, каз каурые, каз канаты, үрелгән каз оясы

**Бәйрәм барышы:**

Талгын гына “Каз канаты” көе яңгырый. Сәхнәгә зур кәрҗин күтәргән балалар шаулашып килеп керә. (Арттан кергәне борылып карый- карый кычкыра)

**Нәфисә** : Ярый, әби, ярый. Аңладык бит инде ничек эшләсен, эшләрбез. Син коймагыңны пешер.

(бу вакытта балалар кәрҗин алдында сөйләшә- сйләшә мәш киләләр)

**Нәфисә** : (аларга таба килеп) Эй, туктагыз сез бит анын нишләтәсен белмисез. Мина әби 3 сәгать буе сөйләде.

**Г.Ильсинә** : Аңладыңмы соң?

**Нәфисә** : башта аңлаган кебек булдым, аннары оныттым аннары әби эшләгәндә исеңә төшәр әле дип мине чыгарып җибәрде.

(Кәрзин янына сәхнә алдына бер җиргә җыелалар)

**Балалар**: Нишлибез хәзер?

**Нәфисә**: (кулына бер каурый ала) Менә бу каз каурые дип атала.

**Дәмин** : Эй, Нәфисә каз каурые икәнлеген беләбез. Чебинеке түгел бит.

**Нәфисә** : Әби эйтте, “Без кечкенә чагында каз өмәсе көнне балаларны каурый өмәсенә җыялар иде. И-и кызык була иде безгә! Эрҗә белән каурыйлар, сындырылган йонны кәрзингә җыяр идек ди- мендәрне бик шәп кабарта ул каурый йоны ди. Соңыннан сыдырылган каурыйларны су буена чәчеп, бәбкәләрнен күп булуын теләп кайта идек ди.

**Азамат**: Бездә шулай эшлибезме?

**Нәфисә**: Эйе, аннары коймак ашыйбыз.

**Барысы да** : Әйдәгез, әйдәгез.

**Радмир** : Канат сыдырабыз. Әйдәге әле, кем остарак, сыдырыр икән?

**Әминә** : Ай- һай, күп монда каурый, әбинең казлары бик күп булган, ахры.

**Нәфисә**: Әйе, безнең әби ел да иллешәр бәбкә үстерә ул.

**Сөләйман** : Аларны үстерергә бездә булыштык шул:

Тилгән, тилгән,

Бәбкә алырга килгән,

Бер аягы тимердән,

Бер аягы камырдан, көш-көш!

дип тилгәннәрдән саkладык.

**Рамилә** : Ә мин икенче төрлесен беләм:

Тилгә, тилгән,

Ата- анаң үлгән,

Песи барып күмгән,

Сиңа хәбәр килгән,

Уң күзенә туфрак,

Сул күзеңә яфрак, көш-көш!

**Г.Ильсинә** : Мин дә беләм:

Тилгән, тилгән,

Бәбкә күргәч, тилергән,

Бер бәбкә дә алалмыйча,

Көне буе тилмергән.

**Нәфисә** : Күз курка, кул эшли, дигән мәкаль дөрес икән. Каурыйлар бигрәк күп, ничекләр бетерербез дип курыккан идем, менә бит эшебез төгәлләнеп бара.

**Радмир** : Азамат синен эшләр ничек?

**Азамат**: Хәлләр шөкер, җилкә чакыр, кабыргам киң, мин кемнән ким? (икенче яктагы малайга төртеп) Әй, Дәмин эшләр шәпме?

**Дәмин** : Авыр эшкә беләк бар,

Кыю эшкә йөрәк бар!

Шулай бит, кызлар?

(кызлар бергә җыр белән җавап бирәләр)

Биек тауның башларында

Утыра бер алачык,

Күп сөйләште, аз эшләде,

Борчак сибә, мактанчык (көләләр)

**Нәфисә**: Күрәсезме, күмәк эштә һәркем сынала аз сөйлә куп эшлә. Шулайда гел сөйләшмичә дә күңелле түгел бит. Әйдәгез кызлар бер биеп алыйк.

**Бию “Каз канаты “**

**Нәфисә** : Биеп, көлеп каурый беткәнен дә сизми калганбыз! Эш беткәч уйнарга да ярый. Җырлыйк, биик, күңел ачыйк!

**Җырлы- биюле уен: “Челтәр элдем читәнгә”**

Сәхнә эченнән әби тавышы килә: Балалар, әйдәгез коймагым табадан тәгәрәп төште, керегез өйгә.

**Балалар**: Әйдәгез, әйдәгез, коймак белән чәй эчәбез (дип кереп китәләр).

**“Йомырка җыю бәйрәме”**

***Каримуллина Гөлназ Сөләйман кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ш.т. Байлар Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге Саба 1 нче “Шатлык” балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** Балаларны татар халкының онытыла барган бәйрәмнәре, аларның гореф – гадәтләре, милли уеннары һәм бию элементлары белән таныштыру. Балаларда бәйрәмгә карата уңай тәэсирләр калдыру. Сүз байлыгын тулы –ландыру. Балаларда патриотлык һәм Ватанга мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

**Бәйрәм үткәрү урынын җиһазлау:** залда татар авыл йорты күренеше, йортның ике ягында койма, өстәл һәм агач озын урындыклар, йортның эчке бизәлеше милли рухта бизәлгән: кичке күренеш – уртада өстәл тора, өстәлдә чигүле ашъяулык ябылган, аның өстендә буялган йомыркалар салынган тәлинкә, самавыр һәм милли ризыклар куелган. Бер як койма янында агач озын урындык һәм икенчесендә катнашучылар утыра. Иртәнге күренеш – өстәл һәм бер озын агач урындык алына, ишегалдына охшатып уртага агач макеты куела.

**Катнашучылар**: өлкәннәр – хуҗабикәләр, ике ишегалдына – малайлар  һәм кызлар.

**Бәйрәм барышы:**

*Залда талгын гына милли көй яңгырый.*

**Алып баручы:** Безнең бабаларыбызның онытыла барган бәйрәмнәре, аларның гореф – гадәтләре, нихаять, яңадан әйләнеп кайта башлады. Татар авылларында яз айлары истә кала торган мизгелләрнең берсе булган. Язның бер көнендә балалар, өйдән өйгә кереп, күкәй җыйганнар. Бу көн турында халыкка алдан ук белгерткәннәр, шуңа күрә хуҗабикәләр кичтән күкәй кызартып, күчтәнәчләр әзерләп куйганнар. Иртән сабыйлар, “Аягым җиңел булсын” дип, тели – тели, авыл буйлап, өй саен кереп йөргәннәр. Бер үк вакытта алар күршеләре, туганнары, авылдашлары белән дә танышканнар. Өлкәннәр дә сабыйларны сынаганнар: кем баласы исәнләшә һәм рәхмәт әйтә беләме, кыюмы, зирәкме, аның үз – үзен тотышы ничек һ.б. турында белгәннәр.

Җыелган күкәйләрне кырга алып чыгып, балалар төрле уеннар уйнаганнар. Сыйланганнан калган күкәйләрне җир өстенә сибеп киткәннәр. Шулай иткәндә игеннәр мул була, ел җиңел

килә, дип ышанганнар. Татар халкының гореф – гадәтләре, милли йолалары күңелебездән чыкмаган әле. Алар белән кызыксыну арта гына бара.

*Тонык кына яктылык төшә (кичке күренеш). Бер як койма ягындагы озын агач урындыкта 3 кыз утыра алар каршында әниләре. Балаларның алларында янчыклар. Алар җырлап янчык тегәләр.*

Төрле һөнәр беләбез,
Матур итеп тегәбез.
Асыл төсле җепләр белән
Без янчыклар тегәбез.

*Көй астында кызлар шигырь сөйлиләр*

**1 Кыз**:

Капчык тегәм, капчык тегәм
Йомыркалар салырга

**2 Кыз:**

Уйнап, көлеп, җырлап, биеп
Күкәй җыя һәр бала.

*Кызлар шигырь сөйләгәннән соң яңадан 1 куплет җыр җырлыйлар.*

**Әни:** Иииии йокларга вакыт җитә икән бит ... Булдымы балакайларым?

**Кызлар:** Булды!

*Кызлар теккән янчыкларын әниләренә күрсәтәләр һәм биергә басалар.*

**Татар бию көенә янчык тотып бию.**

*Бию ахырында “сәхнә артына” кереп китәләр.*

**Әни:** Янчыклар бигрәк матур булган ( *һәм сәхнә артына кереп китә*)

**Декорация ишегалдына үзгәртелә.**

*Әтәч кычкыру фонограммасы яңгырый, аннан уяну көе. Хуҗабикә әни чыга.*

**1 Хуҗабикә:** Хәерле иртә балаларым! Торыгыз! Бәйрәмне йоклап калмагыз! Бүген бит йомырка җыю бәйрәме!

**1 Бала: (уртага йөгереп чыга)**

Май аеның ни икәнен
Белми торгансыз әле.
Безнең якта май ае –
Күкәй җыю бәйрәме

# “КАПКА ТӨБЕНДӘ”

***Фәррәхова Люзия Әбелмәксән кызы***

*Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы “8 нче номерлы гомуми үсеш тибындагы “Кояшкай” балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат һәм бурычлар:**

Балаларның татар халык йолалары, бәйрәмнәре турында белемнәрен баету. “Капка төбендә” уены белән кызыксынуларын арттыру.

Халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына хөрмәт, ихтирам, дуслык, татулык тәрбияләү.

Җырлау, сәнгатьле сөйләү, бию сәләтләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

Күтәренке кәеф тудыру .

**Җиһазлар:** Стенада өй рәсеме, янда өй макеты, капка, койма, чәчәкләр, таяк, утырырга эскәмияләр, урындыклар, сандык, аудиоязмалар , гармун

*(Матур көй яңгырый)*

**1 малай**

Халкыбыз йолаларын

Искә төшерик әле,

Капка төбендә бергәләп,

Эх, күңел ачыйк әле**!**

Әйдәгез, киттек капка төбенә!

**Язилә**

Әллә берәү дә чыкмаган инде бүген капка төбенә.

Кызлар , сез кая?

**Айгөл** *(таяк тоткан, карана-карана керә)*

Сәлам, Язилә. (*һаман нидер карый)* Матурым, матурым, кая югалды соң бу чукынмыш Кәҗә? (*кәҗә тавышы килә)* Мин хәзер киләм.

**Ләйлә** (*керә, койма ягыннан карый)*

Сәлам, дустым. Нишләп берүзең карачкы кебек утырасың? *(утыра)* Симички кирәкме? (*бирә, көнбагыш чиртәләр*)

**Айгөл** (*керә, этенеп, уртага утыра)* Кая башка кызлар?

**Язилә**

Нишләптер берәү дә юк әле.

*(2-3 кыз керәләр)*

**Кызлар**

Сәлам, кызлар.

**Язилә, Айгөл, Ләйлә**

Сәламегезне алдык, кесәгә салдык. Килегез монда, утырыгыз.

**Арина**

Кызлар, а че вы тут делаете? (*Көзгедән карый)*

**Язилә**

Әйдә, кил монда. Шәп булачак, менә күрерсең.

**Арина**

Как можно здесь веселиться. Интернета нет, телефон не ловит *(Кулында телефон, утыра)*

**Айгөл**

Куй инде шул телефоныңны. Нигә кирәк сиңа интернет? Аннан башка да күңелле бездә. *(егетләрнең җырлаган тавышы ишетелә)*

Эх, алмагачлары,

Сайрый сандугачлары.

Сайрый-сайрый, сайрый-сайрый

Сагындыра башлады.

**Ләйлә (***тора да, койма башыннан карый)*

Әнә егетләр дә киләләр

*(Егетләр капка алдында туктап калалар)*

**2 малай**

Әй, тук-тук

**Кызлар (***берничәсе үрелеп карый)*

Ни кирәк?

**1 малай**

Ни кирәк түгел. Кем кирәк?

**Айгөл**

Алайса, кем кирәк?

**Малайлар**

Кара кашлы кыз кирәк.

**Кызлар**

Керегез инде тизрәк.

**3 малай**

Алма бакча – челтәр капка,

Ачыла ике якка.

Килдек, кызлар, сезнең белән

Уйнап, күңел ачарга.

**4 малай**

Сәлам, кызлар,чибәр кызлар,

Һавадагы йолдызлар.

Капка төбен җанландырып,

Җырлыйбызмы соң, дуслар?

**<u>Җыр “Әй, кара каш, кара күз”</u>** *(Җырлый-җырлый бииләр)*

**Кызлар**

Су буенда куаклар,

Безгә килгән кунаклар.

Сездә ничек, бездә шулай

Җырлап бирә кунаклар.

**Малайлар**

Эх, кара каш, кара күз, замечательная,

**Кызлар**

Капка төбендә утыру- обязательная.

**Малайлар**

Әйдә, дустым, безнең якка,

Безнең якта бәке бар.

Әйдә, дустым, безнең якка,

Утырырга сәке бар.

**Малайлар**

Эх, кара каш, кара күз, замечательная,

**Кызлар**

Капка төбендә утыру- обязательная.

**Кызлар**

Безгә керә китегез,

Безгә керә китегез.

Кунакка килгән булсагыз,

Әйдә,  рәхим итегез.

**Малайлар**

Эх, кара каш, кара күз, замечательная,

**Кызлар**

Капка төбендә утыру-  обязательная.

**Малайлар**

Безнең “Кояшкай” кызлары

Бигерәкләр дә чибәр.

Капка төбенә килгәнсең-

Әйдә җырлап та җибәр.

**Малайлар**

Эх, кара каш, кара күз, замечательная,

**Кызлар**

Капка төбендә утыру-  обязательная.

*(Тәрәзә ачыла)*

**Әни (***тәрәзәдән әйтә)*

Әтисе, кара әле, безнең капка төбенә балалар килгән түгелме соң?

**Әти**

Әйе шул, әнисе. Балалар, нишлисез анда?

**1 малай**

Әйдәгез, чыгыгыз безнең янга, капка төбенә.

*(Әти белән Әни чыга)*

**Әни**

Әстәгыфирулла, нишләп йокламыйсыз, соң бит инде?

**Әти**

Әнисе, яшь чакта без дә утыра идек бит капка төбендә.

**Әни**

Без яшь  чакта “Капкалы” уенын уйный идек, әйеме, әтисе?

**“Капкалы” уены**

Әйдә, безгә килегез,

Капкалардан керегез.

Капкалардан керегез,

Өебезгә үтегез,

Өебезгә үтегез,

Җырлап, бәйрәм итегез. (*балалар, “Иделләре” көенә җырлап, түгәрәктә әйләнәләр. Җырның ике юлы җырланганда, кыз белән малай җитәкләшеп уртада йөриләр. 3-нче юлдан балалар кулларын өскә күтәрәләр, ”капка” ясыйлар, бу парны “капкадан” үткәрәләр. Көй туктаганда , “капка ябыла”, балалар кулларын төшерәләр. Кайсы “капкада” калалар, шул балалар белән уртада дүртәүләп, уң куллары яисә сул куллары белән тотынып түгәрәктә әйләнәләр. Соңыннан парлап әйләнәләр. Башка балалар да бу вакытта парлап әйләнәләр. Беренче пар башка балалар янына баса, икенче пар уенны дәвам итә.Уен берничә тапкыр уйнала)*

**Әти** *(өйдән сандык алып чыга)*

Кемнәр оста, кемнәр тапкыр,

Минем янга килегез.

Сандыкта нәрсә барлыгын

Бик тиз генә әйтегез.

Үзе кечкенә, матур. (*балалар үз җавапларын әйтәләр)*

Асыл ташлары да бар.

Бармакка кияләр. (Йөзек)

Булдырдыгыз. *(Йөзекне сандыктан алалар)*

**5 малай**

Дуслар, әйдәгез йөзек белән уйныйбыз.

*(балалар түгәрәктә баралар, сүзләрне әйтә-әйтә, күрсәтмәскә тырышып, йөзекне бау буйлап үткәрәләр. Уртадагы бала , сүзләр бетү белән, йөзекнең кемдә булуын белергә тиеш)*

Сөләйманның йөзеген

Дию кызы урлаган.

Йөзек анда калмаган,

Суга төшеп югалган.

Кемдә йөзек? *(Баланың исеме әйтелә). (Уен 2-3 тапкыр уйнала)*

**6 малай**

Капка төбе бик күңелле,

Биедек әй кыздырып.

Айгөл җырласын әле,

Моңлы итеп сыздырып.

**“Күгәрчен гөрлидер” җыры**

**Әни**

Әтисе, әйдә керик инде. Тәмләп кайнар чәй эчмичә  йоклап булмас бүген.

**Әти**

Рәхмәт, балалар, яшь чакларга кайтып килдек. (*өйгә кереп китәләр)*

**7 малай**

Әйдәгез, бер уйнап-биеп алабыз да, таралышабыз.

**“Әнисә такмаклары”**

**Арина**

Здорово. Так интересно было. Завтра где встречаемся?

**Балалар**

Капка төбендә *(җырлап, чыгып китәләр)*

Әх, кара каш, кара күз, замечательная,

Капка төбендә утыру – обязательная. *(чыгып китәләр)*

*(Рәхим кире керә йөгереп)*

**Рәхим**

Иртәгә сез дә чыгыгыз капка төбенә. Күңелле булачак!

*Биючеләргә кушыла*

**Татар бию көе – сәламләү.**

*Балалар бию ахырында икегә бүленеп ике якка койма яныныа басып шигырьләр сөйлиләр:*

**1 Бала:**

Безнең якта бәйрәм бүген,
Бездә бүген тантана!
Өйдән – өйгә йөреп әнә
Күкәй җыя һәр бала.

**2 Бала:**

Төсле күкәй, төсле күкәй!
Бик матуры бер генә!
Иң матуры – иң өлгергә,
Алыгыз, кем өлгерә!

***Күңелле татар көе яңгырый, шушы көйгә ике ишегалды балалары такмак әйтеп кара – каршы киләләр:***

“Кыт, кыт, кыт – кытыйк,
Чиби – чиби чип тавык,
Хуҗалар өйдәме?
Бер йомырка бирәме?”

**1 Хуҗабикә:** Өйдә, өйдә әйдәгез түрдән узыгыз. Сезне килерләр дип көттек.

**Балалар:** (барсы бергә). Исәнмесез!

**3 Бала:**

Әби, әби, әбекәй,
Җәтрәк бир безгә күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй.

**1 Хуҗабикә:** Әйдә, әйдә керегез, сезгә дип әзерләп куйдым.

**4 Бала**:

Табакка каймак кирәк,
Май, күкәй, коймак кирәк.
Күмәчен дә кызганма,
Озак яшә сызланма.

**5 Бала:** Безне бик зурладылар, сый хөрмәт күп җыелды. Еллар тыныч, уңышлар мул булсын.

- Мә-ә, мә-ә, куйларыгыз күп булсын,
- Му-у, му-у, сыерыгыз сөт бирсен, бозавыгыз булсын,
- Кыйтак, кыйтак тавыкларыгыз йомырка салсын, чебиләр чыгарсын,
- Га-га-га казларыгыз күп булсын, ястык түшәк жыегыз.

*Хуҗабикә балаларга рәхмәт әйтә, йомырка һәм күчтәнәчләр өләшә. Балалар йомыркаларын янчыкларына салалар.*

*Йола дәвам итә, ә хәзер икенче ишегалды балалары беренче ишегалды балаларына каршы такмак әйтә – әйтә киләләр.*

Чеби – чеби чип тавык,
Куначага мен тавык,
Кунакчага менәлмәсәң
Чебешеңне җый тавык
Хуҗалар өйдәме соң?
Бер йомырка бирәме соң?

**2 Хуҗабикә:** Әйдә әле, кил әле муллык өстәп бир әле.

Уйныйк әле, уйныйк әле,
Сынатыштан булмасын.

Сезнең арада берәү дә
Авыз йомып тормасын.
Бик тиз җавап бирсәгез,
Күкәй бирермен сезгә.

1. Яшел чирәм өстендә корт – корт кортлар.
   Канатларын җәеп балаларын туплар. (Тавык)
2. Бозын ватсаң, көмеш чыгар, көмешен ватсаң, алтын чыгар.
   Ак күл, ак күл эчендә сары күл. (Йомырка)

**2 Хуҗабикә:** Бик тапкырлар, зирәкләр икәнсез, моның өчен сезгә йомырка бирермен!

*Икенче ишегалды балаларына да йомырка һәм күчтәнәчләр өләшенә, алар да йомыркаларын янчыкларына салалар һәм хуҗабикәгә матур теләкләр телиләр:*

- Малларыгыз күп булсын!
- Карак кермәсен, көчекләрегез карак җибәрмәсен!
- Аягым җиңел булсын!

**6 Бала:** Апакай, безгә сезнең өйдә күңел ачарга, җырлап биергә рөхсәт итмәссезме икән?

**2 Хуҗабикә:** Рөхсәт, балалар, рөхсәт. Бергә – бергә күңелле булыр**.**

**7 Бала:** Рәхмәт апакай. Әйдәгез күңел ачабыз. “Капкалы” уенын уйныйбыз.

*Балалар парлашып басалар. Уртада калган парга җәза бирелә. Мәсәлән, беренче пар җырлый, икенчесе бии, өченчесе шигырь сөйли.*

**8 Бала:** Ә хәзер “Яшьләр уены”  уйныйбыз.

*Кызлар һәм малайлар кара – каршы тезелеп басалар. Бер – берсенә “Челтәр элдем читәнгә” дигән татар халык җырының куплетларын җырлыйлар.*

**9 Бала:**

Җырларыбыз юлдаш булсын,
Юлдаш булсын, яңгырап торсын.
Эшләрегез уңнан булсын,
Илебезне бизәп торсын.

*“Матур булсын” дигән татар халык җыры башкарыла.*

**Хуҗабикә:** Кадерле балалар! Минем сезгә зур үтенечем бар: табигатьне саклагыз, елгаларның суы саекмасын, болыннарыбыздан киек казлар китмәсен. Әби – бабайларга, яклаучысы булмаганнарга ярдәм итегез. Дөньялар тыныч булсын, зәңгәр күкне кара болыт капламасын. Үләннәр һәрчак яшел торсын. Игеннәр һәрчак мул уңыш бирсен. Барлык изге теләкләрегез кабул булсын.

**Балалар:** Амин, шулай булсын!

**10 Бала:** Без уйнадык, җырладык, биедек, күңел ачтык. Ә хәзер барыбыз да бергәләп су буена төшәбез, шунда җыелган күчтәнәчләр белән сыйланырбыз.
*(Көй астында чыгып китәләр).*

**“Әбидә кунакта”**
**(каз өмәсе)**

***Ибнеева Раушания Радиф кызы***

*Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Актаныш гомуми үсеш бирүче 4нче балалар бакчасы" мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат**: Милли гореф-гадәтләрне һәм йолаларны торгызу.

**Бурычлар**:

1. Балаларда татар милли йолаларына кызыксыну тәрбияләү, башка милли халыклар белән дуслыкны ныгыту.
2. Балаларга сәхнә осталыгы, сәнгатьчә бию, җырлау күнекмәләре бирү, сөйләм телләрен үстерү.
3. Балаларны татар халык иҗатының гүзәл үрнәкләре белән таныштыру, татар халкының милли, зәвыклы, матурлык яратучы халык икәнлеген аңлату.

**Җиһазлау**: сандык, мендәрләр, чиккән сөлгеләр, кульяулыклар, самовар, савыт-саба, татар халкының милли ризыклары, тәрәзә макеты, гармун, эче тутырылып теккән казлар, каз каурыйлары, каз канатлары, май канатлары, аудиоязмада каз кычкырган тавыш, баян.

**Көтелгән нәтиҗә:**

**1.** Балаларда татар милли йолаларына кызыксынуларына ирешү, башка милли халыклар белән дус булу теләген булдыру.
2. Балаларда сәхнә осталыгы, сәнгатьле бию, җырлау күнекмәләре булдыру, сөйләм телләре үсү.

3. Балаларның милли гореф-гадәтләрне һәм йолаларны белүләренә ирешү

*Музыка залы татар карчыгының өе кебек бизәлә. Салмак кына татар халыкының “Каз канаты” дигән көй уйнап тора. Каз өмәсе өчен кирәкле әйберләр, алдан тиешле урынга куела. Әби чыга, сөйләнә:*

Каз каңгылдый

**Әби** -И, и, и, гөмеркәйләр, менә тагы каз өмәләре җитте (тәрәзәдән карый). Нишләп бу кызлар һаман юк икән, кояш күтәрелеп бетте бит инде. Бабай белән казларны да әзерләп куйдык...

*“Каз канаты” көенә кызлар көянтәгә чиләк асып керәләр, көянтә-чиләк белән 3-4 күнегү ясыйлар, көянтә, чиләкләрне илтеп куялар.*

**Әби:** И рәхмәт яугырлары, буш килмәгәннәр, үзләре белән су да алып килгәннәр. Әйдәгез, әйдәгез менә монда куегыз

*Кызлар тастан казлар алы, каз йолкый башлыйлар*

**Ләйсән:** И, кызлар, казлары бигрәк тә симез, әйме?

**Зәлия**: Ширпылы гына була күрмәсен инде.

**Айзилә:** Кызлар, иртәгә кемдә икән каз өмәсе?

**Адилә:** Бәдри әбиләрдә.

**Әби:** Әйе, иртәгә, Бәдри әбиегезгә каз өмәсенә барырсыз, балакайларым. (Әби кызлар янына утыра да). И-и-и, әйтмә инде, балалар, үзе кызык, үзе ямансу инде шушы каз өмәләре. Казның итеннән нинди генә ризыклар әзерләмиләр. Алай гынамени әле, татар халкының иң зур күчтәнәче кунакка барганда каз булган. Туйларда яшьләрне хәзер дә зурлап, изге теләкләр, пар булып яшәүләрен теләп, урлап пар каз чыгаралар. Ә килен булган кыз, каз мамыгыннан пар мендәр алып килгән. Карагыз әле, кызлар, әниләрегез сезгә дә пар мендәрләр әзерләгәннәрдер инде, әйме? (Кызлар көлешәләр, әби казларны карый-карый). Әй, казларны йолкып бетерә язгансыз бит, телемә салынып утырам икән, өстәл әзерлисем, каз коймагы пешерәсем бар бит (Әби икенче бүлмәгә кереп китә).

**“Шома бас”** ***музыка яңгырый***

**Адилә** - Кызлар, егетләр килә

*Шома бас җырын җырлап егетләр керә*

**Егетләр керә:**

**<u>«Шома бас»</u>**

Уйнат, уйнат гармуныңны,

Биесеннәр егетләр.

Безнең илнең егетләре

Бары да бөркет кебекләр.

Их, күңел ачабыз,

Ничек шома басабыз!

Сайрат, сайрат гармуныңны,

Җилкенсеннәр яшь кызлар.

Безнең кызлар нурлы йөзле,

Әйтерсең лә йолдызлар.

Их, күңел ачабыз,

Ничек шома басабыз!

Әйдә, әйдә, катырак бас,

Биегәнне күрсеннәр;

Баскан җирдән ут чыгара

Безнең яшьләр, дисеннәр.

**Раян:** -Исәнмесез, барчагыз,

-Бездән сәлам алыгыз!

**Капма-каршы җыр: "Челтәр элдем читәнгә" татар халык көе, сүзләре.**

**Егетләр:**

Челтәр элдем читәнгә,

Җилфер-җилфер итәргә.

Без килмәдек буш китәргә

Килдек алып китәргә.

**Кызлар:**

Алын алырсыз микән

Гөлен алырсыз микән,

Урталарга чыгып сайлап

Кемне алырсыз микән.

**С.Алия**

Бүген бездә каз өмәсе

Уз, рәхим ит, әйдә кунакка,

Өреләре чыккан каз ашларын

Табалмассың башка эзләп тә.

**Данил**

-Каз өмәсе бик шәп бәйрәм

Күңел ачаек әле.

**Булат**

Көзләр җиткәч казлар киткән кебек

Вакыт җиткәч китә кыз бала.

Авылларда хәзер каз өмәсе

**Бергә:**

Өмә җыры һәрбер өйдә.

**Җыр: “Каз өмәсе”. Р.Гобайдуллин музыкасы, Н.Гәрәева сүзләре.**

Каурый сибәм су юллыны

Ишле булсын казыгыз,

Өмәләрдә эш күрсәтеп,

Җырлап биеп калыгыз.

Бии кызлар һәм егетләр,

Чыңлый чулпы төймәсе.

Борынгыдан калган гадәт

Татарның каз өмәсе.

Юл аягы – каз коймагы

Сыйлансаң суык тимәс.

Өмәләрдә йөргән кеше

Кайгы – хәсрәт бер күрмәс.

**Элвина:**

Авылларда бүген кызлар җыры

Гармон моңы чыңлый өйләрдә.

Күңелләрдән күңелләргә күчеп

Кабатлана иске көйләрдә.

**Ранил:**

Ап-ак яуган ак мамыклар

Тузып кала пар ат артыннан,

Кыңгыраулар хәтта әбиләрне

Яшьлек елларына чакырган.

**Гүзәл:**

Авылларда бүген каз өмәсе

Ак мамыкка дөнья күмелгән,

Һәм әбиләр сүзсез генә җырлый

Үз яшьлеген җырын сагынган.

**Данил:** Кызлар, егетләр әйдәгез биеп алык!

**Бию: “Татар егетләре һәм кызлары”.**

**Әби чыга:** Иии кызларым тәбикмәктә пешеп җитте.

(әби тәрлинкә белән тәбикмәк күтәреп чыга)

Менә тамаша, егетләр дә килеп җиткән. Әйдәгез балакайларым тәбикмәк белән сыйланыгыз.

И-и-и, яшь чакларым искә төшеп китте әле, балалар, шулай каз өмәсендә егетләр килер иде, китәр иде уен-көлке, җыр-биюләр, бүләк алышулар, бүләк бирешүләр. Әйдәгез әле, безнең яшь чагындагы бер уенны уйнап алыйк әле.

**Уен: “Йөзек салышлы”**

- Шигырь Х.Ләйсән “Балан” М.Җәлил
- Җыр К.Данил “Гармун”
- Үзбәк биюе Ш.Айзилә

**Уен: “ Чума үрдәк чума каз”**

**Уен; “Куш кулым”**

(Уенда йөзек кемдә кала, аңа җәза бирелә).

**Әби:** Менә шулай, уеннар, кул эшләре эшләп, таң атканын да сизми кала идек. Әйдәгез әле, кич утырып каз канатын сыдырып алыйк.

*Балаларга каз канатлары, канат салырга савыт бирелә, берничә төркемгә бүленеп канат сыдырала.*

Менә шулай, балалар, канат каурыйларын ишек төбеннән су буена кадәр чәчә идек. Әйдәгез, балалар, быел да йоласына туры китерик, канатларны бергәләп Ык буена кадәр чәчик.

*Әби алдан бара, балалар арттан каурый чәчеп баралар.*

**Әби** (сөйләнә-сөйләнә): Алдан барсын әткәсе, арттан барсын әнкәсе, әткәсенә-әнкәсенә иярсеннәр утыз-кырык бәбкәсе!

**Балалар:** Дөньялар имин булсын! Казлар күп булсын!

**Наилә:**

Менә шулай каз өмәсен
Татарда үткәргәннәр.
Ә яшь кызлар күңел биреп,
Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Әби:** И, балакайларым казларны юып кайтыр вакытта җитткән... Әйдәгез су буенда казларны юып кайтыйк

***Татар халык көе Каз канаты” көенә балалар парлашып салмак кына бииләр, алып баручы сөйләп тора.***

Авылларда каз өмәсе гөрли
Су буена канат сипкәннәр,
Канат очларына баса-баса
Кызлар каз юарга киткәннәр.

*Кызлар көянтәләренә казларны асып, малайлар чиләкләр тотып, талгын музыка астында залдан чыгып китәләр.*

**«Каз канаты»**

Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була;
Чит җирләрдә бик күп йөрсәң,
Сөйгән ярың ят була.
Каз канаты каурый-каурый,
Хатлар язарга ярый.
Уйнамагач та көлмәгәч,
Бу дөнья нигә ярый.
Каз канаты ап-ак була,
Ир канаты ат була;
Чит илләрдә йөргән чакта
Бик сагынган чак була.

**“Милләт яме – йола, бәйрәмнәрдә. Мунчала чыгару йоласы.”**

***Мирзина Энҗе Мәсгут кызы***

*Татарстан республикасы Саба*
*муниципаль районы Эзмә“Саф чишмә”*
*мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** милли традицияләребезне саклап калу, онытылган йола, гореф-гадәтләрне яңадан торгызу һәм яшь буынга җиткерү.

*Балаларга алдан төшерелгән видеоязъмада авылыбыз агайлары белән су буенда юкә агачын ничек суга салу,әзер булгач мунчаланы ничек төшерү турындагы видео күрсәтелә.*

*“Юкә, юкә” җырының икенче куплеты белән сәхнәгә чыгасы.*

Алып баручы: юкә чәчәге – **бал** ***(кара белән бирелгән сүзләр хор белән әйтелә)***

Алып баручы: кабыгы – **мунчала**

Алып баручы: череге – **дару**

Алып баручы: агачы – **сөян**

***“Юкә, юкә” җырының өченче куплеты башкарыла***

– Кызлар, егетләр мунчала чыгару бәйрәме мөбәрәк булсын!

– Быел мунчала бик калын төшкән кызлар.

– Бик чиста да

– Малайлар, сез мунчала чыгару серләрен беләсезме соң?

**1 бала:** чимал булып җитешсен өчен, күлдә дүрт ай тотасы. Өлгермәсә, мунчала аз чыгачак.

**2 бала:** мунчала нык булсын өчен, күлдән чыгаргач, кечкенә кибәндә пешеп ятуы мөһим.Ләмдә ятып каралган урыннарын аерырга кирәк. Мунчала сары, ак төстә булса матур.

**3 бала:** әйе,кызлар,минем әбием дә башта өстенә кайнар су салып, кер сабыны белән йомшартып, бер кат пычрагын чыгара. Чайкап, мич ташына куеп, пешереп ала. Юкә мунчаласы тәнгә бик файдалы.

**4 бала:** минем әбием файдалы дип гел юкәдән ясалган мунчала белән юындыра. Юкә агачын буага салып әзерләгән абыйлардан алды.

**5 бала:** ә минем әбием үзләренең элекеге фотоларыннан ничек итеп юкәдән чып та да үргәннәрен курсәтте. Аны палас итеп тә кулланганнар, кышын туңмасын өчен ат өстенә каплап та куйганнар. Аннан соң мунчаланы ишеп бау итеп тә кулланганнар

**6 бала**: мунчала йомшак булсын өчен аны яхшылап тарарга кирәк, менә шушылай ***(тарап күрсәтә)***.

**Тәрбияче:** юкә мунчаласы минем өчен, иң беренче чиратта – балачак хатирәсе. Аның хуш исен бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Ул мине бүген дә балачакка алып кайта. Без традицион татар гаиләсендә, әби-бабайлы йортта үстек. Әби белән мунчага бергәләп керә идек. Моңа кадәр юынган мунчала искергән булса, ул яңасын кайнар су белән пешекли, аннан шундый тәмле ис чыга иде. Без шуның белән юына идек. Әби мунча керүнең тәртибен өйрәтте. Хәзер кибеттә мунчаланың ниндие генә юк. Мин һаман да юкәнекен сатып алам. Мунчала кирәклектән түгел, хатирәсе, хуш исе өчен генә булса да тотам. Табигый әйберне бернәрсә дә алыштыра алмый.

**1 бала:** и сөйлибез, и сөйлибез, и мактыйбыз юкәне. Әйдәгез дан булсын әле, бер җырлап алыйк булмаса.

**2 бала:** әйдәгез , эшли – эшли яраткан такмакларны җырлыйбыз.

*(“Тала – тала” җыры көенә,тәрбияче Мирзина Э.М.сүзләре)*

1. Өмәгә җыелдык бүген
Чыгарабыз мунчала
Егетләр менә дигәннәр (кызлар әйтә)
Кызлары да ничава (егетләр әйтә)
**Әй мунчала, мунчала,**
**Мунчаланы кем сала?**
**Хуш исле гади мунчала**
**Тарихта калып бара**.
2. Җырлый – җырлый эшләгәндә
Эшебез гөрләп бара.
Чын осталар күрим дисән
Эзмәгә килеп кара.
3. Аркан белән бау ишәбез
Ясыйбыз пумаласын.
Үткәннәрне барлап яшик
Йолалар югалмасын.
*(Милли киемнән гармун тотып бала сөйли)*
1.Җәй җитүгә өмә ясап
Урманнарга барганнар
Юкә агачын кисеп, егып
Кабыгын салдырганнар
2.Тошергәндә җебетергә
Елга, күлгә батырып
Түземсезлек белән көтеп
Җебегәнен, пешкәнен
Суда ятып кабыгыннан
Аерылып төшкәнен
3.Каян белгән безнең халык
Шул сыйфатын юкәнең...

Шул юкәдән нинди матур

Чабата үрелгәнен

**Эх чабата, чабата**

**Чабата шәп атлата**

**Гармунчысы уйнап торса**

**Биетә дә, җырлата**

*(Чабата биюе башкарыла, музыка уен кораллары кушыла)*

**Тәрбияче:** балалар, сезгә бүгенге бәйрәмнең бер истәлеге итеп авылыбыз агайлары йомшарткан мулчалаларны бүләк итим эле ***(алдан әзерләнгән пумалаларны өләшә)***.

**Тәрбияче:** Үргән чабата, суккан чыпта

Искә алам гел карап

Кәрҗин, сумка, пумаласы

Юынырга мунчала

Онытылып барасыз бит

Юкә, кабык, ***мунчала (хор белән әйтелә).***

***“Юкә” җырының кушымтасын җырлап кереп китәләр.***

**Видео өчен текст.**

Хәерле көн дуслар! Бүген без сезнең игътибарыгызга юкә мунчаласы чыгару йоласын тәкъдим итәбез. Юкә мунчаласы бүген кем өчендер тансыкка әйләнсә, шул ук вакытта аннан беркайчан аерылмаучылар да бар.

Вахит абый юкә агачыннан каерыны сызыра. Матур эшли Вахит абый. Шушы сызырылган каерыны аннан соң инде күлгә мунчала оешсын, ясалсын өчен батырып куябыз ди. Хәер, бу турында абый үзе сөйләсен әле

Мин кечкенә чакта ук безнең авылда мунчала кулләре бар иде. Мин бабаема, әтиемә ияреп төшеп бу эшнең технологиясен өйрәнеп калдым.

Май уртасында юкәнең кабыгын салдыра башлыйлар. Агач юанрак булган саен, мунчала күбрәк чыга. Агачларның кабыгын аерып, июнь башында күлгә салып, агач белән батыралар. Кайрыларны салдырган көнне үк батырырга кирәк. Киптерергә ярамый. Өч ай суда әчегәч, сентябрьдә кабыкларны чыгарып, мунчаласын кубаралар, кечкенә кибәнгә өеп куялар. Берничә көн шулай пешеп тора. Аннан махсус урынга киптерергә эләләр. Кояшлы булганда, ике көн дә җитә. Чимал шулай әзер була. Аллага тапшырып менә бүген суга батырып куярбыз.

**“Карга боткасы” бәйрәме сценариясе**

***Гатауллина Лилия Рамил кызы.***

*Татарстан Республикасы Балтач*
*муниципаль районы “Катнаш төрдәге*
*“Тургай” Норма балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә*
*белем бирү учреждениесе*

**Максат**: Татар халкының мили бәйрәме “Карга боткасы” бәйрәме турында балаларның белемнәрен киңәйтү. Милли, горурлык хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар:**

• Бәйрәмдә катнашасы килү теләге булдыру, иптәшләренең чыгышларын дикъкать белән карарга һәм тыңларга өйрәтү;

• Бәйрәм хисе булдыру, балаларда күтәренке кәеф тудыру;

• Матур әдәбият һәм фольклор әсәрләрен сәнгатьле итеп башкарырга өйрәтү.

**Җиһазлар:** Кәрзиннәр, казан, тәлинкәләр, калаклар, учак, гармун, ярмалар, чиләкләр.

**Алдан әзерлек эше:** Җырлар, шигырьләр, мәкальләр, биюләр өйрәнү.

***Экранда язгы көн сурәтләнгән табигать күренеше.***

Салмак кына татар халык көенә өч кыз чыга. Ял итәсе урынны карыйлар.

**1 кыз:** Менә, ичмасам, бигрәк матур урын, чишмәсе дә бар.

**2 кыз:** Монда уйнарга, җырларга ,биергә дә була. Балаларны чакырыйк әле!

**3 кыз:** Кызлар, малайлар, килегез, яхшы урын таптык!

Балалар керәләр:

**1 кыз:**

Яз бәйрәме килгәнне

Бар халыклар күрсеннәр,

Менә нинди матур бәйрәм,

Нурлы бәйрәм дисеннәр.

***Экранда каргалар очып барганы күренә.***

**2 кыз:**

Карагыз әле, кара,

Каргалар очып бара.

Сез беләсезме,

Алар да бит сөйләшә ала.

***Каргалар булып киенгән дүрт бала керә:***

**1 карга:**

Канат очларына тагып

Яхшы хәбәр алып килдек!

**2 карга:**

Матур язлар алып килдек,

Күңелле җәйләр китердек!

**3 карга**:

Карр, карр.

Туем җитте, бар, бар!

**4 карга**:

Ярма, күкәй алып бар!

Карр, карр.

**3 кыз:** Менә, балалар, каргалар да килеп җитте. Аларга да күңелле булсын, бер уйнап-җырлап алыйк әле!

**Малай:**

Хуш киләсез, үтегез,

Түрдән рәхим итегез!

Бездә бүген зур бәйрәм,

Уйныйбыз әйлән-бәйлән.

**Җыр “Яз җитә”**

**1 кыз:** Борын заманда кешеләр нилектән яз булганын белмәгәннәр. Алар язны кара каргалар алып килә дип уйлаганнар. Шуның өчен карлар эреп, җирләр кипкәч, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясаганнар. Аны “Карга боткасы” дип атаганнар. Балалар бергәләшеп өйдән-өйгә йөргәннәр, сый-хөрмәт җыйганнар. Ә аннары җыйганризыклардан су буенда ботка пешергәннәр, уеннар уйнаганнар. Әйдәгез, без дә өйләргә барыйк, дусларны чакырыйк, сый-хөрмәт җыйыйк! Аннары шушы урында ботка пешерербез, уйнарбыз. Сез ризамы?

**2 кыз:**

Каргалар да килсеннәр,

Яз бәрәмен күрсеннәр.

Майлы ботка чүпли-чүпли,

Карр, карр, диеп йөрсеннәр.

***Экранда капка төбе, өй куренеше Балалар сөйләп, беренче өйгә киләләр.***

**Бергә:**

Кыт-кытыйк,

Әби-бабай өйдәме?

Бер йомырка бир әле,

Бирсәң безгә өч күкәй,

Тавыгың салыр йөз күкәй.

Май кирәк, ярма кирәк,

Карга туена бар да кирәк.

***Балаларны капка төбендә бабай ярма, май белән каршы ала.***

**Бабай:** Исәнмесез балакайларым! Әбиегез базарга киткән иде бит әле, балалар. Сый хөрмәтне үзем бирим, мәгез, мә, үскәннәрем, рәхим итегез. Каргалар да безнең сыйдан авыз итсеннәр.

**Балалар:** Рәхмәт бабакай.

***Балалар икенче өйгә сойләп китәләр.***

**Бергә:**

Шикәр кирәк, тоз кирәк,

Карга туена бар да кирәк.

Тагын булса, он чыгар,

Пешерербез без чумар.

Синең кебек уңган тутәй

Бу дөньяда бик сирәк.

***Эби капка төбендә балаларны ярма, тоз белән каршы ала.***

**Әби**: Һәй, кунаклар бар икән. Сез бәйрәмгә җыйналгансыздыр? Хәзинәдәниләр булса, барын да бирербез. Мәгез балакайларым!

**Балалар бергә:** Рәхмәт сиңа, әбекәй!

**3 кыз:** Әбекәй, бабакай, әйдәгез безнең белән бәйрәмгә!

**1 кыз**: Бабакай син безгә ботка пешерергә казаныңны биреп тор инде! Әбекәй, безгә чишмәдән су алып менәргә чиләкләр дә кирәк була бит, биреп торырсың инде! Бабакай, син, гармуныңны да ал, калмасын!

***Балалар казанны, чиләкләрне, ярмаларны алалар. Бабай гармунда уйный. Аланга җырлап китәләр.***

— Әйлән-бәйлән, әйлән-бәйлән,

Онытылмасын бу бәйрәм,

Балалар язны каршылап

Уйнаган әйлән-бәйлән.

**Әби:** Күпме сый-хөрмәт җыйналган, ярма да бар, май да бар. Хәзер инде, балалар, тәртип белән генә эшкә керешик!

**Бабай:** Иң элек казаны урнаштырыйк. Аны кай төшкәрәк асыйк икән соң? Менә монда әйбәт булыр микән?

**Әби**: Булыр, булыр. Тавышланмагыз, балалар, җайлы гына сөйләшегез, юкса каргаларны куркытырсыз!

**Бабай:** Егетләребез чишмәдән су алып менсеннәр.

**Әби:** Ә сез, үскәннәрем, күңел ача торыгыз.

***Каргалар учак тирәли әйләнәләр***

**Каргалар:**

**1 карга**:

Карр, карр,

Кара урманда кар бар!

**2 карга**: Эреп бетсен тизрәк!

**3 карга:** Учак ягарга кирәк!

**4 карга**: Учак, учак ягарга кирәк!

***Әби белән бабай учак ягу имитациясен башкаралар.***

**Бабай**: Менә учакны да ягып җибәрдек.

**2 кыз**: Кошлар безнең дусларыбыз. Алар табигатькә, кешеләргә зур файда китерәләр, корткыч кортларны, бөҗәкләрне юк итәләр. Шулай булгач, безгә кошларны рәнҗетмәскә, күчмә кошлар өчен оялар әзерләп куярга кирәк. Билгеле, сез аларны әзерләп куйгансыздыр. Әйдәгез, балалар, инде барча кошларны чакырыйк, бәйрәмне күрсеннәр, шигырьләр, җырларны ишетсеннәр!

**1 бала:**

Кар сулары аккан чакта,

Тезелешеп җылы яктан

Торналар кайттылар безгә,

Канатлар кактылар безгә.

**Кычкырдылар**: “Торыйк-торыйк,

Сезнең белән дуслар булыйк,

Көзгә чаклы бергә торыйк!

Торыйк-торыйк, торыйк-торыйк!”.

**2 бала**:

Яз җиттеме, безнең әби
Ясый “Карга боткасы”,
Ботка белән сыйлананалар
Бөтен авыл баласы.
Аның яме! Аның тәме
Телләреңне йотарлык!
Аның тәмен ел буена
Саклап кына тотарлык.

**Әби**: Булдырдыгыз, балалар. Канатлы дусларыгызны рәнҗетмәгез, безнең якта рәхәтләнеп яшәсеннәр, ишәйсеннәр, матур итеп сайрашсыннар.

**1 кыз**: Балалар, эйдәгез бергәләп җырлы-биюле уеннар уйнап алабыз!

**Уен: Агыйдел**

**Әби**: Бигерәкләр дә матур итеп җырлыйсыз инде балакайларым. Иген-ашлык уңсын өчен яңгыр да кирәк бит. Әйдәгез, яңгырны чакырыйк!

**Бала:**

Яңгыр яу, яу, яу!
Тәти кашык бирермен,
Тәмле ботка бирермен,
Тәти кашык базарда.
Майлы ботка казанда.

**2 кыз:** Бик дөрес, балалар. Иген-ашлык мул булсын өчен кояш та, яңгыр да, җылы да кирәк. Һәм безгә тырышып эшләргә дә кирәк! Сез яз турында, эш турында мәкальләр беләсезме?

**1 бала:** Язгы көн ел туйдыра.

**2 бала**: Яңгыр яуса – жиргә май.

**3 бала**: Эш эшкә өйрәтә.

**5 бала**: Эш беткәч - уйнарга ярый.

**6 бала:** Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма.

**7 бала**: Кем эшләми – шул ашамый.

**Бабай:** Әфәрин балалар, бик куп мәкальләр дә беләсез икән. Аякларыгыз өшемиме, бер биеп тә алыгыз инде!

**Татар талык биюе**

**Эби:** Ух-ух, күрше, ботка көймәсен, бигрәкләр дә җилкенеп утырасың.

**Бабай**: Борчылма әле куршекәем, хәзер карыйм. Балалар, уеннарыгыздан туктап торыгыз, ботка пеште.

***Каргалар казан тирәли әйләнәләр.***

**1 карга**: Ботка пеште, карр, карр.

Менә нинди балалар!

**2 карга**: Бигрәк уңган шул алар,

Күз дә тияр димиләр!

**3 карга**: Шундый матур уйныйлар.

Әйе шул, шулай шул!

**4 карга**: Яз көннәре бигрәк ямьле,

Карга боткасы тәмле!

***Каргалар биюе***

**Әби:** Балалар табын янына рәхим итегез! (ботка бүлә):

-Менә бу ботка, җир-анага,

Ил өстенә муллык бирсен. (1 кыз тәлинкә белән ботканы алып җиргә куя)

-Менә бусы – суга,

Су иясе тотмасын. (2 кыз тәлинкә белән ботканы алып җиргә куя)

-Менә бусы – күккә,

Яңгыр бирсен!

Илгә туклык, гаиләгә иминлек килсен. (3 кыз тәлинкә белән ботканы алып җиргә куя)

-Ә менә монсы инде – каргаларга,

Канат очларында

Язны алып килсен өчен! (әби тәлинкә белән ботканы каргаларга илтеп куя)

**Каргалар бергә:** Карр, карр, тәмлеботка бар, бар,

Әйбәт дуслар бар, бар!

**Әби**: Ә калганы сезгә, балалар, утырыгыз ашарга. Түгеп-чәчеп ашамагыз, сыйланыгыз!

**Бабай:** Сау-сәламәт үсегез, тәуфыйклы булыгыз! (Балалар ашыйлар, рәхмәт әйтәләр).

**3 Кыз**: Балалар! Язгы бәйрәмнәрнең берсе – “Карга боткасы” бәйрәме ахырына якынлашып килә. Әйдәгез, бергәләп язларның мул булуын, иген-ашлыкның күп булуын, дөньяла ртыныч булуын телик!

**Күмәк жыр (Матур булсын көенә)**

Җырлый-җырлый, бии-бии,

Бәйрәм итик гел бергә.

Язлар килсен муллык булсын,

Игеннәр уңсын кырда.

Дуслар булсын һәрбер җирдә,

Тынычлык булсын илдә.

Тыныч булсын, тыныч булсын,

Тынычлык булсын илдә.

## АУЛАК ӨЙ

***Вахитова Диләрә Наил кызы***

*Татарстан Республикасы Питрәч*
*муниципаль районының Шәле «Тургай»*
*балалар бакчасы муниципаль бюджет*
*мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:**

1. Татар халкының онытылып барган бәйрәмнәрен, гореф – гадәтләрен хәтердә яңарту һәм саклау, элекке чорның матурлыгын күрсәтү;

2. Балаларда татар халкының җырлы – биюле уеннарына, авыз иҗатына мәхәббәт уяту;

3. Татар халкына ихтирам, горурлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлау:** проектор, экран, телевизор, телефон, аудио, аулак өйләрдән ясалган фотолар белән презентация, татар халык көйләре, татарча бию көе, татарча җырлар: “Моңнар кайтсын авылга”, “Аулак өй”, “Сөлге чигәм” һ.б., сандык, аның эчендә - чиккән сөлгеләр, кулъяулыклар.

**Зал бизәлеше:** зал түрендә өйнең эчке күренеше, анда борыңгы сандык, чиккән мендәрләр, сөлгеләр, идәндә тукылган паласлар җәелгән.

*Авыл өе. Бүлмә түрендә өйнең эчке күренеше, анда борынгы сандык, чиккән мендәрләр, сөлгеләр, идәндә тукыган паласлар җәелгән. Көн кичкә авышкан. Телевизорда “Моңнар кайтсын авылга” җырын җырлаталар:*

*Әйт, авылым, кайда соң моң,*

*Моң кайда соң, әйт, урам?!*

*Аулак өйле һәм гармунлы*

*Яшьлегемне сагынам.*

*<u>Гөлсем әби яшь чакларын искә төшереп җырлый.</u>*

**Гөлсем әби:** Эх, кайтасы иде бер көнгә булса шул яшь чакларга. Аулак өй, каз өмәләре, кичке уеннарга.

*Шулвакыт күрше бүлмәдән оныгы Алсу керә*

**Алсу** *(оныгы)***:** Әбием, нигә син моңсу?

**Гөлсем әби:** Ий, кызым, яшь чакларымны сагынып куйдым әле. Эх,бар иде бит ул яшь чаклар. Егетләр урам тутырып җырлап әйләнер иде, ә кызлар аулак өйләрдә сер бирмичә генә егетләрне көтеп утырыр иде. Ә егетләр килгәч, китәр иде уен-көлке, җыр-бию, такмак әйтешү. Хәзер искә төшереп утырырга гына калды инде!

**Алсу (оныгы):** Әбием, нәрсә соң ул аулак өй? Ул ничек була, ничек үтә? Сөйлә әле, минем дә беләсе килә.

**Гөлсем әби:** Берәр кыз яки егетнең әти-әнисе кунакка яки берәр җиргә китсә, бу өйдә аулак өй була иде. Кызлар җыела, алар янына егетләр килә. Шунда китә уен, җыр-бию, такмаклар әйтешү. Бик күңелле була иде. Әле егетнең күз атып йөргән, сөйгән кызын урларга да мөмкиннәр иде.

**Алсу (оныгы):** Әби иртәгә әти-әни囑 эштә була бит. Әйдә, безнең өйдә аулак өй оештырабыз. Мин дус кызларымны чакырырмын. Син безне үзегез уйнаган уеннар, такмаклар, җыр-биюләр белән таныштырырсың.

Минем дә бик нык килә

Аулак өй үткәрәсем.

Иптәшләремне чакырып,

Сезнең яшьлекне күрсәтәсем.

**Гөлсем әби:** Яхшы, кызым. Тик тәртипле, тыныч, матур булсагыз гына. Мин сезгә барысын да аңлатырмын, өйрәтермен *(сандыкка күрсәтә)*. Шушы сандыгымда минем яшьлектән калган бар кирәкле әйбер дә бар (чиккән сөлгеләр, кулъяулыклар һ.б.).Чакыр иптәшләреңне.

**Алсу (оныгы):** Әбекәем, без бик тыныч кына утырырбыз.

*Онык дуслары белән булган төркемгә аудио җибәрә:*

***<u>Фонда аудио бара</u>***

Башкаларга сиздермәгез,
Иртәгә безгә килегез, кызлар,
Аулак өй була бездә.
Йолаларны белеп калыйк,
Гөлсем әбием өйрәткәндә.
Көтәм сезне, бик күңелле булачак.

*Икенче көнне кич җиткәч, Алсуларның өенә яшь кызлар җыела. Кызларның җыелып, Гөлсем әбиләргә кереп баруларын бер төркем егет карап кала.*

***<u>Алсу башкаруында “Аулак өй” җыры (З. Минхаҗева сүз. В. Ахметшин көе)</u>***

**Кызлар** *(әби белән кул бирешеп исәнләшәләр)***:** Әссәламәгаләйкүм, Гөлсем әби. Нихәлләрдә яшәп ятасың?

**Гөлсем әби:** Аллага шөкер, балалар. Үзегез нихәл? Әйдәгез, керегез.

**Кызлар:** Әйбәт, Гөлсем әби. Рәхмәт.

**Гөлсем әби:** “Хәтерләүдән курыкмагыз сез!
Үткәнегезне онытмагыз сез.
Белегез сез ерак бабайларның,
Ничек итеп көн иткәнен...
Ни иккәнен, ни чиккәнен,
Нинди җырлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

*Әби сандыгыннан чиккән сөлгеләрен ала. Кызларга сөйли.*

**Гөлсем әби:** Аулак өй, гадәттә, көз һәм кыш айларында үткәрелгән, өлкәннәр өйдә юк чакта кызларга үзара аралашырга, күңел ачарга мөмкин булган.

Аулак өйгә бизәнеп-ясанып, кул эшләрен алып, караңгы төшкәнче үк җыелалар, ләкин бәйләү, чигү кызлар өчен сылтау гына була, аулак өйдә авыл яңалыклары турында сөйләшү, уртак чәй табыны – аулак аш оештыру, күңел ачу – җыр, бию, төрле уеннар чиратлашып

бара. Утырма төн уртасына кадәр дәвам итә. Якын-тирәдә яшәүче кызлар өйләренә кайтып китә, кайберләре исә кунып та кала.

*Әби сөйләгән вакытта экранда презентация аулак өйләрдән фотолар күрсәтелеп барыла.*

Кызлар, без яшь вакытта менә шундый сөлгеләр чигә идек. Аларны чиккәндә “Сөлге чигәм” җырын җырлый идек.

**Кызлар:** Гөлсем әби, безгә дә җырлап күрсәт әле шул җырны?

***<u>Гөлсем әби башкаруында “Сөлге чигәм” җыры</u>***

*(Фасил Әхмәтов көе, Хәлим Җәләлов сүзләре)*

*(Урамда егетләрнең **<u>“Эх, сез матур кызлар” җыры</u>** ишетелә. Бераздан тәрәзәгә шакыйлар, сызгыралар)*

**Кызлар:** Егетләр, килде түгелме? Кертәбезме?

**Егетләр** *(кычкыралар)*: Кызлар, аулак өйгә безне дә кертегез әле?

**Кызлар:** Егетләр, сезгә кем кирәк?

**Егетләр:** Кара кашлы кыз кирәк. Кызлар, кертегез инде.

**Кызлар:** Ач булсагыз, ашап килегез, бер кочак акча алып килегез!

**Егетләр:** Акча бездә бер букча.

**Кызлар:** Ишек бавы бер алтын,

Без кызлар мең алтын!

**Егетләр:** Кызлар, кертегез инде.

**Кызлар:** Ярый инде, керегез!

*(Егетләр керәләр)*

**Егетләр:** Исәнме, Гөлсем әби *(кул биреп исәнләшәләр)*, нихәл кызлар?

**Гөлсем әби:** Шөкер, малайлар.

**Кызлар:** Сезне күргәч бетте хәл. *(көләләр)*

**Гөлсем әби:** Без аулак өй вакытында кызлар-егетләр белән кара-каршы такмаклар әйтешә идек.

***<u>Кызлар-егетләр кара-каршы такмаклар әйтешәләр “Сафия кара әле” көенә</u>***

***1) Кызлар:***

Әнә килә автомобиль -

Төягәннәр калайлар.

Безнең авыл малайлары

Туксан яшьлек бабайлар.

*(Кызлар малайларга каршы 2шәр тапкыр тыпырдап, кулга-кул яки алъяпкычларын тотып киләләр)*

***2) Малайлар:***

Әнә килә автомобиль -

Төягәннәр капчыклар.

Безнең авылның кызлары

Сиксән яшьлек карчыклар.

*(Егетләр кызларга каршы 2шәр тапкыр тыпырдап, кулларын бер-берсенең иңнәренә куеп киләләр)*

***3) Барысы бергә:***

Тыпыр, тыпыр, тыпырдашып

Бергә басаек әле.

Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,

Күңел ачаек әле.

**Гөлсем әби:** И, яшьләр бик булдырасыз. Афәрин! Аулак өйгә килгәч, без төрле уеннар да уйный идек әле. Мәсәлән, “Капкалы”, “Йөзек салыш”, “Чуда үрдәк, чума каз” һ.б.

**Айгөл:** Әйдәгез, **“Капкалы уен”ын** уйныйбыз. Гөлсем әби, кагыйдәсен аңлат әле?

**Гөлсем әби:** Бер кыз белән егет кулларын өскә күтәреп басалар, калганнар парлашып басалар, капкадан чыга башлыйлар. Капкачылар 1 парны тотып калалар. Җәза бирәләр.

Яңа утырткан капканың

Баганасы бик шома.

Капка эләктереп калмасын

Ычкынырга чамала.

***<u>Уен барышында “Тала-тала” көе уйный.</u>***

**Диләрә:** Марат белән Дилбәрне нишләтәбез?

**Барысы:** Дилбәрне җырлатабыз, Марат мәзәк сөйләсен.

***Дилбәр башкаруында җыр: “Су буенда учак яна”***

*Зөһрә Шәрифуллина репертуарыннан, Зөфәр Хәйретдинов көе,*

*Наил Касыймов сүзләре*

**Марат:** Мин мәзәк сөйләмим, табышмак әйтәм.

Сырлы, сырлы, сырлы ул,
Безнең белән җырлый ул,
Биетә дә, җырлата дә,
Күңелле ул, моңлы ул.
Я, нәрсә ул, әйтеп карагыз?

**Марат:** Дөрес, гармун. Илназ гармунда оста уйный, я әле, бер өздереп уйнап җибәр әле.

***<u>Илназ гармунда “Бөрлегән” көен уйный. Калганнар парлап әйләнәләр.</u>***

*Уен дәвам итә.*

**Барысы:** Инсаф белән Азалияне нишләтәбез? Биетәбез.

***<u>Инсаф белән Азалия башкаруында “Татар халык” биюе.</u>***

**Гөлшат:** Бу уен бик күңелле булды. Гөлсем әби, **“Чуда үрдәк, чума каз” уены**н да уйныйк әле.

**Гөлсем әби:** Әйдәгез! Сезне карап утырганда үземне яшьлегемә кайткан сыман хис итәм.

Сандугачлар, былбыллар,
Тургайлар парлы була.
Кем уенда парсыз кала,
Шундук җәзасын ала.

*Уен барышында “Әпипә” көе уйный.*

**Алсу (оныгы):** Рәхмәт, әбием, сиңа,
Шушы матур кич өчен.
“Аулак өй” белән
Таныштырганың өчен.

**Әмир:** Гөлсем әби, чыннан да, бик зур рәхмәт сиңа. Безне аулак өй, аның уеннары җыр-биюләре белән таныштырганың өчен. Монда булган бөтен кызлар-егетләр исеменнән сиңа озын гомер, тыныч картлык телибез.Кызлар, егетләр! Бик күңелле утырдык! Әйдәгез кайтыйк инде!

**Барысы:** Әй, кайтасы килми бит әле!

**Зилә:** Кайтыйк инде, әниләр өйдә көтә.

**Барысы:** Ярар! Әйдәгез!

**Гөлсем әби:** Үзегезгә рәхмәт, балалар! Бигрәкләр дә күңелле булды. Яшь чаклар искә төште. Болай булгач, минем күңелем тыныч. Безнең гореф-гадәтләребез югалмый, аларны дәвам иттерүче сез бар. Менә шулай бәхетле булып, кайгы-хәсрәтсез, тыныч, мул тормышта яшәргә язсын сезгә. Һәрберегезгә дә исән-имин, сау-сәламәт, озын гомерле булып, үз тиң ярларыгызны табып, бәхетле гомерләрдә яшәргә насыйп булсын!

**Камил:** Милләтемнең гасырлардан килгән
Истәлекле йолалары бар.
Күркәм гадәтләрне яшәтүче,
Туган телем - татар теле бар.
**Илһам:** Чал тарихлы горур кешеләр без
Тынмас моң бар безнең каннарда.
Ата-бабам мирас иткән сукмак
Дәвам итәр юлын без барда.
**Камилә:** Милләтебезне саклыйк без
Йолалалрны онытмыйк.
Киләсе буыннарга да
Өйрәтик без, таратыйк.

*<u>Барлык катнашучылар Айдар Фәйзрахманов репертуарыннан</u>*

*<u>**“Аулак өй”** җырын башкаралар</u>*

*Луиза Батыр-Болгари көе, Гарифҗан Мөхәммәтшин сүзләре*

# БӘБИ АЛЫП КАЙТУ ЙОЛАСЫ

***Зиннәтуллина Зилә Хәйдәр кызы.***
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе*
*“Шеңшеңәр төп гомуми белем мәктәбе”*

Татар халкының матур йоласы бәби каршы алу, 8 нче март халык – ара хатын ызлар көненә карата бәйрәм кичәсе.

Җиһанда яз!.

Яз белән әйтерсең, барлык тирәлек, яңадан яңара, табигать озакка талган йокысыннан, күкерәк тутырып сулыш алып күзен ача. Язгы табигать әйтерсең яңа туган сабый! Кар астыннан җир күренер-күренмәс борын төрткән яңа үлән, яңа чәчәк, яңа уҗым, яңа бөре... бар табигать әйтерсең яңадан туа, яңадан ярала. Яз җиһанга үзенең иң матур бәйрәме хатын-кызлар бйрәме белән килә. Хатын-кызның матурлыгы, гүзәллеге, алиһалеге дә, нәкъ менә, язның кояш нурларыннан, тагын да балкый, нәфисләнә, уяна, әйтерсең кар астыннан кояшка тартылган умырзая, язгы ләлә чәчәк ата. Әйтерсең лә хатын-кыз үзенең камиллеге белән язны , тирә-якны тагын да матурлый төшә. Шул ук вакытта, һәр хатын-кыз, күңеле белән яздан нидер көтә, нидер өмет итә.

Хөрмәтле хатын-кызлар әбиләр, әниләр, апалар, кызлар, сезне барыгызны да шушы әле генә үтеп киткән гүзәл бәйрәм белән тәбриклибез! Сезгә, яз ничек ашкынулы дәртле - шундый ук дәртле мәхәббәт, яз сулары ничек ярларына сыеша алмыйча ташый - шундый ташып торган үлчәмсез бәхет, язгы кояш үзенең җылысы белән барлык табигатьне уятырлык көчле - гаиләләрегезнең дә җылысы көчле, шул җылылыкны саклаучы ир-егетләрегез һәр вакыт янәшә булып, тигез канатта, гомерләрегез озын-озак, сәламәтлектә яшәргә насыйп итсен дип теләп калабыз!

Шушы бәйрәм көнегезне тагын да матурлап, нур өстәп балалар белән сезгә үзебезнең бәләкәй генә бәйрәм күчтәнәчебезне бүләк итәбез.

Бәйрәм белән!

**(Театральләнгән күренеш башлана)**

**(Сәхнәгә сөйләшә-сөйләшә 2 хатын чыгалар, (тәрбиячеләр))**

-Гөлүсә ,бүген юлда 2 сабый сөйләшкәнен тыңлап тордым

-Я,я

-Кем буласың үскәч?-диде берсе - иптәшенә төбәп күзләрен.

-Кем булам ди,кем?

-Әни булам диеп җавап бирде.Үзе курчагын кысып кочаклаган. Яннарына барып кочагыма алып бер туйганчы сөйдем үзләрен.

-Зилә, ә менә минем онык: Мин үскәч әби булам әбием" ди. Әби диеп дәшкәннәрен бик өнәп бетерми идем. Оныгым шулай дигәч, әй күңел булды да соң, эрепләр дә киттем инде менә.

-Әнә үзләре килә.

-Әйдә качып кына күзәтик әле үзләрен(сәхнә кырыена чыгалар).

**(Бишек җыры ишетелә).**

Сәхнәгә коляска тартып 2 кыз чыга, коляскада курчаклар.

(**Җыр бетүгә бала елаган тавыш ишетелә**.)

-Уяндыңмыни нәни кызым? Әй минем матур кызым. Хәзер әниең мәми бирер үзеңә.(Сөт эчертә) Тыңласаң сүземне-орышмам үзеңне.

-(2нче бала курчакны кулына ала).Минем улым да торган икән. Зу-ур улым минем. Каяле носкилары төшеп беткән бит аның, кидертим әле.(кидертә)

-Карале Алисә,улыңның битләре кызарган түгелме соң? Әллә температурасы бармы?

-Чирләп киттеңме улым? Каяле(маңгаен тота)Бар икән шул. Хәзер мин сиңа су эчертермен. Аннары Гөлзада апаеңа керербез, яме улым.

**Миләүшә:** (курчакның памперсын тотып карый) У-у, пес итеп куйган. (Мәрьямнең курчагына күрсәтеп) Синеке дә булдырган түгелме соң?

-Әйе шул, әйдә алыштырыйк.

**Мәдинә:** Кызлар минем Алсуым да уянды. Әйдәгез кайтабыз**.**

**(Бишек җыры астында кереп китәләр)**

**Сәхнәгә яңадан 2хатын чыгалар.**

-Карале кызның кырыгыннан диләр,күр әле үзләрен.Әни булып булдырып та уйныйлар.

-Кыз баланы тормыш көтү гыйлеменә сабый чактан башлау фарыз дигәннәр шул.

-Әйе,чөнки кыз бала беркайчан да үзе өчен генә яшәми . Аның ана буласы, бала табасы, улларын-кызларын тәрбия кыласы бар.

-Кызларыбыз нәсел дәвам итүчеләр булуларын онытмасыннар иде.Үз ояларын булдырып, ана булу бәхетенә ирешсеннәр иде.

-Амин,авызыңа бал да май.(Чыгып китәләр.)

**"Балам" җыры.(2 тәрбияче җырлый)**

Шушы җырга инценировка башкарыла, сәхнәгә балалар бию белән чыгалар.

Башта 3 кыз коляскалар белән чыга.

Аннан 3 малай, 3 кыз җитәкләшеп чыга.Бию башкарыла.

Көй ахырында иң кечкенә кыз туп белән уртага чыгып баса . көй бетүгә сәхнәдән чыгып китәләр.

Хәзер бәби алып кайту күренеше:

3 бала керә. (Кулларында шалтыравыклар)

**Гүзәл:** Бәбәй кайтты, бәбәй кайтты!

**Азалия:** Җиңел аягың белән нәни кеше!

**Азалия:** Күршеләргә шатлык-бәхет кайтты!

**Гөлүсә (тәрбияче):** Һай рәхмәт яугырлары, кая соң әле үзләре?

**Илнур (бер баланың әтисе):** Әни, менә без кайттык! (кулында бала)

**Килен (бер баланың әнисе):** Әнкәй исән тордыңмы, менә без кайтып та җиттек! (кулында чәчәк)

**Гөлүсә (тәрбияче):** Исәнмесез балалар, исән-сау кайттыгызмы, төкле аягың, куанычың белән сабыем! Барыгыз әле килен, улым сөенеч алган балаларга бәби күчтәнәче бирегез әле.

**Илнур, килен:** Әйдәгез-әйдә дип чыгып китәләр.

Әби бала белән кала (бәбәй елаган тавыш)

**Гөлүсә (тәрбияче):** Сөбханалла-машалла, бәхетең-тәуфыйгың, киң ризыклар белән балакай! Изге сәгатләрдә раббем! Рәхмәтләреңне киң кыл, ата-анаңа туганнарыңа, күршеләргә, авылдашларга шәфкатле, мәрхәмәтле бала бул, кара әле син моны йокламыйча уйнап ята, яле балам күзеңне йом, ә әбкәң сиңа бишек җырын җырлар, беләсеңме миңа аны әнкәм көйләде, ә аңа әнкәсе. Син дә балам үз балаңа бишек җырын көйләп йоклатырсың. Бишек җырын җырлый белмәгән кыз нинди ана була инде.

**Бишек җыры җырлана :**

Йокла кызым, йом күзең,

Йом –йом күзең, йолдызым.

Кичен йокың кала да

Елап үтә көндезен. (чыгып китә)

А.б керә.Эх бар иде безнең шушындый чаклар, беренче тапкыр ана булу ләззәтен татыган мизгелләр. Мин- ана , минем балам бар, рәхмәт яусын аллахыма... Миннән соң да минем каным аңарда булачак. Минем балам минем күкрәк сөтемне имгәндә, миннән дә бәхетле кем бар дөньяда.! Эх әле сез аны тудырган мизгелне белсәгез...

“ӘНИЛӘР ҺӘМ БӘБИЛӘР” КӨЙ (театрдан өзек)

**Алтынчәч- Фирүзә:** Эх нинди чибәр сез Гөлфинә апа!

**Гөлфинә-Зилә:** Нинди чибәр булыйм мин?! Хатын-кызның чибәрлеге йөзендә түгел, айналаем, хәйләсендә. Мин чибәр дип көзгегә карап тор, чибәр икәнлегеңә ышансаң, башкалар да ышана, үзең ышанмагач, башкалар ничек ышансын, мин менә авызымны бәләкәй итеп күрсәтер өчен бөреп йөрмим, күзләремне акайтып, авызны җырып, елмаеп җибәрәм, Зарифуллам авызыма кереп китәрдәй булып, сокланып карап тора.

**Алтынчәч-Фирүзә**: Ай-һай хәйләкәр дә инде үзегез Гөлфинә апа!

**ФИРДИЯ:** Әйе, Гөлфинә кызым дөрес сөйлисең, ирләргә хәйлә, җылы сүз һәм тәмле ашау кирәк. Ирләр алар хайван терлеге белән бер, вакытында ашатып, эчертеп, тамак астын кашып торсаң, артыңнан ияреп йөри. Менә сыерны гына ал син, тпри-тпри-тпри сыйпап, алдына печән салсаң, күзләрен мөлдерәтеп сиңа карап тора, эт булып, эттә ашатмыйча, пшул дип кусаң, чабуыңнан тартырга күп сорамый., әнкәй мәрхүмә әйтмешли, этне сөяк биреп кенә җиңәләр.

Аңламассың, хәзерге кайсыбер замана кызларын. Иреккә чыкканнар, башбирмәс, каты куллыга әйләнә баралар түгелме? Әй, кызлар, тормышта бит бер-береңне аңлый, хөрмәтли һәм кичерә белергә өйрәнергә кирәк. Шул вакытта гына бәхет киләчәк. Менә мин үземнең картым белән күпме гомер кичердем, ә ул бары бер мизгел... бары чәчләргә чал кергән, йөзләрне сырлар бизәгән.

**Бабай (бер баланың этисе):** Кара әле карчык, кая китеп югалдың, кил әле яннарыма, әй картайдык инде, карчык картайдык, очкан кошлар кебек балалар да таралып бетте, аларның да үз тормышлары, үз мәшәкатләре. Оныклар бик сагындыра, баланың баласы балдан татлы дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр.

**Әби:** Әйе шул, картым. (Залга мөрәҗәгат итеп) Әби белән бабайга тормыштан бик аз кирәк. Игътибарлы һәм ихтирамлы булыйк. Аларга кулларында таянырлык терәк –таяк, ә сездән балалар әз генә кадер-хөрмәт кирәк.

**Ипекәй (бала):** Менә кайда икәнсез, әби-бабай, мин бит әбине бәйрәм белән котларга дип эзләп йөрим. Котлый. Ә сез нишләп бик боек әле?

**Бабай:** Оныкны бик сагындык, кош теле кадәр генә хат та язган идек.

**Ипекәй:** Хәзер барып алам мин аны,

**Әби-бабай:** Әй рәхмәт яусын үзеңә, исән-сау гына йөр.

(Яз турында көй яңгырый)

А .б. Яз килә! Язның беренче бәйрәме килә. Әнә нәни карлыгачлар яз килүен хәбәр итә.Карлыгач киемнәреннән балалар сәхнәгә менә. Бәйрәм бүген дигән җыр яңгырый.

Кадерле әниләр!

Кояш нурын сибә Сезнең өчен,

Тамчылар тама Сезнең өчен,

Кошлар сайрый Сезнең өчен,

Безнең җырларыбыз Сезнең өчен.

**Җыр Мин сине яратам әни**

А.б. Тормышыгыз шатлык белән тулсын, якын кешеләрегез кадерегезне белеп яшәсен. Безнең кыштан арыган йөрәкләребезгә язның беренче җылы нуры булып керүче бүгенге бәйрәм сәламәтлек, бәхет һәм бәрәкәт китерсен!

Язгы гөрләвекләр сезнең тормышыгызга җылылык, тәнегезгә саулык-сәламәтлек, эшегездә уңышлар, күңел тынычлыгы, ә иң мөһиме – бәхет алып килсен!

Язгы бөреләр белән бергә күңелләрегездә матурлык, изгелек, кешелеклелек, сафлык чәчәк атсын! Тирә ягыбыз чиста пакъ, күңелләр саф.Кошлар кайтты, алар һәрберсе бала чыгара. Безнең дә һәрберебез җылы оялы, балалы, дәвамлы булсын, уңышлар Сезгә!

Язгы алсу таңнар сезне иркәләп уятсын, зур эшләргә рухландырсын!

# Әбиемнең серле сандыгы

***Егорова Гөлназ Айрат кызы***

*Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*
*«Мамадыш шәһәре 11 нче «Ландыш» балалар бакчасы»*

Зурлар төркеме балалары өчен күңел ачу кичәсе

**Максат:** татар халкының көнкүреш һәм гореф – гадәтләре, йолалары, уеннары белән таныштыру.

**Бурычлар:**

1. Буыннан-буынга истәлек булып калган әйберләр белән таныштыру, исемнәрен (бала итәкле күлмәк, алъяпкыч, камзул, түбәтәй, калфак) хәтердә калдыру.
2. Шигырь һәм уеннар аша балаларны татар халкының үткәне белән таныштыруны дәвам итү.
3. Балаларда татар милли киемнәренә кызыксыну, татар халкына һәм фольклорына мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

**Алдан эшләнгән эшләр:** Милли киемнәр һәм андагы татар бизәкләре белән танышу; шигырьләр, уеннар, биюләр, мәкальләр өйрәнү.

**Җиһазлау:** татар өе күренешендә бизәлгән зал, сандык, калфак, түбәтәй, күлмәк, алъяпкыч, йорт бизәү әйберләре, каба, өстәлдә самовар, татар халык ашлары.

**Күңел ачу барышы**

**Тәрбияче:** Балалар, бүген без сезнең белән тарихи, истәлекле әйберләр тупланган, матур өйгә кунакка килдек. Бу - әби-бабайларыбызның өе. Үзе нурлы, узе матур. Ә авылларда өйнең түрендә һәрчак хуҗа булып сандык утырган.

*Әби керә.*

**Әби:** Нинди шау-шу дисәм, балаларым килгән икән. Исәнмесез, оныкларым *(исәнләшәләр).*

**Адель:** Хәлләрегез ничек, әбекәй?

**Әби:** Аллага шөкер, балакайларым. Менә шундый тәмле телле булыгыз. Тәмле телле булсагыз, үзегезне бар кеше яратыр.

**Балалар:** *(гаҗәпләнеп)* Ничек инде тәмле телле? Сүзләр күп инде алар, бик тәмлесе нинди икән ул, әбием? Ул бит конфет та, пряник та түгел. Ашап та карап булмый.

**Әби:** Иң тәмле сүз ул балалар, туган тел!

Туган тел – иң татлы тел,

Туган тел – иң тәмле тел.

Тәмле дип телең йотма –

Туган телне онытма!

**Адель:** Мин дә беләм тәмле сүзләрне. Миңа да дәү әнием өйрәтте.

- рәхмәт
- исәнмесез
- сау бул
- хәерле көн

**Әби:** Менә, менә – үзегездә беләсез бит. Бик яхшы. Ярый, балалар сез уйнагыз, ә минем эшләрем бар. Сезнең кебек вакытта, без дә әллә нинди кызыклы уеннар уйный идек.

**Балалар:** Әбекәй, үзегез уйнаган берәр уенны безгә дә өйрәт әле.

**Әби:** И балалар, үзем генә өйрәтә алмам шул. Кая күршекәемне чакырыйм әле. Хәнифә ахирәт, кер әле, кер тизрәк.

*Ерактан тавыш ишетелә*

**Хәнифә әби:** Кунагым бар иде шуууул

**Әби:** Ярар, ярар! Кунагың белән кер. Оныгыңны алып кер.

*Әби белән онык керәләр*

**Хәнифә әби:** Исәнмесез! Исән-сау гына торасызмы?

**Әби:** И ахирәтләр, балалар берәр уен өйрәтүне сорыйлар. Берәрне искә төшереп өйрәтик микән?

**Хәнифә әби:** Безнең уеннар ошар микән аларга? Хәзер заманалар үзгәрде шул.

**Әби:** Җырны магнитафоннан тыңлыйлар, уенарны телефон, компьютердан уйныйлар. Кул эшләрен онытып баралар шул...

**Хәнифә әби:** Үзгәрде заманалар, үзгәрде...

**Әби:** Әйдә соң кичке уенда уйный торган “Чума үрдәк, чума казны” өйрәтик

***Уен “Чума үрдәк, чума каз”***

**Хәнифә әби:** Бик күңелле булып китте әле. Әллә соң табышмаклар да әйтешәбезме?

1. Үлчәүләрдә үлчәнми
   Базарларда сатылмый (Акыл)
2. Акыллы чәчә барар,
   Акылсыз җыя барыр (Белем)
3. Ачыдан ачырак, татлыдан татлырак,
   Усалдан усалрак, дөрестән, дөресрәк
   Нәрсә бар дөньяда?

4. Әйтермен - миннән китәр,

   Тыңламасаң – синнән китәр. (Сүз)

**Әби:** Менә бит, никадәр күп табышмакларга җавап беләсез сез.

**Тәрбияче:** Балалар, менә бу сандыкка игътибар итегез әле. Кызык, нәрсәләр бар икән аның эчендә? Әбекәй, әйдә сандыкны ачып карыйк!

**Әби:** Шулай дисезме, ягез, ачыйк алай булгач. Тезелешеп утырыгыз яныма.

*(салмак кына көй яңгырый, әби сандыкны ача, әйберләрен күрсәтә)*

- Карагыз әле, нинди матур сөлге. Бу сөлгене яшь чакта үзем чиктем. Бүген матур итеп чигелгән затлы сөлгеләр әбиләрнең сандыгында гына саклана. Кайсы гына егетнең иңенә ятмаган да, нинди генә батырларга бүләк булмаган бу сөлге!

- Ә монысы өстәл ашъяулыгы. Күрәсезме нинди матур итеп канәфер, лалә чәчәкләре белән чигеп эшләнгән.

- Менә монысы алъяпкыч. Татар кызларының алъяпкычлары канатлы булырга тиеш. Чиккән алъяпкычлар зифа буйлы кызларга бигрәк тә килешеп торган. Киләчәктә сез дә шулай милли алъяпкычлар ябып йөрерсез әле.

- Бала итәкле күлмәк тә татар кызларының милли киеме. Итәкләре никадәр күп булса, шулкадәр матуррак саналган.

**Әби:** Менә бу нәрсә икән, кайсыгыз белә?

**Балалар:** Түбәтәй.

**Әби:** Бик дөрес. Түбәтәй чигә һәм тегә белгән кеше алтын куллы оста санала иде. Кара бәрхеткә ука яисә сәйлән чигелгән түбәтәйләрне бәйрәмнәрдә генә кияләр.

*Малайга түбәтәйне киертә.*

**Айсылу:** Килешеп тора түбәтәй,

Аның күркәм йөзенә

Нинди матур татар улы,

Күз тимәсен үзеңә.

**Тәрбияче:** Әйдәгез әле, балалар, бераз ял итеп «Түбәтәй» уенын уйнап алыйк.

***Уен «Түбәтәй»***

**Әби:** Ә бу нәрсә, балалар?

**Балалар:** Калфак.

**Әби:** Калфак чигү һәм тегү бигрәк тә зур осталык таләп иткән. Ул ак сәйлән белән күпертеп эшләнелә. Мондый калфакны бай хатыннар гына кия торган булганнар.

**Әби:** Кая әле, килешә микән үзеңә. *(Бер кызга кигертә).*

**Арина:** Дәү әнием энҗе калфак

Бүләк итте үземә.

Энҗе калфак, үзе ап-ак,

Бик килешә йөземә.

*(Сандык тартмасыннан чиккән кулъяулыкка төрелгән йөзек ала.)*

**Әби:**Ә менә монсы чиккән кулъяулык. Карагыз әле, никадәр хезмәт, күңел җылысы салынган бу бизәкләргә. Бу йөзек - әбиемнән калган истәлек. Мин аны бик кадерләп саклыйм. Аулак өйгә җыелгач, шушы йөзек белән «Йөзек салыш» уйнадык.

**Кыз**. Әбекәй, безгә дә өйрәт әле шушы уенны.

**Әби.** Әйдәгез, барыгыз да тезелешеп утырыгыз, учларыгызны тотыгыз. Мин сезгә йөзек салам. Йөзек кемдә икәнне сизсәгез, аңа берәр «җәза» бирәбез. *(Йөзек сала.)* Йөзек кемдә, йөгереп (сикереп) чык.

**Әби**: Кызым, мин сиңа мәкалнең башын әйтәм, син азагын әйт. Белересең микән?

- Теле барның – иле бар.
- Бер рәхмәт, мең бәләдән коткарыр.
- Туган илем – туган телем.
- Тырышкан - табар, ташка кадак кагар.
- Эш сөйгәнне ил сөяр.
- Калган эшкә кар ява.

**Хәнифә әби:** Булдырдыгыз балалар, мәкалләрне беләсез икән. Ә менә минем табышмакка җавап таба аларсыз микән?

Башы – мунчала, койрыгы – сүс. (*Җавабын таба алмыйлар*). И, балалар, сез таба алмассыз шул аның җавабын. (*Сандыктан чабата алып күрсәтә*). Чабата ул. Элек әтиләр чабата үреп бирәләр иде. Төшеп калмасын өчен, артына киндерә, сүс бау да тагалар. Ә яз, көз көннәрендә, пычрак кермәсен өчен табанына шакмак кагып, күтәртмә ясый торганнар иде.

***Бию “Чабата”***

**Хәнифә әби:** Менә бит ничек күңелле утырабыз. Ярый әле кергәнбез, ахирәткәем!

**Кыз:** И әбиләр, әбикәйләр! Сез бездән дә остарак икәнсез бит.

**Әби:** И онытып торам икән бит. “Кунак йөзе – тәмле чәй” диләрме әле.  Мин бит бүген иртүк коймаклар пешергән идем. Әйдәгез әле, табын янына чәй эчәргә рәхим итегез.

***Беренче буразна  бәйрәме***

***Бәйрәмова Тәнзилә Харис кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль*
*районы "Арча 2 нче балалар бакчасы"*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

**Максат:** Балаларны халкыбызның гореф – гадәтләре белән таныштыру. **Бурычлар**: уеннар,җырлар, шигырьләр аша балаларның бөртекле культуралар турындагы белемнәрен ныгыту,игенче хезмәтен хөрмәтләү,мактау.Аның кешеләргә иң зур шатлык китерә торган хезмәт икәнен зиһенгә сеңдерү. Зурлар хезмәтен хөрмәт итү.

**Алдан эшләнәсе эшләр**: техника паркына экскурсия, тракторлар, чәчкечләр, тырмалар белән танышу; *“Чайкала иген кырлары ”(Г.Латыйпов сүзләре, И .Шәмсетдинов көе)* җырын өйрәнү; мәкальләр ятлау, эчтәлекле рәсемнәр карау.

**Катнашкан балалар яше**: 6-7 яшь

**Шөгель барышы:**

*“Чайкала иген кырлары” җырына  балалар җырлап керәләр.*

1.Чайкала иген кырлары,
Уяна таң нурлары;
Киңлекләргә алып бара
Безнең басу юллары.,
Куш.: Игенченең уңганлыгы,
Игенченең хезмәт яме,
Игенченең тырышлыгы
Кырларыннан күренә.

*Балалар ярым түгәрәккә басалар.*

**Бабай**: *(бабай кукәй күтәреп)* Килеп җиттегезме , балалар, әйдәгез рәхим итегез!

**Тәнзилә Харисовна:** Яз җиткәч, бозлар киткәч,кырлар кардан арынгач кыр эшләре башлана. Әтиләр, бабайлар, абыйлар тракторларга зур-зур чәчкечләр тагып чәчүгә чыгалар. Игенче хезмәте- иң беренче һәм иң мактаулы һөнәрләрнең берсе.

**Ләйсән Фиргатовна:** Иген игү борын-борыннан иң изге, иң дәрәҗәле эш саналган. Бабаларыбыз чәчкән бөртекләрнең уңышы мул булсын дип теләкләр теләп буразнага пешкән йомыркалар сипкәннәр. Мин дә сезгә алар кебек теләкләр теләп йомыркалар тәгәрәтергә

тәкъдим итәм (уңышлар мул булсын(Айназ-Айгол), техника эшләп торсын (Зарина-Самат), яңгырлар яусын(Ислам-Ралина), кояш елмайсын (Наргиза-Талгат)

**Бабай:** Бик дөрес, балалар, вакытында җил дә иссен,яңгыры да яусын дип теләкләр дә телик. *(чыгып китә)*

**Ләйсән Фиргатовна:** Әйдәгез әле,балалар ,чәчкән орлыклар уңышлы тишелеп чыксын өчен яңгырны чакырыйк.

Яңгыр яу,яу,яу

Бакчаларда алмагач

Корый яңгыр яумагач.

Игеннәр дә күп булсын,

Сыерлар да тук булсын,

Безгә катык,сөт булсын.

Яңгыр яу,яу,яу

(*"Болыт" балаларны куып җитеп ,әкрен генә кытыклый).*

**Ләйсән Фиргатовна**:Балалар, орлыклар әйбәт кенә тишелсен һәм үссен өчен тагын кояш нурларының җылысы да кирәк. Карагыз әле, кояш безне ишетте,якты нурларын сипте. Кошлар сайрый башлады *(кошлар тавышы яңгырый)*

**Тәнзилә Харисовна:** Бүген бит бәйрәм.Әйдәгез әле, балалар, сезнең белән бик матур татар халык уенын **"Миңлебай"** ны уйнап алыйк әле. Уен барышын Ралинә сөйләп кит әле безгә.

**Бала:** Бер бала уртага чыга. Башка балалар тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, сүзләр әйтеп әйләнәләр.

*Без йөрибез әйләнеп,*

*Син уртада Миңлебай.*

*Син нишлисең, ни кыласың,*

*Без кыланырбыз шулай.*

- Түгәрәк ясаган балалар туктап калалар, уртадагы бала, нинди дә булса, хәрәкәт күрсәтә:

-*Бер болай, бер болай, я кыланыгыз шулай.*

-*Бер болай, бер болай, моны эшләү бик уңай.* Бала артыннан хәрәкәтләр кабатлана. Кабатлый алмаган кеше уртага чыгып Миңлебай була.

**Тәнзилә Харисовна:** Балалар, чәчүгә кырлар әзер. Вакытны бушка уздырмыча чәчү эшләрен башларга кирәк. Икмәкне дә утыртырга вакыт. Икмәк каян килә икән? Әйдәгез әле, уен уйнап алыйк әле. Ике командага бүленәбез. Беренче команданың исеме арыш бөртеге, икенче команданың исеме бодай бортеге. Икмәк үстерүченең эшен күрсәткән эчтәлекле рәсемнәрне тәртип белән тезеп чыгарга һәм сөйләргә кирәк булачак.

**Ралинә:** Яз җиткәч карлар эри башлый. Игенчеләр кырга чыгалар**.** Трактор җирне сукалый, тырмалый, чәчә.

**Айгөл:** Өлгергән башакларны комбайннар белән җыеп алалар.

**Талгат:** Ашлыкларны амбарга китерәләр.Анда аларны чистарталар, киптерәләр.

**Ислам**: Тегермәндә ашлыкларны салып тарталар.Аннан соң он барлыкка килә.

**Зәринә:** Әзер оннан камыр басыла. Камырдан татар халык ашлары пешерәләр.

**Тәнзилә Харисовна:** Бик дөрес балалар.Менә нинди зур юллар үтә икән безнең ипекәебез. Табыныбызда ипи булганда гына күңелләребез шат, тамагыбыз тук булыр.

**Тәнзилә Харисовна**: Без бит җир, басу, иген кырлары, табигать турында мәкалләр дә беләбез. Балалар, әйдәгез, искә төшереп үтик эле.

Т.Х: Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың.

Самат: Иртә чәчкән уңар,буразнасы тулар.

Зәринә: Яз сөрсәң,көз урырсың.

Нәргизә: Яз уңмаган- көз уңмас.

Айназ: Язгы көн- ел туйдыра.

Айгол: Язгы хезмәт-көзге хөрмәт.

**Ләйсән Фиргатовна:** Кыр эшләре тамәмлангач соң һәр халык үзенең милли уеннарын үткәрә.Ә сез беләсезме, тиздән татар халкының милли бәйрәме Сабантуй якынлаша.Ә рус милләтенең бик күңелле Каравон бәйрәме бар.Әйдәгез, балалар, без шул бәйрәмгә барыйк әле. *Чыгып китәләр.*

## Карга боткасы бәйрәме

***Бадертдинова Резеда Рәис кызы.***

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы "49-нчы санлы гомуми үстерелешле балалар бакчасы" муниципаль үзидарә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

| | |
|---|---|
| **Үткәрү көне:** | Апрель ахры |
| **Максат:** | Балаларда күңел күтәренкелеге булдыру. |
| **Балаларның яшь төркеме:** | Уртанчылар төркеме |

| | |
|---|---|
| **Бурычлар:** | **Өйрәтү:** Балаларны татар халкының мәҗүси бәйрәмнәре белән таныштыруны дәвам итү. **Үстерү:** Карга боткасы мәҗүси йола-бәйрәме, ырымнары, уеннары,такмазалары аша сөйләм үстерү.<br>**Тәрбияви:** Халкыбызның борынгы йола-бәйрәмнәренә ихтирам тәрбияләү. |
| **Җиһазлар:** | Кошлар рәсемнәре,ботка пешерү өчен казан,балалар санынча кашык-савытлар,татар халык уеннары өчен атрибутлар. |
| **Белем бирү өлкәләре:** | Сөйләм үсеше;<br>Социаль- коммуникатив;<br>Танып-белү үсеше;<br>Сәнгать һәм эстетик зәвык үсеше. |
| **Тәрбияченең эшчәнлеккә әзерләнү буенча алдан эшләнәсе эше:** | Кичәне үткәрү өчен урын әзерләү,уеннар өчен атрибутлар әзерләү. |
| **Балалар белән алдан эшләнәсе эш:** | Алдан шигырьләр,татар халык уеннарын уйнау. |
| **Методик алымнар:** | 1) күрсәтү; 2)сөйләү; 3)уен. |
| **Структура:** | **I.Кереш өлеш**.<br>а) Балалар залга керәләр. Исәнләшү.<br>б)Җыр: “Умырзая”<br>**II. Төп өлеш**.<br>а) Язгы чәчәкләр турында сөйләшү.<br>б)”Карга боткасы” турында аңлату.<br>в) “Тамчы там” җыры.<br>г) “Күгәрчен гөрлидер” җыры.<br>Ботка өчен әйберләр җыю.<br>Д)”Шәл бәйләдем” җыры<br>е)”Болында”уены<br>ж)Уен:”Уң ягымда дустым бар”<br>з) “Наза” уены<br>и) “Яшерәм яулык” уены<br>III. Йомгаклау өлеше.<br>Ботка ашау. |

**Күңел ачу кичәсенең барышы:**

Матур итеп бизәлгән алан. Чишмә тавышы (магнитофон тасмасында). Бер агач түмгәге өстендә, чишмә агышына сокланып Бабай утыра. Балалар керә.

**Балалар:** Әссәламәгаләйкем, бабай!

**Бабай:** Вәгәләйкем әссәлам, балалар!

**1 бала:** Нинди матур алан!

**2 бала:** Нинди серле чишмә тавышы!

**Бабай:** Әйе, балалар, менә кар сулары да, шушы чишмә суларына кушылып, гөрләвек тавышы чыгарып агалар. Әнә тегендә, яз килүен безгә хәбәр итеп, беренче умырзая чәчәкләре баш калкыта.

**Тәрбияче:** Бабакай, без бит бабалар бакчасыннан. Ә умырзая турында бик матур җыр беләбез. Җырлап күрсәтикме?

*Җыр "Умырзая чәчәге"*

**Тылсымчы:** бигрәк матур җыр икән. Умырзая кар астыннан иң беренче баш калкытучы чәчәк шул. Бик матур җырладыгыз. Рәхмәт сезгә балалар.

**Тәрбияче:** Бабакай, сез монда ни эшләп йөрисез соң?

**Тылсымчы:** шушы язның матурлыгына сокланып, табигатькә хәйран калып йөрим әле. Яз җитте бит. Яз! Һәрбер кош, агач, җан ияләре белән исәнләшәсем, аларга хәерле иртә диеп әйтәсем килә.

Таңнар саен хәерле көн телим
Аяз күкләр телим җиремә.
Кояшлы көн телим бар кешегә.
Һәм именлек телим иленә.

Хәерле көн димен һәр бөҗәккә
Хәерле көн телим гөлләргә.
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Һәм сабырлык телим ирләргә.
Юлчыларга хәерле көн телим,
Чәчәкләргә карап елмаям
Җиргә якты җылы нурын сипкән
Кояшыма карап сокланам.

**Тәрбияче:** Күңелләргә үтеп керерлек шигырь сөйләдегез. Без барыбызда табигатьне бик яратабыз. Аның кояшлы көннәренә, чәчәкле җәйләренә, ак карлы кышларына сокланабыз. Ә бүген шушы матур аланга яз бәйрәмен – "Карга боткасы"н билгеләп үтәргә җыелдык. Әйдә, синдә безнең белән бәйрәм ит бабай!

**Бабай:** Бик, рәхмәт, балалар, әйдәгез бергәләп бәйрәм итик. Элекке заманнарда "Карга боткасы" бәйрәмен бөтен авыл халкы бергә җыйналып бәйрәм итә торган булган. Бергәләп утырып, ботка ашаганнар. Ә сез бу бәйрәмнең ничек килеп чыкканчы беләсезме соң?

**1 бала:** Борын-борын заманда кешеләр ни өчен яз булганын белмәгәннәр ди. Алар язны кара каргалар алып килә дип уйлаганнар.

**2 бала:** Шуның өчен карлар эреп, сулар ага башлагач, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар.

**Тәрбияче:** Әйе, “Карга боткасы” – яз бәйрәме ул. Шагыйрьләр яз турында бик матур шигырьләр язганнар. Әйдәгез, шуларны искә төшерик әле.

Кар сулары ага гөрләшеп,
Дулкын-дулкын серләшеп,
Ярларына сыймый ташкындай,
Кар сулары ага гөрләшеп!

Ак күбекләр уйный, сикерә,
Кыш бабайның соңгы кырларын
Алып китеп ерак диңгезгә,
Ак күбекләр җирдә бөтерелә.

Кышның салкын бураннары үтә,
Менә каба җиргә язлар килә,
Таллар бөре ача, кояш көлә
Язгы кошлар җиргә тавыш бирә.

Карыйм да мин сокланам
Бу нинди иртә икән?
Һәр түбәдән су таша
Кая су җитә икән?

***Җыр: “Күгәрчен гөрлидер”***

Вак шарлар кебек тәгәрәп
Ак карга төшә тамчы
Үзенә ясап тагарак
Бозларны тишә тамчы!

Ник көн дә шулай биидер
Туктамый һич тә алар?

Мин белдем, белдем ниндидер
Зур бәйрәм көтә алар!

Тамчылар бии тып та тып
Амчылар сикерәләр
Аларны булмый туктатып
Алар яз китерәләр!

**Тәрбияче:** Ә яңгыр тамчылары язын тагын да ашыктыралар. Карлар тизрәк эри, агачлар яфрак яра, үләннәр яшелләнә, игеннәр дымга туена. Әйдәгез, язгы яңгыр турында җырлап алыйк.

***Җыр "Тамчы там"***

**Тәрбияче:** Балалар, безнең бәйрәмгә тиздән кунаклар килер. Кара каргалар да очып килеп җитәрләр. Ә безнең әле бернәрсәбез дә әзер түгел. Әйдәгез, бәйрәм өчен нәрсәләр кирәклеген искә төшерик.

**Балалар:** Ярма, сөт, күкәй, казылык,ит.

**Тәрбияче:** Шулай, ә без аларны каян алырбыз икән?

**Тылсымчы:** Элек бәйрәм өчен сыйны балалар өй буенча җыеп йөргәннәр. Әйдәгез бездә шулай итик.

Ә мин тиз генә учак ягып җибәрим.

**Тәрбияче:** Ә без киттек, әйберләр җыерга. Әйләнеп өй янына киләбез.

**Балалар бергә:** Өйдәме түтәй?
Бир зинһар күкәй
Бирсәң безгә күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй!

Әби күкәй бирә. Балалар рәхмәт әйтәләр, юлларын дәвам итәләр, икенче өй янына килеп

**Балалар бергә:** Өйдәме түтәй?
Кызганма түтәй
Май кирәк безгә, яярма кирәк,
Карга туена бар да кирәк!

**3 бала:** Шикәр кирәк, тоз кирәк, чыгар, түтәй, тизрәк!

**4 бала:** Ярма! Сөт! Күкәй! Ит!
Казылык та бир әле, түтәй!

Өйдән әби белән бабай чыгылар!

**Әби:** Менә, балалар, бар да бар, май да, сөт тә!

**Бабай:** Күкәй дә, ит тә. Ботка бик тәмле булыр.

(Балалар әби-бабайга рәхмәт әйтәләр)

**5 бала:** Безне сөендергән өчен сезне Ходай сөендерсен. Бабай, әби әйдәгез, сез дә безнең белән карга боткасы ашарга.

**6 бала:** Менә боткага бөтен әйберләрне дә җыеп алып килдек.

***Җыр "Шәл бәйләдем"***

Җырдан соң балалар чәчәк өзәргә үрелә.

**Бала:** Әгәр мин чәчәк өзсәм
Әгәр син чәчәк өзсәң
Әгәр бергә – син һәм мин
Матур чәчәкләр өзсәң
Бушап калыр бу алан
Бетәр шушы матурлык.

**Тылсымчы:** Әйе, балалар, әгәр без барыбыз да шушы матур чәчәкләрне өзсәк, кошларны җәберләсәк, агачларны сындырсак, безнең урманнарның яме бетәр иде.

**Әби:** Мондый тәртипле, уңган балалар күбрәк булсын иде. Әллә бер биеп алабызмы?

***Татар халык уены:"Болында"***

**Тәрбияче:** Ә без хәзер үзебезнең шигырьләрне дәвам итәбез.

**Яз җитте Резедә Валиева**

Җылы җир сирпеп үтте
Агачларны селкетте
- Уяныгыз, уян тизрәк!
Яз җитте!
Әй, яз җитте!

Кояш нурларын сипте
Тәрәз битләрен үпте
- Ачылыгыз, ачыл тизрәк,
Яз җитте
Әй, яз җитте!

Сыерчык сайрап үтте
Һавалар зыңлап китте

- Чыгыгыз, чык, әй балалар

Яз җитте,

Әй, яз җитте!

Яңгыр сибәләп үтте

Кырлар яшәреп китте

Нурга тулды туган җирләр

Яз җитте

Әй, яз җитте!

***Җыр “Уң ягымда дустым бар”***

**Бабай:** Шудый матур халык җырларын җырлагач бик күңелле булып китте бит әле!

**Әби:** Сиңа әйтәм бабай исеңдәме яшь чакта нинди уеннар уйный иде?

**Бабай:** Исемдә, исемдә, алар бит бик күп. Менә без яшь чакта “Наза”уенын яратып уйный идек.

**Тәрбияче:** Бездә беләбез аны! Әйдәгез балалар уйныйбызмы?

Тәрәзәдән карама

Бурекләрең алама

Бар базарга ямауга,

Бурегеңне ямарга

Аннан килерсең безгә

“Аулак өй”дә уйнарга.

***Уен “Наза”***

*Шулчак “Кар-кар” диеп аланга каргалар килеп керә.*

**Бала:** Кар-кар-кар-кар

**Бала:** Язлар җитте балалар

**Бала:** Матур бәйрәм көнендә бар да күңел ачалар!

**Тәрбияче:** Менә безнең көткән кунакларыбыз, яз хәбәрчеләре каргалар килде. Әйдәгез уйнап алабыз!

***Уен:”Кульяулыгым яшел,яшел”***

**Тәрбияче:** Рәхмәт сезгә, кошкайлар, безгә шундый матур яз алып килгәнегез өчен.

**Бабай:** Безнең боткада пешеп җитте. Әйдәгез, боткадан рәхим итегез!

Җырлап ботка ашарга түгәрәккә утыралар.

**Балалар:** Ал да итәек әле

Гөл дә итәек әле

Күңелле итеп бергәләшеп

Ботка ашаек әле.

(Түгәрәккә утыралар, ботка ашыйлар. Ашап бетергәч савытларынәйләндереп куялар, кашык белән кага башлыйлар)

**Тәрбияче:** Безнең шуның белән “Карга боткасы” тәмам.

Яңгырлар вакытында явып
Кояш – вакытында җылытып
Игеннәр уңып
Еллар тыныч булсын!

**Нигез боткасы” йоласы**

***Захарова Раушания Низаметдин кызы***

*Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 321 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджетлы мәктәпкәчә белем учреждениесе*

***Катнашалар:*** Әти, әни, аларның ике улы һәм төпчек кызы, күрше малае.

*(Әти белән әни моңаеп кына сөйләшеп утыралар).*

**Әти:** Әй, әнисе, әнисе... Аллага шөкер балаларыбыз да үсеп җиттеләр инде.

**Әни:** Әйе шул, үсеп җиттеләр...

**Әти:** Тик мине бер уй борчый бит әле.

**Әни:** Әтисе, нинди уй борчый соң сине?

**Әти:** Безнең балаларыбыз да шәһәргә китеп бармаслар микән?

**Әни:** *(Еламсырап)* Әтисе дим, картайган көнебездә ялгыз калырбыз микәнни?

**Әти:** Балалар китсә, туган йорт, туган нигез бетә бит.

**Әни:** Шулай шул...

*(Шул вакыт балалары керәләр).*

**Олы малай:** Әти-әни, сез нигә монда моңаешып утырасыз.

**Уртанчы малай:** Әллә авырыйсызмы?

**Төпчек кыз:** Я берәр әйберегезне югалттыгызмы?

**Әти:** Тынычлыгыбызны югалттык, балалар.

**Олы малай:** Ничек инде тынычлыкны югалтып булсын?

**Әти:** Балалар, менә сез барыгыз да үсеп җиттегез. Хәзер берәм-берәм шәһәргә китү ягын карарсыз инде.

**Әни:** Картайган көнебездә үзебез генә калырбыз микәнни? *(Елый).*

**Әти:** Әй, балалар, балалар, әгәр дә сез – яшьләр барыгыз да шәһәргә китеп барсагыз, авыллар бөтенләй бетәчәк бит. Кем илгә икмәк үстерер, терлек үрчетер? Сугыш вакытында да бит халык туган нигезен үз теләге белән калдырып чыгып китмәде. Теше-тырнагы белән җиргә ябышып ятты. Үзе кычыткан, алабута һәм черек бәрәңге ашап торса торды, әмма илне, фронтны икмәк белән тәэмин итте.

**Әни:** Бик дөрес әйтәсең, этисе.

**Олы малай:** Мин беркая да китәргә җыенмыйм. Авылда калам, фермер булам.

**Уртанчы малай:** Мин дә авылда калам, агроном булам. Кырлар тутырып икмәк үстерәм.

**Төпчек кыз:** Мин дә шәһәргә китәргә җыенмыйм, авылда калам. Укытучы булам, балаларны татарча язарга, укырга, туган телебездә матур итеп сөйләшергә, җырларга һәм милли гореф-гадәтләребезгә өйрәтермен.

**Әни:** Сөбханалла, машалла.

**Әти:** Ай, рәхмәт, балалар, сөендердегез! Болай булгач, олы улым, сине өй салып башка чыгарам. Менә бу буш урынга бүген үк нигез сала башлыйбыз. Әби-бабайлардан калган йола буенча, туганнарны, күршеләрне чакырып өмә ясыйбыз.

**Күрше малай:** *(Йөгереп керә)* Рифат абый, нигез салабыз, өмә ясыйбыз, дисезме? Күрше хакы, Алла хакы, иң беренче булып үзем булышырга керәм.

**Әни:** И-и-и, бигрәкләр дә игелекле бала икәнсең!

**Әти:** Әйдәгез, балалар эшкә тотыныйк. *(Җиңнәрен сызганып, учларына төкерә)* Хәерле сәгатьтә булсын!

**Әни:** Амин! Хәерле сәгатьтә, балакайларым. Ә мин сезгә борынгы йола буенча тәмле нигез боткасы пешереп ашатырмын. *(Ботка пешерә башлый)*

**Төпчек кыз:** Ә мин табын әзерләрмен. *(Өстәлгә ашъяулык яба, самавыр, чынаяклар, татар халык ашларын чыгарып куя)*

*(Әти һәм өч егет "Өмә" көе астында йорт нигезен салалар)*

**Әти:** Булды бу, балалар, нигезне салып та бетердек. Бәхетле, игелекле нигез булсын!

**Әни:** Минем дә боткам пешеп чыкты. Бу нигездә куаныч-шатлыклар шушы боткадагы ярмалар һәм дә йөзем җимешләре санынча булсын!

**Төпчек кыз:** Минем дә табыным әзер, мул ризыклы булсын бу нигез! Кулларыгызны юыгыз да, өстәл янына рәхим итегез.

**Әти:** Эшләр болай баргач, авылыбыз да бетмәс!

**Олы малай:** Нигезебез дә таркалмас!

**Уртанчы малай:** Авылыбыз кырларында игеннәр һәрчак мул булыр!

**Төпчек кыз:** Туган телебез дә онытылмас!

**Әни:** Тик дөньялар тыныч булсын!

**Барысы бергә:** Күкләребез аяз, җирләребез имин булсын!

*(Барысы да өстәл янына нигез боткасы ашарга утыралар)*

**"Миллек бәйләү" йоласы**

***Шарипҗанова Рүзилә Зөфәр кызы.***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының*
*«Гомүми үсеш бирүче төрдәге Кариле балалар бакчасы»*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат**: балаларны "Миллек бәйләү" йоласы белән таныштыру, татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән кызыксынуларын үстерү.

**Белем бирү бурычы**: балаларны "Миллек бәйләү" йоласы белән таныштыру.

**Үстерү бурычы:** бәйләнешле сөйләм телен үстерүгә һәм иҗади сәләтләрен ачарга булышлык итү.

**Тәрбия бурычы:** балаларда милли горурлык, туган телгә мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Алдан үткәрелгән эш:** табышмаклар, мәкальләр, уеннар, җырлар өйрәнү.

**Җиһазлау:** бутафор мич, өстәл, чокырлар, самавыр, миллекләр, баулар, миллек элгеч, себерке, агач кашыклар, чиккән кулъяулык.

**Бәйрәм барышы:**

*Салмак көй тавышы. Татар өе күренеше, мич янында әби мичтә коймак пешерә, кызы йөгереп керә.*

**Кыз:** Әби, әбием син нишлисең?

**Әби:** Менә, кызым, мичтә коймак пешерәм, аннары миллек бәйләп алырбыз.

**Кыз:** Әби, мин иптәшләремне дә миллек бәйләргә чакырсам буламы?

**Әби**: Була, була, кызым, бергә-бергә күңеллерәк тә булыр.

*Кыз чыгып китә һәм дусларын алып керә. Кызлар исәнләшеп керәләр.*

Әби: Иии, балакайларым, менә бит ничек матур итеп жыелып килгәнсез, рәхмәт яугырлары.

Балалар: Исәнме, Гөлҗиһан әби!

Әби: Исән-сау, Аллага шөкер, бәбкәләрем! Үзегез әйбәт кенә килеп җиттегезме? Балакайларым, әйдәгез өй алдына чыгып бабагыз алып кайткан ботаклардан миллек бәйләү өмәсе ясап алыйк әле. Бергә серләшеп, сөйләшеп тә утырырбыз. Аннары тәмләп мич коймагы белән чәй эчәрбез.

*Миллек бәйләү урынына барып утыралар, сөйләшә-сөйләшә миллек бәйлиләр.*

**Бала:** Әби нәрсә була соң ул миллек өмәсе? Безгә шул турыда сөйлә әле.

**Әби:** Өмә дигән сүз ул балалар дус-туганнар бергә җыелып эшләү була. Элек миллекне дә өмә ясап бәйләгәннәр. Бердәм эшләгән эшнең нәтиҗәсе дә матур була.

**Бала:** Миңа бабам сөйләгән иде. Миллекне юкә чәчәк аткан вакытта бәйләргә кирәк, шул вакытта бәйләгән миллекнең яфрагы да коелмый, шифасы да бик күп була икән.

**Әби:** Бик дөрес әйткән бабаң. Без күбрәк каен миллегенә өстенлек бирәбез. Моның өчен яшь агач сайлыйбыз. Миллекне керәшеннәрнең Питрау көненә кадәр агач яфраклары яшь, нык чакта әзерлибез. Июль урталарына кадәр җыйсаң да була. Монда иң мөһиме - агачның алкаланмаган булуы шарт. *Каен себеркесе мускуллар, буыннар сызлаганда ярдәм итә, тирене чистарта, яраларны тиз төзәтә***.** Аның төп өстенлеге –ул үпкәләрне чистарта. Каен миллеге төнәтмәсе кавыкны бетерә. Шуңа күрә себерке пешергән суны түгәргә ашыкмагыз. Ә сезнең башка төрле миллекләр турында ишеткәнегез бармы соң?

**1 нче бала:** Әйе, әйе имәннән дә миллек әзерлиләр. Аны июньнән августка кадәр җыялар. Имән миллеге чабынганда коелмый, йомшак һәм файдалы була. Ә мунчага чыккан хуш исе нерв системасын тынычландыра.

**2 нче бала:** Минем юкә миллеге турында ишеткәнем бар. Юкә чәчәк атканда аннан да мунча себеркесе әзерләргә була. Анысы инде артык зур итеп бәйләнми. Учка сыярлык, дәва өчен тотарлык кына була. *Юкә миллеге салкын тиюдән файдалы.*

**3 нче бала:** Кычыткан миллеген дә ясыйлар бит име, әбекәй. Миллек әзерләү өчен кычытканны чәчәк атар алдыннан яки чәчәк аткан вакытта җыярга кирәк. Аның, буыннар сызлаганда файдасы бар.

**Әби:** Әйе, кычыткан миллеген зур итеп бәйләмиләр. Чабыныр алдыннан аны 1-2 минут кайнар, аннан 3-4 минут салкын суга салып тоталар.

**Әби:** Иии, балакайларым, бигрәк күп беләсез икән үзегез дә. Арып та киткәнсездер, аякларыгыз да утырып оеп киткәндер инде. Бер уйнап-биеп алыйк.

**Кыз:** Әбием, өстәлдә нинди матур кашыклар ул?

**Әби:** Иии, кызым, бар алып кил әле (*кыз кәрзингә салган агач кашыкларны алып килеп әбигә бирә*)

**Әби**: Балакайларым, агачлардан бик күп әйберләр ясыйлар. Өстәл, урындыклар, ишекләр, шкафлар, менә бу кашыклар да агачтан ясалган

**Кыз:** Әбием, алар бит гади генә кашыклар түгел, әйдәгез, кызлар, шушы кашыклар белән әбиемә матур көй уйнап күрсәтәбез.

*Кашыклар белән "Әнисә" көен уйнау.*

**Әби:** Бигрәк булдырып уйнадыгыз, балакайларым**.** Әйдәгез,

"Башы телемдә, ахыры төендә" дигән уенын уйнап алыйк. Мин мәкальнең башын әйтәм, ә сез ахырын әйтеп бетерерсез.

- Гаилә-бәхет ачкычы.

-Тирләп эшләсәң, *тәмләп ашарсың*.

-Әткәй-шикәр, *әнкәй-бал.*

-Ана җылысы - кояш җылысы.

-Ата һөнәре - балага мирас.

-Карама кешенең сүзенә, *кара эшенә.*

-Эшләмәгән *ашамый.*

-Җәй эшләсәң, *кыш ашарсың.*

-Көн-эш өчен, *төн-ял өчен.*

**Әби**: Булдырдыгыз, балалар. Эшләгәндә кулыгыз-кулга йокмый, сөйләгәндә телегез дә бик оста икән.

**1 нче бала:** Әйдәгез, дусларым, тәңкә салыш уенын уйныйбыз.

**2 нче бала:** Мин санамыш әйтәм.

Аладан, боладан,
Песи бара колгадан.
Песи түгел, ата каз,
Ата каздан тизрәк кач!
Талия син саласы. (*Айсылуга салалар*)
Айсылуны нишләтәбез?

**Балалар:** Җырлатабыз.

*"Җиләк җыям чиләккә" җыры башкарыла.*

*Тәңкә тагын бер балага салына*

-Нишләтәбез?

-Биетәбез.

-Әйдәгез бергә биеп алыйк.

*Татар бию*е

*Тагын бер салына*

**3нче бала**

Телисезме, дусларым, мин сезгә табышмаклар әйтәм.

**Балалар:** Әйдә,әйдә

**3 нче бала:**

Кыш көне дә яшел кием
Килешеп тора безгә.
Күркәләр бүләк итәрбез,
Килерсез әле көзгә.

**(*Нарат*)**

Кыйнамый, сукмый, үзе елата.

(*Кычыткан*)

Кәүсәсе ак, яулыгы яшел.

*(Каен)*

**Бала:** Әйдәгез әле каен турында да җыр җырлап алыйк әле

*«Ак каен» җыры башкарыла.*

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә жәйгән кебек һәр ягы.
Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәр көн тау ягы.
Яшь балалар, бигрәк матур кызлар
Ак каенны сөеп мактыйлар.
Яз башында алар һәр ел саен
Ак каенда бәйрәм ясыйлар.
Ап-ак каен, инде бик карт каен,
Бизәлә ул язлар килгәндә.
Яшел яфрак яра һәр ел саен,
Кояш жылы нурлар сипкәндә.

**Кыз:** Әбием, миңа күрсәткән матур чигүле кулъяулыгыңны безгә уйнарга биреп тор әле.

**Әби:** Бирәм, бирәм балакаем. (*Әби чигүле яулыгын кызына бирә*)

**Кыз:** Әйдәгез, кызлар, кулъяулык уенын уйнап алыйк әле.

*“Яшерәм яулык” уенын уйнау.*

*Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында-кулъяулык. Ул түгәрәктән чыгып биеп йөри һәм балалар җыр җырлап бетергәнче бер баланың кулына кулъяулыкны салып китә.*

-Кулъяулыгым яшел, яшел,

Алдым каен башыннан.

Сиздермичә салып китәм

Бер иптәшем артына.

*Сүзләр әйтелеп бетүгә, кулъяулыклы бала уртага чыга һәм салучы белән җитәкләшеп әйләнәләр.*

**Әби:** Бигрәк матур уйнадыгыз, яшь чакларыма кайткандай булдым. Балакайларым, миллекләрне дә урнаштырыр вакыт җитте. Аларны озак итеп кояш астында тотарга ярамый, алар артык кибеп китеп үзләренең файдалы сыйфатларын, хуш исләрен югалта башлыйлар, миллекләрне күләгәле урынга урнаштырырга кирәк, әйдәгез бергәләп элеп куйыйк аларны. Кызым, барыгыз зелпе агачыннан ясалган себеркене алып килеп коелган яфракларны да себереп алыгызчы. Эш беткәч, эш урынын чиста итеп калдырырга кирәк.

*Миллекләрне элеп куялар. Эш урыннарын җыештыралар.*

**Әби:** Уйнадык та, эшләдек тә, әйдәгез, балакайларым, бер чәй эчеп алыйк әле, тәмле коймаклар белән, мин сезгә шифалы үләннәрдән тәмле чәй дә ясап куйдым. *Әби белән бергәләп чәй эчәргә кереп китәләр.*

## ҖИМЧӘЧӘК БӘЙРӘМЕ


**_Хафизова Фәридә Фирдәвес кызы._**

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль Районының "Катнаш төрдәге Балтач 5 нче балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*


**Максат:** татар милли гореф - гадәтләре белән таныштыру аша илебезнең халык мәдәниятенә ( традицияләренә, халык авыз иҗатына, милли халык уеннарына) кызыксыну уяту.

**Бурычлар:**

*Белем бирү бурычы*: төрле фольклор (табышмаклар, санамышлар) жанрларын һәм матур әдәбият (шигырьләр)  үрнәкләрен кабул итү тәҗрибәсен баету. Балага туган якта булган тарихи вакыйгалар турында тәжрибәне тупларга булышу. Халыкларның кайбер бәйрәмнәре табигать белән бәйле булуы, сезонлы булуы турында күзаллау формалаштыру.

Үстерү бурычы: игътибарны, хәтерне, хыялый фикерләүне , сәнгатьчә-эстетик кабул итүне үстерү.

Тәрбия бурычы: милли гореф-гадәтләргә карата кызыксыну уяту. Туган як гореф-гадәтләре белән горурлану, табигате белән соклану хисләрен тәрбияләү. Балаларның күмәк уеннарга омтылышларын хуплау.

**Балалар яше:** 5-6 яшь

**Җиһазлау**: SMART- такта, урындыклар, зәңгәр тукыма (киңлеге 40-60 см), чишмә буе декорациясе ( агач төпләре, чыршылар, умырзая чәчәкләре, куаклар),  уен өчен атрибутлар (күз бәйләргә яулык, түбәтәй, йөзек....)

**Төзелеше:**

I. Кереш өлеше

Исәнләшү

Г.Тукайның «Яз» шигырь-табышмагын тыңлау (балалар)

«Сорау –җавап» уены

II. Төп өлеш

1. Умырзая турында табышмак
2. ИКТ: «Язгы урман» виртуаль сәяхәт.
3. «Гөрләвек» уены оештырыла.
4. Уенга җыю җыры.
5. «Зимчәчәк» уены
6. Балаларның теләкләре буенча милли уен.

III. Йомгаклау өлеше

Чараның барышы:

*Залда ярымтүгәрәк итеп урындыклар куелган.  Залның бер өлешендә елга буе чагылдырган декорация урнаштырылган: агач төпләре, чыршылар, умырзая чәчәкләре, куаклар, SMART-такта.*

*Татар милли киемнәренә  киенгән балалар залга керәләр,  урындыкларга утыралар*.

**Ике бала Г. Тукайның «Яз» шигырь - табышмагын сөйлиләр.**

А.б.: Рәхмәт, дусларым.

**«Сорау –җавап» уены**

А.б.: Дусларым «Сорау –җавап» уенын уйнап алыйк! Балалар, иптәшләрегез нинди ел фасылы турында сөйләп үттеләр?

*(Балалар җаваплары: «Яз»)*

А.б.: Дөрес, яз. Ә сез язның тагын нинди билгеләрен беләсез?

*(Балаларның җаваплары)*

**Умырзая турында табышмак**

А.Б: Балалар, мин дә бер табышмак беләм . Кем җавабын тизрәк табар икән? Язгы кояш нурын чәчкәч,

Бар чәчәктән уздырып,

Җир өстенә калыктым

Кар мендәрен туздырып. *(Умырзая)*

А.Б: Бик, дөрес. Бу умырзая чәчәге.

2. ИКТ: «Язгы урман» виртуаль сәяхәт.

А.б. : Балалар, мин сезне Язгы урманга чакырам.

*Балалар SMART- такта янына чакырыла. Идәндә такта алдыннан тиешле арада умырзая чәчәкләре куелган.*

А.б.: Күрәсезме: чәчәкләрне? Ул – умырзаялар. Сак булыгыз : өстенә басмагыз, өзмәгез. Алар «Кызыл китапка» кертелгән.

Умырзая чәчәге - язнын ин беренче чәчәге. Боз катлавы эреп, жир куренә башлагач, урман аланында шәмәхә – аксыл төстәге чәчәкләре белән яз хәбәрчесе – тәүге умырзая калкып чыга. Апрель ахырларында калкып чыккан берничә көнлек кенә гомерле бу чәчкә кайдадыр сары чәчәк атса, алып таулары итәгендә куз явын алырлык ак төстә була.

*Алып баручы сөйләгән вакытта экранда умырзая чәчәге сүрәтләнгән слайдлар алмашынып тора.*

А.Б.: Дусларым, сез ишеткәнегез бар микән? Татар халыкның умырзыя белән бәйле милли бәйрәме дә бар.

*(Балалар җавабы булырга мөмкин)*

А.б: Сез нинди татар милли бәйрәмнәрне беләсез?

*( Сабантуй, Карга боткасы, Нәүрүз һ.б.)*

А.б.: Язгы бәйрәмнәрнең берсе - Җимчәчәк бәйрәме. Анда төрле күмәк, әйлән-бәйлән уеннары башкарыла. Җимчәчәк йоласы, үсемлекләр дөньясы белән бәйле. Ул язгы ташкыннар җиткән көннәрдә, беренче чәчәк (умырзаялар) кар астыннан күренә башлагач, уздырыла. Яшьләр матур киенеп, елга буена киләләр.

А.б: Без сезнең белән урман янында. Җимчәчәк бәйрәменең  йолаларын күз алдына китереп карыйк. Карагыз, гөрләвек ага. Аның аша сикереп  матур аланга чыгарбыз.

**«Гөрләвек» уены оештырыла.**

Уен үткәрелгән уртасына чишмә – борылмалы ике сызык үткәрелә; төсле буяулы ике бау сузып салына. Ике сызыкның арасы 40-60 см була. Балалар татар лирик көй астына йөрергә чыккан булалар. Аларга юлда чишмә очрый. Алар бер-бер артлы тезелеп чишмә аркылы сикереп чыгалар.Чишмәне чыгып аланга чыккач балалар таралып йөгереп уйныйлар.

А.б.: Килеп тә җиттек. Без шундый матур табигать  кочагында. Уйныйк, күңел ачыйк!

*Балалар түгәреккә басалар.*

**Уенга җыю җыры:**

Әйдәгез, дуслар, җыелыйк,
Җитәкләшеп тезелик.
Тәгәрәктә бергәләп,
Күңелле көлик, уйныйк!

А.б.: Элек яшьләр Җимчәчәк бәйрәмендә  «Зимчәчәк» уенын яратып уйнаганнар**.** Без дә уйнап алыйк!

**«Зимчәчәк» уены оештырыла.**

Кызлар бер сафка, малайлар аларга каршы якта икенче  сафка тезелеп , кулга-кул тотынышып басалар.

Малайлар сафы ( кызларга җырлап киләләр):

“ Киртә буе зимчәчәк, зимчәчәк,
Киртәсендә сәмеркош, сәмеркош.

Кызлар:

 Сәмеркош, сәмеркошка ни кирәк, ни кирәк?

Малайлар:

 Салма алыр кыз кирәк, кыз кирәк

Кызлар:

Аны салыр кем кирәк, кем кирәк?

Малалайлар:

Алсу ( Сәмирә) атлы кыз кирәк, кирәк.

Исеме атап әйтеп чакырылган кыз малайлар ягына чыга.  Икенче юлы кызлар җырлый һәм малайлардан берсенең исемен әйтеп чакыра. Уен шулай  тапкыр үткәрелә.

**Балаларның теләкләре буенча милли уен**

А.б.: Тиздән бакча эшләре башланачак , эшләр күбәячәк. Хәзер күңел ачыйк, уйныйк бергә! Нинди бәйрәм бездә?

*Балалар: Җимчәчәк бәйрәме.*

А.Б.: Сез нинди милли уенны яратасыз?

*Балалар тәкъдим итә («Йөзек салыш»,«Утыр,утыр, Мәликә», «Түбәтәй» һ.б)*

А.б: Кайсыгыз саный?

*Санамыш әйтелә. Берничә уен оештырыла.*

А.б.: Балалар, безгә кайтырга да вакыт. Караңгы да төште инде. Бу уеннан бер атна буе үтә. Бу аланга иртәгәдә килербез әле?Ничек уйлыйсыз?

*Балалар тәрбияче артыннан залдан чыгап китәләр.*

**“Сабый туды җиргә...”**

**Балага исем кушу йоласы**

***Хәлилова Энҗе Шамил кызы.***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Катнаш төрдәге Чепья балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Максат:** балаларда үз халкының гореф – гадәтләренә, йолаларына һәм мәдәниятенә карата уңай хисләр, мөнәсәбәтләр формалаштыру.

**Бурычлар:**

- балаларны исем кушу йоласы белән таныштыру;
- балада татар халкының гореф- гәдәтләренә кызыксыну уяту;
- милләт тойгысы һәм милли горурлык хисе тәрбияләү;
- буыннар бәйләнеше, исемнәр, аларның килеп чыгышы, мәгънәсе турында күзаллауларын тирәнәйтү;
- гаиләң белән горурлану хисләре, өлкәннәргә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү;

**Җиһазлау:** татар халкы өе күренеше өчен атрибутлар, өстәл, урындыклар, бәби бишеге, “бала елаган тавыш” – аудио, түбәтәй, йөзек.

**Алдан башкарылган эш:** татар халык уеннары уйнау, татар халык әкиятләрен тыңлау һәм карау, “Балага исем кушу” темасына әңгәмә үткәру, санамышлар һәмбишек җырлары өйрәнү, татар исемнәренең мәгънәсен ачыклау.

**Катнашалар:** әни, әти, әби, малай, кыз, дәү әни, дәү әти, 2 онык (кунак малай, кунак кыз), мулла.

**Чараның барышы.**

Авыл өе. Бишек янында әни бала тирбәтеп утыра. Бала әнинең кулында. Читтәрәк әти, әби, малай һәм кыз утыра.

**Әни:** Бала туды бүген җиргә,
Фәрештәләр аңа юл ачты.
Күкләр иле садә җаннан булган
Бер баласын җиргә  озатты.
-Бүген бездә зур шатлык. Өйдә гаиләгә яңа ямь, юаныч, өмет, бәхет өстәлде. Бәхетле булып, алтын канатлы булып үссен сабыебыз.

*Бишек янына килеп,  бишек җыры җырлый.*

**Бишек җыры** (Г. Тукай шигыре, татар халык көе)

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла, углым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезең. ***(баланы бишеккә сала)***
**Әби чыга:**  Күрим әле оныгымны,
Карап туймаслык бала.
Улым, килен котлыйм сезне
Күз тимәсен Сөбеханалла.
-Шундый онык бүләк иткән өчен зур рәхмәт сиңа, килен. *(Киленнең аркасыннан сөя)*

Әти: Бүген бездә бәйрәм булыр,

Исем кушарбыз уйлап.

Яхшы исем, матур исем

Мәгънәсе булыр чынлап.

Әни: - Әниләр дә килеп җитте. Әйдәгез, рәхим итегез!

***(Дәү әни, дәү әти, 2 оныкк (кыз һәм малай) керә. Кунак малай исәнләшә)***

**Кунак малай** : Әссәләмәгәләйкүүүүүүм!

Исәнмесез –саумысез

Бәби күрергә килдек без,

Нигә каршы алмыйсыз?

**Әби:** Хуш киләсез, кунаклар,

Рәхим итегез, әйдә.

**Кунак кыз:** Күчтәнәчләр алып килдек,

Барыгызга күп итеп.

Баллысын да, татлысын да

Озын юлларны үтеп.

***(Әбигә күчтәнәч тапшыра)***

**Дәү әни:** Күз тимәскә миләш тегеп,

Күлмәк бүләк итәрбез.

Сау –сәламәт бала булып,

Үскәнен дә көтәрбез.

***(Әнигә бүләк тапшыра)***

**Дәү әти:** Күчтәнәчне җәлләмәдек,

Алып килдек күп итеп.

Бәбине күрсәтсеннәр дип,

Әниләренә читек.

***(Әнигә бүләк тапшыра)***

**Малай (бәбәйнең абыйсы):** Сеңлем, энекешкә исем кушабыз бүген. Ләкин әлегә исем сайламадык, бик матур исем кирәк инде безнең энекәшкә.

**(балалар түгәрәкләп басалар)**

**Кунак кыз:** (санамыш әйтә)

Аладан, боладан,

Песи бара колгадан.

Песи түгел, ата каз,

Ата каздан тизрәк кач!

***Уртага бер баланы чыгара, бала уйланып тора да:***

Айсылу! Шат күңелле, ачык дигәнне аңлата!

**Малай (бәбәйнең абыйсы):** Кит әле, безнең бәби  малай бит!

**Кунак малай:** Әйдә, хәзер мин саныйм.

Өйгә кергән бер чыпчык,

Очып йөри чык-чырык.

- Чыпчык, чыпчык, син чыпчык!

Атлап түгел, очып чык!

**Кыз (бәбинең апасы):** Мин таптым, мин таптым. Әмирхан булсын!

Малай (бәбинең абыйсы): Булсын, булсын, бик күркәм,

Туры килсен үзенә.

Бай күңелле малай булып,

Үссен безнең кечкенә!

Дәү әни: Әмирхан -  бик матур исем. Өметле, ышанычлы дигәнне аңлата. Әмирхан исемен йөртүче кеше - төгәл кеше. Ул кайда һәм ничек эшләргә кирәк икәнлеген һәрвакыт яхшы белә.

**Кунак кыз:** Мулла абзый килгәнче,

Бала уянып җиткәнче

Кызык итик, тик тормыйк,

Җырлы уеннар уйныйк.

***(Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. “Түбәтәй” уены уйныйлар)***

**Кыз (бәбинең апасы):** - Әйдәгез, йөзек салыш та уйныйбыз.

***“Йөзек салыш” уены.***

**Әни:** Күз карасы кебек үстерербез,

Нарасыйны, газиз улыбызны.

**Әти:** Өсте бөтен, тамагы тук булыр,

Ышан миңа, ышан, әнкәсе!

***Бала елаган тавыш ишетелә.***

**Әти:** Исем таптык бик матурны

Уянды балабыз да.  *Баланы бишектән ала, тәрәзә янына барып:*

-Мулла абзый да килеп җитте. Эйдэгез, түрдән узыгыз!

***(Һәммәсе дә тезелешеп утыралар)***

**Мулла:** Әссәләмәгәләйкум!

Хәерле көн сезләргә!

Исем кушу йоласын

Башлап җибәрик, әйдә.

*(Мулланы түргә утырталар. Бәбине аның янындагы мендәргә салалар. Мулла балага исем куша. "Азан" әйтә. Башта уң колагына, аннан сул колагына "Исемең булсын Әмирхан"- дип кабатлый, дога укый)*

**Дәү әти:** Синең матур исемең "Әмирхан" дип,
Хәзер шәҗәрәгә языла.
Энеләрең, сеңелләрең тусын,
Дәвам итеп нәсел агачын.

**Барысы бергә:** Амин! Амин! Шулай булсын! Еллар имин, тыныч булсын! Амин!

**Әни (әкрен генә сөйли ):**Үз милләте көен ишетеп үссә
Халык хәтерен саклар буыннар.
Тарихлардан килгән гореф-гадәт,
Туган телен көйли бу җырлар.
-Кызым, кил бераз бишекне тибрәт эле.

(*Бәбинең апасы бишек җыры җырлый)*

Бәү-бәү итә энекәш,
Вакыт җиткән йокларга.
Абыйларга, апаларга
Кечкенә балаларга.
Көн үтте, ә кояшны
Кара карга урлаган.
Нәни энекәшебез
Әле йоклап туймаган.
Энебез дәү - дәү үсә,
Ай бишектә төн үтә.
Шул төн үткән вакытта
Дәү егет бәү-бәү итә.

**Әби:** Саклыйк буыннарга рухи хәзинәне,
Бишек җыры-күңел көзгесе.
Киләчәктә шәхес булыр өчен
Тәүге адым, яшәү өлгесе.

**Әни:** Ә хәзер барыгызны да бәби чәенә чакырам. Әйдәгез, рәхим итегез.

**«Татар дөньясы» китабы эзләреннән.**

***Шәрифуллина Айгөл Мөзәкир кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*“Бала үсеше үзәге-Арча шәһәре 4 нче балалар бакчасы”*

Авыл өе күренеше. Сәкедә намазлык өстендә әби дисбе тартып утыра. Әниләре кунакка барырга төенчек, сумкалар әзерләп йөри. Ике кыз әниләрен тын гына күзәтәләр. Сәхнә артыннан ир кеше тавышы ишетелә.

**Әти.** Т-ррррр, малкай. Менә шулай( *сәхнә артыннан кышкы киемнән, бүреген сала-сала килеп чыга)*Сиңа әйтәм, булдыгызмы? Машина ватык чакта, атның кирәге чыга шул. Ат әзер, әйдә, юл кешесенең юлда булуы хәерле. Кышын көннәр кыска, караңгы төшкәнче барып җитик. Яшь чакларны искә алып, ат җигеп кунакка барып кайтыйк әле.

**Әни.** *(Әбигә карап)* Ярар, әнкәй, без кузгалабыз. Ике кич кунып, кече атнага кайтып җитәрбез, боерган булса. Йорт-җиргә күз-колак булып торырга ярый сез бар әле. Исәнлектә күрешергә насыйп итсен. Кызым, сезгә әйтәм, ишетсен колагыгыз, безнең йөзгә кызыллык китерәсе булмагыз. Малай-шалай, егетләр кертә күрмәгез. Аллам сакласын, авыл буйлап данygыз китәр. Әбиегезнең сүзен тыңлагыз. Мичкә бәлеш тыктым, бер сәгатьтән алып ашарсыз яме.

**Олы кыз**.Әстәгъфирулла, әни, ни сөйлисең син. Зинһар борчылмагыз, тыныч булыгыз. Исән-сау йөреп кайтыгыз. Кодаларга, апа белән җизнигә сәлам әйтегез.

**Кечке кыз**. Әни, әни, сез кайчан кайтасыз?

**Әни.** Ике кич кунарбыз. И, рәхмәт төшкере, кая соң төенчегем?! Кызым, теге зур шәлемне дә алып бирче, бөркәнеп утырырмын(*кече кыз табып бирә*).

**Әти**. Буласызмы сез бүген?! Утырышыгыз барыгыз да, борынгыча, юл алдыннан бер дога кылыйк. Әйдә, әни укып җибәр (*сәкегә утырып бергә дога кылалар һәм төянеп чыгып китәләр).*

**Кече кыз.** Апа, апа дим, әни беркемне дә кертмәскә кушты. Ә кызлар килсә ни диярбез?

**Әби.** (*сөйләшкәнне ишетеп ала, кеткелдәп көлә*) Борчылма балам, мин өйдә бит. Кертербез ахирәтләрегезне. Килегез әле, бер әйбер күрсәтәм. *(Сандык янына алып бара, аннан «Татар дөньсы» китабын ала.)*Менә карагыз әле, Әсмабикә әбиегезнең улы Мансур миңа Казаннан нинди затлы бүләк алып кайткан. Син авылның абыстае, сиңа атап алдым, кече буынга тәрбия бирерсең диде. (*Ишек шакыган тавыш ишетелә)* Менә иптәшләрегез дә килде бугай.

**Кече кыз.** Апа, апа, ачыйммы?

**Олы кыз.** Хәзер сеңлем, үзем ачам. Кем бар анда?

**Тавыш.** Бәлеш исен сизәбез, аулак өйгә киләбез.

Әйдәгез, кызлар әйдәгез. *(Киттеләрме, кайчан кайталар, озак торалармы һ.б. шундый сораулар белән шаулашалар)*

**Әби.** Оланнар, бире килегез әле. Мансур абыегызның бүләген бергәләп карыйк. *(Әби тирәсенә җыелып утырмакчы булалар, тагын ишек шакыйлар*) Монсы егетләрдер ахрысы. Без яшь чакларда эти-әни кунакка киткәч шулай егетләр-кызлар җыелыша торган идек. Кызым, кара әле, кем бар анда.

**Олы кыз.** Хәзер әбекәй, син өйрәткән такмакны сөйлим, ошатсалар керерләр

Чыгам өйдән

Карасам, берәү килгән.

Аягында җилән.

Өстенә читек-кәвеш кигән.

Борынына төшкән бүрек,

Булмый йөзен күреп,

Бүреген күтәреп карасам,

Вот тебя раз, Ибрай таз!

*(Көлешеп малайлар керә)*

**Малай.** Минем бабам өйрәткәнне дә тыңлап карагыз.

Ошбу баскычларга басмас идем,

Баскычлары бадьян агачы.

Ошбу йортка кермәс идем,

Хуҗалары – сандугач баласы.

**Әби.** Килүегез бик яхшы булды әле. Мансур абыегыз бүләк иткән китапны бергәләп карарбыз. Анда татар халкы турында татарча да, русча да бик тәфсилләп язылган*(күрсәтә).* Әкрен генә таныша башласак, шәт сез дә милләтебезнең үткәнен белерсез, үзегезгә сеңдерерсез. Әйдә, эскәмиягә, сәкегә тезелешеп утырыгыз.

**Кече кыз.** Әби, әби, син миңа сәке турында өрйәткән шигырь-не сөйләп күрсәтимме?

**Әби.** Әйдә балам.

**Кече кыз.**

Сәке – безнең өстәл иде,

Сәке – безнең карават.

Кирә кчакта чәй эч шунда,

Кирәк икән – кырын ят.

Сәке – безнең сандык иде,

Каз оясы сыярлык.

Сәке асты сарай иде,

Ярган утын куярлык.

Сәке түренә өелгән

Түшәк, ястык, мендәре.

Сәке – әби-бабаемның

Намаз укыр мөнбәре...

Йорт-кураның төп җиһазы

Сәке булган элгәре.

Әйтерсең, шунда төйнәлгән

Җир һәм Җиһан егәре!

**Әби.** Шулай шул, балам. Менә әтиегез дә борынгыны хөрмәт белән искә алып өебезгә сәке ясап куйды шул.

**Кыз бала.** Әбекәй, ә сез нинди уеннар уйнарга ярата идегез? Безгә дә өйрәт әле.

**Әби.** Оланнар, без элекке заманнарда эштән ял иткәндә «Чәчкеч, суккыч» уенын бик ярата идек. Уртага дүрт бала чыгып баса. Калганнар түгәрәктә. Бергәләп җырлап түгәрәктә әйләнәбез. «Чәчкеч, суккыч»ны әйткәндә, уртадагы балалар белән кушылып, култыклашып биибез.

Самолеттан күренәдер

Татарстан кырлары.

Чәчкеч, чапкыч, ургыч, суккыч,

Триер-триер комбайн.

Космос киңлеген яулады

Безнең ил батырлары.

Чәчкеч, чапкыч, ургыч, суккыч,

Триер-триер комбайн.

Кызыл байрак уртасына

СССР дип язылган.

Чәчкеч, чапкыч, ургыч, суккыч,

Триер-триер комбайн.

Кызыл байрак шуңа кыйбат –

Кан эченнән табылган.

Чәчкеч, чапкыч, ургыч, суккыч,

Триер-триер комбайн.

Аллы-гөлле чәчәк ата

Безнең урман буйлары

Чәчкеч, чапкыч, ургыч, суккыч,

Триер-триер комбайн.

**Малай.** Бик күңелле уен булды бу әби. Китапны тагын карыйк әле. (*карыйлар)*

**Малай.** Элекке заманнарда безнең халыкның киемнәре күз явын алырлык матур булган икән. Без дә түбәтәй, камзул, читекләрне яратып киябез. Шуларны күрсәтеп бер биеп алыйк әле.

*Парлы бию башкарыла.*

**Малай.**

Челтәр икән якасы,

Бигрәк матур тәңкәсе.

Аккош микән, былбыл микән

Моны тапкан әнкәсе?

**Малай.**

Их, безнең татар кызлары,

Ак калфак киюләре.

Калфак кигән чибәрләрнең

Ягымлы көлүләре.

Үзебез турында бер матур җыр да башкарыйк әле.

*«Шома бас» җыры башкарыла. Татар халык көе, Гамир Насрый сүзләре.*

**Әби.** Булдырдыгыз, балакайларым. Китапның иң тәмле битләрен дә күзәтик әле. (*балалар китапны карыйлар*) Хәзер ризыклар бик мул, кибет киштәләре сыгылып тора. Без үскәндә иң тәмле ризык – тир түгеп үстергән икмәк булды. Шулай да барына риза булдык. Балакайлар, китап ошадымы сезгә? Мәктәптә укый башлагач, тагын килерсез әле яме. Китапны бергәләп укып чыгарбыз. Сезнең өчен тупланган бу хәзинәне саклап, үскәч, үз балаларыгызга да тапшырырсыз. Татар милләтен бергәләп сакласак, телебез дә сакланыр, киләчәгебез дә өметле булыр.

**Олы кыз.** Әни бер сәгатьтән бәлеш ашарга кушкан иде... Исе чыккан бит, әйтмисез дә. «Татар дөньсы» китабындагы тәмле ризыкларны күргәч авыз суларыгыз килгәндер.

**Әби.** *(бәлеш алып чыга).*Әйдәгез әле оланнар, борынгыча, сәкегә утырып, бисмилланы әйтеп бәлештән авыз итик.

Бәйрәм күңелле көй астында чәй эчү белән тәмамлана.

**Каз өмәсе**

***Исрафилова Раилә Мөхәммәтфатих кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы “Бөрбаш балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Максат:** Милли гореф-гадәтләрне һәм йолаларны торгызу.

**Бурычлар:**

*Балаларда татар милли йолаларына кызыксыну тәрбияләү, башка милли халыклар белән дуслыкны ныгыту.

*Балаларга сәхнә осталыгы, сәнгатьчә бию, җырлау күнекмәләре бирү, сөйләм телләрен үстерү.

*Балаларны татар халык иҗатының гүзәл үрнәкләре белән таныштыру, татар халкының милли, зәвыклы, матурлык яратучы халык икәнлеген аңлату.

**Хәзерлек эшләре:** сынамышлар, санамыш, табышмаклар, җырлар, биюләр, уеннар өйрәнү, тамаша өчен атрибутлар, костюмнар әзерләү, өй эчен бизәү өчен җиһазлар ясау.

**Җиһазлау:** сандык, мендәрләр, чиккән сөлгеләр, кулъяулыклар, самовар, савыт-саба, татар халкының милли ризыклары, тәрәзә макеты, гармун, эче тутырылып теккән казлар, каз каурыйлары, каз канатлары, май канатлары, аудиоязмада каз кычкырган тавыш, баян.

Тыйнак кына җыештырылган, милли итеп бизәлгән авыл өе эче. Почмакта чигүле сөлгеләр, кулъяулыклар эленгән, түрдә аш өстәле, стена кырыенда сандык, аның өстендә каз мамыгы тутырылган мендәрләр, чиккән кулъяулыклар, урындыклар, каз салу өчен табаклар, өстенә чигүле эскәтер япкан сәке.

Хуҗа әби каз йолкучы кызларга өстәл, каз мамыгын салу өчен табаклар әзерләп йөри, сөйләнә:

-Бүген каз өмәсе ясап алырга ниятләдем әле. Авылыбызның уңган, булган чибәр кызларына да эндәштем. *(Авыз эченнән көйли)*

Каз өмәсенә җыйналды

Тирә-күрше кызлары...

*(Тышта аудиоязмада каз кычкырган тавышлар, каз тоткан тавышлар ишетелә)*

Күрше әби керә.

-Керергә мөмкинме? Күршекәем, нихәлләрең бар?

-Бик яхшы, әйдә кер, утыр. Үзеңнең хәлләрең ничек соң?

- Әйбәт кенә йөреп торам. Я, йортка бер дога кылыйк. (Утырып дога кылалар)

**Күрше әби:** Ихатаңда кешеләр йөргәнен күргәч кердем, әллә берәр эш майтарасыңмы?

-Шулайрак иде шул, менә казларны суеп йолкырга өмә җыйган идем.

-Андый вакытта кеше артмый. Мин дә җыенып керим әле.(Чыга)

Казларны тотып кызлар керә.

**Олы кыз Гөлфия:** Әби, казларны кая куйыйк?

**Әби:** Менә монда куегыз, үзегез дә тезелешеп җайлап утырыгыз. Казларны алдыгызга берәм-берәм алыгыз. Хәерле сәгатьтә булсын.

**Күрше әби керә:** Хай, көне дә көне, салкынайтып җибәрде. Ярар, әйдә салкынайтсын, казларны салкын суда юсаң, ите дә тәмле була, тәне дә аграк була.

**Олы кыз Гөлүсә:** Кызлар, казларыгызны кулдан төшереп җибәрә күрмәгез, казны кулдан төшереп җибәрсәң, кул арты китә, диләр.

**Айсинә:** Без дә беләбез андый сынамышларны. Көз озын килсә, яз соң килер.

**Ризәлә:** Кыр казлары иртә китсә, кыш иртә килә.

**Әминә:** Кыш көне кошлар түбән очсалар, кыш салкын, югары очсалар, кыш җылы килә.

**Галия:** Әгәр беренче кар коры булса, җәй яхшы килер.

**Олы кыз Гөлфия:** Кызлар, бик күп беләсез икән бит сез сынамышларны, бер җырлашып утырыйк әле.

**Кызлар:** Җырлыйбыз, күңелләр күтәрелеп китәр. *(Бергәләшеп “Каз канаты” көенә җырлыйлар)*

Каз канатларын йолкабыз,

Без эшне яратабыз.

Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,

Күңелне юатабыз.

Каз канаты тәмле пешә

Утын яккан мичләрдә.

Сөйләшәбез, серләшәбез Бу

күңелле кичләрдә.

**Олы кыз Гөлүсә:** Бигрәк моңлы, бигрәк матур җыр. Нинди җыр бу?

**Кызлар:** Бу татар халык җыры “Каз канаты”.

**Әби:** Кара, казлар ничек чиста булганнар. Кызлар, берничәгез каз юарга чишмәгә төшәргә әзерләнегез, берничәгез монда калырсыз, миңа булышырсыз. Каз мамыгы тутырып куярбыз. Хай, бу каз мамыгының йомшаклыгы, менә монысы узган елгы мендәр, бигрәк йомшак.

Камилә тотып карый: Әби, бигрәк йомшак икән бит бу! Бу мендәргә баш тиюгә йоклап китәсең.

Олы кызлар иңнәренә көянтә асалар, каз элеп чыгалар.

**Гөлүсә:** Кузгалдык, кызлар, хәерле сәгатьтә булсын.

**Әби:** Шулай булсын, ипләп кенә юып кайтыгыз әле.

*Кызлар җырлый-җырлый каз юарга китәләр.*

**Күрше әби:** Мин сезгә каурый сыдырырга өйрәтим әле. Менә шулай сыдыралар *(өйрәтә)*. Аннан соң сыдырылган каурыйларны су юлына сибәләр, монысы тагын да күңелле эш. Каурыйларны берәм-берәм рәттән сибәләр, икенче елга да шул юлдан бик күп казлар тезелешеп су коенырга төшсеннәр, дип.

**Гөлфия:** Әйдәгез, кызлар, табышмаклар әйтешәбез.

**Камилә:** Үзем әйтим әле беренче: үзе су,  үзе каты, нәрсә ул? (боз)

**Айсинә:** Соскы борын бакылдык, күп сөйләшә такылтык. (үрдәк)

**Галия:** Яңа савыт – тишелеп беткән. (иләк)

Каз юучы кызлар кайталар.

**Ризәлә:** Казларны бик әйбәтләп юдык, әби.

**Зилә:** Чишмә суы бигрәк салкын.

**Дилия:** Казлар бик симез булганнар.

**Әминә:** Бу каз бигрәк файдалы кош инде.

**Әби:** Рәхмәт яугырлары, туңмадыгызмы? Кара әле, Гөлфәния, ничек ап-ак булганнар!

**Күрше әби:** Әйе, салкын су үзенекен эшләгән, казлар бик матур, сөбеханалла.

**Әби:** Сулары да саркыр, менә шул сәкегә тезеп куйыйк. Мин сез кайтышка каз маенда гына кыздырып коймак пешердем, казның вак-төякләреннән бәлеш салдым. Табынга рәхим итегез.

Кызлар бергәләшеп чәй эчәләр.

**Ризәлә:** Әби, коймагың бик тәмле булган.

**Камилә:** Ә бәлеше тагын да тәмлерәк, телеңне йотарлык!

**Әби:** Үзегез дә бик тәмле телле икәнсез, ашагыз әле, ашагыз. Менә чәй ясадым, эшләгәндәге кебек ашагыз.

Өстәл яныннан рәхмәт әйтеп кузгалалар.

**Гөлфия:** Берәр уен уйнап алабызмы?

**Кызлар:** “Яшел-яшел кулъяулыгым”ны.

**Дилия:** Үзем саныйм.

Зәйни-зәйни Зәйнәбем,

Атны кая бәйләдең?

Алмагачка бәйләдем.

Алма төште шап итеп,

Зәйнәп чыкты ялт итеп.

Түгәрәкләнешеп басалар, артта бер кыз кулъяулык тотып биеп әйләнә, җыр тәмамлануга бер иптәшенең артына сиздермичә генә яулыкны ташлый, үзе алга биеп китә һәм теге кызның урынын ала.

Яшел-яшел кулъяулыгым

Яшел чирәм өстендә.

Сиздермичә ташлап китәм

Бер иптәшем артына.

**Ризәлә:** Биисе килә. Биик әле.

Лирик бию "Каз канаты"

Еракта малайлар җырлап килгән тавыш ишетелә.

Су буенда зәңгәр чәчәк,

Якты нурлар тарата.

Безнең кызлар һәм малайлар

Зәңгәр чәчәк ярата.

Дус-ишләрең арасыннан

Берсен сайлап ал әйдә.

Тезләреңә ипле булсын,

Мендәреңне сал әйдә.

**Малайлар:** Исәнмесез, кызлар!

**Кызлар:** Сәламегезне алдык, кесәгә салдык.

**Ильяс:** Казларыгыз симез булсын, кызлар.

**Кызлар:** Казларыбыз симез, кызларыбыз игез.

**Әмир:** Кертегез инде, кызлар!

**Әби:** Ишек бавы бер алтын, безнең кызлар мең алтын, бүләгегез бармы соң?

**Олы малай:** Бар, Мәрфугаттәй, менә *(иңенә шәлъяулык сала)*

**Әби:** Болай булгач кертмичә булмас инде, кызлар.

**Кызлар:** Керсеннәр. *(Малайлар керәләр)*

**Әмир:** Кызлар, җырлы-биюле уен уйныйбызмы?

**Барысы бергә:** Уйныйбыз. Кайсын уйныйбыз?

**Рамазан:** "Чума үрдәк, чума каз" уенын.

**Түгәрәктә "Чума үрдәк, чума каз" уенын уйныйлар**

Чума үрдәк, чума каз,

Чума үрдәк, чума каз.

Тирән күлне ярата шул, ярата,

Тирән күлне ярата шул, ярата.

Әмир үзенә иптәш эзли,

Әмир үзенә иптәш эзли,

Белмим кемне ярата шул, ярата,

Белмим кемне ярата шул. ярата.

**Әби:** Ничек матур итеп җырлап-биеп уйныйсыз сез. Карап торам да үземнең яшь чакларым исемә төшә. И-и-и, без яшь вакытта күңелле иде ул! Күрше Кукмара, Саба районнарыннан керәшен, мари, удмурт, рус карендәшләребез килеп кушылгач, түгәрәгебез тагын да киңәеп, җырларыбыз дәртләнеп китә торган иде. Дус яшәдек шул, күршекәем, әйеме? Менә сугыш дигән афәт кенә урлады яшьлегебезне. 76 ел көтәм инде бабаегызның кайтканын, күренми генә. *(Яулык чите белән күзләрен сөртә)*

**Күрше әби:** Күңелсезләнмә әле син болай, кунаклар килергә тиеш дигән идең, кемнәр соң алар?

**Әби:** Менә исәр баш, онытканмын бит.(Тәрәзәгә барып карый) Килеп җиткәннәрдер инде алар, каршы алыйк .

**Керәшен кызлары:** Саулармы, сез! (Ипи бирәләр)

**Удмурт кызы һәм малае:** Зечбуресь! (Милли киемле курчак бирәләр)

**Рус кызы һәм малае:** Здравствуйте! (Кул эше агач савыт һәм кашык бирәләр)

**Рус малае:** Безнең тагын бүләкләребез бар.

Һәр милләт үз милли биюен башкара.

**Олы малай:** Кунак ашы  - кара-каршы, диләр, кунакларга “Алларын да алырбыз, гөлләрен дә алырбыз” ны җырлыйбызмы?

**Барысы бергә:** Җырлыйбыз.

Малайлар бер, кызлар икенче якка тезелешеп басалар һәм кара-каршы җырлыйлар.

**Малайлар:** Уйнасак та, җырласак та

Гармун кулларыбызда.

Алсу гөлләр чәчәк атсын

Йөргән юлларыгызда.

Кызлар: Алын алырсыз микән,

Гөлен алырсыз микән?

Урталарга чыгып сайлап,

Кемне алырсыз микән?

**Малайлар:** Алларын да алырбыз,

Гөлләрен дә алырбыз.

Күңелебезгә кем ошаса,

Шуны сайлап алырбыз.

**Кызлар:** Челтәр элдем читәнгә,

Җилфер-җилфер итәргә.

**Малайлар:** Без килмәдек буш китәргә,

Килдек алып китәргә.

**Бергә:** Алларын да алырбыз,

Гөлләрен дә алырбыз.

Күңелебезгә кем ошаса,

Шуны сайлап алырбыз.

**Әби:** Рәхмәт, балалар, мин дә сезгә яшь вакытта яратып уйнаган бер уенны өйрәтим әле. (“Түбәтәй” уенын уйныйлар)

**Әмир:** Дуслар, күңелле ял иттек, әбигә рәхмәт әйтеп, кунакларны да алып уеннарыбызны клубта дәвам итик.

**Барысы:** Әйе шул, киттек әйдә.

**Гөлфия:** Югары очларны да чакырыйк.

**Гөлүсә:** Түбән очларны да.

Парлашып басалар һәм җырлап әйләнәләр.

Биек икән тавыгыз,

Каршы ява карыгыз.

Без килдек тә кунак булдык,

Инде үзегез барыгыз.

Алай итәргә кирәк,

Болай итәргә кирәк.

Хуҗаларга рәхмәт әйтеп,

Кайтып китәргә кирәк.

*Балалар җырлаганда  ике кыз кунакларга май канаты өләшәләр.*

***Безнең аулак өйдә***

***Антонова Алсу Фәрит кызы***

*«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең гомуми үсеш бирүче төрдәге 5 номерлы Саба «Бэлэкэч» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда үз Ватаннрына карата мәхәббәт хисе үстерү, патриотик сыйфатлар булдыру һәм татар мәдәнияте мирасын арттырырга омтылу.

**Чараның бурычлары:**

**Тәрбия бурычы:** иҗади активлык күрсәтүгә ярдәм итү, балаларның мәдәни-эстетик хисләрен формалаштыру.

**Үсеш бирүче бурыч:** театральләштерелгән форма чарасы аша мәктәпкәчә яшьтәге балаларда татар телендә ирекле аралашу күнекмәләрен үстерү.

**Укыту бурычы:** балаларның татар халык бәйрәмнәренең эчтәлеге һәм тарихы турында күзаллауларын формалаштыру (авылларда утырышлар -аулак өй).

**Балалар белән алдан эшләү:**

-татар телендә мультфильмнар карау;

-биюне өйрәнү;

-татар халкының гореф-гадәтләре белән танышу;

-татар халык әкиятләрен уку;

-мәкальләрне, җырларны, шигырьләрне ятлау.

**Кирәкле җиһазлар:** татар йорты почмагы: милли күлмәк, чигелгән сөлгеләр, мич, табын, самовар һ. б.

**Төп геройлар:** кунаклар (балалар), тәрбияче, әби.

**Чара барышы.**

**Тәрбияче:** татар халкы борынгы заманнарда «Аулак өй» бәйрәмнәрен уздыруы белән аерылып торган. Гадәттә, бу утырышлар кыш җитү белән башланган.

Авыл яшьләре үзләре белән аталган йортка кул эшләре алып килгәннәр. Бу йортта егетләр һәм кызлар бииләр, җырлыйлар, уйныйлар һәм бергәләп күңелле кич үткәрәләр.

*Төркем бәйрәмчә бизәлгән: чигелгән сөлгеләр, өстәлдә самовар һәм касәләр. Әби йон эрли, кинәт ишек шакыла һәм төркемгә балалар керә.*

**Балалар:** Исәнмесез!

**Әби:** минем кадерле балаларым килде *(балаларны кочаклый).* Исәнмесез, туганнарым! Әйдәгез, табынга сыйлар җыябыз. Сез бал, чәк-чәк, кыймакларны безнең өстәлгә урнаштырыгыз, ә мин әлегә самавырны куям.

*(Әби самовар белән ишек артына чыга, ә балалар чәй өстәленә сыйлар җыялар).*

**Әби:** утырыгыз, кадерлеләрем! Күңелле итеп сөйләшербез. Әйдәгез, бергәләп дога укыйк *(балалар әби белән дога укыйлар).*

Безнең матур һәм күңелле яшьлек чоры бар иде балалар! Егетләр гармунга җырлар җырлап авылның киң урамнары буйлап йөриләр, ә кызлар үз йортларында тыйнак кына аларны көтеп утыралар.

Кызганычка каршы, хәзер яшьләр без уйнаган уеннарны бөтенләй белми.

**Тәрбияче:** Әйе, сез барысын да дөрес әйтәсез әби. Хәзер яшьләр күңелле һәм матур вакыт үткәрә алмый. Алар авылларда аулак өйнең ничек үткәнен дә белмиләр.

**Беренче бала:** әби, ә нәрсә ул аулак өй? Аны ничек үткәрәләр?

**Әби:** элек, авыл кызының яки егетнең әти-әнисе өйдән киткән булса, мондый йортны аулак өй дип атаганнар. Монда яшьләрнең кичке очрашулары уза.

Кызларга кунакка яшь егетләр килә. Бу вакытта шаяртулар, биюләр, җырлар башкару башлана. Вакыт бик тиз һәм күңелле үтә.

**Икенче бала:** әби, без сезнең яшьлек уеннарын уйнарга телибез. Сез безне өйрәтерсезме?

**Әби:** балаларым, сезнең кунакка килүегез бик яхшы. *Тәрбиячегә мөрәҗәгать итеп:* әйдәгез, балаларыбызны аулак өебезнең кызыклы уеннарына өйрәтик.

**Тәрбияче:** Бу уен, мөгаен, «Уйла һәм тотып ал» дип аталадыр?

*Әби һәм балалар бергәләп «Уйла һәм тотып ал» уенын уйныйлар.*

Балалар бер рәткә идәнгә утыралар. Алда уенны алып баручы тора. Аның күзләре яулык белән бәйләнгән. Балаларның берсе җитәкче янына килә һәм аның исемен әйтә. Шул вакытта аның җилкәсенә кулын куя.

Уен җитәкчесе тавышы буенча баланы танырга тиеш, әгәр исемен дөрес дип атый икән, ул тиз генә күзләрен ача һәм качкан кешене куа башлый. Әгәр исем дөрес булмаса, башка уенчы алып баручыга чыга. Әгәр исем фаразланса, уенчы җитәкченең җилкәсенә (икенче тапкыр) кагылып, билге бирә.

Әгәр дә җитәкче уенчыны тотмаса, уенны аның белән тагын бер тапкыр кабатларга мөмкин. Әгәр уенчы тотылса, җитәкче рәтнең азагында урын ала, ә тотылган бала җитәкче була. Уенда чират үтәлергә тиеш.

**Тәрбияче:** безнең вакытта аулак өй утыру һәм күңел ачу урыны гына түгел иде. Мондый кышкы, озын кичләрдә авыл кызларының кул эшендә никадәр талантлы булуларын тикшерәләр. Кызлар барысы бергә булачак кәләшләр өчен бирнә әзерләгәннәр.

**Өченче бала:** бирнә нәрсә ул?

**Әби:** бирнә - бу кыз өчен олы тормышта кирәкле чигелгән әйберләр. Менә сезнең алда минем сандыгым *(әби сандыгын ача һәм әйберләрен күрсәтә).*

Бу минем алъяпкычларым, сөлгеләрем, яулыкларым. Карагыз, ашъяулыкта матур чәчәкләр, аккошлар һәм үсемлекләр чигелгән. Татар кызларының алъяпкычлары һәрчак игүтибарны үзләренә җәлеп итәләр. Воланнар белән тегелгән күлмәк шулай ук татар кызының милли бизәге булып тора. Егетләр үзләренең түбәтәйләрен хөрмәт иткәннәр.

**Тәрбияче:** мин түбәтәйне күрдем һәм шунда ук аулак өйдәге уенны искә төшердем, ул «Түбәтәй»дип атала.

*(Музыка астында түгәрәктә торган балалар түбәтәйне кулдан кулга тапшыралар. Җыр туктагач, кулларында түбәтәй калган бала биремне үтәргә тиеш (җыр җырларга, биергә, көлкеле табышмак сөйләргә һ.б.)).*

Ерактан килдем,
Түбәтәйне кидем.
Барысын да
Гаҗәпләндерергә теләдем!

Түбәтәй, түбәтәй,
түбәтәйдә матурлык –
Менә кемнең түбәтәе бар
Без шунарда тукталдык.

**Әби:** ә менә шушы көянтә белән мин чишмәгә су алырга бара идем *(татар көйләре әкренләп башкарыла кызлар «Каз канаты» биюенә чыгалар).*

**Әби:** безнең яшь вакытлар кайда соң? Мондый утырышларда без күңелле уеннар үткәрдек: «Челтәр элдем читәнгә», «Тәгәрәшле», «Йөзек салыш» һ. б.

**Икенче бала:** Әйдәгез, сезнең белән «Йөзек салыш»уенын үткәрик. Ризамы?

Балалар әйләнә буйлап матур итеп утыралар. Уен җитәкчесе кулында яшеренгән йөзекне аларның учларына салырга тиеш. Ул һәр катнашучының кулларына кагыла һәм бөтен түгәрәкне әйләнеп чыга. Берәрсе янында ул тоткарлана. Башкалар алып баручының тәртибен, аның ишарәләрен күзәтеп, йөзекне кем алганын билгеләргә тиеш.

Катнашучылар арасында йөзекне алмаганнан соң, алар аны алганнарына ишарә итүчеләр дә булырга мөмкин. Уен ахырында алып баручы түгәрәкнең үзәгенә баса һәм «Йөзек алучы капка янына чык!» дип дәшә.

Йөзек хуҗасы түгәрәкнең үзәгенә йөгерергә тиеш, ә башка балалар аны тотарга тырышалар. Әгәр дә йөзек алган бала алып баручыга кадәр йөгерә алса, ул үзе бу рольне башкара.

**Беренче бала:** Әйдәгез уенны тагын бер тапкыр кабатлыйк!

**Әби:** ә хәзер мин сезгә тагын бер кызыклы уен тәкъдим итәм, бу һәркем өчен күңелле булыр иде.

Уен «Кызыклы сикерү» дип атала.

Зал уртасында диаметры 25 метрга кадәр булган түгәрәк билгеләнә. Зур түгәрәк эчендә һәр катнашучы өчен кечкенә түгәрәкләр (диаметры 35 см) билгеләнә. Зур түгәрәкнең үзәгендә җитәкче тора.

Җитәкче сикерү өчен старт бирә. Бу сүзләрдән соң, уенчылар бер аякта сикергәндә урыннарын алыштыралар. Бу вакытта җитәкче берәр уенчының урынын алырга тиеш, ул шулай ук аяк төбендә сикерә. Кем урынсыз калса, ул җитәкче була. Ике уенчыга бер түгәрәктә булу тыела. Бер-береңне түгәрәктән этеп чыгарырга ярамый.

**Әби:** сез нинди акыллы, тырыш һәм җитез! Сез барыгыз да тиз, кыю һәм акыллы!

**Малайлар:** кызлар сез безгә бик матур бию күрсәттегез, әйдәгез хәзер бергә биибезме? *(балалар «Аулак өй» парлы биюен башкаралар).*

Тарала моңнар урамга кайда бүген аулак өй?
Аулак өйдә туган сөю – гомерлек ул аулак өй.
Сагынып сине искә ала әби-бабай аулак өй-
Яшьлекнең иң гүзәл чагы булып истә калган өй!

Аулак өй, аулак өй, әй аулак өй, аулак өй
Уйната да, җырлата да, биетә дә аулак өй!
Аулак өй, аулак өй, әй аулак өй, аулак өй-
Аулак өйгә йөрмәгән кыз, егет күңелен яуламый!

Әби: безнең балаларыбыз нинди җитез!

*(Яшьлеген искә төшереп, балалар белән бии башлый).*

**Тәрбияче:** сез ничек яхшы, җиңел һәм матур биисез әби. Менә сезгә кунаклар бездән күчтүнәч *(йомыркалар өләшә).*

Аннан соң «Йомырка салыш»уены үткәрелә. Балалар кашыкларга йомырка салалар һәм бер-берсе белән ярышалар *(авызларда кашыклар белән йөгерү).*

Балалар ярымтүгәрәк булып тезеләләр.

**Беренче бала:**

Без бик күңелле вакыт үткәрдек!

Хуҗаларга рәхмәт әйтик.

Күчтүнәчләрне кесәгә салыйк,

Барыбыз да өйгә кайтыйк!

**Икенче бала:**

Очрашу бик тату үтте,

Җырладык, биедек, уйнадык.

Безнең белән күңел ачмаган кешеләр

Күп нәрсәне югалтты.

**Әби:**

Һәрвакыт дус булыгыз,

Күңелле һәм күркәм яшәгез.

Кайгы сездән китсен

Бәхет озакка килсен!

**Тәрбияче**: барысы ничек кызык үтте, әбиебез үзенең бәхетле һәм күңелле яшьлеген искә төшерде. Бу бәйрәмне үткәрүебез яхшы. Бу очракта без традицияләребезне югалтмыйбыз, аларны дәвам итәчәк һәм арттырачак буын бар! Рәхмәт сезгә балалар!

Балалар: рәхмәт сезгә. Безгә китәргә вакыт. Сау булыгыз!

**Җыр: «Без бәхетле диябез».**

***"Бирнә җыю" йоласы***

***Гайфиева Гөлүзә Тимерхан кызы***

*"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Кызыл-Мишә "Акчәчәк"балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе"*

**Бурычлар:** Балалар бакчасында балаларны милли тәрбия бирү, гореф-гадәтләр белән таныштыру.

Бирнә" жыю" бәйрәм турында күзаллауларын киңәйтү, анда катнашырга теләк тудыру. Халык бәйрәмнәре аша балаларга милли рух, күңел күтәренкелеге, шатлык хисләре тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Спорт мәйданчыгы бәйрәмчә төрле төстәге шарлар, чигелгән сөлгеләр белән бизәлә.

**Алдан эшләнгән эш:** Татар халык бәйрәме Сабан туй турында тулы мәгълүмат бирү, шигырьләр, җырлар, биюләр өйрәнү, алдагы көнне барлык төркем балаларын бәйрәмгә чакыру.

**Бәйрәм барышы:** Тантаналы көй астына балалар чыга.

**Алып баручы:**

"Сабантуй бәйрәме –дуслык бәйрәме ул"

Сабан туе көч сынашу, күңел ачу бәйрәме.

"Сабантуй" дигәндә кемнең дулкынланмый йөрәге!

Тайлар йөгәнләдеңме, атлар иярләдеңме?

"Сабан туе" җитә диеп, бүләк әзерләдеңме?

**Алып баручы:**

Авыл халкым минем, Кызыл-Мишә халкым

Изге җирем, газиз Ватаным !..

Бүгенгеңне синең аңлар өчен

Үткәннәргә барып кайтамын.

**Алып баручы:**

Кызыл - Мишә дигән авылым бар,

Татар дигән халкым бар минем.

Узганнардан түгел, мин халкыма

Киләчәктән урын барлыймын.

**Сәхнәгә "Сабантуй" җырын җырлап бер төркем егет - кызлар керә**

1)Бүген бездә Бирнә җыю бәйрәме-

Биибез дә җырлыйбыз

Җырлап-биеп куанышып

Сабантуйны зурлыйбыз.

Сабантуй, сабантуй,

Чәчү беткән кырларда.

Яңа җырлар өйрәндек без

Сабантуйда жырларга.

Тыпыр-тыпыр тыпыр-тыпыр,

Тыпырдашып басабыз.

Бирнә җыю - ул шундый бәйрәм,

Бергә күңел ачабыз.

- Сабантуй илдә! Сабантуй! Йоклап калучылар юкмы?

- Сабантуй – ул дуслык бәйрәме.

-Сабантуй – ул татар халкының көтеп алган изге бәйрәме!

**Бергә: Котлы булсын Сабан туйлары!**

- Хәерле көн абыйлар,

Хәерле көн апалар!

Хәерле көн егет-кызлар

Барча-барча авылдашларлар!

- Бәйрәмгә бирнә җыярга

Кузгалдык әле бергә.

Бүләкләрнең иң затлысы –

Сабантуй батырына.

Яшь кызлар, яшь киленнәр, сөйкемле апалар! Сездән сабантуйга бүләк көтәбез!

*Каршыга чигүле сөлге тотып* **Алсу** *чыга:*

- Бәйрәмгә дип әзерләнгән чигүле сөлгем менә

Бүләгемне тапшырырсыз көрәштә җиңүчегә.

**Бергә: Рәхмәт яусын! Рәхмәт яусын!**

Балалар бергә:

Түтәйләр,түтәйләр,

Чыгарыгыз күкәйләр

Безгә бирсәң бер күкәй

Тавыгыгыз салыр йөз күкәй

*Бер чиләк йомырка тотып* **Рамилә** *керә:*

- Сабантуйга бирнә җыясыз икән. Минем дә бүләгем бар. Бәхетегез шушы йомыркалар кебек түгәрәк булсын.

***Бергә:*** **Рәхмәт яусын! Рәхмәт яусын!**

**Рамилә***:*

- Ә минем бүләгем – чигүле кульяуык! Җиңүчегә!

- Әй, бүләге дә, бүләге

Бигрәк затлы, карале.

Бүләкләрне котлап без дә

Бер биеп алыйк әле.

***Татар халык биюе***

“**Кәләпүшем, калфагым” җыр**

Самир:

- Бабайлар һәм әбиләр,

Абыйлар һәм апалар!

Әниләр һәм бәбиләр,

Әтиләр һәм энеләр!

Алсу:

Сабантуйга килегез!

Җырлап-биеп, уйнап-көлеп

Бергә бәйрәм итәрбез!

Сабантуйга килегез!

***Бергә:*** **Сабантуйга килегез!**

Менә, дуслар, көтеп алынган “Бирнә җыю” бәйрәме тәмам. Алда Сабантуй бәйрәме. Киләсе елга да Сабан туйларында очрашырга язсын. **Бергә: Сау булыгыз! Сабантуйга килегез!**

***Күңелле йола -“Сөрән җыю”***

***Дәминова Ясминә Мәүлет кызы.***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*“Катнаш төрдәге Балтач 1 нче балалар бакчасы”*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

Зал бизәлеше: түрдә матур итеп бизәлгән авыл йортының эчке күренеше. Өстәлә самавыр, чәй табыны. Өстәл артында Әби кунакка кайтасы оныгын көтеп утыра.

**Әкрен генә гармун тавышы яңырый.**

**Зәйнәп апа**: Бүген авылыбызда зур бәйрәм-Сөрән җыю. Бик күңелле борынгыдан килгән бәйрәм шул. Яле, чәйләремне яңартыйм, алма бөртегем сеңлем дә, кайтып җитәр.

(Кыз керә, апасы белән күрешәләр)

**Кунак кыз**: Әбекәй, әбекәем, өйдәме син, мин кайтып җиттем. Кара әле, әбием, бөтен авыл халкы капка төбендә, (гармун тавышы яңгырый), ишегалларында табын әзерләнгән. Берәр төрле бәйрәмме эллә авылыбызда?

**Зәйнәп апа**: И-и-и кызым, син бик уңышлы кайттың. Бүген авылыбызда борынгы йола-Сөрән җыю бәйрәме.

**Кунак кыз:** Нинди бәйрәм соң ул, апам? Нәрсәне аңлата?

**Зәйнәп апа**: Сөрән җыю-борынгыдан килгән йола. Сабантуй бәйрәменә бүләк җыюны аңлата. Өй саен кереп. Бүләк җыюны сөрәнгә чыгу. Сөрән җыю дип атаганнар. Кичен авыл яшьләре болынга, ягъни сабан туе буласы урынга кичке уенга җыела.

Егетләр-кызлар татар халкының җырлы-биюле уеннарын, “Назлы”, “Биш парлы”, “Балыкчы”, “Капкалы”, “Биеп алышлы”, “Каешлы” һәм башка уеннар уйныйлар. Аннан инде, кызым, сөрән җыю башлана. Сөрәнче-сабан туена бүләк җыючы булган. Сөрән җыючы егетләр башларына түбәтәй. Аякларына киез итек, ак күлмәк, кара чалбар киеп, билләренә чиккән сөлгеләр, кызыл төстәге билбау кичке мәҗлестән кичке уенга киләләр. Авыл халкы ишек алдына табын әзерли. Табынга буялган йомыркалар, татар халкының милли ризыклары куела. Һәр йортның хуҗабикәсе сабантуйга бүләк чыгара торган булган. Хуҗалар сабантуйга биргән бүләкләрен колгага бәйләп куйгач бүләк җыючы егетләр: “Сабантуйга, Татарстан бәйрәменә биргән бүләкләрегез өчен, ура. Ура, ура!-дип рәхмәтләрен белдерәләр.

**Зәйнәп апа**: Апам, бигрәк матур, күңелле йола бит бу. Әйдә, без дә сөрән җыюны карыйк әле.

Зәйнәп апа белән кыз Сөрән бәйрәмен карарга китәләр (чыгып китәләр).

*Залга сөрәнчеләр-колга тоткан егетләр керә.*

*“Алмагачлар” көенә такмаклар җырлап керәләр.*

Сөрән җыю бик күңелле,

Бәйрәм шул бүген бездә.

Күңелле булсын сезгә дә,

Җырлыйбыз бергә-бергә.

**1 бала**: Шатлыклар-күңелебездә

Ал кояш-күгебездә.

Килегез дуслар, кунакка,

Сабантуй бүген бездә!

**2 бала**: Җилферди чиккән сөлгеләр.

Бүләкләр-күгебезгә.

Көрәшик тә, узышыйк та –

Сабантуй бүген бездә!

**3 бала**: күңелле сөрән җыюлар,

Бүген бәйрәм, зур бәйрәм.

Сөрән җыю-борынгы йола,

Уйныйбыз әйлән-бәйлән.

*Чабата биюе.*

**4 бала**: Әй егетләр, егетләр, кызлар килә түгелме?

*Көянтә биюе (кызлар керә)*

**Егетләр**: Исәнмесез кызлар,

Һавадагы йолдызлар.

*(кызлар белән кара-каршы басалар)*

**Кунак кыз**: Бигрәк күңелле икән

Буслар җыелган җирдә

Ягез әле, уйнап алыйк,

Бер халык уенын да.

*Татар халык уен җыры "Эх зилем-зиләм"*

1)Җитәкләшеп, тезелешеп,

Без урманга барабыз.

Урманда яшел аланда

Җырлап-биеп алабыз.

Кушымта: Эх, зилем-зиләле,

Сандугачым кил әле,

Кил әле дустым кил әле

Бергә әйләник әле.

2)Кояшлы матур аланда

Гөлләр чәчәк аталар.

Тирә-юньгә ямь матурлык

Хуш исләр тараталар.

Кушымта: Эх, зилем-зиләле,

Сандугачым кил әле,

Шушы матур аланда

Икәү әйләник әле.

**Кунак кыз**: Бигрәк матур сөлгеләр, кулъяулыклар. Барысы да кулдан чигелгән, ләбаса.

**1 кыз бала**: Әйе, Динә, яшь киленнәр сөрәнгә бик матур чигелгән сөлге, ә яшь кызлар күз явын алырдай итеп чигелгән кулъяулык биргәннәр. Алай гына да түгел, һәр йортта 15 яшьлек кызның чигелгән кулъяулыгы булырга тиеш. Ул аны сөрәнчеләр арасындагы бер егеткә атап бирергә тиеш.

**2 кыз бала**: Яшь киленнәрдән алган сөлге иң кыйммәтлесе булып саналган. Килен аны шушы йоланы истә тотып, үзенең бирнәсендәге иң матур бизәкле сөлгедән әзерләгән.

**1 бала**: Әйдәгез, сөрән җыюны дәвам итик.

*(Зәйнәп апа чыгып утыра)*

**Балалар такмаклар җырлап әйләнәләр.**

1.Сөрән җыю бик күңелле,

Бәйрәм шул бүген бездә.

Күңелле булсын сезгә дә,

Җырлыйбыз бергә-бергә.

2.Алмагачым чәчәк ата

Майның унбишләрендә

Шул алмагач чәчәге күк

Минем дус-ишләрем дә.

*Егетләр Зәйнәп апа янында туктыйлар.*

Зәйнәп апа каршы ала. Кулында сабантуйга бүләк, кунак кызның кулында кулъяулык, егетләргә бирә.

**Сөрән җыючы егетләр**: “Зәйнәп апаның Сабантуйга. Татарстан бәйрәменә биргән бүләге өчен, ура, ура! Ура! Ура!-дип рәхмәт әйтәләр.

**Егетләр**: Әйе шул.шулай шул,

Кунак кыздан кулъяулык

Биек икән тавыгыз,

Каршы ява карыгыз.

Без килдек тә кунак булдык,

Сабантуйга килегез.

**Кызлар**: Хуҗаларга рәхмәт әйтеп, яшь күңелне җилкендереп, әйдәгез, бер биеп алыйк.

**Татар халык күмәк биюе.**

**Кунак кыз:** (апасын кочаклап). Зәйнәп апам, бүгенге искиткеч матур, мәңге хәтердә калачак бәйрәмне-Сөрән җыюны мин үземнең дусларыма да сөйләрмен.

Халкымның гореф-гадәтләре, йолалары онытылмый, бәйрәмнәрнең рухы безнең каныбызда яшәр!

**1 бала:** Чал тарихлы горур кешеләр без,

Тынмас моң бар безнең каннарда

Ата-бабай мирас иткән сымак

Дәвам итәр юлын без барда.

**2 бала**: Онытылган гореф-гадәтләрне

Күңел янә яңартсын.

Уен йолалары, җыр-биюе,

Һәр киләчәк көнне бизәсен.

**Җыр: "Сабантуй".**

1.Сабан туенда гына

Була гаҗәп ярышлар:

Ат чабышы, чүлмәк ватыш,

Җыр ярышы, аркан тартыш,

Кул көрәше, таяк тартыш,

Тәңкә табу, капчык сугыш.

Иң кызыгы, иң кызыгы

Көрәш, көрәш барышы.

2.Сабан-сабан-сабантуе

Уйнап -көлеп, җырлап-биеп,

Гөрләп килә Сабантуй!

Гөрләп килә Сабантуй!

***Җеп эрлибез бергәләп***

***Шәйдуллина Ләйсән  Рәфкать кызы.***

*Татарстан Республикасы Биектау районы “Сандугач”*
*Катнаш төрдәге балалар бакчасы  мәктәпкәчә*
*белем бирү муниципальбюджет учреждениесе*

**Кереш**

Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре, йолалары  була. Татар халкында да алар бик күп. Без үзебезнең “Җеп эрлибез бергәләп ”  дигән музыкаль  театраль сценарийбызны әзерләдек. Балаларны  татар халкының гореф –гадәтләре, йолалары белән таныштырасыбыз килде.

Татар халкының милли бәйрәмнәре балаларга тәрбия бирүдә бик зур чара булып тора, алар борынгы заманнарда да булган. Шул йолалар ярдәмендә балалар күңелендә туган теленә,  жиренә, халкына  мәхәббәт, өлкәннәргә мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләнә. Милләтебезнең  гореф-гадәтләре, тормыш-көнкуреше балаларны кешелекле, шәфкатьле булырга өйрәтә.

Әлеге йолаларны күреп  үскән балалар киләчәк буыннарга да ана телен саклап калырга, милли хәзинәбезне онытмыйча, гомер буена үз милләтенә тугъры калырга ярдәм итәр дип ышанабыз.

**“Җеп эрлибез бергәләп”.**

**Максат:** Онытылып барган татар йолалары аша хезмәт сөючәнлек тәрбияләү,тормышта һөнәрнең мөһим икәнлеген аңлату.

**Бурычлар:**

1.Татар халык йолаларының, гореф- гадәтләренең әһәмиятен балалар күңеленә төшендерү.

2.Балаларның иҗади активлыгын камилләштерү һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

3.Эстетик тәрбия бирү,татар милли сәнгатенә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Авыл өе, түрдә мич, ипи көрәге, сәке ,анда чигелгән мендәрләр, йон кабасы, орчык, сандык, өстәлдә самавыр тора.

Сәке янында үз үзе белән сөйләшеп ана йон эрләп утыра.

**Әни** : -Эх,бар иде бит безнең дә яшь чаклар! Өмә ясап җеп эрли идек, анда егетләр-кызлар була иде. Уен-көлке, җыр- бию, такмаклар әйтешә идек. Өйгә кыз килеп керә

**Айзиля :** Нишләп үз –үзең белән сөйләшеп утырасын, әнием?

**Әни**: Әй кызым,яшь чакларны искә алып утырам әле.

**Амалия** :Әнием,сезне алма апалар кунакка чакырды, барасызмы?

**Әни :** Чакырган җиргә барабыз,кызым,барабыз.

**Амалия:** Сез кунакка киткәч, кызлар белән җеп эрләү өмәсе ясап алыр идек...

**Әни:** Бик әйбәт булыр, кызым. Бергә-бергә эшләгәндә, эш тә тиз эшләнә. Хәзер әтиеңә генә әйтим дә...

**Амалия**: Кызларга әйтергә барам,

Барысы да килсеннәр.

Бездә аулак өй икәнен

Егетләр дә белсеннәр

**Азалия:** Йон тетәрбез, җеп эрләрбез,

Кайсыбыз камыр изәр.

Егетләрне дә чакырыйк.

Гармунда уйнар Хәлил.

Кыз чыгып китә.Залның бер почмагында кызлар тора. Кыз аларның янына килә.

**Амалия:**

Кызлар, килегез безгә,

Орчык бәйрәме ясыйк.

Егетләр килә башласа

Барыбыз бергә качыйк.

**Элина:** Кызлар: Әйдәгез, барабыз! Барабыз!

**Айзиля:** Рәхмәт инде,дускаем,

Безне чакырган өчен.

Көне буе ял иттем,

Юкка китмәстер көчем.

**Амалия:** Өмә ясыйк әле бүген,

Әтиләр өйдә юкта.

Кызлар исемлеген төзик,

Санап куйыйк орчык та.

(Бергәләп җыелгач, күмәк эш башлана:кемдер йон яза, кемдер йомгак чорный, кемдер бәйли)

(Гармун уйнап егетләр килә).

**Талия**: Егетләр килә! Качабыз.

**Сәидә:**Эзләсеннәр әле безне,

Бар җирдән карасыннар.

Безнең санны белер өчен

Орчыклар санасыннар.

Кызлар качалар. Егетләр керә.

Егетләр: Исәнмесез, кызлар! Кая соң үзләре?

**Рамир**: Орчыклары монда,үзләре дә ерак түгелдер.Орчыкларын саныйк әле, ничә кыз бар икән?

**Әмир**:Берәү, икәү,өчәү,дүртәү,

Барысы бергә сигез.

**Шамиль** :Эрләгән йомгакларының

Зурлыклары бертигез.

**Хәлил:**Кызлар,чыгыгыз инде!

( Кызлар чыгалар.)

**Рамир:**Җепләр эрлисез икән,

Эшләрегез уң булсын.

Оекбаш, бияләй белән

Мич башларыгыз тулсын.

**Талия:**Ярышып җепләр эрләдек,

Бөтерелде орчыклар.

Алып килгән йоннар бетте,

Бушап калды капчыклар.

Кызлар,әйдәгез егетләрне тапкырлыкта сынап карыйк.

Аларга табышмаклар әйтик.

**Сәидә:**

-Әйләндергән саен калыная (Йомгак)

-Зыр-зыр әйләнә,үзе килеп бәйләнә(Орчык)

Алим:Әйдәгез кызларны да  мәкаль әйтеп сынап карыйк.

**Кызлар бергә.**Без риза, әйдәгез.

-Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

-Илнең күрке –тынычлык

-Икмәк-тормыш нигезе

-Балалы кеше-бай була

-Гаилә -бәхет ачкычы

**Айзиля:**Егетләр, кызлар, әйдәгез җырлап биеп алабыз.

“Зәңгәр чәчәк” җырлы-биюле уен

Уйнау тәртибе

Балалар, кулга кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар.Бер бала чигүле кечкенә мендәр тотып,уртага чыгып баса.Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:

Юл читендә зәңгәр чәчәк

Якты нурлар тарата.

Безнең кызлар һәм малайлар

Зәңгәр чәчәк ярата.

Туктап биеп-җырлап торалар,ә уртадагы бала, мендәр тотып,түгәрәк буенча биеп йөри.

Якын дуслар арасыннан

Берсен сайлап ал әле.

Тезләнергә ипле булыр-

Мендәреңне сал әле.

Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, аңа тезләнеп, кулын бирә.Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.Уен алга таба шулай дәвам итә.

**Айзиля:**Җырлап –биеп күңел ачтык,

Күңелле булды кичә.

(Әни белән әти кайтып керәләр.)

**Әни** Йә, ничек утырдыгыз?

**Талия:** Вакытның үткәнен сизми дә калдык.Әйдәгез хәзер бергәләп чәй эчеп алыйк,үз күчтәнәчен белән чәй эчсән озын гомерле буласын дип әйтәләр бит.

***Сөннәт боткасы***

***Гыйләҗетдинова Ләйсән Марсел кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Биектау «Көнбагышкай» балалар бакчасы», мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** балаларны борынгыдан килгән гореф-гадәтләр, йолалар белән таныштыру, кызыксыну уяту.

**Бурычлар:** - диалогик һәм сөйләм телен үстерү

- хөрмәт итү, горурлану хисен тәрбияләү
- җырлар өйрәнү
- әти-әниләрнең бергәләшеп сценарий куюда ярдәм итүе.

**Җиһазлау:** сандык, чиккән сөлгеләр, самавыр, бишек, милли ризыклар

**Алдан эшләнгән эш :** «Сөннәт боткасы» темасына әңгәмә үткәрү. Халыкның башка төрле йолалары, гореф- гадәтләре белән таныштыру. Татар халык милли биюен өйрәнү. Җыр өйрәнү.

**Катнашучылар:** әби, бабай, әти, әни, малай, кыз.

**Чараның барышы.**

*Авыл өе күренеше. Түрдә бишек. Кыз аны тирбәтә. Бер кырыйда тәрәзә янында әби бәйләм бәйли. Өстәл янында малай китап карый.*

**Әби.** (*тәрәзәгә карап*) Кызым, кунаклар килә, әйдә каршы ал. (*Кунаклар керә*).

**Кунаклар.** Исәнмесез!

**Әби:** Исэнмесез, кадерле кунаклар, әйдәгез, түрдән үтегез!

**1 кунак:** Өегезгә нур өстәп шатлыклы зур бәхет килгән сөенечегез белән котлыйбыз.

**2 кунак:** Нәсел агачын дәвам итүче улыгыз нык билле, дәү, таза, тәмле сүзле, шат йөзле, үткен күзле, бәхетле, акыллы үссен.

**3 кунак:** Улыгыз шук та булсын, ут та булсын.

**Әби:** Һай, бигрәк матур теләкләр теләдегез. Теләкләрегез фәрештәләрнең “Амин” дигән чагына туры килсен!

**Әти-әни:** Бик зур рәхмәт сезгә, улыбызны зурлап килгәнегез өчен.

**Әби:** Бүген бездә зур бәйрәм - оныгыбызнын сөннәт боткасы. Шуңа атап ясалган махсус бәлеш белән сыйланырга зур бәйрәм өстәленә рәхим итегез! (*Өстәл тирәли утыралар*).

**Бабай:** Ә сез беләсезме бәйрәмнең ни өчен "сөннәт боткасы" дип аталганын? Гаиләдә малай туганнан сон, мөселманнарга хас булганча, аны 7 көн үткәч сөннәткә утырталар. Шуннан соң аны котлап туганнар жыела һәм үзенчәлекле ботка – "сөннәт боткасы" пешерелә. Ул ботка карабодайдан ясала, жимешләр һәм йөзем кушыла. Аны камыр жәеп, астына корт салып өстенә шул ботканы салып каплап пешерәләр. Килгән кунаклар өстәл артына утыргач, сөннәт боткасына багышлап дога укыла.Укып бетергәннән соң, бала исән сау гына терелсен дип эти-әнисе хәер тараталар. Әйдәгез әле сез дә авыз итеп карагыз. (*Әни кеше сөннәт боткасын алып чыга*). Килгән кунаклар, рәхмәт әйтеп, шул ботканы ашыйлар.

**Әби.** Балалар, кунакка килгәч, күңелсезләнеп утырмыйлар. Әйдәгез бер күңел ачып алыйк. Улым, кызым сездән башлыйк. Менә инде зур кеше – абый һәм апай кеше булдыгыз.

**Малай:** Шигырь сөйләп күрсәтимме?

Шатлыклар куңелебездә,
Ал кояш – күгебездә.
Рәхәтләнеп бәйрәм итик
Гаилә бәйрәме бездә.

**Кыз:** Бәйрәмебез гөрләп утсен,
Истә калсын гомергә
Бәйрәмнәрсез яшәп булмый
Җирнең якты йөзендә…

**Әти:** Матур җырлар өзелмәс,
Шатлык өстәр гармун да
Күмәк бию, уен-көлке,
Кызык булачак монда.

Әйдәгез, бер җырлап, биеп алыйк әле.

***Жыр: "Балама"***

Сагынганда балам күккә кара,
Якты кояш булып балкырмын.
Өшегәндә сине нурым белән
Жылытырмын, сөеп кочармын.
Арыганда балам җилләр булып,

Чәчләреңнән сыйпап үтәрмен.

Күлмәгеңне синең җилфердәтеп,

Әкрен генә арттан этәрмен.

Моңсу гына яшьләр түккән чакта,

Җылы яңгыр булып явармын.

Күкрәгемә кысып, битләреңнән үбеп,

Юатырмын сине, назлармын.

Адашканда болытларга кара,

Ак болытлар булып йөзәрмен.

Изге сукмаклардан юл күрсәтеп

Зәңгәр күкләр булып агармын.

Елга буйларында басып торсаң.

Дулкын булып сиңа йөзәрмен.

Нәни чакта кебек аягыңны

Йомшак сулар белән юармын.

Моңсу гына яшьләр түккән чакта,

Жылы яңгыр булып явармын.

Күкрәгемә кысып, битләреңнән үбеп,

Юатырмын сине, назлармын.

Хәсрәтеңне куып, изге дога кылып,

Тормыш бәхетләре теләрмен.

*“Күмәк бию”*

**Әни**: Бүгенге бәйрәмебезгә нур өстәп килгәнегез өчен рәхмәт сезгә, кадерле кунаклар! Хәзер аш-су озату догасын укып, алып килгән күчтәнәчләрегез өчен дога кылып алыйк. Борынгыдан килгән мондый гореф-гадәтләребез онытылмасын иде.

*Хуҗаларга рәхмәт әйтеп кунаклар таралышалар.*

***Аулак өй***

***Шәрипова Мәүлидә Илфер кызы***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы «Курсабаш «Кояшкай» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Алып баручы**. Һәрбер халыкның үзләренә генә хас милли бәйрәмнәре бар. Күп кенә шундый бәйрәмнәр элекке заманнарда ук – берничә йөз еллар элек барлыкка килгән дисәң дә була. Авыллар, шәһәрләр, әйберләр, һөнәрләр һәм табигать үзгәрә, ә милли бәйрәмнәр яшәүләрен дәвам итәләр. Татар халкының милли бәйрәмнәре табигатькә, гореф-гадәтләргә, кешеләрнең бер-берсенә хөрмәт хисе һәм ихтирамы белән сокландыралар.

Бүген сезнең игътибарга милли традицион «Аулак өй» бәйрәменең өзеген тәкъдим итәбез.

Татар халкы торган кайбер төбәкләрдә борынгы заманда «Аулак өй» бәйрәмнәре уздырылган. Алар кыш җиткәч башланганнар. Бер өйдә яшьләр җыелып, үзләре белән кул эшләре алып килеп, җыр, бию, такмаклар әйтеп күңел ачканнар.

*(Зал бәйрәмчә бизәлгән – стенада чиккән сөлгеләр,өстәлдә самовар белән чынаяклар, урындыкта йон эрли торган каба . Бер кыз йон эрләп утыра, шулчак ишек шакыган тавыш ишетелә. Малайлар белән кызлар керә).*

**Малай.** Исәнмесез, саумысыз!

Нигә кәҗәгезне саумыйсыз?

Әтәчегез күкәй салган

Нигә чыгып алмыйсыз?

**Кыз.** Эй, Әпсәләм, Әпсәләм!

Сәлам бирдем Әпсәләм.

Синнән безгә тиештер бит

Вәгаләйкемәссәләм!

**Малай.** Исәнмесез, дусларым!

Хәерле кичләр булсын!

Уен – көлке, җыр моңнан

Күңелләребез тулсын!

**Кыз.** Бүген сездә аулак өй дип

Дусларымнан ишеттем,

Йомгагымны чорнарга дип

Мин сезгә килеп җиттем.

**Кыз.** Бүген бездә аулак өй,

Яңгырасын матур көй.

Биик – җырлыйк, уйныйк – көлик,

Гөрләп торсын безнең өй,

И-и күңелле аулак өй.

*(Бер малай гармунда көй уйнап ала, аннары икенче малай җырлый. Җыр «Эй бии итек читекләр»)*

**Кыз.** Дусларым, әйдәгез уйныйк - көлик, җырлыйк – биик, күңел ачыйк. Тик иң әлек аулак өебезнең зирәген белик, малайларга сораулар бирик, ә алар җавап бирсеннәр.

Бөтен татар өендә бар,

Үзе дөньяда бер генә. (Казан)

**Кыз.** Нинди шәһәр суда йөзә? (Алабуга)

**Кыз.** Кемнең аяклары колакларына урнашкан? (Чикерткә)

**Кыз.** Чәйне ник эчәләр? (Ашап булмаганга)

**Кыз.** «Җ» белән – ел вакыты,

«Ч» белән – сыеклык. (Җәй, Чәй)

**Кыз.** Стакан төбендә нәрсә бар? («Н» хәрефе)

**Кыз.**Чәйнең уртасында ни бар? («Ә» хәрефе)

Булдырасыз егетләр, молодцы!

**Кыз.** Егетләргә бер җырлап күрсәтик әле.

*(Җыр «Ал чия төпләрендә»)*

**Малай**. Сандугачның балалары,

Талга кунганнар икән.

Кызларыбыз бигрәк чибәр,

Бигрәк уңганнар икән.

*(Ике кыз биеп килеп, ике малайга басалар, аннары парлап биеп китәләр. Парлы бию бииләр)*

**Кыз**. Әйдәгез, уеннар да уйнап алыйк. «Чума үрдәк, чума кыз» ны уйнап алыйк.

*( «Чума үрдәк, чума каз» уены уйнала.*

*Чума үрдәк, чама каз,*

*Чума үрдәк, чума каз,*

*Тирән күлне ярята шул, ярата,*

*Тирән күлне ярата шул, ярата,*

*... үзенә иптәш эзли,*

*Белмим кемне ошата?*

*... ошата шул, ошата,*

*... ошата шул, ошата.*

*Җыр кабатлана, исемнәр үзгәртелә)*

**Кыз.** Әмир синең түбәтәең бигрәк матур, үзеңә килешеп кенә тора. Бу түбәтәйне күргәч, «Түбәтәй» уены искә төшеп тора, уйнап алабызмы?

*(«Түбәтәй» уены уйнала. Уен барышында түбәтәй кемдә кала, шул бала җырлый, бии, сикерә, әтәч булып кычкыра һәм башкалар.*

*Түбәтәеңне кигәнсең,*

*Бик ераклардан килгәнсең,*

*Төскә матурлыгың белән*

*Шаккатырыйм, - дигәнсең.*

*Түп – түп – түбәтәй,*

*Түбәтәең укалы.*

*Чиккән матур түбәтәең*

*Менә кемдә тукталды).*

**Малай.** Ах, бигрәк ардырды, бераз ял итеп алыйк.

*(Малайлар утырып торалар. Салмак кына татар көе башкарыла, кызлар «Каз канаты» биюен биергә чыгалар)*

**Кыз.** Әйдәгез, «Капкалы» уенын уйнап алыйк.

Яңа утырткан капканың

Баганасы бик шома.

Капка эләктереп калмасаң

Элекмәскә чамала.

*(Уен «Капкалы». 10 пар җитәкләшеп зур түгәрәккә капка ясап басалар. Куллар өскә күтәрелгән. Көй башлануга арадан бер пар үзе теләгән капкага керә, алар урынына баса, әлеге пар икенче капкага бара. Көй туктауга капкага керә алмаган пар җәза ала).*

**Кыз.** Әйдәгез парлап биибез. «Челтәрле»не беләсезме?

*( Кара – каршы бию «Челтәр элдем читәнгә».*

*Челтәр элдем читәнгә*

*Җилфер – җилфер итәргә.*

*Без килмәдек буш китәргә*

*Килдек алып китәргә.*

*Алын алырсыз микән,*

*Гөлен алырсыз микән.*

*Урталарга чыгып сайлап*

*Кемне алырсыз икән.*

*Алларында алырбыз,*

*Гөлләрендә алырбыз.*

*Күңелебезгә кем ошаса*

*Шуны сайлап алырбыз).*

**Малай.** Йөрәкләрне җилкетә торган көй. Белмим ничек түзәргә.

*(Малай бии башлый)*

**Малай**. Бас, бас, катырак бас

Бии икән дисеннәр.

Безнең яшьләр табаныннан

Ут чыгара дисеннәр.

**Кыз**. Җитәр, җитәр уздырдың

Бикрәк тузан туздырдың.

Аягыңны шакылдатып

Колагымны тондырдың.

**Малай**. Әбиеңнең кәҗәсе

Бакчада кәбестәдә.

Биемәгәч, җырламагач

Мин монда нәмәстәгә.

(Малайлар бергә бииләр. Алга таба «Йөзек салыш» уены уйнатыла. Уен беткәч, малайлар һәм кызлар ярымтүгәрәк ясап басалар)

**Малай.** Таң атар, чыгар кояш

Әкренгә кузгалыйк.

Хуҗаларга рәхмәт әйтеп

Өйләргә таралышыйк!

**Кыз.** Уйнадык та, җырладык та

Бүген бездә аулак өй,

Аулак өйдә булмаганнар

Безнең күңелне аңламый.

**Малай.** Һәрвакыт күркәм булыгыз,

Авырмагыз беркайчан.

Кайгыларга бирешмәгез,

Шатлыклар йөрсен алдан!

**Кыз.** И-и кызлар, егетләр соңга калганбыз инде. Хуҗаларга рәхмәт әйтеп таралышыйк. Киләсе аулак өй чираты Азатларда була. Анда да шушылай күңелле итеп утырырбыз.

**Малайлар.** Бигрәкләр дә күңелле булды, рәхмәт сезгә. Безгә дә китәргә вакыт. Саубулыгыз!

*(Кызлар, малайлар башкарунда «Матур булсын» җыры җырлана)*

***Татар халык йоласы: “Кунаклашу”***

***Әхмәтшина Айсинә Хәмит кызы.***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Килдебәк “Кояшкай” балалар бакчасы” муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясы*

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар халкының гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте белән таныштыру.

**Бурычлар:** балаларда татарларның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, фольклоры һәм милли киемнәре турында белем һәм күзаллаулар формалаштыру;

балаларның кунакчыллык, чәйнең файдасы турында белемнәрен ныгыту, татар мәкальләре белән таныштыруны дәвам итү;

татар халык биюләре белән таныштыру;

татар халык биюләренең, музыкасының, киемнәренең матурлыгына уңай эмоциональ җавап тудыру; балаларда татар халкының гореф-гадәтләре белән танышуга кызыксыну уяту.

**Татар халык йоласының үткәрелү урыны:** музыка залы

Йоланын барышы:

*Балалар рус һәм татар халык костюмнарын кигән. Тыныч кына татар көе яңгырый.*

**Рус костюмында тәрбияче:**

-Кадерле балалар, сезгә мәгълүм булганча, безнең Татартсан респуликасында бик күп төрле милләтләр яши. Һәр халыкның үз мәдәнияте, үз гореф-гадәтләре, гореф-гадәтләре бар. Һәм безнең барыбызның да төрле гореф-гадәтләребезнең булуы бик яхшы. Үзебез өчен шулкадәр күп яңа һәм файдалы нәрсәләр белән танышканда, тормышыбыз никадәр кызыграк була бара. Без сезнең игътибарыгызга татар халкы мәдәниятенең аз өлешен тәкъдим итәбез. Кунакларны каршы алу һәм кабул итү гадәте теләсә кайсы милләт кешеләренә хас. Татар халкының кунакчыллыгы турында риваятьләр йөри. Безне бүген татар гаиләсенә кунакка чакырдылар : Асия апа һәм аның оныгы.

-Кунакка барабызмы?  Татарлар элек - электән бик игътибарлы, кунакларга карата кайгыртучан һәм әдәпле. Тәмле табын әзерләргә, төрле ризыклар белән сыйларга тырышалар. Кунакларны сыйлау гына түгел, бүләкләр дә бирү гадәте дә бар. Гадәт буенча кунак та шулай ук җавап кайтара. Әйдәгез без сезнең белән Асия апага һәм аның оныгына бүләкләр җыярбыз.

**Алия:** - Мин чигелгән сөлге алам.

**Алсу:** Мин-хуш исле сабын.

**Азат:** Ә мин рәсемле яулык.

**Күрше:** Ә мин үзем белән яңа табадан төшкән пәрәмәчләрне алырмын.

*Өй янына килеп җиткәч, татар киемендәге тәрбияче һәм балалар чыга, сөлгесенә чәк-чәк тоткан.*

**Хуҗабикә**: Исәнмесез, Айсинә Хамитовна! Исәнмесез балалар! (балалар исәнләшәләр).

**Күрше:** Иминлек телим сезнең өегезгә! (керәләр, бүләкләр бирәләр, кулларын кысалар, кулларын юалар, сөлгегә сөртәләр).

**Хуҗабикә:** Кунаклар килү ул - бик әйбәт.  “Кунакны яратмаган, шатлык һич белмәс “ - минем авылда шулай диләр. Үзеңне хөрмәт итүләрен теләсәң, икмәк-тозлы, ачык йөзле, юмарт бул. Бу синең мал-мөлкәтеңне югалтмас, бәлки, күбрәк тә итәр.

**Татар костюмындагы 1нче бала:** " Әгәр сый булмаса, кунакны сүз белән иркәлә. "

**Татар костюмындагы 2 нче бала:** “Кунакчыл булмаган кеше – кимчелекле кеше”.

**Татар костюмындагы 3 нче бала:** " **Сыйлаганда су эч** ", — дип өйрәтә татар халык мәкальләре.

*Барысы да өстәл артына утыралар, кызлар бер якта, малайлар икенче якта. Хуҗабикә чәй ясый.*

**Хуҗабикә:** Борынгы татар йоласы буенча, кунак хөрмәтенә бәйрәм ашъяулыгы җәеп, өстәлгә иң яхшы ризыклар-татлы чәкчәк, ширбәт һәм, әлбәттә, хуш исле тәмле чәй. Тәмле булсын чәйләрегез!

**Нәргизә:** Җиз самовар өстәл өсләрендә,
Сүрелгәнен күргән юк әле.

Иреннәрдән гомер китмәс инде
Алма – мәтрүшкәле чәй тәме.
**Әсхәт:** Чәй эчәм мин дә тәмләп,
Мәтрүшкәләп - үләнләп.
Чәйсез торалмыйм хәзер,
Иртә - кичен чәй әзер.

**Хуҗабикә:** Кадерле кунаклар, чәй турында нәрсәләр беләсез. Мин мәкальләр сөйләрмен, ә сез аны дәвам итәргә тырышырсыз.

-Чәй эчсәң-сәламәтлекне саклыйсың

-Чәй эчсәң, бәла-казаңны белмисең.

- Чәй авырттырмый, ә сәламәтлекне арттыра. Чәй эчмәсәң, кайдан көч аласың?

- Чәй арыганлыкны бетерә, кәефне күтәрә.

- Чәй эчү-яшәү рәхәт. Кайнар һәм каты чәйгә шикәрдән тыш сөт тә өстиләр. Әстерхан татарлары кайнар чәй эчәргә яраталар, аңа тоз, май һәм кайчакта кара вакланган борыч өстиләр. Тыңлагыз әле, малай Марат белән нинди вакыйга булды.

*Шаян күренеш*

Милли киемнән Марат исемле малай керә.

**Марат:**Исәнмесез, дусларым!

Сезгә бәйрәмгә килдем.

Исемем минем Марат!

Бабайның авылында

Миңа һәркем бик шат!

Мин Шаян, наян!

Менә нинди вакыйга

Булды минем белән!

Бабай чәй сатып алгач.

**Бабай**. Син аны пешерергә тиеш!

**Марат.** Ләкин мин бөтенләй белмим бит,

Грузин чәен ничек пешерергә?!

**Бабай.** Син бер чиләк су ал,

Чәйне тизрәк чүлмәккә сал...

**Марат.** Мин борыч, суган өстәдем

Һәм петрушка тамырлары

Кәсәләргә кайнатма салдым…

Яхшылап болгаттым,

Аны бераз суыттым…

Бабаема әзер чәй бирдем!

*Бабай (иреннәренә якын китереп, җыера, төкерә*)

Чәйдән соң эчендә

Бөтен нәрсә актарылды

Тизрәк ашык!

Докторны миңа чакыр.

**Марат.** Озак уйладым, гаҗәпләндем

Нәрсә дөрес эшләмәдем?!

Аннары аңладым

Чәйне онытканмын ... тозларга!

*Кунаклар көлешәләр*

**Хуҗабикә:** Безнең өстәлдә бүген татар халык ашлары күп: болар бәлеш, өчпочмак, самса, пәрәмәч, өлеш. Әйдәгез, татар халкының “Самовар” уенын уйныйбызмы? Балалар берәр тәлинкәгә татар ризыгы алып, түгәрәккә басалар. Уртада бала (самовар).

**“Самовар " уены**

Уен барышы: Берәр нинди сүзле татар көе астында балалар түгәрәк буенча баралар. Сүзләр беткәч, “Самовар” каршысында туктаган бала янына килә һәм кулындагы ризыкны табып ала.

Бөтен балалар сорый : «Тизрәк уйлап кара әле, нәрсә белән чәй эчәм? "

“Самовар” бала кулы белән күрсәтеп, милли бәлеш яки татлы ризыкны атый. Дөрес тапса, балалар парлап бииләр, дөрес булмаса, алып баручыны сайлыйлар. 2 тапкыр уйныйлар.

Там, там, тамчы там,
Тамуынны яратам,
Там, там, тамчы там,
Тамуынны яратам.
Самовардан темле итеп,
Чэй эчэрге яратам.

**Хуҗабикә:** Безнең өстәлдә иң тәмле ризык-татлы чәкчәк. Телисезме без сезгә чәкчәк турында татар экиятен сөйлибез? Ә сез безнең белән уйнап алыгыз (балалар басалар).

*Хәрәкәтле уен.*

Елга буендагы аланда яшәгән ди булган әби белән Бабай . (куллар билдә, балалар 5 тапыр чүгәлиләр)

Бабай белән әби чәк-чәк яратканнар. (эчләрен сыйпыйлар)

Хатын камыр баскан, Чәк-чәк тә пешергән, (балалар камыр баскан хәрәкәт ясыйлар)

Аны майга салган Һәм менә шулай калдырдым.(кулларын күрсәтәләр)

Чыкты ул алсуланып, матурланып.

Кояшка кады охшап. (битләрен сыйпыйлар)

Ул йөрергә теләде, әби белән бабайдан качарга уйлады (урында йөгерәләр)

Сукмак буйлап тәгәрәде, таралып бетте...(кулларны ике якка җәеп җибәрәләр)

Ой, балалар, чәк-чәк вак-вак кисәкләргә таралды! Әби-белән бабайга булышабызмы, чәк-чәк җыярбызмы?

*Уен*

Көй астына шарлардан төрле формада чәк-чәк ясыйлар: күбәләк, чәчәк, һ. б.

**Хуҗабикә:** Кадерле кунаклар өчен без «Татар биюе» (бию)бүләге әзерләдек.

*Бию башкарыла*

**Хуҗабикә:** Кунакка килгәнегез өчен бик зур рәхмәт! Хәерле юллар,хәерле сәгатькә!

**Күрше:** Хәзер сезне кунакка көтәбез! Бер-берегезгә кунакка йөрешик. Чөнки кунакларда иң мөһиме - дөнья тоткан кадерле кешеләр белән аралашу шатлыгы.

## *Сабантуйга бирнә җыю*

***Нургалиева Гелюсә Ильшат кызы***

*Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - Теләче №1 балалар бакчасы*

**Максатлар:**

1) Сабантуй йоласының килеп чыгуы турында белешмә бирү;

2) Диолоик һәм монологик сөйләм телен үстерү;

3) Милли бәйрәмнәр һәм йолалар аша халкыбызның үткән тарихы белән танышуны дәвам итү;

4) Татар халкының үткәне, йолалары белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:**

Презентация, сөлгеләр бәйләнгән сөрәнчеләр колгасы, рәсемнәр, дага, чигелгән сөлгеләр.

**Тәрбияче сүзе:**

Якты чырай, яхшы кәеф
Күрәм мин йөзегездә.
Исәнмесез, хәерле көн
Телим мин һәммәгезгә.
Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син.

Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен.
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

(Сәхнәгә “Сабантуй” җырын җырлап бер төркем егет-кызлар керә.)

Җырлыйк әле матур итеп,
Бәйрәм хисен иңдереп,
Бүген дуслар Сабантуй,
Ачыйк күңел типтереп.
Борынгыдан калган гадәт,
Батырларны зур итү,
Җирдә үскән ашлыкларга,
Бетмәс рәхмәтләр уку.

Тыныч торсын заманалар,
Имин булсын туганнар,
Хәр эшләр кайнап утырсын,
Юллар бәхетле булсын.

Яшьләр йөресен якты юлда,
Олылар зур хөрмәттә,
Халкыбыз торсын намуслы,
Мул уңышлы гомердә.
Кушымта:
Сабантуй, сабантуй,
Уйнау-җырлау бәйрәме,
Эштә батыр, җырда матур,
Горур халкым бәйләүе.

**Динара:**

Сабантуй бәйрәме –дуслык бәйрәме ул
Сабан туе көч сынашу, күңел ачу бәйрәме.
Сабантуй дигәндә кемнең дулкынланмый йөрәге!
Тайлар йөгәнләдеңме, атлар иярләдеңме?
Сабан туе җитә диеп, бүләк әзерләдеңме?

**Тәрбияче:**

Сабантуй илдә! Сабантуй!

Йоклап калучылар юкмы?

Хәерле көн абыйлар,

Хәерле көн апалар!

Хәерле көн егет-кызлар

Барча-барча халыклар!

Бәйрәмгә бирнә җыярга

Кузгалдык әле бергә.

Бүләкләрнең иң затлысы –

Сабантуй батырына.

**Адилә:** (Каршыга чигүле сөлге тотып:)

Бәйрәмгә дип әзерләнгән чигүле сөлгем менә

Бүләгемне тапшырырсыз көрәштә җиңүчегә.

(Ике егет көрәш куренешен күрсәтә. Батыр калган егет чигүле сөлгене ала.)

**Ясминә:**

Әйдәгез әле бер уйнап алыйк!

Алтын капка уены.

Әлчи, бәлчи,

Әни күлмәк үлчи

Үлчи торгач җитмәде,

Кисә торгач бетмәде.

Чәүкә, чыпчык,

Син кал, бу чык!

(«Алтын капка» Санамыш ярдәмендә ике бала билгеләнә.)

Алар кулга кул тотынып капка ясап басалар. Калган балалар музыкага тугәрәктә йөриләр. Музыка туктауга капка ябыла. Капкага эләккән бала капка ясаучылар белән баса. Уен дәвам итә.

**Тәрбияче2**: (Бер чиләк йомырка тотып керә:)

И, балалар, Сабантуйга бирнә җыясыз икән. Бигрәк күңелле итеп уйныйсыз! Минем дә бүләгем бар. Бәхетегез шушы йомыркалар кебек түгәрәк булсын.

**Егетләр бергә:**

Егетләр, әйдәгез бергә рәхмәт әйтик апага!

**Бергә:**

Рәхмәт яусын апага! Рәхмәт яусын апага!

**Камилә:**

Ә минем бүләгем – чигүле кулъяулык! Җиңүчегә!

**Егетләр:**

Әй, бүләге дә, бүләге
Бигрәк затлы, карале.
Бүләкләрне котлап без дә
Бер биеп алыйк әле.

**(Татар халык биюе.)**

Бабайлар һәм әбиләр,
Абыйлар һәм апалар!
Әниләр һәм бәбиләр,
Әтиләр һәм энеләр!
Сабантуйга килегез!
Җырлап-биеп, уйнап-көлеп
Бергә бәйрәм итәрбез!
Сабантуйга килегез!

**Бергә:**

Сабантуйга килегез!

**Мәдинә:**

Минем сабантуйга бүләгем шәл яулык.

**Диләэ:**

Болай булгач ,  «Яулык салыш» уенын да уйнап алыйк!

(Балалар түгәрәктә. Көй башлануга яулык кулдан-кулга түгәрәк буйлап җибәрелә. Көй туктауга яулык кемдә кала, шул җәза ала.)

Сайрый тургай тугаенда
Җәйнең матур аенда!
Көч сынашыйк, бәйрәм итик
Ямьле Сабан туенда!
Сау булыгыз! Хушыгыз!
Сабантуйга килегез!

*Татар халкы кунакчыл халык*

***Хәбибуллина Резеда Ирек кызы.***
***Әсхәдуллина Айгөл Гарафетдин кызы.***

*МБМБУГомуми үсеш бирү төрендәге*
*Арча 11 нче номерлы балалар бакчасы"*

**Максат:** Балаларны татар халкының гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте белән таныштыру.

**Бурычлар:**

***Танып белү үсеше***: балаларда татарларның яшәү рәвеше, аларның гореф-гадәтләре, фольклоры һәм милли костюмнары турында белем һәм күзаллаулар формалаштыру.

***Сөйләм үсеше:*** балаларда татар мәкальләрендәге кунакчыллык, чәйнең файдасы турында белемнәрен ныгыту.

***Сәнгать-эстетик үсеш:*** татар халык биюләре белән таныштыру; музыка, киемнәрнең матурлыгына карата уңай эмоциональ күзаллау формалаштыру.

***Физик үсеш:*** татар халык уеннары белән таныштыру.

***Социаль-коммуникатив үсеш***: балаларда татар халкының гореф-гадәтләре турында кызыксыну уяту. Балаларда алган белемнәрне, татар халкы турындагы күзаллауларны мөстәкыйль эшчәнлектә куллана белүне формалаштыру.

***Җиһазлар***: өстәл, эскәтер, самовар, савыт-саба, татар йорты җиһазлары, татар халык кухнясы эшләнмәләре (тозлы камырдан), чәк-чәк, сөлге, сабын, су чүмече, традицион рус халык кухнясы эшләнмәләре (кәрзиндә), тукыма кисзкләре, бизәкле кулъяулыклар, поднос.

**Чара барышы:**

*Балалар рус һәм татар халык костюмнарына киенгән.*

*Әкрен генә музыка яңгырый.*

**Тәрбияче**: Кадерле балалар, белгәнегезчә, безнең илдә бик күп төрле милләтләр яши. Һәр халыкның үз мәдәнияте, үз йолалары, гореф-гадәтләре. Әлбәттә бу бик яхшы, чөнки без барыбыз да төрле- төрле. Без бер-беребез белән танышкач һәм үзебез өчен бик күп яңа һәм файдалы нәрсәләр белгәч, тормышыбыз никадәр кызыклы була.

**Бала:**

Россиядә төрле халыклар элек-электән яши.

Бер өлешенә – тайга ошый, икенчеләренә - дала киңлекләре.

**Бала:**

Һәр халыкның үз теле һәм киеме

Берсе күлмәк киеп йөри, икенчесе халат.

**Бала:**

Берсе - тумыштан килгән балыкчы, икенчесе - болан тотучы.

Бер кымыз пешерә, икенчесе бал әзерли.

**Бала:**

Илебездә халык төрле-төрле

Ә Россия безнең барыбызга да - бер.

**Тәрбияче** : Ә бер халык икенчесеннән нәрсә аера соң? (*балаларның җаваплары)* Әйе, сез хаклы: тел, кием-салым, кухня, гореф-гадәтләр, гореф-гадәтләр, дин. Бүген без сезнең игътибарыгызны татар халкы мәдәниятенең аз өлешен тәкъдим итәбез. Кунакларны каршы алу һәм кабул итү теләсә кайсы милләт кешеләренә хас. Татар халкының кунакчыллыгы турында риваятьләр йөри. Бүген безне татар гаиләсенә кунакка чакырдылар. Дусларыбызны каршы алырбызмы?

Татарлар элек-электән кунакларга карата бик игътибарлы, кайгыртучан һәм әдәпле. Тәмле өстәл әзерләргә, күп итеп төрле ризыклар белән сыйларга тырышалар. Кунакларны сыйлау гына түгел, бүләк бирү дә кабул ителгән. Йола буенча кунак та шулай ук бушкулбелән килми. Әйдәгез, без сезнең белән хуҗаларга бүләкләр җыябыз.

**Бала**: Мин чиккән сөлгене алам.

**Бала:** Ә мин кулъяулык .

**Бала:**Ә мин тәмле пешкән пәрәмәч.

**Тәрбияче:** Ярар, мин үземнең тәмле бөккәннәрне алырмын.

*Өйгә якынлашып киләләр, кулына чәкчәк тотып, татар киеменнән балалар һәм тәрбияче чыга.*

**Хуҗа хатын**: Исенмесез балалар! *(балалар исәнләшә).*

**Тәрбияче:** Исәнмесезхуҗалар.Менә сез чакырдыгыз һәм без килеп тә җиттек! (*керәләр, күчтәнәч бирәләр)*

**Хуҗа хатын**: Кунаклар яхшы ул. «Кунак чакырырга яратмаган кешегә сөенеч юк», - диләр бездә. Сине хөрмәт итсеннәр дисәң, ипи-тоз, якты чырай, юмарт бул. Синең кунакчыллыгың үзенең әҗерен бирер. Әйдәгез өстәл янына рәхим итегез.

*Барысы да өстәл тирәли утыра, кызлар бер яктан, икенче яктан, малайлар. Хуҗа хатын самовардан пиалларга чәй ясый, кунакларга бирә.*

**Хуҗа хатын:** Борынгы татар гадәте буенча, без кунакны матур аш су белән каршыалырга өйрәнгән. Шуңа өстәлгә яңаматур ашъяулыкны җәеп җибәрдек һәм табынга иң яхшы

ризыкларны - татлы чәк-чәк, бавырсак, кош теле һәм әлбәттә, **хуш исле чәй китердек. Чәегез тәмле булсын!**

**Бала:**

Самавыр кайнап тора,
Аннан җылы пар чыга.
Без бергәләп чәй эчәбез,
Сәламәт булык кына.

**Бала:**

Самавыр сызгырып тора,
Малай кызыгып тора,
Күзен кыздырып тора:
- Нинди озын сызгара,
Бу миннән дә уздыра!

**Хуҗа хатын:** Кадерле кунаклар, ә хәзер чәй турында ниләр белә сезикән, тикшереп карыйк әле. Мин мәкальләр сөйлим, ә сез аны дәвам итәргә тиешсез.

- Чәй эчәсең икән - *сәламәтлекне саклыйсың.*
- Чәй эч - *бәла-казаларны белмә.*
- Чәй эчкәндә юкә булмый, *ә сәламәтлеге арта.*
- Чәй эчмисең - *көч каян аласың?*
- Чәй бөтен арганлыгын бетерә, *кәефен күтәрә.*
- Чәй эчү - *яшәү күңелле.*

**Хуҗа хатын:** Кайнар һәм каты чәйгә шикәр белән бергә сөт яисә кайнатылган сөт, яисә май өстиләр. Ә Әстерхан татарлары кайнар чәй эчәргә яраталар, тоз, май һәм кайчакта кара сөт борычы өстиләр. Менә карагыз әле, Булат исемле малай белән нинди вакыйга булды.

***Шаярту күренеше***

*Милли киемнән Булат килеп керә.*

**Булат:** Исәнмесез, дусларым!
Сезгә бәйрәмгә миндә килдем.
Мине исемем Булат!
Бабайның авылында миңа һәркем бик шат!
Мин күңелле һәм шаян!
Менә тыңлап карагыз әле,минем белән авылда нинди вакыйга булды ! Бер вакыт минем бабай чәй сатып алган ...

**Бабай:** Син аны пешерергә тиешсең, ди.

**Булат:** Мин грузин чәе пешерәбелмим?

**Бабай:** Чиләк белән су алда, бөтен чәйне тизрәк чүлмәккә сал...

**Марат**: Мин борыч, суган өстәдем,

Һәм петрушкада салдым,

азрак кынаболгатып

пыялаларга салдым.

**Бабай**: (*иреннәренә китерә, чыраен сыта, төкерә)*

Чәй эчүгә,эчне борды

Табибка мин йөгердем

**Марат.**Озак уйладым, гаҗәпләндем

Нәрсәсе ярамады?!

Ә аннары сизендме

Чәйгә бит онытканмын...

Тозда тагын өстәргә!

*(Балалар көлешәләр)*

**Хуҗа хатын**: Безнең өстәл өстендә бүген татар халык сый-нигъмәтләре күп: бу - бәлеш, өчпочмак, сумса, пәрәмәч, өлеш. Әйдәгез, татар халкының «Самовар» уенын уйныйбызмы?

*Балалар бер татар сый-нигъмәтен алалар да түгәрәк эченә басалар. Уртада бала (самавыр).*

**"Самовар" уены**

***Уен барышы:*** Татар көе астында балаларның сүзләре түгәрәк буенча бара. Сүзләр ничек бетә, самовар теге бала янына килә, аның каршына килеп баса да кулына тоткан ризыкны эзләп таба.

**Бөтен балалар:** «Чәйне нәрсә белән эчәбез, тизрәк чамалап кара әле», - дип сорыйлар.

**Бала - "Самовар"** кулы белән ишарәли һәм милли пирог яки татлы ризыкның исемен атый. Әгәр дөрес тапса, балалар парлап бииләр, дөрес булмаса, алып баручыны сайлыйлар. *2 тапкыр уйныйлар.*

*Сүзләр башта татарча, аннары рус телендә әйтелә.*

Там, там, тамчы там,

Тамуыңны яратам,

Там, там, тамчы там,

Тамуыңны яратам.

Самовардан тәмле итеп,

Чәй эчәргә яратам.

С самовара льется чай
Самовару не мешай
Ох, с самовара льется чай
Ложку с медом мне подай
Дуем, дуем,  чай мы пьем
Потом хором все споем….

**Хуҗа хатын:**

Безнең өстәлдәге иң тәмле ризыкларның берсе - татлы чәк-чәк. Телисезме без *сезгә чәкчәк турында татар әкиятен сөйлибез? Әйдәгез,сездә безнең белән уйнагыз. (Балалар торып баса).*

***Уен барышы.***

Баба белән бабай яшәгән.
Елга буендагы аланда. (*куллары билдә, борылып чүгәләр)*
Бабайларын сыйладылар.
Бал белән тәмле чәк-чәк. *(эчләрен сыйпыйлар)*
Әби камыр куйган
Тәмле чәч-чәк пешергән, (*камыр басалар)*
Аны майга салдым
Менә шулай калдырдым. (*Уч төпләрен күрсәтәләр.)*
Ул алсу, матур чыкты
Кояшка да охшаган. (*битләрен сыпыралар)*
Чәк-чәк йөреп керергә теләгән.
Бабасы белән әбисеннән качып китәргә, (*баскан урынында йөгерәләр)*
Юл буйлап тәгәрәп киткән.
Һәмшунда таралып беткән. *(Кулларны як-якка аералар)*

**Тәрбияче:** Ай-яй, чәк-чәк битбезнеңтаралды! Бабай белән әбигә ярдәм итик, чәк-чәкне җыябызмы?

***Уен үткәрелә:*** *төркемдән 5әр кеше һәм кунаклардан 5 кеше сайлап алына. Музыка астына шарчыклардан кечкенә чәкчәк ясыйлар*.

**Хуҗа ханым:** Булдырдыгыз, әфәрин.

Игътибарыгыз өчен барыгызга да рәхмәт.

Бер-берегезгә кунакка йөрегез, ачык, ягымлы, дустанә булыгыз. Кунакта иң мөһиме - табын түгел, бәлки, мәгълүм булганча, дөнья тоткан кадерле кешеләр белән аралашу шатлыгы.

***Хәрби хезмәткә озату йоласы***

***Хисамиева Ләйсән Илсур кызы.***

*ММББУ Хәсәншәех балалар бакчасы*

**Максат.**

1.Балаларны татар милләтенең гореф -гадәте бн таныштыру.

2.Балаларны йолаларга, гореф-гадәткә карата хөрмәт тәрбияләү.

3.Балаларның сүз байлыгын арттыру.

4. Балаларда сәхнә культурасын булдыру.

5.Балаларга патриотик тәрбия бирү.

**Җиһазлау:** өй эче күренеше. капка алды күренеше. агачлар,эскәмия.

**Тәрбияче:** Ватанны саклау һәр егетнең бурычы. Безнең әби -бабайларыбыз егетләрне солдатка озатуны зурлап

уздырганнар.Солдатка алынган егет дуслары белән җыелып, гаиләләре бн хушлашу мәҗлесе үткәргәннәр. Авыл халкы бн саубуллашып,урам буйлап гармунда уйнап, җырлар җырлап йөргәннәр. Кызлар солдатка кульяулыклар чигеп бүләк иткәннәр. Солдатта булу олы дәрәҗә саналган. Солдат егет исән сау кайтсын өчен төрле йолалар уздырганнар.

Бу күренештә шул гөреф -гадәтнең бер өлешен искә тәшерербез.

**Солдат киеме кигән егет әти-әнисе бн саубуллаша.**

**Солдат:** Әти-Әни хәрби хезмәткә китәр чагым җитте. Хәерле юл теләгез миңа . Солдат булу- егет кешенең Ватан алдындагы бурычы. Борчылмагыз бар да әйбәт булыр.

**Әти:** Нык, уяу,түзем,көчле бул улым.

**Әни:** Улым, менә бу икмәкне каптырам, аша, калганын алып куям. Ул син кайтканчы, сандыкта сакланыр, сине ризыгың өйдә көтеп торыр .Ватан сагында бурычыңны үтәп исән- имин кайтырга язсын улым.

**Солдат малай:** Рәхмәт Әти-Әни.(кочакланышалар)

**Гармун уйнап, егетләр керә.(исәнләшәләр,күрешәләр,кочакланышалар)**

**Ярым түгәрәк басып иңнәрдән кочакланышып җырлыйлар.**

Без авылда үскән идек

Тал тамырлары кебек

Үсеп җиткәч таралыштык

Кош балалары кебек

Салкын чишмә буйларында

Атлар әчерсәң иде

Туган үскән җирләрдә

Гомер кичерсәң иде.

**Бер егет:** егетләр кызлар тавышы ишетелә урамга чыгыйк.

**Әти**: Егетләр,бераз сабыр итик. Әнисе , улыбызга дога язылган бөтине киертик әле. Бу догалар улым сине саклап йортер.(бөти киертә)

**Капка төбенә чыгалар. Кызлар солдатка кульяулык бирәләр.солдат аларны бер-берсенә бәйләп иң өстенә сала.**

**Кызлар:**

Исән - сау кайт.

Хәерле юл.

Сау бул.

Еллар имин булсын.

**Бер егет:** Әйдәгез юлга кузгалганчы, үзебезнең яраткан уеннарыбызны уйнап алыйк.

**Түбәтәй уены.Чума үрдүк,чума каз уены.**

**Күмәк татар халык биюе.**

**Җәзалар -бию ,теләк теләү,әтәч, сыер, кәҗә булып кычкыру.**

**Әни:** улым,олы юлга чыгар алдыннан сиңа дога кылыйк.(әмин тоталар). Туган йортыңа исән- сау әйләнеп кайтырга язсын.

**Солдат малай:** Сау булыгыз . Барыр юлым уңышлы булсын, үз аякларым бн исән – имин кайтырга язсын.

**Агачка кул яулык бәйли солдат.**

**Солдат:** Кульялыкны күргән саен мине искә алыгыз. барыгызда исән имин яшәгез.

**Гармун уйнап егетләр китә. Кызлар, әти-әни кул болгап калалар.**

**Тәрбияче:** Хыяллар бер!Күкләр булсын аяз.

Тыныч булсын килер көнебез.

Уткәннәрдән гыйбрәт алабыз без,

Бүгенгене бизәп яшибез. дигән шигъри юллар аша тәмамлыйсым килә. Илебездә тынычлык булсын,солдатлар исән - имин әйләнеп кайтсын .

***Карга боткасы***

***Гыйлфанова Лилия Камил кызы.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль Районының муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе «Арча 3 нче башлангыч гомуми белем мәктәбе – балалар бакчасы»*

***Максат:*** *Балаларны электән килгән «Карга боткасы» йоласы белән таныштыру.*

***Бурычлар:***

- *татар халкының борынгыдан килгән бәйрәм, йолалары белән таныштыруны дәвам итү;*
- *элеккеге халык уеннары белән танышуны дәвам итү;*
- *балаларда бәйрәм, йолаларга карата кызыксыну уяту.*

*Каргалар кычкырган тавышлар килә. Сәхнәгә Дамир йөгереп керә.*

***Дамир***. Кар да кар килэләр, әллә кара каргалар килгән инде?(Кулын маңгаена куеп һаваны күзәтә). Әәә әнә бит каен башында берничә кара карга утыра.

*Илллария керә.*

***Иллария***. Дамир, нәрсә күзәтәсең анда?

***Дамир.*** Иллария, кара каргалар килгән. Шуларны карыйм.

***Иллария.*** Чынлапмы? Димәк тиздән чын яз җитә. Тизрәк карлар эреп бетсен инде, җәйне сагындым, кошлар тавышын ишетәсем килә.

***Дамир.*** Иллария, әйдә каргалар килгән хөрмәткә бәйрәм ясыйбыз!

***Иллария.*** Кит инде, шундый бәйрәм буламыни!?

***Дамир.*** Була. Әбием сөйләгәннәрдән беләм: элек заманда кара каргалар килгән хөрмәттән «Карга боткасы» бәйрәмен оештырганнар.

***Иллария.*** Кызык, ничегрәк була икән ул карга боткасы?(Уйга бата)

***Дамир***. Ничегрәк булганын шул бәйрәмне оештыргач күрерсең. Әйдә, әбимнән сорашыйк әле! Бәйрәмне оештырырга да ул безгә ярдәм итәр.

*Чыгып китәләр.*

*Карга булып киенгән берничә бала музыкага тезелешеп чыгалар. Түгәрәк буйлап әйләнәләр.*

***1нче карга***. Карга әйтә кар, кар,

***2 нче карга***. Туем җитте бар, бар!

***3 нче карга***. Ярма, күкәй алып бар,

***4 нче карга***. Ипи-итең алып бар,

***Бергәләп.*** Карр, карр, карр!

*Каргалар чыгып китә.*

*Балалар керәләр. Кулларында кәрҗиннәр.*

***1 нче бала.*** *Безнең якта бәйрәм бүген,*

*Бездә бүген тантана!*

*Өйдән өйгә йөреп әнә,*

*Күкәй җыя һәр бала.*

*Йортның ишеген кагалар.*

***2 нче бала.*** Өйдәме, түтәй!

Җәтрәк бир бер күкәй.

Бирсәң безгә өч күкәй,

Тавыгың салыр йөз күкәй.

*Өйдән хатын булып киенгән бала чыга. Балаларга күкәй бирә.*

***3нче бала***. Май кирәк, ярма кирәк,

Карга туена бар да кирәк.

*Хатын булып киенгән бала өйдән май, ярма алып чыгып бирә.*

***4нче бала.*** Тагын булса он чыгар,

Пешерербез без чумар.

*Хатын он алып чыга.*

***5 нче бала.*** Шикәр кирәк, тоз кирәк,

Чыгар, түтәй, тизрәк!

*Хатын тоз, шикәр алып чыгып бирә.*

***Балалар бергәләп.*** Зур рәхмәт, түтәй!

Синең кебек уңган түтәй

Бу дөньяда бик сирәк.

*Балалар чыгып китәләр.*

*Музыка тавышы. Малайлар кереп учак ягалар, казан асалар. Әби казанда ботка пешерә.*

***Иллария.*** Иртә белән барыбыз да

Җыелдык киң болынга-

Авылыбыз янындагы

Җанга якын урынга.

***Әмир.*** Учак яктык, казан астык,

Пешердек тәмле ботка.

Озак итеп карап тордык

Шарт та шорт янган утка.

***Азаль***. Уйнадык, шаярдык, көлдек,

Корып куйдык зур табын.

Ботка янына чыгардык

Йомырка, ипи, кагын.

***Камилә.*** Кем кыстыбый алып килгән,

Кем чәкчәк, кем өчпочмак...

Хәзрәт чишмәсенең суын

Эчтек бергә кушучлап.

***Дамир***. Яз җитте дип безнең әби

Ясый карга боткасы,

Ботка белән сыйланалар

Бөтен авыл баласы.

***Әби.*** Балакайлар, әйдәгез утырышыгыз, карга боткасы пеште!

*Балалар җәймәгә утырышалар, ботка ашыйлар.*

***Раян.*** Ботканың тәме

Телләреңне йотарлык!

Аның тәмен еллар буена

Саклап кына тотарлык.

Әйдәгез, бергәләшеп җырлып та алыйк әле!

*«Яз җитә» җыры башкарыла.*

***Ясминә.*** Әйдәгез «Чылбыр ишү» уенын уйныйбыз!

***Балалар.*** Әйдәгез, уйныйк!

*Санамыш ярдәмендә ике бала сайлап алына. Балалар, кулга-кул тотынышып, ярым түгәрәккә басалар. Сайланган ике бала кулларын күтәреп капка ясыйлар. Көй башлангач түгәрәкнең икенче башындагы бала башкаларны ияртеп капка аша чыга бара, балаларны чылбырга тезә бара. Уенчылар чылбырга тезелеп беткәч түгәрәк ясап кушылалар һәм чылбыр башыннан бер-бер артлы кирегә сүтеләләр. Уен шулай дәвам итә.*

***Әмир.*** «Зәңгәр чәчәк» уенын да уйныйк, дуслар!

***Балалар.*** Әйдәгез, уйныйк!

*Балалар түгәрәккә басалар. Бер бала чигүле мендәр тотып уртага баса. Балалар җырлап түгәрәк буенча әйләнәләр. Җыр беткәч уртадагы бала бер бала алдына мендәрен куя, аңа тезләнеп кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә. Башкалар кул чабып тора.*

*Каргалар очып чыга. Әби алар алдына калган ботканы куя.*

***Әби.*** Быел да менә пешердек:

Салдык тәмле ярмалар,
Сыйланыгыз, туган якны
Сагына белгән каргалар!
Ашагыз, кара каргалар,
Тәмле пешкән ботканы.
Рәхәтләнеп бәйрәм иттек
Бүген Карга боткасын!
Изге йола, еллар кичеп,
Киләчәккә дә барсын.
Үз боткаларын ашарга
Берүк каргалар калсын!

*Балалар, җитәкләшеп, күңелле музыкага астында чыгып китәләр. Алар артыннан каргалар каркылдашып оча.*

***Капка төбендә***

***Шакирова Эльвира Илсур кызы.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча 9 нчы балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

**Максат:** Милли мәдәният, татар халкының җырлы – биюле уеннары белән таныштыруны дәвам итү. Халык уеннары, җырлары, такмаклары аша балаларны татар халкының мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән таныштыру; халык иҗатына кызыксыну, мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау**: өй макеты, эскәмияләр

**Бәйрәм барышы:**

**Тәрбияче:** Кызлар! Малайлар! Әйдәгез әнә теге капка төбенә барып утырабыз.

Бергәләп ял итәрбез: җырларбыз, әйтешләр әйтербез, биербез, уеннар уйнарбыз, рәхәтләнеп күңел ачарбыз!

*(Балалар шау-гөр килеп капка төбенә киләләр. Балалар тавышын ишетеп өйдән әби белән бабай чыга)*

**Әби:** Дәү әтисе, кара әле, безнең капка төбенә балалар килгән түгелме соң?!

**Бабай :** Әйе шул, дәү әнисе. Балалар, нишләп йөрисез?

**Бала:** Исәнмесез Минзия абый, исәнмесез Гөлниса апа! Сезнең капка төбендә ял итеп алмакчы идек. Ярыймы?

*( berbersenә карашып алалар)*

**Бабай:** Ярый балалар, ярый.

**Әби:** Балалар сез каршы булмасагыз без дә сезнең белән бергәләп ял итәр идек.

**Балалар:** Юк, без каршы түгел.

**Тәрбияче:** Кердек алма бакчасына,

Алма җиргә коелган.

Матур әйтешләр сөйлик

Якын дуслар җыелган.

**Гомәрова Әминә** Тьфү, тьфү дияем Җиргә байлык Үземә саулык теләем.

**Рамина** Исәнлеккә саулыкка

Тазалыкка байлыкка

Бакаларга ярлыкка

Үзебезгә байлыкка.

**Мәрьям** Дусларым, әкият сөйлимме? Бер бай яшәгән. Аның 3 сарае булган: берсе – агачтан, берсе – калайдан, берсе – таштан. Сөйлимме яңа баштан?

**Тәрбияче:** Алма бакча – челтәр капка,

Ачыла ике якка,

Килдек, дуслар, сезнең белән

Уйнап күңел ачарга.

Әйдәгез, “Кулъяулык” уенын уйнап алыйк!

**“Кулъяулык” уены**

*Талым, талым, талчыбык Уртасында балчыбык.*

*Ал яулык, гөл яулык Бир син миңа бер яулык.*

**Тәрбияче:** Матур шигырь белән безне Темирлан сөендерсен әле

**Роберт Миңнуллин "Яз булмас микәнни?"**

ШәҺәргә кар явып тора,

Абыйлар ташып тора.

Ник ташыйлар икән дип, мин

Аптырап басып торам.

Болай булгач, гөрләвеккә

Карлар да калмас инде.

Гөрләвекләр гөрләмәгәч,

Яз була алмас инде!

**Тәрбияче:** Бие эле, бие эле!

Биегәнне күрсеннәр.

Баскан җирдән ут чыгара

Бишенче төркем дисеннәр

**Татар халык биюе**

**Тәрбияче:** Капка төбе бик күңелле,

Биедегез сыздырып.

Әйдәгез бер җырлап алыйк,

Моңлы итеп, өздереп!

**Җыр «Минем әти гармунчы»**

**Әби:** Карагыз әле, балалар, күңел ачып кич җиткәнен дә сизми калганбыз.

**Бабай:** Рәхмәт, барыгызга да, балалар, бик әйбәт ял иттек. биедек тә, җырладык та, уеннар да уйнадык.

**Тәрбияче:** Иртәгә дә чыгабызмы соң, балалар? Чыгарбыз.

**Әби белән бабай:** Иртәгә дә килегез! Сезнең белән миңа да бик күңелле булды.

**Хуҗабикә:** Рәхмәт балалар, бик әйбәт ял иттердегез. Биедек тә, җырладык та, уеннар да уйнадык. Болай булгач гореф-гадәтләребез югалмый, җырларыбыз, уеннарыбыз онытылмый икән. Балалар, ә хәзер, әйдәгез, өйгә кереп тәмләп чәй эчеп алыйк.

***Аулак өй***

***Шәмсиева Лилия Гәптелфәт кызы.***

*"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә гомуми урта белем мәктәбе"*

**Максат һәм бурычлар:**

1. Балаларда халкыбызның йола бәйрәмнәренә кече яшьтән үк кызыксыну уяту.
2.Балаларны милли йолалар белән якыннан таныштыруны дәвам итү.
3.Сөйләм телен үстерергә һәм иҗади сәләтләрен ачарга булышлык итү.
4.Халык авыз иҗаты әсәрләренә кызыксыну уяту, туган телебезгә, халкыбызның йола бәйрәмнәренә хөрмәт хисләре тәрбияләү

***Зал бизәлеше:*** зал түрендә өйнең эчке күренеше, анда борынгы сандык, чиккән мендәрләр, сөлгеләр, идәндә тукыган паласлар җәелгән.

Залга сөйләшә - сөйләшә әби белән бабай чыга:

- Әби , әйдәле әле теге оч Мәрьямнәргә кунакка барып кайтыйк әле, бик күптән күрешкән юк бит, өйдә утыру да ялыктыра башлады никтер
- Ярар, картым, барсак барырбыз шул дөрес әйтәсен үзем дә бик сагындым үзләрен, сөйләшер сүзләрем дә байтак җыйналды. Тик бабасы өйдә кемне калдырабыз соң, күрше Хәтимә дә авырып тора бит әле вакытсыз.
- Әй, карчыгым, кызыбыз бар бит, юкка кайгырма, ул кала.
- Барын бар да бит, никтер бераз куркыта, яшьләрне җыеп ятмасын дим
- Кызым, чык әле бире, тыңла әле сүзләремне

  (Сәхнәгә кыз чыга)

- Кызым, тыңла яхшылап, без бабаң белән түбән оч Мәрьямнәргә кунакка барып кайтабыз, озак тормыйбыз, син монда без юклыктан файдаланып дус егет-кызларынны җыеп ята күрмә тагын, яме, ишетсен колагын!!!
- Әй, әбекәем, борчылма инде юкка, тынычлап йөреп кайтыгыз

  (Әби белән бабай залдан чыгып китәләр).

  Кыз залдагы тамашачыларга карап:
- Әйдәгез әле бергәләп күңел ачыйк, аулак өй оештырыйк!!

Кыз тәрәзәне ачып дус кызларын аулак өйгә чакыра

**1 нче кыз :** Әйдә безгә килегез

Капкалардан керегез

Капкалардан керегез

Өебездән үтегез

Өебездән утегез

Җырлап бәйрәм итегез

Җырлап бәйрәм итегез

Кунак булып китегез.

**2 нче кыз** : Сез дә килгәнсез икән,

Без дә килгәнбез икән.

Аулак өйләр хөрмәтенә

Биеп җибәрик микән.

***Күмәк бию татарча***

- Кызлар, безнең биюне ишетеп малайлар да килеп җитте бит әле монда, нишлик икән сон кертикме аларны?

  **Егетләр:** Әй, кызлар ачыгыз ишекне, безнең дә уйныйсыбыз килә.

  **Кызлар:** Бусага ялын түләмичә кертмибез!

  **Егетләр:** Түлибез, түлибез, кертегез инде!

  **Кызлар:** Ялыгыз нинди?

  **Егетләр (берәм-берәм):** Мин биим, мин җырлыйм, мин такмак әйтәм!

  (Егетләр кереп исәнләшәләр)

  (Залның бер ягына кызлар, икенче ягына малайлар тезелеп басалар, кара – каршы җырлыйлар.)

  **“Челтәр элдем читәнгә” җырлы уены башкарыла ( тат.х.җ.).**

  **Малай:** Исәнмесез, кызлар – йолдызлар!
- Хәерле кич сезгә бу җирдә!

  **Кыз:** Барчагыз яраткан аулак өйгә

- Чакырабыз хәзер сезне дә!

**Кыз:** Таныштык та, дуслаштык та
Урыннарга утырыйк
“Йөзек салыш” уенын
Бергәләп уйнап алыйк!

**“Йөзек салыш” уены уйнала.**

**Кыз:** Үзем саныйм. Зәй. Зәй, Зәйнәбем. Атны кайда бәйләдең?
Алмагачка бәйләдем.
Алма төште шап итеп, Зәйнәп чыкты ялт итеп!

(Кемдә йөзек , шул сикереп чыга)

**Кыз:** Нинди җәза бирәбез?

**Егет**. Әтәч булып кычкырсын (уен ике мәртәбә уйнала)

2 нче отылган бала шигырь сөйли:
Әбием аулак өйләрдә
Халык җыры җырлаган
Халык җыры - бай мирас, дип
Бу көнгәчә саклаган!

**3 нче бала:** Һич моңаеп утырмыйк
Бер уйнап – җырлап алыйк
“Яулык салыш” – кызык уен,
Ул сизгерлекне сорый
Дуслар ярышкан вакытта
Кул чабып тормый булмый.

**“Яулык салыш” уены уйнала.**

**1 нче отылган бала иптәшләренә үзе шигъри юллар белән җәза бирә:**
Игътибар белән тыңлагыз
Җәзаны үзем бирәм
Матур – матур сүзләрне
Кайсыгыз күбрәк белә.

Түгәрәккә утырган балалар чиратлашып матур – матур сүзләр әйтәләр: алмам, күгәрченем, былбылым, йолдызым, матурым, алтыным, чибәрем, йомшагым һ.б.

**2 нче отылган бала:** Кунак килсә сый – хөрмәтсез
Камыр – ашсыз булмый бит.
Кем нинди ашамлык белә?

Я, дуслар, әйтеп карыйк
Татар халык ашларын
Без тукталмыйча саныйк.

Балалар халык ашларын әйтешәләр: чәк – чәк. өчпочмак, коймак, тәбикмәк, бәлеш, кыстыбый, кош теле һ.б.

(Әби белән бабай кайтып керәләр.)

**Әби:** И, карале, картым боларны! Кызың- Хәлимәң нишләгән бит! Аулак өй ясап яталар! Хәлимә кызым, без бит сине өй сакларга калдырдык, ә син оялмыйча яшьләр белән уйнап, җырлап-биеп ятасың!

**Бабай:** Ачуланмасана, әллә үзебезнең яшь чакларны оныттыңмыни?

**Әби:** И-и, онытыламы соң ул яшь чаклар?!

**Әби җырлап җибәрә:** Ак тавыгым бар иде, йомыркасы пар иде
Безнең дә бит сезнең кебек, яшь вакытлар бар иде.

**Хәлимә:** Ягез инде, яшьлегегезне искә төшергәч, бер биеп тә алыгыз инде.

(Әби белән бабай бииләр.)

**Бабай**: И-и-и, бигрәк матур да биедек! Яшьлекләремә кайткандай булдым бит, карчыгым.

**1 кыз :** Таң атар, чыгар кояшы
Өйләргә таралышыйк
Хуҗаларга рәхмәт әйтеп
Дусларым саубуллашыйк!

(Ярымтүгәрәк ясап басалар, “Аулак өй” көенә җырлыйлар.)

**1бала:**Уйнадык та, җырладык та
Бүген бездә аулак өй,
Аулак өйдә булмаганнар
Безнең күңелне аңламый.

**2 бала:** Татар халык иҗатын
Милли гореф – гадәтен
Тугры халык антларга
Сүз бирәбез сакларга!

Дуслык җебе өзелмәс ул
Халык моңы бар җирдә
Безнең мондый очрашулар
Истә калсын гомергә.

(Балалар залдан татар көенә биеп чыгып китәләр**)**

***Карга боткасы***

***Сабирҗанова Лилия Рашит кызы.***

*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче 1 нче балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** “Карга боткасы” йола-бәйрәме белән таныштыру, бер-берсенә карата җылы мөгаләмә тәрбияләү, ата-бабалардан калган мирасны кадерләргә өйрәтү, туган җирне олылау хисен булдыру, сөйләм телен ныгыту.

**Бәйрәм барышы**

*Бина эче милли рухта бизәлгән. Экранда яз һәм язны каршы алу белән бәйле сурәтләр күрсәтелә. Ә экран почмагында “Карга боткасы” йола-бәйрәме турында мәгълүмат тупланган сылтама куела (QR-код).*

*Залда берничә агач һәм агачаларда каргалар утыра.*

**Тәрбияче:** Әссәламәләйкүм! Хәерле көн, балалар! Әйтегез әле миңа, хәзер елның кайсы фасылы?

**Балалар:** Яз!

**Тәрбияче:** Бик дөрес. Яз ул – гади генә ел фасылы түгел. Ул - тереклекнең уянуы, яңаруы. Язны элек-электән олылаганнар. Бабаларыбызның язга бәйле йолалары да байтак булган. Әлбәттә, ул йолаларның күбесе инде онытылып бара. Шуңа да безнең бурыч аларны яңадан торгызып, киләсе буыннарга тапшырып калдыру. Шушы максаттан без сезнең белән бүген бер матур йола-бәйрәмне үткәрергә җыелдык.

*Бер әби чыга.*

**Әби:** Иии, менә ничек рәхәт урамда. Яз бигрәк матур килде быел. Тиздән бар дөнья яшеллеккә күмелер. Агачларда кошлар сайрар. Яратам да инде язны.

**Балалар:** Әби, әби, күрдеңме әле, кара каргалар кайткан.

**Әби:** Бәрәкалла! Менә нинди сөенеч! Юк, күрмәгән идем әле. Рәхмәт сөенечле хәбәрегез өчен. Димәк, карга туе булачак.

**Балалар:** Карга туе? Ул нинди туй әби?

**Әби:** Кара каргалар язны алып килүче кошлар, элек-электән шундый ышану яшәгән. Шуңа да кара каргаларны зурлаганнар. Каргалар кайткач без балачакта бөтен авыл җыелып, зур казан асып ботка пешерә идек. Шул боткадан олылар каргаларга да өлеш чыгара иде. Кошларның шул боткага җыелып бергә каркылдый-каркылдый ашауларын олылар карга туе, диләр иде. Шуңа ботканы да “Карга боткасы” дип атаганнар.

**1нче бала:** Әби, әйдә без дә карга боткасы пешерәбез.

**2нче бала:** Минем дә каргаларның туен күрәсе килә.

**3нче бала:** Карагыз әле, кара, кара каргалар очып бара.

*4-5 бала каргалар булып чыга.*

**1нче карга:** Кайттык ерак-еректан

Сезне сагынып.

Кайттык үзебез белән

Без язны алып.

**2нче карга:** Туган яклар сагындырды,

Туган якта ямьле.

Читтә чакта беленә шул

Туган якның кадере.

**3нче карга:** Инде бүген бәйрәм бездә

Бүген – карга туе.

Бәйрәм итик бергә-бергә,

Әйдә көне буе.

*Каргалар биюе. Аннан каргалар чыгып китә.*

**Әби:** Чыннан да, нинди сөенеч каргаларның безнең янга кайтуы.

**4нче бала:** Әби, ә без кайчан ботка пешерәбез?

**Әби:** Балалар, ул ботка бит гади генә ботка түгел. Йоласына туры китереп пешерелергә тиеш.

**1нче бала:** Ә йоласы нинди алайса?

**Әби:** Әйдәгез, иң башта барысына да хәбәр итик. Аннан йоланы башлап җибәрербез. Йоланың асылын үзегез аңларсыз, балалар.

**2нче бала:** Дусларым, дусларым,

Ишетәсезме мине?

Бәйрәм бүген бездә, диеп,

Сәламлимен мин сезне.

**3нче бала:** Әби-бабайлар йоласы-

Карга боткасы бездә.

Бүген менә җыелышып

Үткәрик әле бергә.

**Әби:** Әйдәгез,балалар, хәзер бергәләп өйдән-әйгә кереп ярмалар, май,йомырка җыеп чыгыйк. Ишетмичә калганнарны бәйрәмгә чакырырбыз.

**5нче бала:** Карга әйтә: кар, кар,

Туем җитте, барр, барр,

Ярма, күкәй алып бар,

Сый, маеңны салып бар.

Ипи-чәең алып бар..

*Берничә урынга балаларны парлап яки үзләрен генә утырталар,ягъни алар йорт хуҗалары була. Әби белән калган балалар алар янына килеп ярмалар, йомырка,май җыеп йөриләр.*

*Һәр "йорт"ка тукталуны концерт номерлары белән аралаштырырга мөмкин. Ә ярмаларны җыю электән калган такмаклар белән дәвам итә.*

Өйдәме тутәй, тизрәк бир күкәй.

Бирсәң безгә өч күкәй

Тавыгың салыр йөз күкәй.

**Әби:** Менә балалар күпме сый-нигъмәт җыелды. Әйдәгез, җыйганнарыбызны пешерүче апаларыгызга тапшырыйк, ә үзебез ботка пешкәнче уеннар уйнап, җырлап-биеп зирәклектә-тапкырлыкта көч сынашырбыз.

**Балалар сөйли:**

- Җирләр-күкләр аяз булсын,

Басуларда иген уңсын.

Муллык алып килсен бу яз

Еллар һәрчак имин узсын.

-Яңгырлары шифалы,

Кояшы җылы булсын.

Якты матур булып һәрчак

Җиргә яңа көн тусын.

-Каргаларга ияреп

Җиргә янә яз килде.

Сөенәбез, шатланабыз

Безгә бик тә күңелле.

**Тәрбияче:** Балалар, ә сез яз белән бәйле табышмакларны беләсезме? Әйдәгез, мин сезне сынап карыйм әле.

-Ак юрганымны алып куйдым,

Яшел юрганымны җәеп куйдым. (*Кыш китеп, яз килүе*)

-Борынсыз чыпчык боз тишә. (*Тамчы*)

-Ут та түгел, ук та түгел,

Күзгә төшә, карны кисә. (*Кояш нуры*)

**Тәрбияче:** Афәрин,балалар! Сез яз турындагы табышмакларны беләсез икән. Әйдәгез, бергәләп яз турындагы җырны да әбиебезгә җырлап күрсәтик әле.

*Бергәләп “Яз җитә” җырын җырлыйлар.*

**Әби:** Элек бабайлар яз көне эретмичә озак туңдырып торса, җәй коры була, дип әйтәләр иде. Балалар, ә сезнең яз турында сынамышлар ишеткәнегез бармы?

-Бар.

-Елгалар боздан озак ачылса, ашлык уңар.

-Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.

-Черкиләр яз көне иртә күренсә, һава җылыныр.

**1нче бала:** Әби, ә элек нинди уеннар уйный идегез?

**Әби:** Уеннар бик күп төрле иде инде ул,балалар. Мәсәлән, сезгә бик таныш булган “Йөзек салыш” уены, аннан “Түбәтәй”, “Капкалы”, “Әтәчле”, “Яулык салыш” уеннары. Менә бүген бергәләп “Гөлбану” уенын уйныйк әле. Уеннарыбыз да югылмасын, буыннан-буынга тапшырылсын.

*“Гөлбану уен”ын уйныйлар.*

*Уен беткәч каргалар чыга.*

**1нче карга:** Бәйрәмегез күңелле,

Сезгә кушыйлыйк әле.

Сезнең белән бергәләшеп

Биеп-җырлашыйк әле.

Күмәк җыр башкаралар.

**Тәрбияче:** Балалар, менә безнең боткабыз да пеште. Әйдәгез, бергәләп “Карга боткасы” белән сыйланыйк һәм, әлбәттә, каргаларны да сыйлыйк.

**Ахырдан 2нче карга:** Рәхмәт безне зурладыгыз,

Ботка белән сыйладыгыз.

Онытмыйча бергәлекне

Тагы шулай җыйналыгыз.

**Знче карга:** Бердәмлектә – көч,диләр.

Бергә җыелу кирәк.

Туганнарың,дусларың

Сиңа һәрчак гел терәк.

**Тәрбияче:** Аңладыгызмы инде балалар, “Карга боткасы” йоласы каргаларны зурлау, яз килгәнгә сөенү генә булмаган, ул бергә җыелу, күмәкләшеп бәйрәм итү дә. Кешеләр йолалар аша туганлык җепләрен саклаганнар, бер-берсе белән аралашканнар, ил-көнгә һәм үзара җылы теләк теләшкәннәр. Мондый йолаларны торгызу безнең бурычыбыз. Үткәннәребез ядькәрләрен бергәләп барлыйк, бергәләп саклыйк!

***Сабантуй бәйрәме***

***Бәшәрова Лилия Хөсәен кызы.***

*Теләче муниципаль районы Теләче*
*1 нче балалар бакчасы муниципаль бюджет*
*мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

Соңгы елларда халыкның туган җиренә милли мәдәниятенә игътибары көчәя бара. Бу исә балаларда кече яшьтән үк ана теленә,үз милләтенең традицияләренә мәхәббәт, ихтирам тәрбияләү ихтыяҗын да арттыра. Шушы максатта балалар бакчаларында элек-электән килгән милли бәйрәмнәрне билгеләп үтү дә зур әһәмияткә ия.

Милли бәйрәмнәр- халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Аларда өлкәннәр дә теләп катнаша, алар кеше күңелендә бик озак саклана.

Сабантуй да әнә шулай хәтергә сеңеп кала торган бәйрәмнәрнең берсе. Аны без балалар бакчасында үткәрәбез.Ул ничек оештырыла соң?

Иң элек сабантуй турында әңгәмә уздырыла,аннары милли киемнәр, кечкенә сөлгеләр,кульяулыклар әзерләнә,җырлар,шигырьләр, уеннар өйрәнелә; төрле ярышларда җиңүчеләргә тапшыру өчен бүләкләр алына,чакыру кәгазьләре языла. Ә паркта исә “ат чабышлары”, төрле уеннар өчен агач атлар,мәйданчык әзерләнә.

Сабантуй буласы көнне мәйданчык бәйрәмчә бизәлә:озын колгага чигүле сөлгеләр,кулъяулыклар,төрле төстәге шарлар эленә.Уеннар оештырыла торган урыннар тиешенчә җиһазландырыла.

Әнә бәйрәм башланыр вакыт җитә, мәйдан алдына милли киемнәр кигән тәрбиячеләр һәм балалар тезелешеп баса. Кечкенәләрнең кулында-төсле шарлар, флагчыклар, уенчыклар, гармуннар. Мәйданның бер ягына кунаклар урнаша.

“**Сабантуй бәйрәме”**дигән җыр яңгырый(халык көе, М.Садри шигыре), һәркем шушы җырга кушыла.

Сабан туе-хезмәт туе,

Шатлык һәм бәхет туе,

Уйнап биеп, җырлап, көлеп,

Бәйрәм итик көн буе.

Шау-гөр килә киң болыннар,

Кырлар һәм су буйлары,

Котлы булсын, балалар,

Ямьле сабан туйлары!..

Берничә бала Х.Вахитның “**Балачак турында”** дигән шигырен сөйли.

**1 нче бала:**

Алсу гөлләргә күмелгән
Безнең тирә-як.
Гүзәл гөлләрдән дә гүзәл
Безнең балачак.

**2 нче бала:**

Без җырлаган дәртле җырлар
Истә калачак.
Дәртле җырлар төсле дәртле
Безнең балачак.

**Җыр:”Кояшлы ил”**

**3 нче бала:**

Күңелләр шатлыклы булганга,
Без чыгыйк шаулашып урманга.
Үзебез тезелеп сафларга,
Әти-әниләр, карагыз:
Флаглар күтәреп барабыз!
Күргәннәр сокланып калалар:
Без-илдә бәхетле балалар.
Әтиләр-әниләр, карагыз:
Җыр белән гөр килеп барабыз!..

**Җыр “Чат-чат”**

Без уйныйбыз, уйныйбыз
Якты көннән туймыйбыз;
Кулны-кулга чаба-чаба, бии-бии җырлыйбыз.

**Кушымта:**

Без бииибез, безнең яшь чак, шат чак,
Шуңа биеп, кул чабабыз чат-чат!..

**Алып баручы:**

Бүләк түфлигә күңеле
Күтәрелән Сараның
Хәзер инде тыпыр-тыпыр
Биисе килә аның.
Бик матур көй уйнар өчен
Бер гармунчы табыгыз,
Бер гармунчы тапмасагыз,
Бергәләп кул чабыгыз.
Менә шулай,менә шулай,
Менә шулай кызык ул
Такмак әйтеп кул чапканга
Һаман бии кызып ул.
(Н.Мадъяров.”Бер гармунчы”)

**Алып баручының** соңгы сүзләреннән соң бер кыз биеп китә.

**4 нче бала:**

Бүген дә кыстатып утырмадым табында.
Әни нәрсә китерсә-ялт иттердем барын да
Бәрәңгесе дә бүген шундый тәмле, ярмалы..
Тик бер кабым ипине кабар җирем калмады.
Киткән чакта табыннан әни шундый мактады,
Ә дәу әти нигәдер мактарга сүз тапмады.
Авыр сулап куйды да: Улым,-диде-их сине!.
Китәләрме калдырып бер  кабымлык ипине.

(Х.Халиков.”Кырдан кайткач”)

**5 нче бала:**

Ипи басуда үсә,аннан амбарга күчә,
Аннары мичтә пешә,кызарып мичтән төшә.
Шуннан килә өстәлгә,безгә куәт өстәргә,
Ипи булса табында,булдырам мин барын да.

(Р.Миңнуллин.”Ипи булса”)

**Алып баручы**:

-Менә күрәсезме, балалар, икмәк ипи булып җиткәнче нинди юл үтеп безнең табынга килә. Шуңа ул бик кадерле дә .Яз көне безнең уңган кыр батырларыбыз басуда бодай бөртекләрен чәчәләр, көзен исә мул уңыш җыеп алалар. Бүген безнең  бәйрәмдә механизатор абыйлар да катнаша. (Аннары кемнәр катнашуы,аларның ирешкән уңышлары,балаларның өлкәннәргә булышулары турында әйтә)

Балалар,әйдәгез әле хезмәт батырларына узебезнең җырларыбызны бүләк итик, барыбыз бергә **“Иртәнге нур”(**С.Садыйкова көе,З Вәли шигыре) дигән җырны җырлыйк:

Туган илкәем, сөйгән җиркәем
Иртәнге саф нурга күмелә:
Урман буйлары, басу юллары
Бигрәк инде матур күренә.
Уяна сабый, елмаеп карый
Иртәнге саф кояш нурына,
Матур уйларым, татлы хыялым

Кушылсын шат хезмәт җырына.

Иртәнге җырлар, иң якты уйлар

Кая барсам минем күңелдә.

Һәрвакыт шулай сайрасын тургай

Туган илнең тыныч күгендә.

Җырлы бию башкарыла, балалар төрле эш башкару хәрәкәтләре ясап бииләр.

**Тәрбияче:**

Күрсәтегез әле, балалар
Ничек кошлар очалар?

**Балалар:**

Менә шулай,м енә шулай
Шулай кошлар очалар?

**Тәрбияче:**

Күрсәтегез әле, балалар ,
Ничек йөри поездлар?

**Балалар:**

Менә шулай, менә шулай,
Шулай йөри поездлар.

**Тәрбияче:**

Күрсәтегез әле, балалар,
Ничек урак уралар?

**Балалар:**

Менә шулай, менә шулай,
Шулай урак уралар.

Кулына гармун тоткан малай Җ.Дәрзамановның **“Гармун**” исемле шигырен сөйли:

Гармунным алты телле,
Тавышы-алты төрле.
Бармаклар бишәү генә
Юк инде нишләү генә.
Уйнап карыйм көйләп тә,
Җырлап, шигырь сөйләп тә...

Җыр да чыга, шигырь дә.

Тик боекмыйм юкка мин,

Уйныйм һаман,туктамыйм.

-Ура!Бу бит “әпипә”,

Тырышкач чыкты бит, ә!

**Алып баручы:**

Бүген бәйрәм, әйлән-бәйлән,

Уйныйк, гөрләшик.

Ә хәзер сабан туенда уйнала торган уеннарны оештырыйк: малайлар көрәшсеннәр,көч сынашсыннар, ә кызлар исә көянтә-чиләкләр белән су ташысыннар. Капчык киеп йөгерергә, бау тартышырга, колга башына менәргә, ат чабышлары һ.б..уеннар уздырырга мөмкин.

Уеннар, ярышлар башлана,мәйданчык шау-гөр килә, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырыла. Кабат “Сабантуй бәйрәме” җыры яңгырый. Бәйрәм шуның белән тәмамлана.

***“Милли бәйрәмебез - Сабантуй”***

***Хөсәинова Рәзинә Равил кызы.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Мөндеш балалар бакчасы" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

Бәйрәмдә катнашучы персонажлар: Алып баручы, Былтыр, Шүрәле.

**Җиһазлау**: капчыклар, канат, йомыркалар, кашыклар, агач атлар, чүлмәк, таяк, бүләкләр.

*Сабантуй буласы мәйданчык бәйрәмчә бизәлә. Озын колгага чигүле сөлгеләр, кулъяулыклар, төрле төстәге шарлар эленә. Уеннар оештырыла торган урыннар тиешенчә җиһазландырыла.*

**Бәйрәм “Сабантуйга барабыз” җыры белән башлана.**

1. Карагыз, карагыз,

Сабантуйга барабыз.

Сабантуйга барабыз.

Уйнап бүләк алабыз.

2. Сабантуйга барабыз.

Сикерәбез, чабабыз.

Җырлап, биеп алабыз,

Уйнап бүләк алабыз.

**Алып баручы (милли киемнән):**

Күңелләрне җилкендерә Сабантуй,

Йөрәкләргә моң, дәрт өсти Сабантуй.

Исәнмесез, кадерле балалар, без сезнең белән сабантуй бәйрәменә җыелдык. Бу бәйрәм бар халыкны берләштерә, күңелләрне күтәрә.

(Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларына сүз бирелә)

**1 нче бала:** Шатлыклар күңелебездә,

Ал кояш күгебездә.

Килегез, дуслар, кунакка:

Сабантуй бүген бездә.

**2 нче бала:** Җилферди чиккән сөлгәләр,

Бүләкләр күбебезгә.

Көрәшик тә, узышыйк та-

Сабантуй бүген бездә.

**3 нче бала:** Бүген бездә сабан туй,

Эшләреңне барын куй.

Тизрәк йөгер мәйданга:

Бәйрәм башлана анда.

**4 нче бала:** Кемдә нинди һөнәр бар?

Йөгерергә кемнәр бар?

Кызганмый табаннарны

Урагыз мәйданнарны.

**5 нче бала:** Сабантуймы? Сабантуй-

Уеннар туе бит ул.

Тәм-томнар туе бит ул,

Җиңүләр туе бит ул.

**6 нчы бала:** Чаптар өстендә чабып,

Катыктан тәңкә табып,

Колга башына менеп,

Узышлыга йөгереп.

**7 нче бала:** һәм татарча көрәшеп,

Аркан белән сөйрәшеп,

Ватмый йомырка ташып,

Тапкырлыкты сынашып

Җиңсәң әгәр, Сабантуй –

Эчкә шатлык сыймас туй!

*Былтыр килеп чыга.*

**Алып баручы:** Балалар, карагыз әле кем бу? Былтыр син түгелме? Урманга барасыңмы, әллә бездә сабантуй икәнен белдеңме?

**Былтыр:** Әйе, ишетеп килдем, сезнең матур җырларыгыз еракка яңгырый. Минем дә сезнең белән бәйрәм итәсем килә.

**Алып баручы:** Әйдә, Былтыр, син дә безнең белән күңел ач.

*Зурлар төркеме "Әпипә" биюен башкара.*

**Былтыр:** Ай-һай, матур биисез икән. Минем сезгә күчтәнәчләрем бар иде, ләкин мин юлда капчыгымны югалттым.

**Алып баручы:** Күчтәнәчләрең күп идеме соң? Балалар, әйдәгез әле, эзләшик капчыкны.

*Балалар капчыкны табалар. Капчык селкенә. Аны ачып җибәргәч, Шүрәле чыга.*

**Былтыр:** Нәрсә бу? Качкынмы? Җенме? Нәрсә бу? Искитәрлек нәрсә бу?

**Шүрәле:** Нәрсә бу? Танымыйсың инде әллә? Мин матур, мин әйбәт, тик мин сезгә үпкәләдем. Ник сез мине бәйрәмгә чакырмадыгыз? Мин сезгә бүләкләрегезне бирмим.

**Былтыр:** Шүрәле, бәлки без синең белән көч сынашырбыз?

*Былтыр белән Шүрәле канат тартышалар. Балалар булышалар. Шүрәле егыла.*

**Шүрәле:** Минем бәйрәм күрәсем килгән иде. Былтырдан бирле Сабантуй күргәнем юк бит.

**Алып баручы:** Шүрәле, Сабантуй елга бер генә була ул. Әйдә, кал, безнең белән уйнарсың.

**Шүрәле:** Бик теләп калам, мин бит кети-кети уйнарга яратам.

**Алып баручы**: Юк, Шүрәле, без милли уеннарыбызны уйныйбыз. Син дә кушыл.

*Уеннарны Алып баручы, Былтыр, Шүрәле, тәрбиячеләр оештыра.*

1 ярыш: "Капчык киеп йөгерү".

2 ярыш: "Кашык белән йомырка кабып йөгерү".

3 ярыш: "Чүлмәк вату".

4 ярыш: "Таяк тартышу".

5 ярыш: “Кашык белән су ташу”.

6 ярыш: “Ат чабышы”.

7 ярыш: “Күзне бәйләп уенчык кисү”.

*Татар бию көенә күмәк бию.*

Уеннарда катнашкан, җырлаган, биегән балаларны бүләкләү. Барлык балаларга Былтыр белән Шүрәле тәм-томнар тараталар. Милли ризыклардан авыз итәргә чакыралар, чәй табыны әзерләнә.

## *Аулак өй*

***Яруллина Айгөл Альберт кызы.***

*Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы “Дусым балалар бакчасы”муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Максат:**

1. Балаларны татар халкының гореф-гадәтләре, борынгы йолалары белән таныштыру.
2. Баларның фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерергә һәм иҗади сәләтләрен ачарга булышлык итү.
3. Борынгы уеннар, җыр-биюләр аша туган телгә хөрмәт, кызыксыну уяту.

**Алып баручы:**

Хуш киләсез, кунаклар,

Рәхим итегез түргә!

Сезне көттек бик сагынып,

“Аулак өй” үткәрергә!

Халкыбыз йолаларын

Искә төшерик әле

Куңелле итеп бүген
“Аулак өй” үткәрик әле.

«Аулак өй»нең нәрсә икәнен, мөгаен, һәр кеше дә беләдер, чөнки бу гореф- гадәт бик борынгыдан килә. Элек, олылар туганнарына яисә эшләре буенча киткәч, кызлар үзләре генә калганнар һәм кунакка дус кызларын чакырганнар. Озакламый аларга егетләр дә килеп кушылган. Зур һәм шаян төркемдә бию һәм җыр, мәзәкләр сөйләү башланган. Егетләр һәм кызлар милли татар уеннары уйнаганнар. Нәкъ менә шул «Аулак өй» татарларның гореф-гадәте булып киткән. Менә без дә халкыбызның матур гореф-гадәтләрен дәвам итеп, шушы Аулак өй күренешен уйнап күрсәтербез.

*(Авыл өе. Бүлмә түрендә өйнең эчке күренеше, анда борынгы сандык, чиккән мендәрләр, сөлгеләр, идәндә тукыган паласлар җәелгән. Бүлмәгә әни белән кыз керә)*

**Әни:** Кызым, без кодаларга кунакка барабыз. Әбиең мунчада, аңа чыккач мәтрүшкәле чәй эчертерсең. Аулак өйгә иптәш кызларың да килми калмас. Сез матур гына торыгыз инде яме, кызым? Әбиеңгә дә күз-колак булырсың.

**Кыз:** Борчылма, әнием! Мин инде җиткән кыз, барысын да беләм. Без кызлар белән кул эшләре генә эшләп утырырбыз дигән идек.

**Әни:** Беләм инде, кызым, беләм. Ярый безгә кузгалырга кирәк. Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

**Кыз:** Исән-сау йөреп кайтыгыз, әнием! Хәерле юл сезгә!

*(Залга әби керә)*

**Әби:** Ай мунчасы да, мунчасы...Шундый эссе.

**Кыз**: Иии әби җаным, чыгып та җиттеңмени? Кая әле сиңа чәй ясап бирим, бергәләп чәй эчеп алырбыз.

**Әби**: Рәхмәт, кызым!

(*Чәй эчәләр*)

**Әби:** Кызым, күрше Гөлбикә апаң авырып киткән әле. Мин кереп хәлен белеп чыгыйм, берәр сәгатьтән әйләнеп кайтырмын.

**Кыз:** Ярар, әби.

*( Әби музыка астында залдан чыгып китә)*

*( Кыз өй тәрәзәсе янына килеп дус кызына эндәшә)*

**Кыз**: Гөлназ, әйдә кер! Бездә бүген аулак өй!

**1 нче кыз:** Бүген сездә аулак өй дип

Дусларымнан ишеттем,

Йомгагымны чорнарга дип

Мин сезгә килеп җиттем.

*(Кызлар тезелеп утырып кул эшләре эшлиләр)*

**"Каз канаты"** (татар халык җыры) **җырын җырлыйлар.**

*(Гармунда уйнаган көй яңгырый)*

**1 нче кыз**: Кызлар, малайлар тавышы бит бу!

**Малайлар:** Кызлар, ачыгыз ишекне! Безнең дә уйныйсыбыз килә!

**Кызлар:** Юк, ачмыйбыз!

**Малайлар**: Кызлар, ачыгыз инде!

**1 нче кыз**: Кызлар, әллә кертәбезме? Бергә күңеллерәк тә булыр.

**Кызлар:** Ярар, әйдә кертәбез!

*(Малайлар өйгә керәләр. Кара-каршы тезелеп басалар: кызлар залның бер ягында, малайлар икенче ягында)* ***"Челтәр элдем читәнгә"*** *( Татар халык җыры)* ***җыры башкарыла.***

**Кыз:** Таныштык та, дуслаштык та

Урыннарга утырыйк

"Йөзек салыш" уенын

Бергәләп уйнап алыйк!

*(Санамыш ярдәмендә йөзек салучыны билгелиләр)*

**1 нче бала:** Йөзек салучыны үзем билгелим!

Санамыш:

Әке, бәке, кыек сәке

Саескан, чыпчык,

Син кал, бу –чык!

Тотылган уенчыларга җәза: шигырь сөйләү.

**Малайлар**: Без сезгә бүләккә бию дә алып килдек.

**(***Малайлар бии)*

**Кызлар**: Булдырасыз икән, бигрәк оста биедегез. Без дә үзебезнең һөнәребезне күрсәтик әле сезгә!

**"Аулак өй"** *(Луиза Батыр-Болгари көе, Гарифҗан Мөхәммәтшин сүзләре)* **җыры башкарыла**

Ә хәзер, әйдәгез, бергә күңелле итеп "Капкалы" уенын уйнап алабыз!

Тотылган уенчыларга җәза: мәкальләр әйтергә.

1. Кем эшләми, шул ашамый.
2. Җиде тапкыр үлчә, бер тапкыр кис.
3. Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.
4. Китап – белем чишмәсе.
5. Икмәк – иң зур байлык.

**Кыз**: Малайлар, тагын нинди һөнәрләрегез бар?

**Малай:** Әйдәгез, табышмаклар әйтешәбез!

1. Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач. ***(Йолдызлар һәм ай)***
2. "Ак ашьяулык таптым, җир өстенә яптым" ***(Кар)***
3. Җир астында җиз бүкән.
   Ул ни икән? (Бәрәңге)
4. Утыра бер ак чүлмәк,
   Өстенә кигән йөз күлмәк. ***(Кәбестә)***
5. Кечкенә генә йорт,
   Эче тулы корт. ***(Кыяр)***

6. Җәен соры, кышын ак,

   Аңа шулай яхшырак. ***(Куян)***

7. Бер нәрсә тегә белми,

   Энәләр тагып йөри. ***(Керпе)***

**Малай**: Миңа бабаем “Уклау тәгәрәтү” уенын да өйрәткән иде. Әйдәгез, уйныйбызмы?

**Балалар:** Әйдәгез әле, әйдәгез!

Җәзага балалар халык ашларын әйтешәләр: өчпочмак, чәк-чәк, кыстыбый, кош теле, тәбикмәк, бәлеш һ.б.

*(Залга әби керә)*

**Әби:** Иии балалар, сезне ишеттем дә, исемә төште. Мин дә бит өчпочмаклар пешергән идем. Әйдәгез, шул өчпочмаклар белән тәмләп чәй эчәбез.

*(Бөтенесе бергә өстәл артына утырып чәй эчәләр)*

**Алып баручы:** Дуслык җебе өзелмәс ул,

Халык моңы бер җирдә.

Безнең мондый очрашулар

Истә калсын гомергә.

***Татар халкының милли бәйрәме –Аулак өй***

***Мөһәммәдиева Энҗе Рафис кызы.***
***Сәйфетдинова Гөлия Зөфәр кызы.***
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Салавыч балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Максат:** балаларны татар халкының милли гореф-гадәтләре белән таныштыруны дәвам итү; балаларда бу гореф гадәтләргә,йолаларга хөрмәт,ихтирам тәрбияләү,милли җырлы- биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү, балаларның сүз байлыкларын арттыру.

**Җиһазлау**: зал бәйрәмчә бизәлә-чиккән сөлгеләр,өстәлдә самовар белән чашкалар, йон эрли торган каба .

**Бәйрәм барышы.**

Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар!

Менә сез дә килеп җиткәнсез.

Безнең бакчабызның шау тормышын

Күреп китик әле, дигәнсез.

Исәнмесез, кадерле дуслар!

Хәерле көн сезгә бу җирдә.

«Аулак өй» кичәсен карарга

Чакырдык без бүген сезне дә.

Онытылган гореф — гадәтләрне

Яңартабыз хәзер көннән-көн.

Уен йолалары, җыр- биюе,

Һәр киләчәк көнне бизәсен.

*Сәхнә артыннан машина тавышы килә, Әби сәзләре ишетелә: Ярар, балалар, исән-сау, хәвеф-хәтәрсез генә йөреп кайтыгыз. Кыз белән Әби сәхнәгә чыгалар,Әби йон эрләргә утыра,кыз бала бер читкә барып, ноутбуктан нәрсәдер карап утыра.*

**Әби**: Кызым,әти-әниең кунакка киткәч, өйләр буш булып, күңелсезләнеп калды, бар булмаса күрше әбиеңне чакырып кер әле, бер сөйләшеп, чәйләп алырбыз.

**Кыз:** Ярый, әбекәй хәзер. (Кыз телефоннан күрше кызына шалтырата:

-__________, әниләр кунакка киттеләр, әбиең белән безгә керегез, әби чәй эчергә чакыра.

**Әби**: Әй алланың рәхмәте, кара инде бу дөнья дигәннәрен генә бер, өйдән дә чыгасы юк, күршеләрне дә телефоннан гына чакырып яталар хәзер балалар.

**Ишек шакыйлар.**

**Исәнләшеп күрше әби белән кыз керә.**

**Күрше әби:** Исәнмесез, саумысез! Нишләп ятасыз,Хәлләрегез беркөеме?

**Әби**: Түрдән уз күрше. Алланың биргәненә шөкер. Балалар кунакка киткән иде. Менә онык белән икәү боегып тик утырабыз. Бер утырып сөйләшеп, чәйләп тә алырбыз дип сезне дәштергән идем.

**Кызлар бер читтә мәш килеп ноутбуктан әйбер карыйлар.**

**Әби:** Күршекәем, бу балаларны гына кара әле бер, шул пласма тактага башлары белән кереп чумалар да дөньяларын онытталар.Бөтен тормышлары шул тартмада диярсең.

**Күрше әби:** әйтмәдә генә инде ахирәткәем. Замана балалары шул.

Эх,бар иде бит безнең яшь чаклар. Егетләр гармун уйнап,җырлап урам әйләнерләр иде,кызлар өйләрдә кешегә сиздермичә генә егетләрне көтеп утыралар иде. Эх, хәзер яшьләр элекке без уйнаган уеннарны оныттылар шул.Заманаларны шушы телевизор,компьютер дигән зәхмәт басты бит.

**Әби**: Шулай шул бик дөрес сөйлисең,Һәрбер кеше үз почмагында бикләнеп тик утыра.Бер матур итеп җырлый,бии белмиләр.Күңелле итеп ял итә белмиләр.Безнең замандагы аулак өйләрне генә әйт әле син!!.

**Кыз**: Әбекәй, нәрсә соң ул аулак өй ? Ул ничек була ? Сөйләгез әле безгә дә.

**Әби**: Берәр кыз яки егетнең әти-әнисе кунакка яки берәр җиргә китсә, бу өйдә аулак өй оештыралар иде.Кызлар янына егетләр килә. Шул чагында китә инде уен-көлке,җыр-бию,такмак әйтешү.Бик күнелле була да инде.

**2 Кыз:** әбекәй,безгә дә өйрәтегез шул вакытта уйнаган уеннарыгызны,җыр- биюләрегезне.

**Әби**: бик рәхәтләнеп. Менә нәкъ бүген әниләрегез дә кунакка китте. Әйдә күршекәем, балаларга бер аулак өй ясап үткәннәрне искә төшереп алыйк әле.

**Күрше әби:** Дөрестән дә, без аларны
Искә төшерик әле.
Халык йоласын кайтарып,
Бер уйнап алыйк әле.

Барыгыз кызым, иптәшләрегезне аулак өйгә чакырыгыз, тиз генә өйне тәртипкә китереп куегыз. Кунаклар килгәндә өй чиста, күркәм булырга тиеш.

**Кызлар телефоннан иптәшләрен чакыралар, өйне тәртипкә салалар.**

**Тыштан ишек шакыйлар.**

**Күрше әби:** Бәрәч, дуслары килеп тә җиттеләр. Каршы ал кызым кунакларны.

**Балалар керә. Бер малай:**

Исәнмесез, саумысез,
Нигә кәҗә саумыйсыз.
Әтәчегез кукәй салган,
Нигә чыгып алмыйсыз!

**Әби:** Хай улым, булдырдың. Безнең элекке сөйли торган сүзләребезне каян белеп сөйләдең әле?

**Малай:** Габдулла бабай өйрәтте. Гөлҗамал әбиләреңә баргач шуны сөйләп кер, мин яшь чакта сөйләгәнне бик ярата иде ул, диде.

**Әби:** Хәй Габдулла бабаң Һаман да онытмаган мени әле ул шигырен. **(Көлешәләр)**

**Күрше әби:** Әйдәгез оланнар, урнашыгыз түрдән. Бүген бездә аулак өй. Ә аулак өйдә без бер дә тик утырмый идек: кайсыбыз чигү чигә, бәйләү бәйли, кемдер каз каурые сыдыра,

йомгак чорный. Җырлап, биеп, төрле уеннар уйнап, күңел ачыгыз, без дә үткән яшьлекләрне искә алырбыз.

**Балалар үзләре алып килгән кул эшләрен эшлиләр.**

**Әби:** Сез инде балалар без элек яратып уйнаган уеннарны белми торгансыздыр.

**1 кыз:** И әбекәй, нишләп белмәскә, безгә бит бакчада татар халык уеннарын өйрәтеп, уйнатып торалар. Дусларым әйдәгез «Йөзек салыш» уенын уйныйбыз (йөзек күрсәтеп):

Кашлы йөзек кулымда
Карагыз әле монда.
Йөзек кемгә эләгә
Шигырь сөйләп күрсәтә.

**(Балалар тезелешеп кулларын-кулга куеп утыралар, йөзек салучы кыз бер баланың кулына йөзек сала, барсын да үтеп чыккач сорый):**

— Йөзек кемдә, йөгереп чык, - ди.
— Йөзек миндә, мин шигырь сөйлим.
Шигырь сөйли.

**Уен берничә тапкыр уйнала.**

**2 кыз:** Мин дә бер бик матур уен беләм. "Алтын капка" дип атала. Әйдәгез әле дусларым, уйнап алыйк әле.

**«Алтын капка» уены.** ( Санамыш әйтеп чыгарылган ике бала кулга-кул тотынып, кулларын өскә күтәреп «капка ясыйлар», калган балалар җитәкләшеп бу «капкадан» кереп—чыгып йөриләр, уен сүләре беткәч куллар төшерелә, «капкага» эләккән бала нәрсәдер эшләп күрсәтергә тиеш).

Бу безнең алтын капка
Ачык тот аны, япма.
Кереп чыгып йөрибез,
Тукталмыйбыз беребез.

Капкага җил кагылса
Шап иттереп ябыла,
Көтеп торып керәсең
Эләктерик берәрсен.

**Капкага эләккән балалар такмак әйтә:**

1.Тәрәзәңә карар идем,
Тәрәзәңә боз каткан.
Кунак кызың ялкау икән
Сәгать сигездә яткан.

2. Иртән торып эшкә чыксам,
Кәҗәләр кар көриләр.
Чикерткәләр туфли киеп
Җырлап — биеп йөриләр.

3.Аргы төркемнән килдеңме,

Бирге төркемнән килдеңме?

Без сагынганны белдеңме,

Үзең сагынып килдеңме?

**Әби:** Ай-яй, булдырасыз икән балалар. Сезгә карап күңелләр сөенеп утыра, шулай бит күршекәем?

**Күрше әби:** Шулай, шулай ахирәткәем. Инде мин бу уеннарны белүче юктыр дигән идем, менә бит оланнар ничек матур итеп уйнап күрсәттеләр, рәхмәт яугырлары!

**3кыз:** Әле без “Миңлебай” уенын да беләбез, әби. Әйдәгез дусларым, басыгыз әле түгәрәккә.

**Балалар түгәрәк ясап басалар, санамыш белән Миңлебайны уртага чыгаралар.**

**4кыз.** Кызлар, малайлар, ә без нишләп утырабыз, йокыга китәсез түгелме соң инде? Әйдәгез әле, болар бер нәрсә дә белмиләр икән дип уйламасыннар, үзебезнең “Куш кулым” уенын уйнап күрсәтик әле.

**Балалар парлашып түгәрәккә басалар. “Куш кулым” уены уйнала**

1.Уйнадык та, җырладык та

Бүген бездә аулак өй,

Аулак өйдә булмаганнар

Безнең күңелне аңламый.

2.Татар халык иҗатын

Милли гореф – гадәтен

Тугры халык антларга

Сүз бирәбез сакларга!

**Әби:** Әй балалар. Халкыбызның онытылып барган гореф-гадәтләрен, уеннарын уйнап, җырларын җырлап сез безне бүген яшьлегебезгә кайтарып килдегез.

**Күрше әби**: Бигрәк тә күңелле ял булды. Болай булгач гореф- гадәтләребез югалмый икән. Рәхмәт сезгә, балалар!

**Әби:** Аулак өйдә уйнала торган уеннарны, җырлана торган җырларны бер көндә генә башкарып бетереп булмый. Хөрмәтле кунаклар! Туган телебезне, гореф-гадәтләребезне саклыйк, киләчәк буыннарга да тапшырыйк! Шуның белән безнең Аулак өй кичәсе тәмам, игътибарыгыз өчен рәхмәт!

***Карга боткасы***

***Бурнашева Альбина Марат кызы.***

*Татарстан Республикасы Баулы муниципаль*
*районы "Кызылъяр балалар бакчасы"*
*мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Алып баручы:** Бу язгы бәйрәм чәчү эшләре төгәлләнгәннән соң оештырыла. Иртән балалар күршедән-күршегә йөреп ботка өчен кирәкле азык-төлек җыялар. Азык-төлек биргән кешеләргә мактау сүзләре әйтәләр. Аннары бөтен авыл белән зур казанда ачык һавада ботка пешерәләр, аны авылдашларга өләшәләр. Ботканың бер өлешен кара каргалар өчен дә калдырырга кирәк, чөнки кара каргалар - яз символы. Бу йоланы үткәреп, кешеләр яхшы уңыш алырга өметләнә.

**Максат:** Балаларда туган илгә, туган авылга, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү. Татар халкының иҗатын, тарихын, гореф-гадәтләрен өйрәнүне дәвам итү һәм аңа кызыксынучанлык хисе тәрбияләү.

**Бурычлар:** Балаларны татар халкының мәҗүси бәйрәмнәре белән таныштыруны дәвам итү.

Карга боткасы мәҗүси йола-бәйрәме, ырымнары, уеннары,такмазалары аша балаларның сөйләм телен үстерү.

Халкыбызның борынгы йола-бәйрәмнәренә ихтирам тәрбияләү.

**Методик алымнар:** әңгәмә, уеннар, күрсәтү, сәхнәләштерү.

**Тәрбияченең алдан эшләнгән эше:**

Шигырьләр, милли җырлар, уеннар өйрәнү; залны бизәү өчен җиһазлар әзерләү, костюмнар әзерләү.

**Күңел ачу иртәсенең барышы:**

*Зал матур итеп бизәлгән: бер якта 2өй тора, залның түрендә аланлык,*

**А.б:** Бу язгы бәйрәм чәчүлекләр төгәлләнгәннән соң оештырыла. Иртән балалар күршедән-күршегә йөреп ботка өчен кирәкле азык-төлек җыялар. Азык-төлек биргән кешеләргә мактау сүзләре әйтәләр

-балалар өйдән-өйгә йореп кирәкле ризык күчтәнәчләр җыялар.

**Балалар:Әйдәгез,әйдәгез!**

**1нче бала.** Өйдәме түтәй?

Җәтрәк бир күкәй.

Бирсәң безгә өч күкәй,

Тавыгың салыр йөз күкәй.

Май кирәк, ярма кирәк,

Карга туена бар да кирәк.

**2нче бала.** Ал да итәрбез әле,

Гөл дә итәрбез әле

Матур җырлар җырлый-җырлый

Бәйрәм итәрбез әле.

**3нче бала.** Аягыбыз җиңел булсын,

Мал-туарыгыз күп булсын,

Кайгы-хәсрәт күрмәгез

Хуш, сау булыгыз!

**4нче бала**. Сый җитәрлек булды,карга боткасын пешерергә кай тирәгә барыйк икән?

**Каргалар**: 1. Карр-каааар. Очабыз, җылы илләрдән, очабыз дусларыбыз янына.

2. Исәнмесез, балалар,

Очрашуыбызга без бик шат.

**А.б:** сөйләгез әле, кошлар, сез кайда булдыгыз?

Сөйләгез әле, кошлар, сез нәрсә күрдегез?

**Каргалар :** эссе илләрдә эссе җәй,

Анда кыш та, кар да юк.

Анда  филләр йөри

 Көне буе маймыллар кычкыра.

Анда лиана агачлары, пальмаларда бананар үсә.

**А.б:** өйдән еракта яхшы яшәдегезме? Сез таныш булмаган илләрдә кем белән дус идегез?

**Каргалар:** 1. Без авылны сагындык,

Чыңлап торган инеш буйларын.

2.Агачлардагы сыерчык ояларын,

Күрше чыпчыкларны,өебез каенлыкны.

**А.б.** Балалар димәк киттек каенлыкка.Менә нихәят килеп җиттек, казаннарны,кәрзиннәрне куегыз, чиләкләрегезне тагыгыз. Матур итеп биегез

**Чиләкләр белән бию**

**“Түбәтәй”**

**Бала**. Ялтыравык әйберләрне

Ташый ул оясына

“Карак” дигән яман аты

Чыккандыр менә шуңа. *(саескан.)*

**Саескан**: Бар язган әйбергә ышанырга ярамый ич, минем кирәгем чыгар, барыйм әле миндә сезнең белән.

**Балалар:** саескан саескан әйдә син дә безнең белән тәмле ботка пешерерсең, без нәни дусларыңны сыйларсың!

**Саескан**: Булыр, балалар, бары да булыр.

Карга килер – казан асар,

Торна килер – тоз салыр,

Тукран  килер – салма салыр,

Песнәк килер – пешерер,

Чыпчык килер – тикшерер,

Карга ашап бетерер.

Кап та коп.

*(көлешәләр)*

**А.б*:*** Балалар,ботка пешкәнче,рәхәтләнеп уйнап алыбыз мы әллә?

***“Чума үрдәк,чума каз.”уены***

***“Башмакчы”***

***“Болында”***

**Саескан:** Балалар, уеннарыгыздан туктап торыгыз:

Ботка пеште, балалар,чәй кайнады.*(ботка бүлә)*

-Менә бусы җир – анага

Җир атасы – җирән сакал!

Җир анасы – асыл бикә!

Түбәсенә туклыгың бир,

Тамырына ныклыгың бир,

Ил өстенә муллыгың бир,

Ил эчендә безгә дә бир!

Менә бусы суга

Су иясе тотмасын!

Менә бусы күккә

Яңгыр бирсен!

Кояшлы җылы көннәр бирсен!

Илгә туклык, гаиләгә иминлек килсен!

-Бусы каргаларга.Канат очларында язны алып килгән өчен.

*(җиргә сибә)*

**А б:** Менә инде сыйландык, килегез минем янга, тугәрәккә басып уйнап җырлар җырлап алыйк!

**Түгәрәк уены:"Бир кулыңны"**

**"Без бәхетле шат балала"уены**

**А.б.** Хөрмәтле, дуслар! Иң күңелле язгы бәйрәмнәрнең берсе"Карга боткасы" тәмам, кайтыр вакыт җитте.

Сәламәт булыгыз, зур булып үсегез, сабыйларны рәнҗетмәгез, өлкәннәрне хөрмәт итегез. Тату бәхетле булып яшәгез!

***Читекчеләр данын югалтмыйк!***

***Гыйльметдинова Әлфинур Габдуллаҗан кызы.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 1 нче балалар бакчасы" муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

**Максат:** Балаларны татар мили мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итү.

Татар читекләренең үзенә генә хас булган билгеләрен өйрәнү, сүз байлыгын баету.

Балаларыбызда күн белән эшләүче осталарыбыз хезмәтенә кызыксыну уяту, читекче һөнәренә ихтирам тәрбияләү.

**Җиһазлау:** милли киемнәр, читекләр, күн эшкәртмәләр.

***Зал элекке өй рәвешендә бизәлгән, сандыктан милли чигүле кул эш әйберләре күренә.***

**Алып баручы:**

Күрегезче,нинди матур кул эшләре...

Сизелә монда уңган кешеләр кулы...

Колагымда чыңлый татар моңы,

Еракларга илтә безне хәтер юлы...

***Тәрбиячеләр кулларындагы әйберләр турында сөйлиләр:***

Татар хатын-кызлары

Эшнең серен белгәннәр.

Кич утырып, җырлар җырлап,

Кулъяулыклар чиккәннәр.

Бу сөлгеләр,эскәтерләр

Тамбур белән чигелгән.

Мендәр тышлары, япмалар

Гел чәчәккә күмелгән.

Бай тарихы булган милләтемнең

Ачыйк әле асыл серләрен.

Кайдан килде икән бу читекләр

Кемнәр текте икән күннәрен?

**Алып баручы:**

“Кайдан килде икән бу читекләр”-дип аптырарлык урын юк безгә:

Арча ягы читекчеләр белән данлыклы.Арча данын еракларга таратуда зур өлеш керткән читек чигүче Фәридә Кәримуллина бездә кунакта. Ул күн белән эшләү серләрен безгә өйрәтер.

Әйдәгез, сүзне Фәридә апайга бирик.

-40 елдан артык чигәм инде,-ди ул.Менә күрәсез,читек,чүәкләр-алар төрле бит.Чигү сурәтләре,төсләре берсеннән-берсе матур.Кызыл төс туйдырса,зәңгәренә тотынабыз.Монысы тагын да матуррак булды дия-дия үсенеп эшлибез.-ди Фәридә апа.

*Фәридә апай хезмәте белән таныштыра, үрнәкләр күрсәтә*

**Тәрбияче:**

Калфак,яулык, күлмәк,камзул-

Боларын инде беләм.

Аягыгызда нәрсә соң?

Шуны беләсем килә.

**Икенче тәрбияче:**

Бизәк төшкән итекләрне

Читекләр дип йөрткәннәр.

Аларны татар кызлары

Бәйрәмнәргә кигәннәр.

**Алып баручы:**

Эх, Арча читекләре

Чигүле,искитмәле!

Арча читекләрен киеп

Очып биеп кит әле.

**Бию “Эх, Арча читекләре”**

**Алып баручы:**

Биегән саен биетә

Чигүле читекләре.

Үзегезгә килешеп тора

Арчаның читекләре.

Бәйрәмнәргә киеп, биеп кенә калмаганнар, читекне олылып җырлар язылган,уеннар уйналган. Әйдәгез, бер уен:

**“Читекче” уены.**

Әй, читекче, читекче,

Син бит оста тегүче,

Кызганмыйча бу эшең

Бирче миңа читегең.

-Бу каюлы читегем беренче килүчегә...

-шигырь сөйләүчегә:

Салават күпере төсле

Җемелди читекләр дә.

Останың кул җылыларын

Тоямын читекләрдә.

-тел шомарткыч әйтүчегә:

Читек чигә читекче

Читекчедән күрмәкче.

Чүлмәген дә чүлмәкче

Читек кебек чикмәкче.

**Алып баручы:**

Уйный-уйный,

Җырлый-җырлый,

Бәйрәм итик гел бергә.

Безнең бәйрәм гөрләп шулай

Истә калсын күңелдә.

**Җыр “Эх, Арча читекләре”**

**Алып баручы:**

Кулны-кулга тотынып,

Читекләргә карашып,

Уйнасак  шулай бергә

Күңелсез булмас бер дә.

**Уен “Кәрия-Зәкәрия”***(оста читекче дип җырлаганда,Фәридә апайны уртага алабыз)*

Буыннардан күчә-күчә килсен иде

Халкыбызның асыл киеме.

Хәзер инде Арчабызны данлый

Күн чәчәкле Арча читеге.

Сез әлегә кечкенә

Сез киләчәк җимешләре.

Сезнең кулга күчәр әле

Читек чигү эшләре.

-Хөрмәтле Фәридә апай, сезнең күңел җылыларыгыз кереп чигелгән читекләрне балалар бик яратып, кызыгып  карадылар. Катлаулы хезмәтегез өчен бик зур рәхмәт. Киләчәктә читек чигү эшләребез тәрбияләгән балалар кулына да күчәр дип ышанасы килә.

***Гаиләм иң зур хәзинәм***

***Хаммадова Лилия Ясәви кызы.***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Красносельский «Рябинушка» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда гаилә кыйммәтләрен һәм гореф- гадәтләрен ныгыту; балаларда гаилә тарихына кызыксыну уяту; өлкән буынга хөрмәт тәрбияләү; балалар – ата-ана мөнәсәбәтләрен ныгыту.

**Бурычлар:**

Тәрбия бирү, укыту:

- Балаларның гаилә, туганлык бәйләнешләре һәм һәр кеше тормышында гаиләнең әһәмияте турында күзаллауларын киңәйтү;
- Гаилә традицияләре һәм гореф-гадәтләренең төрлелеге белән таныштыру;
- Балаларның сүзлек запасын гаилә әгъзаларын, гореф-гадәтләрен белдерүче сүзләр белән баету;
- Гаилә белән бәйле үз фикерләреңне һәм хисләреңне чагылдыра белүне формалаштыру.

Үстерү:

- Балаларның иҗади сәләтләрен үстерү (җырлауда, биюләрдә, инсценировкаларда);
- Аралашу күнекмәләрен үстерү (уеннарда, яшьтәшләр һәм өлкәннәр белән аралашуда);
- Игътибар, хәтер, фикерләүне үстерерү.

Тәрбия:

- Гаилә әгъзаларына, бигрәк тә өлкән буынга карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү;
- Үз гаиләсе өчен горурлык хисе формалаштыру;

- Башка кешеләрнең гаилә традицияләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

**Кулланыла торган технологияләр:**

Мәгълүмат-коммуникация технологияләре (ИКТ):

Мультимедиа презентациясен гаиләләрнең фотосурәтләрен, традицияләрне сурәтләгән иллюстрацияләрне күрсәтү өчен куллану;

Бәйрәм атмосферасын тудыру өчен музыкаль озата баруны (җырларның фонограммаларын, минусовкаларын) куллану;

Видеоматериаллар куллану (гаилә традицияләре турында кыска видеороликлар).

Уен технологияләре:

Балаларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру һәм уңай эмоциональ фон булдыру өчен төрле уеннар һәм конкурслар куллану.

Сәламәтлекне саклау технологияләре:

Балаларның артык аруын булдырмау өчен эшчәнлек төрләрен (акыл, хәрәкәт, эмоциональ) чиратлаштыру;

Уңай психологик атмосфера тудыру.

Проект эшчәнлеге технологиясе:

Проект эшчәнлеге кысаларында тема белән алдан танышу (әңгәмәләр, фотографияләр карау, рәсем ясау, үз гаиләң турында хикәяләр язу).

**Мәгариф өлкәләре (интеграция): «**Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгать-эстетик үсеш», «Физик үсеш».

**Методлар һәм алымнар:** күрсәтмә, сүз, уен, практик, проблемалы якын килү, индивидуаль якын килү, шәхескә юнәлтелгән якын килү.

*Бүлмә балаларның алдан алып килгән гаилә фотосурәтләре белән бизәлгән.*
*Балалар «Минем гаиләм» җырын башкаралар*

**Алып баручы:**

Аш кашыгы – агачтан,

Чәй кашыгы – көмештән.

Җиз самавыр кайнап тора –

Суы - изге инештән.

Әбием һәм әнием Безгә бәлеш пешергән.

Бәлеш уңган, күрәсең,

Өйгә тәмле ис тулган.

Әби-бабай, әти-әни,

Мин, нәни кыз, Наилә.

Менә нинди сокландыргыч

Безнең матур гаилә!

Исәнмесез, кадерле кунаклар! Бүген бездә кеше өчен иң кадерле булган – гаиләбезгә багышланган искиткеч бәйрәм! Гаилә – җир йөзендәге иң җылы, һәм ышанычлы урын, анда безне һәрвакыт яраталар һәм ярдәм итәләр. Гаилә җылысын саклап торучы бер әйбер ул – гаилә традицияләре!

**1нче бала:**

Әгәр миннән сорасагыз,

«Бәхет нәрсә, -диеп-Айсылу?»

Бер дә уйлап тормыйм, җавап бирәм Бәхет –әти-
әниле булу.

**2нче бала:**

Ике иңемдәге канатымның
Берсе-газиз әнием.

Икенчесе-көчле рухлы
Таянычым минем,әтием.

**3нче бала:**

Тәрәзә төбен тутырган,

Дәү әнием гөлләре.

Нинди генә чәчәкләр юк,

Өйгә тулган исләре.

**4 нче бала:**

Көнаралаш су сибәргә
Йомшартырга төпләрен,
Өйрәтте дәү әни үземне
Яратырга гөлләрен.

**5нче бала:**

Үсеп инде буйга китте,

Әти белән утырткан ак каен. Көндә
безгә сәләм бирә

Урамга чыккан саен.

**6нчы бала:**

Әнкәм пешергән бәлешнең,
Онытмыйм тәмле исен

Бар гаилә бәлеш ашарга,

Җыелабыз без кичен.

**Алып баручы**: Гаилә гореф-гадәтләрен хәтеребез алтын кебек саклый. Алар безне балачактан ук чолгап алалар, якыннарның кадерен белергә өйрәтәләр. Хөрмәтле кунаклар, безнең сезгә күчтәнәчебез бар. Игътибар экранга.

*(экранга балалар катнашындагы видео куела. Биредә балалар үзләренең гаиләләре турында, гаиләдә булган гореф-гадәтләре турында кыскача сөйлиләр).*

**Алып баручы:** Хөрмәтле әти-әниләр, сезгә безнең балалар белән әзерләгән бүләк ошаган дип уйлыйбыз. Киләчәктә дә шундый матур гаилә булып, бер- берегезне шатландырып яшәгез!

Балалар хәзер без сезнең белән уен уйныйбыз. Экранда гаиләне берләштерүче йолалардан фотосурәтләр күрсәтеләчәк, әгәр дә сезнең дә гаиләгездә шундый йолалар бар икән, сез урыныгыздан торып басасыз, булмаса, утырасыз. Сез әзерме?

**Балалар:** Әйе!

*Экранда чыга торган фотосурәтләр*

1. *Гаилә белән туган көннәрне уздыру*



2. *Йоклар алдыннан китап уку*



3. *Гаилә белән өстәл уеннары уйнау*



4. *Гаилә белән кино карау*



5. *Гаилә белән табигатьтә ял итү*



6. *Яңа елга гаилә белән чыршы бизәү*



7. *Гаилә белән бергә ашарга пешерү*



**Алып баручы:** Афәрин, балалар! Ә сез тагын нинди гаилә йолаларын беләсез? *(балалар үз вариантларын әйтәләр).* Күрдек, әти-әниләрегез сезнең белән төрле чаралар уздыралар икән. Ә хәзер әйдәгез аларны бирегә чакырыйк.

*(Һәр бала янына әтисе яисә әнисе капма-каршы утыра, балаларга да, әти- әниләргә дә кәгазь битләре һәм карандашлар таратыла)*

**Алып баручы:** Балалар, хөрмәтле әти-әниләр хәзер без сезнең белән рәсемнәр ясыйбыз, тик бу гади генә рәсемнәр түгел. Балалар үзләренең әти-әниләре белән иң яраткан, ә әти-әниләр

балалары белән иң яраткан вакыт үткәрү чарасын яисә берәр йоланы ясарга тиеш буласыз, ә соңыннан уй-фикерләрегез туры киләме юкмы икәнен күрәчәкбез.

*(рәсем ясау барышында гаилә турында җыр яңгырый)*

**Алып баручы**: Сездә нинди яхшы рәсемнәр килеп чыкты! Алар сезгә якыннарыгыз һәм гаилә гореф-гадәтләрегез турында искә төшереп торачак.

**Алып баручы:** Рәсем ясауны төгәлләдек, ә хәзер сүз сезгә хөрмәтле әти-әниләр һәм балалар!

*(һәр гаилә үзенең рәсеме турында сөйләп китә) (балалар башкаруында «Әниемә булышам» дигән бию)*

**Алып баручы:** Бәйрәмебез ахырына якынлаша, балалар, әйдәгез тагын бер кат безнең өчен гаилә нәрсә икәнен йомгаклап әйтеп чыгыйк.

**1нче бала:** Гаилә – ул гади сүз, тик аның белән бик кадерле без.

**2нче бала**: Гаиләдә җылылык, уңайлык һәм наз, тормыш монда – әкияттәге кебек ямьле.

**3нче бала:** Гаилә гореф-гадәтләре безне балачактан әйләндереп ала һәм мәңге хәтердә яши.

**3нче бала:** Гаилә ул зур табын артында бергә җыелу, пироглар пешерү һәм узганнарны искә төшерү, бәйрәмнәрдә бүләкләр бирү.

**3нче бала:** Гаилә гореф-гадәтләре – ул хәзинә.

**Алып баручы:** Хөрмәтле әти-әниләр, шуның белән безнең бәйрәмебез ахырына якынлашты, ә бүгенге гүзәл мизгелне мәңге истә калдыру өчен шушы истәлекне бүләкне балалардан кабул итеп алыгыз! Сезнең гаиләләрегезгә тынычлык, яхшылык һәм мәхәббәт телибез!

*(балалар әти-әниләренә алдан ясалган гаилә шәҗәрәсен тапшыралар) (Бәйрәм балалар башкаруында җыр белән тәмамлана.)*

***Аулак өй***

***Әхәтова Рәзинә Камил кызы.***

***Марданова Әлфия Рашит кызы.***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының*
*“Катнаш төрдәге Балтач 4 нче балалар бакчасы”*
*муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Максат:** балаларны татар халкының милли гореф-гадәтләре белән таныштыруны дәвам итү; балаларда бу гореф гадәтләргә,йолаларга хөрмәт,ихтирам тәрбияләү,милли җырлы- биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү, балаларның сүз байлыкларын арттыру.

**Җиһазлау**: зал бәйрәмчә бизәлә - чиккән сөлгеләр,өстәлдә самовар белән чокырлар

**Бәйрәм барышы.**

(Бер кыз һәм бер малай залга чыгалар)

**Мурат:** Бүген безнең бакчабыз да

Шундый рәхәт күңелле

Чөнки кунак булып безгә

Әниләребез килде.

**Энҗе:** Әниләрнең бәйрәме белән

Чын күңелдән котлыйбыз

Озын гомер телик сезгә

Юлларыгыз уң булсын

Матур бәйрәм көнегездә

Теләкләр кабул булсын

**Мурат:** Энҗе, бәйрәмне башларга вакыт. Кая соң безнең балалар?

**Энҗе:** Әй Мурат, алар әллә кайчан әзер инде, безнең чакырганны гына көтәләр.

**Мурат:** Алай булгач залга балаларны чакырабыз.

**Энҗе:** Рәхим итегез дусларым. (төркем балалары залга керәләр, ярым әйләнә ясап басалар. Әниләргә багышлап шигырь сөйлиләр)

1.Җир йөзенең бөтен матурлыгын

Килә сезгә бүләк итәсе

Дөньядагы матур сүзләрне дә

Иң җылысын сезгә әйтәсе.

2.Минем әнием һәрвакыт
Иркәләп дәшә сөеп
Күңелемне күтәрә ул
Якты йолдызым диеп
Бүген иртән иртүк торгач
Кызык ачыш ясадым
Мин аның йолдызы булсам
Әни минем кояшым.
3.Әни сүзе- иң бөек сүз
Юк аңа һичбер алмаш
Иң-иң әйбәт кешеләр дә
Әни кебек була алмас
4.Дөньяда иң акыллы
Иң уңган минем әни
Менә шуңа синең яннан
Бер дә китәсе килми
5.Әнием минем матур
Күзләре якты көләч
Шундый күңелле була
Ул өйгә кайтып кергәч
6.Әни кебек булсам иде
Гел көлеп торсам иде
Тирә-юньгә әни кебек
Гел нурлар чәчсәм иде
7.Иң кадерле, иң хөрмәтле
Булсын җирдә әниләр
Әниләрне кадерләсәк
Тыныч булыр көннәр
8.Әниләрнең назы белән
Без керәбез һәр көнгә.
Кояш кирәк җир йөзенә
Әни кирәк һәркемгә.
9.Әнием минем кадерлем
Миңа тормыш бүләк иткән.
Сөеп, иркәләп устергән

Ул кочаклап мине үпкән.

10.Без сине бик яратабыз

Бәйрәм белән котлыйбыз.

Бүләк итеп үзегезгә

Бер матур җыр җырлыйбыз.

11.Әнием гел балкып тора

Күктәге йолдыз кебек.

Мин дә тырышам булырга

Газиз әнием кебек.

12.Өйрәтәсең һәр нәрсәгә

Зур сабырлыклар белән.

Рәхмәт әйтеп тәбриклим

Әниләр көне белән.

13.Иренә белми әнием

Көн буе эшләп арый.

Күңелемне юатырга

Син бар бит әле ярый.

14.Авыр сүзләр әйтмик әниләргә

Аларга без итик гел ярдәм

Әниләрне саклыйк, яратыйк.

Калсын әле алар гел күркәм.

(Балалар музыка астында залдан чыгалар, залга әби керә)

**Әби:** Әй, шул арада караңгы да төште, көннең узганы вак-төяк эшләр белән сизелми дә үтте. Хәзер үк ятсам, төн бик озын әле, боргаланып кына ятармын. Әзрәк носки бәйләп утырсам да ярар иде (ишек шакыйлар)

**Күрше әби:** Нихәл, Зәйтүнә күрше. Исән-сау гына торасыңмы? Бүген ишегалдында да күренмәдең. Тукта, мин әйтәм, уты бар, бер кереп хәлен белеп чыгыйм әле дидем

**Әби:** Әй, рәхмәт күршекәем.

Күрше әби: Әйдә, йортка бер дога кылыйк.

**Әби**: Үзеннең хәлләрен ничек соң Мәфтуха?

**Күрше әби:** Әй, картларча инде Зәйтүнә.

**Әби:** Эх, бар иде бит безнең дә яшь чаклар.Егетләр урам тутырып җырлап әйләнерләр иде, ә кызлар аулак өйләрдә чигү чигеп, җырлап егетләрне көтеп утырыр иде.

**Күрше әби:** Ә егетләр килгәч китәр уен-көлке, җыр, бию, такмак әйтешү.

**Әби:** Аулак өй икәнен белеп күрше рус, мари,удмурт авылларыннан да егет-кызлар килеп җитәр иде. Сагынып сөйләргә генә калды (ишек шакыйлар)

**Күрше әби:** Чү. Киләсе кунагын бар идеме әллә?

**Әби:** Юк, әллә бер-бер хәл бар микән, төнгә каршы. Кем бар анда?

Оныкчык керә: Әбекәй матурым исәнме? Әйбәт кенә яшәп ятасынмы?

**Әби:** Әйбәт кызым.  Хәл белергә килдеңмени? Хәзер чәй куеп җибәрәм.

**Оныкчык:** Юк-юк әбекәем,чәй куеп торма. Минем сиңа бер үтенечем бар иде.  Әбекәем, кызлар белән чигү чигеп синдә кич утырыйк әле. Каршы килмә инде әбекәем.

**Әби:** Ярар, мине барыбер Мәфтуха әбиең чакыра кергән иде ( күз кысышалар) Тик кызым тәртипле генә утырыгыз, егетләр кертә күрмәгез, әти-әниләрегез ишетеп мине сүзгә калдырмагыз.

**Оныкчык:** Юк,юк әбекәй нинди егетләр ди ул.(Әбиләр китә) Кызлар, әйдәгез аулак өйгә! (кызлар керә) Булды кызлар, әбине ризалаттым.

**2 кыз:** Әйдәгез кызлар, кулъяулык чигеп алыйк.

**3 кыз:** Карагыз әле кызлар, ничек матур чыкты минем бизәкләрем.

**4 кыз**: Әйдә күзегезне бетереп утырмагыз. Кызлар, әбекәйнең матур шәлләре күп икән әйдәгез шулар белән бер биеп алыйк әле

( Шәлләр белән бию.)

**5 кыз:** Бик матур биедек. Әйдә йөзек  салыш уйныйбыз. (Сала) Кемдә йөзек сикереп чык! Алиягә нинди җәза бирәбез.

**6 кыз:** Табышмакка җавап бирсен. Ике корсаклы, 4 колаклы ул нәрсә?

**7 кыз:** Бигрәк шаян инде син Фәридә. Ике корсаклы әйбер буламыни?

**6 кыз** Була шул була. Каз мамыгыннан нәрсә ясыйлар?

**Бергә:** Мендәр.

Тагын йөзек салыш.

**1 кыз**: Кәримәгә нинди җәза бирәбез

**2 кыз:** Кайсы егетне ярата шуның исемен әйтсен

**3 кыз:** Әй шаярмагыз әле кызлар (Ишек шакыйлар)

**4 кыз:** Кызлар егетләр килә кертәбезме?

**5 кыз:** Егетләр кертмәгәч аулак өй буламени?

Әби-бабайлардан калган йола бит ул.

**6 кыз:** Тик егетләр килгәч тәртипле булыйк . Эләгә инде миңа әбидән.

**7 кыз:** Җырласалар чәнечкеле җыр белән җавап кайтарырбыз.

**1 кыз:** Үпкәләп кайтып китмәсләрме соң?

**2 кыз:** Чын егет булсалар, үпкәләмәсләр.

**Егетләр:**

Сандугачның балалары

Талга кунганнар икән.

Кызларыгыз тырышып эшли

Бигрәк уңганнар икән.

Тәрәзәдән карыйсыз

Карап кемне таныйсыз.

Карап тилмереп торганчы

Ник чакырып алмыйсыз.

Кызлар:

Масаеп йөрмәгез әле

Уйлагыз керү ягын.

Ишекне бикләп куярбыз

Шундый сүз булса тагын.

Егетләр:

Ишекне ача белмиләр

Торабыз өшеп-катып.

Ишегегезне күтәреп

Китәрбез әле кайтып.

**1 кыз**:Бусага хакын җәлләмә

Сиңа киңәш шул егет.

Кызлар йөзен күрәм дисәң

Акча түләп кер егет.

**Кызлар:**

Сезнең ара, безнең ара

Алмагач белән каен.

Әй,дускаем сиңа сәлам

Миләш яфрагы саен.

**Егетләр:**

Сезнең ара-безнең ара.

Арасында таллар бар.

Сездә ничек, бездә шулай

Җырлый торган хәлләр бар.

**Кызлар:**

Алын алырсыз микңн

Гөлен алырсыз микән?

Урталарга чыгып сайлап

Кемне алырсыз икән?

**Егетләр:**

Алларын да алырбыз,

Гөлләрен дә алырбыз.

Күңелебезгә кем ошаса

Шуны сайлап алырбыз.

**1 егет:**

Әйдәгез, дуслар ашыгыйк

Үзебезгә пар табыйк.

Сезнең белән бергәләшеп

Шәп итеп биеп алыйк.

“Татар халык биюе”

(2 әби керә.)

**Әби:** Әстәгъфирулла!Бу ни хәл?Әйттем бит Мәфтуха,күңелем тыныч түгел дип.Егетләр дә керткәннәр.

**Күрше әби:** Һай аллам,кертсә соң.Үзеңнең яшь чакларыңны оныттыңмыни?Алар бит җырлап биеп кенә утырганнар.

**Әби:** Нинди тавышлар килә анда?Ходаем, аулак өй икәнен ишетеп Мализадан удмуртлар килгән бит!

**Балалар керә:** Зёч бюрес, гажано ишиоз!(Удмурт биюе,утыралар)

**Күрше әби:** Әнә тагын киләләр! Болары Улисьялдан мари кызлары!

**Кызлар керә:** Поро кече погалыме, йолташвлак!

(Мари биюе, утыралар)

**Әби:** Чепьядан русс кызлары да килеп җиткәннәр.

**Эльвина:**

Пришли мы к вам в гости,

И с праздником поздравить.

Людей посмотреть, да себя показать.

Пришли мы не с пустыми руками

А с весёлыми танцами!(русс биюе, утыралар)

(этәч кычкыра)

**Әби:**Ишетәсезме, балалар,таң әтәчләре кычкыра.Инде таралырга вакыт!(Балалар теләкләр әйтеп чыгалар)

**Күрше әби:** Ярар, ахирәтем, мин дә чыгыйм, иртәнге намазга да күп калмады.Бик күңелле булды буген.Рәхмәт!

**Әби:**Тыныч йокы, күршекәем.Үзеңә рәхмәт, исән бул!

***Уйнат тальян гармуныңны***

***Искәндәрова Венера Вагыйз кызы.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*«Арча 10нчы балалар бакчасы» муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

**Зал бәйрәмчә бизәлгән.**

**Балалар җиңелчә хәрәкәтләр белән биеп керәләр, урыннарына басалар.**

**Алып баручы***:* Исәнмесез, мөхтәрәм кунаклар, кадерле балалар!Без бүген сезнең белән инде онытылып бара торган, әмма татар халкының иң яраткан уен коралы-тальян гармунга багышланган бәйрәмгә җыелдык. Биредә яңгыраган тальян моңы сабыйларыбызның күңелендә уен коралына карата сүнмәс мәхәббәт очкыны кабызыр дип ышанасы килә.

Чиканас авылыннан,  иң оста гармунчы, тальянчы, һәвәскәр артист Әхлиуллин Вагыйз, бүген сезгә тальян моңнарын бүләк итәчәк. Күңелле ял итегез!

Уйна тальян гармуныңны,
Телләре лә батмасын.
Уят, үзәкләрен өзеп,
Кызлар йоклап ятмасын.

**Тальянын сыздырып, залга Вагыйз Әхлиуллин килеп керә.**

**Вагыйз әфәнде:** Исәнмесез, балалар! Мин Чиканас авылыннан сезнең бәйрәмгә дип ашыгып килдем.

**1 нче бала.** Вагыйз абый, әйдәле,
Хуш киләсең, уз бире.
Кунак булып килер, дип,
Бик нык көттек без сине.

**2 нче бала.** Нәкъ Арча уртасында бардыр,

Бер бакча –«Чишмәкәй» диләр,

Тальянның моңлы тавышыннан

Яңгырап тора, диләр.

**3 нче бала.** Исәнмесез, хәерле көн!

Килеп җиттегезме бәйрәмгә?

Әйдә, сүзне сезгә бирик,

Моң иясен тыңларга.

**Алып баручы:** Исән имин килеп җиттегезме, Вагыйз әфәнде?

**Вагыйз әфәнде:** Аллага шөкер, балакайларым, рәхмәт сезгә. Бүген сезнең бакчагызда Тальян гармун бәйрәме икәнен белгәч, тукта, мин әйтәм, гармунымны алып, "Чишмәкәй" балалар бакчасына барып кайтыйм эле, дим. Менә бик вакытлы килеп җиткәнмен икән.

**Алып баручы:** Ай рәхмәт сиңа, Вагыйз әфәнде, синең тальян моңы безнең балалар һәм кунаклар күңеленә бик хуш килер.

**4 нче бала.** Рәхмәт, Вагыйз абый, килгәнеңә

Бүген безнең бәйрәмгә.

Сыздыр әйдә тальяныңны,

Калсын сагынып сөйләргә.

**Татар халык көйләренә тезмә башкарыла.**

**Алып баручы**. Бүгенге бәйрәмдә, минем музыка укытучым Вагыйз абый Әхлиуллин. Ул безне җырларга өйрәтте. Сезнең көйләрегезне тыңлагач, күңелләр тулып моңланып китте, яшьлекләр искә төште. Вагыйз абый, гармунда уйнаган чакта сезнең дә күңелегез шулай нечкәрә торгандыр, яшь чакларыгыз искә төшә торгандыр? Бала чагыгыз нинди заманга туры килде?

**Вагыйз әфәнде үзенең тормышын, уй-кичерешләрен сөйли. Теләкләрен тели.**

**Алып баручы.** Изге теләкләрегез өчен сезгә бик зур рәхмәт инде. Ә хәзер, безне үзегезнең яшь чакта уйнала торган берәр уен яисә җырлы уен белән таныштырып үтсәгез иде.

**Вагыйз әфәнде.** Була ул. Без яшь чакларда түгәрәктә әйләнеп уйнарга бик ярата торган идек. Әйдәгез, "Ал чия төпләрендә" дигән җырлы уенны уйнап карыйк.

**Алып баручы.** Әйдәгез, балалар, түгәрәккә басыгыз. Вагыйз абый гармунда уйнасын, ә без сезнең белән җырлап-биеп алыйк!

**Балалар.** Ал да булыр чагыбыз,

Гөл дә булыр чагыбыз.

Без җырламый, кем җырласын-

Безнең җырлар чагыбыз. (Уңга баралар.)

Кушымта:

Ал чия төпләрендә,

Гөл чия төпләрендә.

Сулар сибеп үстерәләр,

Тәрәзә төпләрендә. (Парлашып әйләнәләр.)

Ал да итәрбез әле,

Гөл дә итәрбез әле,

Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,

Бәйрәм итәрбез әле.

Кушымта. (Кушымтада парлап әйләнәләр.)

**Вагыйз әфәнде**. Әй, балалар, бигрәк тә күңелле, матур итеп җырладыгыз бит. Яшь чакларыма кире әйләнеп кайткандай булдым.

**Алып баручы.** Безнең балаларыбыз бик булдыклылар, алар әле матур итеп бии дә беләләр.

**Хәзер кызлар һәм бер егет башкаруында "Гармунчы егет" биюен карарсыз.**

**Бию тәмамлана, ишектән гармун кычкыртып, Ата ялкау (кем нинди герой кертәсе килә) килеп керә.**

**Алып баручы.** Тукта әле, кем буласың син? Нишләп болай, гармуныңны ямьсез тавышлар белән кычкыртып, безнең бәйрәмебезне бозып йөрисең?

**Ата ялкау.** Минме? Нишләп бозыйм, ди мин сезнең бәйрәмегезне? Мин иң оста гармунчы Ата ялкау булам. Киресенчә, гармунымда уйнап, сезнең бәйрәмегезгә ямь өстәп чыгыйм әле, дип килгән идем. Бигрәк матур уйныйм бит мин гармунда, әйеме? Тагын бер мәртәбә уйнап күрсәтимме сезгә, балалар? (Гармунын кычкырта башлый.)

**Алып баручы**. Тукта, Ата ялкау, тукта, уйнамый тор әле. Син үзеңне бик оста гармунчы дип мактанасың да мактанасың, балалардан сорап карыйк әле, мактанырга ярый микән?

**Балалар**. Юююк, мактанырга ярамый.

**Алып баручы**. Ата ялкау, син ишеттеңме инде. Бүтән алдашма. Менә матур уйнаучы гармунчыларны тыңлап кара әле. Бүгенге кунагыбыз, безнең әле җырлар авторы да. Бик матур җырлый. Шул уңайдан, Вагыйз әфәнде Әхлиуллинның җырлавын тыңлап үтик әле.

**Җыр башкарыла.**

**Алып баручы**. Ничек, Ата ялкау, яхшы уйныйлармы?

**Ата ялкау**. Әйе, менә ичмасам, уйныйлар дисәң дә ярый. Карале, Вагыйз әфәнде дигәнең дә бик оста уйный икән бит!(Гармунын тоткалап карый.) Кыңгыраулары чыңлап тора диген, ә-ә! Оста барда кулың тый, дигәннәр шул аны бабайлар. Я, ярый, балалар, мин башка вакытта болай бәйрәмегезне бозып йөрмәм.

**Алып баручы**. Ничек, балалар, гафу итәбезме Ата ялкауны?

**Балалар**. Әйе, гафу итәбез.

**Ата ялкау**. Менә шуның өчен мин сезгә бер уен өйрәтәм. Ул “Капкалы”дип атала.(Бу уенга кунакларны да чакырырга мөмкин.)

**Алып баручы**. Әйдә башла уеныңны.

**Ата ялкау**. Әйдәгез, балалар, парлап түгәрәккә басыгыз, бер пар уртада кала. Көй башлануга уртадагы пар, кырый парлар капкасының берсеннән кереп, алар урынында басып кала, урынсыз калган пар уртага йөгереп чыга һәм икенче капкага йөгереп керә. Уен көй туктаганчы дәвам итә.

**Уен башлана, кинәт көй туктый. Уен шулай дәвам итә. Җәза бирелә. Ахырдан җәза биюдә кала. Монда татар халык биюе башкарырга мөмкин. Ә безнең кызларыбыз “Шәлләр биюен” башкаралар. Шәл урынына чигелгән яулыклар да тотарга мөмкин.**

**Ишектә бер кулына төенчек тоткан, икенче кулын маңгаена куеп, сөйләнә-сөйләнә, әби керә.**

**Әби**. Исәнмесез, балакайларым! Сез минем бабамны күрмәдегезме? Вагыйз исемле ул, би-и-к оста итеп гармунда уйный ул, кызым.

**Алып баручы**. Исәнмесез, әбекәй. Менә шушы бабай түгелме, әби? Аның да исеме Вагыйз.

**Әби.** Әй, карале, күрми торам бит, шушы кызым, би-и-к шушы. И картым , сине югалттым бит.Монда берәр төрле бәйрәм мәллә? Кешеләр дә җыелган бит.

**Алып баручы**. Әйе, әби, бездә бүген Тальян гармун бәйрәме иде шул. Вагыйз абыйны да шуңа чакырган идек, белми калдыңмыни?

**Әби**. Миңа да әйтеп китмәгән шунда. Белмичә дә калдым.

**Вагыйз әфәнде**. Әй карчык, әле бер дә соңа калмагансың, бик вакытлы килгәнсең. Әйдә, яшь чакларны искә төшереп биеп ал әле.

**Әби бии.**

**Әби.** Уф, хәлем бетте, балалар, арып киттем.

**Алып баручы**. Әйдә, әби, менә бирегә утырып ял итеп ал әле.

**Әби**. Ай, рәхмәт, кызым. Картым, дим, менә бу төенчегемдә тәмле конфетларны балаларга өләшеп чыгыйк әле.

**Вагыйз эфэнде**.Бик яхшы булыр,карчык.

**Төенчекне ачалар, өләшәләр.**

**5 нче бала.** Безгә гармун бәйрәменә

Бабай килде кунакка.

Ул сыздыра тальянында,

Биетә дә җырлата.

**6 нчы бала**. Бәйрәм тагы да ямьләнде,

Әби дә килеп кергәч,

Күчтәнәчкә тәмле-тәмле

Кәнфит өләшеп биргәч.

**7 нче бала**. Без аларга: “Рәхмәт”,-дибез,

Озын гомер телибез.

Түгәрәгебез җыры дип,

Бер җыр бүләк итәбез.

**“Дуслык” җыры башкарыла.**

**Әби.** Менә, картым, яшьләрнеке яшьләрчә шул инде. Бигрәкләр дә матур җырлыйлар. Рәхмәт инде сезгә, балакайларым!

**Вагыйз әфәнде.** Балалар, бигрәк тә булдыклылар икән сез, бәйрәмегез дә бик күңелле булды. Шулай да безгә китәргә вакыт җитте. Тальян моңын онытмагыз. Ул сезнең яшь йөрәкләрегезгә үрләсен, чәчәк атсын! “Көйсез, моңсыз үткән көннәр-яшәлмәгән көн бит ул”, - дип җырлый безнең халык.

Бәхетле, шатлыклы, тәүфыйклы булыгыз, балалар! Сау булыгыз! Әйдә әби, киттек. **“Гармун алыйк әле, дускай” көен уйнатып, залдан чыгалар.**

**Алып баручы.** Татар халкының яраткан уен коралы тальян гармунга багышланган бәйрәмебез инде ахырына якынлашты. Исән, имин торыгыз, сау булыгыз.(Үзем иҗат иткән шигыьрләр кулланылды.)

***Боз озату бәйрәме***

***Галимова Ләйсән Фәрид кызы.***

*«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең гомуми*
*үсеш бирүче төрдәге 5 номерлы Саба «Бэлэкэч» балалар*
*бакчасы» мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе.*

**Максат:** Балаларга яз көне елның иң матур вакыты икәнен аңлату. Язгы табигать, табигать күренешләре белән һәм татар халкының яз көне уздырыла торган йола бәйрәмнәренең берсе - Боз озату йоласы белән таныштыру.

**Бурычлар:** Туган ягыбыз, тарихыбыз белән горурлану, халкыбызның йола-бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә кызыксыну уяту;

Табигатькә соклана белү, табигать байлыкларына сак караш тәрбияләү;

Балаларда үз халкы өчен горурлык хисе уяту, сөйләм телен, истә калдыру сәләтен үстерү.

**Сәхнә бизәлеше:** Күпер, язгы елга күренеше, зәңгәр су, бозлар, кояш, болытлар, үрдәк-казлар. Арткы фонда агачлар, йорт, йорт алдында эскәмия.

**Атрибутлар:** татар, рус милли киемнәре, тубал, кәрзин, пешкән (яки киндер-сюрприз савытыннан ясалган) йомыркалар, сары тасмалар, умырзая чәчәкләре;

**Катнашалар:** каргалар, әби, бабай, кояш, яз кызы.

**Алып баручы:** Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар! Без бүген төрки бабаларыбыздан калган, ләкин төрле сәбәпләр аркасында юкка чыгып баручы йола бәйрәменә җыелдык. Элек елга-инешләрдә боз кузгалган көн - бер олы бәйрәмгә әйләнә торган булган. Елгада боз кузгалганны карарга ерак авыллардан да әби-бабайлар, яшь-җилкенчәк һәм бала-чагалар җыелган. Ташу аккан елга буе бәйрәм төсен хәтерләткән. Яшьләрнең шатланып көлүләре, өздереп гармун уйнаган тавышлары төнгә кадәр еракларга ишетелеп торган. Ә инде бер-берсенә бәрелә-бәрелә агучы бозларның яңгыравы яңарып килүче табигатькә сихри ямь өстәгән.

**Каргалар биюе.** Бию барышында әби керә.

**Әби:** Кара син, каргалар да кайткан икән бит. Каргалар яз килүен хәбәр итә инде.

**1 Карга:** Мин карга, кара карга!
Яз чакырам дөньяга!
Кар-кар!

**2 Карга:** Карга килгәч китә кар!
Канатымда хатым бар!
Кар-Каррр!

**Әби:** Каягыз әле, нәрсә язганнар икән хатыгызда. Балалар, бу бит яздан хәбәр. “Юлга чыктым, сезне күрәсем килә.Тик күктә соры болытлар, кояш күренми, кояш булмагач мин дә соңга калам”, - дип язган. Кояш бит ул язның иң зур ярдәмчесе, таянычы. Әйдәгез, бергәләп чакырып карыйк әле үзен.

“Кояшны чакыру”
Кояш, кояш, кояш чык!
Кояш безгә бик кирәк.

Кояш чыккач үләннәр,

Агачлар үсә тизрәк.

Татар көе астында Кояш керә.

**Кояш:** Мин елмаеп карасам, бар дөнья көлә.

Тамчы тама, бозлар эри, күңел сөенә!

Кызганмыйча өләшәмен алтын нурларым,

Бар дөньяга ишетелсен шатлык җырларым.

-Исәнмесез, дусларым!Болытларны куып, мине чакырып чыгардыгыз. Сезне күрүемә мин бик шат.

**Җыр «Яз килә»** (Э. Авзалова сүзләре. М. Ярмиева көе.)

1. Җил җылы һәм иркә ,

Кояш та елмая.

Бар дөнья уяна,

Бар дөнья уяна.

Кушымта:

Яз килә! Яз килә!

Чәчәкләр уяна.

Йөрәккә яз килде, -

Бар дөнья куана!

Яз килә!

2. Канатлы җырчылар

Моңлана талларда.

Бар дөнья уяна,

Бар дөнья уяна.

Кушымта:

Яз килә! Яз килә!

Чәчәкләр уяна.

Йөрәккә яз килде, -

Бар дөнья куана!

Яз килә!

**Кояш:** Рәхмәт, дусларым! Мин сезне бик яратам, ләкин эшләрем бик күп, табигатьне уятып бетерәсем бар. Мин сезгә үземнең алтын-сары нурларымны калдырам. (Кояш нурларын елгага сибә, күңелле көй астына чыгып югала.)

Кояш нурлары бию.

**Алып баручы:** Тиздән елгада боз да кузгалыр, әзерләнеп торырга кирәк.

Күпер өстенә йөгереп бер малай чыга.

**Малай.** Барыгызда тыңлагыз! Барыгыз да
ишетегез!
Кояш нурлары белән
Елга бозын эреткән,
Боз китә, боз! Боз кузгалган!

Балаларга кулы белән ишарәли, чакыра. Күпер янына салмак музыка астында татар, рус миллли киемнәре кигән кызлар керә.

**1нче кыз**:
Елгада бозлар кузгалды…
Елмая, көлә кояш.
Урамнар буйлап атлады
Ямьле һәм күңелле яз.

**2 нче кыз:**
Көннәр аяз, күктә алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы –
Сагынып көткән яз килә.

**3 кыз:**
Язгы ташкын башлануын
Хәбәр итеп дөньяга,
Зәңгәр бозлар агып китте
Зәңгәр сулы дәрьяга.

Бергә: Яз бәйрәме мөбарәк булсын!

Күңелләргә шатлык тулсын! 1нче кыз.Кызлар, әйдәгез малайларны да чакырыйк әле.

**Бергә:** Әйдәгез, әйдәгез.

Төркемнән 3 малай чыгып кызларга кушыла. Берсе уенчык ат башы тотып бара, икенчесендә кәрзин. Кызлар, малайлар бергәләшеп йорт янына барарлар.

**1нче малай:** Әби, бабай өйдәме сез?
Бер йомырка бирәмсез?

**2 нче малай:** Әй әбекәй, бирсәң безгә өч күкәй
Тавыгың салыр йөз күкәй!

**Әби:** Исәнмесез, балакайларым,  без сезне күптән көтәбез.
Менә сезгә йомыркалар,  күптән әзерләп куйдым, бәйрәмнәр ямьле үтсен!

**1нче малай:** Бәйрәм котлы булсын!

**2 малай:** Игеннәрегез уңсын!

Йомырка кебек тук булсын!

**3 малай** (залга карап):

Ишекләрне ачыгыз.

Тәрәзләрне ачыгыз!

Бәйрәмгә ашыгыгыз!

Елга купкан, боз кузгалган!

**Әби:** Рәхмәт чакыруыгызга, барабыз барчабыз да!

Балалар кәрзинне тотып залны әйләнәләр.

**Әби:** Без дә нәкъ шушы вакытта боз озату бәйрәмен каршылый идек. Матур бәйрәм ул ! Бәйрәмгә без берничә көн алдан әзерләнә башлый идек. Иң матур киемнәребезне киеп, боз акканны карарга төшә идек. Елга буе җыр-бию, уен-көлкедән яңгырап торыр иде!

**1 кыз:**

Җыр-биюгә без дә оста

Түгәрәктә без биик.

Әйлән-бәйлән җырлар-җырлап

Бәйрәмне дәвам итик.

**Әби:** Я, ярый балалар, мин утырып торыйм. Матур гына күңел ачыгыз, уйнагыз, җырлагыз, биегез.

**Татар халкының “Чума үрәэк, чума каз” җырлы-биюле уены.**

Бер татар бабае килеп керә. Кулындагы тубалда бодай бөртекләре.

**Бабай:** Исәнмесез, балалар! Елгада боз киткәнен ишеттем дә, мин дә килдем менә. Монда кеше күп икән: барча авылдашлар, күрше авыллар да килеп җиткәннәр (Бабай күпердән елгага ашлык бөртекләре сибә)

Илләребез, җирләребез имин булсын, гаиләләрегезгә кайгы килмәсен, булган борчу-хәсрәтләрегез шушы язгы сулар белән агып китсен! Балалар сәламәт, бәхетле, игелекле булып үссеннәр.

**Бабай:** (кәрзинне күреп): Ай-яй, бигрәк күп җыйгансыз йомырканы. Йомырка – туып килүче яңа тормыш. Тереклек символы һәм ул үлән-үсемлекләрнең гайрәтен арттырырга тиеш дип фикер йөрткәннәр борынгылар. Без балачакта ул йомыркаларны таудан тәгәрәтә идек. Әйдәгез әле, сезнең белән“Кемнең йомыркасы ераграк тәгәри”уенын уйнап алыйк.

Уен.

**Бабай:** Ай булдырдыгыз!

**Бала:** Елга тулып боз ага

Сокланабыз без аңа.

Кояш көлә. Көн аяз.

Бозга басып килә яз.

Матур милли көй яңгырый. Яз керә.

**Яз:** Исәнмесез балалар!

Мине чакырдыгызмы?

**Балалар:** Исәнме,яз, матур яз

Безне сагынып килдеңме?

Агачларга, куакларга

Яшел чуклар элдеңме?

**Яз:** Әйе, минем дусларым!

Сезне сагынып килдем мин

Сезгә аяз көннәр дә

Яңгыр да китердем мин.

**«Яз җыры»**

Ашкынулы йөрәк җырын җырлап,

Гөрләвекләр акты урамда.

Сагыну моңын сузып, күк юлыннан

Сайрар кошлар кайтты урманга.

Зифа каен яшел яфрак ярды,

Яфраклары шаулый җил белән.

Ул каршылый язны күтәренке

Һәм шатлыклы яңа җыр белән.

Күкне иңләп күксел болыт килде,

Аккорд бирде яшен һавада.

Арфа төсле яңгыр тамчылары

Сузылдылар кырга, далага.

Концерт бирә дәртле, шатлыклы яз,

Аны тыңлый бөдрә тирәкләр.

Гөлчәчәкләр, җирдән баш калкытып,

Һәм яз төсле ярсу йөрәкләр

Яз:Рәхмәт, балалар. Инде тапкырларны да күрик, зирәкләрне белик.Мин табышмак әйтәм, тапкырлар җавап бирәләр.

Ак юрганымны алып куйдым,

Яшел юрганымны җәеп кудым.          (яз килү)

Килделэр агайлар,балтасыз,

Салдылар купер тактасыз.(боз)

Борынсыз чыпчык боз тишә (тамчы)

Утта янмый, суда батмый.(боз)

Ут та түгел, ук та түгел,

Күзгә төшә, карны кисә. (кояш нуры)

Агач башында йорты,

Эчендә яши җырчы. (сыерчык)

**Яз:** Бигрәк зирәкләр икәнсез. Ләкин миңа китәргә вакыт. Минем әле эшем бик күп. Бөреләрне уятасым, карларны эретеп бетерәсем, кошларны җылы яктан кайтарасым бар. Сезгә беренче чәчкәләремне калдырам.

Яратыгыз айларны

Яратыгыз елларны

Кешеләр, табигатьне

Саклагыз сез аларны.

Яз саубуллашып чыгып китә. **“Умырзая” биюе башкарыла.**

**Алып баручы:** Кадерле балалар! Без бүген ямьле яр буенда бозлар шаулавын тыңладык, яз килүенә бергәләшеп шатландык. Без дә сезнең белән – шушы гүзәл табигатьнең бер кисәге. Бергәләп табигатьнең бизәкләрен – урман күлләрен, елга-инешләрен саклыйк, чиста тотыйк.

**Әби:** Яз безгә шатлык алып килсен. Яз сулышы гаиләгезгә иминлек, муллык алып килсен, барчагызга саулык –сәламәтлек китерсен.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт сезгә!

***Чәк-чәк бәйрәме***

***Ганиева Гөлия Хәлил кызы.***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы*
*ш.т. Б.Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге 5 номерлы*
*Саба "Бәләкәч" балалар бакчасы мәктәпкәчә*
*белем муниципаль бюджет учреждениясе*

**Максат:** Балаларны татар халкының милли бәйрәме – "Чәк-чәк бәйрәме" белән таныштыру.

**Бурычлар**: Балаларны кунакчыл, ачык йөзле булырга өйрәтү.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләрен формалаштыру.

Халкыбызның милли бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә, авыз иҗаты әсәрләренә кызыксыну уяту.

**Бәйрәм барышы.**

*Авыл өе күренеше. Музыка астында татар халык киемнәреннән алып баручы чыга.*

**А.б.** Исәнмесез, хөрмәтле кунаклар! Бүген барлык бәйрәмнәр арасындагы иң татлы, иң баллы, иң тәмле бәйрәм. Телегезне йота күрмәгез: 14 октябрь Чәк-чәк көне билгеләп үтелә. Кояш һәм кунакчыллык символына әйләнгән табыныбыз күркен бөтен дөнья буйлап кем генә белми дә, кем генә яратмый. Бүген без сезнең игътибарыгызга "Чәк-чәк бәйрәме" тәкъдим итәргә булдык. **"Әссәләмәгәләйкүм" җыры** (Госман Садә сүзләре, Резидә Әхиярова музыкасы).

**1 бала.** Бүген чәк-чәк көне икән,
Татар милли ризыгы,
Чәк-чәк белән сыйланыгыз,
Белми калмагыз тагы.

**2 бала.** Татарның милли ризыгы –
Чәк-чәк, аны беләсез,
Табын күрке бәйрәмнәрдә,
Яратасыз һәммәгез.

**3 бала.** Бакча күрке – чәчәк булса,
Бәйрәм күрке ул чәк-чәк.

Чәй табыннары янында

Ашагыз аны чәк чәк.

**4 бала.** Борынгы заманнан ук

Өстәлләрне бизәгән,

Шуңа күрә халкым аны

Өстәленнән өзмәгән.

(Балалар утыралар)

**Әби керә.**

**Әби:** Бүген мине “Чәк-чәк бәйрәме” нә чакырганнар иде бит. Тизрәк барыйм. Соңга калмый тагын.

**Әби:** Исәнмесез, балалар!

**А.б.** Исәнме, әби! (кул биреп күрешә).Без бүген балалар, кунаклар белән “Чәк-чәк бәйрәме” нә җыелдык.

**Әби.** Бик күркәм бәйрәм үткәрергә уйлагансыз. Афәрин!

**5 бала**. Кунакларны каршы ала,

Ипи, тоз, баллы чәкчәк,

Татар халкы кунакларын,

Көткән, көтә, көтәчәк.

**6 бала.** Һичкем аны табынына

Күрсәтергә куймаган.

Халкым яраткан кунагын

Чәкчәк белән сыйлаган.

**7 бала.** Баллы да ул, татлы да ул,

Әнкәй пешергән чәкчәк,

Тыныч булсын, якты булсын,

Матур булсын киләчәк.

**8 бала.** Майдай йомшак күңелебез

Балдай татлы телебез.

Чәкчәк кебек бердәм булып

Дус яшәргә телибез.

**9 бала.** Әйдә бергә җырлыйк әле

Балачак – матур чәчәк.

Байлык, муллык билгесе ул

Өйләрдә баллы чәк-чәк.

**Җыр: “Чәй эчәбез бергәләп”** (А.Минһаҗев сүзләре, Р.Сәрвәров көе)

**Әби:** Без дә яшь чакта төрле-төрле бәйрәмнәр үткәрә идек, и рәхәтләнеп бии идек, җырлый идек, таң атканчы уйный идек.

**А.б.** Әбиләр, үзегезнең яшь вакытта уйнаган уеннарыгызны балаларга да өйрәтегез әле.

**Әби**. Әйдәгез, “Йөзек салышлы” уйныйбыз. Йөзекне салучыны санамыш санап сайлап алыйк.

**Санамыш әйтү:**

Чәк-чәк, коймак, пәрәмәч, кыстыбый, йомшак күмәч,

Гөбәдия, кош теле, син утыр, син кил бире.

***Уен: “Йөзек салыш” (Татар халык бию көе куела)***

**Әби.** Менә бит нинди уңган балалар! Без дә бәләкәй чакта, шундый кызыклы уеннар уйный идек. Ә үсә төшкәч кич утырулар, аулак өйләр була торган иде.

«*Самавыр» уены.*

*«Самавыр» куела. Калган балалар читтәрәк тезелешеп утыралар. Балаларга чәй ризыклары исемнәре әйтеп чыга, аларны самавыр ишетмәскә тиеш.Әби самавырның күзләрен каплап: «Чәй эчәргә килә-килә ...шикәр!»- ди. Шикәр, әкрен генә килеп, самавырның аркасынатөртә дә, үз урынына барып утыра. Самавыр караганда, балаларбарысы да баш бармакларынөскә*

*каратып утырган булалар. Самавыр кем төрткәнен әйтергә тиеш. Әгәр белсә, тотылган бала самавыр була. Белмәсә, шикәргә икенче исем кушылып, уен дәвам итә.*

**А.б**. Бездә бүген “Чәк-чәк бәйрәме”. Ә чәкчәкләр һаман пешмәгән. Кунаклар бит бездән чәкчәк көтә.

***Уен “Чәк-чәк пешерү”.***

(Бер өстәлдә бер подноска сары төстәге киндер-сюрприз шарлары куела. Аларга ябыша торган тасмалар ябыштырылган. Балалар ике командага бүленеп, икенче өстәлдәге ике түгәрәк тәлинкәгә киндер шарларыннан “чәкчәк” өяләр. Әбиләр балаларның “чәкчәкләренә” игътибар итәләр, уңганлыкта, җитезлектә мактыйлар)

**А.б**. Чәк-чәк чынлап та бик тәмле чәй ризыгы. Балалар, хәзер килгән кунакларга бик матур итеп өстәл әзерләп алыйк.

(Балалар шигырь юлларына туры китереп өстәл әзерләп куялар. )

Без әзерлибез табын,

Китереп бөтен ягын.

Уртага куйдык чәчәк,

Чәчәк янына — чәкчәк.

Бавырсак һәм кош теле.

Ризыклар төрле-төрле:

Сумса, бәлеш, өчпочмак,

Гөбәдия һәм коймак.

Һәркемгә чыгар өлеш:

Бар кыстыбый һәм бәлеш!

- Җитешегез, кунаклар,

Кыстатмагыз, кунаклар!

Өйгә кайтып китәргә

Ашыкмагыз, кунаклар!

**10 бала.** Чәк-чәк табынга куела
Ямьле бәйрәм көнендә,
Иң тәмле ризык санала
Һәр татарның өендә.

**11 бала.** Баллы була,татлы була,
Оста пешергән чәк-чәк,
Тыныч булсын илләребез,
Якты булсын киләчәк!

**Җыр: "Чәк-чәк"(**Т.Низами)

**Әби.** Бүген "Чәк-чәк бәйрәмегез" бик күңелле булды. Яшь чакларыбыз искә төшереп, матур җырлар җырладыгыз, уеннар уйнадыгыз. Рәхмәт сезгә, балалар.

***Орчык өмәсе***


***Гарифуллина Ләйсән Дамир кызы***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 5 нче балалар бакчасы" муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*


**Максат:** Балаларны татар халкының милли бәйрәме «Орчык өмәсе» белән таныштыру.

**Бурычлары:**

1. Балаларга татар халкының тормышы, көнкүреше, милли киемнәре, бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре турында мәгълүматләр бирү.

2. Балаларның бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү, үз фикерләрен тулы итеп әйттерүгә ирешү, милли бәйрәмнәргә, гореф-гадәтләргә карата кызыксынучанлыгын арттыру.

3. Балаларга рухи-әхлакый тәрбия нигезләре бирү һәм татар халкының милли бәйрәмнәренә, гореф-гадәтләренә карата соклану хисе тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Кабалар, орчыклар, җеп йомгаклары, йон, сандык, бәйләнгән киемнәр, чигелгән сөлгеләр һәм кулъяулыклар, эскәмияләр, өстәл, самавыр, чәйнек, чынаяклар, чигүле мендәрләр белән карават, сугылган паласлар.

**Техник чаралар:** Музыка үзәге.

**Залның бизәлеше:** Авыл өе күренеше.

**Балалар белән алдан эшләнгән эш:** Балалар белән халык авыз иҗаты әсәрләрен (табышмаклар, мәкальләр, санамышлар), татар халык җырларын, уеннарын, биюләрен өйрәнү. Балаларга милли бәйрәмнәр, өмәләр турында сөйләү. Каба, йон, орчыклар, йомгаклар карау, аларны ничек кулланыуларын аңлату.

**Бәйрәм барышы**

*Авыл өенең эчке күренеше. Як-ягына матур итеп тукылган сөлгеләр эленә. Идәндә сугылган паласлар. Өстәлдә – самавыр, чынаяклар, ашамлыклар. Идәндә – сандык. Анда кулдан бәйләнгән киемнәр, чигелгән сөлгеләр, кулъяулыклар, йомгаклар. Эскәмияләрдә йон бәйләнгән кабалар, орчыклар. Караватөстендә чигүле мендәрләр. Түгәрәк өстәл, өстәл өстендә самавыр тора.*

**Автор сүзе:** Орчык өмәсе көнне хуҗа кеше күп итеп йон әзерли, кичкә тәмле ризыклар пешерә, дусларын, күршеләрен чакыра. Алар җыелып беткәч, күмәк эш башлана. Кемдер йон яза, кемдер эрли, ә кемдер аны ката һәм йомгакка чорный. Ә кемдер бәйли. Эшне бар кешегә дә бүлеп бирәләр. Ә күңелле булсын өчен, ул бию, җырлау, шигырь сөйләү, табышмаклар һәм мәкальләр белән аралаштырылып барыла. Эш беткәч, табынга утыралар. Менә, ул шундый бәйрәм.

*Әби самавыр чистартып утыра. Бабай йон күтәреп керә.*

**Бабай:**Карчык, карчык!

**Әби:**Монда мин, монда!

**Бабай:**Кара, нинди яхшы язгы йон таптым сиңа! *(Өстәлгә куя)*

**Әби:** СөбханАлла, МашАлла! Кайлардан таптың? Күренеп тора шул язгы икәне, бигрәк йомшак.

**Бабай:** Үзеңә генә күп булыр инде бу. Йон язарга кызлар чакырмыйсыңмы?

**Әби:** Киләләр алар, картым, киләләр. *(Йон яза тора)*

**Бабай:** Минем янга әле бүген егетләр дә киләбез дигәннәр иде. “Бабай, орчык ясарга өйрәт әле” дип алҗытып бетерделәр. Кая, мин дә сиңа булыша торыйммы соң?

**Әби:** Әйдә, картым, яза торыйк әле.

**Бабай:** Әйдә, әйдә.

***Ишек шакылдаган тавыш. Кызлар керә.***

**Кызлар:** Исәнме, Миңзифа әби!

**Әби:** Исәнмесез, кызларым! Әйдәгез, әйдәгез, түрдән узыгыз! Әйдәгез утырыгыз. *(Кызлар утыралар).*

-Менә, балалар, без бәләкәй чакта безне орчык өмәсенә чакыралар иде. Менә шул чакларны искә төшереп, сезне дә орчык өмәсенә чакырган идем. Әби-бабаларның гореф-гадәтләрен белү һәрберебезгә дә кирәк. Әйдәгез башта чәй эчеп алыйк, аннан соң эшкә тотынырбыз.

**1 кыз:** Рәхмәт, Миңзифа әби. Башта эшлик әле, аннан соң чәй эчәрбез.

**2 кыз:** "Эше барның-ашы бар" диләр. Шундый әйтем бар.

**3 кыз:** "Хезмәтнең тире-ачы, җимеше-татлы була".

**4 кыз:** "Кем эшләми, шул ашамый".

**Әби:** Әйе шул, Тукаебыз да шулай дип әйтеп калдырган "Эш беткәч, уйнарга ярый" дигән. Ярар, ярар, эшлим дип торган кешегә сүз әйтеп булмый. Чәйгә дә өлгерербез. (Йонны өләшеп бетерә)

**Егетләр тавышы:** Исәнмесез!Керергә ярыймы? (бергә)

**3 кыз:** Абау, кызлар! Егетләр дә килә түгелме соң? Орчык өмәсенә кызлар гына йөри бит.

**Бабай:** Егетләр килә шул, орчык ясарга өйрәнәбез дигәннәр иде.

**Әби:** Килүләре бик әйбәт булган әле (егетләр керә)

**1 егет:** Оооо, монда кызлар да бар икән бит!

**Бабай:** Әйдәгез, әйдәгез, егетләр, түрдән узыгыз!

**Әби:** Исәнмесез, оланнар!

**2 егет:** Хәерле кич, кызлар!

**Бабай:** Кара әле, карчык, бу безнең чып-чын орчык өмәсе була бит инде. Кызлар да килде, егетләр дә. Һәр кешегә эш җитә.

**3 егет:** Мулланур бабай, орчык өмәсе нәрсә соң ул? Аны кайчан уздыралар?

**Бабай:** Карчык, аңлатып кит әле балаларга.

**Әби:** Орчык өмәсе безгә борыңгы заманнан калган йола. Ул җиргә кар яугач, көз көне үткәрелә.

**Бабай:** Орчык ясар өчен белем, игътибарлылык кирәк. Ә калганнары аның-вакыт эше. Әйдәгез, эшне башларбыз.

**Әби:** Әйдәгез, кызларым, без дә эшкә керешик. Вакыт бара ул. *(Эшли башлыйлар)*

**Бабай:** Менә карап эшләгез, менә шулай, менә шулай итәбез.*(Бабай эш барышын күрсәтә)* Балаларга күңеллерәк булсын өчен, табышмаклар әйтешик.

Табышмак әйтәм мин сезгә

Йон бирә безгә нәрсә?

**1 егет:** Кәҗә түгелме соң ул?

**4 егет:** Кечкенә генә карчык, зыр-зыр әйләнеп, йон җыя.

**Бергә: Орчык.**

**1 егет:** Биш агайга бер күлмәк.

**Кызлар: Бияләй.**

**1 егет: Дөрес, бияләй.**

**2 егет:** Әйләнгән саен зурая.

**4 кыз:** Йомгактыр әле ул.

**2 егет:** Дөрес, йомгак.

**Бабай:** Ииии, балалар, бигрәк тапкыр икән үзегез. Әйдәгез бер уен уйнап алабыз. Мин мәкальләрнең башын әйтәм, ә сез-ахырын.

**Бабай:** Тирләп эшләсәң, **тәмләп ашарсың. (бергә)**

**Бабай:** Биш әйткәнче, **бер эшлә. (бергә)**

**Бабай:** Карама кешенең сүзенә, **кара эшенә. (бергә)**

**Бабай:** Эш беткәч, **уйнарга ярый. (бергә)**

**Әби:** Булдырдыгыз, балалар! Эшләгәндә кулыгыз кулга йокмый, сөйләгәндә телегез дә шундый икән. Әйдәгез, орчык бөтерү уенын уйнап алабыз. *(Орчыкны ала)* Түгәрәккә басабыз *(басалар).* Орчыкны уртага куям, әйләндереп җибәрәм *(әйләндерә).*

___________________________________ гә эләкте ***(бергә** әйтә балалар)*

**1 кыз:** Нинди җәза бирәбез?

**Бергә:** Җырласын.

*(Орчык кемдә кала-шул балага җәза бирелә. Уен шулай дәвам итә.)*

“Орчык бөтерү” уеныннан соң әби шәл алып чыга.

**Әби:** Карагыз әле, кызларым, яшь вакытта күпме шәлләр бәйләгәнбез.

**1 кыз:** Кызлар, әйдәгез Миңзифа әбигә “Шәл бәйләдем” дигән бию биеп күрсәтик әле.

**2 кыз:** Яшь вакытларын искә төшерсен.

***(Бию)***

**Бабай:** Егетләр, кызлар биеп тә күрсәттеләр инде. Сез бик оялып кына утырасыз.

**3 егет:** Эшлибез бит, бабай.

**4 егет:** Хәзер җырлап күрсәтәбез без.

***Малайлар “Күгәрчен гөрлидер” татар халык җырын башкара***

**Әби:** Менә, балалар, орчык өмәсе шулай үтә дә инде. Эшен дә эшләдек, уеннар да уйнадык, җырладык, биедек. Әйдәгез хәзер табынга рәхим итегез!

***Солдатны озату йоласы***

***Гайнетдинова Миләүшә Алимас кызы.***

*Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иләбәр “Умырзая”балалар бакчасы*

**Максат:** балаларның татар халкының милли гореф-гадәтләре белән таныштыру, патриотик тәрбия бирү; балаларда бу гореф-гадәтләргә,

йолаларга хөрмәт, ихтирам, милли җырлы-биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү; балаларның сүз байлыкларын арттыру, сәхнә культурасы булдыру; халык авыз иҗатына, гореф-гадәтләренә, йолаларга, милли уеннарга хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Җиһазлау:** бүлмәнең бер өлешендә авылның урам ягы: агач йорт, сәке,

агачлар. (Бүлмәнең икенче өлешендә авыл йортының эчке күренеше. Өстәл, самавыр, сандык, чиккән сөлгеләр.)

**Бәйрәм барышы:**(Сөләйман әти-әнисе белән түгәрәк өстәл артында чәй эчеп утыралар)

(Сельсовет-Шәүкәт ишеккә шакый, керә, кулында армия сафларына чакыру кәгазе)

**Сельсовет-Шәүкәт:** Хәерле көннәр булсын! Нихәлләрегез бар? Сезгә хәбәр китердем. Улыгызга армия сафларына чакыру кәгазе бар, кабул итеп, кул куеп алыгыз.

**Солдат малай -Сөләйман:** Яхшы, рәхмәт. Ватаныбызны саклау һәр егетнең изге бурычы. Әти-әнием, сезнең хәер-догада исән-сау хезмәт итеп кайтырмын.

**Сельсовет-Шәүкәт:**

Туган җирдән аерылып, еракларда –
Көнне төнгә, төнне көнгә ялгап,
Туган илнең иминлеген саклап,
Изге эштә — хезмәттә син, Солдат!
Бәйрәм белән сине, батыр солдатыбыз!
Сине һәркөн искә алып үтәбез!
Изге бурычыңны яхшы тәмам итеп,
Исән-имин кайтуыңны көтәбез!

**Солдат малай- Сөләйман:** Ярар, әтием- әнием, без бер урам буйлап җырлап әйләнеп кайтабыз әле.

**Әнисе-Хәят:** Ярар, ярар улым.

(Малайлар,урам буйлап җырлап, кулъяулык җыеп йөриләр,«әби-бабайларның барысы да капка төбендә.Гармунга кушылып, малайлар җырлыйлар.)

Без авылда үскән идек

Тал тамырлары кебек.

Үсеп җиткәч таралыштык.

Кош балалары кебек.

(Балалар “урам әйләнәләр”.  Әбиләр сәкедә утыралар.)

**Солдат малай-Сөләйман**: Әбиләр, мин армия сафларына китәм инде.

Хәерле юл теләгез миңа.

**Фәүзия әби:** Халык: “Ил барда- егет хур булмас, синең кебек егетләр барда-ил хур булмас”,-ди. Билең  нык булсын, биле ныкның- иле нык була.

**Хәтимә әби:** Ватан сагындагы изге эшең иминлектә узып, туган ягыңа, туган әнкәң янына сау-сәламәт  килеш кайтырга язсын. Әәмиин.

**Солдат малай-Сөләйман:** Ярар, әбиләр, мине догагыздан ташламагыз. Мин кайтканчы, исән-сау торыгыз.

**Мәрьямбикә әби:** Исәнлектә  күрешергә  язсын, улым. Сау бул. Без сиңа хәер-дога кылып торырбыз. Менә, улым, берәр кирәгеңә тотарсың. (Акча бирә.)

**Солдат малай-Сөләйман:** Рәхмәт, әбиләр. Сау булып торыгыз. (Малайлар, гармунга җырлап  икенче  капка төбенә киләләр.)

**“Малайлар”.**

Салкын чишмә буйларында

Атлар эчерсәң иде.

Туган үскән җирләреңдә

Гомер кичерсәң иде.  (Капка төбендә бер бабай ишегалды себерә.)

**Солдат малай -Сөләйман:** Бабай, сау булып тор. Мин ил чикләрен сакларга китәм.

**Бабай-Ризат:** Ярар, балам, сау бул. Еллар имин, күкләребез аяз булсын, таңнарыбыз тыныч атсын. Хәерле имин юллар сиңа, балам.

**Солдат малай -Сөләйман**: Рәхмәт бабай. Сау булыгыз. (Малайлар җырлый-җырлый  чыгып китәләр.)

**Малайлар:**

Без авылдан чыккан чакта

Күтәрелде томаннар.

Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,

Сау булыгыз, туганнар!    (өйдә өстәл янында дәвам итә.)

**Армиядә хезмәт итеп кайткан солдат малай-Солтан:** Ярар, дускаем. Без үзебезнең  ил алдындагы  бурычны  үтәп  кайттык. Чират синдә. Анда баргач,  җебеп торма, үзеңнең  кыю

йөрәкле татар егете икәнлегеңне онытма. Татарстан егетләре һәркайда мактаулы. Шул дәрәҗәне төшермә. Туган ягыбызга исән-имин әйләнеп кайт.

**Кыз-Мәрьям:** Әйдәгез, уеннар уйнап алыйк әле.

**Бергәләп:** Нинди уен уйныйбыз?

**Кыз- Мәрьям:** Әйдәгез, бергәләп "Яулык салыш" уенын уйныйбыз.

**Бергә:** Әйдәгез. (Санамыш әйтешәләр.)

Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Алты, җиде, сигез, тугыз, ун.
Байлар кия кызыл тун.
Кызыл тунның бәясе –
Йөз дә кырык сигез сум.

**Уен:**

Кулъяулыгым яшел, яшел
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм,
Бер иптәшем артына.
(Уен уйнаганнан соң эскәмиягә килеп утыралар)

**Әтисе-Аяз:**Улым, кыю бул, батыр бул.Бер ел күп түгел ул, кеше тормышында бер мизгел генә. Яхшы хезмәт ит. Хәерле юл, улым!

**Әнисе-Хәят:**Улым, минем синең өчен ничек ут йотуымны беләсең. Тәртипле бул. Олыларның сүзен тыңла. Исән-сау кире әйләнеп кайт. Сау бул, балам. Хәерле юл, улым! Исәнлектә күрешергә насыйп булсын, амин. Улым, сиңа икмәк каптырам. Калган кисәкне кисеп пич башына җыеп куям. Ул син кайтканны теләп торыр. (Ипи каптыра.)

**Әбисе-Камилә:**Улымның ризыгы өзелмәсен, туган йортыбызга сау-сәламәт әйләнеп кайтырга язсын.

**Мулла-Раян:** Тукта әле, улым, олы юлга чыгар алдыннан сиңа бер дога укыйм.(Мулла дога укый. Ике кулы белән битен сыпыра. Әтәч кычкырган тавыш ишетелә.)

**Солдат малай-Сөләйман:**Җыенырга вакыт килеп җитте.

**Солдат малай-Сөләйман:** (арты белән ишектән чыга). Барыр юлым уңышлы булсын, үз аякларым белән исән-имин туган йортка кабат керергә язсын.

**Бергә:** Әәмиин!

**Яраткан кызы-Мәрьям:** Ярый, Сөләйман, сау бул. Исән-сау йөр.

**Солдат малай-Сөләйман:** Син мине көтәрсеңме,Алсу?

**Яраткан кызы-Мәрьям:** Кыз. Көтәрмен, Сөләйман. Борчылма.

**Солдат малай-Сөләйман:** Вәгъдәме?

**Яраткан кызы-Мәрьям**: Вәгъдә. Тыныч хезмәт ит, ярыймы. Менә сиңа вәгъдә билгесе – кулъяулык. (пар чиккән кулъяулык бирә)

**Солдат малай -Сөләйман:** Рәхмәт. Мин аны йөрәк түремдә генә саклармын. (Машина кычкырта)

**Дусты- Әмир:** Ярый, егетләр, кузгалырга вакыт.

**Солдат малай -Сөләйман:** Сау булыгыз, туганнар, дуслар, күршеләр! Сау булыгыз, әти-әни! Сау бул, Мәрьям!

**Барысы бергә**: Сау бул,Сөләйман. Исән-сау йөреп кайт.

***Кунак каршылау йоласы***

***Хәкимова Гүзәлия Мәхмүт кызы.***

***Вәлиева Зөлфия Җомагыл кызы.***

*МБМБУ Гомуми үсеш бирү төрендәге*
*Арча 11 нче номерлы балалар бакчасы"*

**Максат:** балаларны халкыбызның кунакчыллык, тыйнаклык, дуслык кебек күркәм сыйфатлары белән таныштыру.

**Белем бирү бурычы:** кунакны матур итеп каршы ала һәм сыйлый, табын артында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәтү.

**Үстерү бурычы:** балаларның сөйләм телләрен үстерү, татарча иркен аралаша өйрәтү.

**Тәрбия бурычы:** татар халкының гореф-гадәтләрен хөрмәтләргә өйрәтү; табын әдәбен, үзеңне әдәпле тоту күнекмәләрен , кунакчыллык, чисталык, пакълык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләү.

**Чараның барышы**

*Бәйрәм үткәреләсе зал матур итеп бизәлгән. Авыл өе күренеше.*

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Исәнмесез, балалар! Хәерле көннәр сезгә! Балалар, бүген без татар халкының күркәм сыйфатлары: кунакчыллык, тыйнаклык, дуслык турында сөйләшербез, үзебез дә кунак булырбыз. Татар халкы элек-электән үк кунакчыл, кунак чакырган, кунакка йөрешкән.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Балалар, әйтегез әле, кешеләр ни өчен бер-берсенә кунакка йөриләр?

**1 нче бала**. Бергәләшеп бәйрәмнәр уздыруы күңеллерәк.

**2 нче бала.** Чөнки кунакта тәмле ризыклар белән сыйлыйлар.

**3 нче бала.** Туганнар һәм дуслар белән аралашып яшәргә кирәк.

**Хуҗабикә -тәрбияче**. Ә ни өчен без кунак килгәнне яратабыз?

**Бала.** Чөнки кунаклар килгәч күңелле, уйныйбыз, җырлыйбыз, тәмле сыйлар белән сыйланабыз.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Кунакны нинди сүзләр белән каршы алабыз соң?

**Бала.** Рәхим итегез, керегез, утырыгыз, сыйланыгыз без бик шат сезне күрүебезгә дигән сүзләр белән каршылыйбыз.

**Хуҗабикә -тәрбияче**. Ә сез үзегез кунак килү турында нинди сынамышлар беләсез?

**1 нче бала**. Коры табынга кунак утыртмыйлар.

**2 нче бала.** Кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ач.

**3 нче бала.** Кунак килсен, каза килмәсен.

**4нче бала**. Кунак сые: якты йөз, тәмле сүз, аннан кала ипи, тоз.

**5 нче бала.** Кунаклы йорт – хөрмәтле йорт.

**Хуҗабикә -тәрбияче**. Ә хәзер балалар, татар халкы кунакны нинди ризыклар белән сыйлый микән. Әйдәгез шулар турында шигырьләр тыңлап китик.

*Интерактив тактада татар халкының милли ризыклары рәсеме күрсәтелә.*

**Бала.** Татар халык ашларыннан

Иң җиңеле кыстыбый

Ул аш булса өстәлләрдә

Табын тулы нигъмәт, сый.

**Бала.** Бәлеш пешә бәйрәм көнне

Көндә бәлеш пешмидер,

Ә өчпочмак татарларның

Табынынан төшмидер.

**Бала.** Менә табын түрендә

Тәмле бәлеш күренде

Йөзе шат көлеп тора

Хуш ис бөркелеп тора.

**Бала.** Һәр өстәлнең бизәге мин

Исемем минем чәк-чәк

Баллы да мин, тәмле дә мин

Кабып карагыз чак-чак.

**Бала.** Рәхим итеп авыз итик

Менә бу милли ашлар

Тәрбияле һәрбер кеше

Бисмилла әйтеп ашар.

**Бала.** Табын түрен һәрчак бизи

Майда пешкән кош теле.

Авыз итми һич тә китми

Килгән кунак билгеле.

Кунакка килегез!

Кунакларны бик яраткан

Электән безнең халык.

Юмарт диеп, уңган диеп,

Килгән күптән макталып

Татар кызы - Таңсылу мин

Уңган буласым килә.

Чәем кайнар, чәк-чәк әзер,

Йә, кем кунакка килә?

*Ак әби килә.Кулына ипи тоткан.*

**Әби.** Исәнмесез, балакайларым,

Менә мин килеп җиттем.

Бакчагызның шау тормышын

Бер күреп китим, дидем.

Әссәләмәгаләйкем, улларым, кызларым!

**Балалар.** Исәнмесез, әбекәй!

**Бала**. Әбекәй, әйдәгез рәхим итегез, түрдән үтегез.

**Әби.** И рәхмәт, балакаем.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Кәефләрегез ничек әбекәй? Исән-сау гына килдегезме? Килүегез өчен бик зур рәхмәт.

**Әби.** Бик сөенә-сөенә килдем. Балалар, безнең халкыбыз хуҗаларга ихтирам, хөрмәт йөзеннән кунакка һәрвакыт күчтәнәч белән йөргән. Бу матур гореф-гадәт хәзергә кадәр сакланган. Менә мин дә сезгә күчтәнәч итеп ипи алып килдем. Икмәк- ул тормыш тоткасы. Шуңа күрә аның кадерен белергә кирәк.

**Хуҗабикә -тәрбияче**. Күчтәнәчең өчен рәхмәт әбекәй. Аяк кулларың сызлаусыз булсын. Әйдәгез әле, балалар кунакны сүз белән генә сыйламыйлар, Ак әбиебезне табын артына чакырыйк.

**Бала**. Әбекәй, әйдәгез утырыгыз, ял итегез.

**Әби.** Рәхмәт, балакаем.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Ак әби, менә без сез килүгә дип бавырсак та пешереп куйган идек. Сез бавырсакны авыз итә-итә чәй эчә торыгыз.

Ә без балалар белән «Кәрия-Зәкәрия» җырлы уенын уйнап алырбыз.

**Җырлы уен «Кәрия-Зәкәрия»**

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Балалар, ә хәзер Ак әбиебезгә үзебезнең тәрбияле балалар булуыбызны , табын янында әдәп кагыйдәләрен белүебезне әйтеп үтик.

**1 нче бала**. Өстәл артына утырганчы кулларны юарга кирәк.

**2 нче бала**. Олы кешеләрдән алда өстәл артына утырырга ярамый. Башта аларга урын бирергә кирәк.

**3 нче бала.** Аш янында уйнарга ярамый.

**4 нче бала.** Борын тартырга, чөмереп ашарга ярамый.

**5 нче бала**. Ризыкны әз-әзләп кенә кабып ашарга кирәк.

**6 нчы бала.** Чиста, пөхтә ашарга кирәк.

**7 нче бала**. Аштан соң кулларны юарга кирәк.

**Хуҗабикә -тәрбияче**. Бик дөрес, балалар. Ә хәзер Алинә безгә Рәсимә Хәйруллинаның **«Табын кагыйдәләре»** исемле шигырен сөйләр.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Рәхмәт Алинә, бик дөрес сүзләр әйттең. Ә хәзер балалар татар халкының иң дәрәҗәле ризыгы булга чәк-чәк ясау серләрен өйрәник әле. Сез әбекәй безгә ярдәм итеп торырсыз, бу эштә өлкән кешенең ярдәме бик кирәк.

**Әби.** Бик теләп ярдәм итәм. Чәк-чәк – һәрбер өйнең түрендә. Аның белән мәртәбәле кунакларны каршы алалар балакайларым.

*(балалар алдан әзерләнгән өстәл янына киләләр, алъяпкыч ябалар, яулык бәйлиләр һәм чәк-чәк кисәләр)*

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Булдырдыгыз балалар, бик матур кискәнсез. Карагыз әле безнең чәк-чәкләр әзер дә әзерен, ә аннан соң нишлибез?

**Бала.** Чәк-чәкләрне майда пешерәбез һәм баллыйбыз.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Әйе дөрес, Адилә . Майда чәк-чәкләребезне пешекче апаларыбыз пешереп бирерләр. Әбекәй, без сине күчтәнәчсез җибәрә алмыйбыз инде чәк-чәкләребез өлгергәнче син яшь чакта уйнаган уеннарның берсен балалар белән «Йөзек салыш» уенын уйнап алырбыз.

**«Йөзек салыш» уены**

**Әби.** Рәхмәт сезгә, балакайларым. Әдәпле кунак, китәр вакытын үзе белер- ди халык. Миңа балалар кузгалырга вакыт җитте, кайтыр юлым бик ерак.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Безнең халык борынгыдан кунакчыл һәм юмарт булган. Бу чәкчәгебез сезгә бездән күчтәнәч булсын. Рәхим итеп ал әбекәй.

**Балалар**. Сау бул әбекәй.

**Әби.** Сау булыгыз, балалар.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Менә бәйрәм кичәбез инде ахырына якынлаша. Балалар, бүгенге кичәбездә өйрәнгән кагыйдәләрне һәрвакыт истә тотарсыз дип ышанам.

Һәркөн диярлек күрешәбез без,

Һәрбер шатлыкны бүлешәбез без.

Мәңгегә шулай дуслык-татулык

Торсын яктырып диешәбез без.

Нинди олы бәхет җыелышып

Уйнап-көлү, бию гел бергә.

Насыйп булсын иде сөенешеп

Шатланышып яшәү гомергә.

**Хуҗабикә -тәрбияче.** Әйдәгез, күмәк җырлап саубуллашыйк дуслар.

**«Туган ил»** җыры җырлана.

# ШӨГЫЛЬЛӘР



## “ӘКИЯТ ИЛЕНДӘ”

***Гыйләҗиева Энҗе Рәшид кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*«Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Максат:**

- Балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен берләштереп, татар халкының “Өч кыз” әкиятен искә төшерү, ныгыту.

**Бурычлар:**

- Әкият аша балаларда яхшылык, бөеклек, ярдәмчеллек һәм ярату сыйфатларының иң мөһим сыйфатлар булуына ышаныч булдыру
- Балаларның сөйләм күнекмәләрен үстерү, матур әдәбият белән кызыксынуларын формалаштыру
- Әниләргә, әбиләргә, апаларга чәчәк бәйләме ясау күнекмәләрен үстерү. Гаилә кыйммәтләрен ныгыту.

**Сүзлек**: гөберле бака, үрмәкүч, эрли.

**Җиһазлар**: шкатулка, рәсемнәр, серле сандык, әзер шаблоннар

(Социальләштерү, аралашу, сынлы сәнгать эшчәнлеге, музыкаль белем бирү өлкәләре)

**Эшчәнлек барышы**.

1. Хәерле иртә, балалар! Хәлләрегез ничек? Кәефләрегез яхшымы? Мин бик шат. ***(Балаларның бакчага кем белән килүен, өйдә кемнәр калганын сорыйм, балалар җавап бирә)***

- Һәрберебезнең көннәре хәерле булсын! Бүгенге шөгылебез дә хәерле булсын. Мин сезгә барыгызга да уңышлар телим! ***(Ишек шакыган тавыш ишетелә. Бер баланы җибәрәм, ишекне ачып чемоданны алып керә)***
- Балалар, нәрсә калдырганнар безгә? ***(балалар җавап бирә)***
- Балалар, безгә кемдер бик матур чемодан калдырып киткән. Хаты да бар, укып карыйк әле. “Кадерле балалар! Мин әкиятләр иленең патшасы, сездән ярдәм сорыйм. Явыз сихерче безнең илебезгә килеп әкият геройларын, җиһазларын адаштырып, бутап китте. Сез безгә аларны үз урыннарына кайтарырга ярдәм итмәссез микән? Моның өчен сезгә серле чемоданда яшеренгән биремнәрне үтәргә кирәк булыр. ***(зур***

***чемоданны ачам, саннар куелганын әйтәм, кайсы санны беренче алырга тиеш икәнлеген сөйләшәбез. 1....2.....3. Бер бала 1 санын ача. Нәрсә икәнен әйтәләр).***

- Балалар, бу нәрсә?
- Алтын тарак.
- Ул кайсы әкияттә очрый?
- Су анасы. ***(Раяна су анасы)***
- Бик дөрес, балалар. Су анасы үзе безгә кунакка килгән. Алтын таракны үзенә тапшырыйк. ***(Бер бала алтын таракны су анасына алып барып бирә.).***
- Су анасы: Исәнмесез, балалар. Сез миңа алтын таракны табырга ярдәм иттегез. Бик зур рәхмәт сезгә. Бергәләп "Су анасы уенын уйнап алыйк. ***(Су анасы уртага баса, "Су анасы" уенын ике тапкыр уйныйлар.)***
- Рәхмәт, балалар, алтын тарагымны таптым, сезнең белән күңелле итеп уйнадым, хәзер миңа су буена кайтырга кирәк.
- Саубулыгыз. ***(су анасы чыгып китә, балалар саубуллашып кала.)***
- Димәк, алтын таракны без кемгә бирдек?
- Су анасына.
- Яхшы балалар. Кайсы санны алырга кирәк? Бер санынннан соң нинди сан килә? ***(балалар җавап бирә. Бер бала 2 санын куелган тартма ала, ача)***
- Бу нәрсәләр, балалар?
- Ничә әтәч?
- Ике
- Балалар кайсы әкияттә бар әле безнең әтәчләр?
- Дөрес "Чукмар белән Тукмар". Әйдәгез аларны үз урыннарына урнаштырыйк.
- Балалар безнең Чукмар белән Тукмар әкияте эчендә нинди хайваннар бар, кайсылары дөрес урнашмаган, карыйк? ***(балалар кыргый һәм йорт хайваннарын аералар. Дөрес итеп урнаштыралар.)***

**"Дөрес әйт" уены уйнала.**

- Димәк, ике әтәч кайсы әкияттән?
- Чукмар белән Тукмар.
- Балалар, серле чемоданда нинди сан калды? ***(Бер бала 3 санын ала һәм тартманы ача.)***
- Тиен, бака, үрмәкүч.
- Алар кайсы әкияттән булырлар икән?
- "Өч кыз" әкиятеннән.

- Бик дөрес. Ягез, әкиятне искә төшереп алыйк әле.
- “Өч кыз”әкияте ***(Балалар үзләре әкиятне сөйлиләр.)***
- Димәк, балалар без сезнең белән нинди әкият тыңладык? Әниләрегезгә һәрчак булышып, аларны кадерләп, олыгайган көнәрендә дә терәк булып, миһербанлы, игелекле булып яшәгез. Һәрчак әкияттәге кыздан үрнәк алыгыз. Әниләрнең хәлен белеп, матур, ягымлы сүзләр әйтеп, бүләкләр белән сөендереп торырга кирәк. Мин сезгә чәчәк ясарга тәкъдим итәм. ***(Музыка куела, балалар белән аралашып чәчәк ясыйбыз).***
- Балалар, чәчәкләрне кемгә бирергә мөмкин? Нинди ягымлы сүзләр әйтеп бирәбез? ***(балаларның җаваплары, аралашу)***
- Йомгаклау:
- Үстерешле уен.
- Әйдәгез, “Урынын тап!” уенын уйнап алабыз. ***(Картиналар бирелә, тиешле рәсемне ябыштыралар)***
- Өйдә кемнәр яшәгән? (әни, өч кыз)
- Урманда нәрсә яшәгән? (тиен)
- Әни янына ярдәмгә иң беренче нәрсә килә? (тиен)
- Беренче кыз нәрсәгә әвереләр? (бака)
- Икенче кыз нәрсәгә әверелә? (үрмәкүч)
- Өченче кыз нишли? Нәрсә кирәк? (камыр)
- Әнисенең хәлен белергә кайсы кыз килә? (өченче кыз)
- Булдырдыгыз, балалар, бик яхшы эшләдегез. Авыр вакытта ярдәмгә килдегез. Һәрвакыт шулай ярдәмчел, миһербанлы булыгыз!
- Бүгенге шөгыльдә нинди яңалык белгәнегезне, нәрсәләр эшләгәнегезне кайткач кемнәргә сөйлисез? ***(җаваплар)***
- Балалар, эшләребезне бетердек, “Су анасы” уенында чиратта кем калган иде, дәвам итәбез. (Балаларны уйнарга җибәрәм, кунакларга рәхмәт әйтеп саубуллашам)

**“Эх, Арча читекләре”**

***Гыйльметдинова Әлфинур Габдуллаҗан кызы.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 1 нче балалар бакчасы" муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

**Максат:**

Балаларны татар-милли гамәли сәнгате белән таныштыруны дәвам итү.

Аларны күн белән эшләргә өйрәтү, күн белән эшләү сәнгатенә кызыксыну уятү.

Балаларда һөнәрчеләр эшенә мәхәббәт һәм иһтирам тәрбияләү, аларның хыялын үстерү, иҗади карашларын киңәйтү.

Аларның татар милли бизәкләре турындагы белемнәрен арттыру, билгеле бер җайга (системага) салу.

Күргәзмә әсбаплар: татар халык бизәкләре төшерелгән рәсемнәр, картиналар, түбәтәйләр, читекләр, түфлиләр, мендәрчекләр, күннән тегелгән киемнәр, сумкалар, акча, ачкыч, күзлек янчыклары.

Җиһазлау: төсле күн кисәкләре, әзер читек силуэтлары, клеенка, чүпрәк, җилем-момент, пумалалар.

Шөгыль барышы:

Тәрбияче: Балалар, әйтегез әле, без нинди республикада яшибез?

Бала: Без Татарстан республикасында яшибез.

Т: Әйе, балалар, бик дөрес әйттегез. Без Татарстан республикасында яшибез. Ә безнең республикада нинди милләт халыклары яши?

Б: Безнең республикада татарлар, руслар, марилар, чувашлар, удмуртлар яши.

Т: Әйе, безнең республикада татарлар, руслар, марилар, чувашлар, удмуртлар яши, алар бик тату һәм дус яшиләр. Бергәләшеп төрле матур әйберләр ясыйлар, матур киемнәр тегәләр. Чигәләр.

Элек-электән, әби-бабаларыбыз заманында ук, матур итеп сөлгеләр, түбәтәйләр, киләмнәр чиккәннәр. Ә менә күннән өс киемнәре, аяк киемнәре теккәннәр. Алар гади генә итеп текмәгәннәр – аларга төрле-төрле бизәкләр ясап, чигеп теккәннәр.

-Балалар, хәзерге вакытта да күннән нәрсәләр ясалганын, тегелгәнен әйтегез әле.

Бала: Бүрекләр, каешлар, сумкалар, итекләр, читекләр, туфлиләр, перчаткалар.

Өстәл янына чыгып күрсәтү.

Т: Балалар, мин сезне бүген күннән эшләнгән әйберләр һәм күнгә бизәк төшерү сәнгате белән таныштырып үтәм. Халкыбыз гасырлар буенча үзенең тормышына, табигатькә карап сәнгать аша бу матурлыкны күрсәтергә тырышкан.

Безнең татар халкы элек-электән чигелгән күн киемнәре кияргә яратканнар. Оста тегүчеләр, чигүчелә аларны чәчәк бәйләмнәре төшкән бизәкләр белән бизәгәннәр.

Т: Ягез, балалар, әйтегез әле, татар халык бизәкләренә нәрсәләр керә?

Бала: Чәчәкле үсемлекләр.

Т: Ә нинди чәчәк мотивларын очратабыз. (Тактада күрсәтү)

Бала: Лалә, кыңгырау, дәлия, мәк, ромашка, яфраклар.

Т: Әйтегез әле, балалар, бу бизәкләрне теккәндә, чиккәндә нинди төсләр кулланган икән осталар?

Күннәрне күрсәтү.

Бала: Алар төрле төстә – яшел, кызыл, сары , ак, зәңгәр булалар.

Т: Ә күн төрле төстә булыр өчен аларны ни эшләтәләр?

Бала: Аларны төрле төстәге буяуларга маналар.

Т: Әйе, дөрес. Күнне Салават күперенең барлык төсләренә дә маналар. Аннары бизәк төшергәндә трафаретка салып кисәләр. Күн кисәкләреннән ясалган бизәкләрне мозаика тәртибендә урнаштырып, төсле җепләр белән тоташтырып чыгалар.

(Ике бала бизәкләрдән мозаика тезеп күрсәтә)

Т: Димәк, мозаика бизәге нигезендә нинди сурәтләр ята?

Бала: Йөрәк, дулкын, лаләсыман, дулкынсыман сурәтләр ята.

Бала: Күннән бизәкләп эшләнгән әйберләр һәрвакыт кул белән эшләнә. Шуңа күрә уникаль була.

Т: Хәзер без сезнең белән читекләр бизәрбез.

Практик эш.

Читекләр карау. Бизәкләрнең ничек урнашуларына игътибар итү.

Т: Менә, балалар, сез дә шул бизәкләргә карап сокланыгыз, чөнки бу милли бизәкләр бездә генә бит. Зур үскәч, бәлки кайберләрегез чигүче, читекче һөнәрен сайларсыз. Безнең милли сәнгатебезне дәвам итәрсез, әгәр сез дәвам итсәгез, безнең гореф-гадәтләребез яшәр һәм чәчәк атар!

Балалар эше, аларның эшенә бәя бирү.

Читтә торган читеккә игътибар итү.

1Бала: Читтә тора яңа читек

Ник уртага кермидер?

Тегеп кенә бетердек шул

Әле бии белмидер.

2 Бала: Аягымда чиккән читек

Карыйммы соң әле биеп.

Ничек оста бии читек

Тек-тек, тек-тек.

Чет-чет, чет-чет.

**Җыр**

Л.Б.Болгари музыкасы

**“Эх,Арча читекләре”**

***Гаиләм кыйммәтләрен эзләп***

( Мәктәпкә әзерлек төркемендә шөгыль конспекты)

***Әхмәтханова Гөлсинә Камил кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*Кече Рәс "Дуслык" балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

Максат: гаиләдә балаларда әти-әни , әби-бабайга, бертуганнарга карата ярату, хөрмәт хисе тәрбияләү, нәсел, гаилә кыйммәтләре турындагы белемнәрне системалаштыру.

Бурычлар:

1.Белем бирү: балаларны нәсел, туганнар гаилә турындагы мәкаль-әйтемнәр белән таныштыру, нәсел агачы-шәҗәрә төзергә өйрәтү.

2. Үстерешле: балаларның аралашу сәләтен , иҗади активлыгын үстерү, күмәк эшчәнлектә катнашу теләген уяту.

3. Тәрбияви: балалар бакчасында гаиләдә бер-береңә карата игътибарлылык , ярдәмләшү , үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү.

Материал: проектор, рәсем репродукцияләре төшерелгән слайдлар, сары түгәрәк төшерелгән плакат, гаилә кыйммәтләре (игелек, хөрмәт, мәхәббәт, кайгырту, дуслык) исемле нурлар; йомшак уенчык йөрәк; туп; "Гаилә агачы төзе" уены (һәр балага буш түгәрәкле агач сурәтләнгән битләр , баланың гаилә әгъзаларының фотолары); "Игелекле гамәлләр агачы" уены (игелекле эшләр сурәтләнгән яфраклар, агач рәсеме): кечкенә кояш ( нурларында гаилә кыйммәтләре язылган 5 кечкенә кояш) .

Шөгыль барышы.

Тәрбияче: балалар, мин сезне картиналар күргәзмәсенә чакырам. Бу картиналарны игътибар белән карагыз. Алар төрле рәссамнар тарафыннан язылган.

(Экранда картиналар репродукцияләре төшерелгән слайдлар күрсәтелә:

1.Фәридә Хасьянова "Гаиләм"

2.А.Ван дейк "Гаилә портреты",

3. Я. Колокольников –Воронин “Хатыны һәм улы белән автопортрет”

Тәрбияче: сез ничек уйлыйсыз, бу картиналарны нәрсә берләштерә?

Аларда кемнәр сурәтләнгән?

Балалар җавабының варианты. Бу картиналарда гаиләләр сурәтләнгән.

Тәрбияче: әйе. Ни өчен сез шулай уйлыйсыз?

Балалар җавабының варианты. Рәсемнәрдә әниләр, әтиләр, балалар, бәбиләр, бабайлар сурәтләнгән.

Тәрбияче: балалар , сез гаилә сүзен ничек аңлыйсыз?

Балаларның җавап вариантлары.

Гаилә-ул балалары булган ир-ат һәм хатын-кыз, ул сиңа теләсә кайсы минутта ярдәм итәргә әзер булган якын кешеләр, туганнарым, яраткан кешеләрем һ. б.

Тәрбияче: дөрес, гаилә – ул бергә яшәүче, бер-берсен яратучы олылар һәм балалар.

Тәрбияче: әйтегез әле, рәссамнар аларның мәхәббәтен, назын, кайгыртуын, бер-берсен ратуларын ничек җиткерә алганнар?

Балаларның җавап вариантлары. Әти-әниләр балаларын иркәләп кочаклыйлар, һәркемнең йөзе елмая , алар бергә ял итәләр, бергә өй эшләрен башкаралар.

Тәрбияче: гаиләдә барысы да бер-берсен яраталар, димәк, башка кешегә яхшы булсын өчен эшлиләр, бер-берсенә ярдәм итәләр.

Тәрбияче: балалар , гаиләгез нинди икәнен сөйләгез әле.

Туп белән уен « "Минем гаиләм иң....." җөмләсен дәвам ит.

(Тәрбияче балаларның берсенә туп ыргыта һәм сорау бирә)

-Дилә , синең гаиләң нинди? (бала җавабы)

-Рәлинә, синең гаиләң нинди? (б.ж.)

-Риназ, синең гаиләң нинди? (б.җ.)

-Айназ, синең гаиләң нинди? (б.ж.)

-Влад, синең гаиләң нинди? (б.җ.)

Тәрбияче: балалар, гаилә нык һәм бәхетле булсын өчен ул “Гаилә кыйммәтләре” белән баетылырга тиеш. Ә сез гаилә кыйммәтләренең нәрсә икәнен беләсезме? Беләсегез киләме? Ул чагында мин сезгә “Гаилә” исемле гаҗәеп илгә барырга һәм аларны шунда табарга тәкъдим итәм. Сез ризамы?

Тәрбияче: мин бер, ике, өч дигәндә күзләрне йомып урында әйләнәбез һәм күзләрне ачабыз.

Плакатта гаилә рәсеме төшерелгән зур сары түгәрәк ясалган.

Без сезнең белән гаилә илендә". Әйдәгез, бу илнең урамнары буйлап йөреп, гаилә кыйммәтләрен эзлик. Гаилә кыйммәтләрен табу өчен сезгә һәр тукталыштагы биремне үтәргә кирәк. Менә беренче тукталышка килеп тә җиттек.

1.”Минем шәҗәрәм”тукталышы

Тәрбияче: балалар, гаилә гаять зур агачка охшаган. Бу агачның тамырлары-карт бабаларыгызның һәм карт әбиләрегезнең эти-әниләре . Агачның калын ботаклары-дәү әти, дәү әниләрегез . Юкарак ботаклар - сезнең этиләрегез һәм әниләрегез, ә иң нечкә ботаклары - сез, балалар.

Үзегезнең гаилә агачын төзергә тырышыгыз. Үз гаиләгезнең әгъзаларының фотосурәтләре салынган конвертларны алыгыз һәм аларны агач модельләренә ябыштырыгыз. Иң өстә сезнең фотографиягез; янәшәдә бертуганнарыгыз( апа, абый, энекәш, сеңел), аннан астагы ботакларда сезнең эти-әниләрегез, тагын астарак дәү эти, дәү әниләрегез.

“Гаилә агачы төзе” уены

Тәрбияче: үз шәҗәрәгез турында сөйләгез

(5 бала гаилә агачына карап хикәя төзи. Мәсәлән, бу минем ботак. Бу мин, минем исемем Айназ. Бу минем олы абыем. - Булат. Монысы кечкенә абыем- Фердинанд. Бу минем әнием- Гөлия . Минем әтиемнең исеме - Айрат . Дәү әтиләрем –Ринат , Фазыл. Дәү әниләрем – Әлфия, Сания)

Тәрбияче: ә хәзер, әйдәгез, гаиләдә кемнең кем икәнен белик.

Уен " Син миңа кем?”

(Балалар әйләнәдә  басып тора, тәрбияче чиратлап балалар янына килә һәм үзен гаилә әгъзаларының берсе дип атый, мәсәлән, " мин синең әниең, ә син миңа кем?"- кыз; мин синең апаң, ә син миңа кем – энең (сеңлең) мин синең дәү әниең, ә син миңа кем  – онык ).

Тәрбияче: әйе, балалар, гаиләдә һәркемгә, бигрәк тә әти-әниләргә, әби-бабайларга хөрмәт белән карарга кирәк. Өлкәннәргә булган хөрмәтебезне ничек күрсәтә алабыз? (ярдәм итәргә, кайгыртырга, бүләкләр бирергә).

Менә без беренче гаилә кыйммәтен таптык – бу “ХӨРМӘТ”.

("ХӨРМӘТ”  дип язылган  нурны плакатка  беркетәбез)

2.«Ягымлы сүзләр» тукталышы

Тәрбияче: гаиләдә һәркем бер-берсен яратып, назлап карый. Хәзер без “Ягымлы эндәш ” дип аталган уен уйнаячакбыз.  Гаиләгезнең барлык әгъзаларына да ягымлы итеп эндәшегез.

“Ягымлы эндәш ”дидактик уены

(Балалар йомшак уенчык – йөрәк тапшыралар һәм ягымлы сүзләр әйтәләр)

1. Әбием, әбекәем;
2. Бабам, бабаем, бабакаем;
3. Әнием, әнкәем ;
4. Әтием, әткәем;
5. Абый, абыем.

Тәрбияче: менә без тагын бер гаилә кыйммәтен таптык-ул МӘХӘББӘТ

(“МӘХӘББӘТ" дигән язулы нурны  плакатка беркетәбез)

3 .”Кайгыртучанлык”тукталышы

Тәрбияче: әти-әниләрнең  үз балаларын яратуы аларның кайгыртуында чагыла. Әти-әниегез сезнең турыда ничек кайгырта?

(Балаларның җаваплары. Әни уенчыклар сатып ала, аш пешерә, кер юа, җыештыра, китаплар укый, тегә, безне дәвалый.  Әти велосипедта йөрергә, футбол уйнарга өйрәтә, уенчыклар сатып ала, уенчыкларны ремонтлый, безне яклый).

Тәрбияче: әйдәгез әле бераз ял итик.

“Әти һәм әни эшләре " динамик паузасы.

Балалар түгәрәккә басалар, музыка яңгырый, тәрбияче әниләренең һәм әтиләренең эшләрен атый. Малайлар әтине , ә кызлар әнинең эшләрен сурәтли.

Әни кер юа, әти кибеткә киткән, әни баланы йокларга яткыра, әти машина ремонтлый , әни борщ пешерә, әти кадак кага.

Тәрбияче: сез гаиләдә тагын нинди гаилә кыйммәте барлыгын сиздегез? (Кайгырту)

Тәрбияче: әле сез бәләкәй, сезне дәү әти, дәү әни, әти-әниләрегез , абый-апаларыгыз кайгырта. Үсеп җиткәч ,сез алар турында кайгыртачаксыз.

(“КАЙГЫРТУ” дип язылган нурны плакатка беркетәбез)

4.“Игелекле эшләр”тукталышы

Тәрбияче: әйтегез әле, ә сез якыннарыгыз турында кайгыртасызмы?

(Балалар җавабы).

Безгә “Игелекле гамәлләр агачы” ясарга кирәк. Сезгә өйдә якыннарыгызга ничек ярдәм итүегез сурәтләнгән яфрак алырга, нәрсә эшләвегезне әйтергә һәм аны агачка элеп куярга кирәк. (мәсәлән, мин әнигә савыт-саба юарга булышам, мин чәчәкләргә су сибәргә булышам, мин баланы карарга булышам, мин үз караватымны төзәтәм, мин уенчыкларымны җыештырам. Мин табын әзерләргә булышам. һ. б.)

“Игелекле гамәлләр агачы” уены

Тәрбияче: менә нинди матур агач килеп чыкты. Әфәрин.! Игелекле эшләр башкарып, без якыннарыбыз турында кайгыртабыз һәм үзебез дә игелекле булабыз.

Тәрбияче: менә без тагын бер гаилә кыйммәтен таптык-бу игелек.

(“ИГЕЛЕК” дип язылган нурны плакатка беркетәбез )

5. «Мәкальләр»тукталышы

Тәрбияче. Гаилә турында бик күп мәкальләр бар, әйдәгез аларны искә төшерик. Мин мәкальнең беренче яртысын әйтәм, ә сез мәкальнең ахырын әйтергә тиеш.

1. Мәхәббәтсез гаилә – тамырсыз агач.

2. Әткәй — шикәр, әнкәй — бал

3. Атаның сүзе — акылның үзе.

4. Ана куены туннан җылырак.

5. Тату туганнар таштан койма корганнар

Тәрбияче: әфәрин , дуслык ул-гаилә кыйммәте, ул да гаиләдә булырга тиеш.

(“ДУСЛЫК” дип язылган нурны плакатка беркетәбез)

Тәрбияче: балалар, карагыз әле, без күпме гаилә кыйммәтләрен таптык,

Нәрсә килеп чыкты соң? (КОЯШ).

Дөрес, һәм бу очраклы түгел, чөнки гаилә, кояш кебек, үз җылысы һәм назлары белән андагы һәркемне җылыта ала. Ә безгә балалар бакчасына кайтырга вакыт һәм мин гаилә кыйммәтләрен үзем белән алырга тәкъдим итәм. Безнең төркем шулай ук зур гаилә бит һәм алар безгә бик кирәк.

Тәрбияче: күзләрне йомабыз, урында акрын гына әйләнәбеәз, бер, ике, өч күзләрне ачабыз. Без янәдән балалар бакчасында.

Тәрбияче: “Гаилә”сәяхәтебез әнә шуның белән тәмамланды.

1.Әйтегез әле, кешегә ни өчен гаилә кирәк? (Балалар җаваплары)

2.Нинди гаилә кыйммәтләре гаиләне нык, тату итә? (Балалар җаваплары)

3.Сез үз гаиләгезгә нәрсә теләр идегез? (Балалар җаваплары)

Тәрбияче: балалар, сез бүген бик тырыш булдыгыз. Сезнең белемегез һәм тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә без гаилә кыйммәтләренең нәрсә икәнен белдек. Истәлеккә мин сезгә гаилә кыйммәтләре язылган кояш бүләк итәм.

**“Урманга сәяхәт”**

(Зурлар төркемендә экология буенча интегральләштерелгән белем бирү шөгыле)

***Нигъматуллина З.Г., Валиева А.Г.***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*“Дөбъяз “Гөлчәчәк” балалар бакчасы,*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

Шөгыльгә кертелгән белем бирү өлкәләре: танып белү, сөйләм телен үстерү, иҗтимагый–коммуникатив үсеш, иҗади -нәфәсәти үсеш.

Максат: туган якның төрлелеген күзалларга булышу, горурлык хисе һәм мәхәббәт тәрбияләү.

Бурычлар:

белем бирү бурычы: характерлы билгеләре буенча хайваннарны сурәтли белү; җөмләләрдә сүзләрне дөрес итеп төзеп һәм әйтергә өйрәтүне дәвам итү.

үстерү бурычы: ориентлашуны, логик фикерләү сәләтен, хәтерне, бәйләнешле сөйләмне үстерү.

тәрбия бурычы: туган якка, табигатькә, тереклек ияләренә сак караш, мәхәббәт тәрбияләү.

Методик алымнар: сүзле уен, практик эш, сөенечле мизгел, сорау бирү, нәфис сүз, мактау, бәяләү, җыр.

Технологияләр: кейс технологиясе.

Җиһазлау: кечкенә җәнлекләр рәсемнәре, кошлар сайравы тавышы, ноутбук, дүрт өлешкә бүленгән урман һәм ишегалды сурәтләнгән рәсемнәр.

Алдан үткәрелгән эш: кыргый җәнлекләр, йорт хайваннары һәм урманнар турында рәсемнәр карау

Шөгыльнең структурасы: I. Кереш өлеш (2 мин.):

II. Төп өлеш (20 мин.):

1.Балалар урманга бара.

2. Бирем “Урман төрләре ”

3. Бирем “ Табышмаклар”

4.Бирем “Сурәтләү буенча җавабын тап”

5. Бирем “ Җәнлекләрне аер ”

6.Бирем “Кисәкләрдән бербөтен җыю”

III. Йомгаклау (3 мин.).

Шөгыльнең барышы:

Тәрбияче: кулга кул тотынышыйк

Куллар җылысын тойыйк.

Хәерле көннәр телик.

Матур итеп елмайыйк

Шөгылебезне башлыйк.

Туган як ул- кешенең туган җире, шәһәре, авылы. Балалар, без яшәгән авыл ничек дип атала?

Балалар: Дөбьяз авылы.

Тәрбияче: Әйе, без Дөбьяз авылында яшибез. Сез үзегезнең яшәгән авылыгызны яратасызмы?

Балалар: Әйе, яратабыз.

Тәрбияче: Безнең Дөбьяз авылы нинди районга керә, балалар?

Балалар : Биектау районына.

Тәрбияче: Әйе , балалар, бик дөрес, Биектау районына. Быел безнең Биектау районына 90 ел була. Шушы бик күп еллар өчендә безнең районда бик күп эшләр башкарылган. Юллар салынган, матур йортлар тезелгән, балалар бакчалары, мәктәпләр . Кешеләргә ял итү өчен парклар, мәдәният йортлары булдырылган.Алга таба да районыбыз шундый матур булып үссен дигән теләктә калыйк.

Тәрбияче: Без нинди республикада яшибез?

Балалар: Без Татарстан Республикасында яшибез.

Тәрбияче: Безнең яшәгән җиребез бик матур. Аның тирә-ягында җиләкле, гөмбәле урманнар, күлләр бар. Без яши торган өебез, без йөри торган балалар бакчасы, без уйный торган мэйданчыклар, безнең урам, ял итә торган парклар – болар барысы да туган як була инде.

Иркен һәм матур да

Безнең туган илебез.

Урманга бай, суга бай

Гөлбакчалы җиребез,- дип язган туган җир турында Әминә Бикчәнтәева. Һәр кешегә туган җире кадерле, якын, аны һәркем ярата.

Балалар, без бүген сезнең белән бик күңелле сәяхәт оештырачакбыз. Ә кая барачакбыз, сез хәзер табышмакны чишкәч белерсез.

Ямь-яшел куе булганга,

Һәркем ярата аны,

Анда бик күп агачлар,

Җыр суза сандугачлар.

Кызарып җиләк пешә,

Чикләвекләр өлгерә,

Санап та бетереп булмый,

Нәрсә соң ул, кем белә? (урман)

Әйе, балалар, дөрес, бу -урман.

Тәрбияче: Игьтибар экранга. Сез анда нәрсә күрәсез?

Балалар: Урман, агачлар, куаклар, чәчәкләр һ.б.

Тәрбияче: Әйе, балалар , бу урман. Беләсезме, балалар, урман күп катлы йорт кебек.

3 нче кат – агач яфраклары түбә кебек. Алар урманны яңгырдан, көчле җилләрдән, бик кызу кояштан саклый.

2 нче кат – анда куаклар яши.

1 нче кат – аяк астындагы үләннәр, чәчәкләр, җиләк һәм гөмбәләр.

- Әле бу йортның подвалы да бар, анда үсемлекләрнең тамыры яши. Үсемлекләргә тамыр ни өчен кирәк?

Балалар: Үсемлекләр тамыр ярдәмендә туклана алалар, үсәләр.

Тәрбияче: Менә нинди кызык дөнья икән ул урман.

Балалар, без бүген читтән торып табигатькә кунакка барырбыз.Урманга сәяхәт итәбез. Без анда кунак кына. Ә кунак турында сез нинди мәкаль беләсез?

Балалар:" Кунак булсаң , тыйнак бул".

(Ишек шакыйлар, хат кертәләр)

Тәрбияче: Әйдәгез әле, балалар, бу хатны укыйк. “Исәнмесез, балалар, миңа сезнең ярдәмегез кирәк иде, минем урманда яшәүче җәнлекләрне барлап куясым бар, җәнлекләр арасында адашып йөргән хайваннар бар. Сезне урманга кунакка чакырам. **“Урман кызы”.**

Балалар, урманга барабызмы?

Балалар: Әйе, барабыз.

Тәрбияче: Балалар, урманга нәрсә белән барып була?

Балалар: машина белән, сәпит, җәяү, мотоцикл белән.

Тәрбияче: Без бүген барабыз автобус белән. Балалар, автобуска утырыр өчен урманда үзеңне тоту кагыйдәләрен әйтеп үтик әле. Кем дөрес әйтә, шул утыра.

Балалар: Агач ботакларын сындырырга, кош ояларына кагылырга, гөмбәләргә кагылырга, урманда кычкырырга , учак ягарга , кырмыска ояларын туздырырга ярамый.

Тәрбияче: Бик дөрес, балалар. Ә хәзер урманга кузгалабыз.

Әйдәгез "Күңелле сәяхәт" дигән җырыбызны җырлап китик.

(Җыр “Күңелле сәяхәт” Ә.Һадиева музыкасы., А.Минһаҗев сүзләре)

Тәрбияче: Балалар, менә килеп тә җиттек, әйдәгез әле урман тавышын тыңлап алыйк.

(Кошлар тавышы ишетелә, аны тыңлаганда Урман кызы килеп чыга)

Урман кызы: Исәнмесез, балалар.

Балалар:  Исәнмесез.

Урман кызы: Минем сезгә бер үтенечем бар.

Татарстан урманнарының төрлелеген ачыклап, шунда җәнлекләрне урнаштырырга һәм адашкан хайваннарны өйләренә кайтырга ярдәм итүегезне сорыйм, моның өчен сезгә биремнәр үтәргә кирәк, һәрбер дөрес җавап өчен җәнлекләрнең һәм хайваннарның яши торган җирләренең рәсеменең бер өлеше бирелер.

Беренче бирем “Урман төрләре”.

Урман кызы. Балалар, Татарстанда нинди урманнар бар икән, сез шуны беләсезме ?

Балалар: Татарстанда катнаш, нарат, чыршы урманнары бар.

Урман кызы: Катнаш урманнарда нинди агачлар үсә?

Балалар: Нарат, каен, өрәңге, имән агачлары үсә.

Урман кызы: Ә нарат урманнарында нинди агачлар үсә?

Балалар: Нарат урманнарында нарат агачы гына үсә, ул бик караңгы урман.

Урман кызы: Каенлык нәрсә икән ул ?

Балалар: Анда каен агачлары гына үсә.

Урман кызы: Сезгә дөрес җаваплар өчен рәсемнәрнең бер өлешен бирәм.

Икенче бирем “ Табышмаклар”

Урман кызы: Сорыдыр төсе, үткендер теше,

Урманда йөри, куяннар эзли.

Балалар: Бүре.

Урман кызы: Нечкә билле, көлтә койрыклы.

Балалар: Төлке.

Урман кызы: Килә бер батыр атлап,

Аягын баса лап-лап,

Урманда йөри, умартадан бал эзли.

Балалар: Аю.

Урман кызы: Җәен соры, кышын ак,

Аңа шулай якшырак.

Балалар: Куян.

Урман кызы: Бер нәрсә тегә белми, энәләр тагып йөри.

Балалар: Керпе.

Урман кызы: Кош түгел – оча, ябалактан курка,

Чикләвекне ярата, сызгырса урманны яңгырата.

Балалар: Тиен.

Урман кызы: Дөрес җавап бирдегез, менә сезгә рәсемнәрнең икенче өлешен бирәм.

Өченче бирем “Сурәтләү буенча җавабын тап ”

(Берничә бала табышмакларда әйтелмәгән җәнлекләрне сурәтли, ә калган балалар нәрсә турында сөйләгәнен белергә тиеш була).

Бала: Ул җәнлекнең башында куак үсә, ул бик көчле, урман хуҗасы.

Балалар: Поши.

Бала: Бу җәнлек көндез балчыкта күмелеп ята, кич ашарга эзләргә чыга, ул имән чикләвеге ашарга ярата.

Балалар: Кабан дуңгызы.

Бала: Урманда яши, җирдән шуыша, аңа тиергә ярамый.

Балалар: Елан.

Урман кызы: Бик дөрес. Менә сезгә рәсемнәрнең өченче өлеше.

Дүртенче бирем “Җәнлекләрне аер”.

Урман кызы: Балалар, җәнлекләр ике төргә бүленәләр үлән белән тукланучылар һәм ерткычлар.

Урман кызы: Хәзер һәрберегез бер җәнлек рәсемен алып, ике төркемгә бүленеп басырга кирәк. Уң якка –үлән белән тукланучылар, сул якка – ерткычлар басыгыз һәм җәнлегегез яраткан ризыкны табып алып, аның турында сөйләп үтегез. Мәсәлән: Бу керпе, ул гөмбә, җиләкләр белән туклана. Ул аларны урманда агач төпләрендә, аланлыкларда эзләп таба.

Бала: Бу куян, ул яшь агач ботаклары, агач кайрылары, үләннәр белән туклана.

Бала: Бу бүре, ул төрле җәнлекләр белән туклана.

Бала: Бу төлке, ул тычканнар, куяннар, кошлар белән туклана.

Урман кызы: Дөрес, балалар, сезгә рәсемнәрнең дүртенче өлеше.

Бишенче бирем “ Рәсемне төзү”.

Урман кызы: Балалар, сезгә рәсемнең өлешләрен дөрес итеп җыярга кирәк.

Нинди рәсемнәр килеп чыкты.

Балалар: Урман һәм ишегалды рәсеме.

Урман кызы. Әйдәгез, хәзер ике командага бүленик тә , һәрбер хайванны үзе яши торган җиргә урнаштырыйк. (Балалар кечкенә җәнлек рәсемнәрен урнаштыралар).

Урман кызы: Балалар, ә сез урманга нинди җәнлекләр куйдыгыз? Әйдәгез берегез сөйләгез әле.

(Балалар әйтеп чыгалар).

Урман кызы: Болар барысы да нинди хайваннар дип аталалар?

Балалар. Кыргый хайваннар.

Урман кызы. Әйе, балалар , бик дөрес.Ә нинди хайваннар адашып урманга кергән соң монда, балалар

Балалар: эт, мәче, сыер, кәҗә, ат.

Урман кызы: Ә алар кайда яшәргә тиеш соң? Дөрес, балалар, сарайда, кешеләр янында. Аларны нинди хайваннар дип атыйлар ?

Балалар: Йорт хайваннары.

Урман. кызы. Ни өчен алар урманда яши алмый?

Балалар: Алар туңалар, үзләренә ашарга ризык таба алмыйлар, аларны бүреләр ашап бетерә

Урман кызы: Балалар, миңа һәм җәнлекләргә ярдәм итүегез өчен сезгә зур рәхмәт.

Тәрбияче: Балалар, безгә кире балалар бакчасына кайтырга кирәк. Әйдәгез, автобуска утырыйк та , балалар бакчасына кайтыйк.

Урман кызы: Сау булыгыз, балалар.

Тәрбияче: Балалар сезгә бүгенге сәяхәт ошадымы?

Балалар: Бик ошады.

Тәрбияче: Нәрсә күбрәк ошады?

Балалар : Адашкан хайваннарны өйләренә кайтару , аларга ярдәм итү ошады.

Тәрбияче: Яхшы, балалар, рәхмәт сезгә, сез бик мәрхәмәтле һәм ярдәмчел булып үсеп киләсез. Алга таба да шундый булып калыгыз. Урманнарны бергәләп саклыйк һәм яклыйк.

## “Кышкы урманга куянга кунакка”

## (Икенче кечкенәләр төркеме)

***Рамазанова Лилия Фирдинанд кызы*,**

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*«Үрнәк балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә*
*белем бирү учреждениесенең тәрбиячесе*

**Максат:** кыргый хайваннар һәм кыш көне табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәрен ныгыту.

**Бурычлар:**

- әйләнә- тирәгә, хайваннарга карата кызыксынучанлык тәрбияләү;

- балаларның игъбарлыкларын, хәтерен үстерү, танып белү активлыкларын формалаштыру**.**

**Җиһазлау:** агачлар, рәсемнәр белән карточка, хайваннар уенчыклары, уенчык өй һәм агачлар, уенчык аю һәм өне, кошлар рәсемнәре, җимлек, компьютер, зурлар төркеменнән куян булып киенгән бала.

**Эшчәнлек барышы**

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле,бүген безгә күпме кунак килгән. Әйдәгез әле, матур итеп исәнләшик әле кунаклар белән.

**Балалар:** Исәнмесез!

**Тәрбияче:** Балалар, мин сезгә хәзер бер табышмак әйтәм, тыңлагыз:

Һәр җир карланган,

Сулар бозланган,

Уйный җил-буран,

Бу кайчак, туган? ( Г. Тукай)

**Балалар:** Кыш.

**Тәрбияче:** Әйе, хәзер табигатьтә кыш, бөтен җирне кар каплады, урамда салкын.

*Ишек шакыган тавыш ишетелә*

**Тәрбияче:** Кем килде икән, карыйк әле. (*Барып ишекне ача, хат бирәләр)*

**Тәрбияче:** *(Укый)* “Хәерле көн, балалар!Минем бүген туган көнем, мин сезне урманга кунакка чакырам. Шулай ук минем тагын бер үтенечем бар. Кошлар бик тә ачыкканнар, җимләре калмаган, аларга җим салып китә алмассыз микән?!” (Куян)

**Тәрбияче:** Балалар, кунакка барабызмы? Куянның үтенечен үтибезме? Ә бүләккә нәрсә алып барыйк икән? Куян нәрсә ярата? Аны белер өчен әйдәгез әле менә бу өстәлдәге карточкыларны карап, куянның нәрсә яратканың белик әле.

(*Өстәлдә карточкылар, балалар шуларны алып куян нәрсәне ярата, нәрсәне юк икәнен әйтергә тиешләр)*

**Тәрбияче:** Балалар, куян суган яратамы?

**Балалар:** Юк, яратмый.

**Тәрбияче:** Балык, кишер, солы, җиләк, кәбестә яратамы?

**Тәрбияче:** Димәк, балалар, безнең куян кишер, кәбестә.... ярата икән. Карагыз, әле миндә кәрзиндә кишер белән кәбестә бар шуны гына алып бармыйбызмы?

**Балалар:** Алып барабыз.

**Тәрбияче:** Балалар, урманга барган килеш әйдәгез кошларга да җим алып барып, ашарларына салып кайтыйк.

**Тәрбияче:** Сез ничек уйлыйсыз, урамга шушы киемнәрдән генә чыксак буламы?

**Балалар:** Юк, урамда салкын, җылы итеп киенергә кирәк.

**Тәрбияче:** Әйдәгез алайса, әйбәтләп киеник.

(*Бергәләшеп киенгәннәрен күрсәтәләр*)

**Тәрбияче:** Яхшы, балалар, без сезнең белән әзер, җылы итеп киендек. Хәзер урманга барсак та ярый. Балалар, кар тирән әйдәгез минем арттан, "кар көртләрен" ерып, аякларны күтәреп атлап барабыз.

(*Тәрбияче артыннан атлап баралар.Буран, җил искән тавыш ишетелә*).

**Тәрбияче:** Менә, балалар, без сезнең белән урманга да килеп җиттек. Карагыз әле, балалар агачка карагыз әле нәрсәләр ул?

**Балалар:** Кошлар.

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез кәрзиндәге җимне кошларга җимлеккә салыйк. Аларга кыш көнне ашарга табырга бик авыр.

(*Балалар җимлеккә җим салалар)*

**Тәрбияче:** Әйдәгез, балалар, юлыбызны дәвам итик. Карагыз, әле нинди зур кар көрте, анда балалар аюның өне. Анда аю йоклый. Аны уятмыйча гына, әкрен генә узып китик.Балалар, карагыз әле анда агач төбендә безнең куяныбыз түгелме соң?

**Балалар:** Әйе, куян.

**Куян:** Балалар, исәнмесез!Килеп җиттегезме?

**Балалар:** Исәнме, куян! Туган көнең белән сине!

**Куян:** Рәхмәт, балалар, мин сезне күрергә бик шатмын.

**Тәрбияче:**Куян, без сиңа кечкенә генә күчтәнәч алып килдек.

*(Тәрбияче кәрҗинне бирә)*

**Куян:**Рәхмәт, балалар!

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле куянның туны нинди төстә?

**Балалар:** Ак.

**Тәрбияче:** Балалар, ә сез ничек уйлыйсыз куянга суыкмы?

**Балалар:**Юк.

**Тәрбияче:** Ни өчен ул тунын ак төскә алыштырган? *(балалар җаваплары)*

**Куян:** Әйе, балалар, миңа җылы. Минем туным мине суыклардан саклый. Кыш көне мин аның төсен узгәртәм, явыз бүре һәм төлкедән качыр өчен.

**Тәрбияче:**Куян, без балалар белән бик озак килдек, тундык, әйдәгез балалар белән азрак җылынып алынып алыйк әле.

**Куян:** Мин риза

*Физкультминутка*

Йом –йомшак куяннар *(киереләләр)*
Йокыдан уянганнар,
Нинди рәхәт аланда,
Шатланалар алар да. *(сикергәлиләр)*
Тик бүрене күрмиләр, *(як-якка караналар)*
Читтәнрәк йөрмиләр
Бүре – бик явыз нәрсә, *(кулларын, йодрыклап,*
Уйлап тормый һичнәрсә, *бармак белән күрсәтәләр*
Аланга килеп җитә, *бурене курсэтэлэр,*
Куяннар йөгереп кача. *чабып китәләр*

**Тәрбияче:** Әфәрин, балалар, җылындыгызмы?

**Балалар:** Әйе.

**Куян:** Балалар, әйдәгез әле бергә тагын бер уен уйнап алыйк әле.

Дидактик уен "Кыргый һәм йорт хайваннарын аер"

*(Өстәлдә йорт һәм агач макетлары тора. Балалар кыргый һәм йорт хайваннары уенчыкларын аерып куялар. Тәрбияче карап чыга, хаталары булса балаларны төзәтә)*

**Куян:** Әфәрин, балалар, булдырдыгыз!

**Тәрбияче:**Куян, безгә инде балалар белән балалар бакчасына кайтырга вакыт.

*(Балалар куян белән саубуллашалар)*

**Балалар:** Сау бул, куян!

**Куян:** Сау булыгыз, балалар! Мин тагын сезне узебезгә урманга көтеп калам.

**Тәрбияче:** Балалар, минем арттан кардан зур-зур атлап кайтыйк. Менә, балалар, без бакчага кайтып та җиттек. Киемнәрне салыйк. *(Балалар тәрбияче белән киемнәрен салганнарын күрсәтәләр).*

*Нәтиҗә ясау.*

**Тәрбияче:** Балалар, без бүген кемгә кунакка бардык? Сезгә кышкы урманда ошадымы? Без анда нәрсәләр күрдек? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Балалар, безнең инде кунакларыбыз белән дә саубуллашыр вакыт җитте.

**Балалар:** Сау булыгыз!

**“Тылсымлы илгә ярдәм итик”**

(STEM-технологиясен кулланып мәктәпкә әзерлек төркемендә интегральлләштерелгән белем бирү эшчәнлеге)

***Яруллина Алсу Рәфыйкъ кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе*

**Максат:** тәҗрибәләр үткәрү процессында танып-белү эшчәнлеген үстерү. Тикшеренү күнекмәләрен үстерү; кызыксынучанлык, күзәтүчәнлек, кул моторикасы, күзаллау, логик фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү

**Бурычлар:** 1. Предметны тикшерергә һәм предмет белән экспериментлар ясарга өйрәтү, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтү;

- фикер йөртә белү сәләтен үстерү, гипотезалар чыгара белү, нәтиҗәләр ясый белүне өйрәтү;

- кызыксынучанлык, танып белү эшчәнлегенә кызыксыну тәрбияләү;

- балаларда электр турында элементар күзаллаулар формалаштыру;

- су һәм комның үзлекләре турында элек алган белемнәрен камилләштерү;

- сүз байлыгын активлаштыру;

2. Фикерләүне, зирәклекне үстерү өчен шартлар тудыру;

3. Мөстәкыйльлек тәрбияләү, куелган бурычны аңлый белү һәм аны мөстәкыйль үтәүне камилләштерү; авыр хәлдә калучыларга ярдәм күрсәтергә омтылу теләге тәрбияләү.

**Шөгыль барышы**

Балалар һәм тәрбияче түгәрәккә басалар һәм исәнләшәләр

Тәрбияче: Балалар, бүген, мин эшкә барганда юлда сәер предмет таптым (ялтыравыклы таяк күрсәтә). Сез ничек уйлыйсыз, бу нәрсә? (балаларның җаваплары). Сез аны Тылсымлы таяк дип уйлыйсызмы? Тылсымлы таяк каян килде икән безгә? Бәлки Тылсымлы илдә берәр начар хәл булгандыр? Балалар, ә без моны ничек белә алабыз? Илдә барган соңгы яңалыкларны без каян белербез? (балаларның җаваплары). Дөрес, Яңалыклар чыгарылышыннан. Әйдәгез телевизорны кабызыйк.

Экранда әкият персонажы булып киенгән яңалыклар алып баручы Тылсымлы илдә коточкыч давыл булган, ул барысын да астын- өскә әйләндергән, дип хәбәр итә. Иң аянычы шул: ул тылсымлы таякны алып киткән, ә аннан башка Патшабикә тәртип урнаштыра алмый.

Тәрбияче: Балалар, нишләргә соң безгә? Ашыгыч рәвештә Тылсымлы илгә барып, Патшабикәгә ярдәм итәргә кирәк. Һәм без һичшиксез үзебез белән тикшеренүченең (исследователь) серле-чемоданын алачакбыз, чөнки Тылсымлы илдә безне бик күп яңа һәм кызыклы әйберләр көтә бит! Мин сезгә анда шарда очарга тәкъдим итәм.

Тәрбияче белән балалар гелий кабарткан шарны тоталар да, тылсымлы сүзләр әйтеп, Тылсымлы илгә эләгәләр. Экранда тылсымлы илнең декорацияләре күренә. Балалар зал буйлап баралар һәм ак төнбоеклар (ак кәгазьдән эшләнгән) күрәләр.

Тәрбияче: Карагыз әле, бу нәрсә?

Балалар: чәчәкләр, төнбоеклар

Тәрбияче: Төнбоеклар кайда үсә?

Балалар: Суда

Тәрбияче: Ләкин хәзер алар җирдә, давыл аларны судан ярга чыгарып ташлагандыр. Әйдәгез аларга ярдәм итик.

Һәр бала чәчәк ала һәм аны сулы савытка-«күл»гә сала. Суга кергәч, төнбоеклар тарала башлый.

Тәрбияче: Балалар, карагыз әле, безнең чәчәкләргә нәрсә булды?

Балалар: Алар ачылдылар

Тәрбияче: Сез ничек уйлыйсыз, ни өчен шулай килеп чыкты?

Балалар: Чөнки төнбоеклар кәгазьдән эшләнгән, аларның җепселләре су белән чылана һәм авырая.

Тәрбияче: Әйдәгез карыйк, шулаймы икән?

Тәрбияче: Кәгазь җепселләрен карау өчен, безгә серле чемоданнан нәрсә кирәк булыр?

Балалар: Лупалар!

Балалар судан чәчәкләрне алалар һәм чемоданнан лупалар алып аларны тикшерәләр.

Тәрбияче.: Кәгазь чылангач, кәгазь җепселләре калыная яки юкара?

Балаларның җаваплары (калыная)

Тәрбияче: Безнең юеш төнбоекларның хәзер җепселләре нинди?

Балалар: Калын.

Тәрбияче: Дөрес, шуңа күрә безнең төнбоеклар аларның авырлыгы астында суда үзләренең таҗ яфракларын ачтылар.

Балалар чәчәкләрне суга салалар һәм лупаларны кире чемоданга урнаштыралар.

Тәрбияче: Ә безгә юлны дәвам итергә кирәк

Тәрбияче һәм балалар таулар ясалган декорацияләр янына киләләр.

Тәрбияче: Балалар бу тауларда гномнар асылташлар чыгара. Мин сезгә эчкә узарга тәкъдим итәм, нәрсәләр бар икән анда, карыйк әле.

Декорация җәелә. Балалар матур ташлар һәм ком яткан декоратив комлык янына киләләр. Янәшәдә көрәкләр һәм чиләк ята.

Тәрбияче: Монда да давыл бәла-каза китергән! Барлык асылташлар ком белән күмелгән. Ташларны комнан ничек аерырга соң? (балаларның тәкъдимнәре) Балалар башта куллар яки көрәкләре белән комнан ташларны җыярга тәкъдим итә алалар). Балалар безнең серле-чемоданда ташларны комнан тиз генә аеру өчен бер ысул бар.

Балалар серле-чемоданнан ком иләү өчен иләк табалар һәм ташларны комнан аерып, чиләккә җыялар.

Тәрбияче: Афәрин! Монда да без тәртип урнаштырдык һәм Тылсымлы илдә яшәүчеләргә ярдәм иттек. Ә Патшабикә узе кайда соң? Мин сезгә аны эзләргә барырга тәкъдим итәм.

Физкультминутка үткәрелә.

Син барасың, мин барам, *(атлыйлар)*

Син чабасың, мин чабам, *(йогерәләр)*

Син йөзәсең, мин йөзәм, *(йөзәләр)*

Син эчәсең, мин эчәм, (*эчәләр)*

Син ашыйсың, мин ашыйм, (*ашыйлар)*

Син уйныйсың, мин уйныйм, *(уйныйлар)*

Син җырлыйсың, мин җырлыйм. *(җырлыйлар)*

Син биисең, мин биим. *(бииләр)*

Без бергә тату дуслар. *(кул чабалар)*

Аермаслар дошманнар. (*кул чабалар)*

Тәрбияче: Балалар, без сезнең белән барган арада кич җитте һәм бик тиз караңгы төште. Ләкин ни өчен соң Тылсымлы илдә урам яктырткычлар (фонарьләр) янмый?

Күрәсең, давыл электр чыбыклары урнашкан манараны аударган

Тәрбияче: Балалар без ничек ярдәм итә алабыз?

Балалар: Яңа манара төзи алабыз

Тәрбияче: Әйе, әлбәттә. Без аларга манара төзербез. Мин сезгә манараны нинди материаллардан төзиячәгебезне уйларга тәкъдим итәм. Сез ничек уйлыйсыз, манараны нәрсәдән төзиләр?

Балаларның җаваплары (таш, агач һ.б.)

Безгә балалар суда батмый торган материал кирәк. Мин сезгә эксперимент үткәрергә тәкъдим итәм.

Балалар материалның йөзүчәнлеген билгеләү өчен таш һәм агач кубик белән «Йөзә-калка» экспериментын үткәрәләр. (Сулы савытка агач кубик белән ташны төшерәләр, таш бата, ә агач кубик суда йөзеп кала). Барысы бергә нәтиҗә ясыйлар: таш бата, ә агач юк.

Акыллы уеннар сериясеннән “Манара” уенын кулланып балалар манара төзиләр.

Тәрбияче: Балалар утлар янды, һәм без сигнал бирүче манара янына килеп җиттек! Тылсымлы шарлар безгә Патшабикәне чакырырга ярдәм итәчәк!

Балалар шарлар кигән (1,5 л шешәдән )торган манара янына киләләр.

Тәрбияче: Карагыз, безнең шарлар шиңгән. Давыл монда да тырышкандыр. Әйдәгез аларны күтәреп карыйк.

Балалар шарларын күтәрәләр һәм алар үзләре кабара башлыйлар (шешәләрдә серкә, ә шарларда сода).

Тәрбияче: Безнең шарлар үзеннән-үзе кабардылар! Тылсыммы?

Балалар. Әйе!

Тәрбияче. Ләкин мондый тылсым гади генә түгел, ә фәнни һәм без аны үзебезнең лабораториядә бакчага кайткач эшләп карый алабыз.

Экранда Патшабикә күренә һәм тылсымлы илдә яшәүчеләргә ярдәм иткәннәре өчен балаларга рәхмәт әйтә. Балалар һәм тәрбияче Феягә Тылсымлы таяк бирәләр, ә ул тылсымлы илне коткарган өчен балаларга медальләр бүләк итә.

Тәрбияче: Булдырдыгыз балалар! Сезнең ярдәм белән без Тылсым иленә ярдәм иттек. Ләкин безгә балалар бакчасына кайтырга вакыт җитте. Әйдәгез, тылсымлы шарыбызга тотыныйк та өйгә очыйк (балалар шарны алалар тылсымлы сүзләр әйтәләр).

Тәрбияче. менә без тагын бакчада. Сөйләгез әле, безнең сәяхәттә сезгә барыннан да бигрәк нәрсә ошады?

(Балалар тәэсирләре белән уртаклаша)

Тәрбияче. Әйдәгез яңалыкларны кабызып карыйк, Тылсымлы илдәге хәлләр ничек икән?

Экранда алып баручы тылсымлы илдә мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбияләнүчеләре ярдәмендә яңадан тәртип торгызылды, Тылсымлы илдә яшәүчеләр рәхмәт йөзеннән бүләккә тәмле конфетлар сандыгын җибәргәннәр һәм балаларны тагын кунакка көтеп калалар дип хәбәр итә.

Тәрбияче:(сандыкны күрсәтеп) менә конфет салынган сандык. Барыгызга да төркемгә барып чәй эчәргә тәкъдим итәм.

**Остаханәдә кунакта.**

(мәктәпкә әзерлек төркеме)

***Шәймәрданова Ләйсән Мәхмүт кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы “Катнаш төрдәге Норма балалар бакчасы “Тургай” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Максат:** Татар милли киемендәге бизәкләр турында балаларның күзаллауларын тирәнәйтү һәм күләмле сурәтләр (арт-стринг) техникасы ярдәмендә бизәк ясау.

**Бурычлар:**

**Үстерү бурычы:**.

- игътибарны, күзәтүчәнлекне, логик фикерләүне үстерү; вак моториканы үстерү;

- җепләр һәм кадаклар белән эшләү күнекмәләрен, күз үлчәмен үстерү.

**Тәрбия бирү бурычы:**

- Балаларда хезмәт алымнарын үтәгәндә пөхтәлек, хезмәт сөючәнлек, тыңлау, аралашучанлык, активлык, коллективта эшли белү тәрбияләү.; бер-беребезгә карата кайгыртучан мөнәсәбәт, ярдәмчеллек тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы:** Татар халкының милли бизәкләре («лалә», «кыңгырау») исемнәре белән таныштыру;

**Сүзлек:** Арт-стринг, бизәк

**Методик алымнар**: әңгәмә, сораулар, аерым җаваплар, күрсәтмә материаллар (бизәк төшерелгән кием күрсәтү), гамәли эш алымнарын күрсәтү

**Материаллар**: Маркерлар, кашыклар, агач түгәрәкләре, җепләр.

**Шөгыль барышы:**

**Тәрбияче**:

-Исәнмесез, балалар! Әйдәгез килегез, бирегә рәхим итегез әле. Матур итеп ярым түгәрәккә тезелеп басыйк әле.

-Балалар,кәефләрегез ничек?

-Яхшы.

-Балалар, бүген без сезнең белән милли киемнәр, татар милли бизәкләре турында сөйләшербез.

- Ә иң элек миңа әйтегез әле без яшәгән республика ничек дип атала?

-Татарстан.

- Ә безнең республикада нинди милләтләр яши?

-татарлар, руслар, удмуртлар һ.б.

-Яхшы, балалар, мин сезне бүген үземнең остаханәмә чакырам. Сезнең минем остаханәмне күрәсегез киләме? Сез бит хәзер минем остаханәмдә кунакта булачаксыз, әйдәгез кунакта үзеңне ничек тотарга кирәк, искә төшереп үтик әле.

- Ә хәзер рәхим итегез минем остаханәмә. Менә бу манекенга игътибар итегез әле, анда кайсы милләт киеме?

*Балалар җавабы (татар халкыныкы)*

-Дөрес. Ә сез аның татар милләте киеме икәнен ничек белдегез?

-*балалар җавабы (анда төшерелгән бизәкләр ярдәмендә).*

Балалар,карагыз әле, ә бу бизәк безнең ничек атала?

*балалар җавабы ләла.*

______ ә бу бизәк?

*бала җавабы яфрак.*

______ ә менә монысы?

*бала җавабы кыңгырау.*

-Яхшы, ә безнең бу бизәкләр нәрсәгә нигезләнеп эшләнелгән?

*Бала җавабы үсемлекләр.*

-Дөрес, балалар ә сез беләсезме, мин татар бизәкләрен җанландыра да алам...сезнең дә үз кулларыгыз белән аларны җанландырып карыйсыгыз киләме?

-*Балалар җавабы*

**Тәрбияче:** әйдәгез рәхим итегез *(утыралар)*. безгә аларны җанландырыр өчен ярдәмгә су, кашыклар, маркерлар киләчәк.

Балалар, бу нинди бизәк?

-*Балалар җавабы (кыңгырау чәчәге).*

-Бик дөрес.

-Менә сезнең алдыгызда хәзер кыңгырау чәчәгенең рәсеме тора, шуңа карап хәзер әйдәгез маркерлар ярдәмендә менә шушы бизәкне ясыйбыз. Әйдәгез эшкә керештек.**Музыка**

*Эш барышында сорыйм:* ______ *синеке килеп чыгамы?*

-Бизәкләрне ясадык, ә хәзер миңа әйтегез әле, сезнең кыңгырау чәчәген кайларда күргәнегез бар?

*урманда, болында...*

_______ ә синең кайларда күргәнең бар?

Яхшы, _______ безнең кыңгырау чәчәгебез нинди төстә?

-*Зәңгәр.*

-Дөрес, әйдәгез бизәгебез кипкән арада без дә сезнең белән шушы зәңгәр чәчәк турында шигырь юллары әйтеп әйтеп алыйк әле.

-**Юл читендә зәңгәр чәчәк,**

**Якты нурлар тарата.**

**Безнең кызлар һәм малайлар**

**Зәңгәр чәчәк ярата.**

-Ә хәзер әйдәгез, сулышны борын белән алып авыз белән кыңгырау чәчәгенә өреп чыгарабыз. Бу күнегүне 3 тапкыр кабатлыйбыз һәм бергәләп әкрен генә бизәгебезне суга төшерәбез, ашыкмыйбыз, ашыксагыз килеп чыкмый... карагыз нишлиләр безнең бизәкләр?

-*Балалар җавабы(йөзәләр)*

**Тәрбияче:** балалар карагыз әле әкрен генә өреп алсак эле алар биеп тә алалар...

-Булдырдыгыз! Сезнең барыгызны да бизәкләрегез бик матур килеп чыкты! Миңа барыгызныкы да ошады. Ә сезнең үзегезгә ошадымы?

**Тәрбияче:** Ә хәзер, әйдәгез юлыбызны дәвам итеп бирегә килеп басыйк әле.

-Балалар бу нәрсә?

*балалар җавабы: сандык.*

- Бу безнең гади генә сандык түгел, ә тылсымлы сандык. Аны ачар өчен сандык турында матур сүзләр әйтергә кирәк. Әйдә әйтегез әле безнең сандык нинди?

Ә хәзер ______ әйдә әле безнең сандыгыбызны ачып кара әле, нәрсәләр бар икән анда?

**Сандыкны ача һәм аның эченнән табышмаклар язылган ләла чәчәге килеп чыга.**

-Әйдә әле миңа ләла чәчәген алып бир әле, ой балалар аның артында сезнең өчен табышмаклар бар икән. Әйдәгез әле табышмакларга бергәләп җаваплар табыйк. Хәзер мин сезгә табышмакларны укыйм ә аларның җаваплары сандыкта булыр.

**1.Яңа гына идем итек,**

**“Ч” өстәгәч булдым ... (читек)**

- ______ бик дөрес. Әйдә әле шушы сандык эченнән безгә җавапны табып күрсәт әле.

**2.Әнием ак сәйлән тезеп,**

**Чиккән яшел бәрхетне,**

**Ул үзем кебек бәләкәй**

**Ә исеме ... (түбәтәй)**

*түбәтәйне таба.*

**3.Җырлый, җырлый сәхнәләрдә**

**Аларның биер чагы.**

**Кызларга бик килешә**

**Башындагы ... (калфагы).**

*калфакны таба.*

Яхшы балалар. Ә сез тагын татар халкының нинди милли киемнәрен беләсез? Булдырдыгыз , балалар! Ә хәзер мин сезне остаханәмнең алдагы өлешенә чакырам. ***Утыралар.*** Без бүген сезнең белән АРТ СТРИНГ алымын кулланып лəла чәчәген ясарбыз. АРТ-СТРИНГ-ул инглиз сүзе, ул кадакка сузылган җепләр ярдәмендә күләмле сурәтләр ясау техникасы.

Без буген сезнең белән чын осталар булачакбыз һәм менә шушындый матур лəла чәчәген ясыйбыз. Эш өчен безгә кирәк булачак: кадак кадакланган агач түгәрәкләре, җепләр**. Сезнен кулларыгыз кадакларга эләкмәсен өчен, һәм уңайлы беркетү өчен мин эчләренә җепләр кергән ручка саплары куйдым ...**

Сезгә җепләр белән барлык кадакларны да бер-берсе белән тоташтырып, дуслаштырып чыгарга кирәк булачак. Хәзер мин сезгә эшләп күрсәтәм, аннан сезнең белән бергә эшләрбез. Әйдәгез эшкә керештек. **Музыка.**

**Эшли башлагач:** Менә балалар элек безнең әби-бабаларыбыз шушылай аулак өйләргә җыелып уеннар уйнаганнар, шәлләр бәйләгәннәр.

**Йомгаклау.**Менә безнең лалә чәчәкләребез әзер! Ә хәзер әйдәгез әле минем янга килегез әле. Без бүген сезнең белән нәрсә эшләдек? Өйгә кайткач, кемнәр белән эшләп карыячаксыз? Ә хәзер әйдәгез мин сезне төркемегезгә озатып куям.

**Кечкенәләр төркеме өчен**
**«Танып белү үсеше» белем бирү өлкәсендә**
**«Серле кыш»**
**темасына эшчәнлек конспекты**

***Нәҗипова Гөлназ Илнур кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*"Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"*

**Максат:** Нейроуеннар ярдәмендә балаларның әйләнә – тирә белән таныштыру буенча белемнәрен формалаштыру.

**Бурычлар:**

**Белем бирү бурычы:** табигатьтәге кышкы үзгәрешләргә игътибар итү, балаларның сенсор сәләтләрен, предметларны тану, аларның төсләрен аеру мөмкинлекләрен ныгыту, күзаллауларын киңәйтү, балаларның кыш билгеләре һәм кышлаучы кошлар турындагы сүзлек запасын баету.

**Үстерү бурычы:** Хәтерне, игътибарны, фикерләүне, вак моториканы, эстетиканы, диологик сөйләмне үстерү, ритмны тою, музыканы ишеткәч төрле хәрәкәтләр ясап музыкага сәләтне һәм күрү-хәрәкәт координацисын үстерү.

**Тәрбия бурычы:** игелеклелек, ярдәм итү теләге, балалар арасында бердәмлек, эшне башкарганда пөхтәлек, табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү.

**Төп белем бирү өлкәсе:** "танып белү үсеше"

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** "иҗтимагый – коммуникатив үсеш", "сөйләм үсеше", "физик үсеш", "сәнгати -эстетик" үсеше.

**Җиһазлар:** Кар кызы уенчыгы,  кошлар рәсеме (песнәк, кызылтүш), сандык, табигать күренеше, җимлек, өстәлләр, җилем- карандаш, тастымал, кар өемнәре, агачлар.

**Алдан үткәрелгән эш:** кыш рәсемнәрен карау, табышмаклар чишү,  уеннар.

**Сүзлек эше:**  кочаклашалар, "Сәлам" бирә**,** Кар кызы, һава торышы, кар бөртекләре, җимлек, песнәк, кызылтүш, кышлаучы кошлар, буран чыга, җил исә.

**Эшчәнлек барышы.**

**I.  Оештыру моменты.**

**Тәрбияче:**  Исәнмесез,балалар! Минем исемем Гөлназ Илнуровна.

**Балалар:** Исәнмесез, Гөлназ Илнуровна.

**Тәрбияче**: Мин дә сезнең исемнәрегезне күрәм. Әйдәгез, матур түгәрәк ясап, кулга –кул тотынышыйк. Мин сезгә тылсымлы кәрзинемне алып килдем.

Ул гади түгел, анда тылсымлы  кар бөртекләре  бар. Хәзер шул кар бөртекләренә  карап, бер-беребезне сәламләп алыйк. Бу кар бөртекләре  нишли?

**Балалар**: Алар кочаклашалар.

**Тәрбияче**: Бик дөрес, хәзер бездә күршеләребезне кочаклыйк. Бер – беребезгә җылылык өстик. Ә монда нишли?

**Балалар**: Алар "Сәлам" бирәләр.

**Тәрбияче**: Бездә сәлам бирик әле.  Менә ничек күңелле булды.

**Тәрбияче**: Балалар, карагыз әле, минем кәрзинем нишли соң? Бер яна, бер сүнә. Туктагыз әле, минем тылсымлы кәрзинем урманга илтте түгелме соң безне? Шулаймы*? (Тылсымлы тавыш иетелә)* Сизмичә дә калдык.

**Балалар**: Әйе.

*(Кар кызы елаган тавыш ишетелә)*

**Тәрбияче:** Чү... тыңлагыз әле, ишетәсезме, кемдер елый бугай? Кем елый икән? (Эзләнәбез) Хәзер тиз генә  карап килим. (тәрбияче  уенчык-Кар кызын таба).

**Тәрбияче:** Ай, бу Кар кызы елый түгелме соң? Балалар, таныдыгызмы?

**Балалар:** Әйе, бу Кар кызы.

**Тәрбияче**: Балалар, чү, Кар Кызы минем колакка гына әйтәм ди, нәрсә булды икән? Тыңлыйм әле.

(Тәрбияче Кар кызын колагына якын китереп, аны тыңлый) Балалар, Кар кызының сезгә бер йомышы бар. Ул урманда сандыгын югалткан. Ярдәм итәбезме?

**Балалар**: Әйе.

**Тәрбияче**: Бигрәк ярдәмчел икәнсез сез, балалар. Әйдәгез урман эченә керик. Урман эченә кергәндә  үзебезне матур тотабыз. Әйдә искә төшереп үтәбез. Бер – беребезне этмибез, кычкырып сөйләшмибез, агач ботакларын сындырмыйбыз, кошларга тимибез һәм миннән ерак китмәгез. Яхшымы, балалар?

**Балалар:** Яхшы!

**Тәрбияче**: Карагыз әле, урман нинди матур! Саф һава! Бөтен җир ап-ак кар.Матурмы? Әйдәгез, кар өемнәренә  бер утырып алыйк.

**Тәрбияче**: Балалар, кыш көне салкын була. Тагын нинди  һава торышы була әле?

**Балалар:** Җилле, буранлы, кар ява. Тагын бер кат кабатлыйк әле.

Агачлар нишли әле, балалар?

**Балалар**: Аларның яфраклары коелып беткән һәм кар бөртекләре кунган.

Әйдәгез, бергә кабатлыйк әле (*Балалар белән бергә кабатлыйлар)*

**Тәрбияче**: Кыш көне сез нишләргә яратасыз?

**Балалар**:  Чанада шуарга, кар бабайлары ясарга, кар атарга.

**Тәрбияче:** Әйдәгез бездә йомры кар белән уйнап алабыз. Йомры  карларны алыйк. Кар нинди , балалар? (Суык, ак төстә). Аны ике кулыгызга алып, минем арттан кабатларсыз. Башта без тупларны ике кулга алып, җирдә сикертәбез.  Шуннан соң, бер кулны өскә күтәрәбез, аннан икенче кулны, соңыннан икесен бергә кул чапкандай сугабыз. Балалар игътибарлы булыгыз!

*Уен "Йомры кар".*

**Тәрбияче:** Менә бит ничек кызык, матур булды. Балалар, сезгә ошадымы?

**Балалар:** Әйе, ошады.

**Тәрбияче**: Ай, балалар, никтер салкын булып китте әле, җил чыкты ахры. Әйдәгез бер җылынып алыйк әле. Сез ризамы?

**Балалар**: Әйе.

**Тәрбияче**: Балалар, басыйк әле, куяннар кебек сикереп алыйк, кулларны бер – берсенә ышкыйбыз. Мин сезгә уен тәкдим итәм. Уен "Бераз җылынып алыйк" дип атала. Иң беренче без сезнең белән кул чабабыз. Аннары тезләрдә кулларны сикертәбез. Аннан соң җилкәләргә сугабыз. Әзерме сез?

**Балалар**: Әйе!

**Тәрбиче:** Алайса башлыйк.

*Ял итү. Музыка астында уен уйнала.*

**Тәрбияче:** Җылындыкмы?

**Балалар:** Әйе, җылындык.

**Тәрбиче**: Балалар, әйдәгез юлны дәвам итик. Игътибар белән карагыз әле, агачларда нәрсәләр күрәсез сез?

**Балалар**: Кошларны күрәбез.

**Тәрбияче:** Кайсы кошлар сезгә таныш?

**Балалар**: Кызылтүш,песнәк.

**Тәрбияче**: Бик дөрес әйтәсез! Болар безнең кышлаучы кошлар. Алар салкын кыш килгәч, безнең туган – ягыбыздан китмиләр, бездә кышлыйлар. Әйдәгез бергә кабатлыйк әле. *("Кышлаучы кошлар" дип кабатлыйлар)* Аларга җим табу авыр. Әйдәгез, без аларга җимлекләргә юл табып күрсәтәбез.

**Тәрбияче**: Яхшы, балалар, шушы тылсымлы юллар аша кошларга җимлеккә төшәргә кирәк. Миңа күрсәтмә бармакларыгызны күрсәтегез әле. Шул бармаклар белән берьюлы җимлеккә төшәргә кирәк.

*Уен "Кышлаучы кошларга җимлеккә юл табарга булыш".*

**Тәрбияче**: Балалар, булдырдыгыз. Әйдәгез алга таба барыйк.

**Тәрбияче**: Менә бит ул сандык. Кар Кызы, без сандыкны таптык. (Кар Кызы сөенә) Балалар, сандыкны ачып карыйк әле. Аның эчендә нәрсә бар соң?

**Балалар**: Анда кошларга җимлек бар!

**Тәрбияче** Бик дөрес. Туктагыз әле балалар, безнең агачта кошлар бик күп бит. Ә монда бары тик 1 генә җимлек. Әйдәгез, бик күп итеп җимлекләр эләбез.

**Тәрбияче:** Иң элек, без бармакларны җылытып алырбыз. Минем арттан кабатлагыз әле:

***Кар бөртеге***

***Кун кулга.***

***Бераз ял ит син шунда.***

***Бер карасаң – боз син.***

***Бер карасаң – йолдыз син!***

Булдырдык. Ә хәзер өстәлләр артына килик. Аркалар төз, аяклар бергә, кулны әлегә яшердек. Иң элек, сезнең өстәлләрегездә матур җимлекләр һәм җилем - карандашлар ята. Балалар, куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерик әле, авызга клей алырга ярыймы? (Юк) Бер – берегезгә комаучауларга ярыймы? (Юк). Бирелгән җимлекләргә кошлар ябыштырык. Без бары тик ак ягына гына клей сылыйбыз да, җимлекләргә ябыштырып куябыз. Эш беткәч, кулларны тастымал белән сөртәбез.

Менә ничек матур килеп чыкты. Афәрин!

**Тәрбияче**: Балалар, әйдәгез, шушы матур җимлекләребезне агачларга элеп куйыйк. Кошлар сезгә рәхмәт әйтер.

**Тәрбияче**: Хәзер инде минем янга түгәрәк ясап басыгыз әле һәм искә төшерик әле, нишләдек без сезнең белән?

**Тәрбияче**: Нинди юллар аша уздык әле без?

**Балалар**: Уеннар уйнадык, кыш турында сөйләштек.

**Тәрбияче**: Кошларга ничек булыштык?

**Балалар**: Җимлекләрне күп итеп элдек.

**Тәрбияче:** Афәрин, балалар, сез мина ошадыгыз, ярдәм иттегез. Рәхмәт сезгә. Кар кызы сезгә бүләкләр дә бирәм ди әле. Сандык төбен карыйк әле. Бу Кар Кызы бүләге. Без бу бүләкләрне төркемебездә ачарбыз. Рәхмәт әйтик әле.

**Балалар:** Рәхмәт, Кар Кызы.

**Тәрбияче**: Кар Кызы, син урманыңда кал инде, безгә кире балалар бакчасына кайтырга кирәк. Сау бул, Кар Кызы.

**Балалар**: Сау бул, Кар Кызы.

**Тәрбияче:** Балалар, мин дә тылсымлы шар бар, шул шарны җир буйлап тәгәрәтеп җибәрәбез дә, ул безне балалар бакчасына кайтарыр. Киттек, әйдәгез.

**“Уйный, уйный, өйрәнәбез...”**

**темасына интеграль шөгыль эшкәртмәсе**

***Йосыпова Гөлсинә Фәүхетдин кызы***

*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы*
*Теләче 2нче балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү*
*муниципаль бюджет учреждениясе*

**Максат:** Балаларның төсләр турындагы белемнәрен тирәнәйтү

**Бурычлар:**

1) балаларны тәрбияче ярдәме белән төсләрне танырга, аерым предметлар турында сөйләргә өйрәтү, бәйләнешле сөйләм булдыру;

2) балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен, күзаллауларын, вак моторикаларын, рәсем ясау, санау күнекмәләрен, иҗади сәләтен үстерү;

3) балаларда төсләр белән кызыксыну теләге тәрбияләү

**Җиһазлау:** ком өстәле, вак предметлар, аудиоязма, курчак, вак уенчыклар, салфетка, чәчәкләр

**Сүзлек эше:** Гөлбикә, кояш нурлары

**Әзерлек эше:** шигырьләр өйрәнү, төсләрне кабатлау

**Эшчәнлек барышы:**

*Төркем бүлмәсендә салмак кына “Туган тел” җыры яңгырый*

**Тәрбияче:** Балалар, безнең бүлмәбездә рәхәт, якты, матур көй яңгырый.Без күрми дә калганбыз, безнең бүлмәбезгә кунаклар килгән икән. Әйдәгез, башта ерактан килгән кунаклар белән исәнләшеп алыйк әле.*(Исәнләшү)* Карагыз әле эскәмиядә моңаеп кына кем утыра икән? *(Татар кызы)* Әйдәгез, алар белән танышыйк, исемнәрен сорыйк.

**Тәрбияче:** Мин Гөлсинә.Ә син кем? *(Гөлбикә)*

*Һәр бала үз исемен әйтеп чыга*

**Тәрбияче:** Балалар, карагыз әле никтер Гөлбикәгә бик күңелсез. Аның кәефен күтәрү өчен нәрсәләр эшләргә була? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Әйдәгез, Гөлбикәнең кәефе яхшырсын өчен нәрсә кирәген табышмак аша табыйк. Тыңлагыз.

**Табышмак:**

Иртә белән чыга, түгәрәк, сары, ул җирне җылыта.

Ул нәрсә? *(Кояш)*

*Балалар белән бергәләп ком өстәлендә кояш ясау*

*Гөлбикәне якынгарак утырту*

**Тәрбияче:** Димәк, Гөлбикәнең кәефен күтәрү өчен кояш кирәк. Кояш чыккач безнең барыбызга да рәхәт, җылы була.Кәефләр күтәрелеп китә.Әйдәгез, бергәләп кояш ясап карыйк.Кояшны нәрсә белән ясап була. *(Балаларның җаваплары)* Ә менә без бүген кояшны комда ясарбыз

*Тәрбияче комда түгәрәк ясый.*

**Тәрбияче:** Балалар мин нәрсә ясадым? *(Түгәрәк)* Ничә түгәрәк? *(Бер.Бармаклар белән күрсәтү)*

**Тәрбияче:** Балалар, кояшның тагын нәрсәләредер җитми? Нәрсәләре икән? *(Кояшның нурлары.Кабатлау.Ныгыту)*

*Балалар белән комда кояшка нурлар ясау*

*Тәрбияче кояшның төсен яндыра*

**Тәрбияче:** Гөлбикәгә һаман күңелсез. Ни өчен икән? Кояшның нурлары бар, ә төсе юк? Әйдәгез кояшка төс кертәбез! Балалар, мин кояшның төсен дөрес яндырдыммы? *(Балаларның җаваплары)* Кояш нинди төстә? *(Сары)*Дөресме?*(Өстәлне яндыру)*

**Тәрбияче:** Ә хәзер, әйдәгез ял итеп алыйк. Гөлбикә дә карап өйрәнеп утырсын.

Кулны-кулга тотынып

Ясыйбыз зур түгәрәк
Алга таба киләбез
Була кечкенә түгәрәк
Артка таба китәбез
Ясыйбыз зур түгәрәк
Бу кояшның – уртасы
Ә без, аның – нурлары
Шатланабыз, көләбез
Һәркемгә нур сибәбез

*Ял итү барышында комга уенчыклар яшерелә*

**Тәрбияче:** Уйнап, ял итеп алдык. Беләсезме балалар, безгә килгән кунаклар сезгә сюрприз ясаганнар. Нинди сюрприз икәнен беләсегез киләме? Безнең сюрпризны кунаклар комга күмеп куйганнар. Әйдәгез ком өстәле янына килеп эзләп карыйк.Нәрсә барлыкка килгән монда? *(Балаларның җаваплары)*

**Тәрбияче:** Шушы биек тауның эчендә безгә дигән сюрприз бар икән. Әйдәгез, актарып карыйк әле. *(Балалар һәрберсе комнан предметлар алалар һәм урындыкларга утыралар)*

**Тәрбияче:** Бу нәрсә?

**Бала:** Бу чыршы.

**Тәрбияче:** Чыршы нинди?

**Бала:** Чыршы яшел (һ.б)

***Уен: "Бу нәрсә?", "Ул нинди?"***

**Тәрбияче:** Балалар, бүген безгә кемнәр кунакка килде, нәрсәләр эшләдек. Гөлбикәнең дә күңеле күтәрелеп китте.Миңа да сезнең белән бик күңелле. Мин кояшның уртасы, ә сез аның нурлары. Һәркемгә шатлык һәм җылы чәчеп яшик. Әйдәгез үзебезне мактап кул чабабыз!

**"Күчтәнәчтә кунакта"**

*(Уртанчылар төркеме өчен эшчәнлек эшкәртмәсе)*

***Камалиева Гөлназ Рәис кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*"Арча 1 нче балалар бакчасы" муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

**Максат:** балаларны, тәҗрибәләренә таянып, тәрбияче тәкъдим иткән темага сөйләргә өйрәтү; урман җәнлекләре лексикасын кабатлау, балаларда уңай эмоциональ хәләт булдыру, яхшы эшләр эшләп, бер-берсенә ярдәмләшү кебек уңай сыйфатлар тәрбияләү.

**Җиһазлау:** уенчык төлке, песи, эт; тылсымлы сандык, ширма, төсле яулыклар, урман җәнлекләре рәсемнәре, йомгак.

**Эшчәнлек барышы**

**1. Оештыру. Кызыксындыру этабы.**

Тәрбияче: - Исәнмесез, балалар, хәерле көн! Әйдәгез әле, дусларыгызны сәламләп алыгыз әле!

Балалар: Исәнмесез!

Тәрбияче: Балалар, карагыз әле, безгә кунакка кемнәрдер килгән. Песи белән эт икән бит алар. Балалар, әйдәгез тыңлыйк әле аларны. Алар безгә нәрсәдер әйтергә телиләр бугай.

Йомшаккай: - Исәнмесез, дусларым! Без күчтәнәч тапшыруыннан Йомшаккай белән Акбай. Без кая килеп чыктык соң?

Нинди җир бу?

Тәрбияче: Балалар, Йомшаккай белән Акбай кая килгәннәр? (бакчага)

Тәрбияче: Исәнмесез, ни булды сезгә?

Акбай: Балалар, без бит әбине югалттык! Нишлибез инде хәзер?

Тәрбияче: Ничек югалттыгыз инде сез аны?

Йомшккай: Без әби белән урманга җиләк җыярга барган идек. Җиләк җыя-җыя әбидән аерылып киткәнбез, аннары күпме эзләдек, әмма таба алмадык.

Тәрбияче: Ай-һай, бер дә әйбәт булмаган әле бу

**2. Төп этап.**

**2.1.Проблема кую этабы.**

Тәрбияче: Йомшаккай, Акбай нишлибез инде хәзер? Бәлки бездә генә калырсыз! Балалар безнең бакчабыз нинди? Йомшккай белән Акбайга әйтеп күрсәтик әле! (якты, зур, матур, җылы)

Йомшаккай: Юк балалар, безгә әбине эзләп табарга кирәк!

Айбай: Әйе, табарга кирәк, Әби борчылып беткәндер инде!

Йомшаккай: Безнең бит “Күчтәнәч” тапшыруын алып барасыбыз бар! Әби бездән башка нишләр?

Акбай: Балалар, безгә юлны табарга булышыгыз әле, зинһар өчен!

Тәрбияче: Балалар, булышабызмы Йомшаккай белән Акбайга? (әйе, булышабыз)

Тәрбияче: балалар, Йомшаккай белән Акбай урманда югалганнар, әйдәгез без дә юлны шунда тотыйк әле. Аларны да үзебез белән алыйк. Бер-бер артлы тезелешеп утырыйк та, юлга кузгалыйк.

Барабыз,барабыз

Без урманга барабыз.

Иелеп тә алабыз,

Йөгереп тә барабыз.

**2.2. Материал белән таныштыру этабы.**

Уен ситуациясе. Тәрбияче балаларның игътибарын ширмага юнәлтә.

(Ширмада төлке балаларга эндәшә).

Төлке: – Исәнмесез, балалар! Кая болай юл тоттыгыз?

Тәрбияче: - Төлкебикә, без әбине югалттык, син күрмәдеңме аны?

Тәрбияче: - Нишләп күрмәскә, күрдем? Сезгә юлын да күрсәтә алам хәтта!

Тәрбияче: - Ничек әйбәт булды имә, балалар!

Төлке: - ләкин мин сезгә юлны болай гына күрсәтмим! Аның өчен минем биремнәремне үтәргә кирәк!

Тәрбияче: - Балалар, төлке әйткән биремнәрне үтибезме?

Төлке: Балалар, менә карагыз әле, минем тылсымлы сандыгым бар. Аның эчендә биремнәр. Әгәр биремнәрне үти алсагыз, мин сезгә юлны күрсәтәм. (Сандык ачыла)

1 нче бирем.

Төлке: - Минем урманда якын дусларым бар! Нәрсәләр икән ул, табышмаклардан белерсез!

Тәрбияче: - Өрә белми, улый белә,
Башын чөеп югары.
Урман эчендә яши ул,
Этнең ерак туганы. (бүре)

Тәрбияче: Балалар, бүр ничек улый әле ул?

Тәрбияче: Урмандагы өнендә
Кышны йоклап уздыра.
Бал ашыйсы килсә әгәр,
Умартаны туздыра. (Аю)

Хәзер менә бу рәсемнәр арасыннан аю нәрсә ярата, шуны сайлап алырга кирәк!

Кыска гына койрыгы бар,
Колаклары бик озын.
Соры тунын кияр өчен,
Ак тунын сала кышын. (куян)

Балалар, куян ничек сикерә?

Төлке: булдырдыгыз, балалар, икенче биремемне тыңлагыз!

Мин бизәнергә, ясанырга яратам, яулыкларым да бик күп. Ләкин алар буташып беткәннәр. Миңа шуларның парларын табырга булышыгыз әле!

“Парлы яулыклар” уены. (музыка уйнаганда балалар түгәрәккә басып биеп йөриләр, музыка туктагач, яулыклар алып, парлашып бииләр)

Төлке: 3 нче бирем менә бу капчык эчендә.

Тәрбияче: Балалар, капчык эчендә әкиятләрдән әйберләр төшеп калган! Әйдәгез карыйк әле! (түгәрәк ипи, теремкәй, итекләр)

“Болар кайсы әкиятләрдән?” уен күнегүе.

**2.3. Проблеманы практик чишү этабы.**

Тәрбияче: Төлке дус, без синең биремнәреңне үтәп бетердек, син безгә юлны күрсәтәсеңме инде?

Төлке: - Менә сезгә серле йомгак, шуның артыннан барсагыз, әбигә юлны табарсыз.Сез бик булган, дус, тату балалар икәнсез! Гел шундый булып калыгыз!

Тәрбияче: Әйдәгез, балалар, йомгакны тәгәрәтик әле! Тәгәри китте йомгагым!(Балалар бер-берсенә йомгакны биреп җибәрәләр, йомгак тәгәрәп китә, ишектән әби чыга).

Әби: и, менә кая икән бит минем Йомшаккаем, Акбаем! Монда тагын күпме бала да бар икән бит әле.

Тәрбияче: әби, менә балалар Йомшаккай белән Акбайга сине табарга булыштылар. Төлке әйткән биремнәрне үтәп чыктылар.

Әби: рәхмәт инде, балалар!

**3. Йомгаклау этабы.**

Тәрбияче: - Балалар, сезгә бүгенге эшчәнлек ошадымы?

Балалар: - Әйе, бик ошады!

Тәрбияче: - Иң ошаганы нәрсә булды?

Балалар: -.

Тәрбияче: - Без бүген нинди файдалы эш башкардык?

Балалар: - Йомшаккай белән Акбайга булыштык.

Тәрбияче: - Балалар, хәзер басыгыз һәм бер-берегезнең кулын тотып, елмаеп, “Син минем якын дустым” диеп әйтегез әле.

Балалар: - Син минем якын дустым.

Тәрбияче: - Шуның белән эшчәнлек тәмам, ә сезгә мин ярдәмләшеп гел бердәм булып яшәвегезне телим, сау булыгыз.

Балалар: - Сау булыгыз!

**Җиңү көтә бүген, сабыйлар.**

**(балалар бакчасында 5-6 яшьлек балалар белән әңгәмә)**

***Мингазова Миләүшә Билсур кызы***
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*«Салавыч балалар бакчасы» муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе.*

**Максат:** Балаларны Җиңү бәйрәменең асылына төшендерү, аларда Ватанга карата хөрмәт рухы тудыру, "Җиңү көтә бүген сабыйлар" шигырен мәгънәсенә төшенеп тыңларга өйрәнү, сәнгатьле итеп сөйләүне ныгыту. Балаларда патриотик хисләр, Бөек Ватан сугышы ветераннарын олылау, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар:**

• Бабамның аяусыз көрәше өчен бирелгән орден-медальләрен барлау;
• Туган җиребезгә, илебезгә карата мәхәббәт хисләрен чагылдыру;
• Аның асыл сыйфатлары аша өлкән буын кешеләренә карата хөрмәт, алар белән горурлану хисләрен белдерү;
• Тәрбияче иҗат иткән шигырьне тәрбияләнүчеләр күңеленә дә җиткерү.

**Кереш өлеш**

1.Җиңү көтә сабыйлар шигырен сәнгатле итеп уку, балаларга шигырьнең мәгънәсен аңлату.

**Төп өлеш**

1.Бабамның аяусыз көрәше өчен бирелгән орден-медальләрен барлау, аларны балаларга күрсәтү. Нәрсә өчен бирелүләрен аңлату.

2. Авылыбызның сугышчан батырлары белән таныштыру.

3. Батырларга символик бүләк әзерләү.

4.Канәфер чәчәге, георгий тасмасы, мәңгелек ут төшенчәләре белән таныштыруны ныгыту.

5. Мәңгелек утка чәчәкләр кую.

**Йомгаклау өлеше.**

1.Кемнәр алар батырлар?

2.Кемнәр көтә җиңүне?

3.Батырларның батырлыгы турында каян белдек?

**Җиңү көтә бүген сабыйлар.**

Буыннарны тарих бәйли диләр,

Уйлап баксаң, бар да хак сүзләр.

Кайсы чорда, кайчан ни булганын

Без эзләми аны кем эзләр?..

Нәни балалар да әтиләрен

Озата бүген сугыш кырына.

Сагынудан шушы сабыйларның

Йөрәкләре әрни, кырыла.

Балакайлар әле аңламыйлар

Әтиләре герой икәнен.

Илдә тынычлыкны саклар өчен

Яу кырына чыгып киткәнен.

45нең оныклары бүген

Кабат изге яуда, көрәштә

Сабыйларның тыныч көне өчен

Үзен аямыйча көрәшә.

Ил сакчысын халык данга төргән,

Зурлаганнар Җиңү көнендә.

Чираттагы зур Җиңүне көтә

Дүрт күз белән халык бүген дә!

# ДИДАКТИК УЕННАР



## Дидактик уен «Минем миллəтем»

***Зиннəтова Айсылу Гаптелнур кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*«Үрнəк балалар бакчасы» муниципаль бюджет*
*мəктəпкəчə белем бирү учреждениесе тəрбиячесе*

| | |
|---|---|
| Уенның авторы | Зиннəтова Айсылу Гаптелнур кызы |
| Балалар бакчасының исеме | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Үрнəк балалар бакчасы» МБМББУ |
| Уенның исеме | “Минем миллəтем” |
| Уенның максаты | Туган илгə, милли йолаларыбызга, халык уеннарына карата кызыксыну һəм мəхəббəт хислəре тəрбиялəү. |
| Уенның нигезе | Ике төрле зурлыктагы фанердан киселгəн түгəрəклəр, ук, ламинатланган рəсемнəр, карточкалар, фотографиялəр. |
| Ничə яшьтəн уйнап була | 4-7 яшьлек балалар өчен. |
| Уйнау вариантлары<br><br> | Уен сигез өлештəн тора. Уенны ике телдə уйнап була.Уен санамыш ярдəмендə башланып китə. Бала укны əйлəндереп җибəрə. Ук кечкенə түгəрəкнең кайсы карточкасына чыга, бала шуңа туры килгəн карточкаларны таба, таныштырып үтə. Һəр яңа бүлек башланыр алдыннан шулай ук санамыш яки табышмакка җавап бирəлəр (уен шулай дəвам итə).<br>1. Сабантуй (сабантуй уеннары ясалган карточкаларны табу, уеннарның эчтəлеген сөйлəү)<br>2. Өстəл ( татар халкының милли ризыкларын табып кую, аларны тасвирлап бирү)<br>3. Татар киеме кигəн кыз ( төрле миллəт киемнəре арасыннан курчакны татар халык киемнəрен киертү)<br>4. Əкиятлəр илендə (татар халык əкиятлəре геройлары кергəн карточкаларны табу, кыскача эчтəлеген сөйлəү) |

| | |
|---|---|
| | 5. Татар киеме кигән малай<br>(төрле милләт киемнәре арасыннан курчакны татар халык киемнәрен киендерү)<br>6. Китап тоткан малай ( татар балалар язучыларын табу, исемнәрен әйтү)<br>7. Күңелле ноталар (татар халык уен коралларын табу, исемнәрен әйтү)<br>8. Бизәлгән алъяпкыч (алъяпкычны табу, татар халкының милли бизәкләре белән бизәү, бизәкләрнең исемнәрен әйтү) |

## Габдулла Тукай әсәрләре буенча уен-йөреш

***Хөснуллина Миләүшә Әдеһәм  кызы***

*Саба 6 нчы номерлы "Балачак"*
*балалар бакчасы тәрбиячесе*

| | |
|---|---|
| Уенның авторы | Хөснуллина Миләүшә Әдеһәм  кызы |
| Уенның исеме | Габдулла Тукай әсәрләре буенча уен-йөреш |
| Яшь үзенчәлеге | 3 яшьтән 7 яшькә кадәр |
| Максат | Балаларның танылган татар язучысы Габдулла Тукай әсәрләре турындагы белемнәрен актуальләштерү һәм тулыландыру; элек алган белемнәрен практикада куллану өчен шартлар тудыру. |
| Бурычлар:<br>- дидактик<br>(белем бирү, уен- үстерү<br>- тәрбия | -балаларның Г. Тукай иҗаты, аның әсәрләре турында белемнәрен ныгыту һәм гомумиләштерү, автор әсәрләрен һәм аларның төп геройларын атау осталыгын ныгыту, балаларның күзаллауларын киңәйтү;<br>- балаларның әкият геройлары турында, әкият предметлары турында белемнәрен гомумиләштерү;<br>- балаларны актив танып-белү эшчәнлегенә җәлеп итү;<br>- сәнгать әдәбиятына, Г. Тукай әсәрләренә карата кызыксынуны үстереү һәм саклау; |

| | |
|---|---|
| | - бәйле сөйләм, игътибарлылык үсешенә ярдәм итү;<br>- балаларның иҗади сәләтләрен үстерү;<br>- зирәклекне, тапкырлыкны, сабырлыкны үстерү;<br>- иптәшлелек һәм үзара ярдәмләшү хисе тәрбияләү;<br>- әкиятләргә мәхәббәт тәрбияләү, әсәрләрнең образлы эчтәлеген эмоциональ рәвештә кабул итә белү. |
| Уен атрибутлары | Уен кыры, йөрешләр санын билгеләү өчен кубик, төрле төстәге дүрт фишка, тиешле фигуралы һәм төсле конвертларга салынган биремле карточкалар. |
| Уен кагыйдәләре | Уенда дүрт кеше катнаша ала. Һәркем үзенә бер төстәге фишканы сайлый. Фишкаларны старт түгәрәгенә куялар. Балалар чират буенча кубикны тәгәрәтеп җибәрәләр һәм фигураларны кубикта төшкән очколарга карап, шул санга кадәр алга таба хәрәкәт итәләр. Беренче булып очколары күбрәк булган кеше йөри. Уенчы кызыл һәм сары түгәрәктә, квадратта яки өчпочмакта туктала, аларның һәркайсына шул ук төстәге фигуралы конвертта бирем туры килә. Ул тиешле фигуралы конвертны сайлый һәм биремне үти. Әгәр уенчы биремне үти алмаса, бер йөрешне уздырып җибәрә. Беренче булып финишка кадәр килеп җиткән кеше җиңә. |

**«Гаиләм хәзинәсе» дидактик өстәл уены**

***Сабирова Ләйсән Наил кызы,***
***Сабирова Резедә Әгъзәм кызы***
*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының*
*«Васильев Божа балалар бакчасы» муниципаль бюджет*
*мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе тәрбиячеләре*

«Гаиләм хәзинәсе» дидактик уены мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән балалар бакчасында оештырылган белем бирү эшчәнлеге яки индивидуаль эш вакытында, балаларны төркемнәргә бүлеп эшләгәндә һәм шулай ук иректе эшчәнлектә кулланырга тәкъдим итəлергә мөмкин. Уенның аерым өлешләре мөстәкыйль дидактик уеннар шикелле кулланырга, балаларның яшь

үзенчәлегеннән чыгып төрләндерергә һәм тулыландырырга мөмкин. Уен татар телендә алып барыла.



Бу уенны балалар бакчалары тәрбиячеләре, башлангыч мәктәп укытучылары һәм шулай ук ата-аналар өй шартларында уйнау өчен дә куллана ала.

**Уенның актуальлеге:** Без яшәгән заман - тирән үзгәрешләр һәм үзгәртеп корулар чорына туры килә. Заманнан артка калмас өчен мәктәпләрдә һәм балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирү эшен ФГОС һәм ФББП таләпләренә туры килерлек итеп, балаларны сәләтле , белемле, тәртипле итеп тәрбияләүгә зур игътибар сорала. Бүгенге көндә балаларда гражданлык һәм әхлакый ориентирлар формалаштыруга, гаилә кыйммәтләренә, тарихына, туган телебезгә, милләтебезгә һәм аның гореф-гадәтләренә, йолаларына кызыксыну уяту һәм мәхәббәт тәрбияләү - иң мөһим бурычларның берсе. Бала җәмгыятьтә үзен чын кеше итеп тойсын өчен, аңарда иң беренче итеп гаиләсенә, туган нигезенә, туган теленә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт һәм ихтирам, туганнары өчен горурлык хисен тәрбияләү, буыннар чылбырын өзмәү һәм дәвам итү тәрбиячеләрнең төп вазифаларының берсе.

**Уенның максаты:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гаилә турында күзаллауларын киңәйтү, гаилә кыйммәтләре, татар халкының тарихы, мәдәнияты, гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре аша әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү, гаилә әгъзаларына карата ихтирамлы мөнәсәбәт, мәхәббәт, горурлык хисе булдыру, буыннар элемтәсен ныгыту.

**Уенның бурычлары:**

Тәрбияләүче: балаларда гаилә кыйммәтләренә һәм татар халкының мәдәниятына, традицияләренә, тарихына карата җылы караш тәрбияләү; коллективта эшли белүне (өлкәннәр һәм яшьтәшләр белән диалог алып бару; үз карашыңны яклау; җавап бирү; сорауларны дөрес аңлата белү; үз омтылышыңны башкалар мәнфәгатьләренә яраклаштыру; иптәшеңне тыңлау һәм уртак карарга килә белү) тәрбияләү.

Үстерүчән: тәрбияләнүчеләрдә яңа сыйфатлар һәм белемнәрне мөстәкыйль рәвештә үзләштерергә һәм алган белемнәрне реаль тормышта кулланырга (мөстәкыйль, нәтиҗәле, уен эшчәнлегендә) өйрәтү; балаларның татар телендә сүзлек запасын баету һәм тулыландыру; бәйләнешле сөйләмен үстерүгә ярдәм итү; танып-белү, иҗади сәләтен, карашын, логик фикерләвен, хәтерен, кызыксынучанлыгын, күзәтүчәнлеген, вак моториканы һәм күрү-мотор

координациясен, аналитик белемнәрне (классификацияләү, анализлау, проблеманы хәл итүгә үз карашын тәкъдим итү) үстерү; балаларның күзаллауларын киңәйтү.

Белем бирүче: балаларда гаилә һәм аның көнкүреше турында белемнәрен формалаштыру; функциональ билгеләнештәге предметларны классификацияли белү күнекмәләрен булдыру; татар халкының мәдәниятенә, гаилә кыйммәтләренә, гореф-гадәтләренә балаларны җәлеп итү.

**Уенда катнашучылар:** мәктәпкәчә яшьтәге балалар, тәрбияче/ата-ана.

**Уйнаучылыр яше:** мәктәпкәчә өлкән яшьтәге балалар.

**Уен әсбаплары:** сандык, биремнәр салынган конвертлар, әкият чемоданы, уен шакмагы, фишкалар.

**Уен барышы:**

Уенда бер яки берничә бала катнаша ала. Уен чиратын балаларга санамыш ярдәмендә билгеләргә тәкъдим ителә. Беренче булып чыккан бала уен шакмагын ыргыта. Төшкән сан бирем өлкәсенең санын билгели. Бала шул өлкә биремнәре арасыннан берсен сайлап ала һәм шуны үти. Җавап дөрес булса, уенчыга фишка бирелә, ялгыш булса, башка балаларга җавап бирү мөмкинлеге ачыла һәм фишканы дөрес җавап биргән бала ала. Чираттагы бала шакмакны ыргытып, уенны дәвам итә. Уен биремнәр беткәнче дәвам итәргә яки балалар теләге белән тәмамланырга мөмкин. Иң күп фишкалар җыйган бала җиңүче дип табыла.

Сандыкның йозагын ачып, уенны башлап җибәрер өчен балаларга табышмак әйтелә яки бармак уены уйнарга тәкъдим ителә.

Табышмак:

Аяксыз, кулсыз өй саклый. (Йозак)

Бармак уены:

Йозак тора ишектә,

ачып булмый ничек тә.

суккалыйбыз, боргалыйбыз,

тарткалыйбыз, йозакны ачабыз.

**Уенның төрләнеше:**

«Минем гаиләм – минем байлыгым» бүлеге

«Минем гаиләм» дидактик уены

«Бу кем? Бу нәрсә? » дидактик уены

«Тылсымлы гаилә чәчәге» дидактик уены

«Гаилә» бармак уены

«Гаиләдә без җидәү» пазл-дидактик уены

Тематик рәсемнәр

Гаилә турында мәкальләр, табышмаклар, җырлар, шигырьләр

Буягычлар

**«Әбиемнең серле сандыгы» бүлеге**

«Курчакны милли киемгә киендер»;

«Милли кием сурәтләнгән рәсемне җый»;

«Кием өлешләрен ата»;

«Киемне милли бизәк белән бизә»;

«Бизәкне әйт» дидактик уены;

«Парын тап» (домино) дидактик уены;

«Бизәкне төзе» дидактик уены;

«Үзең бизә» дидактик уены;

«Таны һәм әйт» дидактик уены;

«Буягычлар».

**«Әниемнең тәмле ашлары» бүлеге**

«Нәрсә артык?»;

«Милли ризык сурәтләнгән рәсемне җый»;

«Татар халкының милли ашлары»;

«Татар халкының милли ризыгын тап»;

«Яшь пешекчеләр».

**<u>«Әтием моңнары» бүлеге</u>**

«Милли музыкаль инструментны танып бел» дидактик уены;

«Музыкаль инструментының рәсемен җый» дидактик уены;

«Милли музыкаль инструментны буя»  дидактик уены;

Балалар җырлары, җырлы-биюле уеннар өчен көйләр тупланган CD диск.

**<u>«Шаян телле бабаем» бүлеге</u>**

«Мәкальне тап» дидактик уены;

«Милли халык бәйрәмнәре»;

«Җырлый-җырлый уйныйбыз»;

«Тизәйткечләр»;

«Бармак уеннары»;

«Табышмаклар».

**<u>«Әбием әкиятләре дөньясында» бүлеге</u>**

«Рәсем буенча әкиятне тап» дидактик уены;

«Рәсем буенча әкиятне сөйлә» дидактик уены;

«Әкият сурәтләнгән рәсемне җый» дидактик уены;

«Өстәл театры»;

«Буягычлар».

**Көтелгән нәтиҗә:** мәктәпкәчә яшьтәге балалар татар халкының яшәү һәм көнкүреше белән таныш, бер-берсенең фикерен ихтирам итеп коллективта эшлиләр; үз фикерләрен аңлаешлы һәм дөрес итеп җиткерә беләләр.

**Бирем төрләре**

**<u>Минем гаиләм – минем байлыгым</u>**

***«Минем гаиләм» дидактик уены***

Максат: гаилә әгъзаларына туры килгән предмет рәсемнәрен, кем нишли? соравына җавап булган пиктограммаларны, кем нәрсә ярата? соравына ашамлыкларны дөрес итеп үз урыннарына урнаштыру, балаларның логик фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру, күзаллауларын киңәйтү.

***«Бу кем? Бу нәрсә? » дидактик уены***

Максат: гаилә әгъзаларының, ашамлыкларның, уенчыкларның исемнәрен хәтердә калдыру, фикерләү сәләтен үстерү, игътибарларын арттыру.

Уен кагыйдәләре: Уенда берничә бала катнаша ала. Балаларга буш карточкалар бирелә. Уенчылар рәсемнәр белән буш карточкаларны тутырырга тиешләр.Алып баручы рәсемне күрсәтә, балалар карточкадагы рәсемне атыйлар һәм үзләренең карточкасындагы буш урынга куялар. Кемнең карточкасы тизрәк тула, шул җиңүче була.

***«Тылсымлы гаилә чәчәге» дидактик уены***

Максат: балаларда гаиләгә һәм аның әгъзаларына карата мәхәббәт һәм ихтирам хисен тәрбияләү, сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру, күзаллауларын киңәйтү.

Уен кагыйдәләре: уенчыга гаиләдә тәрбияләнергә тиешле сыйфатларны атарга һәм чәчәк таҗларын җыярга тәкъдим ителә.

***«Гаилә» бармак уены***

Максат: бармак уеннары белән таныштыру, балаларның шигырь эчтәлегенә туры китереп бармаклар белән хәрәкәт итү күнекмәрәлен формалаштыру; уен сүзләрен дөрес әйтеп, мөстәкыйль рәвештә сөйләүгә омтылыш булдыру, сөйләм телен арттыру.


Бу бармак бабай,

Бу бармак әби,

Бу бармак әти,

Бу бармак әни,

Бу бармак бәби,



Аның исеме чәнти.

Бу бармак бабай,

Бу бармак әби,

Бу бармак әти,

Бу бармак әни,

Бу бармак малай (кыз).

***Бармак уены “Бергәләп уйныйбыз”***

(Исәнме, бармак, Хәерле көн, кич, иртә)



Исәнме, бабай.

Исәнме, әби.

Исәнме, әти.

Исәнме, әни.

Исәнме, малай (кыз).

***«Гаиләдә без җидәү» пазл-дидактик уены***

Максат: гаилә әгъзаларының исемнәрен истә калдыру, аларны дөрес итеп атау, рәсемне кечкенә кисәкләрдән җыю күнекмәсен ныгыту, балаларның фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру, күзаллауларын киңәйтү.

Уен кагыйдәләре: уенчыга гаилә рәсеме төшерелгән рәсемне кечкенә кисәкләрдән җыярга тәкъдим ителә.

***Гаилә турында мәкальләр.***

Максат: Балаларны мәкальләр белән таныштыру, аларның мәгънәсен аңларга өйрәтү.

Уен кагыйдәләре: Бала тәрбияче артыннан мәкальне кабатлый, истә калдыра.

***Гаилә турында табышмаклар***

Максат: гаилә әгъзалары турында табышмаклар белән таныштыру; сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен үстерү.

***Гаилә турында җырлар***

Максат: гаилә әгъзалары турында җырлар белән таныштыру; аларның сүзләрен өйрәнү, бәйрәмнәрдә куллану, сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен үстерү.

***Гаилә турында шигырьләр***

Максат: гаилә, гаилә әгъзалары, гаилә кыйммәтләре турында шигырьләр белән таныштыру; сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен үстерү.

***Тематик рәсемнәр***

***Буягычлар***

**<u>Әбиемнең серле сандыгы</u>**

***«Курчакны милли киемгә киендер» дидактик уены***

Максат: балаларда милли киемгә карата кызыксыну уяту. Милли кием һәм аларның элементлары турында белемнәрен ныгыту.

Уенның кагыйдәләре: уенчылар киселгән кәгазь курчакларны алалар һәм шуларга туры килердәй костюмны сайлап “киендерәләр”. Костюмның бизәлеше, үрнәкләре, төсе турында сөйлиләр.

***«Киемне милли бизәк белән бизә» дидактик уены.***

Максат: балаларга милли орнаментны төзергә өйрәтү.

Уен кагыйдәләре: алып баручы балаларга киемне үзләре теләгәнчә татар милли бизәге белән бизәргә тәкъдим итә.

***«Милли кием сурәтләнгән рәсемне җый» дидактик уены***

Максат: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны рәсемнең өлешләрен чагыштырырга, өлешләрнең төсенә, формасына карап, дөрес итеп бер-берсенә ялгап, бербөтен рәсем җыярга өйрәтү, балаларның татар халыкларының милли киемнәре турында белемнәрен арттыру.

Уен кагыйдәләре: балалар алдында өстәлдә рәсемнең киселгән өлешләре ята. Тәрбияче аларга игътибар белән карага һәм бербөтен рәсем җыярга тәкдим итә. Башлангыч этапта балаларга өлешләрне бербөтен рәсем өстенә җыярга да тәкъдим итәргә була.

***«Кием өлешләрен ата» дидактик уены***

Максат: балаларның татар халыкларының милли киемнәре турында белемнәрен арттыру, кием өлешләрен атау күнекмәләрен булдыру.

Уен кагыйдәләре: балалар рәсемгә карап татар халкының милли киемнәренең исемнәрен атый.

***«Бизәкне әйт» дидактик уены***

Максат: балаларда аерым элементлардан татар милли бизәген төзү күнекмәләрен булдыру.

***«Парын тап» (домино) дидактик уены***

Максат: балаларны бертөсле рәсемнәрне табып, аларны бер чылбырга җыярга өйрәтү. Татар орнаментының бизәкләрен дөрес итеп атау күнекмәләрен булдыру.

***«Бизәкне төзе» дидактик уены***

Максат: балаларда аерым элементлардан татар бизәген тәзү күнекмәләрен булдыру.

***«Үзең бизә» дидактик уены***

Максат:балаларда татар милли орнамент элементларын танып дәрес итеп атау, киемнәрне, савыт-сабаларны үз зәвыклары белән бизәү күнекмәләрен булдыру.

***«Таны һәм әйт» дидактик уены***

Максат: балаларда татар милли орнамент элементларын танып дөрес итеп атау күнекмәләрен булдыру. Сүз байлыгын арттыру.

**Әниемнең тәмле ашлары**

***«Нәрсә артык?» дидактик уены***

Максат: балаларда фикерләүне, игътибарлыкны, предметларны аерым билгеләр буенча классификацияли, гомумиләштерү белүне үстерү.

Уен кагыйдәләре: балаларга рәсемнәрдә сурәтләнгән милли ризыкларны карарга һәм артыгын табарга тәкъдим ителә.

***«Милли ризык сурәтләнгән рәсемне җый» дидактик уены***

Максат: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны рәсемнең өлешләрен чагыштырырга, өлешләрнең төсенә, формасына карап, дөрес итеп бер-берсенә ялгап, бербөтен рәсем җыярга өйрәтү, балаларның татар халкының милли ризыклары турында белемнәрен арттыру.

Уен кагыйдәләре: балалар алдында өстәлдә рәсемнең киселгән өлешләре ята. Тәрбияче аларга игътибар белән карага һәм бербөтен рәсем җыярга тәкдим итә. Башлангыч этапта балаларга өлешләрне бербөтен рәсем өстенә җыярга да тәкъдим итәргә була.

***«Татар халкының милли ризыгын тап» дидактик уены***

Максат: балаларда татар халкының традицион милли ашлары турында күзаллау булдыру, милли ризыкларны тышкы кыяфәте буенча аера белү сәләтен үстерү, балаларда татар халкының гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияләү.

Уен кагыйдәләре: алып баручы балаларга татар халкының билгеле бер милли ризыгы төшерелгән карточканы табарга тәкъдим итә.

***«Яшь пешекчеләр» дидактик уены***

Максат: балаларның пешекче эше турында күзаллауларын киңәйтү, бу һөнәр ияләренә хөрмәт тәрбияләү, “өчпочмак” һәм “токмачлы аш” кебек милли ашларның ингредиентлары турында белемнәрен ныгыту.

Уен кагыйдәләре: балаларга татар халкының милли ризыгы «өчпочмак» һәм рус милли ризыгы «токмачлы аш» әзерләү өчен кирәкле ингредиентларны бүләргә тәкъдим ителә.

**<u>Әтием моңнары</u>**

***«Милли музыкаль инструментны танып бел» дидактик уены***

Максат: татар халкы, аларның гореф-гадәтләре, орнаменты, көнкүреше белән таныштыру. Балаларның игътибарын, хәтерен үстерү.

Уен кагыйдәләре: балага милли музыка уен кораллары сурәтләнгән карточкалар арасыннан билгеле берсен сайларга һәм аның яңгыравын тыңларга тәкъдим ителә.

***«Музыкаль инструментның рәсемен җый» дидактик уены***

Максат: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны рәсемнең өлешләрен чагыштырырга, өлешләрнең төсенә, формасына карап, дөрес итеп бер-берсенә ялгап, бербөтен рәсем җыярга өйрәтү, балаларның татар халкының милли ризыклары турында белемнәрен арттыру.

Уен кагыйдәләре: балалар алдында өстәлдә рәсемнең киселгән өлешләре ята. Тәрбияче аларга игътибар белән карага һәм бербөтен рәсем җыярга тәкъдим итә. Башлангыч этапта балаларга өлешләрне бербөтен рәсем өстенә җыярга да тәкъдим итәргә була.

***«Милли музыкаль инструментны буя»  дидактик уены***

Максат: рәсем буяу аркылы музыкаль инструменлар белән танышу, татар халык иҗатына мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Шаян телле бабаем**

***«Мәкальне тап» дидактик уены***

Максат: балаларны мәкальләр белән таныштыру, аларның мәгънәсен аңларга өйрәтү.

Уен кагыйдәләре: Бала рәсемгә карап мәкальне  танып әйтергә тиеш.

1. Җиде кат үлчә, бер кат кис.

2.  Китап – белем чишмәсе.

3. Эш беткәч, уйнарга ярый.

4. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.

5. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.

6. Ни чәчсәң, шуны урырсың.

***«Милли халык бәйрәмнәре»***

Максат: балаларда татар халкының милли  бәйрәмнәре турында белемнәрен арттыру, күзаллауларын киңәйтү.

***«Җырлый-җырлый уйныйбыз»***

Максат**:** татар халык уеннарын төрле чараларда кулланып балаларның

аралашу тирәлеген киңәйтү, милләтебезгә хас сыйфатлар тәрбияләү, милли

үзаң уяту.

Уен барышы: карточкада язылган уенның кагыйдәләрен укып балалар белән уйнарга тәкъдим итү.

***«Тизәйткечләр»***

**Максат:** артикуляцион гимнастикалар, тел төзәткечләр, тизәйткечләр кулланып балаларның сөйләм телен камилләштерү.

***«Бармак уеннары»***

**Максат:** халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру һәм аларга карата мәхәббәт хисе тәрбияләү; балаларның шигырь эчтәлегенә туры китереп бармаклар белән хәрәкәт итү күнекмәрәлен формалаштыру; уен сүзләрен дөрес әйтеп, мөстәкыль рәвештә сөйләүгә омтылыш булдыру, сөйләм телен арттыру.

***«Табышмаклар»***

**Максат:** халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыру һәм аларга карата мәхәббәт хисе тәрбияләү; сөйләм телен һәм фикерләү сәләтен үстерү.

**<u>Әбием әкиятләре дөньясында</u>**

***«Рәсем буенча әкиятне тап» дидактик уены.***

Максат: игътибарны, сөйләм телен, фикерләү сәләтен, хәтерне үстерү, рәсем буенча әкиятне танып-белүне булдыру.

Уен кагыйдәләре: алып баручы таныш әкиятләргә рәсемнәрне иллюстрацияле ягы белән аска таба каплап сала. Бала аларның берсен күтәрә һәм әкиятнең исемен атый яки аның өзеген сөйли.

***«Рәсем буенча әкиятне сөйлә» дидактик уены.***

Максат: игътибарны арттыру, сөйләм телен, фикерләү сәләтен, хәтерне үстерү, рәсем буенча әкиятне танып-белүне булдыру.

Уен кагыйдәләре: алып баручы таныш әкиятләргә рәсемнәр чылбырын күрсәтә. Бала аларны дөрес итеп төзеп әкиятнең исемен атый һәм сөйли.(берничә бала дәвам итеп сөйли ала)

***«Әкият сурәтләнгән рәсемне җый» дидактик уены***

Максат: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны рәсемнең өлешләрен чагыштырырга, өлешләрнең төсенә, формасына карап, дөрес итеп бер-берсенә ялгап, бербөтен рәсем җыярга өйрәтү, балаларның татар халкының милли ризыклары турында белемнәрен арттыру.

Уен кагыйдәләре: балалар алдында өстәлдә рәсемнең киселгән өлешләре ята. Тәрбияче аларга игътибар белән карага һәм бербөтен рәсем җыярга тәкдим итә. Башлангыч этапта балаларга өлешләрне бербөтен рәсем өстенә җыярга да тәкъдим итәргә була.

***«Өстәл театры» дидактик уены***

Максат: татар әкиятләрен сәхнәләштерү аркылы балаларда татар һәм башка Идел буе халыкларының мәдәниятына, тарихына, мохитына мәхәббәт тәрбияләү, сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру, күзаллауларын киңәйтү.

***«Әкиятнең парын тап» дидактик уены***

Максат: әкиятләрнең эчтәлеген искә төшереп рәсемнәрнең парларын табарга.

<u>Сәхнәләштерү һәм уйнау өчен тәкъдим ителгән әкиятләр һәм шигырьләр исемлеге:</u>

*Татар халык әкиятләре*

«Өч кыз»

«Төлке белән Каз»

*Рус халык әкиятләре*

«Шалкан» («Репка»)

«Кар кызы» («Снегурочка»)

«Теремкәй» («Теремок»)

«Йомры икмәк» («Колобок»)

*Башкорт халык әкияте*

«Ятим төлке» («Лиса-сирота»)

*Чуваш халык әкияте*

«Әтәч дус» («Дружок-петушок»)

*Мари халык әкияте*

«Керпе һәм куян» («Ёж и заяц»)

*Мордва халык әкияте*

«Аю һәм төлке» («Медведь и Лиса»)

*Удмурт халык әкияте*

«Акыллы кәҗә» («Умный козел»)

*А.Алиш әкиятләре*

«Сертотмас үрдәк»

«Куян кызы»

*Г.Тукай әкиятләре*

«Кәҗә белән Сарык»

*Г.Тукай шигырьләре*

«Кызыклы шәкерт»

«Бала белән Күбәләк»

«Эш беткәч, уйнарга да ярый»

«Гали белән Кәҗә»

«Шаян песи» һ.б.

**Күпфункцияле диктик уен**

***Серле тартма - «Минем шәҗәрәм»***

***Шәйхиева Рузилә Рафаэль кызы***

*"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Дөбьяз "Гөлчәчәк" балалар бакчасы, мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе тәрбиячесе*

Бүгенге көндә милләтебезнең гореф-гадәтләре, гаилә традицияләре, ядкарьләре белән кызыксыну, буыннар бәйләнешен барлау киң колач алды. Ә нәсел тамырларыңны барлау - зур һәм саваплы эш. Бу эш – яшь буынны әхлаклы, иманлы, мәгърифәтле, милли җанлы итеп тәрбияли. Балаларны Шәҗәрә белән таныштыру, без-өлкәннәр тарафыннан аңа зур игътибар бирү яшьләрдә туган җиргә, телгә, милләткә мәхәббәт; туганнарга хөрмәт күрсәтеп яшәргә кирәклеген искәртеп тора. Шул ният белән мин әлеге уенны ясарга булдым.

**Яшь үзенчәлекләре:** 5- 7 яшьлек балалар өчен.

**Максат**: балаларны «нәсел», «шәҗәрә агачы” төшенчәләре белән таныштыру; үз гаиләләренең шәҗәрәсен төзергә өйрәтү.

**Бурычлар**:

Белем бирү бурычы: балаларның  гаилә, үз шәҗәрәләре турында күзаллауларын киңәйтү, туганлык мөнәсәбәтләрендә ориентлашырга өйрәтү; балаларның  сөйләм телен баету.

Үстерү бурычы: балаларның сөйләм телен,сорауларга җавап бирү осталыкларын, кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү.

Тәрбия бурычы: балаларга милли тәрбия бирү; үз гаиләңә, нәселеңә, халкыңа, дәүләтеңә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү; үткән буыннарны барлый белү,  яшь буынга әхлакый тәрбия бирү.

**Белем бирү өлкәләренең интеграциясе:**

- Социаль-коммуникатив үсеш,
- Танып белү үсеше,
- Сөйләм үсеше,
- Сәнгати-эстетик үсеш.

**Кулланылган материал**: уенның нигезе итеп картон тартма алынды.  Аны яшел  фетр белән тышладым. Яшел төс бу  әсбабка милли калорит бирә. Тартманың һәр ягына дидактик уен урнаштырылды. Уеннарның төп максаты балаларны татар милләте вәкилләре булганлыкларын исләренә төшерү. Уеннар тематикага туры китерелгән ламинировать ителгән төсле рәсемнәр һәм ябыштыра торган элементлар ярдәмендә эшләнде. Ягъни, нинди максат куюыгызга карап, тартманы төрле тема өйрәнгәндә кулланып була.

Тартманың эчке ягында фетрдан эшләнгән агач сурәте урнаштырылган, анда бала гаилә әгзалары сурәтләре ярдәмендә үз нәсел агачын җыя. Баланың гаилә әгъзаларының фотосурәте булса, шәҗәрәне ясау тагын да кызыклырак һәм үтемлерәк була.

Әлеге дидактик әсбабны белем бирү эшчәнлегендә, режим моментларда һәм бала белән индивидуаль эшләгәндә кулланып була. Әсбапның эстетик яктан  җәлеп итүчәнлеге, гадәти булмаганлыгы балалар өчен танып белү процессын тагын да мавыктыргыч итәргә мөмкинлек бирә.

1.




1. Дидактик уен ***«Шәҗәрә»***

**Уенның максаты:**

Балаларны «гаилә», «нәсел», «шәҗәрә агачы» төшенчәләре белән таныштыру. Балаларны үз гаиләләренең шәҗәрәсен

төзергә өйрәтү.
2. Үз гаиләңнең тарихын белү ихтыяҗын үстерү. Гражданлык һәм патриотик хисләр үстерү.
3. Әти-әниеңә, туганнарыңа хөрмәт, гаиләңә карата җаваплылык хисе тәрбияләү.
**Уен барышы**: балалар тәрбияче ярдәме белән тәкъдим ителгән гаилә әгзалары сурәтләреннән үз нәсел агачын җыя.
**Уен вариантлары**: баланың үз гаиләсенең фотоларын ябыштырып була. Сурәтне урнаштыруны бу гаилә әгъзасы турында шигырь яки аның турында хикәя белән озата барырга мөмкин.

2. Дидактик уен ***«Татарстаным»***

**Уенның максаты:** яшь буында дәүләт символларына хөрмәт тәрбияләү, гражданлык һәм патриотизм хисләре формалаштыру.
**Уен барышы:** балалар тәрбияче сорауларына дөрес җавап биреп, тиешле рәсемне табырга һәм билгеләнгән урнына ябыштырып куерга тиеш.
**Уен вариантлары**: бу уенны шулай ук берничә команда ярышлары рәвешендә уздырырга мөмкин. Символиканы дөрес тапкан команда анда сурәтләнгән элементларны, шулай ук аларның барлыкка килү тарихын аңлатырга тиеш.

*3.* Дидактик уен “***Эмблеманы җый”***




**Уенның максаты**: балалар бакчасы эмблемасы турында балаларның күзаллауларын ныгыту; балалар бакчасы эмблемасын башка билгеләрдән аерып күрсәтә белү.
**Уен барышы:** балаларга балалар бакчасының эмблемасын карарга һәм үзенчәлекләрен билгеләргә тәкъдим ителә. Балалар контурлы шаблон буенча, үрнәк-шаблон ярдәмендә мозаикадан балалар бакчасының эмблемасын җыялар.
**Уен вариантлары**: балаларның иҗади сәләтләрен үстерү нияте белән үз эмблемаларын ясап, аны тасфирлап аңлатырга тәкъдим итергә була.

4. Дидактик уен: ***«Татар орнаментлары»***

**Уенның максаты:** балаларны татар орнаменты элементларын: лалә, кыңгырау, яфрак һ.б. табарга

һәм атарга, алардан композицияләр төзергә өйрәтү; балалар сүзлеген татар милли орнаменты исемнәре белән баету. Игътибарны, хәтерне үстерү.Татар халкы сәнгатенә кызыксыну тәрбияләү.

**Уен барышы:** бала тәкъдим ителгән орнаментлар арасыннан татар орнаментын табарга һәм үзенең сайлавын аңлатырга тиеш.

**Уен вариантлары**: тәрбияче рус Һәм татар кызы тәкъдим итә. Бала кызлар өчен көндәлек һәм бәйрәм киемнәрен сайлап бизәргә тиеш була. Уенны ярыш формасында да үткәреп була.

5. Дидактик уен ***«Үзең белән таныштыр»***

**Уенның максаты:** үзең турында хикәя төзи белүне үстерү; сүзлек запасын баету; вак моториканы, игътибарны үстерү.

**Уен барышы:** балаларга үзләре турында сөйләргә ярдәм итә торган төрле рәсемнәр тәкъдим ителә. Балаларның бурычы-сурәтләрне тоташтыру, үзе турында хикәя төзү.

**Уен вариантлары**: Балаларның исемнәрен истә калдыру өчен «кар йомарламы» алымын кулланырга мөмкин; түгәрәк эчендә утырган беренче бала үз исемен әйтә, икенчесе - беренче баланың исемен кабатлый һәм үзенекен әйтә, өченче бала беренче һәм икенче баланың исемнәрен һәм үзенекен әйтә... танышып чыкканчы уен дәвам итә.

**Көтелгән нәтиҗә:**

- «шәҗәрә» төшенчәсен аңлау;
- туганлык мөнәсәбәтләре турында күзаллау булу;
- балалар үз гаиләләре, үз тамырлары, гаилә әгъзалары, гореф-гадәтләре, якыннары һәм ерак туганнары турында күбрәк белү;
- һәр баланың үз гаиләсенең барлык әгъзаларына карата кайгыртучанлык һәм хөрмәт күрсәтү;
- үз хокукларын һәм бурычларын белү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балаларда бәйләнешле сөйләм теле үстерү;
- иҗади сәләтләрен,танып-белү активлыкларын үстерү.

**“Милли хәзинәләр” дидактик уены**

***Фәйзрахманова Гөлназ Вәзил кызы***

*Татарстан республикасы Арча муниципаль районы “Бала үсеше үзәге- Арча шәһәре 4 нче балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

“Милли хәзинәләр” дидактик уены өлкәннәр һәм мәктәпкә хәзерлек төркемнәрендә куллану өчен ясалды.

**Уенның максаты:**

-балаларны татар халык мирасы белән таныштыруны дәвам итү;

-югалган һәм бүгенге көндә дә сакланып калган хәзинәләрне барлау;

**Бурычлары:**

- Төрле уеннар аша милли хәзинәләребезнең исемнәрен сөйләмдә кулланырга өйрәтү;
- Хәтерләрен, кул чукларын ныгыту, җитезлек, игүтибарлылыкны арттыру;
- Үз халкыңа, мәдәниятына хөрмәт уяту;



Уеныбыз фетрдан тегелгән зур сандыктан гыйбарәт. Һәр сандыгыбызга милли бизәкләр һәм төрле рәсемнәр ябыштырылган. Шушы рәсемнәргә таянып, мнемотаблица ярдәмендә, балалар хәзинәләрнең төрләрен үзләре ачыкларга тиеш .

Беренче сандыгыбыз тышына Татарстан гербы, әләме һәм канатлы барс ябыштырылды. Барс безне җирдә һәм күктә яклаучы, саклаучы. Димәк , сандык эчендә- хәзинә, байлык ята. Аның канатындагы җиде каурые белән бәйле рәвештә, хәзинәләребез җиде сандыктан торачак. Һәр карточка катырылган, балага тотар өчен уңайлы.

Сандыгыбыз – куп функцияле. Атрибутлар, уеннар тагы да тулыландырыла ала.

Икенче сандыгыбыз **“Милли ашлар” хәзинәсе** диеп атала. Монда “Пешекче”, “Кайсы артык” уеннары урын алды.

Максаты: татар халык ризыклары белән таныштыру.

Уен барышы: “Пешекче “уенында балалар милли ашлар пешерсәләр, “Кайсы артык” уенында татар милли ризыгы булмаган артык ризыкны табарга тиешләр.

“Пешекче” уенын ярышлар уздырганда кулланам. Балалар ике командага бүленеп басалар. Беренче команда баллы ризык “Чәк-чәк”, икенче команда “Өчпочмак” пешерәчәк. Залның икенче ягында милли ризыкны пешерү өчен кирәк булган карточкалар урнаштырыла. Балалар түмгәктән түмгәккә сикереп, тар басма аша чыгып тиз генә милли ризык пешерергә тиеш булалар.

Өченче сандыгыбыз **“Милли киемнәр дөньясы”** диеп атала.

Максаты: татар халкының милли киемнәре белән таныштыру, сүз байлыгын арттыру.

Ул үз эченә “Күләгәсен тап”, “Алъяпкычны һәм читекне бизә”, “Курчакны киендер”, “Кискән рәсемнәрдән кием-салымны дөрес итеп җый һәм исемен ата” диеп атала.

Киләсе сандыгыбыз **“Милли йолалар”.**

Максаты: балаларны ел фасыллары белән таныштыруны дәвам итү, туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү;

Уен барышы: бала ел фасылына туры китереп милли йоланы табарга, бу йоланы үткәрүдә кирәкле җиһазларны дөрес итеп урнаштырырга тиеш.

Чираттагы сандыгыбыз **“Борынгы һәм хәзерге”** диеп атала. Ул үз эченә “Һөнәрләр”, “Көнкуреш кирәк яраклары”, “Уеннар”ны берләштерә.

Максаты:сүз байлыгын арттыру. Һәр уен элекеге һәм хәзерге вакыт белән чагыштырып бирелде.

**“Көнкүреш кирәк – яраклары”.**

Уен барышы: балаларга төрле карточкалар өләшенә . Көй яңгырый, балалар зал буйлап йөриләр. Көй туктауга, алар үзләренә пар табарга тиешләр.(бишек- кроватж; зур мич-газ плитәсе һ.б.)



**“Һөнәрләр”** тартмасындагы уеннар:

1 уен “Һөнәрчегә ни кирәк” лотосы

2 уен “Кайсы команда тизрәк җыела?”

Уен барышы: балаларга төрле рәсемнәр таратыла. Көй яңгырый, көй туктауга югалган һәм хәзерге вакыттагы һөнәрләрне табып балалар ике командага бүленеп басарга тиешләр.

3 уен“Кайсы һөнәр югалды?”

Уен барышы: балаларга төрле һөнәр рәсемнәре күрсәтелә. Күзләрен йомалар, бер рәсем алып куела, балалар кайсы һөнәрнең югалганын әйтергә тиешләр.

**“Уеннар”** тартмасы.

Уен барышы: балаларга төрле рәсемнәр күрсәтелә. Һәм алар ул уеннарның исемнәрен атарга тиешләр. Мәсәлән, ашлы капчык (элек ашлы капчык белән сикерсәләр, хәзер зур тупларда сикерәләр), таш рәсеме (элек- чуыр таш, хәзер классиклар)

Чынлап та бу сандыгыбызда татар халкының көч куатен, зурлыгын, зирәклеген, гаделлеген мәңге яшәр сүнмәс тормышын чагылдыручы 12 төрле уен- хәзинә ята.

**“Г.Тукай әсәрләрендә милләтем хәзинәсе”**

**дидактик уен китапчыгы.**

***Сәйфелганиева Миләүшә Альверт кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*«Салавыч балалар бакчасы» муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*

**Максат:** Габдулла Тукай, аның иҗаты, экиятләре турында булган белемнәрен камилләштереп, татар халкының милләте, аның гореф-гадәте, көнкүреше чагылган өлешләрен аерып алырга өйрәтү, әсәрләре аша милләтебегә карата горурлык хисләре тәрбияләү.

**Тәрбия бурычы:**

Әкиятләр нигезендә балаларда милләтебезгә хас шәфкатьлелек, миһербанлылык, дуслык, гаделлек, әдәплелек хисләре, өлкәннәргә карата игътибарлы булу сыйфатын тәрбияләү.

**Үстерү бурычы**: Милләтебезнең бөек шәхесе Г.Тукай әкиятләре аша үсеп килүче буынның сөйләм телен, иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

**Белем бирү бурычы**: Милләтебезгә хас гореф-гадәтләрнең көнкүреше чагылган җиһазларын аерып алып, сорауларга тулы җавап бирү күнекмәләрен формалаштыру. Әкият геройларының эшләгән эшләренә милләтебез күзлегеннән чыгып дөрес бәя бирә белүгә өйрәтү.

**Дидактик уенның кулланышы.**

**“Бала белән күбәләк” шигырендә милли сыйфатлар.**

**“Кем миллионер булырга тели?” уены**

**Максат**: Г.Тукайның "Бала белән күбәләк" шигырендә милли сыйфатларны танып табарга өйрәтү, татар милләтенең күркәм сыйфатлары күплеген ачыклау, милләтебезнең күркәм сыйфатларын яшь буында тәрбияләү.

**Уен барышы.**

Балага әкиятне карау өчен куар код бирелә, шуның буенча әкият карала. Куар код буенча уенга кереп, «Кем милионер булырга тели?» уенын уйнау.

| | |
|---|---|
| | Әсәргә ссылка |
| | Уенга ссылка |

**“Г.Тукайның “Су анасы” әкиятендә миллилекне эзләп тап” – викторина.**

**Максат**: Г.Тукайның "Су анасы" әкиятендәге милли киемнәрне танып табарга өйрәтү, логик фикерләү күнекмәләрен камилләштерү, милләтебезнең күренекле шәхесе Г.Тукай әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү.

**Уен барышы.**

Балага әкиятне карау өчен куар код бирелә, шуның буенча әкият карала. Куар код буенча уенга кереп викторинада катнашу.

| | |
|---|---|
| | Әкияткә ссылка |
| | Уенга ссылка |

**Г.Тукайның "Кәҗә белән сарык" әкиятендәге**

**милли әйберләрнең парын тап.**

**Максат:** Г.Тукайның "Кәҗә белән сарык" әкиятендәге миллилекне эзләп табарга өйрәтү, хәтерләп калу күнекмәләрен камилләштерү, милләтебезнең күренекле шәхесе Г.Тукай әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү.

**Уен барышы.**

Балага әкиятне карау өчен куар код бирелә, шуның буенча әкият карала. Куар код буенча уенга керү, сорауларга җавап биреп, уенны уйнау.

| | |
|---|---|
| | Әкияткә ссылка |
| | Уенга ссылка |

**“Шүрәле” әкиятендә милли бизәкләрне эзләп тап.**

**(Җаваплы викторина).**

**Максат:** Г.Тукайның "Шүрәле" әкиятендәге милли киемнәрне эзләп табарга өйрәтү, хәтерләп калу күнекмәләрен камилләштерү,милләтебезнең күренекле шәхесе Г.Тукай әсәрләре буенча милли бизәнү әйберләренә карата мәхәббәт тәрбияләү.

**Уен барышы.**

Балага әкиятне карау өчен куар код бирелә, шуның буенча әкият карала. Куар код буенча уенга керү, сорауларга җавап бирү, уенны уйнау.

| | |
|---|---|
| | Әкияткә ссылка |
| | Уенга ссылка |

**“Гали белән кәҗә” әсәрендә көнкүреш җиһазларының милли бизәкләрен ачыкла.**

**(Җаваплы викторина).**

**Максат:** Г.Тукайның "Гали белән кәҗә” әкиятендә көнкүреш җиһазларының милли бизәкләрен эзләп табарга өйрәтү, хәтерләп калу күнекмәләрен камилләштерү, милләтебезнең күренекле шәхесе Г.Тукай әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү.

**Уен барышы.**

Балага әкиятне карау өчен куар код бирелә, шуның буенча әкият карала. Куар код буенча уенга керү, сорауларга җавап биреп, уенны уйнау.

| | |
|---|---|
| | Әкияткә ссылка |
| | Уенга ссылка |

**“Г.Тукайның “Карлыгач” әсәрендә милләтебез**

**символикасының парын тап” уены.**

**Максат:** Г.Тукайның “Карлыгач” әсәрендә милләтебез символикасын ачыкларга өйрәтү, патриотик хисләр тәрбияләү.

**Уен барышы.**

Балага әкиятне карау өчен куар код бирелә, шуның буенча әкият карала. Куар код буенча уенга керү, сорауларга җавап бирү, уенны уйнау.

| | |
|---|---|
| | Әсәргә ссылка |
| | Уенга ссылка |

**Г.Тукайның "Эш беткәч уйнарга ярый" әсәрендә**

**нинди милли сыйфатлар чагыла?**

**Максат:** Г.Тукайның "Эш беткәч уйнарга ярый" әсәрендә нинди милли сыйфатлар чагылуын ачыклау, балаларда милләтебезнең асыл сыйфатларын тәрбияләү.

**Уен барышы.**

Балага әкиятне карау өчен куар код бирелә, шуның буенча әкият карала. Куар код буенча уенга керү, сорауларга җавап бирү, уенны уйнау.

| | |
|---|---|
| | Әсәргә ссылка |

| | |
|---|---|
| | Уенга ссылка |

**Туган авыл, туган як - миллəтебезнең горурлыгы.**

**Максат:** Г.Тукай əсəре аша туган як, туган авылга карата игътибарлылык хисен үстерү, туган якка мəхəббəт аша милли хислəр тəрбиялəү.

**Уен барышы.**

Балага əкиятне карау өчен куар код бирелə, шуның буенча əкият карала. Куар код буенча уенга керү, сорауларга җавап бирү, уенны уйнау.

| | |
|---|---|
| | Əкияткə ссылка |
| | Уенга ссылка |

**Татар халкының милли киемнəре белəн таныштыру**

**(“ Купфункцияле ширма “дидактик кулланманы кулланып эшлəү алымнарын ачу)**

**( 6-7 яшь)**

***Хəбибуллина Лилия Юрьий кызы***

***Кəлимуллина Гөлназ Марат кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*«Салавыч балалар бакчасы» муниципаль*
*бюджет мəктəпкəчə белем бирү учреждениясе*

**Максат:** Мəктəпкəчə яшьтəге балаларны Россиядə яшəүче халыкларның мəдəниятенə, гореф-гадəтлəренə, милли костюмнар белəн таныштыру юлы аша җəлеп итү.

**Бурычлар:**

**Белем бирү бурычы**: -Мəктəпкəчə яшьтəге балаларны Россиядə яшəүче халыкларның мəдəниятенə, гореф-гадəтлəренə, милли костюмнар белəн таныштыру юлы аша җəлеп итү.

**Үстерелешле бурычлар**

-Җөмләләрне дөрес итеп төзи белүләрен үстерү

- Балаларның рус һәм татар халык милли киемнәре турында белемнәрен киңәйту,киемнәрдәге бизәкләрне чагыштырырга өйрәту;

-Балаларда фантазия белән эшләуне дәвам иту,вак кул моторикасын арттыру.

**Тәрбия бирү бурычылары:**

-социаль-коммуникатив күнекмәләр ярдәмендә хезмәттәшлек һәм иглеклелек тәрбиясе булдыру;

-җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү.

**Белем бирү өлкәләрен интеграцияләү:**

Сөйләм үсеше:

- « Милли киемнәр»дигән лексик тема буенча сүзлекне баету һәм активлаштыру;

-фикерләрне дөрес итеп рәсмиләштерү күнекмәләрен ныгыту;

- сөйләм нормаларын үтәргә өйрәтү.

Танып-белү үсеше:

- Россиядә яшәүче халыклар һәм аларның милли киемнәре белән таныштыру;

- рус, башкорт, татар милли киемнәре элементлары белән таныштыру;

Алган белемнәрне уен эшчәнлегендә мөстәкыйль куллану күнекмәләрен камилләштерү;

- танып-белү гамәлләре формалаштыру.

Сәнгать-эстетик үсеш:

- Россия халыкларының үткәне белән кызыксынуны формалаштыру;

- Ватанга мәхәббәт, үз халкы һәм мәдәнияте өчен горурлык хисе тәрбияләү.

- сөйләгәнне тыңлый белү һәм максатчан караш формалаштыру ;

Физик үсеш:

- гомуми моториканы, хәрәкәтләрне һәм сөйләмне координацияләүне үстерү;

**Җиһазлар**:купфункциональ ширма,татар милли орнаментлары, татар милли киемнәре, читек, кәләпүш, татар милли уеннар җыентыгы, татар милли бизәкләре җыентыгы, татар милли халык -аваз иҗаты җыентыгы.

**Шөгыль барышы.**

**Кереш өлеш**

“Кәләпүшем калфагым “ җырын җырлап залга тәрбияче керә.

**Төп өлеш**

Әйтегез әле, мин сезгә нәрсә турында җыр җырладым? (Кәләпүш, калфак)

- Дөрес,балалар.Ә минем өстемдә нинди киемнәр?(татар күлмәге, кәзәки, калфак)

-Әйе, минем өстемдә татар кызлары кия торган киемнәр. Минем әле универсаль күпфункцияле ширмам да бар, менә шунда игътибарны юнәлтик әле. Әйдәгез, якынрак килегез әле. Мин сезгә дидактик уен әзерләп килдем. Ширмага төрле милләт кызлары һәм малайлары беркетелгән. Без сезнең белән татар милләтеннән булмаган кыз һәм малайларны аерып алырга тиеш. Игътибар белән карагыз әле (балалар рус,башкорт, мари милләтеннән булган кыз һәм малайларны алалар)

-Менә монда калганнары нинди милләтнеке? (татар кызы һәм малае)

-Татар милләтеннән булуын каян белдегез? (чөнки аларның киемнәренә татар бизәкләре төшерелгән)

-Сез бик булдырдыгыз, балалар!Ә хәзер мин сезне зәңгәр экраннар каршына ”Милли хәзинә” тапшыруына чакырам.



- Хәерле көн, хөрмәтле тамашачылар. Сез “Милли хәзинә” тапшыруын карыйсыз. Бүгенге тапшыруда без сезне татар милли киемнәре белән таныштырырбыз.

-Татарнын милли баш киемнәренә калфак, түбәтәй, яулык керә. Аларны бик матур итеп чигеп, бизәп эшләгәннәр. Ир-егетләребездә хәзер дә түбәтәйләрне еш очратырга мөмкин. Калфакларны элегрәк йон тукымадан эшләсәләр, хәзер аны күбрәк бәрхет тукымадан ясыйлар.

-Татарның милли өс киемнәренә килгәндә, күлмәк,кәзәки,камзул, алъяпкычларны атарга мөмкин. Күлмәкләрне күбрәк бала итәкле итеп теккәннәр. Бу киемнәргә дә бик матур татар бизәкләре төшергәннәр, чиккәннәр.

-Татарның милли аяк киемнәренә читек, чабата, чүәк керә. Читекләр бүгенге көндә дә төрле биюләр башкарганда яратып киелә. Ә инде чабатаны “Чабата” биюен башкарганда кияләр.

-Тапшыруыбыз ахрына якынлашты, без сезнең белән бүгенге тапшыруда татар халкының милли киемнәре турында сөйләштек. Киләсе тапшыруларга кадәр сау булыгыз.

- Балалар, сезгә тапшыру ошадымы? Әйтегез әле, бу матур киемнәрне кайларда киделәр икән?(балалар җавабы)

-Әйе, бу киемнәрне кичке уеннарда, өмәләрдә, кичәләрдә,бәйрәмнәрдә кигәннәр. Минем ширмамда бер китапчыгым бар, ул китапчыкта бик күп милли уеннар тупланган. Әйдәгез, шулар арасыннан “Түбәтәй” уенын уйнап китик әле.

Иң элек мин сезне уенның шарты белән таныштырам. Матур итеп түгәрәк ясап басыйк әле. Җырны җырлаганда түбәтәйне бер-беребезнең башына киертәбез, җыр туктаганда түбәтәй кемдә кала - шул кешегә җәза бирәчәкбез. Ә хәзер җырның сүзләрен өйрәнеп китәрбез.

Түбәтәеңнекигәнсең,

Бик еракларданкилгәнсең,

Төскәматурлыгың белән

Шаккатырыйм, дигәнсең.

Кушымта:

Түп-түп-түбәтәй,

Түбәтәең укалы.

Чиккән матур түбәтәең

Менә кемдә тукталды.

Балалар, сезгә уен ошадымы? Минем әле сезгә алып килгән кечкенә генә бүләгем дә бар, бу серле сандык. Аның эчендә бик матур калфаклар бар. Менә шуларны сезгә бүләк иткәнче бизәргә кирәк.  Мин сезгә төрле  бизәкләр алып килдем, аларның барысы да татар бизәкләре түгел. Татар бизәкләрен эзләп табып, бу калфакларны матурларга кирәк. (Татар бизәкләре белән балалар калфакларны бизиләр)

-Рәхмәт, балалар, сезнең калфакларыгыз искиткеч матур килеп чыкты.

**Йомгаклау өлеше**

Без нинди яхшы гамәл башкардык?

Шөгыльдә өйрәнгәннәрне кайда куллана аласыз?

**“ Зирәк гаилә”**

***Хасанова Рания Илсур кызы,***

*Казан шәһәре Совет районынын «402 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем  бирү учреждениесе*

**Максат**: “Зирәк гаилә” дидактик уены аркылы 4-5 яшьлек балаларның танып белү, санау күнекмәләрен үстерү.

**Бурычлар**: *белем бирү бурычлары:*

-геометрик фигураларны, аларның исемнәрен, аермаларын белү;

-1дән 10га кадәр саный белүне ныгыту;

-төсләрне,формаларны аерырга өйрәтү;

-кушу һәм алу күнекмәләрен камилләштерү;

*күнекмәләрне үстерү бурычлары:*

- вак моториканы, конструктив күнекмәләрне,хәрәкәтне координацияләүне, фантазия һәм иҗадилыкны үстерү;
- анализлау, чагыштыру, күләмне чамалау күнекмәләрен үстерү;
- сорауларга җавап бирә белү, сөйләмне камилләштерү өстендә эшләү;

*тәрбияви бурычлар:*

- уен кагыйдәләрен төгәл үтәү;
- тәрбиячене тыңлый белү;
- эстетик зәвык булдыру;
- татар милләтенә, аның гореф-гадәтенә, көнкүрешенә кызыксыну уяту.

**Актуальлеге**: әлеге уен универсаль һәм күп функцияләрне үз эченә ала. Белем алуның төрле өлкәләренә кагыла. Бала шәхесенең төрле яктан үсешенә, милли тәрбия алуына һәм иҗади яктан камилләшүенә ярдәм итә.

**Уен кагыйдәләре**

Тәрбияче уенны башлар алдыннан балаларга төрле сораулар биреп кызыксындыра ала. Мәсәлән:

**1нче вариант**. Гаилә әгъзалары турында табышмаклар әйтү.

2.Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә.

Өебезнең нуры ул, барыбыздан олы ул. **(Әби)**

1.Ул бик күпне күргән, сугышта да булган ул.

Йөзе нурлы айдай… Кем дисезме? Ул минем **(бабай).**

3.Ул зирәктә, шаян да, акыллы да, әйбәттә!

Иң – иң батыр кеше ул, минем **(әти),** әлбәттә!

4.Мин аны бик  сагындым, күңелем әрни, уйлый әллә ни.

Кем соң аны белми? Ул бит минем **(әни).**

5. Мин нәсел дәвамчысы, әтинең булышчысы.

Машиналар яратам, велосипедта чабам (**малай)**.

6. Мин гаиләдә бер генә, бер генә дә, гөл генә,

Курчаклар белән уйныйм, әни кебек булыйм дим. **(кыз)**

Тәрбияче: Балалар, табышмакларны чиштегез, димәк без бүген нинди уен уйныйбыз? (Гаилә)

**2 вариант**. Тәрбияче: балалар, сезнең гаиләдә кемнәр бар? (Балалар саный). Ә без бүген зирәк татар гаиләсе белән танышабыз. Әйтегез әле бу кем? (рәттән һәр фигураны күрсәтә, исемнәрен әйттерә, киемнәренең төсләрен, фигураларның санын саната).

***Уен барышы***

**“Зирәк гаилә”** дидактик уены үз эченә төрле кызыклы биремнәр туплаган 6 фигурадан: бабай, әби, әти, әни, малай һәм кыздан тора. Алар татар халкының милли киемнәреннән, зурлыклары төрле.

1нче фигура- **“Бабай”**-“Әкият сөйлә”. Бабайның камзулы эченә кесәле өстәл театры яшерелгән. Анда йорт, куян, бака, тычкан, аю, төлке бар.




Театр нәниләрне сихри дөньяга алып керә, аларның сәләтен ачарга ярдәм итә, иҗади фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерә, актерлык осталыгына өйрәтә, эстетик һәм әхлакый тәрбия бирә.
2нче фигура- **“Әби”-** “Әби бәлеш пешергән”. Бәлешне әби кисәкләргә бүлгән. Бәлешнең хәр кисәгендә төрле күләмдә предметлар урнаштырылган.Бала һәр кисәктәге предметларны дөрес итеп санап каптыргычтагы саннар белән туры китерергә
тиеш.
3нче фигура **–“Әти”-** “Геометрик фигуралар”. Әти киеме эченә яшерелгән фигураларны дөрес урнаштыру, төсләрен, исемнәрен атау.




4нче фигура- **“Әни”-** “Кисәкләрдән җый”. Фигура эчендәге милли киемнәрне җый, исемнәрен дөрес итеп атау.

Балаларны халкыбызнын күңел бизәкләре белән якыннан таныштыру, нәфис бизәлешенә соклану, эстетик зәвык аша әхлак тәрбиясе бирү бүгенге көндә актуалҗ булып кала.

5нче фигура-**“Малай**”- “Пазл”. Кисәкләрдән татар халык әкиятен җый һәм нинди әкият икәнен билгелә.






Татар халык әкиятләре балаларны гаделлеккә һәм яхшылыкка өйрәтәләр.

6 фигура –**“Кыз**”- “Табышмаклар”. Кыз киеме әченә яшерелгән табышмакларны игътибар белән тыңлап дөрес җавап бирергә өйрәтү. Балаларның туган якларының табигате, андагы җәнлекләр, кошлар, үсемлекләр турында белемнәрен ныгыту.

“Зирәк гаилә” уены даими тулыланып, яңа биремнәр өстәлеп тора.



## «Серле юрган»

***Мөхтәрова Гөлүсә Фердинант кызы**,*
*Татарстан республикасы Биектау муниципаль районының*
*“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” мәктәпкәчә белем*
*бирү муниципаль бюджет учреждениесе тәрбиячесе*

**Уенның максаты:**
Балаларның туган телне өйрәнүдәге белемнәрен камилләштерү.
**Бурычлар:**

**Белем бирү:** татар халкының милли ашларын, уеннарын, музыка уен коралларын, киемнәрен, бәйрәмнәрен, орнаментын өйрәнү;

**Үстерелешле:** балаларның логик фикерләвен, хәтерен, үстерү, кул чукларын ныгыту;

**Тәрбия бирү:** милли һәм эстетик тәрбия бирү, үз халкыңа хөрмәт, ярату хисләре уяту;

**Социаль-коммуникатив:** сөйләм телен үстерү, балаларның үзара аралашуына, дустанә мөнәсәбәттә булуына, үзара һәм олы кеше белән киңәшеп, ярдәмләшеп эшләвенә ирешү.

**Уен 4-7 яшьлек балалар өчен әзерләнде**

**Уен алдыннан башкарылган эш**: татар халкының милли ашлары, музыка уен кораллары, киемнәре, бәйрәмнәре турында әңгәмәләр алып бару, рәсемнәр, мультфильмнар карау, татар балалар фольклоры белән танышу, татар орнаментын, уеннарын өйрәнү.

**Кулланылган җиһазлар:** чигелгән һәм татар орнаменты белән бизәлгән юрган, милли киемдәге фетрдан эшләнгән күбәләк һәм аны күчереп йөртү өчен бау; төрле биремнәр урнаштырылган 6 кесә, биремнәрне салу өчен янчыклар. **“Милли ашлар”** биреме өчен милли бизәкле, самавыр белән чынаяклар төшерелгән түгәрәк картон өстәл һәм милли ашлар ябыштырылган каптыргычлар; **“Милли бизәкләр”** биреме өчен татар орнаменты төшерелгән агач мәрҗәннәр һәм аларны тезү өчен шнурлар; **“Милли музыка уен кораллары”** биреме өчен бер ягына табышмак, икенче ягына уен коралының рәсеме ясалган карточкалар; **“Милли киемнәр”** биреме өчен картоннан малай һәм кыз курчак һәм алар өчен милли орнаментлы киемнәр; **“Милли бәйрәмнәр”** биреме өчен пазллар һәм бәйрәмнәрнең рәсемнәре; **“Милли уеннар”** биреме өчен бер ягына рәсем, икенче ягына уенның аңлатмасы язылган карточкалар. Уенда 5-6 бала катнаша ала.

**Уен барышы:**

Тәрбияче юрганны келәмгә яки өстәлгә җәя, үз янына түгәрәккә балаларны утырта. Иң башта юрганга, аның бизәлешенә игътибар юнәлдерелә, бу “серле” юрганның бизәлеше татар милләтенә хас булуы әйтелә. Лалә чәчәкләрен карап, төсләрне кабатлатырга мөмкин. Аннан соң бергәләп күбәләкне карыйлар. Аның канатларында шулай ук татар орнаменты, башында калфак, өстендә чигүле күлмәк. Әлеге күбәләк бүген балаларга биремнәр сайларга ярдәм

итәчәк. Шуннан биремнәргә күчәләр. Күбәләкне күчереп, чәчәк янына китерәләр. Чәчәк ябыштырылган кесәләрдә бирем салынган янчыклар урнаштырылган. Яшь үзенчәлекләренә карап, биремнәрне җайлырак һәм катлаулырак итеп үтәргә була.

**“Милли ашлар”** Кечерәк яшьтәге балаларга милли ризыкның исемен атау җитә: пәрәмәч, өчпочмак, чәкчәк, талкыш кәләвә, бәлеш, кош теле, гөбәдия. Зурраклары белән тәрбияче: бу ризык нәрсәдән әзерләнә, ашаганың бармы, кем өйдә пешерә? Кебек сораулар белән әңгәмә оештыра.




**“Милли бизәкләр”** Кечкенәрәк балалар мәрҗәннәрне шнурга матурлап тезәләр, зурраклары татар орнаментының бизәкләре ничек аталуын да әйтергә тиешләр.

**“Милли киемнәр”** Балалар киемнең исемен әйтеп “малай” һәм “кыз” курчакны киендерәләр: күлмәк, алъяпкыч, читек, чалбар, түбәтәй, калфак. Шулай ук киемнәрнең бизәлешенә дә игътибар итәләр.
**“Милли музыка уен кораллары”** Бу уен өчен бирелгән карточкаларның бер ягында гармун, курай, думбра, саз, кубыз кебек уен коралларының рәсеме, ә икенче ягында аның турында табышмак язылган. Балалар табышмакларны чишеп, уен коралының рәсемнәрен карыйлар. Зуррак балалар белән тәрбияче музыка уен кораллары турында әңгәмә оештыра.




**“Милли бәйрәмнәр”** Тәрбияче балалар белән милли бәйрәмнәр: сабантуй, нардуган, карга боткасы, сөмбелә турында әңгәмә оештыра. Соңрак төрле геометрик фигуралар формасында киселгән пазллардан балалар бу бәйрәмнәрнең рәсемнәрен төзиләр.

**“Милли уеннар”** Бу уен өчен әзерләнгән карточкаларның бер ягында рәсем, ә икенче ягында шул уенны уйнау тәртибе язылган. Рәсемгә карап балалар уйнарга теләгән уеннарын сайлыйлар: “йөзек салыш”, “капкалы”, “мендәрле”, “яшерәм яулык”, “түбәтәй”, “башмакчы”. Тәрбияче аңлаткач бергәләп әлеге татар халык уеннары уйнатыла.

# МАСТЕР – КЛАССЛАР





## Мастер-класс “Шаян кашыклар”

***Мөхәммәтшина Альбина Фәрит кызы***

*Балтач районы Катнаш төрдәге*
*Карадуган балалар бакчасы*

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәләтләрен уеннар, иҗади метод һәм алымнар ярдәме белән үстерү.

**Бурычлар:**

1. Агач кашыклар белән күрсәтмәлекләр ясарга кызыксыну уяту;

2.Иҗади сәләтләрен,фантазияләрен үстерү;

3.Татарларның милли көйләре, киемнәренә карата ихтирамлылык хисләре тәрбияләү;

**Кулланылган материаллар:** серле тартма, агач кашыклар, алдан әзерләнгән курчаклар киемнәре, презентация, ноутбук.

**Мастер-классның барышы:**

**I өлеш – теоретик.**

Исәнмесез, хөрмәтле хезмәттәшләр! Белгәнебезчә, тәрбияче алдына шәхси фикере, идеяләре булган, фантазияле, иҗади сәләтле балалар тәрбияләү максаты куела. Шул максатларны тормышка ашырыр өчен без төрле алымнар кулланабыз.

Үз чыгышымны түбәндәге сүзләр белән башлар идем : “ Сөйлә миңа- мин онытырмын, күрсәт - истә калдырырмын, кызыксындыр - өйрәнермен”.Чынлап та без нәрсәгә дә булса өйрәтергә телибез икән, иң беренче кызыксындыру уятырга кирәк. Бугенге эшчәнлегем дә, бәлки, кемдәдер кызыксыну уятыр.

Ә бүгенге чыгышым ни турыда булуын белер өчен сезгә уен тәкъдим итәсем килә. Җавап шушы матур тартма эченә яшеренгән.Ул яшерелгән. Аны “ Әйе, юк ” уены аша табарга кирәк булачак. Нинди төркемгә кергән әйбер икәнлеген белү өчен сез миңа сораулар бирә аласыз. Ә мин аңа “ Әйе”, “Юк” дип кенә җавап бирәчәкмен. Ягез, кайсыгыз яшерен сүзне табар икән?

-Ул җанлымы?

-Тавышы бармы?

-Ашый торган әйберме? һ.б.

(Белмәсәләр, ярдәмлек: без аны иртәнге, көндезге, кичке аш вакытларында кулланабыз)

**Калак – кашык**

Мастер-классымның исеме “Шаян кашыклар” дип атала.

Тәрбияче:-Әйтегез әле, кашык безгә ни өчен кирәк? (Ашарга)

Тәрбияче:-Тагын кашык белән нәрсәләр эшләп була?

**Көтелгән җаваплар:**

-микрофон ролендә кулланырга;

-музыка уен коралы итеп;

-кечкенә балаларга күрәк урынына , һ.б.

Хөрмәтле хезмәттәшләр, без бит барыбыз да балачактан, хәзер дә, хезмәтебез балалар белән бәйле булгач, балачакта яшибез. Кашыкны музыка уен коралы итеп уйнарга була дидек , әйдәгез исбатлыйк әле. **Татар халык көе “Баламишкин” (кашыкларда уйнау)**

Булдырдыгыз! Бик зур рәхмәт,чын кашыкчылар ансамбле дә болай булдыра алмас.

**II өлеш - практик.**

Бүген мин сезгә тагын бер яналык әйтәсем килә: агач кашыкларны төрле костюмнар киертеп театр да уйнап була икән. Кулларында кашык булучылар, рәхим итеп, сезгә дип әзерләнгән өстәлләрдә үз урыннарыгызны алуыгызны сорыйм. Күргәнегезчә, сезнең алдыгызда агач кашыклар һәм күп төрле әзер костюмнар куелган. Әйдәгез кашыкларны “киендерик” әле. Кашыклардан курчаклар ясарбыз.

Нинди әкиятне уйнап күрсәтәсегезне алдан күзаллап курчакларны әзерлисегез була.

Әкиятне әзерләгән арада, залда утыручылар, минем Сезгә мөрәҗәгать итәсем килә.

Әйдәгез,интерактив тактага күз салыйк әле.Хәзер без сезнең белән “Татар халык әкиятләрен беләсеңме?”дип исемләнгән уен уйнап алырбыз.

1 нче слайд

“Бу кайсы әкият?”(әни,кыз,тиен)

Җавап:“Өч кыз әкияте”

2 нче слайд

“Кайсы әкият артык?”(куян,итек,әни,шалкан)

Җавап:“Куян кызы”әкияте янына рус халык әкиятеннән шалкан кергән.

3 нче слайд

Г.Тукайның “Кәҗә белән сарык”әкиятендә бүреләр учак янында нәрсә пешерәләр?(ит,ботка,аш)

Җававп;ботка пешерәләр.

4 нче слайд

А.Алишның “Чукмар белән Тукмар”әкиятендә Чукмар кем ул?(тавык,әтәч,чеби)

Җавап:әтәч.

5 нче слайд

Г.Тукайның “Гали белән кәҗә”шигырендә кәҗә Галигә нәрсә ди?(рәхмәт,исәнмесез,хәерле көн)

Җавап: рәхмәт.

Барыгызга да рәхмәт!

Ә хәзер, өстәл янында утыручы булачак курчак театры артистларына сүз бирик.

**Кашыклар ярдәмендә төркем белән әкият уйнап күрсәтелә.**

Хөрмәтле хезмәттәшләрем, бүген минем бу теманы алуым юкка гына түгел. Гади агач кашык белән дә нинди эш төрләре алып барып булгандыгын күрсәтәсем килгән иде. Агач кашыкны аш вакытында гына түгел, аны музыка уен коралы, нәниләр өчен уенчык итеп, театр куйганда да кулланырга мөмкин.Ә иң мөхиме, бу кашыклар экологик яктан чиста материалдан эшләнгән, сәламәтлек өчен зыянсыз. Балачак, чыннан да, бәхетле, борчусыз булсын дисәк, балаларга рәхәтләнеп яшәргә шартлар булсын. Әйдәгез, үзебезнең балалар белән дә ешрак уйныйк. Киләсе очрашуларга кадәр.

**“Энәсез корамалы техникасында лалә чәчәге ясау”**

***Гайфуллина Лилия Фирденат кызы***
*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*“Дөбъяз “Гөлчәчәк” балалар бакчасы,*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

Максат: текстиль иҗатының популяр төре белән таныштырырга һәм шул ысул белән татар халкының милли бизәге булган лалә чәчәген ясау.

Бурычлар:

1) белем бирү бурычлары:

- яңа күнекмәләргә өйрәтергә;

- татар халкының милли бизәкләре белән таныштыруны дәвам итү;

- тукыманы кисеп алынган контурларга тутыру күнекмәләрен беркетү;

- пластик пычак, кайчы белән эшләгәндә ТБ кагыйдәләрен белүне ныгытырга;

2) тәрбия бирү: мөстәкыйльлек, хезмәт сөючәнлек, сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү;

3) Төзәтү-үстерү бурычлары:

-күрсәтмә-образлы фикерләүне, игътибарлылыкны, бәйләнешле сөйләмне, озак вакытлы хәтерне үстерү;

-балаларның күз үлчәмнәрен, вак моториканы үстererү;

- физминуткалар куллану юлы белән балаларның эшкә сәләтен арттыру;

- үз-үзеңне һәм үзара контрольдә тоту күнекмәләрен формалаштырыру.

- тырышлыкны, игътибарлылыкны, төгәльлекне, төсләрне кабул итүне үстерү.

Кулланган ысуллар:

-сүзле: әңгәмә;

- күрсәтмә: рәсем ясауның технологик эзлеклелеге (карточкалар һәм үрнәкләр), әзер эшләнмә үрнәге;

- практик.

Җиһазлар һәм күрсәтмә әсбаплар:

- кайчы;

- пластик пычаклар;

-лалә чәчәге шаблоны ;

- каләм;

- линейкалар;

- пенопласт плиткаларының күләме ;

- әзер эшләнмә үрнәге;

Материаллар: кирәкле төстәге трикотаж тукыма корамалары

Сүзлек: пенопласт, трикотаж тукыма, тукыманы тамгалау.

Оештыру моменты.

Максат: эшкә психологик әзерлек.

1.Сәламләү.

Без бүген корамалап тегү ысулы белән танышырбыз һәм шул ысулны кулланып татар халкының милли бизәге булган лалә чәчәген ясыйбыз.



Бу эшне башкарырга безгә түбәндәге җиһазлар кирәк була: кайчы, пластик пычаклар, лалә чәчәге шаблоны, каләм, линейка, пенопласт плиткалары, туры килгән төстәге берничә тукыма, әзер эшләнмә үрнәге.

Иҗатыбызда иң мөһиме - эш урыны. Инструментлар һәм җайланмалар эшләүчедән уң якта, ә материаллар сул якта урнаштырыла. Эшләгәндә кул кораллары белән куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен үтәргә кирәк.

Әйдәгез аларны искә төшерик.

Кул эшләрен башкарганда:

1.Кылычлары йомык кайчыны бо̧җралар белән уңга үзеңә куярга;

2.Кайчыны бо̧җралар белән алга тапшырырга;

3.Пычакның үткенлегенә бармак белән кагылмаска.

Эш барышы:

1.Безгә ошаган рәсемне сайлыйбыз.

2. Рәсемне пенопласт өстенә ясыйбыз, рәсемне алып куябыз, эзне карап чыгабыз һәм пычак белән барлык сызыкларны әйбәтләп кисеп чыгабыз:

3. Кирәкле төстәге тукыма алабыз.

4.Аннары пычкы ярдәмендә мозаиканың һәр элементын кисеп алынган контурларга тукыма белән җентекләп тыгабыз, кырыйларын кисәбез, ә калганнарын буыннарга яшерәбез.

5. Рәсемнең һәр өлеше белән шулай эшләүне дәвам итәбез.

2. Әзерләү эзлеклелеген белүне ныгыту.

Нинди эшне беренче булып башкарачаксыз? (Картинканы пенопластка төшерәбез).

Алга таба нишләрсез ? (Рәсемне алып куябыз)

- Шуннан соң нинди эш ясарсыз? (Пычак белән барлык сызыкларны пөхтә итеп кисеп чыгабыз).

- Шуннан соң нинди эш ясарсыз? (Туры килгән тукыманы конкрет детальгә салабыз, тукыма белән киселгән контурларга тамгалыйбыз).

- Икенче этап-артык кырыйларны кисеп, калганнарын буыннарга яшереп кую.

3. Физкультминутка .

«Тау» Күнегүе.

Өстәлләр  артыннан торыгыз. Кулларыгызны Түбән төшерегез, аркагызны тигезләгез, башыгызны иеп тормагыз. Кулларыгызны әкрен генә Өскә күтәрегез, кулларыгызны ачыгыз. Күз алдыгызга китерегез, сезнең гәүдәгез – кояшка таба сузылган агач. Бергә сузылдылар, бер якка, икенче якка чайкалдылар. Кулларыгызны әкрен генә төшерегез һәм елмаегыз. Әфәрин!

4. Практик эш. Лалә чәчәген ясау.

5. Күзләр өчен Гимнастика.(Утырган килеш)

Күзләрне йомарга (5 секунд).)

Күзләрне киң ачарга (5 секунд).)

Башыгызны күтәрмичә генә күзләрегезне өскә күтәрегез, аска төшерегез. ( 2-3 тапкыр). Уңга, сулга карагыз. ( 2-3 тапкыр).

6.Нәтиҗә.

Безнең эшебез ахырына якынлашты. Әйтегез әле,  без текстиль иҗатының нинди популяр төре белән таныштык? (корамалап тегү). Без бүген нинди чәчәк ясадык? (Лалә чәчәге).

Эш урыннарын җыештыру.

**"Әниемнең серле алкалары"**

***Закирова Рәүзия Мөдәррис кызы,***
***Шәрәфетдинова Лилия Рифат кызы***
*Татарстан Республикасы*
*Арчаның “Чишмәкәй”10 нчы балалар бакчасы*

**Максат:** Татар халкының милли бизәнү әйбере– колок алкасы белән таныштыру һәм аны матур итеп бизәү.

**Бурычлар:** милли традицияләребез нигезендә ятучы кыйммәтле, милли, әхлаклы сыйфатларны саклау;

-татар хатын-кызларының бизәнү әйбере – алка  турында мәгълүмат бирү;

– милли мәдәниятыбызга ихтирам һәм мәхәббәт хисе тәрбияләү.

**Үткәрү формасы:** Мастер -класс



**Җиһазлау:** Компьютер,проектор, әнинең сүрәте, алка үрнәкләре, клей, кайчы, кисточка, салфетка.

**Мастер-класс барышы**

1. **Исәнләшү. Оештыру.**

-Исәнмесез, хәерле көн балалар. Матур сүзләр әйтеп , елмаеп хәлләрне белик.

-Хәерле көннәр, сезгәдә.

-Ничек сезнең хәлләрегез?(балаларның тулы җаваплары)

-Әйдәгез, кәефебезне тагын да яхшыртыр өчен, кулларны кулга куйыйк. Шулай чылбыр төзик. Чылбырыбыз нык булсын,дус булыйк.

-Балалар, менә сезгә бүген минем әни хат җибәргән. Ул Казанга театрга барырга җыена, ә аның алкасы югалган, таба алмый икән. Әйдәгез әле без сезнең белән "әнигә" матур алкалар ясап бирик. Сез ризамы?

-Нәрсә соң ул. алка балалар?(балалар җаваплары)

- Әйе, алка ул хатын-кызның бизәнү әйбере.

АЛКА хатын – кызларның бик яраткан бизәнү әйбере итеп саналган. Элек-электән хатын-кызлар матур киенеп йөрергә тырышканнар. Чәчләрен үреп.чәчнең аскы өлешенә чулпылар элгәннәр, матур алкалар тагырга ятратканнар.

-Алкаларны без татар орнаментларын кулланып ясаячакбыз. Менә, әйтегезче, нинди татар орнаментларын төрләрен беләсез ?(балаларның җаваплары)

-Менә карап китегезче,нинди татар орнаментлары бар икән безнең?

-Балалар, татар халкының үзенә генә хас булган төсләре дә бар. әле(балаларның җаваплары)

-Хәзер үзебезнең остахәнәбезгә барыйк.

**2. Алка эшләү.**

Бүген без үзебезне милли остаханәдә дип хис итик. Үз кулларыбыз белән алка эшләп карыйк. Бу алкаларны тагып сез кунаккада бара алачаксыз

**3. Алка турында белешмә бирүне дәвам итү.**

-"Татар кызын иң элек ишетәсең , аннан гына күрәсең” – дигән әйтем бар. Чыннан да элек татар кызларының бизәнү әйберләре шулкадәр күп булган, атлаган саен чылтырап торганнар алар.

АЛКА хатын – кызларның бик яраткан бизәнү әйбере булган. Шушы матур алкаларны алар бәйрәмнәргә, кунакларга барганда киеп барганнар.

**4. Видео карау.**

(Үрнәк нигезендә әзер өлешләрне ябыштырып җыю)

**5. Эш тәртибе.**

Алка нигезлеген болай ясыйбыз. Каты картон алып,нинди форма кирәк шулай фетрдан кисәбез. Иң башта видео карап алыйк, ничек дөрес эшләү тәртибен күзәтик. Балалар үзләренең кискән нигезлектән алкаларны матур итеп урнаштырып ябыштыралар. Алкалар татар орнаментларыннан киселгән иделәр. Эш башланганнан соң, аларны колакка кию өчен элмәккә тоташтырып куябыз.

- Әфәрин балалар, сезнең алкалар бик матур чыгалар. Бу эш сезгә бик ошый ахрысы.
- Балалар,элмәкне ничек итеп тоташтыруны аңлатып китим. Алканың өске өлешдә кечкенә генә тишек ясап, элмәкне ике яктан тоташтырабыз.

**6. Эшләрне бәяләү.**



Алкаларыгызны киеп, бер-берегезгә күрсәтеп, елмаеп алыйк.

Бик матур булган рәхмәт сезгә! Кул җылысы, бигрәк тә күңел җылысын биреп башкарылган эш һәрчак уңышлы була.

-Мондый алкаларны “Оста куллар” түгәрәгендә дә эшләргә мөмкин.

-Хөрмәтле балалар, мастер- класста актив катнашуыгыз өчен бик зур рәхмәт. Сезнең алкалар бик матур булды.

**«Милли киемле саклаучы (оберег) курчак**

***Муртазина Айназ Рафис кызы***

*Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы*
*“47 нче санлы гомуми үстерешле балалар бакчасы”*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюдҗет учреждениесе*

Безнең көннәрдә кибет киштәләрендә бик күп матур уенчыклар күрергә була: зур-кечкенә, йомшак уенчык дисеңме, электронмы, үзе сөйләшә, атлый торганнары... Әмма

шундый төрлелек булуга карамастан, аларның күбесе бер төсле, фабрика ысулы белән эшләнгән, димәк, ул курчаклар, аларны ясаучының күңел җылысыннан мәхрүм дигән сүз.

Мин исә, балалар, зур тиражлар белән бер типта чыгарылган курчакларны гына түгел, ә үз җанын, осталыгын, яхшы теләкләрен аларга салган, ә иң мөхиме - үз куллары белән эшләнгән уенчыкларны да күрергә, белергә тиеш дип уйлыйм.

Моннан тыш, шундый оберег курчакларны милли киемнәргә киендерү, бик тә отышлы күренеш булып тора. Чөнки милли бизәкләр, орнаментлар халыкның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, рухи байлыгын чагылдыра.

**Курчакны ясар өчен** безгә джут бавы, эрләгән җеп, бер кагәзь бите, линейка, качы һәм кайнар клей кирәк булачак. Әзер курчакны бизәү өчен мили орнаментлы тасмалар, төсле тукыма, бисер кулланылачак.

**Төп эш джут бавын һәм әрләгән җепне үлчәп, кисүдән башлана.**

Курчакның башы өчен: 40 см. 30 җеп.

Чәчләр өчен: 40см. 25 җеп.

Күлмәк өчен: 45см. 50 җеп.

Куллар өчен: 20см. 50 җеп кирәк була.

**Баш ясау тәртибе**

Башны ясар өчен 40см.-лы **джут бавын** һәм курчакның чәчләре буласы, көрән төстәге 40см-лы **эрләгән җепне** алабыз. Бәйләмнәрне бергә кушып, уртадан нык итеп тарттырып бәйлибез. Ясаган бәйләмне, көрән төстәге җепләрне аста калдырып, бөклибез. Шушы әзер бәйләмнең кырыеннан 3см чамасы үлчәп, тагын бәйләп куябыз. Курчакның йөзен формалаштыру өчен, бауларны җайлап кирегә бөклибез, шунда муен ясап, ныклап бәйләп куябыз.

**Куллар ясау тәртибе**

Кулларны, **уч төбе ясаудан** башлыйбыз. 20 см-лы 2 җеп алып, урталай бөгәбез, 1,5см озынлыгында үрәбез. Ике жепне тыгыз итеп бөтереп, элмәк ясыйбыз һәм бәйләп куябыз. Икенче уч шулай ук эшләнелә.

Кул өчен җыелган бәйләмне алып, артык җеп очларын кисэбез. Бәйләмнең уртасына, ясалган уч төбен урнаштырып, бәйлибез.

**Гәүдә ясау тәртибе**

Алга таба, гәүдә ясыйбыз. Инде ясалган курчак башын алып, аннан (баштан) артып төшкән баулар бәйләмен 2 өлешкә бүләбез. Курчакның бите буласы якка джут бауларын күбрәк, ә арка буласы якка азрак итеп аяерабыз һәм ясалган кулларны аралыкка урнаштырабыз. Гәүдәне матурлап формалаштыргач, бәйләп куябыз.

**Күлмәк ясау тәртибе**

Курчакны киендерә башлыйбыз. Күлмәк өчен җыелган бәйләмне уртасыннан ике бертөрле өлешкә бүлеп, җепләрне курчакның җилкәсеннән төшерәбез. Бөтен җепләрне матурлап, тигезләп урнаштырабыз. Һәм күкрәк асты турыннан бәйләп куябыз.



Менә курчак ясалды, формалашты дисәк тә була. Ул ныклап басып торсын өчен, кәгазь битеннән конус ясыйбыз һәм аны айнар клей ярдәмендә, курчакның гәүдәсенә ябыштырабыз. Җепләрне итәк әйләнәсе буенча тигез итеп бүлеп, клей белән ябыштырып чыгабыз.

Курчакның күлмәген халык орнаментлары төшкән тасмалар, тукыма кулланып бизибез. Бизәкле тасма ярдәмендә, камзул да ясыйбыз. Вак һәм эре бисердан муенса, чулпылар җыябыз. Курчакның башына калфак кигерәбез. Ниһаять, милли киемле саклаучы оберег курчагыбыз әзер.

Балаларны менә шушындый курчаклар белән таныштыру, үз халкы белән горурлану, гореф-гадәтләргә һәм тарихка хөрмәт хисе тәрбияләүдә мөһим роль уйный.

Үз милләтебезне генә түгел, ә милләтләр, халыклар арасындагы дуслык, тигезлекне үзләштергәндә генә, бары тик милли хисләр хөрмәт ителгән җирдә генә без яңа буында милләтенә тугры һәм халкына хөрмәт белән карый торган кешеләр үсүен күрербез.

# “Милли белем һәм тәрбия бирүдә яңа инновацион технологияләрне куллану”

# Куар – кодлар технологиясе

***Әхмәдуллина Лилия Илсур кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*“Дөбъяз “Гөлчәчәк” балалар бакчасы,*
*мәктәпкәчә белем бирү бюджет учреждениесе»*

Максат: балаларны мәктәпкә әзерләгәндә, һәр баланың үз юнәлешендә үсү мөмкинлекләре һәм киләчәктә белем алуга омтылыш булдыру өчен шартлар тудыру. Бу максатка ирешер өчен үзем нинди яңа инновацион алымнарны кулланганымны һәм укыту-тәрбия бирүдә эшне ничек җиңеләйтеп булганын күрсәтү.

2023 елның ноябрь аенда мин “Бала-Сити” мультилингваль балалар бакчасында атналык курслар үтеп кайттым. Бу балалар бакчасы белгечләре уйлап тапкан Рәсәйдә һичбер белем бирү оешмасында тиңе булмаган “Акыллы уеннар” программасы буенча укулар иде.Мин бу уеннарның тренеры дигән исемгә лаек булдым, сертификат алып кайттым. Акыллы уеннар- Татарстанда эшләнгән алдынгы уникаль белем бирү программасы. Бу проект Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән тормышка ашырылды.

Уеннарның төп максаты- балаларда татар теленә мәхәббәт ояту, туган телдә сөйләшү күнекмәләрен саклау һәм арттыру, мәдәниятебезне үстерү, уңышлы укыту системасы булдыру, балаларда шәхес формалашу өчен нигез салу. Мондый программа-илебезнең бер төбәгендәдә юк. Бу программа буенча эшләү яңа инновацион технологияләрнең берсе дип саныйм. Бу программага 10 уен кергән.

1. **“Җәйге алан уены”.** Иң кечкенәләр дә уйный алалар. Игътибарлыкны, зирәклекне, тизлекне, вак моториканы үстерә, дус булырга өйрәтә. Таякчык белән дөрес итеп суга да белергә кирәк.

2. **“Читекләр уены”** татар халык аяк киеме белән таныштырудан башлап, андагы татар орнаментлары белән таныштыруны дәвам итә. Шулай ук санарга, төсләрне танып әйтергә өйрәтә, вак моториканы үстерә.

3. **“Түбәтәй”** уены татар халык баш киеме белән таныштыра. Кул моторикасын үстерә. Тизлек белән беррәттән, фикерләү сәләтен үстерә. Бик игътибарлы һәм сабыр булырга өйрәтә.

4. **“Манара”** уены авыр уеннарның берсе. 3d пространствода модель төзү, логик фикерләү, геометрик фигураларны өйрәнүдән тыш, аларны яссыда күрә белергә өйрәтә. Мисал өчен цилиндрны пространствода борсак анны түгәрәк итеп тә күреп була, турыпочмаклык итеп тә күреп була.

5. **“Кара-кара”** уены бик күңелле төркем уены. Җитезлекне,тизлекне, тапкырлыкны, логик фикерләүне үстерә. Математикадан кушу һәм алу кергән бу уенга. Шулай ук төсләрне татарча өйрәнү һәм кабатлау.

6. **“Башваткыч”** уены. Икенче төрле танграмм уены. Бик авыр уен. Шулай ук 3д фигураларны яссылыкта күрә белергә өйрәтә. Логик фикерләү беренче урында.


7. **“Мин булдырам”** уены. Геометрик фигураларны, төсләрне кабатлау.


8. **“Нәрсә бу?”** уены бер генә кисәктән, рәсемдәге сүрәтне танып белергә өйрәтә. Бу уенның максаты- барлык сүрәтләрне татарча әйтә белергә кирәк. Рус телле балалар да бик тиз отып калалар сүзләрне.

9. **“Мин төзүче”** уенын уйнар өчен игътибарлык һәм түземлек кирәк.


10. **“Тылсымлы сөлгеләр”** уенында геометрик фигуралар, төсләр белән таныштыру бара. Шулай ук логик фикерләүне үстерү, фигураларны яссылыкта төрле яктан күрә белергә өйрәтә.

“Нәрсә бу?”-уены аша яңа инновацион технологияләрнең икенче ысулы белән таныштырасым килә. Мисал өчен, карточкада “Шалкан” сүрәте килеп чыга. Шалкан турында әкиятне җайлы гына телефон аша интерактив тактага чыгару юлын таптым. Башта телефонда “Связь с Windows” дигән кушымта күчереп куябыз. Аннары ноутбукта “Связь с телефоном” дигән кушымта күчерәбез. Бу кушымтаны кушкач, телефон эзләп табылачак. Һәм телефон аша гына теләгән видеоны яки сүрәтне туп-туры такта аша карап була. Кыскача әйткәндә, телефон экранында нәрсә күренә, шул интерактив тактага күчерелә. Бик җайлы ысул дип таптым үзем өчен. Чөнки вакытны алмый дип әйтсәк тә була. Тиз һәм уңайлы ысул.








Шулай ук төрле мәгълүматне, картинамы ул, яисә видеомы җайлы гына “QR-код” аша да карап була. “QR-код”ны ничек ясап була. Беренче адым итеп үзебезнең эшли торган браузерга керәбез (Яндекс, Google һ.б), һәм кирәкле мәгълүмәтне эзләп табабыз. Минем очракта “Шалкан” турында әкият. Икенче адым-видеоның сылтамасын күчереп алабыз (ук белән күрсәтелгән). Аннары генератор “QR-код”ов дигән сайтны ачарга кирәк.




Сайтны ачкач видеоның ссылкасын (адресын) беренче ак турыпочмаклыкка күчереп куярга кирәк. Монда кызыл галочка белән күрсәтелгән, аннары “Создать код» дигән турыпочмаклыкка басарга кирәк. Монда зәңгәр ук белән күрсәтелгән. Уң якта безгә кирәкле әзер QR-код килеп чыгачак. Шушы QR-кодны кәгазьгә чыгарып




кирәкле сүрәт янына ябыштырып куя аласыз. Минем очракта “Шалкан” ясалган карточкага ябыштырылган. Телефонда “Сканер QR-код”ов дигән кушымта аша, интерактив тактага (икенче ысулны кулланып) чыгарып карап була.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә, инновацион ысуллар куллану, беренчедән вакытны экономияли, икенчедән, өстәмә мәгълүмат бирә, өченчедән, балаларга төрле дәрәҗәдәге биремнәр бирергә мөмкинлек бирә.



# “ Мультфильм төшерү ”

***Хәбирова Алинә Равил кызы***

*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы*
*Теләче 2нче балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү*
*муниципаль бюджет учреждениесе*

Федераль белем бирү программасы максаты баланың мәктәпкәчә яшьтәге чорында, рухи-әхлакый кыйммәтләр, шулай ук Россия Федерациясенең тарихи һәм милли-мәдәни традицияләре нигезендә яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, һәрьяклап үстерү.

Федераль белем бирү программасы нигезендә, бала үзенең туган телендә сөйләшергә һәм үзенең гореф гадәтләре, туган ягының тарихы белән танышырга тиеш. Ничек итеп балаларны кызыксындырырга соң? Ничек итеп балага моны җиткерергә?

Балаларның көн дәвамында күтәренке кәефләре саклансын, алар балалар бакчасында уеннар аша әйләнә-тирәне танып белсеннәр, туган телләрендә аралашсыннар, сөйләм телләрен камилләштерсеннәр өчен төрле эшчәнлек алып барам. Ничек итеп бу көндәлек эшчәнлекне төрләндерергә? Ничек итеп балаларда кызыклы, мавыктыргыч формада туган телләренә, татар халык иҗатына, уеннарына, тарихына, гореф-гадәтләренә өйрәнүгә теләк үстерергә? Бу сорауларга җавап эзләү мине яңа программалар, методикалар, технологияләр белән танышырга этәрде.

Шушы эзләнүләр нәтиҗәсендә, педагогиканың күрсәтмәлелек принцибы күздә тотып, мин балалар белән бергә авторлык туган татар телебездә мультфильмнар төшерергә булдык.

Иң беренче эш итеп, мультфильмнар төшерү проектын башлар алдыннан без үз алдыбызга максат һәм бурычлар куйдык.

Максатыбыз: баланың мәктәпкәчә яшьтәге чорында, рухи-әхлакый кыйммәтләр, шулай ук Россия Федерациясенең тарихи һәм милли-мәдәни традицияләре нигезендә яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрне исәпкә алып, һәрьяклап үстерү.

Бурычлар:

– балаларда мультфильм ясауга теләк булдыру;

– эзлеклелеген үзләштерүдә элементар техник белем һәм күнекмәләрне үстерү;

– татар халкының традицияләрен, фольклорын кулланып, балаларның сөйләм, сәнгать һәм иҗат мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итү, белемнәрен ныгыту;

Мультфильм ясаганда түбәндәге этапларны алдык.

Татар милләтенә хас сюжет уйлау.

Атрибутлар табу (пластилиннан курчаклар ясау).

Мультфильм өчен кадрларны фотога төшерү.

Тавыш яздыру (программа ярдәмендә).

Монтажлау (bolide movie creaton-программасын кулланып).

Төшерелгән мультфильмны карау.

1 нче этап

Уйланылган (тар халкының гореф-гадәтләре, фольклорына нигезләнгән һәм образланган) уен ситуациясен тудыру: Балалар: – беренче - элек өйрәнелгән күнекмәләрне куллана ала; икенче- яңа чишелешләр эзлиләр; өченче- мөстәкыйльлек инициативасын күрсәтәләр. Шулай итеп, балаларда уңай хис-кичерешләр, үз гамәлләренә ышаныч, иҗат итү теләге уятыла башлый.

Балалар өчен бу яңалык үз идеяларын һәм иҗатын традицион булмаган юллар белән тормышка ашыру. Узган уку елында без балалар белән бергә бу технологияне өйрәнеп һәм кулланып үзебез туган телне камилләштерү, табигатькә сакчыл караш уяту, һәм юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту нигезеннән мультфилемнар булдырдык. Үзебезнең мультфилемнарыбыз белән район һәм республика күләмендә җиңүчеләрдә рәтенә кердек.

Сюжетларга килгәндә, балалар аларны үзләре уйлый. Шулай итеп, аларның фантазияләре эшкә җигелә.

Төрле сюжет сызыкларыннан иң ошаганын сайлап алып, эшне башлыйбыз. Атрибутлар ясау бик кызыклы. Балаларга төрле мультфильмнар төшерү өчен геройлар (пластилиннан курчаклар) ясау – шулай ук төп мәсьәләләрнең берсе. Аларны без йомышак пластилиннан, фетрдан кисеп тә ясыйбыз.

Шулай итеп, балалар белән берлектә, киң күләмле, дәвамлы эш алып барыла. Эшчәнлектә федераль белем бирү программасы буенча куелган барлык белем бирү өлкәләре дә катнаша: балалар рәсем ясый, кисә, әвәли, ябыштыра, бии, җырлый,саный, сөйли, фикер йөртә.

Бу күпкырлы лабороториядә без һәрвакыт яңа шартлар тудырырга тырышабыз, кызыксындырабыз,төрле материаллар, оригиналь технологияләр кулланабыз, сайлап алу мөмкинлеге бирәбез. Балалар бик кызыксынып эш алып баралар, икенче төрле әйтсәк, алар монда кайныйлар, иҗат итәләр. Шуңа эшләрендә күңелсез, бер төрлелек юк. Балалар өчен бик кызык: тулысы белән әлеге процесска кереп китәләр. Бу эштә, билгеле, безгә бакча мөдире, әти-әниләр белән хезмәттәшлек бик зур ярдәм итә. Шул рәвешле “Video Guru” һәм “Stop motor” кушымтасында эшне үзләштерәбез, яссы һәм күләмле мультфильмнар ясарга, кадрлар төшерергә, фон сайларга өйрәнәбез.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: әлеге проектның кызыклы һәм уңышлы булуы нәкъ менә милли традицияләрнең заманча технологияләр белән үрелеп баруында, дип уйлыйбыз.

Үз өстенлегемне үзгәртмичә, үз эшчәнлегемдә мин ике технологияне калдырырга булдым, чөнки алар икесе дә бик нәтиҗәле булып чыктылар.

Бу күрсәткечләр миңа алга таба да яңа идеяләр кертү, тәрбия һәм белем бирү процессында яңа методикалар, технологияләр куллануга этәргеч бирә.

**“Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтүдә предметлы тирәлекнең нәтиҗәле мөмкинлекләрен куллану”**

***Хидиятуллина Алсу Наил кызы***
*Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе*
*“Солнышко" Биектау балалар бакчасы"*
*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтүдә ESL һәм физик җаваплылык ысуллары нигезендә эшләнгән уеннарның кулланылу нәтиҗәсен күрсәтү.

**Бурычлар:**

- ✓ мәктәпкәчә яшьтәге балаларны уен эшчәнлеге нигезендә көндәлек тормышта бер – берсе һәм олылар белән татар телендә аралашырга өйрәтү;
- ✓ балаларның элемтә чарасы буларак сөйләм телен камилләштерү;
- ✓ сүз байлыгын арттыру, сөйләм кунекмәләрен формалаштыру;
- ✓ коммуникатив белем кунекмәләрен, татар телендә аңлау, гади сорауларга җавап бирә белүне үстерү;
- ✓ әдәпле аралашу кунекмәләрен, татар теленә карата мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** уенчылар саны буенча урындыклар, “Яшелчә”, “Җиләк – җимеш”, “Мәктәп кирәк яраклары”, “Ризыклар”, “Уенчыклар”, “Гаилә әгъзәлары” темасына караган карточкалар, туп, рус һәм татар телендә темалар язылган карточкалар җыелмасы, түгәрәк өстәл, өчке яктан җәнлекләрнең хәрәкәтен аңлаткан сүрәтләре ябыштырылган стаканннар, 1 – 5 кадәр саннар күләмендә һәм төрле төстә булган предметлар төшерелгән карточкалар җыелмасы, төсләр (сары, кызыл, зәңгәр, яшел) төшерелгән дүрткырлы шакмак, 1 – 5 кадәр саннар күләмендә нокталар төшерелгән дүрткырлы шакмак, командалар өчен фишкалар, алып баручы өчен бейджлар.

**Мастер – класс барышы:**

**1. Кереш өлеше:**

Хәерле көн хөрмәтле хезмәттәшләр!

Күп кенә галимнәр, тәрбиячеләр һәрдаим телне өйрәнү, үзләштерүнең яңа ысулларын эзләп табып, кулланылуга кертүдә күп көч куялар. Хәзерге көндә төрле алымнарга нигезләнгән үзенчәлекле методлар һәм методикалар бик күп.

Балаларны икенче телгә өйрәтүдә иң нәтиҗәле методлар булып ESL һәм физик җаваплылык методикалары тора.

**ESL методикасының максаты** булып, билгеле бер телдә мөмкин кадәр тиз вакыт аралыгында даими сөйләм кунегүләре аркылы, сөйләшү, аралашуны устеру. Әлеге ысул узенең тамырларын икенче телгә өйрәтү методы буларак Германия һәм Франциядән алган.

**Физик җаваплылык методының максаты –** сүз һәм гамәл кординациясенә нигезләнеп тел өйрәтүдән гыйбәрәт. Әлеге телгә өйрәту методы физик (хәрәкәт) җитезлелек аркылы үзләштерелә. Бу методны 20 гасырның 60 – 70 нче елларында Америка психологы Джеймс Ашер дөньяга таныта. Аның төп нигезе – уен һәм хәрәкәт.

Элеге методикаларны кулланып без мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтү өчен кызыклы уен җыелмаларын барлыкка китердек.Элеге уеннар өчен без кул астында булган, уңайлы, көндәлек тормышты куллана ала торган матералларны алдык. Бүген шушы җыелмага кергән берничә уен белән сезне дә таныштырып китәсебез килә. Мастер – класcның практик өлешенә күчәбез. Беренче уен “Җырлы урындыклар” дип атала.

**2. Практик өлеш**

**“Җырлы урындыклар” уены**

**Максат:** балаларның “Кем?”, “Нәрсә?”, “Нинди?” сорауларына җавап бирә белүен ныгыту.

**Җиһазлар:** уенчылар саны буенча урындыклар, “Яшелчә”, “Җиләк – җимеш”, “Мәктәп кирәк яраклары”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Гаилә әгъзәлары” темасына караган карточкалар.

**Уен барышы:** уенда катнашучылар саныннан бергә ким сандагы урындыклар янына килеп уенчылар түгәрәк ясап басалар. Утыргычлар өстенә кире ягы белән төрле сүрәтләр төшерелгән карточкалар салынган. Музыка башланып китү белән уенчылар түгәрәк буенча хәрәткәтләнә башлыйлар. Музыка туктау белән утыргычтагы карточканы кулга алып урындыкка утырырга кирәк. Урынсыз калган уенчы уенны алып баручы ролен үз өстенә ала. Уенчылар “Кем?, “Нәрсә?”, “Нинди?” сорауларына таянып карточкада нәрсә сүрәтләнгәнен аңлатып бирергә тиеш булалар. Дөрес җавап бирмәгән уенчы уеннан чыга. Ә инде алып

баручы шул уенчының урынын ала. Җавап дөрес булса алып баручы узе уеннан чыга. Уен бер уенчы калганчыга кадәр уйнала.



**“Мин биш .... атамасын беләм” уены**

**Максат:** балаларның лексик минимумын ныгыту.

**Җиһазлар:** туп, рус һәм татар телендә темалар язылган карточкалар җыелмасы.

**Уен барышы:** бу уен ирекле рәвештә парларга бүленеп уйнала. Парларга бүленгәннән соң, парның бер уйнаучысы карточка сайлый, ә икенче катнашучысы кулына туп ала. Туп алган уйнаучы тупны идәнгә бәрү белән беррәттән карточкада язылган темага карата сүзләрне бер – бер артлы атап чыгарга тиеш була. Уенны “Мин биш .... атамасы беләм” дип башлап, бер – бер артлы темага туры килгән сүзләрне санап чыгарга кирәк. Дәвам итеп уенчылар урыннары белән алышыналар, уен янәдән кабатлана.

**“Серле стаканнар” уены**

**Максат:** “Нәрсә?”, “Нишли?” сорауларына таянып җәнлеклекләр, аларның хәрәкәтләрен аңлаткан сүзләрне сөйләм телендә ныгыту.

**Җиһазлар:** түгәрәк өстәл, өчке яктан җәнлекләрнең хәрәкәтен аңлаткан сүрәтләре ябыштырылган стаканнннар.

**Уен барышы:** бу уенның эчтәлеге бик гади һәм аңлаешлы. Уенчыларга өстәл тирәли куелган стаканнарга капма – каршы түгәрәк ясап басырга кирәк. Билгеле бер ритмик музыка астында сулдан алып уңга таба “Алдым – куйдым” такты буенча стаканнар уенчылар буенча күченеп баралар. Бары тик музыка туктагач кына һәр уенчы уз каршында туктап калган стаканны әйләндереп алып карап андагы сүрәтнең нәрсә аңлатканын “Нәрсә?”, “Нишли?” сорауларына таянып җавап итеп, аңлатып бирергә тиеш була. Барлык уенчылар сорауларга җавап биргәннән соң стаканнарны бутап янәдән төзеп куеп уенны дәвам итергә була.

**“Карточкаларны туры китер”**

**Максат:** балаларны “Бу нәрсә?”, “Нинди төстә?”, “Ничә?” сорауларын кулланылып җавап бирә белергә өйрәтү, бирелгән биремгә тиешле карточканы тиз сайлый белүдә күнектерү.

**Җиһазлар:** 1 – 5 кадәр саннар күләмендә һәм төрле төстә булган предметлар төшерелгән карточкалар җыелмасы, төсләр (сары, кызыл, зәңгәр, яшел) төшерелгән дүрткырлы шакмак, 1 – 5 кадәр саннар күләмендә нокталар төшерелгән дүрткырлы шакмак, командалар өчен фишкалар, алып баручы өчен бейджлар.

**Уен барышы:** уен ике командага бүленеп уйнала**.** Уенчылар ирекле рәвештә ике командага бүленә. Командалар ике рәт ясап төзелеп басалар. Уенчылар алдында ике өстәл тора. Беренче өстәл өстендә ике төрле кубик һәм фишкалар, ә икечесендә карточкалар. Һәр командада алып баручы сайлана, билгеләмәсе бирелә. Команда буенча алып баручылар кубикларны атып узләренең командасына бирем бирә. Алып баручыдан кала, башка уенчылар икенче өстәл янына барып биремгә туры килгән карточканы алып килеп басалар. Команданың барлык уенчылары кире урыннарына килеп баскач кына алып баручы куелган биремнең дөрес үтәлгәнме, юкмы икәнлеген «Бу нәрсә?», «Нинди төстә?», «Ничә?» соруларына таянып тикшереп чыга. Бирем дөрес үтәлгән очракта командага бер фишка бирелә. Дәвам итеп команданың алып баручысы үзгәрә. Уен уенда катнашучы һәр уенчы алып баручы ролендә булып чыкканчыга кадәр уйнала, фишкалар санала, җиңүче команда билгеләнә.

### 3. Йомгаклау өлеше

Мастер – классның азагында минем сезгә тагын бер бик җиңел уен тәкъдим итәсем килә. Уен “Дөрес – дөрес түгел” дип атала. Әгәр сез мин биргән сорау дөрес дип уйлыйсыз икән сезгә алкышларга кирэк булачак, ә дөрес булмаса бернидә эшлисе түгел. Димәк:

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсешенә юнәлтелгән кайбер педагогик мәсьәләләрне төрле методлар ярдәмендә чишеп була.
2. Мин әлеге методларны үз эшемдә кулланырга телим һәм кулланырмын.
3. Уен эшчәнлеге баланың күпкырлы үсешенә тәэсир итә.

Сезгә киләсе эшләрегездә уңышлар телибез. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

**“Милли белем һәм тәрбия бирүдә цифрлы технологияләрне куллану”**

***Галиәхмәтова Рәсилә Харис кызы***
*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының*
*Шәле «Тургай» балалар бакчасы муниципаль бюджет*
*мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

*“Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр”*
*Р.Фәхреддин*

Заманча бала үсә торган дөнья аның әти-әнисе үскән дөньядан аерыла.

Бүген ул - цифрлы технологияләр дөньясы. Анда кешеләрне гаджетсыз күз алдына китерү мөмкин түгел: кәрәзле телефоннар, планшетлар, компьютерлар – алардан башка без хәзерге тормышыбызны күз алдына да китерә алмыйбыз.

Безнең балалар барлык төрле цифрлы технологияләрне шундый җиңел үзләштерәләр, олылар гаҗәпләнәләр генә: әле сөйләшергә дә өйрәнмәгән, ә инде планшетын кабыза һәм сүндерә белә, телефон белән уйнарга сорый яки каналларны яраткан мультфильмына ничек күчерергә икәнен белә.

Балалар бакчасында мәгълүмати – коммуникатив технологияләрне куллану мәктәпкәчә белем бирүнең мөһим яңалыгы булып тора. Күпләр һәтта үз дәресләрендә ничек кулланырга икәнен аңламый. Минемчә, аларны дөрес кулланганда, цифрлы технологияләр үзләрендә бик зур үсеш бирә торган, мәгариф һәм тәрбия ресурсын алып бара.

Үземнең белем бирү эшчәнлегендә цифрлы технологияләрне актив кулланам. Минемчә, техник чараларны дөрес кулланганда, цифрлы технологияләр үзләрендә бик зур үсеш бирә торган, мәгариф һәм тәрбия ресурсын алып бара.

Цифрлы технологияләр, бу компьютерлар һәм аларның программа тәэминаты гына түгел. Цифрлы технологияләр дигәндә оештыруның инновацион ысулы күздә тотыла – күрсәтмәлелекне тәэмин итә торган электрон ресурслардан файдалануга нигезләнгән белем бирү процессын.

Үз эшемдә киң кулланган технологияләрнең берсе – «QR - код» технологиясе – тәрҗемәдә «тиз җавап» дигәнне аңлата. Бу технология күбегезгә яхшы таныш, хәзерге вакытта

ул бөтен җирдә кулланыла. Әлеге технологияне үземнең һөнәри эшчәнлегемдә, балалар бакчасының бер мәгариф проекты мисалында ничек куллануымны аңлатасым килә. Мисал өчен, «Мәктәпкәчә финанс академиясе» дигән озак вакытлы проектны алыйк, ул безнең балалар бакчасында гамәлгә ашырыла. Бу проект, мөгаен, балалар бакчасындагы барлык төрле проектлар кебек үк, балалар, балалар һәм тәрбиячеләр, балалар һәм ата-аналар арасында үзара хезмәттәшлекне оештыруга корылган. Һәрбер шундый хезмәттәшлек кысаларында билгеле бер эш планы төзелә.

Балаларның үзара хезмәттәшлеген оештырганда, аларның дәресләрдән буш вакытта уен формасында, бу тема буенча дәресләрдә белгәннәрен кабатлау һәм эшкәртү мөмкинлеге булуын теләдем. Мәсәлән, гыйнварда безнең алда балаларны башка илләрнең валютасы белән таныштыру, байлык төшенчәсен аңлау һәм башка бурыч тора иде. Мин үземнең тәрбияләнүчеләр өчен QR-кодлы китапчыклар эшләдем. Алар белән шогыльләнер өчен безнең төркемдә иректе кулланылышта булган планшетлар бар. Китаплардагы барлык видеороликлар бик кыска һәм мәгълүмати, вакыт буенча сузылмаган. Бала планшет белән озак эшләмәсен өчен, һәр китапта практик юнәлешле иҗади бирем бар.

Шулай итеп, балалар арасындагы үзара хезмәттәшлекне оештырып, мин балаларда кирәкле мәгълүматны табу һәм белемне мөстәкыйль алу күнекмәләрен үстерү өчен, алшартлар тудырам.

Оешкан белем бирү эшчәнлеге вакытында, балалар белән эшләү өчен, мин үстерә торган интерактив уеннар картотекасын эшләдем, шулай ук QR-код технологиясен кулланып. Ул үз эченә инде 50 дән артык уенны ала.

Интерактив уенны үзләштерү барышында балаларда яңа белем һәм тәҗрибә барлыкка килә, алар уен аралашу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Уенны индивидуаль рәвештә дә, бөтен төркем белән дә уйнарга мөмкин. Интерактив уеннарны гади программалар (Microsoft Office PowerPoint, Paint) һәм электрон ресурслар кулланып үзем эшлим. Мин балалар өчен интерактив уеннарның берничә төрен эшләдем. Аларны дәресләрдә дә, режимлы моментларда да кулланам. Шулай ук балалар үзләре дә мөстәкыйль эшчәнлек вакытында уйный алалар.

Нәкъ менә QR-код технологияләре һәм интерактив уеннар, үз эшчәнлегемдә иң нәтиҗәле дип саныйм. Әлбәттә, болар мин кулланган барлык цифрлы технологияләр дә түгел. Шулай ук аудиокитаплар кулланам, бергәлек алып барам, балалар белән видеороликлар, мультфильмнар булдырам.

Минем эшчәнлектә цифрлы технологияләрне куллану инде үз нәтиҗәләрен бирә.

Без балалар белән республикакүләм олимпиадаларда, танып белү үсеше буенча викториналарда катнаштык, анда тәрбияләнүчеләрем призлы урыннар алды. Үзем дә шулай ук төрле дәрәҗәдәге конкурсларда актив катнашам, призер һәм җиңүче булам.

Минем үз остазларым бар, алар мине дәресләр төзү методикасына өйрәтә, балалар өчен дидактик биремнәрне дөрес сайларга ярдәм итә, әмма мин дә алар өчен остаз булып торам - мин аларны цифрлы технологияләргә өйрәтәм.

Цифрлы технологияләр - ул киләчәктә киң кулланылышта булачак технологияләрнең берсе. Үземнең педагогик эшчәнлегемдә цифрлы технологияләрне кулланып, мин балаларда алган белемнәремне заманча дөньяда куллану күнекмәләрен үстереп кенә калмыйм, шуның белән берлектә үзем дә камилләшәм.

# ПРОЕКТ ЭШЛӘРЕ



# “Татар халкының милли мирасы”

***Шәрипова Энҗе Госман кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының*
*Дөбъяз “Гөлчәчәк” балалар бакчасы*
*мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

**Кереш.**

Җәмгыятебезнең, милләтебезнең киләчәге яшьләрне тәрбияләүче эти - әниләрдән һәм бездән тора. Татар халкының гасырлар буена тупланып килгән тормыш тәҗрибәсен, дөньяга карашын, бай традицияләрен, идеалларын яшьләргә эзлекле рәвештә төрле чаралар ярдәмендә житкерә алсак, без бөтендөнья һәм милли культурага ия булган гражданнар — киләчәгебезгә өмет уятучы шәхесләр тәрбияли алырбыз. Рухи таләпләр тәрбияләүдә кешелек шактый бай тәҗрибә туплаган. Ләкин вакытлар үтү, заманалар үзгәрү, бу таләпләргә үзгәреш кертүгә ихтыяҗ тудыра.

**Проектың актуальлеге.**

Бердәм булып, иңне – иңгә куеп,
Күмәкләшеп йөкне тартмасак,
Милләт язмышына битарафлык
Күрсәтүгә аяк атласак,
Кем соң безгә ата – бабаларның
Гореф – гадәтләрен саклашыр?
Татар телен, ата – ана телен
Читтән килеп кемнәр яклашыр?

Хәзерге чорда радио һәм телеведение, урам тәрбиясе балаларның аңына һәм рухына әдәпсезлек үрнәкләрен дә сеңдерә. Алар милләтнең гасырлар буе формалашкан әхлак кагыйдәләрен кире кагалар. Мондый шартларда мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә нәниләрне халкыбызның күркәм аралашу традицияләре нигезендә тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирелергә тиеш. Ана телендә тәрбияләнгән бала гына үз милләтенә, аның теленә һәм гореф – гадәтләренә чын мәгънәсендә ихтирамлы була.

Безнең киләчәк, халыкның алдагы язмышы яшьләрнең бүгенге тәрбиясе белән бәйләнгән. Шуңа күрә яшь буынны максатчан тәрбияләү - аеруча кирәкле эш һәм монда хәл итәсе мәсьәләләр бик күп.

Балаларны халкыбызның күңел бизәкләре белән якыннан таныштыру, нәфис бизәлешенә соклану, эстетик зәвык аша әхлак тәрбиясе бирү – бүгенге көндә дә актуаль булып кала.

**Проект эшенең максаты:**

-мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар халкының тарихы, мәдәнияте һәм көнкүреше белән таныштыру. Татар халкының гасырлар буена тупланып килгән мирасын, күңел бизәкләренең матурлыгын балаларга җиткерү.

**Проект эшенең бурычларны:**

- балаларның йөрәкләренә мәдәни мирасның бишеген салу.

- мәктәпкәчә яшьтәге балаларны музей дөньясы, үткән елларда халыкларның тарихы, мәдәнияте һәм көнкүреше, татар халык иҗаты белән таныштыру.

- халкыбызның рухи хәзинәләре нигезендә балаларның сөйләм телен баету, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү;

- Татарстанның тарихи үткәненә хөрмәт хисе формалаштыру.

- балаларның күңелендә милли мәдәниятkә мәхәббәт, үз тамырларын, милли чыганакларын аңлаган шәхес тәрбияләү.

**Проектта катнашучылар:** зурлар төркеме балалары (5-7 яшь), ата-аналар, музыка җитәкчесе, тәрбияче.

**Проектның төре:** иҗади-эзләнүле, мәгълүмати юнәлештә.

**Гамәлгә ашырылу вакыты:** 2 ел.

**Проект эшчәнлегенең тәэмин ителүе:**

- күргәзмә һәм дидактик материаллар, проектта куллану өчен татар халкының милли иҗаты турында кирәкле материал туплау.

- кул эшләре күргәзмәсе булдыру.

-татар халык аваз иҗатын куллану.

**Проекттан көтелгән нәтиҗәләр:**

Үз яшенә карап, узган гасыр кешесенең тарихы, мәдәнияте һәм көнкүреше буенча мәгълүматка ия булырга тиешләр.

-балаларның туган телдә дөрес, матур итеп аралашырга, татар халкының электән сакланып килгән бәйрәмнәрен, йолаларын өйрәнү.

- халык-аваз иҗаты белән кызыксыну, аңа хөрмәт белән карау.

- әхлаклылык, әдәплелек кебек сыйфатлар тәрбияләү.

**Проектның планы:**

**1 нче (2024-2025) уку елы (зурлар төркеме)**

| **№** | **Ай** | **Тема** | **Максат, бурычлары** | **Метод һәм алымнар** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Сентябрь | Хуҗабикәдә кунакта | Балаларны татар халкының торагы белән таныштыру. Торакны ничек төзегәннәр: гореф-гадәтләргә кызыксыну, өлкәннәргә карата хөрмәт уяту.<br>Сүзлек эше: өй, бүрәнә, мүк, тәрәзә йөзлекләре.<br>Балаларның сөйләмен татар телендәге мәкальләр, әйтемнәр белән баету. Үткәнне танып белүгә кызыксыну тәрбияләү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия. Хуҗабикә белән очрашу.<br>Әңгәмә. Өйне карап чыгу. (өй макеты). Тәрбияче аңлатмасы. Сүзлек эше.<br>Уен. “Хуҗа хатынга кем тизрәк ярдәм итәр” Йомгак ясау. |
| 2 | Октябрь | Борынгы әйберләр дөньясы. | Балаларны музей экспонатлары белән таныштыруны дәвам итү. Сүзлекне активлаштыру: мич, табагач, кисәү, көянтә, йорт кирәк-яраклары. Хуҗалыкта моның ничек кулланылганын күз алдына китерү, сөйләм телендә мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар куллану. Халык көнкүреше белән кызыксыну тәрбияләү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия. Экспонатларны карау. Тәрбияче аңлатмасы. Сүзлек эше.<br>Уен: “Көянтә белән суны кем тизрәк китерер”.<br>Йомгак ясау. |
| 3 | Ноябрь | Озын кичләрдә оста куллар ниләр майтарган? | Үткәндә эш коралларының җитен, йон, җепсел эшләнмәләр эшкәртү буенча нинди урын алып торганын балаларга аңлату. Балаларның сүзлек эше: каба, орчык, тарак.<br>Балаларда танып белү сыйфатларын формалаштыру.<br>Балаларны “Өч кыз” әкияте белән | Балалар бакчасы музеена экскурсия. Хуҗабикә белән очрашу.<br>Экспонатларны карау. Тәрбияче аңлатмасы. Сүзлек эше.<br>Уен: “Кем тизрәк йомгак чорный” “Өч |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | таныштыру.<br>Хезмәт сөючәнлек тәрбияләү. | кыз” әкиятен уку.<br>Йомгак ясау. |
| 4 | Декабрь | Эшче куллар ял белми. | Балаларны авыл хуҗалыгы эшләре өчен эш коралы белән таныштыру.<br>Сүзлек эше: сабан, чалгы, тырма, урак, пычкы, чүкеч.<br>Балаларны “Башак” әкияте белән таныштырыру.<br>Кызыксынучанлыкны үстерү.<br>Өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Экспонатларны карау.<br>Тәрбияче аңлатмасы.<br>Сүзлек эше.<br>Әкият уку: “Башак”.<br>Хезмәт турындагы мәкальләр.<br>Йомгак ясау. |
| 5 | Гыйнвар | Кул эшләре осталары | Балаларны узган гасыр кул эшләре белән таныштыру. Балаларда үткән тарихка кызыксыну формалаштыру. Сүзлек эше: чигүче, уймак, алъяпкыч, ашъяулык, пәрдәләр.<br>Балалар фольклоры белән таныштыруны дәвам итү. “Кемдә яулык” уенына өйрәтү. Матурлыкны күрә белү, чигүченең хезмәтенә соклану хисе тәрбияләү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Сюрприз момент: “Әбием сандыгы”<br>Экспонатларны карау.<br>Тәрбияче аңлатмасы.<br>Уен: “Яулыгың кемдә?”.<br>Йомгак ясау. |
| 6 | Февраль | Без элек шулай киенә идек. | Балаларны милли киемнәр белән таныштыруны дәвам итү.<br>Борынгы замандагы татар киемнәрен карау. милли костюмның бизәлеше белән танышу.<br>Сүзлек эше: калфак, түбәтәй, камзул, читек. Сөйләм телен үстерерү.<br>Толерантлык тәрбияләргә. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Сюрприз моменты “Әбием сандыгында төрле киемнәр”<br>Кием-салымны карау.<br>Уен: «Курчакны дөрес киендер". “Курчакның ничек киенгәнен сөйләп бир”. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Йомгак ясау. |
| 7 | Март | Нинди бәйрәм ул – “Нәүрүз?” | Балаларны татар милли бәйрәме “Нәүрүз”: аның тарихы, кайчан уздырылуы, бу бәйрәмдә нинди гореф-гадәтләр үтәлүе белән таныштыру.<br>Балалар сүзлеген баету. Танып-белү белән кызыксынуны үстерү.<br>Татар халкының гореф-гадәтләренә хөрмәт хисе тәрбияләү. | “Нәүрүз” булып киенгән курчак.<br>Тәрбияче аңлатмасы. (ни өчен бүген курчак матур итеп киенгән?)<br>Тәрбияченең бәйрәм турында сөйләве. Яз турында мәкаль-әйтемнәр.<br>Җыр: “Яз тормышы”.<br>Уен: “Инеш”<br>Йомгак ясау. |
| 8 | Апрель | Чырадан алып электр лампасына кадәр. | Балаларны керосин лампасы белән таныштыру. Аның ничек эшләвен, элек кешеләрнең электрсыз ничек яшәүләрен күз алдына китерү.<br>Балаларның сүзлек запасын баету: чыра, шәм, керосин лампасы, керосин, корым, электр.<br>Балаларда тикшеренү сыйфатын формалаштыру.<br>Кызыксынучанлык тәрбияләү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Экспонатларны карау.<br>Тәрбияче аңлатмасы. (элек өйне ничек һәм нәрсә ярдәмендә яктырткannар)<br>Сораулар: -әгәр электр булмаса, нәрсә булыр иде? Уен: "Ян, ян учак".<br>Йомгак ясау. |
| 9 | Май | Туган ягыңны ярат һәм аның турында җырла. | “Сабантуй” бәйрәме турында төшенчә бирү:<br>-Сабантуйга бүләкләрне ничек җыялар,<br>-бәйрәмне ничек үткәрәләр, -бәйрәм нәрсәгә багышлап үткәрелә.<br>Балаларда танып-белү эшчәнлеген үстерергә. | Сабантуй турында җыр яңгырый. Тәрбияченең “Сабантуй” бәйрәме турында сөйләве. Иллюстрацияләрне карау.<br>Шигырьләр уку. «Сабантуй» бәйрәмен балалар әти-әниләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Татар мәдәнияте белән кызыксыну тәрбияләү. | белән ничек үткәрәләр, шул хакта әңгәмә. Уен: “Капкаллар”, “Түбәтәй”. Йомгак ясау. |

**2 нче (2025-2026) уку елы (мәктәпкә әзерлек төркеме)**

| № | Ай | Тема | Максат, бурычлар | Метод һәм алымнар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Сентябрь | Безнең өйгә рәхим итегез. | Борынгы йортлар белән таныштыруны дәвам итү. Балалар сүзлеген баету: сәке, Ак өйдә, мичтә. Балаларны кунакчыллык турындагы мәкальләр һәм әйтемнәр белән таныштыру. | Балалар бакчасы музеена экскурсия. Макет: өйнең эчке төзелеше һәм бизәлешен карау. Тәрбияче аңлатмасы. Сүзлек эше. Уен: “Буш урын”. Йомгак ясау. |
| 2. | Октябрь | Ак күлмәкле мич. | Балаларны йортның төзелеше, аның төп истәлекле урыны - Мич белән таныштыруны дәвам итү. Өйдәге мичнең берничә функция үтәгәнен күз алдына китерү өчен: анда ипи пешергәннәр, кышка азык - төлек әзерләгәннәр, җиләк-җимеш, гөмбә киптергәннәр, дәваланганнар, җылынганнар: мич салу һәм мичченең серләре турында аңлатма бирү. “Йомры икмәк”, “Казлар-аккошлар”, “Чуртан кушуы буенча” кебек рус халык әкиятләрен искә төшереп, балаларга мичнең ни өчен | Балалар бакчасы музеена экскурсия. Мич турындагы табышмак өйрәнү. Тәрбияченең мичнең төзелеше һәм аның билгеләнеше турында сөйләве. “Мич турында нинди әкиятләрдә сөйләнә?” искә төшерү. Сүзлек эше. Йомгак ясау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | кирәклеген аңлату. Мәкаль әйтемнәр, табышмаклар аркылы балаларның сүзлек запасын баету. Мичче хезмәтенә хөрмәт хисе тәрбияләү. | |
| 3. | Ноябрь | Икмәк – ил байлыгы. | Балаларга әби-бабаларның икмәк үстерүе һәм мичтә ипи пешерү турында белем бирү.<br>Игенченең хезмәт кораллары белән таныштыру.<br>Икмәк турындагы мәкальләр белән танышу, балаларга аңлаешсыз сүзләрнең мәгънәсен аңлату.<br>Яңа сүзләр: чалгы, урак, тегермән, тырма, башак, кисмәк кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлек запасын баету.<br>Игенче хезмәтенә хөрмәт хисе тәрбияләү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Хуҗабикәнең пешкән икмәк белән каршы алуы.<br>Тәрбияче аңлатмасы: (элеккеге заманда икмәкне ничек үстергәннәр һәм хәзер ничек үстерәләр)<br>Экспонатлар күрсәтү.<br>Икмәк һәм хезмәт турында мәкаль-әйтемнәр.<br>Уен: “Ак калач”<br>Йомгак ясау. |
| 4. | Декабрь | Савыт-сабалар үзләре турында нәрсә сөйләр. | Балаларны көнкүреш әйберләре белән аш бүлмәсе кирәк-яраклары белән таныштыруны дәвам итү. Балаларны татар халык ашлары белән таныштыру. Балаларның сүзлек запасын ашамлык, савыт-саба исемнәре исәбенә киңәйтү: чуен, тоткыч, казан, чүлмәк. Таныпбелү эшчәнлеген үстерү. Кем белән янәшә яшисең, мәдәниияткә кызыксыну тәрбияләргә. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Хуҗабикә белән очрашу. Ашамлыклар турында әңгәмә.<br>Экспонатларны карау.<br>Тәрбияче аңлатмасы.<br>Сүзлек эше.<br>“Чуен” турында әкият.<br>Йомгак ясау. |
| 5. | Гыйнвар | Әбием | Музейда тәкъдим ителгән | Балалар бакчасы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сандыгы | хатын-кыз һөнәрләре әйберләре белән таныштыру: чигелгән тастымаллар, сөлгеләр, халык костюмнары, өй бизәкләре. Татар милли баш киемнәренең, аяк киемнәренең ничек аталуын искә төшерү. Балаларның белемнәрен киңәйтү. Татар халык кәсепләре турындагы белемнәрне һәм аларны кеше көнкүрешен бизәүдә куллануны ныгыту. Борынгы әйберләргә хөрмәт һәм сакчыл караш тәрбияләү. | музеена экскурсия.<br>Сюрприз моменты: “Әбием сандыгы”. Тәрбияче аңлатмасы. Сүзлек эше.<br>Уен: “Түбәтәй”<br>Йомгак ясау. |
| 6. | Февраль | Тере борынгылык. | Балаларны йорт кирәк-яраклары белән таныштырырга. Балаларның борынгы әйберләр белән кызыксынуын формалаштырырга. Иҗади һәм танып белү эшчәнлеген үстерергә. Балаларның сүзлек запасын баетырга: көянтә, тагарак, үтүк, кер юу тактасы, комган. Балаларны фольклор белән таныштыруны дәвам итәргә. Музей экспонатларына сакчыл караш тәрбияләү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Борынгы әйберләр турында табышмаклар.<br>Тәрбияче аңлатмасы, экспонатлар күрсәтү.<br>Эш: “Хәзерге вакытта бу предметларны нәрсә белән алмаштырганнар?”<br>Сүзлек эше. Мәкаль-әйтемнәр. Йомгак ясау. |
| 7 | Март | Бәйрәм- “Карга боткасы” | Балаларны «Карга боткасы” татар милли бәйрәме белән таныштыру. татар халкының гореф-гадәтләре, халык календаре турында төшенчә бирерү. Ни өчен элек кешеләр яз көне карабодайны җылы каршы | Бәйрәмне уен аша таныштыру һәм халык ышанулары турында аңлату.<br>Яз, кошлар турында табышмаклар.<br>Әңгәмә үткәрү. Уен: |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | алганнарын һәм моның нәрсәгә бәйле булуын күз алдына китерү. Балада татар халкының гореф-гадәтләренә карата кызыксыну уяту. Балаларда толерантлык тәрбияләү | “Мәликә”, “Күрсәт әле үскәнем”<br>Йомгак ясау. |
| 8 | Апрель | Хуҗабикә ярдәмчеләре | Балаларны авыл өендә кич утырулар белән таныштырырга. Утырышларга әзерлек турында күзаллау бирергә (өйне җыештыру һәм бәйрәмчә җыештыру). Балаларны хатын-кызлар һәм ирләр эше белән таныштыру: хатын-кызлар чигү, туку, бәйләү, челтәр эрләү, ирләр каештан чабата, тал чыбыкларыннан кәрзин үрү, агачтан савыт-саба кисү.<br>Сүзлек эше: орчык, эрләү, йомгак, уймак. Балаларны фольклор белән таныштыруны, тарихка кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. | Балалар бакчасы музеена экскурсия.<br>Уен моменты: «Утырма”<br>Тәрбияченең кич утырулар турында сөйләве.<br>Эш: Утырмаларда нәрсә белән шөгыльләнгәннәр?<br>Сүзлек эше. Мәкаль-әйтемнәр.<br>Уен: “Йомгакны кем тизрәк чорный?”, “Капкалы”<br>Йомгак ясау. |
| 9 | Май | Дуслык һәм туганлык байлыктан да кадерлерәк. | Балаларны татар халкының “Сабантуй” бәйрәме белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның халык мәдәнияте традицияләре турында белемнәрен киңәйтү.<br>Халык уеннарында катнашу теләген үстерү.<br>Үз халкың, үзең яшәгән ватаның өчен милли горурлык хисе тәрбияләү. | “Сабантуй” җыры яңгырый. Тәрбиячёнең “Сабантуй” бәйрәме турында сөйләве. Шигырьләр уку. Уен: “Чүлмәккә сугыгыз”, “Сары яулык”.<br>Йомгак ясау. |

**Әти-әниләр белән эш:**

| № | Ай | Тема | Эш төре |
|---|---|---|---|
| 1 | Сентябрь | Дөбъяз урта мәктәбе музее. | Дөбъяз урта мәктәбе музеена экскурсия. |
| 2 | Октябрь | Халык традицияләре, аларның гаилә тәрбиясендә роле. | Консультация |
| 3 | Ноябрь | Иң яхшы татар милли костюмы | Рәсемнәр конкурсы |
| 4 | Декабрь | Бала тормышында бишек җыры | Консультация |
| 5 | Гыйнвар | “Гаиләмнең милли мирасы” | Альбом ясау. |
| 6 | Февраль | Татар милли бәйрәмнәрен, күңел ачуларын, ялларын уздыру-татар милли мәдәниятенә карата кызыксыну, ярату һәм хөрмәт тәрбияләү шартларының берсе. | Консультация |
| 7 | Март | “Нәүрүз” | Бәйрәм |
| 8 | Апрель | “Мич котлау” йоласы | Мәктәпкә әзерлек төркемендә белем бирү эшчәнлеге |
| 9 | Май | “Сабантуй” | Бәйрәм |

**Кулланылган әдәбият**

1. Закирова К.В. “Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия", Казан, РИЦ, 2011.

2.Закирова К.В. , Мортазина Л.Р. "Балачак - уйнап көлеп үсәр чак". Казан, 2012.

3.Зарипова З.М., Исаева Р.С. "Үстерешле уеннар. - Казан, 2013.

4. Закирова К.В.  "Уйный-уйный үсәбез". Казан, 2012.

**«Гаиләдә һәм балалар бакчасында мәктәпкәчә яшьтәге баланың эмоциональ үсеше чарасы буларак, бишек халык традициясе» проекты**

***Шакирова Гөлнара Нәҗип кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының*
*“Арча 9 нчы балалар бакчасы” муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

"Ана җыры-дөньяда иң әһәмиятле җыр; барлык җырларның башы"

Рәсүл Гамзатов

***Актуальлеге.*** Балачак назлы әни куллары һәм йомшак тавышы, тыныч көй яңгырашы һәм тынычландыручы бишек җыры сүзләре белән ассоциацияләнә. Бишек җырының тексты гади, әмма аның интонациясе җылылык һәм кайгырту, аңлау һәм тынычлык белән тулы. Бала очрашкан беренче сүзләр – баланы тынычландырып, бишек җырын җырлаган әнисе сөйләме.

Ерак гасырларда иҗат ителгән, буыннан-буынга күчеп килгән бишек җырлары безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Аларда баланың югары кыйммәте раслана, чөнки тулы психик үсеш өчен балага бу дөньяда аның «мин» билгән урыны — иң яхшысы, аның әнисе — иң яхшысы, ә йорты — иң якын урын икәнлеген раслау мөһим. Бишек җырларында наз, ихлас күңеллелек, күңел тынычлыгы, рухлылык, йомшаклык яңгырый. Алар борчылуны, дулкынлануны бетерә. Бишек-ул бала тирәсен саклаган, явызлык үтеп керүгә юл куймый торган ана куллары.

Бүген бишек җырлары безнең тормышыбыздан югала башлады. Хәзерге әниләр, музыкаль сәләтләре булмавын, сүзләрне белмәвен һәм вакыт кытлыгына сылтап, балаларына бишек җырларын сирәк җырлыйлар. Бик еш, бишек җыры урынына тыныч музыка куялар, яки бала телевизор тавышына йокыга китә. Бүген әниләрнең бик азы гына бишек җырының баланы үстерү һәм аның белән аралашу чарасы буларак мөһимлеген аңлый.

***Проблема.*** “Бишек җыры” темасы буенча төркем балалары белән әңгәмә барышында берничә бала гына йоклар алдыннан әниләре җырлый дип әйткәнлеге ачыкланды. Шуннан соң мин әти-әниләр арасында анкета үткәрдем. Анда 17 әни катнашты, алар бирелгән сорауларга җавап бирделәр.

Нәтиҗәдә 17 % җырлый, сирәк кенә 41% бишек җырлары җырлый, 42% җырламавы ачыкланды. Бу мине ата-аналарны һәм балаларны тәрбия һәм белем бирү мөмкинлекләренең бетмәс чыганагы буларак бишек җырларына җәлеп итү проектын тормышка ашырырга этәрде.

***Проектның төре:*** мәгълүмати-иҗади.

***Проектның вакыты:*** уртача сроклы.

***Гамәлгә ашыру вакыты:*** 2023 елның октябреннән 2023 елның гыйнварына кадәр.

***Проектта катнашучылар:*** “Кояшкай” төркеме балалары, тәрбиячеләр, ата-аналар, музыка мөгаллиме.

***Белем өлкәсе:*** “Социаль-коммуникатив”, “Танып белү”, “Сөйләм үсеше”, “Сәнгати-эстетик”.

***Максат:*** бишек җырлары аша балаларның халык иҗатына уңай мөнәсәбәт формалаштыру.

***Бурыч:***

Белем бирүче:

- балаларны бишек җырларын тоярга һәм аңларга өйрәтү.
- бишек җырларының тарихы, аларның геройлары һәм әсәрләрнең интонация үзенчәлекләре белән таныштырырга.

Үстерүче:

- балаларда әлеге жанрдагы әсәрләрнең образлы эчтәлеген кабул итә белүне үстерү.
- бишек җырларын кабул иткәндә сәнгати-образлы фикерләүне, фантазияне, иҗатны үстерергә.

Тәрбия бирүче:

- сөйләм культурасын тәрбияләү, ишетә белү, фольклорда чагылган хис һәм кәеф төсмерләрен билгеләү.
- халык иҗатына кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

Проектны гамәлгә ашыру принциплары:

Үстерүче белем бирү принцибы - һәр баланың якындагы үсеш зонасындагы эшчәнлеге;

Проблемалылык принцибы-фикер функцияләрен активлаштыру, танып белү процесслары эшен стимуллаштыру, иҗади сәләтләрне үстерү.

Аңлаешлылык принцибы-мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль акыл мөмкинлекләрен, аларның әзерлек һәм үсеш дәрәҗәсен исәпкә алу.

Хезмәттәшлек принцибы-шәхес өстенлегенә юнәлеш бирү, аның үсеше өчен уңай шартлар тудыру.

Индивидуальләштерү принцибы-һәр баланың шәхси потенциалын ачу.

Системалылык принцибы-белем бирү һәм тәрбия юнәлешендәге бурычлар комплексын хәл итү, бу фаразлана торган нәтиҗәгә ирешергә мөмкинлек бирә.

Көтелгән нәтиҗә: Бишек җырларын тыңлаганда һәм җырлаганда балаларда эмоциональ ярдәмчеллек чагылышы.

Балаларның уен эшчәнлегендә курчак белән уйнаганда бишек җырларын куллану (курчакларны йокларга яткырып, бишек җырларын көйләп, бишек җырларын җырлаганда олыларның гамәлләренә охшатып, кулларында тирбәтеп).

Бишек җырларының хәзерге тормышта, халык традицияләрен саклауда мөһимлеген аңлау.

Тәрбиячеләрнең бакчада бишек җырларын куллану.

Ата-аналар йоклар алдыннан балаларына бишек җырларын ешрак җырлый башлау.

Төркемдә эмоциональ яктан уңай климатны саклау.

Ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыту.

Проектны гамәлгә ашыру этаплары:

1.Әзерлек этабы.

Максат: - проектның проблемаларын, максатларын һәм темаларын формалаштыру;

- ата-аналарга анкета бирү;

- әдәбият, аудио һәм видео материал сайлау;

- методик әдәбиятны өйрәнү, халык бишек җыры турында шәхси һәм төркем китапханәләрен тулыландыру;

- проект кысаларында тәрбияви - белем бирү эшен планлаштыру;

- методик әдәбиятны өйрәнү;

- балалар өчен пособиеләр эзләү;

- проектны гамәлгә ашыру планын эшләү;

- проектның фаразлана торган нәтиҗәләрен билгеләү;

- ата-аналарга анкета бирү;

- “Минем беренче җырым” төркем альбомын әзерләү;

- йоклар алдыннан бишек җырларының аудиоязмаларын тыңлау;

- тәрбияченең балалар йоклар алдыннан бишек җырларын җырлавы;

– “Бишек җыры-тормыштагы төп җыр!” проектының фотопрезентациясе.

Максат: - проектны гамәлгә ашыру, балаларда үзенчәлекле белем, күнекмәләр формалаштыру.

2 Проблеманы хәл итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру этабы :

Барлык шөгыльләр һәм ирекле эшчәнлек мәктәпкәчә яшьтәге балаларда бишек җыры аша туган илгә, татар халык фольклорына мәхәббәт тәрбияләргә мөмкинлек бирә; балаларның иҗади һәм интеллектуаль сәләтләрен, аларның сөйләм культурасын үстерәләр.

- МБМБУ музеенда булу;

-“Минем әнием” әңгәмәсе;

- бу тематика буенча раскраска буяу;

- бишек турында әңгәмә;

- мәкальләр, мәзәкләр, такмаклар белән таныштыру, аларны ятлау;

- дидактик уеннар – сүз уеннары: “Ягымлы итеп әйт”, “Билгесен тап”, “Гамәл тап”, “Зур – кечкенә” һ. б.

- “Гаилә" бармак гимнастикасы;

- “Татар өе” төркем мини-музее белән уеннар;

- әлеге тематика буенча иллюстрацияләрне карау;

- “Гаилә”, “Кыз-әниләр” сюжетлы-рольле уеннары;
- бишек җырларын драматизацияләү;
- әни турында әңгәмә.
- бишек җырын ятлау һәм җырлау
- аларны театральләштерүдә куллану
- “биләү курчаклары " ясау
- төрле бишек җырларын тыңлау.
- аз хәрәкәтчәнлек уены "Тәрәзә янында йокы йөри”.

Ата-аналар белән эш:

- Ата-аналарны консультацияләр, әңгәмәләр аша җәлеп итү һәм аларның чараларда катнашуы;
-“Үз кулларым белән ясалган бишек”конкурсы;
- “Иң яхшы әни” конкурсы;
-ата - аналар белән “Йомшак курчак” мастер-классы оештыру;
- “Балам өчен яраткан бишек җыры” җыентыгы;
- Авторлык бишек җыры конкурсы.

3. Гомумиләштерү-нәтиҗә ясау этабы.

Максат: - йомгак ясау;

- проектны тәкъдир итүне оештыру;
- балалар белән «Бишек җырлары» бакчасы җыелышында чыгыш ясау; Нәтиҗә: бишек җырлары балага эмоциональ тәэсир итә, ана белән бала арасында тыгыз бәйләнеш урнаштыра. Асылда бишек җыры балаларга бик якын, алар аның тыныч, ягымлы характерын бик җанлы кабул итәләр. Бишек җырларындагы персонажларның образлары кешеләрнең әйләнә-тирә дөньясы һәм көнкүреше белән бәйләнгән, шуңа күрә аңлаешлы формада балага яшәү нормалары һәм кагыйдәләре ачыла, ата-аналар, башка кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләргә мәгънәви карашлар, мөмкин булган куркынычлар турында кисәтүләр формалаша, аңсыз дәрәҗәдә олы тормыш образы салына.

**Татар халкының мәдәнияте, гореф-гадәт, йолалары аша балаларга патриотик тәрбия бирү**

***Гарипова Люция Фәрит кызы,***

***Тимериева Гүзәл Әнвәр кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*“Әлдермеш” Умырзая” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем*
*бирү муниципаль бюджет учреждениясе*

Проектның дәвамлылыгы: озак сроклы (1 ел).

Проектның төре: иҗади – эзләнүчән.

Проектның авторлары: тәрбиячеләр: Гарипова Л.Ф., Тимериева Г.Ә.

Проектта катнашучылар: зурлар төркеме балалары (5-7 яшь), тәрбиячеләр, әти-әниләр, мәдәният хезмәткәрләре.

“Ватан белән шәхси бәйләнешне сизмичә, ата-бабаларыбызның ничек яшәгәннәрен, ничек яратканнарын һәм аны ничек саклаганнарын белмичә, патриот булып булмый”.

**Кереш сүз.**

Баланы патриотик рухта тәрбияләү – катлаулы педагогик процесс Ватан Хисе ул балада гаиләгә, иң якын кешеләргә – әнигә, әби-бабайга мөнәсәбәт белән башлана. Бу тамырлар аны туган йорт һәм якын тирәлек белән бәйли.

Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе – тормышка әзер булган,үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше, Гражданин һәм Патриот тәрбияләү. Патриот үзенең туган җирен, халкын, милләтен, Ватанын сөюче.

Проектның актуальлеге: татар халкының мәдәнияте,гореф-гадәт, йолалары белән таныштыру балалар бакчасыннан ук башланып китә.

Милләтебезгә карата олы ихтирам хисләре тәрбияләү, туган җиребезнең табигатенә, йортына, туган авылына, халкыбызның тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәт, йолаларына, мәхәббәт уяту – патриотик тәрбия бирүнең бер төре булып тора.

Балаларны татар халкының сәнгате,традицияләре белән таныштыру балаларны рухи яктан баета, үзенең милләте өчен горурлану хисләре тәрбияли, аның тарихына, мәдәниятенә кызыксыну уята. Халык йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнү, аларны саклау, Ватаныбызга карата мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә этәргеч көч булып тора. Балаларны халкыбызның күңел

җәүһәрләре, күңел бизәкләре белән якыннанрак таныштыру, традицияләргә карата кызыксыну уяту, эстетик зәвык аша әхлак тәрбиясе бирү – бүгенге көндә бик актуаль булып тора.

Проектның максаты:

- балаларны татар халкының гореф-гадәт, йолалары белән таныштыру;
- балаларны татар халкының мәдәниятенә тарту;
- татар халкының милли киемнәре белән таныштыру;
- Татарстанның купмилләтле республика булуын аңлату, милләтләр арасында дуслык хисе тәрбияләү;
- ата-аналар белән берлектә әби-бабаларыбызның борынгы мирасы турында сөйләү.

Проектның бурычлары:

балалар өчен:

-татар халкының мәдәниятенә, гореф-гадәт, йолаларына, уеннарына кызыксыну уяту;
- Ватаныбызга – авылыбызга, йортыбызга, туган җиребезгә, гаиләбезгә ярату хисләре тәрбияләү;
- балаларны халык авыз иҗаты: әкиятләр, табышмаклар,мәкальләр, сынамышлар белән таныштыру;
- гореф-гадәт, йолалар, бәйрәмнәр төрле милләт халыкларын якынайта, берләштерә торган чара икәнен төшендерү.

педагоглар һәм мәдәният хезмәткәрләре өчен:

- проект барышында татар халкының мәдәнияте, гореф-гадәт,йолалары белән балаларны таныштыру; балаларның танып белү, сөйләм үстеү активлыгын арттыру өчен төрле шартлар тудыру;
- балаларны татар халкының мәдәнияте, гореф-гадәт, йолалары белән таныштыру буенча ата-аналарга методик тәгъдимнәр ясау;
-“Кул эшләре һәр чараның бизәге”дигән күргәзмә оештыру;
- “Әбиемнең чәйләре” дигән бәйрәм оештыру;
- “Туган ягым чишмәләре”нә сәяхәт ясау.

ата-аналар өчен:

- проект чараларын оештыруда ярдәм итү;
- “Халкыбызның күңел җәүһәрләре” күргәзмәсен оештыру;
- “Нәсел агачы”(шәҗәрә) төзеп килергә өндәү;

Проектны тормышка ашыруда көтелгән нәтиҗәләр:

- татар халкының мәдәнияте, гореф-гадәт, йолалары турында күзаллауларын формалаштыру;
- балалар белән татар халык авыз иҗатын өйрәнү;

- төрле мәдәни чаралар, бәйрәмнәр, уеннар аша балаларның күзәтүләрен барлау һәм активлаштыру;

- балаларны татар халкының мәдәниятенә, гореф-гадәт,йолаларына зур ихтирам, ярату белән карарга өйрәтү.

- башка милләт кешеләренә, яшьтәшләренә һәм өлкәннәргә карата толерант мөнәсәбәт формалаштыру;

- балаларда рухи-әхлакый сыйфатларны үстерү.

Проектның этаплары:

1. Әзерлек этабы (түбәндәге чараларны үз эченә алган мәгълумати- эзләнү):

-әдәбият эзләү;

-халык авыз иҗаты әсәрләр, такмаклар, җырлар сайлау;

-Ватан(авыл, шәһәр) әңгәмәләр;

- татар халык уеннары картотекасын төзү;

- татар халкының яратып үткәрелә торган бәйрәмнәрен барлау.

2. Төп этап:

Балалар белән эшчәнлек:

- туган авылның истәлекле урыннарына (мәктәп музеена,чишмә буйларына) сәяхәт;

- татар халык авыз иҗатына кагылышлы такмаклар, сынамышлар, мәкальләр, әйтемнәр өйрәнү;

- татар халык уеннарын уйнау.

Тәрбиячеләр, мәдәният хезмәткәрләре белән эш:

-бакчабыздагы музейны тарихи истәлекле экспонатлар белән туплау, баету;

- балаларны бакчадагы музей белән таныштыру;

- бакчабызга Ватаныбызны саклаучы ир-егетләребезне кунакка чакыру, балалар белән әңгәмә үткәрү;

- мәдәният хезмәткәрләре белән тыгыз элемтәдә тору, мәдәни чаралар үткәрү.

Ата-аналар белән эш:

-күргәзмәләр оештыру;

- күңел ачу чараларында актив катнаштыру теләге булдыру;

- чаралар өчен кирәкле атрибутлар ясау(костюмнар, кирәк-яраклар, тегү, булдыру).

3. Йомгаклау этабы.

- әти-әниләр булышлыгы белән “Гаилә кыйммәтләре” дигән күргәзмә оештыру;

-проектның презентациясен төзү;

-проектның эш нәтиҗәләрен гомумиләштерү, проектны анализлау.

Проектны тормышка ашыруда эшләнелгән эшләр:

1. Татар халык уеннары:
“Миңлебай
“Яшерәм яулык”
“Капкалы”
“Йөзек салыш”
“Парлашу”
“Кәрия – Зәкәрия”
2. Белем бирү өлкәләре:
Танып белү.
-музейда кунакта;
-солдат абыйлар бездә кунакта;
-татар һәм башка милләт халкына кагылышлы альбомнар карау;
-аларның тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәт, йолалары белән танышу.
Сөйләм үстерү.
-әңгәмәләр;
-эшчәнлек;
- бәйрәм иртәләре, күңел ачулар.
Матур әдәбият белән таныштыру.
-такмаклар, җырлар, әйтемнәр, санамышлар;
-татар халкының Бөек шагыйре Тукай иҗаты;
- бәйрәмгә кагылышлы шигырьләр, җырлар.
Нәфасәти тәрбия:
-татар бизәкләре кулланып калфак, алъяпкыч, читек бизәү;
-рәсем ясау;
- “Оста куллар” түгәрәге( тозлы камырдан әвәләү).
Көтелгән нәтиҗәләр:
-балаларда әхлакый-патриотик хисләр; милли үзаң; халык мәдәнияте турындагы белемнәр формалашты;
-татар халкының гореф-гадәт,йолаларына, бәйрәмнәренә карата зур кызыксыну артты;
- фикерләү активлыгы, иҗади сәләт, үзара аралашу күнекмәләре үстерелде;
- бер-берләре арасында дустанә мөнәсәбәт булдырылды;
-башкарылган эш нәтиҗәсендә перспектив тематик план төзелде;

- шушы темага кагылышлы бәйрәм сценарийлары төзелде һәм татар халык уеннары картотекасы булдырылды.
- ата-аналар һәм мәдәният хезмәткәрләре белән тыгыз элемтәдә эшләр башкарылды.
Файдаланылган әдәбият:


1. К.В. Закирова "Уйный-уйный үсәбез".Казан, "Мәгариф"нәшрияты, 2005
2. К.В. Закирова "Балачак аланы" Казан, РИЦ нәшрияты, 2011
3. К.В.Закирова , Г.Р,Мортазина "Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак"Казан, 2012
4. З.М. Зарипова, Р.С. Исаева .Устерелешле уеннар. Методик кулланма Казан,


**"Музей – тәрбия учагы"**


***Югары квалификацион категорияле музыка җитәкчесе:***
***Васильева ИлһамияТаһир кызы***

*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*
*"Катнаш төрдәге Карадуган балалар бакчасы"*


Кереш

Чын татар төбәге буларак, балаларыбызның милли йөзен саклап калу, гореф – гадәтләребезне, йолаларыбызны кире кайтару, милли телебезгә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру, балаларыбызны әхлаклы, иманлы, сәламәт, хезмәт сөючән итеп тәрбияләүдә халык талантларының осталыгын һәм гаиләләрдә халкыбызның асыл сыйфатларын күрсәтүне максат итеп куйдык. Һәр бала үз гаиләсенең, туган теленең тарихын белергә, хезмәтне яратырга, шуның аша халыкка якынаерга тиеш. Халыкның, яшь буынның рухи байлыгын саклауда музейларның әһәмияте бик зур. Алар, матди һәм рухи мирасыбыз булу белән беррәттән, укыту–тәрбия эшендә дә зур ярдәм итә. Без бу мәсьәләне чишү чараларын билгеләдек һәм балалар бакчасында музей оештыруны кулай дип уйладык. 2016 нчы елның 22 апрелендә Татарстан Республикасы һәм Мәгариф Министрлыгы тарафыннан 778 нче номерлы музей таныклыгы бирелде. 2019 нчы елдан музей киңәйтелеп "Балачак иле" исеме астында эшен дәвам итә. Музей эшчәнлегенең беренче юнәлеше – авылда яшәгән әби – бабаларыбызның

борынгы тормыш – көнкүрешен өйрәнү. Икенче юнәлеше – уенчыклар тарихы, өченче юнәлеше – милли курчаклар. Музейда милли киемнәр, борынгы уеннар тупланган милли уеннар җыентыклары, татар халкының көнкүреш әйберләре, нәсел тамгалары, шәҗәрәләр, сәнгатьле чигү, тегү экспозицияләре тупланды.

Музей эшчәнлегенең максаты бер, ул да булса, халкыбызның бай тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнү аша балаларны рухи яктан бай, иҗади сәләтле, югары мәдәниятле камил шәхес итеп тәрбияләү. Балалар бакчасында музей булдыру идеясе - балалар һәм ата - аналары белән эшләүнең яңа формасы. Үсеш мохитенен мөһим элементларын булдыруда катнашучылар булып балалар һәм ата-аналар тора. Бу эштә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның музейда мөстәкыйль эшчәнлеге аерым урын алып тора. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында өлкәләр буенча белем бирү бурычларын хәл итү өлкәннәр тарафыннан төрле балалар эшчәнлеген оештыру аша күздә тотыла. Белем бирү өлкәләренең интеграциясе принцибы нигезендә музей эше уен, танып - белү, коммуникатив, продуктив балалар эшчәнлеген оештыруга юнәлдерелгән.

Музей эшчәнлеге буенча проект эше булдыруның өстенлекләре:

- Музейның балалар бакчасында урнашуы
- Экспонатларга кул белән кагылырга мөмкин булуы
- Балаларның иҗат итүе

Музей эшчәнлеге оештыруның төп принциплары:

- Интеграция
- Эшчәнлек һәм интерактивлык
- Партнерлык
- Мәдәният
- Милли төбәк компоненты

Проект эшчәнлегендә балалар белән эшләүнең төрләре:

- Әңгәмәләр
- Музей кунаклары белән очрашулар
- Фольклор һәм тематик бәйрәмнәр
- Тегү – чигү сәнгате, калфак бизәү буенча өстәмә эшчәнлекләр
- Нәсел тамгаларын, шәҗәрәләрне барлау буенча эшчәнлекләр

Проектның төре: гамәли юнәлешле.

Проектның максаты:

Тарихи, әдәби һәм мәдәни мирасыбызны киләчәк буыннарга тапшыруда музейларның әһәмиятен күрсәтү.

Проектның бурычлары:

1. Халкыбызның хәзинәләренә карата сакчыллык-пөхтәлек тәрбияләү.

2. Халкыбызның гореф–гадәтләрен, йолаларын, буыннан-буынга күчеп килгән гүзәл сыйфатларын саклау һәм үстерү.

3. Борынгы заманнан безгә кадәр сакланып килгән матурлыкны күрә белергә, әби-бабайларыбызның эшләрен дәвам итүчеләр итеп тоярга өйрәтү

Проектның актуальлеге

Мәдәниятебезне өйрәнү бүгенге көндә аеруча зур әһәмияткә ия, чөнки заманча шартларда гореф-гадәтләребез юкка чыгып бара. Ә борынгыдан килгән традицияләребезне саклап калу, өйрәнү фәнни яктан гына түгел, гамәли яктан, халкыбызны эстетик тәрбияләү җәһәтеннән дә мөһим санала. Хәзерге заманда компьютерлар һәм информацион технологияләр киң таралуга һәм аларның күп кенә уңай сыйфатлары булуга да карамастан, балаларны аның тарихи юлын күрсәткән кыйммәтләрдән, мәдәни байлыклардан читләтәләр, хәтта аералар да. Шуңа күрә музейлар балаларның игътибарын шушы чын кыйммәт һәм байлыкларга юнәлтү, аларны саклау һәм үстерү кирәклеген искәртү чарасы булып торалар. Музейлар туган як тарихын, мәдәниятен  өйрәнүдә чын мәгънәсендә методик үзәк булып тора. Алар халкыбызның мирасын кадерләп саклау белән беррәттән, яшьләрне, балаларны туган якның күркәм традицияләре үрнәгендә тәрбияләргә ярдәм итә.

“Балачак иле” музее өч өлештән тора. Беренче өлеше әби-бабайларыбыздан калган борынгы читекләр, савыт-сабалар, бишекләр. Бу өлештә борынгы әби-бабайларның өе сүрәтләнгән. Шул чорны чагылдырган җиһазлар тупланган.

Икенче өлеше - борынгы уенчыклар. Борынгы уенчыкларның ниндиләре генә юк! Бала үз куллары белән тотып карый, үзенә кызык уенчык белән таныша ала.

Музейның өченче өлеше  - курчаклар. Курчаклар төрле материаллардан ясалган - агач, чүпрәк, балавыз һ.б.

Музейда 1748 елның иң борынгы калфагы сакланып килә. Шулай ук чиелгән, төрле итеп бизәлгән калфаклар да тупланган. Балалар бакчасында балаларга милли тәрбия максатыннан, балалар, әниләр белән берлектә түбәтәй - калфак тегеп бизәү эше дә оештырылды. Балалар бакчадан чыгып киткәнче түбәтәй - калфакларын саклап, бәйрәмнәрдә кияләр.

Музей эшчәнлеге программа буенча алып барыла. Тупланган җиһазларны ничек итеп балаларга тәкъдим итә алабыз соң? Борынгы уеннар кергән җыентыклар булдырылды һәм шул уеннар балалар белән берлектә уйнала.

Биредә балалар бакчасының 42 еллык тарихы булган уенчыклар һәм төрле милләт курчаклары, әби-бабаларыбыз уйнап үскән уенчыклар, аларның яшәешен күрсәткән экспонатлар тупланган. Әлеге музей балалар өчен зур хәзинә булып тора.

Балалар бакчасының 42 еллык шәҗәрәсе булдырылды. Шәҗәрәдә бакчада эшләгән барлык хезмәткәрләр билгеләнеп һәр чыгарылыш балаларының исемлеге, бастырылган методик әсбаплар, ирешкән уңышлар тулыландырылып барыла. Шул шәҗәрә эшен дәвам итеп бакчабызда тәрбияләнүче балаларның нәсел агачлары тупланып балалар белән өйрәнелә.

Бүгенге көндә бала тормышында балалар бакчасының роле үзгә. Балалар бакчасы – ул гаиләдән тыш, баланың шәхес булып үсешендә югары уку йорты булып санала һәм анда тудырылган уңай шартлар һәр яклап аның үсешенә зур йогынты ясый.

Бакчаның йөзен тудыруга күп көч таләп ителә, төрле юнәлештә эш алып барыла. Ин беренче чиратта балалар бакчасының йөзен булдыруда эш алымы дүрт төп төркемгә бүленде:

1. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр.
2. Әти – әниләр.
3. Массакүләм мәгълүмат чаралары.
4. Балалар бакчасының коллективы.

Проектта катнашучылар:

Тәрбиячеләр, балалар бакчасы хезмәткәрләре, балалар, ата - аналар, әби-бабайлар.

Көтелгән нәтиҗә:

- Балаларны рухи яктан бай, милли тамырларын аңлаучы шәхес итеп тормышка әзерләү.
- Балаларның татар халкының мәдәнияте, традицияләре турында күзаллауларын баету.
- Татар халкының электән килгән кул эшләренә өйрәтү.
- Ата-аналар белән балалар бакчасы арасында хезмәттәшлекне киңәйтү.

**Проектның календарь планы**

| **№** | **Үткәрелгән чара** | **Чараның кыскача эчтәлеге** | **Җаваплы** | **Вакыт** |
|---|---|---|---|---|
| **1. Әзерлек этабы** | | | | |
| **1** | Проблемаларны ачыклау, норматив базаны булдыру | Норматив документларны өйрәнү һәм сайлап алу | Мөдир, өлкән тәрбияче | Сентябрь |
| **2** | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре практикасына музей педагогикасын кертү мөмкинлеген өйрәнү | Проектны эшләү буенча иҗади төркем формалаштыру | Мөдир, өлкән тәрбияче | Октябрь |
| **3** | Музей оештыру турында ата-аналар җыелышында чыгыш ясау | Консультация «Музейның тәрбия эшендә тоткан роле» | Мөдир, өлкән тәрбияче | Октябрь |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4** | Себер тракты тарихы һәм Муса Җәлил музеена экскурсия | Музей эшчәнлеге белән танышу | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Октябрь |
| **5** | Музейга экспонатлар туплау | Музейны җиһазландыру өчен экспонатлар әзләү буенча эш | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Ел дәвамында |
| **2. Проектның төп өлеше буенча эшләү** | | | | |
| **1** | Музейга экскурсия. Музейдагы экспонатлар белән таныштыру | Борынгы әби- бабайларның көнкүреше, хуҗалык әйберләре белән танышу | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Ел дәвамында |
| **2** | “Онытылып бара торган экспонатлар” | Район мәгариф бүлеге җитәкчесе белән очрашу | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Сентябрь |
| **3** | “Халкымның онытылган уеннары, уенчыклары”<br><br>“Милли курчаклар” | Тәрбиячеләр белән борынгы милли уеннарны җыентыкка туплау. Балалар белән уйнау.<br><br>Борынгы курчаклар белән танышу | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Октябрь Ел давамында |
| **4** | “Бәллүр бишекләр” | Бишекләр тарихы, аларның төрләре, бишек җырлары белән танышу.<br>“Бишек җырлары” музыкаль бәйге - кичә | Өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре, музыка җитәкчесе | Ноябрь |
| **5** | “Калфакларда милләт тарихы” | Халкыбызның милли бизәкләрен өйрәнү, сәйләннәр белән калфак бизәү.<br><br>“Әбидә кунакта” фольклор бәйрәме | Өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре, музыка җитәкчесе | Ноябрь |
| **6** | “Шәҗәрә – безнең тамырлар” | Нәсел агачын барлау, өйрәнү.<br><br>Себер тракты тарихы һәм Муса Җәлил музее директоры белән очрашу. | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Декабрь |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| **7** | “Нәсел тамгаңны беләсеңме?” | Әти – әниләр белән әңгәмә. Район архив бүлеге җитәкчесе белән очрашу. | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Январь |
| **8** | “Кул эшләре иленә сәяхәт” | Халык һөнәрләре белән таныштыру. Чигелгән эшләнмәләргә, матурлыкка, мәхәббәт тәрбияләү. Балаларны кызыксындыру, чигәргә теләк уяту.<br>Җеп һәм энә төрләре, материаллар, инструментлар һәм аларның чигү өчен тукымалар белән таныштыру.<br>Материалларның үзлекләре турында белемнәрне ныгыту.<br><br>Оста куллы үрнәк гаиләләрнең шәхси тәҗрибәсен исәпкә алу һәм алар белән таныштыру. | Өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Январь |
| **9** | “Кульяулык чигү” | Энә белән эшләргә, саплагач җепне төйнәргә өйрәнү. | Өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Февраль |
| **10** | “Тылсымлы энә” | Ике тишекле төймә тагарга өйрәнү.<br>Тегү машинасында эшләү алымнарына өйрәнү. | Өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Март |
| **11** | Гаилә белән бергәләп музейны җиһазландыруда булышуны дәвам итү | Музейга экспонатлар туплауга җәлеп итү. | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре | Ел дәвамында |

| 3. Йомгаклау этабы | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **12** | “Музей – тәрбия учагы”<br><br>“Күнелләрдә халкым бизәкләре” | 18 май – Халыкара музейлар көне уңаеннан эти – әниләр конференциясе. Кул эшләре күргәзмәзсе. | Мөдир, өлкән тәрбияче, төркем тәрбиячеләре, музыка җитәкчесе | Май |

## Милли ашлар табын түрендә

***Гафурова Рафия Ансар кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге «Балачак» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

I. Кереш. Милли ашларның үзенчәлеге.

Татар халкы бик борынгыдан ук аш-су әзерләргә оста булган, тәмле ризыклар пешергән. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган. Татар халкы үз милли ашлары белән бик бай һәм бөтен дөньяга үз ризыклары белән мәшһүр. Татар аш-су осталары бик күп төрле ашамлыклар уйлап тапканнар. Без моны төрле сайтларны һәм әдәбиятны өйрәнү барышында ачыкладык. Бер үк төрле ризыклар төрле-төрле рецептлар буенча әзерләнә, үзенчәлекле ризыклар барлыкка килә. Алар барысы да милли ашларның кулланылышын арттырырга ярдәм итәләр. Болар “ Милли ашлар” темасының актуальлеген билгели. Интернет челтәрендә дә, әдәбиятта да әлеге тема тулысынча яктыртылмаган, чөнки һәр төбәктә һәм хәтта һәр гаиләдә бер үк исемле ризыклар төрле рецептлар белән әзерләнәләр.

Эзләнү-тикшеренү эшенең объекты: камыр ашлары.

Эзләнү - тикшерү эшенең максаты: татар халкының милли ашлары белән танышу, өйрәнү, үзенчәлекләрен табу; милли ризыкларның халыкларны берләштерү чарасы буларак хезмәт итүен ачыклау.

Эзләнү - тикшерү эшенең төп бурычы: татар милли ашларының төрле милләт халыкларын якынайта һәм берләштерә торган чара икәнен дәлилләү.

Кулланылган методлар: фәнни, әдәби һәм матбугат материаллары белән эшләү; өлешчә эзләнүле метод.

Эш өч өлештән тора: кереш, төп, йомгаклау. Кереш өлештә теманың актуальлеге күрсәтелде, максат һәм бурычлар билгеләнде, кулланылган методлар күрсәтелде. Төп өлештә балалар белән эшчәнлек, балалар бакчасы хезмәткәрләре һәм ата-аналар ярдәме белән оештырылган эшчәнлек турында язылды.

Татар гаиләләрендә милли ризыкларның кулланылышы буенча уздырылган тикшеренүләр дә төп өлештә урын алды. Йомгаклау өлешендә эзләнү-тикшеренү эшенә нәтиҗә ясалды.

II. Төп өлеш : Безнең тикшеренүләр

Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге:

1. Татар халык ашлары альбомын карау, исемнәрен истә калдыру (бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, чәк-чәк, гөбәдия, кош теле, коймак).

2. Милли ризыклар турында шигырьләр уку, табышмаклар, санамышлар, уеннар, әйтемнәр, җырлар өйрәнү.

3. Балалар белән әңгәмә. Тема: «Минем беренче хезмәт җимешем» (әниләре белән бер милли ризыкны пешереп карау теләген ачыклау).

4.19 нчы декабрь көнне,балалар бакчасы мөдирләрен кунакка чакырып, районкүләм «Милли ашлар табын түрендә»темасына семинар уздыру.

Балалар ,балалар бакчасы хезмәткәрләре, тәрбиячеләр белән эшчәнлек:

1. Ашханә бүлмәсенә сәяхәт. Пешекчеләр хезмәтен, аш-су җиһазларын читтән күзәтү.

2. Пешекче белән сөйләшү, сөйләшү вакытында пешерү күнекмәләре, куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышу.

- пычак белән сак эш итәргә;
- янып торган плитәгә якын килмәскә;
- кайнар әйберләрне бияләй белән тотарга;
- электр приборларына юеш кул белән тотынмаска.

3. Аш бүлмәсендә пешергәндә , куркынычсызлык кагыйдәләрен истә тоту һәм үтәү турында тәрбияченең аңлатуы.

4. Әдәплелек кагыйдәләрен үтәү.

- ашау алдыннан кулларны сабын белән юарга;
- ашаганда өстәл артында тыныч утырырга;
- авыздагы ризыкны йотып бетермичә, өстәл артыннан кузгалмаска;
- табын артына башта олыларны утыртырга;
- ризык капкан килеш сөйләшмәскә;
- ашап туйгач рәхмәт әйтеп китәргә.

Ата-аналар белән бердәм эшчәнлек:

1) «Милли ризыклар»темасына рефератлар һәм кул эшләре күргәзмәсе оештыру.

2) Балалар белән әниләрнең өйдә яраткан милли камыр ризыгы пешерүе

2) Ата-аналар өчен анкета

- Сез нинди татар халык ашларын беләсез?

- Сез өйдә нинди милли камыр ашлары әзерлисез?

- Сезнең балалар нинди милли камыр ризыклары ярата?

- Тиз әзерләнә торган нинди милли ризык беләсез?

- Милли ризыклар пешергәндә балаларыгыз сезгә булышамы?

3. Көтелгән нәтиҗәләр:

1) Балалар милли камыр ашлары турында күбрәк белделәр.

2) Милли ризыкларны әниләре белән ясап,пешереп карадылар, аның эчлеге белән таныштылар.

3) Пешекче хезмәтенә ихтирам хисе туды.

4) Балаларда үз хезмәтенең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе уянды.

5) Балалар ризыкка хөрмәт белән карарга, үз-үзенә хезмәт күрсәтү күнекмәләренә өйрәнделәр.

6)Ата-аналарда балалар бакчасы хезмәткәрләре белән уңай мөнәсәбәтләрне дәвам итү теләге артты.

III.Йомгаклау:

Татар ашлары күптөрле. Татар ашларын татарлар гына түгел, башка милләтләр дә яратып ашыйлар. Аш әзерләүдә кулланылучы продуктларның күптөрле булуы татар милли ашларының үзенчәлеге булып тора. Татарларда ит, бәрәңге, йомырка, ярма, он ризыклары, бал бик күп кулланыла. Тикшерү вакытында милли ризыклардан бавырсак, гөбәдия, бәлеш, пәрәмәч, чәк-чәк,коймак кебек ризыкларның күп кулланылуын ачыкладык. Эшебездә төп тикшеренү объекты булып камыр ашлары булды. Аларны ачыклау өчен без куелган максат буенча милли камыр ашларын өйрәндек, үзенчәлекләрен таптык; милли ризыкларның халыкларны берләштерү чарасы буларак хезмәт итүен ачыкладык. Татар милли ашлары төрле милләт халыкларын якынайта һәм берләштерә торган чара икәненә төшендек. Эш барышында фәнни, әдәби һәм матбугат материаллары белән эшләдек, өлешчә эзләнүле методы кулландык. Татар милли ашлары өйрәнү өчен бай чыганаклардан санала. Моны өйрәнүне дәвам итәргә кирәк.

Кулланылган әдәбият:

1. Гаиләдә, балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен. – Казан: Мәгариф, 2005.

2. Әхлак нигезе – матур гадәт (Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү): Методик кулланма / , Р. Ә. Кадыйрова. – Казан: Мәгариф, 2004.
3. Иң матур сүз: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2000.
4. Балалар фольклоры / Төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.
5. Татар халык ашлары. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987.
6. Татарская кулинария.Ульяновский дом печати. 2002.
7. Мәктәпкәчә тәрбия: Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү / Төзүчесе . Фәнни редактор . – Казан: РИЦ “Школа”, 2000.

**Милли хәзинәләр студиясе**

***Нотфуллина Ландыш Миннулла кызы***

*Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*
*Алабуга муниципаль районының гомуми үсеш төрендәге*
*32 нче «Садко» балалар бакчасы*

«Милли белем һәм тәрбия бирүче хәзинәләр студиясе» инновацион мәйданчыгы ул – балалар Татарстан Республикасының шәһәрләрендә яшәүче төрле халыкларның мәдәнияте һәм көнкүреше белән таныша торган территория.

Проектның кыскача тасвирламасы.

Безнең балалар бакчасы базасында проект кысаларында, инновацион мәйданчык оештыру планлаштырыла, анда һәр бала, теләсә кайсы милләт вәкиле, үзе теләгән милли колоритлы продукт булдыруда катнаша алачак. Проект балалар, педагоглар, шулай ук ата-аналар катнашында танып-белүгә юнәлтелгән, үстерелешле һәм этномәдәни чаралар комплексын үз эченә ала:

- туган телдә шигырьләр, мәкальләр, табышмаклар, санамышлар, халык уеннары, җырлар, диалоглар, бишек җырлары өйрәнү;
- татар, рус, мари, чуаш, башкорт, әзербайҗан һәм башка милләтләрнең милли орнаментлары белән театральләштерелгән тамашалар өчен персонажлар һәм декорацияләр әзерләү.
- тамашалар өчен милли колоритлы музыкаль композицияләр сайлау;

- тамашачыга үз спектакльләрен тәкъдим итү.

Проект кысаларында инновацион мәйданчыкта көндәлек режим кысаларында атнага ике тапкыр эшчәнлек үткәрү планлаштырыла. Балалар студиясенең булуы Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен өйрәнүне оештыру өчен шартлар тудыруны тәэмин итәчәк, шул исәптән белем бирү оешмасының матди-техник базасын ныгытачак. Студиянең урнашуы балалар бакчасы территориясендә күздә тотыла. Моның өчен кирәкле шартлар бар: туган тел кабинетындагы буш мәйдан балалар студиясен кирәкле материаллар, шулай ук өстәмә элементлар белән җиһазларга мөмкинлек бирә.

Проектның максатлары һәм бурычлары.

Максат: Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телен, тарихын, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү буенча мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә чаралар оештыру өчен шартлар тудыру.

Бурычлар:

- туган телне өйрәнүгә, үз продуктыңны (спектакльне) булдырганда баланы рухи яктан эмоциональ, гармонияле шәхес итеп үстерүгә юнәлдерелгән педагогик процессны яңарту ;

- Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре турында балаларның күзаллауларын киңәйтү;

- Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче татар, рус һәм башка халыкларның бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру;

- үз спектакльләрен булдыру аша татар, рус һәм башка халыкларның милли мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, торгызу, саклау һәм үстерүгә ярдәм итү.

Проектның инновацион әһәмиятен нигезләү.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында Россия җәмгыятенең нигезе буларак, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау, гомумроссия гражданлыгын һәм Татарстанга тәңгәллеген ныгыту бик мөһим бурыч булып тора. Һәр халыкның үзенчәлеге аның теленнән башлана. Туган тел бәйләүче чылбыр буларак теләсә кайсы халык вәкилләренә үз-үзләрен һәм мәдәниятләрен саклап калырга ярдәм итә. Һәр тел, кемнеке булуга карамастан, күп санлы милләт, яки аз санлы халыкныкымы — ул хәзинә, һәм без аны сакларга тиеш. Шуңа күрә туган телне саклау һәм үстерү кебек проблеманы читләтеп үтеп булмый.

Татарстан Республикасы – күпмилләтле территория. Бүгенге көн яшьләре туган телдә аз сөйли, үз халкының күренекле вәкилләрен һәм көндәлек гореф-гадәтләрен атый, мәдәни казанышлары турында сөйли алмый. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә туган телне өйрәнү, кагыйдә буларак, традицион формада уза. Әмма, проблема шунда ки, замана балалары телевизор карау һәм компьютер яки телефондагы уеннарга күп вакыт сарыф итәләр. Шуңа күрә хәзерге вакытта балалар белән белем бирү һәм тәрбия эшен оештыруда традицион

булмаган алымнарны куллану зарур. Бу проблеманы хәл итү өчен мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә милли колоритлы продуктлар әзерләүче студия оештыру булышачак.

Үз продуктыңны булдыруның төп кыйммәте, барыннан да элек, балаларның комплекслы үсеше: иҗади һәм коммуникатив сәләтләрен үстерү, онытылган технологияләрне үзләштерү. Моңа ихтыяҗ бар һәм ул актуаль. Ә кечкенә бөртекләрдән башлап, милли колоритлы үз спектакльләребезне булдыруга җәлеп итү балаларга Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен өйрәнүгә мөмкинлек бирәчәк. Спектакльне булдыру өстендә эшләгәндә, бала иҗади атмосферага чума алачак, ул баланың теге яки бу халык турында күзаллауларын киңәйтергә, димәк, ата-бабаларыбызның хәтерен сакларга һәм патриотизм, мәхәббәт һәм туган илгә карата хөрмәт формалаштыру өчен шартлар тудырачак.

Проектны тормышка ашыру буенча планлаштырылган чаралар.

- проектның планын төзү;
- мастер-класс үткәрү;
- спектакльләр өчен персонажлар һәм декорацияләр әзерләү:
- спектакльне кую;
- спектакльне монтажлау.
- әзер продуктны башкаларга тәкъдим итү.

Проектның ресурслар белән тәэмин ителеше.

Проектны тормышка ашыру өчен матди-техник шартлар булу.

Проектның методик тәэмин ителеше:

- Учреждениедә Идел буе халыкларының мәдәниятен, әдәбиятын һәм милли телләрен өйрәнү өчен билгеләнгән электрон мультимедиа балалар онлайн-китапханәсенә язылу бар;
- Дәүләт телләренә өйрәтү буенча укыту - методик комплекслары бар (авторлары-Зарипова З. М., Исаева Р. С, Кидрячева Р. Г), «Туган телдә сөйләшәбез» (авторлары-Зарипова З. М., Взиева Л. Н., Зөфәрова Р. С)). - «Балалар бакчасында сөйләмне үстерү» методик әсбаплары (авторы Гербова В.В.). «Туганнан мәктәпкә кадәр» программасы буенча укыту-методик комплекты .

Кадрлар:

- тәрбияченең үз белемеңне күтәрү темасы: “ Мәктәпкәчә яштәге балаларның коммуникатив сәләтләрен милли театр педагогикасын куллану процессында үстерү.”
- Балаларны ана теленә өйрәтү буенча тәрбияченең эш тәҗрибәсе бар.

Проектның максатчан төркемнәре.

Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары оештырган чараларга һәрвакыт кече яштәге төркемнәрдә тәрбияләнүчеләр тамашачылар буларак чакырыла. Алар Татарстан Республикасы

территориясендә яшәүче халыкларның гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте үзенчәлекләре турында башлангыч белем алалар. Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары иҗат иткән барлык нәрсә дә кечкенә тамашачыга күрсәтелә.

Проектның көтелгән нәтиҗәләре.

Сан буенча нәтиҗәләр:

- Проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе базасында бер студия эшли.

- Проектны тормышка ашыручы чараларда катнашучы балалар саны - 80;

- Студиядә шөгыльләнүче балалар саны 40 (зурлар, мәктәпкә әзерлек төркеме балалары)

Тамашачыларга күрсәтелгән спектакльләрнең саны – 5, алар арасында: татар телендә иҗат ителгән спектакльләр саны – 2, рус телендә иҗат ителгән спектакльләр саны – 3.

Проектның сыйфатлылыгы нәтиҗәләре:

- Балалар тарафыннан үз спектакльләрен булдыру технологияләрен үзләштерү, балаларның игътибарын Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен өйрәнүгә җәлеп итү.

- Балаларның сүзлек запасын баету, туган телдә сөйләмен активлаштыру, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче теге яки бу халык турында күзаллауны киңәйтү.

- Ата-бабаларыбыз турында хәтер саклау һәм патриотизм, кече Ватанга мәхәббәт һәм хөрмәт формалаштыру.

- Мәгариф эшчәнлеген яңарту һәм тәрбия-белем бирү процессының сыйфатын үзгәртү, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә инновацион эшчәнлекне үстерү.

- Ата-аналарның балалар белән эшләүнең төрле һәм инновацион формаларына булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

- ИКТ өлкәсендә педагогларның һөнәри дәрәҗәсен күтәрү.

**Проектның календар планы.**

| № | Дата | Чараның исеме һәм эчтәлеге. | Проектның бурычлары | Әти-әниләр һәм социаль партнерлар белән эш. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Август | Проектның стратегиясен эшләү . | Проектның командасын һәм эш планын төзү. Норматив-хокукый актларны һәм методик әдәбиятны өйрәнү. Милли мохитле студия моделен уйлап табу. Студиянең календарь эш планын төзү. | Мәдәни социаль үзәктә урнашкан китапханә хезмәткәрләрен план төзүгә җәлеп итү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 2 | Сентябрь | Бакчаның интернеттагы битендә проект башлау турында мәгълүмат урнаштыру. | Проектка җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү. | Әти-әниләргә проект турында хәбәр итү. |
| 3 | Сентябрь | Балалар бакчасы базасында милли студия оештыру (спектакль, мастер-класс, әкиятләр һ.б.) | Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятен һәм традицияләрен өйрәнү өчен шартлар тудыру. | Әти-әниләрдән студия оештыруда ярдәм итүләрен сорау. |
| 4 | Сентябрь | Балаларга өстәмә белем бирү максатыннан мастер - класс оештыру. | Милли театр педагогикасын һәм ИКТ куллану өлкәсендә педагогларның һөнәри белем дәрәҗәсен күтәрү. | Педагогларны проектны тормышка ашыруга җәлеп итү. |
| 5 | Сентябрь-октябрь | Балалар милли студиясен оештыру өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру.<br>Матур әдәбият һәм дидактик кулланмалар сатып алу | Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятен һәм традицияләрен өйрәнү өчен милли студияне җиһазлау. | Әти-әниләрдән студия оештыруда ярдәм итүләрен сорау. |
| 6 | Октябрь–май | Милли студиядә танып-белү, үстерелешле һәм этномәдәни эшчәнлекләр оештыру. | Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен өйрәнүгә балаларның игътибарын җәлеп итү өчен үз спектакльләрен булдыру технологияләрен үзләштерү, | Ял вакытларында үзебезнең җирлектә яшәүче халыклар турында әңгәмәләр оештыру. |
| 7 | Октябрь | Кереш дәрес: «Театр дөньясына сәяхәт». | Театр тарихы, аның төрләре һәм милли студия белән танышу. | |
| 8 | Октябрь | «Карак песи» автор әкияте мотивлары буенча татар телендә әкият булдыру буенча балаларның комплекслы белем бирү һәм иҗади эшчәнлеге: | Балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Әти-әниләрдән персонажлар һәм декорацияләр әзерләүдә ярдәм итүләрен сорау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | - дидактик уеннар һәм кулланмалар белән эшләү, матур әдәбият уку;<br>-татар телендә шигырьләр, җырлар, диалоглар, бишек җырлары өйрәнү;<br>-татар милләтенең милли орнаментлары элементлары белән персонажлар һәм декорацияләр әзерләү;<br>- театр барганда яңгырату өчен милли колоритлы музыкаль композицияләр сайлау. | | |
| 9 | Октябрь | Балалар үзләре ясаган «Карак песи» автор әкиятен кечкенә тамашачыларга күрсәтү.<br>Әкият төшерү һәм монтажлау. | Казанышларны күрсәтү, балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Өйдә әхлак, хезмәт темасына әңгәмә оештыру. |
| 10 | Октябрь | Интернет челтәрендә «Карак песи» автор әкияте буенча әкиятнең видеосын урнаштыру. | Татар халкының бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру. | |
| 11 | Ноябрь 2023 | «Тылсымлы пумала маҗарасы» (И.И. Шишкинга багышланган) автор әкиятен иҗат итү буенча балаларның комплекслы белем бирү һәм иҗат эшчәнлеге:<br>-шигырьләр, җырлар, диалоглар өйрәнү;<br>- милли орнаментлар элементлары белән әкият өчен персонажлар һәм декорацияләр әзерләү;<br>- әкият барышында яңгырату өчен музыкаль композицияләр сайлау;<br>- әкиятне төшерү һәм монтажлау. | Балаларның туган шәһәрләре турында күзаллауларын киңәйтергә мөмкинлек бирүче иҗади атмосфераны булдыру, патриотизм һәм кече Ватанга карата хөрмәт формалаштыру өчен шартлар тудыру. | И.И. Шишкинның картиналарын карау, фотога фотога төшү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | Ноябрь | «Тылсымлы пумала маҗарасы» автор әкиятен кечкенә тамашачыларга күрсәтү. | Балаларның игътибарын шәһәрнең бай тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынуга этәрү. | Фотолардан презентация ясау һәм студиягә йөрүче балаларга тәкъдим итү. |
| 13 | Ноябрь | «Тылсымлы пумала маҗарасы» исемле автор әкиятен Интернет челтәрендә урнаштыру. | Патриотизм, Ватанга мәхәббәт һәм хөрмәтне популярлаштыру. | |
| 14 | Ноябрь | Тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары өчен иҗади кичәдә үз спектакльләрен тәкъдим итү. | Казанышлар күрсәтү, балаларның игътибарын проектның социаль әһәмиятенә җәлеп итү. | Балаларның казанышларын эти-әниләргә тәкдим итү. |
| 15 | Декабрь | А. Алиш әкиятенә нигезләнеп "Койрыклар маҗарасы» автор әсәре мотивлары буенча татар телендә әкият булдыру буенча балаларның комплексны белем бирү һәм иҗади эшчәнлеге:<br>- дидактик уеннар һәм кулланмалар белән эшләү, матур әдәбият уку;<br>-татар телендә шигырьләр, җырлар, диалоглар, бишек җырлары өйрәнү;<br>-татар милләтенең милли орнаментларын кулланып спектакль өчен персонажлар һәм декорацияләр әзерләү;<br>- татар милли музыкаль композицияләрен сайлау.<br>Спектакльне төшерү һәм монтажлау. | Балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Әти-әниләрдән персонажлар һәм декорацияләр әзерләүдә ярдәм итүләрен сорау. |
| 16 | Декабрь | «Койрыклар маҗарасы» автор әкиятен кечкенә тамашачыларга күрсәтү. | Балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Өйдә Абдулла Алиш әкиятләре буенча эшләнгән мульфильмнар карау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17 | Декабрь | «Койрыклар маҗарасы» автор әкияте видеосын урнаштыру. | Татар халкының бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру. | Балаларның казанышларын әти-әниләргә һәм киң җәмәгатьчелеккә тәкдим итү. |
| 18 | Декабрь | Ата-аналар арасында анкета үткәрү. | Ата-аналарның тәрбияләнүчеләрнең туган телне өйрәнүе белән кызыксынуы дәрәҗәсен анализлау. | Туган телне саклау буенча эшне төрләндерү. |
| 19 | Январь | Балаларның татар телендә «Теремкәй» спектаклен булдыру буенча комплекслы белем бирү һәм иҗади эшчәнлеге:<br>-шигырьләр, җырлар, диалоглар, өйрәнү;<br>- украин һәм әзербайҗан халыкларының милли орнаментлары элементлары белән персонажлар һәм декорацияләр әзерләү<br>- украин һәм әзербайҗан музыкаль композицияләрен сайлау.<br>Спектакльне төшерү һәм монтажлау. | Балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Үзебез яшәгән җирлектә яшәче халыклар турында кызыклы мәгълүматларны балаларга җиткерү. |
| 20 | Гыйнвар | “Теремкәй” спектаклен кечкенә тамашачыларга күрсәтү. | Казанышларны күрсәтү, балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм татар халкының мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Үзебез яшәгән җирлектә яшәче халыклар турында кызыклы мәгълүматларны балаларга җиткерү. |
| 21 | Гыйнвар | «Теремкәй» спектакле видеосын урнаштыру | Казанышларын күрсәтү. | Балаларның казанышларын әти-әниләргә һәм киң |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | җәмәгатьчелеккә тәкдим итү. |
| 22 | Февраль | Балаларның татар телендә «Тукай әкиятләренә ияреп...” әкиятен булдыру буенча комплексслы белем бирү һәм иҗади эшчәнлеге:<br>- дидактик уеннар һәм кулланмалар белән эшләү, матур әдәбият уку<br>-татар телендә шигырьләр, җырлар, диалоглар өйрәнү;<br>-татар милләтенең киемнәрендәге орнаментлары белән әкияткә персонажлар һәм декорацияләр әзерләү;<br>- татар милли музыкаль композицияләрен сайлау.<br>Әкиятне төшерү һәм монтажлау. | Балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Әти-әниләрдән персонажлар һәм декорацияләр әзерләүдә ярдәм итүләрен сорау. |
| 23 | Февраль | «Тукай әкиятләренә ияреп...» әкиятен кечкенә тамашачыларга күрсәтү. | Казанышларны күрсәтү, балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм татар халкының мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Өйдә балалар белән хезмәт сөючәнлек, ярдәмчеллек турында әңгәмә. |
| 24 | Февраль | «Тукай әкиятләренә ияреп...» әкияте видеосын урнаштыру | Татар халкының бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру. | Балаларның казанышларын әти-әниләргә һәм киң җәмәгатьчелеккә тәкдим итү. |
| 25 | Март | Балаларның татар телендә башкорт халкының “Рәхмәтле куян” спектаклен булдыру буенча комплексслы белем бирү һәм иҗади эшчәнлеге:<br>- дидактик уеннар | Иҗади атмосфера тудыру, балаларның игътибарын башкорт халкының традицияләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү | Идел буенда яшәүче халыкларның әкиятләре күргәзмәсен карау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | һәм кулланмалар белән эшләү, матур әдәбият уку<br>-татар телендә шигырьләр, җырлар, диалоглар өйрәнү;<br>- башкорт милләтенең киемнәрендәге орнаментлары белән спектакльгә персонажлар һәм декорацияләр әзерләү;<br>- башкорт милли музыкаль композицияләрен сайлау.<br>Спектакльне төшерү һәм монтажлау. | | |
| 26 | Март | «Рәхмәтле куян» спектаклен кечкенә тамашачыларга күрсәтү. | Казанышларны күрсәтү, балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм башкорт халкының тугандаш булуына җәлеп итү. | Башкорт халкының татар халкына тугандаш булуын тормыштагы мисаллар белән төшендерү. |
| 27 | Март | «Рәхмәтле куян» спектакле видеосын урнаштыру | Татар халкының бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру. | Балаларның казанышларын әти-әниләргә һәм киң җәмәгатьчелеккә тәкдим итү. |
| 28 | Март | Әти-әниләр өчен мастер-класс «Үз кулларыбыз белән » | Әти-әниләрнең игътибарын милли студия эшчәнлегенә җәлеп итү. | Әти-әниләрнең кәефләрен күтәрү. |
| 29 | Апрель | «А.Алиш әкиятләре буенча сәяхәт» дип исемләнгән татар телендәге спектакль төшерү буенча балаларның комплекслы белем бирү һәм иҗади эшчәнлеге:<br>-татар телендә | Балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | шигырьләр, җырлар, диалоглар, бишек җырлары өйрәнү;<br>- милли орнаментлар элементлары белән персонажлар һәм декорацияләр әзерләү<br>-татар милли музыкаль композицияләрен сайлау.<br>Спектакльне төшерү һәм монтажлау. | | |
| 30 | Апрель | «А.Алиш әкиятләре буенча сәяхәт» тамашасын кечкенә тамашачыларга күрсәтү. | Казанышларны күрсәтү, балаларның игътибарын татар телен, гореф-гадәтләрен һәм татар халкының мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | А.Алишның балачагы турында кызыклы мәгълүматларны балаларга җиткерү. |
| 31 | Апрель | «А.Алиш әкиятләре буенча сәяхәт» спектакле видеосын урнаштыру. | Татар халкының бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру. | А.Алиш әкиятләре турында киң җәмәгатьчелеккә җиткерү. |
| 32 | Май | Балаларның рус телендә «Идел буенда яшәүче биш халык турында әкият" спектаклен булдыру буенча комплекслы белем бирү һәм иҗади эшчәнлеге:<br>- дидактик уеннар һәм кулланмалар белән эшләү, матур әдәбият уку;<br>-рус телендә шигырьләр, җырлар, диалоглар өйрәнү;<br>- башкорт милләтенең киемнәрендәге орнаментлары белән спектакльгә персонажлар һәм декорацияләр | Иҗади атмосфера тудыру, балаларның игътибарын Идел буе халыклары (башкорт, чуаш, мари, удмурт, мордва ) традицияләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Әти-әниләрдән персонажлар һәм декорацияләр әзерләүдә ярдәм итүләрен сорау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | әзерләү;<br>- башкорт милли музыкаль композицияләрен сайлау.<br>Спектакльне төшерү һәм монтажлау. | | |
| 33 | Май | «Идел буенда яшәүче биш халык турында әкият” спектаклен кечкенә тамашачыларга күрсәтү. | Казанышларны күрсәтү, балаларның игътибарын Идел буе халыклары традицияләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә җәлеп итү. | Өйдә балалар белән бергә Идел буенда яшәүче халыкларның милли ризыкларын пешерү. Бакчада чәй эчү оештыру. |
| 34 | Май | Идел буенда яшәүче биш халык турында әкият” спектаклен социаль челтәрдә урнаштыру. | Идел буенда яшәүче халыкларының бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру. | Үз җирлегебездә яшәүче халыклар турында кызыклы мәгълүматларны балаларга җиткерү. |
| 35 | Май | “Милли хәзинәләр студиясе” җыентыгын булдыру. | Студиянең эш тәҗрибәсен гомумиләштерү. | “Милли хәзинәләр студиясе” эшенең нәтиҗәсен киң җәмәгатьчелеккә тәкдим итү. |
| 36 | Гыйнвар май | Балалар иҗаты конкурсларында һәм фестивальләрендә катнашу. | Милли студия эшенең нәтиҗәлелеген күрсәтү. | Эш тәҗрибәсе белән Алабуга шәһәрендә үтүче педагогларның май киңәшмәсендә чыгыш ясау. |

**«Татар-халык ашлары» проекты**

***Галиәскәрова Гөлфия Фәлах кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*катнаш төрдәге "Шаян" Биектау балалар бакчасы*
*Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*

**Кереш**

Татар халкы бик борынгыдан ук аш-су әзерләргә оста булган, тәмле оригиналь ашлар пешергән. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган. Татарлар элек-электән иген иккән,шуңа күрә оннан, ярмадан ашлар әзерләгән, арыш, бодай, карабодай, борчак, арпа һәм солы онын, тары, карабодай, борчак һәм борай, соңрак дөге ярмасын киң кулланган. Крестьян халкы тарттырмыйча гына борчак белән ясмыктан төрле ашамлыклар әзерләгән. Ит, бигрәк тә сарык,сыер һәм ат(тай) ите татарларның яраткан ашы булган. Яңа суйган терлек итен өстенрәк күргәннәр, әмма җәен,саклар урын булмаганлыктан, тозлы һәм каклаган ит тә кулланганнар. Иттән аш, шулпа пешергәннәр, аштан алган итне еш кына шулпадан соң биргәннәр. Ат итен аеруча яратып ашаганнар, чөнки ул бик туклыклы, халык арасында хәтта ат ите ашаган кеше салкынга бирешми, ару-талуны белми дигән фикер дә яшәгән. Борынгы татар ашлары арасында тавык, каз, үрдәк, күркәдән әзерләнгән ашамлыклар шактый булган,терлек һәм кош итен күбрәк пешереп кулланганнар. Итне бик сирәк, бай татарлар бәйрәм табынына гына кыздырып биргәннәр. Татар ашлары арасында сөт азыклары зур урын алып торган. Ләкин сөтне шул килеш кенә сирәк кулланганнар, чәйгә салып эчкәннәр яисә ашамлыкларга салганнар.Сөттән май язганнар,сөзмә, эремчек, катык, коймак, корт ясаганнар. Татарлар ясаган атлан май бөтен тирә-юньдә дан тоткан. Йомырканы төрлечә пешергәннәр, ашка салганнар,тәбә әзерләгәннәр, камырга һәм төрле бәлешләргә сытканнар. Сабантуй вакытларында ул традицион ашамлык булып саналган. Балыкны азрак кулланганнар. Корбан балыгы, сазан, судак кебек балыкларны кыздырганнар, алардан бәлеш салганнар. Елга балыгыннан тәбә пешергәннәр. Яшелчәләрне күбрәк бәлеш эченә салганнар һәм башка ашамлык янына биргәннәр. Яшелчәләрдән- кабак, чөгендер, суган, шалкан, кишер, ачы торма, кыяр һәм кәбестәне күп кулланганнар. Авыл кешеләре кыргый үләннәрдән: балтырган, кузгалак, кычыткан, көтүче сумкасы, мәтрүшкә, кыр суганыннан беренче һәм икенче ашлар, бәлеш эчләре әзерләгәннәр.

Сонгы елларда халкыбызның гореф – гадәтләрен, йолаларын өйрәнүгә, аларны укыту тәрбия эшендә куллануга игътибар артты.Шуна күрә без зурлар төркеме белән татар-халык ашлары дигән темага альбом карарга булдык.Без бу альбомны караганда балалар бик күп сораулар бирделәр, бигрәктә татар-халык ашларының нинди эчлекләр кулланып ясалганын,

тагын нинди тәмле ризыклар барлыгын, аның тарихын беләселәре килде. Бу теманы өйрәнер өчен мин 1 ай күләмендә проект эшчәнлеген алып бардым. Балаларга , татар халкының нинди ашлары барлыгын кечкенәдән үк өйрәтергә кирәк.Бу эшне без мәктәпкәчә яшьтәге балаларга өйрәтә башласак бик әйбәт булыр иде .Чөнки бу яшьтә баланың үсеше, хәтере һәм кызыксынучанлыгы бик зур.

**1. Проект төре:** информацион-практик юнәлешле.

**2. Проектның дәвамлылыгы:** 1 ай.

**3. Максат: балаларны татар халык ашлары белән таныштыру.**

**4. Бурычлар:**

1. Пешекче хезмәтенә хөрмәт белән карау. Ата-аналарда балалар бакчасы хезмәткәрләре белән уңай мөнәсәбәтләр булдыру.

2. Төгәллек, игътибарлылык, мөстәкыйльлек, пөхтәлек сыйфатлары булдыру. Үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе тудыру.

3. Татар халык ашлары турында төшенчә бирү, милли ризыклар турында белемнәрен киңәйтү.

**5.Проектның методлары:**

**Практик юнәлеше**:проект эшчәнлеген алып бару өчен кирәк булган тирә-юнь мохитен булдыру.

**Сүз методы**: Әңгәмә, күзәтү, матур әдәбият уку, табышмаклар, шигырьләр, җырлар өйрәнү, дидактик уеннар, с\р уеннар уйнау.

**Күрсәтмәлек**: күргәзмә, конкурс, шөгыль, күңел ачу бәйрәме, проект өчен материаллар туплау, рәсем, альбомнар карау.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

1. Балалар татар халык ашлары , гореф-гадәтләре турында белемнәрен киңәйтергә.

2. Милли ризык – өчпочмакны, бәлешне һ.б алар әти-әниләр белән өйдә пешереп карарга.

3. Пешекче хезмәтенә ихтирам хисе белән карарга.

4. Балаларда үз хезмәтенең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе уятырга.

5. Балалар ризыкка хөрмәт белән карау, әхлак кагыйдәләрен яхшы белергә.

6. Ата-аналарда балалар бакчасы хезмәткәрләре белән уңай мөнәсәбәтләрне

дәвам итү теләген булдырырга.

**6. Проектның этаплары:**

**I. Әзерлек этабы:**

- проектның темасын уйлау;

- проектның төрен билгеләү;

- максатын кую;

- бурычларын уйлау;

- перспектив планын язу;

- атрибутлар әзерлә- материаллар туплау;

- пешекчеләр белән сөйләшү;

- эти-әниләрне проект белән таныштыру, биремнәр бирү;

- проектны башкарып чыгу өчен шартлар тудыру.

-эти-әниләр белән анкетирование үткәрү.

- пешекчеләр белән сөйләшү;

- эти-әниләрне проект белән таныштыру, биремнәр бирү;

- проектны башкарып чыгу өчен шартлар тудыру.

- эти-әниләр белән анкетирование үткәрү.

**II. Төп этап**

| Атна көннәре | Балалар белән эшчәнлек | Әти-әни белән эш | Әйләнә-тирә мөхитны баету |
|---|---|---|---|
| 8.02 | «Татар –халык ашлары»дигән темага әңгәмә, китап карау. | Әти-әниләрне проектның темасы һәм структурасы белән таныштыру.Анкета тутыру | Дидактик уеннарга атрибутлар ясау турында әңгәмә, өстәмә эдэбият уку. |
| 12.02 | Татар халык ашлары турында табышмаклар, уеннар,макальләр, санамышлар өйрәнү. | Өйгә бирелгән материалны балалар белән ныгыту, атрибутлар ясарга материал җыю. | Д/уен өчен бәлеш, өчпочмак,чәкчәк, кыстыбый ясау(җептән, паралоннан,чүпрәктән) |
| 15.02 | Шигырьләр, җырлар, уеннар өйрәнү. | Д/уен өчен атрибутлар әзерләү. | Татар –халык ашлары турында материал туплап альбом чыгару. |
| 18.02 | «Минем яраткан ризыгым» рәсем конкурсы. | Өйдә балалар белән рәсем ясау. | Рәсемнәрдән күргәзмә ясау. |
| 21.02 | Шөгыль эшчәнлеге «Татар халык ашлары». Өйрәнелгән табышмак,мәкальләрне кабатлау. | Шөгыль өчен: авыл өе куренеше, савыт-саба, скәтер, самавыр, алъяпкыч табырга булышу. | Һәр балага мамык дискларыннан кисеп ябыштырылган чәк-чәкле альбом бите ясау. |
| 27.02 | Әвәләү конкурсы «Оста пешекче» | Татар –халык ашларын балалар белән өйдә | С/рольле уены «Кафе», «Буфет» |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Сценарий буенча җыр «Кунаклар», шигырьләр,бию«Әпипә” өйрәнү. | пешерү. Әти-әни булышлыгы белән сценарий материалын кабатлау. | өчен кирәкле атрибутларны эшләү.Бәйрәм кичәсенә әзерләнү. |
| 28.02 | Күңел ачу кичәсе «Милли кичә» үткәрү. | Балаларны матур итеп киендереп бәйрәмгә килү. | Кичә өчен пешекчеләр ярдәмендә коймак пешерү.Бәйрәмдә төшкән фота материалларны туплау. |

**Балалар бакчасы хезмәткәрләре, тәрбиячеләр белән эш:**

1. Ашханә бүлмәсенә сәяхәт. Пешекчеләр хезмәтен, аш-су җиһазларын читтән күзәтү (кәстрүл, табалар, сөзгеч, чүмечләр, су баклары, ит тарткыч).

2. Пешекче белән сөйләшү, сөйләшү вакытында пешерү күнекмәләре, куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышу.

- пычак белән сак эш итәргә;

- янып торган плитәгә якын килмәскә;

- кайнар әйберләрне бияләй белән тотарга;

- электр приборларына юеш кул белән тотынмаска.

**III этап.Тәмамлау.**

**Балалар белән эшчәнлек:**

3. Балалар рәсемнәре конкурсы. «Минем яраткан ризыгым».

4. Балалар белән шөгыль эшчәнлеге. Тема: «Татар халык ашлары »

6.Татар халык ризыкларына конкурс. «Оста пешекче » (Әвәләү)

7.Дидактик уеннар:

- «Өчпочмак ясау өчен нинда яшелчәләр кирәк? »
- «Кунакка чакыру»
- «Пешекче киемен ки»
- «Камыр җәю »
- « Кафе», «Буфет».

8.Балалар белән шөгыль эшчәнлеге «Татар халык ашлары».

9.Күңел ачу кичәсе «Милли кичә»

**« Халкымның күңел сандыгы» проекты**

***Хисмәтуллина Л.Р.***

***Фәйзуллина Г.Ф.***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының*

*«Арча 10 нчы балалар бакчасы» муниципаль*

*бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

***Хәтерләүдән курыкма син!***
***Үткәннәрне онытма син.***
***Бел син ерак бабайларның***
***Ничек итеп көн иткәнен.***
***Нинди уйлар, нинди моңнар***
***Безгә калдырып киткәнен.***

Халкыбызның гореф-гадәтләрен әхлак тәрбиясенең «бакчасы» диеп күз алдына китерергә була. Ә менә шул бакчада бик күп төрле җимеш бирүче агачлар үсә. Шушы әхлак тәрбиясенең бакчасына үтеп керү өчен, шундагы «җимешләрне» танып белергә һәм көндәлек тормышта куллана белергә өйрәнергә кирәк.

«Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклагангынамы?» Юк, үлмәгән дә, йокламаган да, ул милли үзаңының яңарыш чорын кичерә. Менә шушы чорда бик күп сорауларга җавап табасы килә. Без кем? Ата-бабаларыбыз кем? Ничек көн иткәннәр? Ни белән шөгыльләнгәннәр?

Р.Фәйзуллин

**Теманың актуальлеге**:

«Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк», - диләр.

Һәр халыкның традицияләре, йолалары үзенчәлекле. Хәзерге вакытта җәмгыятнең үсешендә милләтләр арасында толерантлык тәрбияләүне мәктәпкәчә яшьтә үк башлап җибәрү бигрәк тә актуаль булып тора. Шуның өчен дә үзеңнең халкыңның һәм милләтеңнең мәдәниятен,йолаларын, үткәнен, бүгенгесен белмичә торып , башка милләтләрнең рухи байлыгын аңлап булмыйдыр мөгаен.

Халык сәнгате, традицияләре белән якыннан танышу, бәйрәмнәрендә катнашу, балаларны рухи яктан баета, үзенең халкы өчен горулану хисләре тәрбияли һәм аның тарихына, мәдәниятенә кызыксыну уята. Баланы милли көнкүрешкә, сөйләмгә, җырларга өйрәтү, халык йолаларын, югалтмыйча саклау, кече Ватаныбызга карата мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә төп этәргеч көч булып тора. Татар халкының әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләренең онытылуы, балаларның халкыбызның милли киемнәрен белмәве бик аяныч хәл. Элек-электән үк татар гаиләсендә булган милли киемнәргә, традицияләргә карата

балаларда кызыксыну, ихтирам, хөрмәткә лаек булган матур традиция саклансын иде. Балаларны халкыбызның күңел бизәкләре белән яккыннан таныштыру, нәфис бизәлешенә соклану, эстетик зәвык аша әхлак тәрбиясе бирү – бүгенге көндә актуаль булып кала.

**Проектның максаты:**

-Балаларны татар халкының мәдәниятенә тарту.

-Балаларны татар халык киемнәре, аларның үзенчәлекләре, кагыйдәләре белән якыннан таныштыру.

-Татарстан күпмилләтле республика буларак, милләтләр арасында толерантлык хисе тәрбияләү.

- Балаларда халкыбызның хәзинәләренә кызыксыну уяту, нәниләрнең күңелен халкыбызның хәзинәләре байлыгы белән тулыландыру

-Ата-аналар белән берлектә әби-бабаларыбызның борынгы мирасы турында мәгълүмат бирү.

**Проектның бурычлары:**

1.Татар халкының милли мәдәниятенә, сәнгатенә, йолаларына, уеннарына карата кызыксыну тәрбияләү.

-Үзебезнең кече Ватаныбызга –шәһәребезгә, туган җиребезгә, өебезгә, гаиләбезгә карата мәхәббәт һәм ярату хисләре тәрбияләү.

-Балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре – әкиятләр, табышмаклар, мәкальләр,әйтенүләр, санамышлар һ.б. таныштыру.

-Балаларда татар халкының йолаларын,көнкүрешен өйрәнүләрен үстерү.

-Балаларда матурлыкны үз куллары белән барлыкка китерүне тәрбияләү.

-Татар халкының көнкүреше, милли бәйрәмнәре, йолалары белән кызыксынуларын үстереп, балаларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү.

-Йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрнең төрле милләт халыкларын якынайта һәм берләштерә торган чара икәнен дәлилләү

**Проектта катнашучылар:**

-Балалар

-Әти-әниләр

-Тәрбиячеләр

-Татар теле тәрбиячесе

-Музыка җитәкчесе

**Проектның тибы:**

Аерым төркем балалар һәм әти-әниләрне дә эшчәнлеккә тартып үткәрелә.

**Проектның дәвамлыгы:** февраль-апрель 2024нче уку елы.

Иҗади-эзләнү проекты

**Проектны тормышка ашыру юллары:**

-Татар халкының мәдәнияте, тарихы, йолалары, гореф-гадәтләретурында матур әдәбият аша танышу

-”Гаилә бәхете – балада” альбомы

-Әти-әниләр, дәүәниләр белән татар халык уеннарын, җырларын барлау,халык авыз-иҗатын өйрәнү, бәйрәм иртәләрендә катнашу

-Тема буенча аудио-видео материал туплау һәм куллану

**Әзерлек этабы.**

-Эшчәнлек, әңгәмәләр һәм уеннар өчен материал туплау.

-Күрсәтү өчен материал, илюстрацияләр , рәсемнәр, әдәбият җыйнау.

-Халык авыз иҗаты әсәрләре һәм фольклор сайлау.

-Татар халкының хәрәкәтле һәм түгәрәк уеннары картотекасын төзү.

-Әти-әниләр ярдәме белән көнкүреш предметлары һәм үстерешле мохит өчен материал туплау.

**Проект өстендә эш.**

Проектны тормышка ашыруда төп формалар:

-эшчәнлек

-экскурсияләр

-әңгәмәләр

-матур әдәбият уку

-бәйрәм иртәләре һәм күңел ачулар

-уен эшчәнлеге

-театральләштерү эшчәнлеге

-продуктив эшчәнлек

-ата-аналар белән эш.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

-Балаларга татар халкының мәдәнияте һәм йолаларын өйрәнү зур тәрбияви этәреш бирә. Проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә балаларда әхлакый-патриотик хисләр; милли үзаң нигезе;халык мәдәнияте буенча булган белемнәр формалаша:

-татар халкының язучылары, шагыйрьләре әсәрләренә, халык мәдәниятенә карата уңай эмоциональ караш усә

-бөек татар шагыйре Г.Тукай иҗатына кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләнә.

-балаларда фикерләү активлыгы, иҗади сәләтләре, үзара аралашу күнекмәләре үстерелә.

-ата-аналар  белән бердәм эшчәнлек ныгытыла

-татар халык   костюмнары булдырыла

-проектнын ахырында тубәндәге эшләр башкарыла:

-татар халкының өй  макеты

-фотоальбом ясау

-йомгаклау чарасы -“Мич котлау йоласы” кичә үткәреләә.

**Тематик  план**

| | Тема | Программа эчтәлеге | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Татар халык мәдәнияте һәм йолалары . | Балаларны татар халкының йолалары, бәйрәмнәре, көнкүреше белән таныштыру. Татар өенең күренеше , милли киемнәре, кәсебе, фольклор әсәрләре һәм шулай ук татар халык аш-суы турында күзаллау тудыру. | Проект дәверендә |
| 2. | Татар халык бәйрәмнәре һәм уеннары. | Балаларга татар халык бәйрәмнәре , кайчан, ничек уздырылуы, бәйрәм барышында нинди кагыйдәләр саклануы турында мәгълүмат бирү. Татар халык уеннары “Түбәтәй”,  “Кәрия-Зәкәрия”, “Йөзек салыш” уеннарын өйрәнү. | Февраль<br><br>Проект дәверендә |
| 3. | Татар милли бизәкләре | Татар милли бизәкләре  белән танышу.Танып белү эшчәнлеген формалаштыру һәм иҗади сәләтләрен арттыру. | Февраль |
| 4 . | Татар халкының милли киемнәре.(ирләр һәм хатын-кызлар киеме) | Балаларга татар халкының милли киемнәренең барлыкка килү тарихы, ир-ат (камзул, түбәтәй, читек) һәм хатын-кыз (күлмәк, калфак, альяпкыч) киемнәренең аерым элементларының исемнәре турында күзаллаулар тудыру. Татар халык бизәге белән  алъяпкыч  бизәү. | Март |
| 5. | Дидактик уен. Татар халык бизәге белән читек, тубәтәй, калфак, алъяпкыч  бизәү. | Чигүчеләр хезмәте белән таныштыруны дәвам итү; кызыксыну уяту; аларның күзаллавын, фантазиясен баету. | Март |
| 6. | Татар халкының кунакчыллыгы һәм аш-сулары. | Милли ашамлыклардан чәк-чәк, гөбәдия, бәлеш, кош теле, өчпочмак, кыстыбый һ.б. белән таныштыру. Әвәләү.   Татар халык милли ризыклары “Өчпочмак”, “Чәк-чәк” | Март |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Татар гаиләләрендә кунаклар кабул итү кагыйдәләре белән таныштыру. | |
| 7. | Татарстан Республикасы. Альбом карау. | Татарстан Республикасы , анда яшәүчеләр, туграсы, флагы,гимны һәм табигате белән таныштыру.<br>Татарстан Республикасының башкаласы – Казан шәһәре, истәлекле урыннары белән танышу. | |
| 8. | Татар халык авыз иҗаты ” Теле барның-иле бар” | Балаларны татар халык авыз иҗаты һәм фольклор әсәрләре белән таныштыру.<br>Еллар буе җыелып килгән, халык күзәтүләреннән чыгып төзелгән , мәкальләр белән танышу.<br>Татар халык әкиятләре белән таныштыру. | Проект дәверендә |
| 9. | Г Тукайның иҗаты һәм әкиятләре белән танышу Язучының иҗатына кагылышлы материал туплау | Балаларны Габдулла Тукай иҗаты белән таныштыру.<br>Г.Тукайның “Бала белән күбәләк” шигырен сәхнәләштерү. | Апрель |
| 10. | “Мич котлау йоласы” | Балаларның гаилә һәм аның йола-бәйрәмнәре турында күзаллауларын ныгыту. Гаиләдә саклана торган тарихи вакыйгалар белән бәйле әйберләргә карата кызыксыну уяту һәм шулар бәрабәренә сүзлек запасын баету. | Апрель |

1. Татарстан һәм Идел буе халыкларының гореф-гадәтләре, йолалары, мәдәнияте , аш-сулары , бәйрәмнәре, өс-баш киемнәре турында альбомнар карау.

2. Кичке якта татар халык авыз иҗаты һәм Г.Тукай әсәрләре белән балаларны таныштыру.

3. Балалар өчен китаплар күргәзмәсе.

4.Халык авыз иҗаты әсәрләрен балалар белән яттан өйрәнеп сөйләү.

5. Музыкаль эшчәнлек: татар халык җырларын һәм музыкаль уеннарын өйрәнү.

6. Биюләр кую.

**Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.**

1.Идел буе халыкларының иҗади-сәнгать әсәрләренең рәсемнәрен, Г.Тукай әсәрләренә ясалган илюстрацияләрне карау.

2. Мөстәкыйль иҗади сәнгать (рәсем, кисеп ябыштыру, әвәләү, буягычлар).

3. Иҗади театральләшкән эшчәнлек.

4.Татар халык уеннары уйнау.

**Ата-аналар, педагоглар һәм балалар белән бердәм эшчәнлек.**

1.Татар халык авыз иҗаты әсәрләрен уку.

2.Г.Тукай әсәрләренә багышлап балалар белән әти-әниләрнең рәсем эшләре.

3."Мич котлау йоласы" дигән йомгаклау бәйрәм кичәсендә әти-әниләрне дә катнаштыру.

**Проект эшчәнлегенең нәтиҗәләре.**

1.Балаларны татар халкының мәдәнияте,гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру өчен төркемдә һәм гаиләдә кирәкле шартлар булдырылды.

2.Халык бәйрәмнәренә карата, балаларны күңел ачу чыганагы итеп кенә түгел, танып белү, кызыксыну чыганагы итеп карау мөмкинлеге тудырылды.

3.Балаларда кызыксынучанлык, иҗади мөмкинлекләр, танып белү активлыгы, коммуникатив мөмкинлекләрен үстерелде.

4.Балаларны үзләрең уй фикерләрен әйтә белергә өйрәтелде.

5.Г.Тукайның иҗади эшчәнлеге һәм тормыш юлы белән таныштыру буенча эш системасы җайга салынды.

6.Проектны тормышка ашырганда ата-аналарның актив катнашучылар саны артты .

7.Бала тәрбияче сорауларына теләп, ышанычлы итеп тулы итеп җавап бирергә өйрәнде, өйрәнгән тема буенча белемнәрен арттырылды.

8.Татар халкының көнкүреше, киемнәре турында күзаллаулары үстерелде.

9.Балалар бакчасы, әти-әниләр, балалар арасындагы бәйләнеш ныгытылды.

10.Балалар үзләрен әби-бабаларының эшләрен дәвам итүчеләр итеп тойдылар.

**Проектның перспективалары:**

Киләчәктә Идел буе халыкларының ( татар һәм рус халкы) көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, йола-бәйрәмнәрен, авыз иҗаты әсәрләрен, уеннарын ,аш-суларын өйрәнүне дәвам итү.

**Йомгаклау**

Күргәнебезчә, халкыбызның йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Дөрестән дә, диннән, телдән башка яши алмаган кебек, халык алардан башка да милләт буларак яшәвеннән туктар иде. Татар халкы һәр вакыт үзенең йолаларына тугры булды. Чөнки алар безгә бик ерак бабаларыбыздан мирас булып калганнар. Тик онытмаска, сакларга , буыннан буынга җиткерергә иде аларны. Татар халкының борынгыдан килгән бәйрәмнәре, йолалары бүгенге көндә дә сакланган.
Адәм баласы әти-әнисен, туган җирен, ана телен, динен, гореф-гадәтләрен, йолаларын ихтирам итәргә тиеш. Табигый, буыннан буынга күчә торган рухи тәҗрибә һәм йолалар вакытлар узу белән һич тә әһәмиятләрен югалтмыйлар, киресенчә, аларның кыйммәте арта

гына. Моның шулай булуы әдәби әсәрләр мисалында тагын бер кат исбатлана. Соңгы елларда халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм бәйрәмнәренә игътибар арта бара, Сабантуйларын үткәрүгә, аларны халыкчанрак, җанлырак итүгә, Нәүрүз, бәйрәмен торгызуга һәм яңартуга, каз өмәләрен һ. б. ны тергезеп, көнкүрешебезгә кайтаруга омтылыш көчәя. Димәк, милли рухыбыз, шөкер, сүнеп үк бетмәгән әле!

Татарстан халыклары үзара дус, тату яши. Халыклар арасында дуслык бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер-берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер-берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта.

**"Балалар бакчасында рухи әхлакый тәрбия бирүдә музей педагогикасы"**

***Зиганшина Зөлфия Рафаэль кызы***

*Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының*
*«Зур Күккүз урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль белем бирү оешмасы балалар бакчасы*
1 категорияле тәрбияче

**Актуальлелеге.**

Музей педагогикасы ул - тарихи истәлекләрне, материаль һәм рухи культура байлыкларын саклау,өйрәнү һәм җиткерә торган фәнни-тикшеренү өлкәсе. Шул ук вакытта – балаларда чынбарлыкның кыйммәтен аңлап бәяли торган мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән тәрбия,белем бирү эшчәнлеге.

Музей тирәлегендә бала һәм олы кешенең үзара аралашуы, балаларның эзләнү, иҗат итү һәм тәрбия-белем бирү эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итә. Шул максаттан чыгып, без балалар белән даими рәвештә туган як тарихын өйрәнү музеена сәяхәт оештырабыз. Музейларда көнкүрешен әйберләрен тотып өйрәнү тормышка якынрак килергә,әби-бабаларыбызның тәртип-кагыйдәләрен эш коралларын барларга мөмкинчелек тудыра.

Татар халкының милли бизәкләре, көнкүрештә кулланылган җиһазлары белән таныштыру балаларда үз халкың белән горурлану хисләре тәрбияли. Яңа дәүләт таләпләре нигезендә

югары яшьтәге балаларның күзаллауларын киңәйтү өчен, танып-белүгә кызыксынучанлыгын һәрдаим үстереп торырга кирәк. Бу эш төрле-төрле алымнар һәм методикалар куллануны сорый. Шуннан чыгып туган як музейнда балалар белән: “Нәүрүз”, “Эх,күңелле яшь чаклар”, “Аулак өй”, “Күңелем җәүһәрләре” кичәләре үтте.
Милләтебезгә карата олы ихтирам хисләре тәрбияләгәндә, татар халкының милли мирасыннан файдалануга җитди игътибар ителергә тиеш, шунда гына мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телне яхшы үзләштерүләренә, аны ана теле итеп кабул итүләренә ирешергә безгә музей-педагогикасы ярдәмгә килә.

Татар баласын чын татар, милли рухлы әхлакый шәхес итеп үстерергә телибез икән, киләчәк буын иң беренче ата-бабаларның рухи хәзинәсен белергә тиеш. Ә рухи хәзинә музейларда саклана. Татар халкының милли бизәкләре,моңлы җырлары, мөнәҗәтләре, көнкүрештә кулланылган җиһазлары белән таныштыру,балаларда үз халкың белән горурлану хисләре тәрбияли. Шушы максатларга ирешү өчен без музей-педагогикасына игътибар итәбез һәм кулланабыз.

**Проектның проблемасы:**

Балалар һәм ата-аналарның халкыбыз хәзинәләре турында аз белүләре.

**Проектның максаты:**

Балаларны туган ягыбыз тарихы үткәне,гореф-гадәтләре,йола-бәйрәмнәре, эш кораллары белән таныштыру. Балаларда туган илгә,туган телгә мәхәббәт, әдәплелек, инсафлылык, кешелеклелек һәм рухи әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

**Проектның бурычлары:**

**Белем бирү бурычы**: Балаларны туган ягыбыз музее белән таныштыру;

Күренекле шәхесләр язучылар, дин әхелләре турында мәгълумат туплау;

Халкыбызның милли бизәкләре, көнкүреш җиһазлары атамаларын өйрәнү.

**Үстерү бурычы**: Уеннар аша балаларны иҗади фикерләү, уйлау сәләтләрен үстерү;

Милләтебезнең, туган җиребезнең эш кораллары тарихы белән кызыксындыру;

Халкыбызның гореф-гадәтләрен, йола бәйрәмнәрен өйрәнүләрен дәвам итү.

**Тәрбия бурычы**: Әби-бабаларыбызның хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү;

Җырлы – биюле уеннарга, бишек җырларына кызыксыну уяту.

Балаларның “элек” һәм “хәзер” дигән төшенчәне аңлауларына ирешү.

**Тәрбиячегә бурычлар:** Балаларда проектның актив катнашучысы булу теләге уяту. Кызыксыну хисләре уяту. Проект эшчэнлеген нәтиҗәле алып баруга шартлар тудыру.

**Проектның төре:** Иҗади-эзләнү.

**Белем бирү өлкәсе:** сөйләм үсеше, танып-белү үсеше, нәфис–нәфасәти үсеш, иҗтимагый – аралашу үсеше, физик үсеш.

**Проектның дәвамлылыгы:** 1ел

**Проектта катнашучылар:** балалар, тәрбиячеләр, ата-аналар, мәдәният өлкәсе хезмәткәрләре.

**Проектны тормышка ашыру принциплары:**

-системалылык;

-яшь үзенчәлекләрен исәптә тоту;

-баланың шәхесен хөрмәтләү;

-бала белән бакчада, гаиләдә үзара аралашу, хезмәттәшлек итү эшчәнлеге оештыру.

**Проектның этаплары:**

**1. Әзерлек этабы:**

- проектның темасын, бурычларын билгеләү;
- проект турында әти – әниләр, балалар белән белән фикер алышу;
- проектны тормышка ашыру өчен тиешле шартлар булдыру;
- тема буенча кирәкле материал, атрибутлар булдыру.

**2. Төп этап (практик):**

- музей педагогикасы темасы буенча барлык белем һәм тәрбия бирү процессы эчтәлеген эшкәртү;
- музейга сәяхәт;
- балалар,  әти – әниләр белән иҗади эзләнү һәм практик эшчәнлек оештыру;
- балаларга музейда үз-үзеңне әдәпле тоту турында аңлату.

**3. Йомгаклау этабы:**

- проектны  презентацияләү;
- “Музейның кешелек дөньясында файдасы” - консультация;
- әти –әниләр белән “Түгәрәк өстәл” артына җыелу;
- фотокүргәзмә “Без күргән эш кораллары”;
- “Музей эш коралларыннан табышмаклар” презентация.

**Эшчәнлек планы:**

| № | Үтәлү вакыты | Эш төрләре |
|---|---|---|
| 1. | Сентябрь | Проектны эшкә ашыру өчен план төзү .<br>“Музейның тәрбия эшендә тоткан роле” дигән темага ата-аналар җыйлышында чыгыш ясау. |
| 2. | Октябрь | Китап музее белән танышу. “Борынгы кул язмалар” китапханәче белән әңгәмә.<br>Презентация “Китап музее” |
| 3. | Ноябрь | Музейга сәяхәт.<br>Балалар арасында рәсем күргәзмәсе оештыру “Мин музейда нәрсә күрдем”. |
| 4. | Декабрь | “Шәхидә әбинең сандыгында ниләр бар?”-күңел ачу шөгыле. |
| 5. | Январь | “Халкыбызның күңел бизәкләре” дигән темага стенд төзү.<br>Милли бизәкләр белән чите, кәләпүш бизәү. |
| 6. | Февраль | Милли киемнәр ярминкәсендә “Курчакны киендер!” уен шөгыле.<br>“Аулак өй”, “Күңелем җәүһәрләре” кичәләре үткәрү. |
| 7. | Март | “Могҗизалы эш кораллары” танышу шөгыле.<br>“Эх,күңелле яшь чаклар” мәдәният хезмәткәрләре һәм әниләр белән күңел ачу чарасы. |
| 8. | Апрель | “Музейга нинди хәзинә бүләк итә аласың?” дигән темага әти-әниләр белән әңгәмә.<br>“Нәүрүз” күңел ачу чарасы. |
| 9. | Май | “Һәр әйбернең үз атамасы”. Дәү әнинең биргән үгет-нәсыйхәтләрен тыңлау.<br>Музей хәзинәләреннән табышмаклар презентациясе төзү. |
| 10. | Июнь | Музейда төрле җырлы-биюле “Наза”, “Чума үрдәк-чума каз”, “Талы-талы”, “Мендәр салыш” уеннарын уйнау. |

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

Балалар үзләре күреп күзәткән, тотып караган бар нәрсә турында белделәр. Музейдагы хәзинәләрнең исемнәрен исләрендә калдырдылар, дөрес атый башладылар. Борынгы йола-уеннарны өйрәнделәр. Аларда азмы - күпме тормыш тәҗрибәсе тупланды. Аларның игътибарлылык, кызыксынучанлык сыйфатлары артты. һәм дөньяга тикшеренүче, күзәтүче, беренче чыгыш ясаучылар күзе белән карый башладылар. Дәү әнинең биргән үгет-нәсыйхәтләре балалар күңелендә тирән эз калдырды. Музейларга сәяхәт үткәрү балаларга

үзебезнең, милли гореф-гадәтләренә, көнкүрешенә якынрак килергә, әби-бабай, әти-әниләребезнең әхлакый тәртип-кагыйдәләрен барларга мөмкинчелек тудырды. Китап музейнда булу, борынгы кульязмалар, ташка, тузга язылган язуларны карау, элекке язу станогы, каләме белән танышу балаларда рухи әхлакый тәрбия бирүдә зур өлеш кертте.

**Кулланылган әдәбият:**


- Бергәләп тәрбиялибез.Г.Х.Измайлова Казан Из-во"Мәгариф" 2006 ел Дәресләр, әңгәмәләр.
- Татар балалар фольклоры.Р.Ягъфәров "Раннур" нәшрияты 1999 ел. Уеннар, экиятләр, такмаклар,җырлар.
- Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе.К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Р.А.Низамова Казан"Мәгариф"нәшрияты 1999ел. Дәресләр
- Балаларга үгет-нәсыйхәт.Н.Ибраһимов,К.Бикчәнтәев, Ә.Мәдияров, А.Низамиев.Казан "Дом печати" нәшрияты 2001ел. Әңгәмәләр


## «Туган җирем – бәллүр бишек»


***Камалиева Гөлназ Рәис кызы***

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*
*"Арча 1 нче балалар бакчасы"*


**Кереш сүз**

Туган тел – туган җир, туган ил төшенчәләренең төп мәгънәсен бала аңына җиткерүче иң мөһим чара. Балаларга патриотик тәрбия бирү туган телдән башка мөмкин түгел. Баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып-белүе һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның туган телен – ана телен белүенә бәйле.

Милләтебезгә карата олы ихтирам хисләре тәрбияләгәндә, татар халкының милли мирасыннан файдалануга җитди игътибар ителергә тиеш, шунда гына мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телне яхшы үзләштерүләренә, аны ана теле итеп кабул итүләренә ирешергә мөмкин.

Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне аңлата, ягъни ул бала күңелендә туган илнең табигатенә, туган йортына, туган авылына яки шәһәренә, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбәрәт.

Патриотик тәрбияләүнең төп максаты мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүдә патриотизмны, иң мөһим рухи-әхлакый һәм социаль кыйммәт буларак, туган якка мәхәббәт тәрбияләү аша торгызу. Хәзерге балалар туган шәһәрләре, илләре, халык традицияләренең үзенчәлекләре турында аз беләләр, еш кына якыннарына битараф. Шуңа күрә балалар бакчасының төп бурычы — мөмкин кадәр иртәрәк балаларда туган җиргә мәхәббәт уяту, аларда үз иленең лаеклы кешесе һәм гражданы булырга ярдәм итәчәк характер сыйфатларын формалаштыру, туган йортка, балалар бакчасына, туган урамга мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү. Балаларда ил казанышлары өчен горурлык хисе, армиягә мәхәббәт һәм хөрмәт, сугышчыларның батырлыгына горурлык хисләре, иҗтимагый тормыш күренешләренә кызыксынуларын  үстерү  шулай ук ватанпәрвәрлек сыйфатлары булып тора.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: патриотик тәрбия бирүне әхлак, экологик, эстетик һәм хезмәт тәрбиясеннән аерып алып карарга ярамый. Алар комплекслы рәвештә алып барылса гына, ватанпәрвәрлек тәрбияләүдә уңышка ирешеп була.

**Кыскача тасвирлама**

Проект  “Туган җирем-бәллүр бишек” дип атала. Ул   мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүдә иң мөһим рухи-әхлакый һәм социаль кыйммәт буларак патриотизмны туган якка мәхәббәт тәрбияләү һәм аның  табигатенә, туган йортына, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уяту аша  баетуга юнәлдерелгән.

Безнең балалар бакчасында балалар милли  мохиттә тәрбияләнәләр. Әкиятләр, шигырьләр, табышмаклар белән танышалар, халык җырларын тыңлыйлар, уйныйлар, милли биюләр башкарырга өйрәнәләр. Бу бурычлар туган телгә өйрәтү эшчәнлекләрендә генә тормышка ашырылмый, бәлки рәсем, мөстәкыйль сәнгать эшчәнлегендә дә тормышка ашырыла. Монда декоратив-гамәли сәнгатькә, музыкага, халыкның  гореф-гадәтләре белән танышуга зур роль бирелә.

Проект 3 этапка бүленгән: әзерлек, төп һәм йомгаклау.

Проектта турыдан-туры катнашучылар: балалар бакчаларында  тәрбияләнүче балалар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре), татар теле тәрбиячесе, педагоглар һәм тәрбиячеләр.

Проектның *1 нче –әзерлек этабында* мин педагоглар һәм ата-аналар белән эшләү планын, балалар белән үткәреләчәк чараларның перспектив планын, балалар белән оештырылган белем бирү эшчәнлеге конспектларын, «Туган җирем – бәллүр бишек» проектының календарь планын эшләдем. Шулай ук иллюстратив, демонстратив һәм гамәли материал сайлап алынды, бәйрәмнәр һәм күңел ачу чаралары сценарийлары төзелде.

Төркемнәрдә ата – аналар белән бергәләп «Гаилә һәм балалар бакчасы-бердәм йорт» темасына түгәрәк өстәл уздырылды. Анда ата-аналар проектның планы, актуальлеге, максаты һәм бурычлары, проектның календарь планы белән җентекләп танышты, шулай ук алдагы эшләр буенча ата-аналарга тәфсилле консультация бирелде, буклетлар таратылды.

Проект буенча эш нәтиҗәле булсын өчен, ата-аналарга түбәндәгеләр тәкъдим ителде:

- ата-бабаларының ничек яшәве һәм нәрсә белән шөгыльләнүе белән кызыксынып, үз гаиләңнең тарихын җентекләбрәк белергә һәм иллюстратив материал тупларга;

–үзләре яшәгән төбәк турында мәгълүмати материал туплау.

Проектның *2 нче - төп этабында* түбәндәге чаралар үткәрү планлаштырылды:

- “Минем туган җирем”, “Арча – һөнәрчеләр ягы”, “Минем яраткан милли ризыгым”, “Татар кызы бездә кунакта”, “Читек белән алъяпкыч бизибез”, “Кучтәнәчтә кунакта” дип исемләнгән эшчәнлекләр;

- «Өлкәннәр көне”, “Сөмбелә бәйрәме”, “Әниләр бәйрәме” бәйрәм кичәләре;

- “Әбиемә һәм бабаема әйтер сүзем бар”, “Кичке уеннар” күңел ачу кичәләре, якташ язучыбыз Гөлчирә Нәҗметдинова белән очрашу кичәсе;

- “Мендәр тутыру йоласы”, “Сабантуй бәйрәме”, “Куян кучтәнәче”, “Чәй эчү йоласы” кебек йола бәйрәмнәре;

- әңгәмәләр: «Минем тату гаиләм», « Әниемә булышам», «Безнең сәяхәт», «Күңелле ял итәбез», «Без – кечкенә экскурсоводлар».

Проект кысаларында ата-аналар өчен консультацияләр каралган: “Балалар бакчасында патриотик тәрбия бирү юллары», «Милли гореф-гадәтләр», «Бергәләп тәрбиялибез».

Балалар белән музейларга, китапханәләргә экскурсияләр оештыру, фотокүргәзмәләр ясау.

Ата-аналар һәм тәрбиячеләр ярдәме белән берлектә “Һәр җәүһәрдә халкым тарихы” дип исемләнгән музей почмагы булдыру.

“Уңган куллар почмагы” дип исемләнгән актив почмаклар ясалды. Почмакның максаты балаларны хезмәткә тарту, матурлыкны күрә белергә өйрәтү һәм онытыла барган предметлар белән таныштыру. Анда балалар экспонатларны карап кына калмыйлар, ә үзләре дә әти-әниләре яки тәрбиячеләр белән шөгыльләнә алалар.

Тәрбиячеләр һәм ата-аналар белән берлектә “Арча – данлы төбәк” исемле кече проектлар эшләнде. Аның максаты балаларны Арча төбәгенең даклыклы урыннары белән таныштыру.

“Милли почмак”, “Патриотлар почмагы” дип исемләнгән кече музей почмаклары булдырылды. Аның максаты - шул темага караган атрибутлар белән балаларны якыннанрак таныштыру. Әлеге музей почмакларын һәр төркемгә алып кереп була, ул тәгәрмәчле. Бу музей почмагы белән таныштыруны балалар да оештыра ала. Зур төркем балалары экскурсоводлар буларак чыгыш ясыйлар.

Тәҗрибә туплау һәм башкалар белән уртаклашу максатыннан мин әлеге тема белән Түбән Кама шәһәренең балалар бакчасында “Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел!” дип исемләнгән семинар-практикумда, Саба районының “Балачак” балалар бакчасында үткән семинарда чыгыш ясадым.

“Күннән бизәк ясау” мастер-классы белән “Әти-әни – йортның тоткасы, бала-аның көзгесе” дип исемләнгән мәктәпкәчә белем учреждениеләре оештырган күргәзмәдә катнаштым.

Балаларны туган як белән якыннанрак таныштыру максатыннан “Туган якны өйрәнүчеләр” дип аталган күпфункцияле дидактик әсбап ясалды.

Ата-аналарга проектның барлык үткән чаралары турында хәбәр итү өчен ай саен чыга торган «Чишмә башы» газетасы чыгарылды, анда ата-аналар бакчада тормышын күзәтә һәм яңалыклар белән белән таныша ала. Шулай итеп, газета битләрендә фотосурәтләр, консультацияләр, котлаулар, ата-аналар белән бергә иҗат итү өчен уеннар урнаштырылып барылды.

*Проектның 3 нче - йомгаклау этабында* балалар бакчасында тәрбияләнүче һәр бала үзе яши торган туган җире турында белемнәр алачак һәм туган иленә, аның мәдәниятына, тарихына карата хөрмәт хисләре белән тәрбияләнәчәк.

Проектның ахыргы нәтиҗәсе:

- гаилә өчен милли ризык әзерләү яисә татарча чигү, рәсем ясау, халык җырларын өйрәнү һ.б. буенча осталык дәресләре (мастер-класслар) үткәрү;

- "Балалар бакчасында милли-төбәк компонентын тормышка ашыру юллары" дип исемләнгән республикакүләм семинар үткәрү;

- Массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту.

- "Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү" дип исемләнгән методик әсбап (балалар бакчаларының татар теле тәрбиячеләре, ата-аналар өчен кулланма)

Чыгару.

**Проектның максаты**

Туган як тарихына карата кызыксыну уяту һәм анда яшәүче кешеләргә, аларның мәдәниятына карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү аша ватанпәрвәрлек (патриотлык) сыйфатларын үстерү.

**Бурычлар:**

1.Балаларда үз халкының мәдәни мирасына, рухи кыйммәтләренә, туган җиренә карата хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

2. Балаларда гаилә тарихы, гаилә традицияләре белән кызыксыну уяту.

3.Халыкның мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү, башка милләт кешеләренә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү.

4.Баланың туган җирен өйрәнгәндә белем алу өчен шартлар тудыру.

5.Проектны гамәлгә ашыру һәм бергә эшләү өчен ата-аналарны (законлы вәкилләрне) уртак эшчәнлеккә җәлеп итү.

6. Балаларда әхлакый һәм рухи культура тәрбияләү, тарихи мирасны хөрмәт итүне үстерү.

**Проектның актуальлеге**

Туган як, туган почмак һәр кеше тормышында аерым бер зур, якын, кадерле урын алып тора. Бүгенге заманда туган җирең, аның тарихын, атаклы, дәрәҗәле шәхесләрен, халыкның гореф-гадәтләрен белү бик мөһим.

Кечкенәдән балалар аңларлык итеп туган ил, туган җир, тарихи вакыйгалар белән таныштырып; аны яратырга, сокланырга, горурланырга өйрәтеп, аның тормышы белән даими кызыксындырып торсак - балаларда әхлаки-патриотик тойгылар формалашыр; табигатькә, туган якка, татар халкының йолаларына, сәнгатенә карата мәхәббәт тәрбияләнер, бала туган илнең лаеклы гражданины булып үсәр, аларның кечкенә йөрәкләрендә туган илгә карата мәхәббәт очкыннары кабыныр.

Тагын бер мөһим үзенчәлек - музей педагогикасының ярдәмендә шәхес тәрбияләү. Нигә без кечкенә музейлар булдырдык? Без әңгәмә үткәрдек һәм балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрнең күпчелеге бер тапкыр да музейда булмавын ачыкладык. Сәбәпләре төрле. Беренчедән, күп кенә ата-аналар мәктәпкәчә яшьтәге балаларга мондый учреждениеләргә йөрергә иртәрәк дип саный. Икенчедән, күп кенә әниләргә һәм әтиләргә мондый экскурсия идеясе килми. Шуңа күрә без үзебезнең «музей комплексын» булдырырга булдык. Әлбәттә, балалар бакчасы шартларында музей эше таләпләренә туры килгән экспозицияләр булдыру мөмкин түгел. Шуңа күрә без «кечкенә музей»дип атадык. Кечкенә музейларның әһәмияте шактый югары, чөнки монда мәктәпкәчә яшьтәге балалар китапларны һәм репродукцияләрне, открыткаларны һәм карталарны, чын әйберләрне һәм әйберләрне карап кына калмыйлар, ә үзләре шигырьләр укыйлар, сораулар бирәләр, әңгәмәләр алып баралар. Чөнки патриотик хисләр материаль һәм рухи культура продуктларында гәүдәләнгән социаль тәҗрибәдән барлыкка килә, ул балачакта үзләштерелә. Эш нәтиҗәсендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларда әхлакый-патриотик сыйфатлар формалаштыру максатларында музей педагогикасын куллану нәтиҗәле дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

**Проектның дәвамлылыгы**

Дәвамлы – 3 ай

**Проектта катнашучылар**

Проектта турыдан-туры катнашучылар: балалар бакчаларында тәрбияләнүче балалар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре), татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр һәм педагоглар.

**Проектның көтелгән нәтиҗәләре:**

1. Балалар үзләре яшәгән районның, уз шәһәреңнең исемен белергә; андагы оешмаларны һәм аларның әһәмиятен, истәлекле урыннарын белү.

2. Үз милләтеңне, телеңне, мәдәниятеңне, гореф-гадәтләреңне тирәнрәк белү.

3. Балаларда уз районы, шәһәре өчен горурлык хисләре һәм аны чиста, матур итеп саклау теләге формалашу.

4. Балалар бакчасы тормышы белән кызыксынучы ата-аналарның процентын арттыру.

5. Башкарылган эш йомгаклары буенча массакүләм чараларны оештыру.

**“Туган җирем – бәллүр бишек” проекты буенча үткәреләчәк чараларның календарь планы**

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| | **I. *Әзерлек этабы*** | | |
| 1. | «Туган җирем- бәллүр бишек» проектына багышланган чаралар планын үтәү һәм раслау | Август 2024 | Мөдир, өлкән тәрбияче |
| 2. | Проект буенча календарь планын гамәлгә ашыру | Сентябрь – ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, өлкән тәрбияче |
| 3. | Балалар, педагоглар һәм ата-аналарга куллану өчен тематик әдәбият сайлау | Сентябрь – ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 4. | Әти-әниләр арасында анкета үткәрү «Туган җирем хәзинәсе» | Сентябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 5. | Матур әдәбият әсәрләре һәм методик әдәбият күргәзмәсе оештыру | Сентябрь – ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 6. | Ата-аналар өчен консультацияләр үткәрү: “Балалар бакчасында патриотик тәрбия бирү юллары», «Милли гореф-гадәтләр», «Бергәләп тәрбиялибез». | Сентябрь – ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 7. | Мәгълүмати-белешмә материаллар (буклетлар, күчмә папкалар, чакыру билетлары, газеталар һ.б.) булдыру | Сентябрь – ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |

***II. Төп этап***

***1. Педагоглар белән эш***

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга туган телне өйрәтүдә музей педагогикасы» консультация | Сентябрь | Татар теле тәрбиячесе |
| 2. | Муниципаль, төбәк, бөтенроссия чараларында һәм конкурсларында катнашу | Сентябрь - ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Ата-аналар өчен газета чыгару «Чишмә башы» | Һәр айны | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 4. | Дидактик уеннар, “Уңган куллар почмагы” дип исемләнгән милли актив почмаклар, “Һәр җәүһәрдә халкым тарихы” исемле бакчаның музей почмагын булдыру. | Сентябрь -октябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 5. | Кече проектлар оештыру | Октябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 6. | “Тәгәрмәчле музей почмагы” ясау. | Октябрь-ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |
| 7. | Тәҗрибә уртаклашу - семинарларда катнашу | Сентябрь-ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, өлкән тәрбияче |

***2. Балалар белән эш***

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Режим вакытларында әңгәмәләр: «Минем тату гаиләм», « Әниемә булышам», «Безнең сәяхәт», «Күңелле ял итәбез», «Без – кечкенә экскурсоводлар». | Сентябрь- ноябрь | Татар теле тәрбиячесе |
| 2. | Тематик эшчәнлекләр: “Минем туган җирем”, “Арча – һөнәрчеләр ягы”, “Минем яраткан милли ризыгым”, “Татар кызы бездә кунакта”, “Читек белән алъяпкыч бизибез”, “Күчтәнәчтә кунакта” | Сентябрь- ноябрь | Татар теле тәрбиячесе |
| 3. | Видео-презентацияләр карау: "Татар халык музыка уен кораллары", «Арча – данлы төбәгем» һ.б. | Сентябрь- ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 4. | Татарча мультфильмнар карау «Мульти – Россия», «Татарча мультфильм – Татарстан турында!», «Ак барс» һ.б. | Сентябрь- ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 5. | Татар халык уеннарын өйрәнү | Сентябрь- ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе, физик инструктор |
| 6. | Төркемнәрдә фото күргәзмәләр « Минем | Сентябрь- ноябрь | Татар теле |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гаиләм” | | тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 7. | “Сөмбелә” бәйрәмен үткәрү | Сентябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 8. | Музейларга экскурсияләр | Сентябрь - октябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 9. | Арча үзәк китапханәсенә сәяхәт | Сентябрь - октябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 10. | “Мендәр тутыру йоласы”, “Сабантуй бәйрәме”, “Куян күчтәнәче”, “Чәй эчү йоласы” кебек йола бәйрәмнәре | Ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 11. | Өлкәннәр белән  белән очрашу “Әбием белән бабаема әйтер сүзем бар” | Октябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 12. | Якташ язучыбыз Гөлчирә Нәҗметдинова белән очрашу кичәсе | Октябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 13. | Иҗади кул эшләре күргәзмәсе «Әниемнең алтын куллары». | Ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 14. | “Әниләр көне” бәйрәм кичәсе | Ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе |
| 15. | “Кичке уеннар” күңел ачу чарасы | Ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе, физик инструктор |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ***1. Ата-аналар белән эш*** | | |
| 1. | Түгәрәк өстәл  “Гаилә һәм балалар бакчасы – бердәм йорт” | Сентябрь | Мөдир, өлкән тәрбияче, татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 2. | “Һәр җәүһәрдә халкым тарихы” дип аталган музей почмагын тулыландыру. | Сентябрь-ноябрь | Мөдир, өлкән тәрбияче, татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 3. | Осталык дәресләре үткәрү. | Ноябрь | Мөдир, өлкән тәрбияче, татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 4. | Үзләре яшәгән төбәк турында материал туплау. | Сентябрь-ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 5. | Бәйгеләрдә, проектларда катнашу | Сентябрь-ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 6. | Онлай-флешмоб: “Мин яшәгән шәһәр буйлап сәяхәт” | Сентябрь-ноябрь | Татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| | **III. Йомгаклау этабы** | | |
| 1. | Осталык дәресләре:”Чигү чигәм”,«Татар халык милли ашлары», “Халык җырларын җырлыйбыз”, “Туган ягым табигате – минем рәсемнәрдә” һ.б. | Ноябрь | Мөдир, өлкән тәрбияче, татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |
| 2. | “Балалар бакчасында милли-төбәк компонентын тормышка ашыру юллары”  дип исемләнгән республикакүләм семинар үткәрү | Ноябрь | Мөдир, өлкән тәрбияче, татар теле тәрбиячесе, тәрбиячеләр |

## Йомгаклау

Туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, балаларга патриотик тәрбия бирүдә туган якны өйрәнү зур әһәмияткә ия. Проект шулай ук туган якның, туган авылның, аны буыннан-буынга саклап калдыруда һәм тәрбия эшендә зур ярдәм итте.

Шулай итеп, бүгенгедәй катлаулы чорда әхлаклы шәхес – Ватанга мәхәббәт хисе белән сугарылган, аның тарихы, мәдәнияте казанышлары белән кызыксынучы, милли символларга, изге урыннарга хөрмәт белән караучы, җәмгыятькә һәм халыкка хезмәт итәргә әзер булган,

әдәпле һәм итәгатьле шәхес тәрбиялим дисәң, эшне, беренчедән, балага кечкенәдән үк туган төбәге, халкы тарихын өйрәтүдән башларга кирәктер. Үзен, үз халкын хөрмәт иткән кеше башкаларга да шуны ук күрсәтер.

Икенчедән, әлбәттә, баланың күңеленә кешелеклелек, мәрхәмәтлелек орлыкларын салуга, тәрбия нигезенә халкыбыз тәрбиясе нигезләрен салу зур ярдәм булып торачак. Чөнки халыкның үткәнен, аның бетмәс-төкәнмәс күңел хәзинәләрен өйрәнгәндә генә Ватаныбызны ярату хисләре тәрбияләп була.

Шулай ук, өченчедән, тәрбия процессына ата-аналарны тарту да бу максатка ирешү юлларын якынайтачак.

Тәрбиянең нигезе гаиләдә, әти-әни, әби-бабай катнашында салына, ул шулай дәвам итәргә дә тиеш. Менә шуларны исәпкә алсак кына, без максатыбызга ирешә алырбыз, һәм бакчада тәрбия процессы да мәгънәле һәм нәтиҗәле булыр.

**“Милли хәзинә”**

***Минһаҗева Роза Гаптелхай кызы***
*“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан төп гомуми белем мәктәбе” ГБМБУ*

**Проектың актуальлеге**

Дөньяда иң-иң матур ил,
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел,
Ул – минем туган телем.
(Э.Мөэминова)

Туган илем, туган телем…Үз илем, үз телем… Бүгенге көндә кызганычка каршы үз илендә яшәп тә, үз ана телендә сөйләшә алмаган милләттәшләребезне еш очратырга туры килә. Шуңа күрә дә балаларга кече яшьтән үк үз туган телендә сөйләшергә, үз халкының гореф-гадәтләрен, йола-бәйрәмнәрен, милли ашларын, киемнәрен өйрәтергә кирәк.

Балаларга халык авыз иҗаты әсәрләрен өйрәтү дә бик мөһим. Халык авыз иҗаты әсәрләре - яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак. Халыкның бай рухлы, кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы әкиятләре, киң колачлы җырлары, тирән фәлсәфи әйтемнәре, тапкыр һәм үткер мәкальләре, үзенчәлекле табышмаклары, яшьләргә сабак бирердәй итеп иҗат ителгән әсәрләре киләчәк буынны милләт тормышын дәвам итәрлек, аны үстерүгә өлеш кертерлек итеп тәрбияләүдә зур ярдәм итә.

Балалар үз туган телен яраткан, милләте белән горурланган очракта гына камил рәвештә үз телендә сөйләшә ала. Моңа ирешү өчен балаларга милли мирасны өйрәтү мөһим. Шуңа күрә дә әлеге проект бик актуаль булып тора.

**Максат:** Балаларны татар халкының милли бәйрәмнәре, йолалары, татар милли ашлары, киемнәре, аларның үзенчәлекләре, кагыйдәләре белән якыннан таныштыру, үз теленә, милләтенә карата горурлык хисләре уяту.

**Бурычлар**:

· туган телебезгә карата мәхәббәт тәрбияләү;

· милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау, төсләрнең берләшүенә игътибар итү.

· татар халкының милли бәйрәмнәре, йола уеннары аша балаларның аралашу осталыгын үстерү;

· татар халкының көнкүреше, милли бәйрәмнәре, йолалары белән кызыксынуларын үстереп, балаларга эстетик һәм әхлакый тәрбия бирү;

· балаларның аралашу, коммуникатив осталыгын, сөйләм телен үстерү.

**Проектта катнашучылар:** тәрбияче, катнаш төркем балалары, китапханәче, ата- аналар.

**Проектның төре:** танып белү, иҗади

**Гамәлгә ашырылу вакыты:** гыйнвар-май.

**Проекттан көтелгән нәтиҗә:**

- балалар ана телендә дөрес, матур итеп аралашырга өйрәнәләр;

- татар халкының электән сакланып килгән бәйрәмнәрен, йолаларын, милли киемнәрен, ашларын өйрәнәләр;

- балаларда халкыбызга, милли уеннарына карата хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре уяна;

- татар милләтенә карата горурлык хисләре уяна;

- халык – аваз иҗаты белән кызыксыналар, аңа хөрмәт белән карыйлар.

**Проектны гамәлгә ашыру этаплары.**

- 1 нче этап - әзерлек
- 2 нче этап - төп
- 3 нче этап - йомгаклау

**<u>1 этап – әзерлек этабы</u> (гыйнвар)**

- проектның темасын уйлау;
- максатын һәм бурычларын кую;
- материаллар туплау;
- перспектив эш планы төзү;
- проектны иллюстратив материаллар белән баету;
- методик китаплар һәм матур әдәбият әсәрләре сайлау;
- өстәл уеннары һәм дидактик уеннарны булдыру;
- “Туган як” почмагын тулыландыру;
- эти-әниләрне проект белән таныштыру, анкета үткәрү, биремнәр бирү.

**<u>2 этап – төп этап</u>**

| Ай | Блок | Эшләү алымнары һәм формасы |
|---|---|---|
| **Февраль** | **“Туган телем”** | **<u>Балалар белән эш</u>**<br>- Әңгәмә “Туган телем – татар телем”, “Бишек җырлары”<br>- Тел турында мәкаль-әйтемнәр уку<br>- Табышмаклар чишү<br>- Тел көрмәкләндергечләр, санамышлар өйрәнү<br>- Бармак уеннары уйнау<br>- Җырлы-биюле уеннар уйнау “Зәңгәр чәчәк”, “Чума үрдәк, чума каз”, “Кәрия – Зәкәрия”<br>- Матур әдәбият уку: Ш.Маннур “Яхшы бел”, Н.Мәдьяров “Татар теле”, Ш.Галиев “Туган тел”, Г.Морат “Туган тел”, Ф.Зыятдинова “Татарча белмәүче кәҗәләр”, Мөҗәһит “Тел белү авыр түгел”, “Туган телгә өйрәттек”, Э.Мөэминова “Үз телендә сөйләшә”, Йолдыз “Тылсымлы сүзләр”, Ә.Бикчәнтәева “Тәмле сүз”, Б.Рәхимова “Бәхәс”, Л.Шагыйрьҗан “Туган тел бәйрәме”<br>- Җырлар тыңлау һәм җырлау: Г.Тукай “Туган тел”, Э.Мөэминова “Туган телем”<br>Китапханәче белән очрашу<br>- Презентация карау: “Муса Җәлил – балаларның якын дусты”<br>- М. Җәлилнең “Карак песи”, “Кызыл ромашка” шигырьләрен сәхнәләштерү<br>- “Тылсымлы сандык” дигән лэпбуктан уеннар уйнау<br>- “Әбием әкиятләре” курчак театры белән уйнау<br>- Викторина “Күңелле туган тел”<br>***- “Туган телем – иркә гөлем” әдәби-музыкаль кичә***<br>**<u>Ата-аналар белән эш</u>**<br>“Туган телдә укыйбыз” интернет челтәрләрендә видеоязма урнаштыру |
| **Март** | **“Татар милли киемнәре һәм бизәкләре”** | **<u>Балалар белән эш</u>**<br>- Әңгәмә “Татар халкының милли киемнәре ”<br>- Презентация “Татар милли киемнәре һәм бизәкләре”<br>- Мәкаль-әйтемнәр уку<br>- Табышмаклар чишү<br>- Тел көрмәкләндергечләр, санамышлар өйрәнү |

| | | |
|---|---|---|
| | | - Бармак уеннары уйнау<br>- Җырлы-биюле уеннар “Түбәтәй” , “Башмакчы” “Яулык алыш”<br>- Матур әдәбият уку: Р.Вәлиева “Энҗе-мәрҗән калфагым”, Йолдыз “Тылсымлы түбәтәй”, В.Хәйруллина “Түбәтәй”, Л.Әмирханова “Чигүле читекләрем”, Л.Лерон “Татар баласы”<br>- Җыр тыңлау һәм җырлау: “Без яулыклар юабыз”(С.Сәгъди сүз.,көе), Р.Вәлиева сүз, М.Минһаҗев көе “Кәләпүшем кәләпүш”,<br>- Бию “Бииләр итек, читекләр”(читекләр белән), “Шәл бәйләдем” (шәлләр белән)<br>- Дидактик уеннар “Мин башлыйм, син дәвам ит”, “Киемнәрне бизәү”, “Нәрсә артык?”, “Өйне милли бизәк белән бизә”, ”Курчакны киендер”<br>- Өстәл уеннары “Бу нинди бизәк”, ”Күңелле домино”<br>- “Милли бизәкләр” альбомын карау<br>- Рәсем ясау “Татар милли киемнәре”<br>- Кисеп ябыштыру “Милли бизәкләрдән открытка”<br>- Әвәләү “Түбәтәй”<br>- Буягыч “Калфак”, “Татар милли бизәкләре”<br>- Осталык сәгате “Кульяулык бизәү”<br>- Фотобәйге “Мин – татар баласы”<br>- Мәдәният йортында урнашкан “Туган якны өйрәнү” музеена сәяхәт<br>- ***“Әбиемнең серле сандыгы” әдәби –музыкаль кичә***<br>**<u>Ата-аналар белән эш</u>**<br>“Татар милли бизәкләре” дигән темага кул эше. |
| **Апрель** | **“Татар милли ашлары”** | **<u>Балалар белән эш</u>**<br>- Әңгәмә “Татар милли ашлары”<br>- Презентация карау: “Татар халык ашлары”<br>- Мәкаль-әйтемнәр уку<br>- Татар халык ашлары турында табышмаклар чишү<br>- Тел көрмәкләндергечләр, санамышлар өйрәнү<br>- Бармак уеннары уйнау<br>- Җырлы-биюле уеннар “Ак калач”, “Кунаклар”, “Без-без, без идек”<br>- Матур әдәбият уку: Р.Вәлиева “Ашлар солтаны”, Р.Миңнуллин “Табын янында”, Р.Фәхретдинов “Ашау әдәпләре”, Ә.Бикчәнтәева “Өстәл янында”, Б.Рәхмәт “Аш вакыты”, В.Хәйруллина “Шифа чәе”, С.Сәүбанова “Ботка нигә тәмле?”, “Шифалы сөт”, М.Фәйзуллина “Пешкән, әллә пешмәгән”, Ш.Гәлиев “Әбиләрдә кунакта”, А. Хәсәнов “Бал дәвалый”<br>- Ятлау: Ш.Гәлиев “Кунаклар”<br>- Җырлау: “Чәй эчәбез бергәләп”(А.Минһаҗев сүз., Р.Сәрвәров көе)<br>- “Татар милли ашлары” китабындагы рәсемнәрне карау<br>- Видео карау: “Милли ризык пешерү”<br>- Дидактик уеннар “Нәрсә артык?”, “Кем нәрсә ярата?”<br>- Рәсем ясау “Яраткан ризыгым”<br>- Кисеп ябыштыру “Өчпочмаклар”<br>- Әвәләү “Чәкчәк – табын бизәге” |

| | | |
|---|---|---|
| | | - Буягыч “Милли ризыклар”<br>- “Чемодандагы әкият” (Татар халык әкияте “Калач”)<br>***- Осталык сәгате “Кыстыбый пешерү”***<br>**<u>Ата-аналар белән эш</u>**<br>“Милли ризык – табын күрке” күргәзмә |
| **Май** | **“Татар халкының милли бәйрәмнәре һәм йолалары”** | **<u>Балалар белән эш</u>**<br>- Әңгәмә “Татар халкының милли бәйрәмнәре һәм йолалары” (“Сөмбелә”, “Каз өмәсе”, “Нардуган”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы”, “Сабантуй”, “Аулак өй”)<br>- Мәкаль-әйтемнәр уку<br>- Табышмаклар чишү<br>- Тел көрмәкләндергечләр, санамышлар өйрәнү<br>- Бармак уеннары уйнау<br>- Җырлы-биюле уеннар уйнау “Наза”, “Миңлебай”, “Болында”<br>- Матур әдәбият уку: Р.Миңнуллин “Нәүрүз”, Р.Хафизова “Нәүрүз килә”, Э.Мөэминова “Сабантуй”, Р.Миңнуллин “Сабантуе бүген бездә”, Ш.Гәлиев “Сабан туе батыры”, Г.Зәйнашева “Сабан туе”, М.Фәйзуллина “Ислам дине”, В.Хәйруллина “Азан әйтә бер малай”<br>- Дидактик уеннар “Парын тап”, “Дәвам ит”, “Хатаны тап”<br>- Кисмә рәсемнәрдән бәйрәм күренешләрен җыю<br>- Тозлы камырдан әвәләү “Бәйрәмгә милли ризыклар”<br>- Кисеп-ябыштыру “ Котлау открыткасы”<br>- Фото күргәзмә “Сабантуй мизгелләре”<br>- Рәсем буенча хикәя төзү<br>- Халкыбызның дини бәйрәмнәре ( Ураза, Корбан) белән таныштыру<br>- Авылыбыз мәчетенә экскурсия<br>- Рәсем ясау “Авылым мәчете”<br>- Азан тавышын тыңлау<br>- “Әссәләмугаләйкүм”(Г.Садә сүз, Р.Ахиярова көе) җырын өйрәнү<br>- ***“Сабантуй”бәйрәме***<br>**<u>Ата-аналар белән эш</u>**<br>“Татар халкының йола-бәйрәмнәре” альбом төзү |

**<u>III этап – йомгаклау этабы:</u>**

– алган белемнәргә,эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау;

– үстерешле диалог үткәрү;

– квест-уен “Милли хәзинә” үткәрү.

**Йомгак**

“Үткәнен белмәгәннең – киләчәге юк”,- диелә татар халык мәкалендә. Шуңа күрә дә балалар бакчасы тәрбиячеләре алдында торган максат һәм бурычларның иң мөһиме –

балаларга үз туган телен өйрәтү, шулай ук аларны халкыбызның гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары, милли киемнәре, милли әдәбияты белән таныштыру. Әлеге проект шушы максат һәм бурычларны тормышка ашырырга ярдәм итә.

Мин балалар киләчәктә үз туган телләрен яхшы белүче, үз милләте белән горурланучы, милли гореф-гадәтләре, йолалары белән кызыксынучы шәхес булып үсәрләр дип ышанып калам.

**«Туган телем минем байлыгым»**

***Шәйдуллина Ландыш Рәфит кызы***

*«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ш.т. Байлар Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге Саба 2 нче «Эллуки» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе*

**Аңлатма язуы**

*«Тел-халык җаны. Һәр милләтнең бурычы – үз телеңне саклап калу,*
*һәр кешенең бурычы– туган телеңә җитди һәм изге мөнәсәбәтне саклап калу.»*
*К.Д.Ушинский.*

Һәр кеше өчен туган тел - иң кадерле һәм изге байлык булып тора. Республикабызда яңа тел ситуациясе шартларында баланың формалашуы ике милли мәдәният, гореф-гадәтләр йогынтысында бара.

Россия мәгариф системасы үсешенең хәзерге этабы аның дөньякүләм мәгариф киңлегенә интеграциясенә юнәлдерелгән бик тиз үсә торган инновацион процесслар белән характерлана. Хәзерге вакытта Россиядә мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре пространствосына полилингвальлекне кертүгә юнәлдерелгән яңа мәгариф системасы торгызыла.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары бүген баланың индивидуаль сәләтләрен үстерүгә ярдәм итәргә, аны динамикалы үсеп килүче дөньяның заманча таләпләренә туры килергә әзерләргә омтыла. Полилингваль белем бирү телләр билгеле бер белем өлкәсен үзләштерү, төрле илләр һәм халыкларның мәдәни - тарихи һәм социаль тәҗрибәсен үзләштерү ысулы

буларак чыгыш ясаучы берничә тел чаралары ярдәмендә дөнья мәдәниятенә тартылуның максатчан процессы буларак аңлашыла.

Проект Татарстан Республикасының Саба муниципаль районында яшәүче халыкларның туган телен, мәдәниятен, милли гореф-гадәтләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән. «Туган телем минем байлыгым» проекты кысаларында татар халкының мәдәнияте һәм теле торышын тикшерү, аларны саклау һәм торгызу эшенең төп юнәлешләрен билгеләү планлаштырыла. Рус һәм татар халкы мәдәниятенең үзенчәлеген билгеләүче традицион халык мәдәниятен саклауга юнәлдерелгән чаралар үткәреләчәк, халык мәдәнияте традицияләрен заманча мәдәни практикага һәм иҗтимагый тормышка кертү методлары һәм формалары эшләнәчәк. Тәрбияләнүчеләрнең һәм ата-аналарның милли-мәдәни тематикалы фестивальләрдә, күргәзмәләрдә, конкурсларда катнашуы, традицион халык бәйрәмнәре, фольклор кичәләре, мастер-класслар уздыруы, татар халкы мәдәниятен үстерүгә бәйле чараларны оештыру һәм әзерләү планлаштырыла.

Проект, нигездә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларда туган телне, аның тарихын һәм заманын өйрәнүгә, халык сәнгатенә кызыксыну тәрбияләүгә, иҗади эшчәнлек аша үз-үзеңне белдерүгә омтылуга юнәлдерелгән.

**Проектның актуальлеге һәм социаль әһәмияте** Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче татар халкының туган телен, тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү ихтыяҗына бәйле, һәм бу максатларда җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, берничә чара үткәреләчәк. Мәктәпкәчә яшьтә шәхес нигезләре салына; нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтәге бала аның өчен чын мәгънәсендә эмоциональ, әхлакый һәм эстетик тәрбия өчен уңайлы була.

Балаларны халык мәдәниятенә җәлеп итүдә халык бәйрәмнәре, татар бизәкләрен, милли киемнәрне өйрәнү зур урын алып торырга тиеш. Нәкъ менә монда ел фасылларына, һава торышына, кошларның, бөҗәкләрнең, үсемлекләрнең үз-үзләрен тотышына, аларның гореф-гадәтләренә һәм гореф-гадәтләренә хас үзенчәлекләргә җентекле күзәтү формалаша. Өстәвенә, бу күзәтүләр кешенең иҗтимагый тормышының һәм хезмәтенең төрле яклары белән турыдан-туры бәйләнгән.

2023 елның декабрендә Татарстан Республикасы буенча 100 балалар бакчасы өстәл уеннарын үстерү комплектларын алды һәм «Акыллы Уеннар» программасын гамәлгә ашыра башлады.

«Акыллы Уеннар» - Татарстан Республикасында булдырылган алдынгы EdTech продукты, аның төп максаты балаларның татар телен кечкенәдән үк белү күнекмәләрен саклап калу һәм арттыру, мәдәниятне һәм тәңгәллекне бәяләү, уңышлы укыту, шәхес формалашу һәм үз-үзеңне тормышка ашыру өчен ныклы нигез салу.

Татар халкының гореф-гадәтләре һәм гореф-гадәтләре белән уңышлы танышу өчен балаларга халык мәдәнияте турында күзаллау бирергә, гореф-гадәтләр һәм халык йолалары, орнаментлар белән таныштырырга кирәк, бу исә балаларда уңай кыйммәтләр тудыра. Безгә борынгы һәм мөстәкыйль мәдәниятне саклап калырга кирәк. Без татар җирендә яшибез, шуңа күрә татар мәдәни мирасына хөрмәт белән карыйбыз.

**Проектның максаты:** башка халыкларга, аларның телләренә һәм мәдәниятенә хөрмәт хисе булган иҗади шәхес үсешенә ярдәм итә торган этномәдәни мохит булдыру.

**Проектның бурычлары:**

1. Туган (татар) телне популярлаштыру буенча ата-аналарның мәнфәгатьләрен билгеләү өчен мониторинг һәм анализ үткәрергә.

2. «Акыллы уеннар» проекты буенча уен комплектлары ярдәмендә туган телне өйрәнүдә тупланган тәҗрибәне һәм татар халык сәнгате белән танышуны системага салырга.

3. Тәрбия потенциалын ачу һәм балаларны туган (татар) телен өйрәнүгә һәм танып белүгә җәлеп итү.

4. Балалар бакчасының уникаль, пространство мохитен заманча белем бирү, авторлык материаллары, сенсор китаплар, проектлар һәм гаджетлар белән баету.

5. Тәрбияләнүчеләрне һәм аларның ата-аналарын Ватаныбыз тарихын өйрәнүгә, туган якның мәдәни мирасын һәм гореф-гадәтләрен саклауга җәлеп итү.

6. Белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучыларны проект эшчәнлегенә җәлеп итү һәм «Акыллы уеннар» чемпионатында катнашуы аша туган телнең байлыгын, матурлыгын күрсәтергә.

Без үз алдыбызга мөһим бурыч куйдык – педагогик коллектив партнерлыгы хисабына балалар өчен бердәм белем бирү пространствосы булдыру, ата-аналар бергәлеген һәм социум партнерлыкны җәлеп итү.

**Үткәрү вакытлары:** проект 1 елга исәпләнгән (август, 2024-май, 2025)

1. I этап - әзерлек, оештыру. Гамәлгә ашыру вакыты: август, 2024 ел.

2. II этап – гамәли. Гамәлгә ашыру вакыты: сентябрь-март, 2025 ел.

3. III этап - йомгаклау (нәтиҗәле). Гамәлгә ашыру вакыты: апрель-май, 2025 ел.

**Проектның гамәли әһәмияте** шунда ки, аны теләсә кайсы иҗади педагог үз эшендә куллана ала, аның эчтәлеген үзенең мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе шартларына һәм социум белән үзара хезмәттәшлек итү мөмкинлекләренә яраклаштыра.

**Проектның инновацион әһәмияте:** «Акыл уеннар» проекты Татарстан Республикасында булдырылган продукт, уникаль белем бирү программасы, аның нигезендә үсә торган өстәл уеннары җыелмасы һәм цифрлы кушымта тора. «Акылы уеннар» проектын кулланып, педагоглар үз практикаларында дәресләр һәм режим вакытында «яңа педагогик

практикалар» (туган телдә укытуны һәм тәрбияне оештыруның һәм уздыруның яңа модельләре) куллана алалар. «Акылы уеннар» җыелмасы балаларны туган телдә укытуга һәм тәрбияләүгә юнәлдерелгән 10 үстерүче өстәл уеннарыннан тора.

**Мәгълүмати ачыклык / трансляцион җәлеп итүчәнлек:** семинарларда, конференцияларда, конкурсларда Саба 2 нче «Эллуки» балалар бакчасы педагогларының эш тәҗрибәсен һәм эшчәнлеген белем бирү һәм муниципаль дәрәҗәдә мәгълүматлаштырырга һәм трансляцияларга, бу белем бирү процессында катнашучыларның барысы арасында да челтәр аша хезмәттәшлек итү һәм эш тәҗрибәсен трансляцияләү өчен оператив һәм объектив шартлар тудырырга мөмкинлек бирәчәк.

**Проектның максатчан төркемнәре:** тәрбияләнүчеләр, ата-аналар, балалар бакчасы педагоглары.

**Проектның көтелгән нәтиҗәләре:**

1. «Акыллы уеннар» республика чемпионатында катнашу нәтиҗәләрен арттыру.

2. Саба 2 нче «Эллуки» балалар бакчасында этномәдәни предмет-үсеш мохите булдыру.

3. Татар теленең лексик запасын баету; тәрбияләнүчеләрне татар халкының мәдәнияте һәм традицияләренә тарту.

4. «Акыллы уеннар» проекты буенча педагоглар белән өстәл уеннары эшләү һәм Саба районы педагоглары өчен семинарларда, конференцияларда туган телне тәрбияләү һәм өйрәтү буенча эш тәҗрибәсен уртаклашу.

5. Тукымадан һәм күннән милли сумкалар һәм алъяпкычлар ясау буенча мастер-класслар аша ата-аналарны балаларга туган телне тәрбияләү һәм өйрәтү эшенә җәлеп итү

**Төп өлеше**

«Туган телем минем байлыгым» проектын гамәлгә ашыру өчен юл картасы эшләнде һәм 2024-2025 уку елына гамәлгә ашыру сроклары билгеләнде.

**Әзерлек этабы**

Проектны әзерлек этабында гамәлгә ашыру өчен чаралар планы:

| № | Чаралар | Вакыты |
|---|---|---|
| 1 | “Туган телем минем байлыгым” проектының планын эшләү | Август, 2024 ел |
| 2 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туган телгә өйрәтү һәм тәрбияләү өлкәсендәге норматив-хокукый актларны өйрәнү һәм үтәү | Август, 2024 ел |
| 3 | Милли тәрбия мәсьәләләре буенча мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен үстерү юнәлешләрен билгеләү | Август, 2024 ел |
| 4 | Балаларны туган телдә укыту һәм тәрбияләү процессына җәлеп ителгән гаиләләрне ачыклау өчен мониторинг үткәрү | Август, 2024 ел |

**Гамәли этап**

Проектны гамәлгә ашыру буенча

2024-2025 уку елына Саба 2 нче «Эллуки» балалар бакчасында юл картасы «Туган телем минем байлыгым»

| № | Тема | Үткәрү сроклары | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| **Август** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | Татарстан Республикасы көненә, Саба районы поселогы көненә багышланган бәйрәм чарасы | 29 нчы август | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | Халык әкиятләре мотивлары буенча татар телендә мультфильмнар карау | Бер ай эчендә | |
| 3 | "Минем тугры дустым – Туган телем" әңгәмәсе | Бер ай эчендә | |
| 4 | Саба районының туган якны өйрәнү музеенда булу | Бер ай эчендә | |
| 5 | Байлар Сабасы бистәсе яр буена Экскурсия | Бер ай эчендә | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | Балаларны туган телдә укыту һәм тәрбияләү процессына җәлеп ителгән гаиләләрне ачыклау өчен мониторинг үткәрү | Бер ай эчендә | Педагоглар, ата-аналар |
| 2 | Татарстан Республикасы көненә, Саба районы поселогы көненә багышланган бәйрәмне бәйрәм итү буенча уртак чаралар | 28-29 август | Педагоглар, ата-аналар |
| **Сентябрь** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | Татар телендә ягымлы мөгамәлә бәйрәме | 11 нче сентябрь | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | - Татар язучысы А. Алишның туган көне (1908-1944) / «А. Алиш әкиятләре буенча» чара | 9-13 сентябрьдә | |
| 3 | Электрон китап көне | 18 сентябрь | |
| 4 | Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә урнашкан паркларга максатчан сәфәр | 16-20 сентябрьдә | |
| 5 | Тәрбияче һәм барлык мәктәпкәчә хезмәткәрләр көне | 27 нче сентябрь | |
| 6 | “Туган телендә китап бүләк ит” акциясе | Бер ай эчендә | |
| 7 | Татар рәссамы Лотфулла Фәттаховның (1918-1981) туган көне | 27 нче сентябрь | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | “Акыллы уеннар” – “җәйге алан” проектын гамәлгә ашыру эше | Бер ай эчендә | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | «Безнең гаилә традицияләре» ата-аналарын анкеталау | Бер ай эчендә | Педагоглар, ата-аналар |
| 2 | Балалар-ата-аналар иҗаты конкурсы “А. Алиш әсәрләре буенча кечкенә китапчыклар ясау” | 9-13 сентябрьдә | Ата-аналар, тәрбияләнүчеләр, тәрбиячеләр |
| 3 | Балалар-ата-аналар иҗаты конкурсы йомгаклары буенча А. Алиш иҗатына багышланган күргәзмә | 23-27 сентябрьдә | Ата-аналар, тәрбияләнүчеләр, тәрбиячеләр |
| **Октябрь** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | Әңгәмәләр: “Туган телең нәрсәгә бай”, “Туган телең нинди?” | Ай дәвамында | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | Халыкара өлкәннәр көне | 1 октябрь | |
| 3 | Казан Кремле Көне | 3 октябрьдә | |
| 4 | “Сөмбелә” бәйрәмен үткәрү | 13-17 октябрьдә | |
| 5 | «Минем шәҗәрә агачы» күргәзмәсе | 20-24 октябрьдә | |
| 6 | Татар шагыйрәсе Вәсимә Хәйруллинаның туган көне (1943). | 28 нче октябрь | |
| 7 | «Акыллы уеннар» - «Читекләр» проектын гамәлгә ашыру эше | Бер ай эчендә | |
| 8 | «Татар орнаментлы» Сәйлән бизәнү әйберләре ясау | Бер ай эчендә | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | Ата-аналар өчен туган якны өйрәнү викторинасы «Син үз шәһәреңне беләсеңме?» | Бер ай эчендә | Педагоглар, ата-аналар |
| 2 | «Минем яраткан бистәм» гаилә иҗат эшләре күргәзмәсе | Бер ай эчендә | Педагоглар, ата-аналар |
| **Ноябрь** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | Татар композиторы Сара Садыйкованың туган көне (1906-1986) | 1 ноябрь | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | ТР Конституциясе көне | 6 ноябрь | |
| 3 | «Мин үз бистәмне беләм» викторинасы | 8-12 ноябрь | |
| 4 | Татар шагыйре, язучысы Ш. Галиевның туган көне | 28 ноябрь | |
| 5 | ТР флагы көне (1991 елда кабул ителгән, авторы Т. Хаҗиәхмәтов) | 29 ноябрь | |
| 6 | Бәйрәм “Әниләр көне” | 18-22 ноябрь | |
| 7 | «Акыллы уеннар» - «Түбәтәй» проектын гамәлгә ашыру эше | Бер ай эчендә | |
| 8 | Фетрдан түбәтәй баш киемен | Бер ай эчендә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ясау | | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | Балалар китабы атналыгына багышланган ата-аналар ярдәмендә балалар кулы белән әзерләнгән китаплар күргәзмәсе | Бер ай эчендә | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | “УМК кысаларында коммуникатив сөйләмне үстерү” консультациясе | Бер ай эчендә | |
| 3 | Ата-аналарга татар телен өйрәтү буенча гаилә клубы эше | Бер ай эчендә | Балалар бакчасы педагоглары |
| **Декабрь** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | “Курчакны милли костюмга киендерәбез” дидактик интерактив уен | Бер ай эчендә | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | «Виммельбух» үстерү китабы буенча уеннар | Бер ай эчендә | |
| 3 | “Музейга экспонат бүләк ит” акциясе | Ай дәвамында | |
| 4 | Татар композиторы С. Сәйдәшевның туган көне (1900-1954) | 3 декабрь | |
| 5 | Әңгәмәләр “Туган тел иң матур тел!” | Бер ай эчендә | |
| 6 | «Шагыйрьләр иҗатында кыш» тематик чарасы | 9-13 декабрь | |
| 7 | Нардуган бәйрәме | 24 нче декабрь | |
| 8 | «Акыллы уеннар» - «Мин булдырам» проектын гамәлгә ашыру буенча эш | Бер ай эчендә | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | «Сезнең гаиләгездә халык традицияләре» анкетасы | Бер ай эчендә | Балалар бакчасы педагоглары |
| 2 | Консультация “Балаларга нинди әкиятләр укырга?”- Татар халык әкиятләре белән танышу. | Бер ай эчендә | Балалар бакчасы педагоглары |
| 3 | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайты аша балалар белән татар мультфильмнарын карау | Бер ай эчендә | Балалар бакчасы педагоглары |
| **Гыйнвар** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | «Минем шәҗәрә» проекты | 13-17 гыйнвар | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү |
| 2 | Татар шагыйрәсе Г. Зәйнашеваның туган көне | 13 гыйнвар | |
| 3 | Татар җырчысы А. Авзалованың туган көне | 15 гыйнвар | |
| 4 | «Әбиемнең серле сандыгы» күңел ачу | 20-24 гыйнвар | |
| 5 | «Мин кеше, яшим, уйныйм, | 27-31 гыйнвар | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | өйрәнәм» күңел ачу | | учреждениесенең педагогик коллективы |
| 6 | «Акыллы уеннар» - “Нәрсә бу?” проектын гамәлгә ашыру эше | Бер ай эчендә | |
| 7 | Технология батик: тукымага рәсем ясау. “Үз куллары белән алъяпкыч ясау” | Бер ай эчендә | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | «Туган телем минем байлыгым» проекты планы белән танышу һәм ата-аналарны җәлеп итү | Бер ай эчендә | Шәйдуллина Л. Р., эти-әниләр |
| 2 | Татар орнаменты ясау техникасын өйрәнү өчен ата-аналар белән берлектә күрсәтмә әсбап булдыру | Бер ай эчендә | |
| **Февраль** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | ТР Дәүләт гербы көне | 7 февраль | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | Халыкара китап бүләк итү көне | 14 февраль | |
| 3 | Татар шагыйре М. Җәлилнең туган көне (1906-1944) | 14 февраль | |
| 4 | Чара «Муса Җәлил һәм балалар» | 14 февраль | |
| 5 | Халыкара туган тел көне | 21 февраль | |
| 6 | Татар җырчысы и. Шакировның туган көне (1935-2019) | | |
| 7 | Бөтендөнья татар милли ашлары көне | 14 февраль | |
| 8 | «Акыллы уеннар» - “Тылсымлы сөлгеләр” проектын гамәлгә ашыру эше | Бер ай эчендә | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | «М. Җәлил әсәрләре буенча кечкенә китапчыклар» балалар-ата-аналар иҗаты конкурсы | 14 февраль | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | «Укучы балалар», “Укучы республика” гаиләләр уку марафоны (Татарстан Республикасында Туган телләр һәм Халыклар бердәмлеге елына һәм Халыкара туган тел көненә) | Бер ай эчендә | |
| **Март** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | Бөтендөнья язучылар көне | 3 март | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | «Дулкын» телерадиокомпаниясы тапшыруында катнашу | Ай дәвамында | |
| 3 | Татар шагыйрәсе Клара Булатованың туган көне | 18 март | |
| 4 | «Нәүрүз» татар фольклор бәйрәме | 21 март | |
| 5 | Татар язучысы Р. Батулланың туган көне | 26 март | |
| 6 | «Сәйяр» балалар-яшүсмерләр | Бер ай эчендә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | театрларының муниципаль конкурсында катнашу | | |
| 7 | Яраткан татар әкиятләрен драматизацияләү | Ай дәвамында | |
| 8 | «Акыл уеннар» - «Мин төзүче» проектын гамәлгә ашыру буенча эш | Ай дәвамында | |
| 9 | «Татар милли орнамент брошкасын ясау» | Ай дәвамында | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | «Бала шәхесен формалаштыруда туган телнең роле» ата-аналар өчен консультация | Бер ай эчендә | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | «Балалар бакчасында һәм өйдә халык бәйрәмнәре» ата-аналар өчен анкета | Бер ай эчендә | |
| 3 | Мастер - классы «Үз кулларым белән милли сумкалар» | Бер ай эчендә | |
| **Йомгаклау этабы** | | | |
| **Апрель** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | “Карга боткасы” бәйрәмен үткәрү | 16 апрель | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | Халыкара балалар китабы көне | 2 апрель | |
| 3 | Татар шагыйрәсе Йолдыз Шәрәпованың туган көне | 10 апрель | |
| 4 | “Г. Тукай Иҗаты” чарасы | 28 апрель-2 май | |
| 5 | Балалар белән Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында презентация карау | 28 апрель-2 май | |
| 6 | Г. Тукай әсәрләре буенча чит телләр буенча муниципаль фестивалендә катнашу | Бер ай эчендә | |
| 7 | “Уйный-уйный үсәбез” - татар милли уеннарын уйныйбыз | Бер ай эчендә | |
| 8 | «Акыллы уеннар» - «Манара» проектын гамәлгә ашыру буенча эш | Бер ай эчендә | |
| 9 | Полимер балчыктан ясалган татар бизәнү әйберләре | Бер ай эчендә | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | Ата-аналар һәм балаларның уртак эшләре конкурсы | 28 апрель-2 май | Педагоглар, ата-аналар |
| 2 | “Г. Тукай әкиятләренең могҗизалы дөньясы” | 28 апрель-2 май | |
| 3 | Г. Тукай иҗатына багышланган рәсемнәр, эшләнмәләр күргәзмәсе | Бер ай эчендә | |
| **Май** | | | |
| **Балалар белән эшләү** | | | |
| 1 | “Сугыш турында укыйбыз” | 5-8 май | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | акциясе | | Шәйдуллина Л. Р., мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең педагогик коллективы |
| 2 | Халыкара гаилә көне | 15 май | |
| 3 | Татар шагыйрәсе Э. Мөкминованың туган көне | 18 май | |
| 4 | Район балалар китапханәсенә, музеена, «Саба таңнары» район газетасы редакциясенә экскурсиялар | Елында | |
| 5 | Татар язучысы Бари Рәхмәтнең (1897-1957)туган көне | 29 май | |
| 6 | «Акыллы уеннар» - «Башваткыч», «Кара-кара» проектын гамәлгә ашыру эше | Бер ай эчендә | |
| 7 | Тәрбияләнүчеләрнең «Акыллы уеннар» проектының республика чемпионатында катнашуы | Май азагында | |
| **Ата-аналар белән эшләү** | | | |
| 1 | “Безнең бабаларыбыз-сугыш геройлары!” | Бер ай эчендә | Педагоглар, ата-аналар |
| 2 | “Күңелле хәрефләр” балалар китапчыклары конкурсында катнашу | 19-23 май | |
| 3 | Балаларны туган телдә укыту һәм тәрбияләү процессына җәлеп ителгән гаиләләрне ачыклау өчен мониторинг үткәрү | Бер ай эчендә | Педагоглар, ата-аналар |
| **Бер ел эчендә** | | | |
| 1 | Ата-аналарның балаларга ике дәүләт телен (УМК)өйрәтү өчен тел мохите булдыруда катнашуы | | |
| 2 | Педагогларның һәм тәрбияләнүчеләрнең төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, семинарларда катнашуы | | |
| 3 | ММЧда педагогларның материалларын, сценарийларын, конспектларын, методик эшләнмәләрен бастырып чыгару | | |
| 4 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән балаларны татар телендә тәрбияләү һәм укытуны оештыру буенча база мәйданчыгында хезмәттәшлекне дәвам итү | | |
| 5 | Социум белән хезмәттәшлекне дәвам итү | | |
| 6 | «Акыллы уеннар» проекты буенча педагоглар белән өстәл уеннары эшләү һәм Саба районы педагоглары өчен семинарларда, конференцияләрдә туган телне тәрбияләү һәм өйрәтү буенча эш тәҗрибәсен уртаклашу. | | |

## Йомгаклау

Әгәр тел өйрәнү предметы сыйфатында гына түгел, бәлки даими рәвештә, балаларның көндәлек тормышында һәм эшчәнлегендә актив кулланылса, мәктәпкәчә учреждениедә туган телләрне өйрәнү уңышлы тормышка ашырылырга мөмкин.

Әлеге проект иҗади, психологик һәм тәрбия мәсьәләләрен хәл итәргә генә түгел, ә һәр баланың шәхесен үстерүгә, анда максатчанлык, индивидуальлек һәм инициативалылык

тәрбияләүгә дә ярдәм итәчәк. Проект эше тәрбия-белем бирү процессында кирәк, чөнки бу мөмкинлек бирәчәк:

- һәр бала өчен индивидуальләштерүне тәэмин итәргә;
- шәхеснең үзбилгеләнүе һәм үз-үзен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;
- баланың эшчәнлекне, фикерләрне һәм фикер йөртүләрне ирекле сайлап алу хокукын гамәлгә ашыру.

Проект өстендә эшләү нәтиҗәсендә балалар Татарстан турында, татар халкының гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте турында күзаллауларын ныгыта алачак. Милләт, гореф-гадәтләр, һәйкәлләр, архитектура, шагыйрьләр, рәссамнар төшенчәләре белән танышачак. Шулай ук проект барышында ата-аналарның һәм балаларның иҗади һәм тикшеренү сәләтләрен үстерергә ярдәм итәчәк. Балалар мәгълүмат эзләү һәм җыю, үз эшләрен анализлау һәм тәкъдир итү күнекмәләрен үзләштерә алачак. Болар барысы да патриотизм рухында тәрбияләүгә, район тарихына һәм мәдәниятенә тартылуга, туган як турында белемнәрне системалаштыруга, кече Ватанга мәхәббәт һәм мәхәббәт тәрбияләүгә ярдәм итә.

Әлеге проект педагогларга балаларның таркаулыгы һәм милләтләргә бүленү проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк. Балалар татар милләтен һәм мәдәни үзенчәлекләрен белә алачак.

Проектның гамәли әһәмияте шунда ки, аны теләсә кайсы иҗади педагог үз эшендә куллана ала, аның эчтәлеген үзенең мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе шартларына һәм социум белән үзара хезмәттәшлек итү мөмкинлекләренә яраклаштыра.

Шулай итеп, билгеле бер шартлар тудырганда һәм эшнең төрле формаларын һәм методларын кулланганда, шулай ук проектка кызыксынган өлкәннәрне: педагогларны һәм ата-аналарны керткәндә, балаларга гаилә, Ватан, аларның гореф-гадәтләре һәм гореф-гадәтләре турында гади белемнәрне үзләштерү мөмкинлеге бар дип әйтергә мөмкин.

## “ Татар халкының декоратив- кулланма сәнгате: һөнәрчелек һәм иҗат”

***Галиуллина Алсу Мөнир кызы***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*“Чыршы «Салават купере” балалар бакчасы мәктәпкәчә*
*белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе”*

### 1. Кереш

**1.1.Теманың актуальлеге:** Профориентация - иҗтимагый проблемаларның берсе, чөнки ул җәмгыять торышының күрсәткечләренә, хезмәт базары үсешенә, халыкны эш белән тәэмин итүгә, талантларны ачыклау һәм аларга дөрес юнәлеш бирү өлкәсенә нык бәйле.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны һөнәрләр белән таныштыруда балалар бакчасы беренче һәм төп баскычта тора, чөнки бакчада балалар әйләнә-тирә дөнья белән танышып дөньяга карашларын тирәнтен киңәйтәләр, беренчел тәҗрибә туплыйлар, яшьтән һөнәри юнәлеш алалар. Мәктәпкәчә белем бирү Федераль Дәүләт Мәгариф учреждениесендә "Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы", Р.К.Шаехова программасында татар халкының мәдәниятенә, гореф –гадәтенә кызыксыну уяту, декоратив – кулланма сәнгате белән балаларны таныштыруның зарурлыгы ачык күрсәтелгән. Бу төр эш чорында балаларның хезмәт күнекмәләре формалаша, төрле һөнәр ияләренә ихтирамнары арта, әйләнә-тирә турында белемнәре киңәя. Болар барысы да баланың төгәл бер һөнәргә кызыксынучанлыгын һәм һәвәслеген ачыкларга ярдәм итә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар барыннан да бигрәк уйнарга яраталар.Уен-баланың төп эшчәнлеге. Әйләнә-тирәдә һәм өлкәннәр эшчәнлегендә күргәннәре балаларның уеннарында чагыла. Уен- тормыш чагылышы. Күпчелек уеннар төрле һөнәр ияләренең хезмәтенә багышланган, шуңа күрә яшьтән һөнәри юнәлеш бирү эшен уен аша оештыру мөһим. Бала яшьтән һәр һөнәр кешесен ихтирам итә белергә, һәр һөнәри хезмәт шатлык китерүен, башкаларга файдалы булуын аңларга тиеш. Татар халкы бай гореф-гадәтләрен, милли мәдәниятен гасырлар буе саклап килгән. Бала шушы бай милли мохиттә татар халкы мәдәни традицияләре, үзенә генә хас булган декоратив-кулланма сәнгате белән танышып, шул җәмгыятьтә тәрбияләнеп, төрле юнәлештә үсә. Кече яшьтән үк бала үзенең мили мохитендә яши, "ана сөте" белән үзенә милли байлык һәм әхлакый тәрбия ала. Үсә төшкәч, бала үз халкының гореф-гадәтләрен, декоратив-кулланма сәнгатен саклаучы һәм йөртүчегә әверелә. Безнең Татарстаныбызда бик күп Идел буе халыклары яши: татарлар, руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар, башкортлар, мордвалар һ.б.

Балалар бакчасында һәрбер бала үз милләтенең шәхесе. Үз халкының милли мәдәниятен, һөнәрләрен белгән һәм хөрмәт иткән бала гына башка милләт вәкилләренең гореф-гадәтләрен өйрәнә һәм аңлый ала. Безнең бурыч – һәр сабыйны үз милләте, декоратив-кулланма сәнгате белән горурланучы һәм шул ук вакытта башка милләт кешесен, аның тарихын, мәдәниятен хөрмәт итүче шәхес итеп тәрбияләү . Декоратив-кулланма сәнгать аерым халыкның байлыгы гына түгел, ул гомумкешелек хәзинәсенең бер өлеше. Тәрбияченең бурычы – үткән буыннардан туплаган һөнәрләрне, рухи байлыкны саклап, баетып, аның иң кыйммәтле дип табылган үрнәкләрен балаларга җиткерү. Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның декоратив-кулланма сәнгатенә, милли мәдәниятенә якынайтып, аларда үзаң формалаштыру.

Кызганычка каршы, хәзерге тиз үзгәрүчән чорда әби-бабайлардан калган һөнәрләрнең югалу очраклары күзәтелә, яисә бала ул һөнәрләр турында бөтенләй дә белми дисәң була. Татар халкының декоратив-кулланма сәнгатенә кызыксыну мәдәни традицияләргә хөрмәт

кенә түгел, ә аларны саклауга омтылыш. Алда әйтелгәннәрне истә тотып, балаларга татар халкының бай гореф-гадәтләрен, милли мәдәниятен һәм сәнгатен өйрәтү максатыннан “Татар халкының декоратив - кулланма сәнгате: һөнәрчелек һәм иҗат” дигән проект эшләргә мөмкин.

**1.2.Проектның яңалыгы.**

Инновацион эшчәнлекнең традицион аермасы-тәрбияче ролен остаз түгел, ә процессның партнеры итеп башкара һәм «янәшәдә түгел, ә бергә»торышын тота. Шулай итеп, бала күбрәк ирек тоя, бу күбрәк иҗади активлыкка этәрә. Шулай ук белем тәрбияләнүчегә элеккечә үк әзер түгел, ә үзенең тикшеренү эшчәнлеге барышында үзенә табыла.

Инновацион эшчәнлекне гамәлгә ашыруга балалар бакчасы педагогы алдында түбәндәге бурычлар куела: тәрбияләнүчеләрнең индивидуальлеген үстерү; балаларның инициативасын, мөстәкыйльлеген, иҗади белдерү сәләтен үстерү; тикшеренү эшчәнлегенә кызыксынуны арттыру; тәрбияләнүчеләрнең төрле активлыгын стимуллаштыру (уен, танып белү һ. б.); балаларның интеллектуаль дәрәҗәсен күтәрү; иҗат һәм уйлау сәләтен үстерү.

**1.3. Максат:** һәр баланы үз милләте белән горурланучы һәм шул ук вакытта башка милләт кешесен, аның тарихын, мәдәниятен хөрмәт итүче шәхес итеп тәрбияләү.

**1.4. Бурычлар:**

1. Эш өчен уңай шартлар тудыру.

2.Татар халкының декоратив-кулланма сәнгать үрнәкләре белән таныштыру.

3.Әби-бабаларыбыз иҗат иткән әйберләргә хөрмәт тәрбияләү.

4. Төп мәдәният нигезләрен формалаштыру, татар халык иҗатына,Татарстан тарихына игътибарны арттыру.

5.Татар халкының рухи традицияләренә якынаю һәм милли үзаң формалаштыру.

6.Татар халкының гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияләү.

**1.5. Проектта катнашучылар:** 3-7 яшьтәге төркем балалары, аларның әти-әниләре, тәрбияче, бакча мөдире, кече тәрбияче.

**1.6. Проектның дәвамлылыгы:** дәвамлы проект ( 5 айга кадәр).

**1.7. Проект төре:** иҗади эзләнү проекты.

**1.8. Үткәрү урыны:** балалар бакчасы.

**2. Проектны тормышка ашыру юллары:**

**I этап – әзерлек:** тема сайлау, эш планы төзү, проектны тормышка ашыру схемасын ясау, методик әдәбият сайлау.

**II этап – төп өлеш:** тәрбия һәм белем бирү процессына милләтара мөнәсәбәтләрне үстерүгә ярдәм итүче нәтиҗәле методик алымнар кертү.

**III этап – йомгаклау:** нәтиҗә ясау.

**2.1 . Проектны башкару өчен кулланыла торган методик алымнар:**

- әңгәмә;
- әдәби әсәрләр уку;
- музейга экскурсия оештыру;
- балаларның иҗади эшчәнлеге( әвәләү, рәсем ясау, кисеп ябыштыру, театр эшчәнлеге, бию, музыка, халык уенары һ.б.)

**2.2. Көтелгән нәтиҗәләр:**

**1.** Бу проект үзенең милли тамырларын истә тотучы, гореф-гадәтләрен саклаучы, хәзерге тормышта үз урынын табып, татар халкының гореф гадәтләрен, һәм мәдәниятен хөрмәт итүче шәхес тәрбияләргә мөмкинлек бирү.

**2.** Балаларны татар халкының мәдәният хәзинәләре, әдәбияты, көнкүреше белән таныштыру.

**3.** Балаларга халык әкиятләре, әдәби әсәрләр аша татар халкының тугандаш икәненә төшендерү.

**4.** Өлкәннәр белән бердәм эшчәнлектән шатлану һәм канәгатьләнү хисләрен тою.

3. **Проект эшчәнлегенең перспектив тематик планы:**

**I этап – әзерлек:** тема сайлау, эш планы төзү, проектны тормышка ашыру схемасын яисә технологик карта ясау, методик әдәбият сайлау.

| № | Эшчәнлек тәртибе | Тәрбияче белән балаларның бердәм эшчәнлеге | Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге | Әти-әниләрнең һәм баланың эшчәнлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Методик материаллар туплау. | Балаларны татар декоратив-кулланма сәнгате белән таныштыру. | Татар орнаментлары белән таныштыру. | Әдәби китаплар җыю. |
| 2. | Ата-аналарга консультация. | Ата-аналарга “Татар халкының декоратив-кулланма сәнгате: һөнәрчелек һәм иҗат” исемле проект турында белдерү бирү, проектның максатын һәм бурычларын аңлату. | Татар халкының декоратив-кулланма сәнгате турында видеоматериал карау, дидактик уеннар уйнау. | “Татар халкының декоратив-кулланма сәнгате бүгенге көндә актульме?” дигән анкета үткәрү. |
| 3. | Тәрбиячеләргә консультация. | Татар халкының декоратив-кулланма сәнгате турында материаллар туплау, | Тыңлаган яки видеодан караган әкиятләр буенча рәсем ясау. | Татар халкының гореф-гадәтләре, декоратив-кулланма |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | балалар белән әкиятләр уку(“Һөнәрле үлмәс” Татар халык әкияте, “Ике ялкау”, “ Алтын бөртекләр”Татар халык әкияте), видео карау, рәсемнәр ясау. | | сәнгате, бәйрәмнәре турында әңгәмә үткәрү(“Һөнәрле халкым”), әкиятләрен өйдә уку яки тыңлау. |

**II этап – төп өлеш:** тәрбия һәм белем бирү процессына декоратив-гамәли сәнгатен үстерүгә ярдәм итүче нәтиҗәле методик алымнар кертү.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Газета чыгару: “Татар халкының декоратив-кулланма сәнгате.” | Татар халкының һөнәрләре турында шигырьләр(“Нәни ташчылар” Зәкия Туфайлова, “Әтидән өйрәндем” Галимҗан Латыйп, “Эшкә өндәү” Габдулла Тукай, Резедә Вәлиева “Калфак”), җырлар эзләп табу һәм аларны балалар белән өйрәнү. | Милли татар орнаментлары д/уенын уйнау. Рәсем. Алъяпкычка, кулъяулыкка милли бизәк төшерү. | Газета өчен материалалр җыю. |
| 2. | Татар халкының әкиятләренең этноколекция сенә сәяхәт. | Балалар белән әкиятләр сәхнәләштерү, милли костюм элементларын рәсемгә төшерү, такмаклар, табышмаклар ятлау. | Әкиятләр сөйләү, табышмаклар чишү, җырлар җырлау, уеннар уйнау(“Һөнәрле халкым”, “Көмешче”) | “Тылсымлы сандык“ ярдәмендә “Өч кыз” әкиятен сәхнәләштерү. |
| 3. | Татар халкының сәнгате: күптөрлелек һәм иҗат | Татар халкының милли бизәкләре турында әңгәмә үткәрү. | Милли бизәкләр белән кисеп ябыштырып киемнәр бизәү(Кулъяулыкка милли бизәк төшерү). | “Халкыбызның милли бизәкләре-кулъяулык эшләү” мастер-класс (әниләр, дәү әниләр белән) |
| 4. | Гадәтләр һәм йолалар: миллилекне саклау. | Татар халкының милли бәйрәмнәре турында әңгәмә үткәрү. | Татар халык уеннарын уйнау, рәсемнәр карау. (“Түбәтәй, “Без, без, без идек...”, “Йөзек салыш”). | Кыш озату яз каршылау (Нәүрүз)бәйрә-мен үткәрү. |
| 5. | “ Без бер гаилә | Толерантлык, башка | Идел буе | «Бердәм Идел буе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | булып яшибез". | милләт халыкларына, аларның традицияләренә карата хөрмәт хисе формалаштыру. | халыкларының милли уеннарын уйнау.( "Казык" уены, "Карапка" уены," Караван" биюе) | халыклары» дип аталган бәйрәм кичәсе оештыру. |
| 6. | Иҗади эшләр. | Балаларның иҗади фантазияләрен үстерү, төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашу. | Үстерелешле һәм халык уеннарын уйнау, музыка тыңлау, биюләр өйрәнү. | Халык уеннары картотекасын әзерләү. Конкурсларда катнашуда ярдәм тү. |

**4. Йомгаклау:** нәтиҗә ясау.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Педагогик киңәшмәдә проектны презентацияләү | "Татар халкының декоратив-кулланма сәнгате:һөнәрчелек һәм иҗат"проектына нәтиҗә ясау, йомгаклау. | Дипломнар тапшыру. | Рәхмәт хатлары тапшыру. |

**Милли киемнәр**

***Газизова Дамира Мәхмүт кызы,***

*Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы*
*"Тургай" катнаш төрдәге Красносельский балалар бакчасы"*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе*

•Максат:

Балаларда матурлыкны күрә беләргә һәм милли киемнәргә карата горурлык хисе тәрбияләүгә ирешү.

•Бурычлар:

1. Балаларда татар милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренә кызыксыну тәрбияләү.

2. Бәйләнешле фикерләү сәләтен үстерү, сөйләмдә парлы, кушма, ясалма сүзләр куллану күнекмәләре бирү.

3. Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә куллануны системалаштыру.

Проектны үткәрү тәртибе

•1 өлеш-әзерлек

Балалар һәм эти-әниләр белән максат һәм бурычлар турында фикер алышу, дидактик уеннар, материаллар җыю, проектның планын төзү;

•2 өлеш-төп

Милли киемнәр турында фотолар карау, дидактик уеннар, рәсемнәр ясау, “Милли бизәкне җый” уены уйнау, “Милли баш киемен бизәү” уены, “Алъяпкыч” бизәү уены, фотоларга төшү, табышмаклар әйтешү.

•3 өлеш-йомгаклау

Әти-әниләр һәм балалар белән милли киемнәрнен нәфис бизәлешенә соклану уяту.

Балалар белән эш:

- “Милли баш киемен бизәү”
- Шаблон буенча алъяпкыч рәсемен ясау һәм бизәү
- Телебездәге әдәпле сүзләрне истә калдыру
- Татлы тел тимер - капканы ачар…
- Тел-күңелнең көзгесе…
- Табышмаклар әйтешү
- “Әкият геройларын җыю” уены
- “Милли бизәкләр җыю” уены
- Белем-нур, белмәү-хур…

Әти-әниләр белән эш:

- “Бишек җырлары”
- “Бала тәрбияләүдә халык фольклоры”
- “Милли киемнәр көне”

**ЭЧТӘЛЕК**

1. Шәвәлиева Г.М. “Бал бәйрәме – татлы бәйрәм!”..........................................................6
2. Мөхәммәтшина Д.Ф. “Печән өсте бәйрәме”.................................................................11
3. Шәфигуллина Ә. М. “Йомырка җыю бәйрәме – керәшен һәм татар авыллары дуслыгы...................................................................................................................18
4. Гарифуллина Р.Х. “Сандык җилләтү” йоласы..............................................................24
5. Хәкимова Г.Р., Хисмәтуллина А. Ә., Камалиева Г.Р. “ Мендәр тутыру йоласы”.................................................................................................................28
6. Сәләхова Г. М. “Мич котлау йоласы”...........................................................................33
7. Галимуллина В.И. Борынгыдан килгән йола - татарның каз өмәсе........................... 38
8. Бариева З.Р. “Солдатка озату ” йоласы........................................................................42
9. Солтанова Р.Ә. “Телләр төрле – теләкләр бер”............................................................45
10. Минневәлиева Э.М. “ Алтыда кермәгәнне – алтмышта кермәс”.................................51
11. Хисаметдинова Г.А. “Кызыл йомырка” бәйрәме ......................................................... 56
12. Галиева А.Р. “Сабаларда эчәр суым”.............................................................................61
13. Гәрәева М.М. “ Хуш киләсең, Нәүрүзбикә”...................................................................65
14. Абдреева Г.Ф. “Каз өмәсе” ............................................................................................ 71
15. Җәләлова А.Ә. “Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз!”..............................................................73
16. Шакирова Г.М. “Каурый бәйрәме” ...............................................................................76
17. Ибраһимова Л.Г. “Су буенда кичке уен” ......................................................................78
18. Сәйфуллина Г.Р. “Туган телем – саекмас чишмә” .......................................................82
19. Мостафина Р.С. “ Хәтер сандыгы” ...............................................................................89
20. Гыйлметдинова Н.З. “Карга боткасы” ...........................................................................93
21. Гыйләҗиева А.В. “Орчык бәйрәме” ...............................................................................96
22. Нуретдинова З.С. “Кич утыру”...................................................................................... 98
23. Җиһаншина Ч.Ф. “ Әбидә кунакта” ..............................................................................101
24. Бәзгетдинова Г.Р. “Яшәгез, чишмәләр” .......................................................................103
25. Хөсәенова Р.Н. “Исем – күңел көзгесе” .......................................................................108
26. Сәмигуллина Г.М. “ Татарстан дуслык иле, һәрбер милләт аның теле” ..................112
27. Гарифуллина Р.Г. “Сабан туе – милләтебезнең иң матур бәйрәме” .........................119
28. Шакирова Р.М. “ Каз канаты кайрый- каурый” ...........................................................123
29. Рәхмәтуллина Р.Н. “ Безнең күңелле Сабантуй” .........................................................126
30. Бариева Г.Ф. “Каурый, каз өмәсе” ................................................................................128

31. Мөхтәрова Л.Х. “ Аулак өй “ ........................................................................131
32. Сәгыйтова Г.Ф. “ Бишек җырлары” ...........................................................134
33. Сәлимова Л.К. “Яңгыр теләү” йоласы ......................................................137
34. Билалова Г.Г. “ Дәү әнигә Сабантуйга кунакка” .......................................140
35. Галимуллина Г.Р. “Солдатка озату” ........................................................144
36. Хөсәенова Г.Х. “Нәүрүз, мөбарәк булсын!”..............................................147
37. Хәлиуллина Ә.Ф. “Каз өмәсе” ...................................................................152
38. Зиннәтова Г.Б. “Яңа йортны котлау” йоласы............................................156
39. Гафурова З.С. “Кичке аш вакыты күренеше” .............................................160
40. Диярова Г.М. “Ат тоягы кыздыру” йоласы..................................................162
41. Гарифуллина Г.Ф. “Бишек җыры” бәйрәме..................................................163
42. Шәмсемөхәммәтова Г.И. “Нәүрүз мөбарәк булсын!”...................................166
43. Исламова А.И. “ Каз өмәсе”.........................................................................169
44. Сафиуллина А.Ф. “Сөмбелә” бәйрәме.........................................................172
45. Газимова Р.Р. “ Каз өмәсе” .........................................................................175
46. Уваева А.Д.”Орчык өмәсе” .........................................................................179
47. Камалетдинова Г.Х. “ Зәлидә” уены...........................................................182
48. Рәхмәтуллина Г.И. “Кыз сорау” гореф – гадәте ..........................................184
49. Хәмитова Л.С. “ Орчык өмәсе” ..................................................................187
50. Гыйльметдинова Г.Р. “Самавыр агарту йоласы” ...................................... 190
51. Рәхимова Г.Р. “ Боз озату” йоласы ........................................................... 194
52. Минһаҗева Г.Р. “Ястык кою” йоласы ........................................................198
53. Әминова Л.Р. “Атнакич” бәйрәме ............................................................. 202
54. Гайфуллина Л.Ф. “Каз өмәсе” ....................................................................207
55. Галиәхмәтова Г.Ф. “Бишек җырлары – әнием моңнары” ......................... 212
56. Хаҗиева А.Р. “Каурый өмәсе” .................................................................. 217
57. Кәримуллина Г.С. “Йомырка җыю “ бәйрәме.............................................220
58. Фәррәхова Л.Ә. “Капка төбендә” ...............................................................222
59. Ибнеева Р.Р. “ Әбидә кунакта”(Каз өмәсе).................................................230
60. Мирзина Э.М. “ Мунчала чыгару” йоласы...................................................235
61. Гатауллина Л.Р. “Карга боткасы” ..............................................................239
62. Вахитова Д.Н. “Аулак өй” ..........................................................................245
63. Зиннәтуллина З.Х. “Бәби алып кайту” йоласы ..........................................252
64. Егорова Г.А. “Әбиемнең серле сандыгы” ..................................................257
65. Бәйрәмова Т.Х. “Беренче буразна бәйрәме” ...............................................261

66. Бадертдинова Р.Р. “Карга боткасы” бәйрәме..........................................................263
67. Захарова Р.Н. “Нигез боткасы” йоласы ........................................................................270
68. Шәри пҗанова Р.З. “Миллек бәйләү” йоласы...............................................................272
69. Хафизова Ф.Ф. “Җимчәчәк” бәйрәме ............................................................................276
70. Хәлилова Э.Ш. “Сабый туды җиргә”.............................................................................280
71. Шәрифуллина А.М. “ Татар дөньясы” китабы эзләреннән........................................285
72. Исрафилова Р.М. “ Каз өмәсе”.......................................................................................289
73. Антонова А.Ф. “Безнең аулак өйдә” .............................................................................295
74. Гайфиева Г.Т. “Бирнә җыю” ..........................................................................................299
75. Дәминова Я.М. “Сөрән җыю” .......................................................................................302
76. Шәйдуллина Л.Р. “Җеп эрлибез бергәләп” .................................................................308
77. Гыйләҗетдинова Л.М. “Сөннәт боткасы” ...................................................................312
78. Шәрипова М.И. “Аулак өй” ........ ..................................................................................315
79. Әхмәтшина А.Х. “Кунаклашу” ......................................................................................321
80. Нургалиева Г.И. “Бирнә җыю” ......................................................................................326
81. Хәбибуллина Р.И., Әхсәдуллина А.Г. “Татар халкы кунакчыл халык” .................. 330
82. Хисамиева Л.И. “Хәрби хезмәткә озату” .................................................................... 335
83. Гыйлфанова Л.К. “Карга боткасы” ...............................................................................337
84. Шакирова Э.И. “Капка төбендә” .................................................................................. 341
85. Шәмсиева Л.Г. “Аулак өй” ............................................................................................343
86. Сабирҗанова Л.Р. “ Карга боткасы” .............................................................................347
87. Бәшәрова Л.Х. “Сабантуй” .............................................................................................351
88. Хөсәинова Р.Р. “Сабантуй” ............................................................................................356
89. Яруллина А.А. “Аулак өй” .............................................................................................359
90. Мөһәммәдиева Э.Р., Сәйфетдинова Г.З. “ Аулак өй” ..................................................363
91. Бурнашева А.М. “Карга боткасы” .................................................................................368
92. Гыйльманова Ә.Г. “Читекчеләр данын югалтмыйк”...................................................372
93. Хаммадова Л.Я. Гаиләм – иң зур терәгем.....................................................................377
94. Әхәтова Р.К., Мәрдәнова Ә.Р. “Аулак өй”....................................................................384
95. Искәндәрова В.В. “Уйнат тальян гармуныңны” ..........................................................390
96. Галимова Л.Ф. “Боз озату” ............................................................................................394
97. Ганиева Г.Х. “Чәк – чәк бәйрәме” ..................................................................................401
98. Гарифуллина Л.Д. “Орчык өмәсе” ...............................................................................405
99. Гайнетдинова М.А. “Солдатны озату” йоласы ............................................................409
100. Хәкимова Г.М., Вәлиева З.Җ. “Кунак каршылау” йоласы ............................412

101. Гыйләҗиева Э.Р. “Әкият илендә” ....................................................................419
102. Гыйльметдинова Ә.Г. “Эх, Арча читекләре” .................................................. 422
103. Әхмәтханова Г.К. “Гаиләм кыйммәтләрен эзләп” ..........................................425
104. Нигмәтуллина З.Г., Вәлиева А.Г. “Урманга сәяхәт” .................................... 431
105. Рамазанова Л.Ф. “Кышкы урманга куянга кунакка” ......................................436
106. Яруллина А.Р. “Тылсымлы илгә ярдәм итик” ............................................... 440
107. Шәймәрданова Л.М. “Остаханәдә кунакта” ....................................................445
108. Нәҗипова Г.И. “Серле кыш” ........................................................................... 449
109. Йосыпова Г.Ф. “Уйный- уйный өйрәнәбез...”................................................. 454
110. Камалиева Г.Р. “Күчтәнәчтә кунакта”.............................................................456
111. Минһаҗева М.Б. “Җиңү көтә бүген, сабыйлар”.............................................460
112. Зиннәтова А.Г. “Минем милләтем” ................................................................463
113. Хөснуллина М.Ә. “Г.Тукай әсәрләре буенча уен – йөреш” ..........................464
114. Сабирова Л.Н., Сабирова Р.Ә. “Гаиләм хәзинәсе”..........................................465
115. Шәйхиева Р.Р. Серле тартма “Минем шәҗәрәм”.......................................... 478
116. Фәйзрахманова Г.В.”Милли хәзинәләр” ..........................................................482
117. Сәйфелганиева М.А. “ Г.Тукай әсәрләрендә милләтем хәзинәсе” ................484
118. Хәбибуллина Л.Ю., Кәлимуллина Г.М. “Күпфункцияле ширма”................. 488
119. Хәсәнова Р.И. “Зирәк гаилә”.............................................................................491
120. Мөхтәрова Г.Ф. “Серле юрган” .......................................................................495
121. Мөхәммәтшина А.Ф. “Шаян кашыклар” .........................................................498
122. Гайфуллина Л.Ф. “Энәсез корамалы техникасында ләлә чәчәге ясау” ..........500
123. Закирова Р.М., Шәрәфетдинова Л.Р. “Әниемнең серле алкалары”.................503
124. Мортазина А.Р. “Милли киемле саклаучы (оберег) курчак”..........................505
125. Әхмәдуллина Л.И. “Куар – кодлар” технологиясе.......................................... 509
126. Хәбирова А.Р. “Мультфильм төшерү” ............................................................512
127. Хидиятуллина А.Н. “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтүдә предметлы тирәлекнең нәтиҗәле мөмкинлекләрен куллану”.....................................514
128. Галиәхмәтова Р.Х. “Милли белем һәм тәрбия бирүдә цифрлы технологияләрне куллану”...............................................................................................................518
129. Шәрипова Э.Г. “Татар халкының милли мирасы” ..........................................522
130. Шакирова Г.Н. «Гаиләдә һәм балалар бакчасында мәктәпкәчә яшьтәге баланың эмоциональ үсеше чарасы буларак, бишек халык традициясе»................................ 532
131. Гарипова Л.Ф., Тимериева Г.Ә.”Татар халкының мәдәнияте, гореф-гадәт, йолалары аша балаларга патриотик тәрбия бирү”......................................................536

132. Васильева И.Т. “Музей – тәрбия учагы” ........................................................540
133. Гафурова Р.А. “Милли ашлар табын түрендә”................................................546
134. Нотфуллина Л.М. “Милли хәзинәләр студиясе” ............................................549
135. Галиәскәрова Г.Ф. “Татар халык ашлары” .................................................... 561
136. Хисматуллина Л.Р., Файзуллина Г.Ф. “Халкымның күңел сандыгы”.............565
137. Зиганшина З. Р. “Балалар бакчасында рухи әхлакый тәрбия бирүдә музей педагогикасы”.............................................................................................................. 571
138. Камалиева Г.Р. “Туган җирем- бәллүр бишек” ...............................................575
139. Мингазова Р.Г. “Милли хәзинә” ......................................................................585
140. Шәйдуллина Л.Р. “Туган телем минем байлыгым”........................................ 590
141. Галиуллина А.М. “ Татар халкының декоратив- кулланма сәнгате: һөнәрчелек һәм иҗат”............................................................................................................... 600
142. Газизова Д.М. “Милли киемнәр көне” ........................................................... 605